# Казан утлары

8.1983



# КАЗАН УТЛАРЫ

1922 елның май аеннан башлап чыга

АЙЛЫК ӘДӘБИ-НӘФИС
ҺӘМ ИҖТИМАГЫЙ-
ПОЛИТИК ЖУРНАЛ

ТАТАРСТАН
ЯЗУЧЫЛАР
СОЮЗЫ ОРГАНЫ

8

1983

КПССның
ТАТАРСТАН
ӨЛКӘ
КОМИТЕТЫНЫҢ
ГАЗЕТА ҺӘМ
ЖУРНАЛЛАР
НӘШРИЯТЫ

КАЗАН


## *Бу санда*


КПСС ҮЗӘК КОМИТЕТЫНЫҢ ИЮНЬ (1983 ЕЛ) ПЛЕНУМЫ КАРАРЛАРЫН — ТОРМЫШКА!

**Н. ДӘҮЛИ. Минутларның кадерен белик!** . . . 3

**Ф. ГАЛИЕВ. Икмәк язмышы.** Игенче язмалары . 6

БЕР СОРАУГА — БЕР ҖАВАП

**Ш. РӘКЫЙПОВ** . . . . . . . . . . . . . . . 75

**Р. ХАРИС. Ат нирләү.** Поэма . . . . . . . . 76

**З. ФӘТХЕТДИНОВ. Ачылган серләр.** Маҗаралы повесть . . . . . . . . . . . . . . 82

БАЛАЛАР ӨЧЕН ШИГЫРЬЛӘР

**Р. МИНГАЛИМ. Өстәлеңә ак чәчәк.** Шигырьләр . 131

**Р. БАЙТИМЕРОВ. Сигезьюллыклар.** Шигырьләр . 135

ЛӘБИБӘ ИХСАНОВАГА 60 ЯШЬ

**Г. ШӘРӘФИ. Ихласлык** . . . . . . . . . . . 137

**Л. ИХСАНОВА. Сәгать.** Хикәя . . . . . . . . 141

ӘДӘБИ ПОСТ — АЭС

**М. ӘМИРХАНОВ. Тарихка кергән бер көн** . . . 147

«АВЫЛ ОФЫКЛАРЫ» КОНКУРСЫ

**Р. ӘХМӘТҖАНОВ. «Ишегалдым яшел чирәм»** . . 155

МӨХӘММӘТ ГАЙНУЛЛИНГА 80 ЯШЬ

**Н. ЮЗИЕВ. Өч нәсихәт** . . . . . . . . . . . 157
**М. ГАЙНУЛЛИН. Татар хатын-кыз язучылары** . . 161

БҮГЕНГЕ ПРОЗА: ГЕРОЙЛАР, ПРОБЛЕМАЛАР

**Ф. ХАТИПОВ. Сокланам һәм уйланам** . . . . 169
**Ә. ГАБИДИ. Уңышларыбызны да күләгәләмик** . 176

КУЛЬТУРАБЫЗ ТАРИХЫНА

**Ә. ЕНИКИ. Ике шагыйрь** . . . . . . . . . . 178
**К. ХӘМЗИН. Соңарган хат** . . . . . . . . . 179

СӘНГАТЬ

**Б. ГАЛИЕВ. Төсле моң** . . . . . . . . . . . 186

**Әдәбият һәм сәнгать яңалыклары** . . . . . . 189

**Тышлыктагы сурәтләр** . . . . . . . . . . . 192

*Баш редактор* **РЕНАТ ХАРИС**

**Редколлегия: ШАМИЛ БИКЧУРИН, МАНСУР ВӘЛИЕВ, РАЗИЛ ВӘЛИЕВ, АЯЗ ГЫЙЛӘҖЕВ, РӘИС ДАУТОВ, МАРСЕЛЬ ЗАРИПОВ, ЗӨЛФӘТ,** *җаваплы секретарь* **РОБЕРТ МИҢНУЛЛИН, ТУФАН МИҢНУЛЛИН, ФӘРВАЗ МИҢНУЛЛИН,** *баш редактор урынбасары* **РИНАТ МӨХӘММӘДИЕВ, ЗӘКИ НУРИ, РӘФЫЙК НӘФИКОВ, АТИЛЛА РАСИХ, СИБГАТ ХӘКИМ, НИЛ ЮЗИЕВ**

Техник редактор *Р. Сөләйманова*
Корректорлар *Ф. Кадыйрова, Г. Салихҗанова*

Адрес редакции: 420066, Казань, ул. Декабристов, 2.

**Телефоннар:** баш редактор — 53-07-60, баш редактор урынбасары — 53-07-09, җаваплы секретарь — 53-07-09, проза бүлеге — 53-07-61, поэзия бүлеге — 53-07-61, тәнкыйть бүлеге — 53-07-63, сәнгать бүлеге — 53-07-63, очерклар бүлеге — 53-07-61, хатлар бүлеге — 53-07-63, корректорлар — 53-07-65, техник редактор — 53-07-65, машинисткалар — 53-07-60.

Производствога бирелде 26.05.1983 ел. Басарга кул куелды 25.07.1983 ел. ПФ 07077. Офсет ысулы белән басыла. Кәгазь форматы 70×108 1/16. Учетн.-изд. табак 14,2. Басма табак 12(16,8). Тираж 65044. Заказ Я-227. Бәясе 90 тиен.

Типография издательства Татарского обкома КПСС.
420066, г. Казань, ул. Декабристов, 2.

© «Казан утлары», 1983 ел.

## *КПСС ҮЗӘК КОМИТЕТЫНЫҢ ИЮНЬ (1983 ЕЛ) ПЛЕНУМЫ КАРАРЛАРЫН — ТОРМЫШКА!*

**Нәби Дәүли**

# МИНУТЛАРНЫҢ КАДЕРЕН БЕЛИК!

*Гомумән, төп җитештерүче көч — ул, әлбәттә, кеше, аның хезмәт эшчәнлеге.*

(«КПСС Үзәк Комитеты Генеральный секретаре иптәш Ю. В. Андроповның Пленумда ясаган речь»ннән)

Без техника прогрессы заманында яшибез. Мондый шартлар, завод-фабрикаларда булсын, иген кырларында булсын — кешенең хезмәт җитештерүчәнлеге үсүгә китерә. Берничә генә мисалга тукталыйк. Газеталар хәбәр итүенчә, хәзер Татарстанда көн саен 200000 тоннага якын нефть, 7000000 кубометрдан артыграк газ чыгарыла, 300 ләп «КамАЗ» машинасы ясалып тора.

Димәк, хәзер эш вакытының һәр минуты бик кыйммәт, һәм ул зурлык арткannан-арта бара. Шушы хакыйкать безне иҗатка, хезмәткә, ялга бүленгән сәгатьләрнең, гомумән, гомер агышының кадерен белергә, бу хакта тирәннән уйланырга мәҗбүр итәргә тиеш. Бәхеткә каршы, соңгы вакытларда дисциплинаны ныгытуга җитди игътибар бирелә башлады.

Дөрес, дисциплина дигән сүз шактый кырыс, хәтта аяусыз яңгырый. Мин үзем аны хәрби телдә генә йөри торган термин итебрәк тәсмерлим.

Әйе, хәрби дисциплина да бар. Һәм без беләбез: армия дә — тормышыбызның бер өлеше. Солдатта да хезмәт итәләр. Шактый авыр, катлаулы эшләр башкаралар. Кыскасы, кеше хезмәте булган җирдә, дисциплинасыз — дөнья сансыз. Дисциплинадан башка солдат стройда бер адым атлый да алмый.

Ләкин кеше, солдатта гына түгел, кайда гына булса да, нинди генә эшләр кылса да, нинди генә хәрәкәт ясарга теләсә дә, барыбер ниндидер «команда»га буйсынырга тиеш. Моның да исеме — дисциплина.

Дисциплинадан башка шырпы да кабызып булмый. Хәтта, җирдә тик кенә яткан таш та билгеле бер закончалыкка буйсынган. Гомумән, бу дөньяда бары да дисциплинага нигезләнгән.

Мин кайчак биек йортка карап таң калам. Ул кинәт авар кебек. Юк, аумый, хәтта бик көчле давылда да аңа куркыныч янамый. Могҗизамы? Юк, бернинди могҗиза да юк. Бу биек корылмага проект сызучы осталар барысын да исәпкә алганнар. Йортның үз авырлыгын, нигезенең ныклыгын, төзү материалларының катылыгын сынап-тикшереп караганнар. Шулай итеп, төзүчеләр бу йортның һәрбер кирпечен дисциплинага бастырганнар. Шул тәртип саклангaнда, бу корылма йөз еллар буе төз торачак.

Кеше гомере өчен дә билгеле тәртип бар. Аның тормышы, хезмәте, иҗаты, башка закончалыклардан да аермалы буларак, аңлы дисцип-

линага нигезләнгән. Кешеләр җәмгыятьтәге вазифаларын үз көчләренә, сәләтләренә лаек итеп бүлешкәннәр.

Заводтагы конвейерны күзәтик. Әгәр шул конвейерда эшләүчеләрнең берсе үз бурычын башкармый кала икән, инде аның күршесе дә үзенә тиешле вазифаны үти алмый. Ул күршенең күршесе дә тоткарланырга мәҗбүр була. Шулай итеп гомум эш туктала.

Нәрсә килеп чыкты әле? Дисциплина бозылды. Менә нәрсә килеп чыкты! Тормышта да шулай була. Бер генә члены үз вазифасын үтәүдән баш тарта икән, яки үз эшен яртылаш-портылаш кына башкара икән, коллективта тәртипсезлек туа.

Менә шунда инде дисциплина турында сүз чыкмый хәле юк. Соңгы вакытларда бу хакта гел сөйләшәләр, гел яза торалар. Хәзер бу мәсьәлә бик күпләрне нык борчый, дулкынландыра.

Нәрсә булды? Нигә без бу мәсьәләгә яңадан кайтып төштек әле? Әллә элекке елларда бездә дисциплина юк идеме? Бар иде, әлбәттә, бар иде. Әмма заман таләпләреннән калышкан ул. Без моны бераз сизмичәрәк торганбыз. Моңа игътибарны йомшартканбыз. Эш әнә шунда.

КПСС Үзәк Комитетының 1982 елгы ноябрь Пленумында Юрий Владимирович Андропов, дисциплина турында бик борчылып, өзеп әйтте. Хуҗалыкның теләсә кайсы тармагында да эшләп чыгаруны арттыруда дисциплинаны, иң зур, иң кулай резерв, дип атады. Моңа һичбер өстәмә чыгымнар да тотасы түгел, диде.

Алга куелган планнарның вакытында, тиешле күләмдә, тиешле сыйфат белән үтәлмәүләренең сәбәбе әнә кая кереп яшеренгән. Турырак әйткәндә, эш урыннарында дисциплинаның йомшак куелышында, моңа игътибарсызлыкта. Эшнең турыдан-туры үзенә катнашмыйча, кәгазьләр белән, циркуляр, приказлар белән канәгатьләнеп калуда.

Юрий Владимирович Андроповның бу күрсәтмәләрен мин яңа ачыш белән тыңләр идем. Дөресрәге, эштә, яшәештә, промышленностьның бөтен тармакларында да — яңа алым, яңа башланыш хәрәкәткә китерепде дип әйтергә мөмкин. Моңа инде без үзебез дә турылыклы булып калырга тиешбез. Дисциплина — ул безнең ихтыярыбыздагы, үз кулыбыздагы чара.

Дисциплина турыдан-туры вакытка һәм хезмәт җитештерүчәнлегенә бәйлә.

Вакыт һәм хезмәт бер-берсе белән кул алышып яшиләр. Вакытны — хезмәт, хезмәтне вакыт белән билгелиләр. Алга куйган максатына гомере буе ирешә алмаган ялкаулар бар. Бар, бишьеллыкны ике-өч елда үтәп, хезмәт нәтиҗәсе белән исәпләгәндә, вакытны узып, икешәр-өчәр ел «алданрак яшәүче» уңганнар. Предприятиеләрдә моны, хронометраж ярдәмендә, бик төгәл исәпләп баралар. Хәер, кеше тормышы үзе дә нәкъ хронометр сыман. Ул барысын да исәптә тота. Вакыт белән безнең яшебезне сыный. Гомереңне заяга уздыргансың икән, эш тәртибен бозгансың икән, аның яман нәтиҗәсен «ялт» иттереп күрсәтә дә куя.

Без, дисциплинаны уйлап чыгармаганнар, аны тормыш үзе кушкан дип әйтеп узган идек инде. Ул «кушу» да үзлегеннән генә килеп чыкмаган. Дисциплинаның үрнәген безгә бөек табигать күрсәткән.

Билгеле булганча, безнең планетабыз ниндидер бер вакыт арасында кояш тирәсендә әйләнеп чыга. Бу чакта елның дүрт фасылы булып тора. Нәкъ үз вакытында. Бу нәрсә? Дисциплина бу! Инде җир шары үз күчәрендә бер әйләнеп кайтса, көн вә төн туа. Ягъни, бер тәүлек узган була. Бер дә кичекмичә, үз «графигын» бер дә бозмыйча. Нәкъ үз вакыты белән. Бу нәрсә? Бу — шул ук катгый тәртип, кырыс закончалык, дисциплина!

Кешеләр, шул бер тәүлектә 24 сәгать вакыт уза дип, календарьга язып куйганнар. Моны беркем дә, беркайчан да үзе теләгәнчә үзгәртә алмый. Ә бу нәрсә? Дисциплина. Телисеңме, теләмисеңме, моңа риза булып яшәргә, буйсынырга туры килә.

Әмма без, җирдәге иң алдынгы җәмгыять кешеләре, табигать законнарына буйсынудан бигрәк, әле аңлы рәвештә дә вакыт мизгелләрен файдалы эш белән үткәрергә тиешбез. Безнең җәмгыятьнең төп принцибы бар: кем эшләми, ул ашамый, дибез. Хезмәт — яшәү чыганагы, кешенең җирдә гомер итү мәгънәсе. Тәртипне боздың исә, син вакыт дисциплинасын да бозгансың булып чыга. 24 сәгатьнең кайсыдыр бер өлешен җилгә очыргансың.

Юрий Владимирович Андропов, эшчеләр белән очрашкач, вакытны тиешле рәвешчә файдалану мәсьәләсен дисциплина белән янәшә куеп сөйләгән иде.

Без моңа кадәр дә вакыт белән санаша килдек шикелле. Беләккә бәйләнгән, урам чатларына тагылган сәгатьләрдән күз алмый торган идек. Эш урыннарына да нәкъ вакытында килә идек.

Кайчак исә сизгерлекне киметкәлибез. Бер көн, ике көн эшкә бармый калу, яки кичегү гадәткә керә башлаган икән. Юрий Владимирович Андропов моны шактый кискен рәвештә искә алды.

Юк, биш-ун минутка кичегү шикелле кечкенә фактлар турында әллә ни сүз куертып, вакланырга кирәк түгелдер, бәлки, диде ул. Төп гаеп анда түгел. Сүз эш вакытыннан хуҗаларча дөрес файдалану турында барырга тиеш.

План буенча бирелгән заданиене тиешле срогында, югары сыйфат белән башкарып чыгу һәркемнең изге бурычы итеп каралсын. Эш вакытын әнә шундый аңлы дисциплинага корырга!

Аңлы дисциплинаның мәгънәсе тирән. Барысыннан да элек — намуслылык ул. Намус үз бурычыңа тугры булу белән генә, җан сафлыгы белән генә күрсәтелә. Дисциплина кешене шундый сынауга куя. Сынатырга ярамый. Без инде утлы сынаулар аша узган кешеләр. Әмма үткәндәгеләр бүгенге тормышыбызда тәртипне йомшартып җибәрү өчен башкарылмаган бит ул. Бүгенге бурычлар бездән тагын да җитдирәк мөнәсәбәт, нык дисциплина таләп итә.

Бездә беркем дә бары үз файдасы өчен генә бил бөкми. Һәр кеше үзенең тырыш хезмәте белән туган иленә, туган халкына да дан китерә. Тормышны тагын да тулырак итә, яшәүне тагын да бәхетлерәк, шатлыклырак дәрәҗәгә күтәрә.

Безнең теләкләребез моның белән генә дә чикләнми әле. Без кемнәр? Без — коммунизм төзүчеләр. Безнең киләчәк юлларыбыз өстендә шул маяк яна. Безнең тир түгеп башкарган хезмәтебез шуңа багышланган. Без үзебезнең эшләребез белән, уңышларыбыз белән дөнья халыкларына үрнәк күрсәтергә тиешбез. Безнең әле шундый изге бурычыбыз да бар. Дөнья безгә өметләнеп, ышанып карый.

Ул ышанычны без бары тик һәркайчан да, һәркайда да үзебезнең тотнаклы, аңлы, күркәм дисциплинабыз белән генә аклый алабыз. Аңлы дисциплина — илнең язмышын, шатлыгын, хәсрәтен тоеп яшәү.

Безнең язучыларга да, сәнгать әһелләренә дә олы бурыч тапшырылган. Безнең әсәрләребез, романмы ул, поэма, шигырьме, җыр, музыкамы, яки рәсемме — илебез кешеләрендә җаваплылык тәрбияләргә тиеш.

Хезмәт — кешенең рухи горурлыгы да, намусы да, бөек бурычы да. Әсәрләребездәге геройлар укучыларга әнә шул идеяләрне алып килсеннәр.

Кеше горур яңгырый, дип әйткән иде безнең олы остазыбыз Максим Горький. Вакыт агышына, хезмәткә иҗади, дисциплиналы мөнәсәбәтебез белән без горурлыгыбызга тугрылык сакларга тиешбез.

**Фәйзи Галиев,**

колхоз председателе, СССР Верховный Советы депутаты

# ИКМӘК ЯЗМЫШЫ

ИГЕНЧЕ ЯЗМАЛАРЫ



*Бу язмаларның авторы — Арча районының «Искра» колхозы председателе Фәйзи Галиев — үзенә тапшырылган колхозны 38 ел буена җитәкли. 38 ел! Авылларның сугыштан соң авыр чагын да, ачлык-корылыкны да күргән ул, инде менә кала суккандай төзек, ямьле, мул тормышлы чагын да күреп, ил язмышы — безнең язмыш дип горурланып яши. Фәйзи Әхмәт улы Галиев әлеге язмаларны, «Искра» колхозының музеена дип, яшьләр өлкәннәрнең башкарган эшеннән гыйбарәт алсын, дип әзерләгән иде. Күптәнге дуслыгыбыздан файдаланып, мин аны Фәйзи кордаштан сорап укыдым. Укый торгач, партия һәм хөкүмәтебезнең авылларны үстерү өчен никадәрле кайгыртучанлык күрсәтүен, игенченең эшенә никадәрле зур игътибар итүен, колхоз башлыгы булып эшләүнең коммунист җитәкчедән никадәрле көч, энергия, дипломатия, булдыклылык һәм җан җылысы таләп итүен күрдем. Автор, игенче-практик, шуларны эзлекле рәвештә, бер дә иренмичә, бодай көшелен бөртекләп чүпләгәндәй, җентекләп язып чыккан. Бу язмалар «Искра» колхозы яшьләренә генә түгел, республикабызның барлык колхозчыларына, барлык яшьләренә файдалы булыр дип ышанам. Икмәкне үстерүчеләр генә түгел, үстергән ипине ашаган һәркемнең күңелендә игенчегә ихтирам уяныр, алар икмәкнең бик кыйммәткә төшүен, бик авырлык белән үстерелүен аңларлар дип уйлыйм.*

*Партиябез Үзәк Комитетының 1982 елгы Май Пленумы алга куйган азык-төлек программасын үтәүдә дә бу язмаларның файдасы тияр дип ышанып калам. Менә шундый изге уйлар белән Фәйзи Галиевнең «Игенче язмалары» «Казан утлары» журналына тәкъдим ителә.*

Гариф АХУНОВ

# Багышлау



Октябрь социалистик революциясенең илле еллыгын бәйрәм иткәндә, безнең колхозның партия оешмасы, авыл советы башкарма комитеты, колхоз идарәсе «Искра» колхозының кыскача тарихын язарга дигән карар чыгардылар. Авыл укытучылары: Күнгәрдән — Гарипов Самат, Түбән Шашыдан — Әухәдиев Илдар, Югары Шашыдан — Шакиров Рубис, Күшәрдән — Фазлыев Фоат, Мөндештән — Габдрахманова Әнвәрә, Ташчишмәдән — Ситдыйгуллин Фәтхи, Мокшыдан — Әхмәтжанова Рагмилә житәкчелегендә һәм авылларның тәжрибәле кешеләре катнашында комиссияләр төзелде. Бу комиссияләр үзләренә йөкләнгән эшне намуслы рәвештә үтәделәр.

Алар соңыннан, авыллардагы жыелышларда, картлар авызыннан ишеткән һәм архив документларына нигезләнеп язылган тарих белән колхозчыларны да таныштырып чыктылар. Бу язмаларда авылларның кайчан төзелүе, нинди урынга урнашулары хакында байтак мәгълүмат тупланган. Кешеләренең ни белән шөгыльләнүе хакында да мәгълүматлар житәрлек. Алар нигездә 1940—50 елларга кадәр булган чорны эчләренә алалар иде. Колхозыбыз тарихының калган өлешен язуны идарә миңа тапшырды. Мин, шул бурычларны үтәү йөзеннән, заманында үзем алып барган язмалардан файдаланып, хәтердә сакланып калган вакыйгалар белән тулыландырып, ул тарихны язып чыктым.

Мин — язу остасы түгел, гомеремне кешеләр белән эшләүгә, халык өчен, иң кыйммәтле гәүһәрләрдән дә кыйммәтрәк булган, икмәк үстерүгә багышлаган кеше. Әнә шул икмәк һәм бәрәңге үстерүче, ит һәм сөт әзерләүче кешеләр турында язарга уйладым.

Истәлекләр яза башлау уе мине СССР Верховный Советына депутатлыкка кандидат итеп сайлаган жыелышта туды.

Залда утыручылар бик матур киенгәннәр. Минем алда гына Түбән Шашы, Күшәр авылы сыер савучылары тезелеп утыра, өсләрендә затлы пальто, башларында — мамык шәл, йөзләре алсу, карашлары якты. Шул вакытта күз алдыма авылымның үткәне килде. Ярлылык, ачлык еллары хәтеремнән узды.

Илебез утыз биш ел инде тыныч тормышта яши. Кешеләр яхшы киенәләр, әйбәт тукланалар. Шушы матур тормышны күреп өлгерми яу кырында башларын салган кешеләр дә бар бит әле. Безнең колхозның жиде авылыннан 870 кеше Бөек Ватан сугышы фронтларында кулына корал тотып сугышты, шуларның 580е бүгенге матур тормыш хакына яу кырында ятып калды. Менә мин, шул кешеләр белән бергә, иңгә-иң торып, Ватанымны фашизм коллыгыннан саклашып калган кеше, залда утыручыларга күңелемдәге уйларымны әйтергә телим.

Гомерләре буена «әти» дип әйтүдән мәхрүм булган балалар, ирен иркәли алмаган тол хатыннар, яшьли тол калган кызлар турында язасым килде. Сугыштан соң гаять зур тырышлык белән колхозыбызны алга алып чыккан кешеләр хакында да язасым килде минем.

Бу язмаларда барлык кешеләрнең дә фамилияләрен телгә алып бетереп булмас. Никадәр тырышсам да, аңа ирешүе кыен, шуңа күрә биредә язганнарны колхоз авылы кешеләре барысы да: «Бу бит минем дә башымнан үткән хәлләр, бу бит — минем дә тормышым»,— дип кабул итсен иде.

# Беренче көннәр

Мин колхоз председателе булып сайланган җыелыш 1944 елның 19 июнендә үткәрелде. Көн аяз, дөнья яшеллеккә күмелгән чак иде. Җәйнең шундый бер матур көнендә, элеккеге Әтнә районы Түбән Шашы авылы «Чулпан» колхозының гомуми җыелышы ачык һавада, мәктәп ишегалдында җыйналды. Бу мәктәп кайчандыр Зариф мулла йорты булган. Аның өч көрле өен сүтеп, өч буй итеп, өч класслы мәктәп салганнар. Мәктәп ишегалдында алты почмаклы тәбәнәк кенә мәдрәсә бинасы да торып калган. Төньяк өлешендә мулланың келәте, бер буй лапасы һәм бер буй бура абзары бар. Анда мәктәпнең утыны саклана иде. Ә ишегалдының урта бер җирендә түбәле кое бар, йорт-кура рәшәткә белән әйләндереп алынган.

Җыелыш башланганчы, кешеләр төрле почмакларда сөйләшеп утырдылар. Хатын-кызлар урамы-урамы белән, ирләр төркем-төркем үзләренә аерым киләләр, коеның кырыенда ук малайлар утыра, өч-дүрт малай агач түбәсенә үк менеп чүмәшкән, ә мин, үзебез ише үсмерләр белән, иске мәктәп нигезе буенда пәке кадаш уйный идем.

Менә шушы ишегалдында, Әтнәдән райком вәкиле булып килгән Галиәхмәтов Габдрахман тәкъдиме буенча, мине колхоз председателе итеп сайладылар. Председательлеккә берничә кешене әйтеп карадылар. Хәтеремдә — Галиев Шәңгәрәй кандидатурасы да күрсәтелде, ләкин ул авыру иде. Колхозчылар да, район вәкиле дә Галиев Фәйзине сайлыйк, ул яшь, үзе комсомолец, диделәр. Җыелышта минем кандидатураны тикшерү вакытында Гомәрова Һәдия апа: «Бик яшь шул әле, 19 яше дә тулмаган ич, ничек йөрәгегез җитә? Малайны ут эченә салмагыз!»— диде.

Район вәкиле: «Кайда ул ут? Күрсәтегез!»— дип, сүзне уенга борып, кешеләргә фикерләрен үзгәртергә ирек бирмәде, тиз генә тавышка куйды. Һәм мине колхоз председателе итеп сайладылар. Колхозның идарә составы да сайланды. Миңа кадәр эшләгән Котдусов Нуриаздан абыйны, җитәкчелек итә алмаганы өчен, председатель эшеннән бушаттылар.

Җыелыш беткәч, «Чулпан» колхозы идарәсе урнашкан йортка кердек. Райком вәкиле Галиәхмәтов, колхозда хисапчы булып эшләгән Җәләлиева Һәдиядән колхозның печате кайда икәнен сорады. Һәдия печатьне «подушка»-мендәре белән өстәл өстенә куйды. Штампны да куйды. Печать — мендәр өстендә, штамп — капкачы янында тырпаеп тора иде, болар минем хәтеремдә әле дә сакланалар.

— Менә шулай, Галиев, печәтең булды, калганын үзең кара,— дип район вәкиле чыгып китте. Мин озата чыктым. Заһитов Сабирҗан абзый ат җигеп идарә алдына килеп туктаган иде. Галиәхмәтов ат өстендәге ыңгырчакның үз урынында түгеллеген күреп алды. Усал гына әйтте:

— Нишләп ыңгырчак үз урынында түгел?

Сабирҗан абзый шаян кеше иде:

— Барлык кешеләр ыңгырчакны бер урынга куялар, ә менә мин ул гадәтне үзгәртергә уйладым,— диде. Аның шаянлыгы Галиәхмәтовка ошамады. Район вәкиле атны барып карады да, ыңгырчак булырга тиешле урында атның сырты чиләнгән икәнне күреп, Сабирҗан абзыйны бик каты орышты.

— Колхозны атсыз калдырырга уйлагансың,— диде. Шуның белән сүзне фронтка озатыла торган икмәккә үк китереп бәйләде.

Район вәкилләренең кайберләре ул заманда үзләренә ошамаган җавап ишетсәләр, сине «Гитлер тегермәненә су коючы» дигән сүзләр

белән тиргиләр иде. Бу очракта да шулай килеп чыкты. Кулына чыбыркы тоткан, башына, җәй булса да, бүрек кигән, чалбарының тез башлары берничә кат ямалган Сабирҗан абзыйны мин бик кызгандым. Ул Аки Тае кушаматлы туры ат җиккән, аты уртача гына көрлектә иде. Ул вакытта атлар үлән ашап бераз хәл алган иде инде. Арбасы агач күчәрле, көпчәкләрен, күчәрләрен нарат сагызыннан кайнаткан деге белән майлаган. Арбаның арт күчәрләре арба астына куелган тарткыга юкә бау белән ике яктан да тарттырып куелган, алгы тәҗләре дә юкәдән иде. Камыт бавының да бер ягы гына каеш, икенче ягы мунчала, аркалык-түшлеккә дә каеш эләкмәгән.

Колхоз председателе булып сайлангач күргән ат дирбиялары күңелемдә шулай сакланып калган.

Район вәкиле тарантасына утырып колхоз идарәсе яныннан кузгалып китте. Мин аны болындагы туры юлдан озатып җибәрдем. Ул юлдагы суларга батмасын өчен Ашыт суын ничек кичәргә, кай урыннан чыгарга кирәген аңлаттым. Күшәр болынындагы чыбыклы күпер суын да исенә төшердем. Әтнә урта мәктәбендә укыган елларны бу суның кайсы тугаеннан чыгарга икәнен без белеп бетергән идек инде.

Шулай итеп, мин Миңлебай атлы кешенең капка төбендә япа-ялгызым торып калдым. Сабирҗан абзый да, атын кузгатып, әкрен генә китеп барды.

Кәнсәләрдә мине өстәлгә хисапчы Һәдия куйган печать белән штамп көтеп тора иде. Һәдиягә бу әйберләрне алып куярга куштым, ул аларны алып, фанер ишекле шкафка бикләде.

Идарәдә хисапчы кыз Һәдия белән секретарь кыз Әхмәтҗанова Мәгъмүрә эшлиләр иде. Мин кереп утыру белән алар икесе дә көндезге ашка кайтып киттеләр. Мин, алар киткәч, уйга калып утырдым. Сабирҗан абзый белән район вәкиле Галиәхмәтов арасында булган хәл мине аеруча нык уйланырга мәҗбүр итте. Чөнки мин Сабирҗан абзыйны, бер авылда яшәгәнлектән, күбрәк беләм. Район вәкиленең Сабирҗан абзыйга карата хәтерен калдырырлык сүзләр әйтүе, ул кешенең аны белмәвеннән килеп чыкты дигән фикергә килдем. Әгәр Сабирҗанның колхозда ничек тырышып эшләгәнен, аның үз колхозы өчен күпме файда китергәнлеген белсә, Галиәхмәтов аны, мөгаен, алай рәнҗетмәс иде. Чыннан да, соңыннан күрдем: Галиәхмәтов — районда җир эшләре мөдире иде — дорфа кеше булып чыкмады. Минем эшләремә дә күп ярдәм итте. Шул вакытта минем күңелемә: кешене белеп бетермичә, аның кемлеген ачыкламыйча, син күргән вакыттагы гына кимчелегенә карап, аны җәзаларга яки эшләгән эше өчен беренче күрүдә үк мактамаска дигән уй килде. Киләчәктә, халык белән эшләгәндә, сак эш итәргә дигән фикер уянды. Ә Сабирҗан абзый мисалында ул нәкъ шулай иде дә. Атка камыт яки ыңгырчак сугуда ул гына гаепле түгел. Ат ябыкса, аңа һәрвакыт камыт, ыңгырчак тия торган була. Ә атларга ашатырга юк, он эләкмәгән, кыш көне печән дә салам гына ашап торганнар. Алар әле яшел үләнгә чыккач кына бераз тернәкләнгәннәр. Көн саен җигелгән атның җәрәхәте исә тиз генә төзәлми. Ул атны бераз гына эштән бушатып, бер атна гына ял иттерсәң дә, төзәлгән булыр иде. Ә колхозда нибарысы 16 баш ат калган, аларга ял бирү мөмкинлеге юк. Гадәттән тыш күп файдаланганга, атлар шундый хәлгә төшкәннәр.

Ул көнне миндә туган икенче фикер — атларны ничек итеп булса да аякка бастырырга, аларның дирбияларын тәртипкә китерергә дигән фикер иде. Кәнсәләрдә озак кына утырып, өйгә кайтырга чыккач, янадан Сабирҗан абзый белән очраштык. Ул арбасын үз йортына туарган да, атны абзарына төшереп, йөгәнен тотып өенә кайтып килә иде. Минем белән очрашкач, Сабирҗан абзый хәлләрен сөйләп китте:

— Син белдеңме, бу кеше мине бик рәнҗетте, бик авыр сүзләр әйтте, сине төрмәгә утыртам дип үк куркытты түгелме, ул нишләр икән инде?— диде. Аның күзләренә ихтыярсыз яшь бәреп чыкты.

Мин, Сабирҗан абзыйны тынычландырырга тырышып, ягымлы сүзләр әйттем. Ләкин ул һаман да тынычланып җитмәде.

— Син, энем, беләсеңме, минем бит бүген әле ашамаган. Иртән бер литр сөт эчеп эшкә чыктым, ашарыма юк. Бераз бәрәңгебез бар иде, аны көндез пешерәбез, кичен яңадан бәрәңге белән ат кузгалагы салган сөтле аш эчәбез. Әле ярый безнең сыер бар, үләнгә чыккач, сөте яхшырып китте. Ә менә Сәләх Әминәсе дүрт баласы белән ач утыра, үзе йөргәндә, балаларын ат кузгалагы җыеп, аш пешереп ашата иде, ике көн инде — чыга да алмый. Безнең Майтап, хатынны әйтәм, бераз сөт кертқән иде, балалары сөйләшә алмыйлар, урын өстендә яталар, диде...

Бу сүзләр миндә өченче фикерне уятты. Бүген үк авылда ач ятучыларның исемлеген булдырырга, аларны туклandыру чарасына керешергә кирәк.

Сабирҗан абзый, күз яшьләрен сөртә-сөртә, өенә кайтып китте. Мин үзебезгә таба юнәлдем. Юлда кайтканда Сабирҗан абзыйның тормышы күз алдымнан узды. Ул, яше олы булганлыктан, фронтка китмичә авылда калган иде, 58 нче яше белән бара инде ул, колхозның төрле эшендә эшли иде. Балалары юк. Сабирҗан абзый бик күп мәртәбәләр ерак урманга, Мари урманнарына, Шалангер, Суслонгер дигән җирләргә барып, кыш буена аты белән утын чыгарып ята торган иде. Сугыш елларында паровозлар өчен, зур шәһәрләрне җылыту өчен колхозчылар көче белән утын хәзерләнә иде. Безнең колхоздан 30—40 кеше кыш буе урман кисә. Ә Сабирҗан абзый кебек, Зиятдинов Шакир, Сәмигуллин Фәтхулла, Зарипов Усман кебек олы яшьтәгеләр, яшүсмерләрне ияртеп, утын ташырга унар ат чыгып китеп, кыш буена эшлиләр иде. Сабирҗан абзый аларның бригадиры булып йөри иде.

Ә менә фронттан яраланып инвалид булып кайткач, мине ферма мөдире итеп куйдылар. Хайваннарны туйдыру өчен басудан ташу бик авыр. Сабирҗан абзый белән икәү басуга, саламга барабыз. Аның хәлсез аты карга батып, чыга алмыйча ята. Саламны ат чанасына төяп, үзебез тартып, кар өстеннән чыгарып куябыз, аннан, икенче атларда килгән малайлар белән бергәләп, атны күтәреп, юлга чыгабыз. Урак өстендә Сабирҗан абзый кырдан көлтә ташу звеносы җитәкчесе булып, малайларны оештырып йөри иде.

Авылда әтиләре сугышка киткән малайлар көченнән файдаланырга, аларны ат тота белергә өйрәтергә кирәк. Сабирҗан абзый кебек крестьян тормышын үз җилкәсендә татыган, җирне яхшы таныган, аны эшкәртү ысулларын яхшы белгән кешеләрдән экренләп иген игү серләренә өйрәнә башларга булыр.

19 июнь, 1944 ел, көндезге сәгать 12 дә өйгә кайтып кергәндә, бик күңелсез күренешкә тап булдым. Әни дәшми, елап утыра, аның янында энеләрем аптырап басып торалар иде. Мин килеп кергәч, алар да елап җибәрделәр. Фирдәвескә 9 яшь, Рубиска 5 яшь иде. Нәрсә булды, нишләдегез? — дип соравым булды, әни миңа үпкә сүзләрен тезә башлады:

— Нәрсә күреп персидателлеккә риза булдың? Әле генә Нәгимәбикәләр җыелыштан кайтышлый миңа кереп, синең улыңны колхоз башлыгы иттек дип сөйләп чыгып киттеләр,— диде.

Нәгимәбикә дигән хатын — безнең уң як күршебез, Котдусов Кашшаф абыйның хатыны иде.

— Нишләрсең инде син, балам?— диде әни.— Авыл тулы ачтан шешенеп үләргә яткан кеше, ул балалар үлеп бетсәләр, үзеңне төрмәгә ябып куярлар бит. Безнең барлыкны уйламадыңмыни?— дип елыйелый, минем председатель булуыма риза түгеллеген белдерде.

Мин аны көч-хәл белән тынычландырдым.

Әни бәрәңге пешереп куйган иде. Ул вакытта бәрәңгене чиста итеп юып, урталай ярып кабыгы белән пешерәләр иде. Энеләрем белән сөйләшә-сөйләшә, сөтләп бәрәңге ашадык. Ул вакытта безнең 110 йортлы Түбән Шашы авылында ипи салучы, ихтимал, булмагандыр.

Көндезге чәйне эчкәч тә фермага киттем. Күтәрәмдәге малларны тикшерергә. Җыйнаулашып күтәрергә. Яшел үлән чыга башлау белән, без аларны чирәм кимертә башлаган идек. Менә яңадан шул хайваннарның хәлен белергә килүем. Мал караучылар инде, бераз кычыткан, үлән йолкып, сыерларның алларына салганнар. Сыер күтәрәмгә калса, күзе эчкә бата икән. Башларын сузып ятканда бик кызганыч була иде. Бу юлы мин фермага кергәндә, сыер-таналарны абзарларыннан үлән кимертергә дип чыгарып җибәргәннәр иде. Хәнифә апа дежур тора. Бер сыер юкка чыккан әле, диде ул. Без икебез шуны эзли башладык. Беренче бозау анасы булган шул аклы-каралы сыер инешкә су эчәргә дип кергән дә шунда егылган, су эчендә ята. Сыер караучылар, Җәмилә апа, Хәнифә апа, Сәгурә апа, телсез Фәйрүзә апа белән барып, сыерны күтәреп чыгардык. Егылган урыны бик тар, читен булды. Сыерны күтәрү өчен аның бер уңай ысулы бар: юкә аркан белән сыерны әйләндереп алып, кыршау ясыйбыз да шул арканга барлык кеше ябышып тартабыз. Кайберләре, күтәреп бетергәч тә, аягына басмый, аларның аякларын уабыз, шуннан соң гына басалар. Аякка җан керткәнче, сыерны күтәреп торырга туры килә. Кайбер көннәрне, аркан кулны кисеп кереп, бармак башларына кан килмичә зәңгәрләнеп бетә, бераз селкегәч кенә сизә башлый иде. Миңа бигрәк тә кыен, бер генә кул белән күтәрергә туры килә иде. Бер кул хәрәкәтләнми иде әле минем.

Фермада 45 савым сыер бар, шулар янында 37 баш үсмер хайван, 120 сарык. Сарыкларны Әхмәтова Файзә, Зарипова Бибинур, Мәүлиева Тайфә апалар карады. Сыер савуда Васыйлова Җәмилә, Мәүлиева Фәйрүзә, Хәкимова Хәнифә, Заһидуллина Сагурә эшли. Абдуллина Мәрзия, Юсупова Гөлсем ат белән фермага салам, печән ташыйлар иде. Көлтәләр әвенгә ташып сугылганлыктан, сыер савучылар саламны әвен яныннан күтәреп ташый. Тирес кечкенә чана яки носилка белән ферма янына чыгарыла. Көнлек савым сепаратта аертылып, мае Әтнә май заводына тапшырыла, сыек сөте бозауларга эчертелә. Җәй көннәрендә сыек сөттән ясалган эремчекне базарга илтеп сата да идек. Фермаларда фонарь яндырып эшлибез. Тораклар салкын, тик бозаулар яслесе генә җылытыла, анда мал-туар ашаганнан калган саламны яга идек. Мин кайтканчы, ферма мөдирсез торган. Иң элек хайваннарның баш санын исәпкә алдым. Егермеләп сыер күтәрәмгә калган. Рационда он бер дә юк. Сарыкка, сыерга салам да печән генә бирелә. Язга таба печән дә бетте. Бозаулар өчен генә булса да печән табу кайгысы басты.

Болыннан печән ташыганда эскерт төпләре алынып бетмәгән, анда яз көне, кар эрегәч, эскерт төпләре чыккан дигән хәбәр ишеттек. Ике атны җигеп, Гөлсем апа белән Мәрзия апа, аның малае Самат — дүртәүләп печән җиренә киттек. Иртәдән кичкә кадәр ике олау печән җыйдык. Кайтырга дип кенә торганда, болынга су җәелгән булып чыкты. Су бик күп булган елны да су басмый торган бер биек урынга життек, ары барып булмый иде, авылдан өзелеп калдык. Су көбәйгәннән көбәя. Атлар белән шул суга кердек, үзебез печән өстендә утырабыз. Бер атыбыз, чыгып җитәм дигәндә генә, су астындагы бозга таеп егылды. Чана ага башлады. Суга сикереп төшми хәл калмады. Минем арттан Самат та төште. Чана атны артка сөйри. Атның ике ягыннан аркалыкны күтәреп, атны торгыздык, ат алып чыгып китте. Колагына су керсә, ат үлә икән дигәнне ишеткәнем бар иде. Шөкер, ул-

бу булмады. Авыл башына безне коткарырга дип кешеләр дә килеп өлгергән иде.

Шул ике олау печәнне саклап-саклап кына салып, бозаулар һәм сарык бәрәннәрен үлемнән коткардык.

Фермада эшләгәндә, ел авыр килү сәбәпле, болында бер эскерт торып калган иде. Шул эскертне ташып кую мөмкинлеге булмады. Шунда төннәрен каравыл куйдык. Бер көнне мин дә каравыл тордым. Икенче көнне колхоз председателе Нуриаздан абый торды. Ул торганда Дусым авылыннан ике кеше печән урларга килгән. Нурый абый аларны тотып, аркан белән билләреннән бәйләп, идарәгә алып кайтты. Анда акт төзеп, тегеләрне бик нык орышып, куркытып чыгарып җибәрдек. Шуның белән Дусымнарның салам, печән урлаулары беразга тыелды...

Фермада каравылчы булып Гыймадиева Маһинур, Әхмәтҗанова Хәнифә эшли иде. Алар, төнлә күтәрәмгә калган хайваннарны торгыза алмасалар яки маллар чирләп-нитеп китсә, мине уятып алып чыгалар. Көннәрдән бер көнне фермада каравыл торучы Маһинур апаның Фагал исемле малае боларга булышырга килгән. Шул чагында күтәрәмгә калган сыерны күтәргәндә, Фагал күтәрмичәрәк тора икән. Хәнифә апа әйткән, әйдә, энем, күтәр, әйдә, күтәр, уен эш түгел бу, чуен эш бу, дигән. Бу сүзләр күп еллардан соң да, авыр әйбер күтәрергә туры килгән чакларда, кешеләр тарафыннан әйтелә торган, безнең авыл халкы үзе генә белә торган канатлы сүз булып калды. Яшь бозауларны Әхмәтова Әминә апа карады. Гатауллина Саимә еллар буе сыер сауды, бозаулар тәрбияләде. И яратып та эшлиләр иде соң эшләрен!

Терлекләргә болыннан печән алып менү, ераграк булган эскертләрдән салам, печән китерү эшләрен Юсупова Гөлсем белән Абдуллина Мәрзия апалар башкара иде. Алар икесе дә таза, көчле. Бервакыт болыннан печән төяп менгәндә, чалуга төшеп, йөк авып китте. Инде сүтеп төями булмас дип кайгыга калып торганда, болар икесе (бер генә кул белән булса да мин дә булышкач), чананы күтәреп торгыздылар да чалулы юлдан алып та чыктылар. Бик авыр шартларда бу ике апа терлекләрне азык белән тәэмин итеп тордылар. Ә яз көне әвен түбәсеч үзләре сүтеп, саламны йөккә үзләре төяп, малларга ташып бетерделәр. Әле моңардан тыш алар фермадагы ватылган нәрсәләрне балта-чүкеч тотып, төзәтеп тә йөриләр. Көрәк-сәнәк саплау, носилка төзәтү кебек эшләрне дә аларга куша идек.

Сыерларны җәй көне Васыйлов Ильяс, Габдрахманов Габделхак көтә торганнар иде. Малайлар гына иде әле алар. Бозауларны Әхмәтова Әминә көтә, аңа улы белән кызлары да булыша иде. Ә дуңгызларны Кәрим абый малайлары — Рәшат белән Мөхәммәт көттеләр. Ганиев Габделрәфикъ, Сайфуллин Зәкәрияләр бу эшләрне башкарып тордылар.

Ферма мөдире булып эшләгәндә күрдем: сарык бәрәннәрен, бозауларны саклау авыр. Тораклар тишек-тошык булганлыктан, яшь хайваннарны кабул итә торган биналар бик салкын иде. Су җылыту өчен урын кирәккәч, җимерек бер иске бинаны сүттек. Агачларын кул пычкысы белән кисеп, балта белән ярып, мичкә яга идек. Сөт җылыту өчен дә шулай эшли торган идек. Ә сепаратта аерту алдыннан сөтне җылыту өчен бозаулар торагында казанлы бер мич бар иде. Фермада эшләгәндә, колхоз председателеннән бер ат сорап алдым. Ул яшь кенә җирән кашка иде. Корчангысын дәвалагач, тәнендәге йоны, яллары коелып беткән, койрыгы тукмак шикелле генә булып калган иде. Йонсыз ат бик шыксыз була икән. Без аны тәрбияләдек, июнь аена кадәр үләнгә арканлап тоттык. Аңа йон чыкты, ул танымаслык булып үзгәрде, карап туя алмаслык матур атка әйләнде. Шулай булып өлгергәч,

ул атка кызыга башладылар. Аны язгы чәчү вакытында сукага жигү өчен дә алдылар.

Фермада мөдир булып эшләү теләге миндә бер дә юк иде. Минем барлык теләгем хисап эше иде. Чөнки мин армиягә киткәндә колхозның баш хисапчысы хезмәтеннән киткән идем. Ә ул эштә, мин фронттан кайтканда, Җәләлиева Һәдия бик әйбәт эшли иде. Комсомолец булуымны исәпкә алып, җитәкчеләр мине ферма мөдире булырга риза-лаштырдылар.

Безнең колхозда сыер көтүен Мари урманлыгында Губина дигән поселок янында делянкада көтә торган булганнар. Ә урманда колхоз кискән делянкадагы агачны урман бригадиры Гарипов Кәрим саклады. Ул үтә шаян кеше, иптәшләрен нәрсә белән булса да көлдерә торган иде. Мин ул кешене бик яхшы беләм. Әти белән бертуган Фәтхерахман абыйларга кунак ашларына килә торган иде, анда да төрле мәзәк сөйләп көлдерә иде. Аның хакындагы мәзәкләр халык арасында да йөри. Мәсәлән: бер көнне иртән каты сукага барганда, ул ат җигәргә соңга калып килә. Ул килгәндә, кешеләр инде китеп беткән була. Бригадир Мәгълүм абый: «Кәрим, мин сиңа азан вакытыннан чыгарга дип әйткән идем ич, ник соңга калдың?»— дигәч, Кәрим абый әйтә: «Әнә шул харап итте дә инде, азан әйткәнне көтеп яттым да әллә ишетә алмый калдым микән дип аптырап төшеп карадым инде, менә»,— ди. «Тфү, иблис икәнсең, сиңа җавап табып та булмый»,— дип, Кәрим абый китеп барган.

Икенче очрак: «Арчага, авыл халкы белән бергә, заготзернога ашлык илтә баргач, Кәрим вокзалга йөгереп кергән. Поезд китәргә вакыт аз гына калган икән. Халык, касса алдында тыгылып, төртешеп азаплана. Кәрим абый кассага якынлашучы такыр башлы, бөтенләй таныш түгел бер кешенең янына килгән дә аны читкә алып киткән. Бу кеше, аның артык билеты бардыр, дип уйлаган, килгән. Кәрим абый исә аңа әйткән: «Сезнең авылда күпме көл, кош тизәге һәм фикал җыйдылар? Бездә бу эшкә бик нык игътибар ителәэ»,— дигән. Теге кеше: «Син нәрсә, җүләрме әллә?» — дип, яңадан билет кассасына чапкан. Анда инде кешеләр касса тирәсен чолгап өлгергән, бу кеше керә алмаган, билетсыз калган. Поезд киткәч, кайда ул кеше, үтерәм мин аны, дип Кәрим абыйны эзләп йөргән. Янә дә бервакытны, урман кисәргә баргач, мари авылында бәйрәм икән, бер кемнә дә кунарга кертмәгәннәр. Кәрим абый урамнан җырлап узган мариларга ияргән дә, бераз гына арткарак калып, бер мари егетенең фин сугышына киткәндә җырлаган җырларын, әнисенең исемнәрен дә кушып, марича җырлап җибәргән. Ул марича яхшы белә иде. Шуннан теге мари хатыны, Кәрим абый янына килеп, аны кунакка чакырып, авылдан килгән урман кисүче башкаларны да квартирга урнаштырып, кунак иткән. Менә шушы шаян кеше урманда Абдулла абыйны сынап карарга булган. Хатын-кыз киеме кигән дә, куе агач арасыннан битен күрсәтмичә, күлмәкләрен генә җилфердәтеп, көтүче Абдулла абый йөргән җирдән ерак түгел генә урында: «Абдулла абый, минем янга килеп кенә кит әле, сөйләшеп утырасым килә»,— дип дәшә. Ә Абдулла абый: «Ай сеңлем, мин андый кеше түгел бит, бер дә гөнаһыга кергәнем юк шул, рәхмәт инде чакыруыңа»,— дип китеп бара. Аның белән бергә йөрүче Әхмәтҗанов Габдрахман да шул ук сүзне кабатлый, анысы өстәп тә куя: «Әнә арттан Габдрахман килә, шуны чакыр, ул барыр»,— ди. Анысы Галләмов Габдрахман, үткен, сизгер, усал кеше иде. Кәрим абый аңа да хатын-кыз булып эндәшә. Галләм Габдрахманы моңа: «Кәрим-шайтан, синең эшең бу, чык!»— дип кычкырган. Кәрим абый шаркылдап көлеп чыккан. Шул вакытта беркатлы Абдулла абый әйткән: «Син кайдан белдең аны, Габдрахман?— дигән.— Кара аны, Җәмилә апаң белә күрмәсен, әллә нәрсә уйлар тагын...»— дигән. Алар Җәмилә апа белән бик тату,

бер-берсен хөрмәт итеп яшәгәннәр. Җәмилә апа колхозда сыер фермасы оешкан елдан сыер савучы булып эшли. Аның бу эштә тәҗрибәсе бик зур иде. Үзенең дә сөйләгәне бар, ул мәктәпнең нулевой классында укыган чагында (ул вакытта «нулевой» дип йөртелгән класс та бар иде), авылда беренче мәртәбә, ферма оештыру өчен, хуҗалыктан тана бозауларны җыеп, Зариф мулла лапасына китерәләр, шунда тәрбияләләр. Җәмилә апа шунда таналар карый. Абдулла абый да шунда эшли икән. Аларның йорты мулла йорты белән янәшә иде.

Сугышка кадәр, утызынчы елларда радио сөйли башлагач, авыл картлары моңа ышанмады. Шул вакытта иң гадел кеше итеп Абдулланы Казанга, радио станциясенә җибәрәләр. Бара Абдулла, станциягә керә: «Авылдашлар, Хафиз, Әхмәтҗан, ишетәсезме, бу мин — Абдулла!» — дип эфирга кычкыра. Имеш, авылдашлары шуннан соң гына радиога ышаналар.

1932 елдан башлап Җәмилә апа (башта ире Абдулла белән бергә) фермада эшләде. Ире армиягә киткәч, ул фермада сыер савучы булып торды. Мин ферма мөдире булып билгеләнгәндә дә сыер сава иде әле. Икенче савымчы — Мәүлиева Фәйрүзә апа. Телсез булуына карамастан, сыер савуда бик тырыш иде. Ул гел Җәмилә апа белән бергә йөри. Саймә апа кыз вакытыннан бирле колхозда сыер савучы булып эшләргә тотынган кеше иде. Хәсәнова Сәгурә апа сугыш вакытында сава башлаган. Шулар белән бергә, эвакуацияләнеп читтән кайткан Галимҗанова Гөлсем апа да сыер сава иде. Ә менә Хәнифә апа Хәкимова озак еллар, сугышка кадәр үк, сыер савучы, бозау караучы, хәтта җәй көне бозаулар көтүче булып та эшләде. Хәнифә апаның семья хәле бик авыр, кием-салым ягы аеруча начар иде. Кышкы суыкларда ул өстенә кыска телогрейка кия, бишмәте берничә җирдән ямаулы, хәтта ертык була. Үзе дә бераз таркаурак иде ул. Кыш көннәрендә дә аның ертык күлмәк-ыштаннарыннан тәне күренеп йөри иде. Салам йолыккан вакытларда, кыш көннәрендә тәне кып-кызыл булып кызарган чаклары булды. Бер көнне керсәм, ферма өендә Хәнифә апа елап утыра. Чабатасын салган. Аягыма су түгелгән иде, ди, салам күтәреп кайтканда тезем бик каты туңган иде, менә саламны ташлап булмады, кайтып фермага кереп карасам, тезем өшегән, аяк бармакларым чабата олтырагына ябышкан, дип кар белән уып елый-елый зарланып утыра. Аны тынычландырып, чабатасына коры печән түшәп, киендереп җибәрдек. Хәнифә апа бик таза иде, бер күтәргәндә җилкәсенә 80—100 килограмм саламны эһ тә итмичә күтәрә ала иде. Ул, йортында сыер асрамаганлыктан, фермада сөт эчә, без күрмәмешкә салыша торган идек. Бер вакыт шундый хәл булды. Мин әйтәм боларга, сез бит сөт эчәсез, дим, ә алар, юк эчмибез, диләр. Хәнифә апа әйтә, мин сөт эчәм, энем, сөт эчмәсәм, мин ачтан үләм бит, минем йортымда бернәрсә дә юк бит, ди. Ә телсез Фәйрүзә, мин бер дә эчмим, дигәнне аңлатырга тырышып, «әттә пәт!» дип әйтә торган иде. Шуннан соң мин моны сынап карарга булдым. Башта Җәмилә апа белән сөйләштем. Ул әйтә, һәммә сыер савучыларның да үзләре яраткан куе сөтле сыерлары бар, ди. Минеке Дурин кушаматлы, ә Фәйрүзәнеке әнә теге сыер, дип күрсәтте. Бу май ае иде инде. Мин сыер сауган вакытларда боларны күзәтә башладым. Фәйрүзәнең теге сыеры койма буенда гына тора. Анда зур бер тагарак бар. Тагарак эченә кереп постым да, ярыгыннан карап ятам, Фәйрүзә апа теге сыер янына килде. Җиленен әйбәтләп юды, сөртте, сауды, соңыннан кулына чүмеч алды, җилен төбендәге иң куе сөтне шуңа сауды, як-ягына карады да, авызына китереп бер генә йоткан иде, мин кулдагы таягым белән чүмеченә китереп төрттем. Ул «Пэ» дип кычкырып җибәрде дә көлә-көлә ике кулын берьюлы югары күтәрде, бирелдем,

дип әйтүе булгандыр инде. Шуннан барлык савымчылар жыелды, көлештек. Моннан соң хәрәмләшмәскә, дигән уртак фикергә килделәр.

Менә шушы бәләкәй коллектив белән эшләгәндә авыл кешеләренең әйбәтлеген аңлатып, дөресен дөресчә сөйләп, төшендереп биргәндә, нинди авыр шартларда да халыкның сине тыңлавына ышанган идем инде мин, кешеләрне үз артымнан ияртеп бара алам икән, дигән фикер миндә уянган иде.

Ферма мөдирлеген үзебезнең күрше Әхмәтжанов Шәриф абыйга тапшырганнан соң, кайбер планнарны аңлатып, колхоз идарәсенә төшеп киттем. Фермадагы коллективка ияләшкән идем. Минем белән эшләгәк дәвердә тырыш булганнары өчен рәхмәтемне әйттем. Савымчылар, бозау караучылар мине озатып калдылар.

Фермадан ерак түгел генә колхозның ашлык амбарлары тезелгән. Колхоз берләшкәндә хуҗалыклардан җыеп салган 14 амбар. Аларны саклау өчен каравылчы өе дә бар. Шунда кереп, амбарчы булып эшләгән Галимжанова Гөлчирә апа белән сөйләшеп утырдык. Өч амбарның түбәсеннән су үтә икән, аларны ябу өчен бер такта да юк. Ул вакытта толь, шифер, калай шикелле нәрсәләрне ишеткән дә юк әле. Бәрәңге базын карап чыктык, анысының да түбәсе тишек икән. Базга 500 центнер бәрәңге сыя булып чыкты. Гөлчирә апа белән яңа ашлык кабул итү әвеннәрен барладык. Түбәсе салам белән ябылган илле-алтмышар метр озынлыгындагы ике әвен бар. Кышын, ашлык сугып тукталганда, ничек калган булсалар, шул хәлләреңдә торалар. Ашлык сугу, җилгәрү машиналары да шунда кул да тимәгән килеш утыра. Ул вакытта колхозларда ике яки алты ат белән әйләндерелә торган сугу машиналары эшли иде. Ике малай ат куалый, ике хатын көлтә бирә, бер кеше көлтәләрне барабанга тыгып тора. Ике яки бер кеше машина алдыннан салам ала, дүрт хатын-кыз, саламнарын селкеп-селкеп, агач сәнәкләр белән 10—12 метрга илтеп чүмәлә салалар. Ә ул салам чүмәләләрен бер хатын-кыз ат тарттыручы бер малайга аркан белән бәйләп җибәреп тора. Әвеннән 120—130 метр читтәрәк ике хатын-кыз саламны эскерткә сала. Ә ат җитмәгәндә, бу саламнарны салам таяклары белән хатын-кызлар эскерт янына кадәрле үк илтеп куялар иде. Җилгәрү күбесенчә көрәкләр белән чөеп, җил ярдәмендә эшләнә, җилгәрү машиналары бик аз иде. Җилгәрү машинасын 4 кеше кул белән әйләндереп тора, бер хатын-кыз чиләк белән салып тора, икенчесе алдан тартып тора иде. Җилгәргечләрдән бер кабат чыккан ашлыкны «Триумфка» дигәне аркылы кабат чыгарасың. Ә орлык өчен кулдан әйләндереп чистарта торган махсус триерлар бар иде. Безнең шул машиналар барысы да әвеннәрдә аунап ята. Урып-җыюга бер генә ай калып барганлыктан, миңа бу «техниканы» ремонтлау эшенә бик нык лап керешергә кирәклеге көн тәртибенә килеп басты. Әвеннәрнең икесенең дә түбәсе шыр ачык, чөнки язын үзем ферма мөдире булып эшләгән заманда, хайваннарга бирер ризык калмагач, түбә саламын ашатып бетергән идек. Анысын яңа ашлык суга башлагач та ябарбыз дип уйладым. Бу эшләрне башкару өчен тимерчелеккә эш бик күп булачагын искә төшердем. Гөлчирә апага да яңа ашлык кабул итү өчен әллә ниләр кирәк. Капчыклар җитми, капчык бауларына мунчала юк, себерке дә кирәк, көрәкләр дә аз, төнлә эшләргә, фонарьлар да икәү генә, кимендә, алты кирәк, дип тезеп китте ул.

Шушы фикерләрдән башым тубал булып тимерче алачыгына киттем. Фермалар яныннан авылга таба төшеп, Гөләндәм апаларның бакча башына ук терәтеп кирпечтән салынган тимерче алачыгына кердем. Ул вакытта Барый абый белән Миңлехай абыйлар тимерче булып эшлиләр. Тимерче алачыгының икегә ачыла торган капкасы яңа урамга карап тора. Тимерче алачыгының югары ягында агач мастерское, аның да югары ягында — пекарня. Ул пекарняда шактый зур мич бар иде.

Аларның арт ягында салам түбәле такта яру лапасы. Аның түбән ягында тимерче алачыгы белән бер рәттән завхоз келәте бар. Анда колхозның продуктларыннан бал, ит һәм төзү материаллары саклана иде. Шушы торакларны тышкы яктан гына карап, тимерчеләр белән исәнләшеп кенә алдым да идарәгә кайттым. Анда бригадирлар җыелган иде, элеккеге председатель Котдусов Нуриаздан абый да шунда. Аны беркая да алып бармыйча, шунда сөйләшеп кенә, председательлекне алдым-бирдем эшләдек. Чөнки аның өстендә бер төрле дә материаль байлык юк. Ул бу эштән исән-сау котылганлыгына сөенеп, миңа уңышлар теләп, өенә кайтып китте. Нуриаздан абый бер класс укымаган, наданлыкны бетерү курсларына гына йөреп, укырга-язарга өйрәнгән кеше иде. Язуын бик читенлек белән генә яза. Ул, элек тә кибетче булып эшләгәнлектән, яңадан кибеткә керү теләгән белдерде, әмма, никтер аның ул да тормышка ашмады. Колхозда атлы эштә йөрде. Пөхтә эшли иде. Лашман Тае кушаматлы кашканы җигеп, урманга малайларны оештырып алып бара, карап-барлап эшләтә иде. Шулай итеп, Нуриаздан абыйны озаткач, мин бригадирлар белән идарәдә утырып калдым. Беренче бригадада Әхмәтов Мәгъсүм абый эшли иде. Бу бригадага күпердән башлап, югары урам, икенче бригадага түбән оч һәм Пләтән урамы керә. Бу бригадага Фәйзиева Рәхилә, өченче бригадага Әүхәдиева Мәймүнә апа җитәкчелек итә иде. Бу бригадага яңа урам һәм югары очтан Зиатдинов Шакир, Габдрахманов Назим, Садриев Низамнар керә иде. Бригадирлар белән алгы көндәге эшләр хакында сөйләшеп утырдык та иң әүвәл ачтан шешенгән кешеләргә ярдәм оештыру кирәк булыр, дигән фикергә килдек. Иртә таңнан бу эш буенча икмәк әзерләүче район оешмаларына барырга дигән уй белән таралдык.

Сугыш вакытында күпчелек эшне хатын-кыз көче белән башкарырга туры килде. Байтак хатыннарның ирләре фронтта үлгән, балалары боек. Чөнки ашау өчен аларга икмәк, бәрәңге җитми, бакчаларында яңа бәрәңге өлгергәнче, акбаш, кузгалак, аерата ат кузгалагы ашы, чыпчык кузгалагыннан пешерелгән вак күмәч, колхоз җирендә калган черегән бәрәңгедән пешергән боламык — әнә шулар белән тукланды халык. Шушындый авыр чорларда хатын-кызлар хәлсез һәм басынкы иде. Шул хәлсез кешеләр белән иген игәргә, фронтны икмәкле итәргә кирәк. Моның өчен иң әүвәл аларның тамакларын туйдыру, балаларын саклап калу мәсьәләсе алга килеп басты.

1944 елның 21 июнендә бу мәсьәләдә ярдәм итүне сорап, райбашкармага киттем. Халыкның көнкүрешен тәэмин итү бүлегендә безнең авылның Җәләлетдинов Гыйлаҗ абый эшли иде. Туп-туры аның янына кердем. Ул икмәк карточкалары белән эш итә. Гыйлаҗ абый миңа райсоюздан 100 килограмм (ике капчык) он сатып алырга рөхсәт язуы бирде. Ул онны табып алып кайтканда, ни дәрәҗәдә сөенгәнемне күрсәгез иде!

Мохтаҗ дигәннәргә 80 кешене кертеп исемлек төзедек тә бригадирлар белән бергәләп авыл кешеләренең хәлен белергә чыгып киттек. Бригадирлар көн саен эшкә әйтеп йөргәнлектән, кем йортында нинди хәл икәнен яхшы беләләр иде.

Югары урамда булдык, яңа урамга менеп, андагы кешеләрне йөреп чыктык. Соңгысы итеп икенче бригаданың түбән очыннан үттек. Бригадир Рәхимәнең күңеле бик йомшак икән, кешеләргә кергәч, шешенеп калтыранып яткан балаларны күрү белән, ихтыярсыздан күз яшьләре ага башлый иде. Аның үзен тынычландыру кирәк була иде.

Председатель булуның икенче көнендә янгын сарае янына бардым. Анда идарә члены Әхмәтов Абдулла тора иде. Күп вакытта аның белән сөйләшә, киңәшә торган идем. Бик гадел кеше иде ул.

## Барысы да фронт өчен



Мин фронттан кайтканда, январьның салкын көне иде. Уфа госпитаденнән, Челябинск һәм Свердловск шәһәрләре аркылы, «Свердловск—Казан» поезды белән Чыпчык станциясенә кайтып төштем. Бер кулым эшләми, икенче кул белән госпитальдә мендәр тышыннан ясалган капчыкка ризык-мазарны һәм кирәкле документларны салган идем. Поездан төшкән Әтнә ягы кешеләре белән тезелеп, җәяүләп юлга чыктык. Башта әкрен генә кайттык. Берәздан мин тирли башладым, өч айдан артык госпитальдә яткангадыр, организм бик йомшаган, арылды. Комургужа авылына житеп, урамнан әкрен генә бара идем, Дусым авылының Сәетова Таһирә белән үзебезнен авылның Ганиева Нәсимә очрадылар. Алар мине авыл советына алып кереп, телефоннан мине алмага ат чакырттылар. Райкомол кушуы буенча килгән Таһирәләрне илтергә Комургужа колхозының председателе Гани абый Әхмәтгалиев бер ат бирде. Шуңа утырып Таһирә белән Әтнәгә таба юл тоттык. Мәрҗәнне узып, Шәкәнәч турыларына житә башлагач, карасам, юлдан читтә бер ат тора. Сөйләшүләреннән аңлап алдым: безнең авыл малайлары.

— Менә, Фәйзи абый, сине алмага бара идек, ат арып китте әле,— диделәр.

Минем белән килгән иптәшләргә бик зур рәхмәт әйтеп, әлеге атка күчеп утырдым. Әкрен генә кайтып киттек. Бик озак кайттык, таудан түбән төшкәндә — юыртып, тауга менгәндә атлатып кына бардык. Мине алмага килгән атның кушаматы Кара Кетәк Таек иде. Ә алмага килүче малайлар — Хәйруллин Зиннәт белән Халиков Кави, аларны авыл советы председателе Кави абый җибәргән.

Кичке сәгать унда без авылга кайтып кердек. Авылга килеп житмичә, аны күреп тә булмады. Авыл буена кар көртләре өелгән иде. Тәрәзәләрне, җылы чыкмасын өчен, салам көлтәсе белән каплап, таяклар белән терәтеп куйганнар, шунлыктан сирәк йортлардан гына, бишле лампа яктысы уты җемелдәп кала барды.

Безнең ишегалдына кайттык. Өй кап-караңгы, кеше тормый икән. Мин армиягә киткәч, көз көне, җылыту читен булыр, дип, әни ике энекәш белән мунчага күчкән. Мине алып кайтучы ике үсмер егетне чәй эчәргә шушы мунчага алып кердек. Аларны миңа госпитальдән биргән «коры паек» ризыклары белән чәй эчертеп, рәхмәт әйтеп, озатып калдым. Алар китешкә, миңа әни исеменнән хат язып торучы, колхозда хисапчы булып эшләүче Һадия Җәләлиева кереп утырып, хәлләремне сорашып чыгып китте. Әни каз ите салып аш пешергән иде, каклаган каз итен саклап торган булган. Энекәшләргә үзем белән алып кайткан сохари, колбасаларны бирдем. Колбаса күргәннәре булмаган, бик кызыксынып, бу әйберне нәрсәдән ясыйлар икән, бик тәмле икән, диделәр. Бу төнне эчкән чәебез һәммәбезгә дә, бигрәк тә әнигә күңелле булгандыр. Чөнки 1942 елда гына әти үлеп китте, шул ел азагында мин дә армиягә алындым. Кулым гарип булса да, фронттан исән кайтуыма әни бик сөенде, каушап та китте. Чөнки өч баласы белән бергә җыйналгач, анага шуннан да зур сөенеч булмагандыр, үзең ата-ана булгач кына балалар өчен ничек кайгыруыңны беләсең икән. Менә шул вакыттагы әнинең сөенечен соңгы елларда гына аңлый башладым.

Шулай итеп, фронттан авылга кайтып, үзебезнең мунчада беренче кичне кундым. Кичтән дә, иртән дә, авылыбыз халкы күрешергә, хәлемне белергә килеп тордылар. Авылдашларымның кайгылы, меңмәшәкатьле тормышына минем дә тормышым килеп кушылды. Мин авылдан шәһәргә китү турында бервакытта да уйламадым. Чөнки әти үләр алдыннан мине, әни чыгып киткән вакытта, үзе янына чакырып

алып: «Улым, син бу йортта олы ир кеше инде, мин бик каты авырыйм, үләрмен, ахрысы, әниеңне ташлама, энеләреңне чәчеп-түгеп бетермә, хәер эстәтмәскә тырыш, яме, мин сиңа бик ышанам, син минем олы, акыллы улым ич»,— дип, күкрәгенә башымны кысып торып, бик каты елады. Мин этине гомер буе көчле кеше итеп күз алдына китерә идем, этинең шушылай елаган чагын күреп, аны кызгандым. Кызгануым шуның өчен булды: ул вакытта эти 43 яшендә генә иде әле. Әмма авыру сәбәпле, эшкә яраксыз табылып, 1938 елның көзеннән инвалидлык өчен 141 сум пенсия алып, авырып ята иде. 1942 елның 30 мартында ул үлеп китте.

Эти 1898 елда үзебезнең Түбән Шашы авылында туган, 18 яшенә кадәр авылда яшәгән. Аннары Әстерхан шәһәренә барып, байларга ялланып эшләгән, патша армиясендә хезмәт иткән, шул чорда пленга төшеп, дүрт ай Польшада әсирлектә яткан. Аннан авылга кайтып, авылда совет власте урнаштыруда катнашкан, ярлылар комитетының секретаре булган. Аннан Кызыл Армиягә алынып, Колчакка, басмачыларга каршы сугышларда катнашкан. Шуннан авылга кайтып, Күңгәр авыл советында председатель булып эшли. Күңгәр, Югары Шашы, Түбән Шашы авылларында колхоз төзүдә актив катнаша. Гомумән, ул елларда колхозларның аякка басуында авыл советларының роле бик зур була. Әхмәтов Сәлим белән эти авылда беренче коммунистлар булалар.

Эти 1934 елда Әтнә район советы башкарма комитетында инструктор булып эшли, аннан соң райбашкармада секретарь була. Шул 1934—1938 елларда район советында секретарьлык вазифасын башкару аңа җиңел булмагандыр. Чөнки бер класс та укымаган, үзлегеннән белем алган кешегә русча карарлар язу, аны юридик яктан нигезләү өчен күп тырышлык куярга кирәк булгандыр. Эти русча да бик грамотный язган, аның партия тарихын өйрәнү буенча русча язган конспектларын соңгы елларда карап соклана торган идем. Этинең кешелеклелеге, аның һәрвакыт шат күңеллелеге миндә әле дә саклана. Ул татарча, русча, марича белә иде. Әле дә хәтеремдә: әни Фирдәвес энемне тапкач, этидән телефон аша сөенче алырга кәнсәләргә төштем. Мин сөйләшеп бетергәч, Абдулла абый, Әпәти Абдулласы, миннән телефон трубкасын алды да эти белән марича сөйләшә башлады. Урамда, Нәчә Хәбибулласы белән, мин малай чакта бик озак марича сөйләшеп торды. Алар икесе дә марича яхшы беләләр, малай кешегә әйтергә ярамаган сүзләре булгангадыр инде, минем алда икенче телдә сөйләшүне уңай санаганнардыр.

Икенче бер вакыйга минем күңелемә сеңеп калган. Сугышка кадәр, эти авыл советы председателе булып эшләгәндә, безнең авылга бик күп атларга төялгән чегәннәр килеп тулды. Кәрванның башы авыл уртасындагы кибеткә килеп тоташкан, ә азагы Фәтхерахман абыйлар янында иде. Без, малайлар, мәчет тавында чана шуа идек. Чегәннәрдән куркып малайлар өйләренә качып беттеләр. Эти шулар янына килеп туктагач, мин дә бардым. Эти чегәннәр белән русча бик каты кычкырып-кычкырып сөйләште. Шулай берәр сәгать торганнан соң, чегән таборы кузгалып китте. Алар киткәч, безнең эти нинди зур кеше икән, шул хәтле зур сакаллы кешеләрне кузгатып җибәрә алды, дип уйладым. Кешеләр белән эшләгәндә, этинең акыл-фигыле минем өчен һәрвакыт үрнәк булып тора.

Безнең авылның элекке хәлен күз алдына китерсәк, эти кебек кешеләр анда күп иде. Мин фронттан кайтып, авылда яши башлагач, аларның холкын, эшкә сәләтен өйрәнә башладым. Армиягә киткәнче колхозда күп эшне үз кулым белән эшли идем. Эти авырганлыктан, семьяны алып бару өчен, каникул вакытларында 13 яшемнән печән чаба башладым. Авыру эти минем арттан йөри, чалгыны янап, кайрап

тора торган иде. 11 яшемнән башак чүпләү, житен йолку эшләренә йөрдем. 12—13 яшьләремдә чакта ат жигеп, силос өчен Атау елгасы буеннан печән ташый идем. Безгә, малайларга, печәнне Баһабиев Шаһгали, Заһитов Сабиржан, Садриев Кашшаф, Хисамиев Котдус абыйлар чабып торалар. Соңыннан көлтә кертә торган идек. Ә укулар башлангач, бөтен мәктәбебез белән яшелчә жыюда булыштык. 1940 елны Әтнә урта мәктәбенә йөри башладык. Авылдан Мифтахов Сиражи, Кашшапова Кәүсәрия һәм мин, яхшы гына укып йөргәндә, мәктәптә укыган өчен бер елга 150 сум акча түләргә дигән закон чыкты. Беренче ярты еллыкка 75 сум акча түләдек, ә икенче ярты елга түләү өчен өйдә акча юк икән. Әти, мин пенсия алгач түләрбез, дигән иде, мәктәптә мена шул числога китереп житкермәсәгез, укудан куабыз дип игълан иткәч, мин укуны ташлап кайтып китәргә мәжбүр булдым. Кайтканда үзем генә биш чакрым арадан елый-елый кайттым. Әти ачуланды. Шул көнне миңа колхоз хисапчысы Сәлим абый Әхмәтов очрады, нишләп йөрисең дип сорагач, мин аңа хәлне сөйләп бирдем. Ул миңа, ярар, әйбәт булган, иртәгә колхоз идарәсенә төшәрсең, анда секретарь-кассир урыны буш, риза булсаң, шунда эшләрсең, диде. Мин риза булдым. Хисапчы Сәлим абый миңа эшкә өйрәтте, ул үзе бик таләпчән иде. Колхоз председателе Закир абыйны алмаштырып, Сәлим абыйны сайлагач, укып кайткан Галиев Җаббарны колхозның баш хисапчысы итеп куйдылар. Бөек Ватан сугышы башланган көннәрдә, мин колхозда секретарь булып эшли идем. Ул көнне Әтнәгә базарга барган идем, Әтнә базарында Германиянең безгә каршы сугыш башлаганлыгын белеп кайттым. Базарга җәяү барган идек, кайтканда авылыбызның күп кенә кешеләре белән, Галимҗанов Сабир абыйлар белән бергә кайттык. Кешеләр бик борчылган. Шул көннең иртәгесен үк беренче кешеләр булып авылдан Корбанов Хәсән, Мөхәммәтҗанов Рәхим, икенче-өченче көннәрне Сибгатов Хәким, Абдуллин Нигъмәтҗан, Галләмов Әхмәтгалиләргә хәбәр килде. Армиягә китүчеләр тарафыннан беренче җырны Галләмов Әхмәтгалидән ишеттем. Кич белән урамга чыккан идек. Әхмәтгали абыйлар тәрәзәләрен ачып куйганнар. Армиягә китүчеләрне озатырга туганнары җыелган. Әхмәтгали абый җырлап җибәрде.

Без, яшүсмерләр, мәҗлес беткәнче капка төбендә утырдык. Кешеләр тарала башлагач, без дә кузгалдык. Мәҗлестән чыккан кешеләр гармун уйнап урам әйләнделәр. Китүчеләр алдан гармунга җырлап барды, алар артыннан яшьләр ияреп йөрде. Авыл халкы берсе дә йокламаган икән, барысы да капка төбендә — карты да, яше дә, балалары да. Болар узып киткәндә, елап, моңаеп калдылар. Безнең дә күзләребез яшь белән тулып, күңелләребез әрнеп барды.

Иртәгесен, китүчеләрнең барысы да җыелып беткәч, колхоз председателе Сәлим абый, арбага басып, сүз сөйләде.

— Без авылыбызның иң яхшы егетләрен сугышка озатабыз. Алар алдында явыз дошман тора. Сез, авылдашлар, дошманны җиңеп кайтыгыз, семьяларыгыз өчен борчылмагыз, алар безнең иң кадерле кешеләребез булырлар...

Сугышка китүчеләр авыл халкы белән саубуллашырга тотындылар. Шуннан елаш башланды. Колхоз председателе Сәлим абыйның үзен көч-хәл белән тыеп торуын күрдем мин. Китүчеләр арбаларга утырды, хатыннары Мәйсәрә апа, Мәрзия апа, Латифа апа, Шәһәрбану апалар да утырды. Халык төркеме авылны чыкканчы аларны озата барды. Атлар зират янына житкәч, тагын бер тукталдылар, авыл халкы тагын бер саубуллашып чыкты. Китүчеләр арасыннан Әхмәтгали абый шаянрак кеше иде. Аның гәүдәсе таза, арбага аягүрә баскан көенчә авылга бер карады да: «Хуш, авылым!» — диде. Егетләрнең берсе җырлап җибәрде.

Туган илебезгә, халыкка килгән зур афәт шушы көннән башланды. Шуннан соң көн саен кешеләрне армиягә озата торган булдылар. Алар һәр көнне идарә янына җыелып, Сәлим абыйның озату вакытында сөйләгән сүзләрен тыңлап, ерак юлга чыгып киттеләр.

Сугыш башланганнарның өченчеме, дүртенчеме көнендә фермада мөдир һәм ветфельдшер булып эшләүче Фәйзиев Габделхак абыйга повестка килде. Ул вакытта безнең ферма мари урманында иде. Колхоз председателе Сәлим абый миңа әйтте, энем, син Губинга барып, Габделхакны кайтарып җибәр, үзең ферма эшен кабул итеп ал, бераздан сине алмаштырырга ферма мөдире җибәрербез, диде. Пожарныйда торган Мәүли атының аксыл төстә бер тае бар иде, шуны җиңел тимер хутка җигеп, урманга чыгып киттем. Сугыш башланган елны, безгә, комсомолларга, төрле-төрле йомышларны күп кушалар иде. Менә бу юлы да мине урманга чыгарып җибәрделәр. Ат бик яхшы барды, бездән 30—35 чакрым ары булган урманга мин кич кырын барып та життем. Кардыда сыер савалар иде. Мине эшләреннән туктап каршы алдылар. Габделхак абый карды буенда тезеп куелган берничә бидон сөтне үлчәп, кабул итеп тора иде. Сыер кардысы Иллэт суы буенда иде, аңа кечкенә генә тау өстеннән төшәләр.

— Урманнан тау өстенә пожарный аты килеп чыккач та бу инде, мөгаен, минем арттан киләдер дип уйлаган идем,— дип, Габделхак абый кулындагы сөзгечен бидон өстенә куйды.— Менә, апалар, миңа да жирәбә чыкты,— дип сөйләнеп алды. Мин юл буена ничек итеп әйтермен инде, дип уйлап килгән идем, шул рәвешле Габделхак абый минем эшне җиңеләйтеп тә җибәрде. Ул арада сыер савучылар җыелышты. Аларның берничә генә сыерны савасылары калган иде, тиз-тиз генә савып чыктылар да Габделхак абыйны озатырга әзерләнделәр. Габделхак абый бик тиз җыенып бетте. Килеп туктагач та атка яшел печән салып куйган идем, суынгач аз гына су эчереп, арбага, печән җыеп, Габделхак абыйны печән өстенә утыртып маташканда, ул, авылдан урманга киткәндә, кичләрен күңел ачарга дип алган гармунын сыздырып җибәрде. Мин атны тотып Губин поселогына хәтле озата бардым. Нинди көй уйнаганы истә калмаган, әмма бәләкәй генә гармунның бөтен урманны шаулатканы әле дә хәтеремдә. Поселокта атны ул үзенә алып, гармунын капчыкка тыкты да, аттан төшеп, мине кысып кочаклады, ярый, энем, сау бул инде, дип әйтүе булды, елап та җибәрде. Урманга караңгы төшкән иде инде, ул елагач, мин дә еладым, без икәү елап аерылыштык. Урман юлыннан җырлый-җырлый, атын юыртып, авылга кайтып китте. Аның җыр тавышы, мин ферма кардысына кайтып житкәндә, инде ишетелми башлаган иде. Фермада сыер савучы хатын-кызлар елап утыралар. Алар, монда ятып булмас, ферманы авылга кайтарсыннар иде, дигән фикерне әйтә башладылар. Габделхак абый киткәч, аларның да кәефе үзгәрде. Күзләрен сагыш басты, миңа хәтта күшәп торган сыерлар да, Габделхак абый киткән якка моңланып торган кебек тоелды.

Шулай итеп, мин ферманың мөдире дә, хисапчы да, ветфельдшеры да булып калдым. Фермада күңелсез иде, һәммә кеше кырыс кебек, житмәсә кичтән бик бөркү булды, ә иртән пыскып яңгыр ява башлады. Сыер савучылар, кеше елаганга табигать тә елый дип, яңгыр астында кардыга сыер саварга кереп киттеләр. Мин Габделхак абый басып торган урында сөт үлчәгеч белән сөт кабул итә башладым. Бер атналап эшләгәннән соң, аерткан сөтләрнең майларын, ясаган эремчекне төяп, авылга кайтарырга чыктым. Авылга бу товарны кайтарып, завхоз Хафиз абыйга тапшырдым да колхоз идарәсенә кердем. Сәлим абыйга терлекчеләрнең борчылуын сөйләп биргәннән соң, ул, ферманы алып кайтырсыз, дигән боерык бирде. Безгә сыерларны авылга куып алып

кайтырга туры килде, аннан соң мине ферма мөдирлеге вазифасыннан бушатып, янәдән үз эшемә — хисапчылыкка куйдылар.

Авылыбыз көн саен фронтка ирләрне озата торды. Сугыш башланганның икенче көннәреннән үк, колхозның иң яхшы атларын армиягә ала башладылар. Иң элек Гыйльмәтдин белән Мәгъсүм атының тае китте. Малайлар аларны матур итеп чистартып, ялларын кисеп, койрыкларына чуклар, кызыл чүпрәкләр такканнар. Гыйльметдин аты бригадабызның иң яхшы аты иде. Күршебез Котдусов Кашшаф абыйның аны лобогрейкага җигеп урак урган вакытларын күз алдымнан кичердем.

Авылыбыздан ат күп китте. Аларның күбесе, колхозлашкан елларны хуҗалыклардан кергән атлар булганлыктан, хуҗалары исеме белән йөрделәр. Мин белгән атлардан Миттай атының тае, Шайтан аты, Мәгъсүм тае, Шакир аты, Мөки Шакирыныкы фронтка китте. Көзгә таба Сәлим абый Әхмәтовка да фронтка китәргә хәбәр килде. Аның белән бригадир булып эшләгән Сәмигуллин Гани абый да китте. Сәлим абый председательлекне хәзерләүче вәкил булып эшләгән Халиков Вәлигә тапшырып калдырды. Киткән чакта да нык булды, митинг җыеп сөйләде.

«Авылдашларым, каушамагыз, таралмагыз, тырышып эшләгез. Без фашистларны дөмектереп кайтырбыз!» — дигән сүзләре әле дә исемдә саклана. Сәлим абыйның балалары күп иде. Нәсимә, Хәтимә, Хәтирә, Ринат, тагын кемнәрдер — барысы да озатып калдылар.

Гани абыйның да балалары күп иде, елап калдылар. Гани абый безнең Түбән Шашы авылында төзелгән колхозның беренче председателе булган, шуннан бушагач, гомере буе беренче бригадада, югары очта, бригадир булып эшләде. Армиягә дә бригадир постыннан китте. Ашказаны да авырта торган иде, кесәсендә бәләкәй шешә белән чәй содасы эремәсе йөртә, шуны эчеп, тәненә сихәт таба торган иде.

Менә шул гомерлек сер булган Гани абыйны, кырыс характерлы Сәлим абыйны озатып җибәргәч, авылыбыз бик моңсу булып калды. Колхоз белән җитәкчелек итүдә Сәлим абый усал булса да гадел иде, халык аны хөрмәт тә итә, бераз шүрли дә иде. Берьюлы председатель һәм бригадирны озату — колхозыбызның йомшый башлавы иде инде. Шуннан председательләр алмашыну китте, елга икешәр председатель алмашты, берсе дә файдалы булмады. Дүрт ел сугыш чорында 6 председатель алмашынган. Авыл кешеләре армиягә китә торды, үлгән хәбәрләре килә торды. Иң әүвәл Корбанов Хәсән абыйның үлгән хәбәре килде. Безнең Фәтхерахман абый да китте. Алар Шәрәфиев Мифтах абый белән киттеләр. Мин аларны Әтнәгә кадәр озата бардым. Фәтхерахман абый үтә чыккан тыйнак, аз сүзле кеше иде. Тыйнак тотты үзен, Мифтах абый бераз эчкән иде, миңа аңлашылмый торган җырлар җырлады. Авылдан киткәндә, Фатиха турыларында каласыз ич аерылып дип җырлады. Болынга чыккач, көтүдә йөргән мал-туарны күргәч тә, сыерларым-җанашларым, каласыз ич аерылып дип җырлап җибәрде. Әтнәгә кадәр җырлап барды. Мифтах абый гомере буе хуҗалык хайваннарын көтте. Шуна күрәдер терлекләр белән аерылышуын җырга салып китте.

Фәтхерахман абый колхозда балта эшендә эшләде. Саубуллашырга дип безгә кергән иде, әти аңа киңәшләрен бирде. Әти әйтте, безнең нлебез бик зур, бик куәтле, ул беркайчан да җиңелмәгән, менә күр дә тор, җиңүчеләр булып кайтырсыз, диде...

Фәтхерахман абый бик озак сугышты, дүрт мәртәбә яраланып госпитальләрдә ятты, сугыш бетәсе елны гына үлеп калды.

Әти белән саубуллашырга барысы да килә иде. Әтинең бик яраткан кордашы Габдрахманов Шәрип абый бар иде. Шәрип абыйга хәбәр килгәч, әти янына керде. Беләм, андый чакта сүз авыр була, мин өйдән

чыгып китеп, ишегалдында йөрдем, өйдә тавыш ишеткәч, нәрсә булды, әти авырып китте мәллә, дип керсәм, әти белән Шәрип абый кочаклашканнар, икесе дә кычкырып елыйлар, әти әйтә: Шәрип, син кайтканчы, мин тормам, үләрмен инде, бәхил бул, ди. Шәрип абый әйтә: син әле яшәрсең, мин менә ут эченә китәм, үлеп калсам, бәхил бул, ди. Алар әти белән икесе бергә Гражданнар сугышында Колчакка, басмачыларга каршы сугышканнар икән. Ә бит ут эчендә туган дуслыктан да зуррак дуслык булмыйдыр ул...

Сәлим абый да әти белән саубуллашырга кергән иде. Алар икесе дә — бер авылдан булган ике коммунист. Бик тыйнак кына саубуллаштылар.

Авылыбызның 80 кешесе, шуның эченнән әтинең бертуган энеләре Фәтхерахман белән Һади абыйлар да сугышка китте. Авыл ир-атсыз калды. Ә авылның мәшәкатьләре муеннан иде, болар барысы хатын-кыз, бала-чага өстенә өелде. Бу авыр чорда, сугышның ел ярымында авыл халкына авыр хәсрәт килгәндә, барлык кайгылар уртак иде. Сугышта булган кешеләрнең семьяларына килгән хатларны укып бирү, җавап хаты язарга булышу — минем өстә иде. Халык күңелендәге уйларны үз акылым аркылы үткәрергә тырыштым. Кара печатьле язуны тотып, үксеп-үксеп елаган япь-яшь хатыннарны, аларның үрсәләнеп елаган балаларын күреп, йөрәктән каннар тама иде. Шуның өстенә безнең авылга 80 кеше эвакуацияләнеп киләчәк, Мәскәү кешеләрен кабул итәргә әзер булыгыз, диелде. Алар ул кадәр үк килмәделәр, балалары белән 37 кеше булды. Әмма безнең кебек үсмер егетләргә эш тагын да кыенлашты. Авылда русча белүчеләр бик аз, килүчеләр татарча аңламый, барлы-юклы русчабызны хутка җибәреп, без, комсомоллар, аларны иркенрәк йортларга урнаштырдык. Авыл халкы, туган-тумачасы белән укмашып, килүчеләргә урын бушаткалаганчы, байтак кына вакыт узды. Аларны, бер-ике семьяны Заһидуллин Нәби, Нургали, Әхмәтгали, Әптер Мәгъсүменә һәм башка йортларга керттек. Алар, табигый, колхозга килү белән эш сорый башладылар. Валентина дигән бик үткен бер хатын сыер савучы булып, Дондуковлар семьясы белән бергә фермада эшли башлады. Анатолий дигән яшүсмер малай фермага ат белән су ташырга керешге. Зинаида дигән япь-яшь хатынның баласы туды, ул бала озак та тормый үлде. Янә дә бик чибәр берсе, Антонина дигәне, Әтнәгә йөреп, бухгалтер булып эшләде. Ул арада авыл кешеләре белән аралашып, татарча өйрәнә башладылар.

Авыл халкы читтән килүчеләргә ихтирамлы булды. Бераздан бербersенә шулкадәр ияләшеп киттеләр, аларның кызлары белән безнең егетләр, аларның егетләре безнең кызлар белән дуслаша башлады. Мин шунда тормыш авырлыгы кешеләрне бик тиз якынлаштыруын күрдем.

Бер кыш чыккач, фронт Мәскәүдән ераклашкач, бу кешеләр әкрен-әкрен китә дә башладылар. Аларны бик әйбәтләп озаттылар, ә Валентина дигәне, кешеләр белән бик аралаша ала торганы, иң якын туганнарыннан аерылгандай, елый-елый китте.

Без, комсомоллар, сугыш башлану белән, Кызыл Армия өчен һәр бәйрәмдә бүләкләр җыю оештыра идек: өмә ясап, оекбаш, бияләй бәйләү, янчык тегү... Хәтта тиреләр җыеп, аны Әтнәгә илтәбез, фронтка ярдәм фондына тапшырабыз. Менә шундый олауны бер мәртәбә минем үземә илтергә туры килде. Көз иде, кар ява башлаган чак. Бүләкләрне комсомол исеменнән ВЛКСМ райкомына илтеп, аны бер келәткә бушаттык. Хәтерем ялгышмаса, анда 80 пар бияләй, 25 пар оекбаш, 20 тире, 50 янчык һәм посылка салу өчен 15 данә ящик бар иде. Безнең комсомол оешмасын бу әйберләрне җыйнап тапшырган өчен мактадылар. Башка оешмалардан да фронтка бүләк күп килә иде. Бәрәскә оешмасыннан аеруча күп иде. Аның секретаре безнең авылда балалар

укыткан, аннары Бәрәскәгә киткән Биктаһирова Сара иде. Шул әйберләрне кичкә кадәр тапшыра алмыйча яттык. Сара белән озак кына сөйләшеп утырдык. Аның әйберләре минеке янында булганлыктан, мин аңа булышып тордым. Аннан кич кенә кайтып киттем. Ул бер яшь кенә малайдан ат тоттырып килгән иде. Соңыннан безгә Сара белән тормыш корып, өйләнеп яшәргә насыйп булды. Авыр сугыш елында башланган танышлык безнең чәчләрне чәчкә бәйләде.

Ул елларны райкомол секретаре булып Хәбибуллина Разия эшли иде. Аның тырышлыгы, таләпчәнлеге барлык комсомолларга үрнәк иде. Сугыш чорында комсомоллар гомумән бик күп яхшы эшләр башкардылар.

Армиягә киткән чакта да Разия безне райкомолга чакырып әңгәмә үткәрде, безне озаткан вакытта да шунда булды.

1944 елның 21 июнендә, сугыш башлануга өч ел тулганда, мин, фронттан яраланып кайткан унсигез яшьлек солдат, үзебезнең туган авылыбызның колхоз председателе булып сайлангач, әнә шуларны күз алдымнан үткәрдем.

Алда кыен эшләр, җиң сызганып башкарасы бик зур эшләр көтә иде...

## Камыт зур, эшләр авыр

1944 елның 22 июнендә идарә утырышы үткәрергә булдык. Утырышка идарә членнарыннан Хөснетдинов Лотфулла абый, Әхмәтов Абдулла, Җәләлиева Һәдия, Әүхәдиева Мәймүнә, Фәйзиева Рәхимә, Галимҗанов Миңлехәй килде. Ревизия комиссиясе председателе Һадиев Барый абый, колхоз активларыннан ферма мөдире Әхмәтов Шәриф, өлкән ат караучы Зарипов Усман бар иде. Утырышны көндезге сәгать икедә башладык. Сөйләшү якынлашып килгән урып-җыюга әзерлекне яхшырту хакында барды. Тимерче Һадиев Барый абый бик иркенләп сөйләде. Аның сөйләвендә, колхоз хәлен мин күбрәк белəм, мине тыңлагыз, дигәнрәк киная чагылып калды. Чөнки ул миннән алда гына, Котдусов Нурый абыйга кадәр колхоз председателе булып эшләгән. Сүз уңаеннан бу урында Барый абыйның председательлектән китүенең сәбәбен дә әйтүне кирәк саныйм. Ел бик авыр, эшләр дә бик авыр бара, җитәкчеләргә таләп тә зур булганлыктан, Барый абый армиягә китүне кулайрак саный. Хезмәт армиясенә алына. Председательлекне тапшырганнан соң, Казанга баргач, анда комиссия торганда, авыру аягын күрсәтеп, хезмәт армиясеннән кире борыла, колхоз тимерчелегендә эшли башлый. Бу Барый абыйның үз авызыннан ишетелгән сүзләр. Чыннан да Барый абый армиягә алынырлык түгел. Бала чактан аягы аксак иде. Ул гел титаклап йөрде, кушаматы да «Аксак Барый» иде.

Барый абый, урып-җыюга кирәкле ургыч, лобогрейкаларның ремонтланып бетмәвенә, запас частьларның булмавына бик нык басым ясады. Ә кешеләрдәге уракларның тешәтелмәгәнлеге хакында, эвендә ашлык суга торган машиналарның, җилгәргечләрнең ремонтка да кермәгәнлеге хакында, аларга кирәкле каеш һәм башка запас частьларның юклыгы хакында сөйләде. Хәлләрнең болай булуы мине куркуга салды, чөнки уракка төшәргә бер ай чамасы гына калып бара иде. Эшләрнең шушы хәлдә икәнлеген Галимҗанов Миңлехәй дә раслады. Бу иптәш икенче тимерче булып эшли, Барый абый нәрсә кушса, шуны үтәргә әзер тора иде. Әлеге утырышта да алар икесе тик бер юнәлештә сөйләделәр. Фермадагы хәлләр дә телгә алынды, күтәрәмгә калган

хайваннарның әле аякка басып бетмәве, шулай да менә инде бер атна яшел үлән чабып алып кайта башлагач, тернәкләнүләре әйтелде. Сыерларның хәле яхшырак, сарыклар шактый ук кырылган иде.

Бригадирлар каты сука эшенең барышы хакында күңелне юатырлык итеп әйттеләр. Чөнки хәзер арыган атлар юк, атлар тазара төште. Алар белән эшләүче малайларның гына хәлсез булуы хакында сүз барды. Бригада егетләре Атау елгасы буенда эшлиләр, атларны көнгә өч-дүрт мәртәбә яртышар сәгать үзәнлектә ашатып алалар, шул вакытта үзләре дә үзәнлектә үскән кузгалак, акбаш белән тукланалар. Атлар, көне буе эшләгәннән соң, кичен төнге көтүгә җибәреләләр иде...

Идарә членнары, колхоз активы белән эшләү шушы көннән башланып китте. Бу утырышта идарә членнарыннан Җәләлиева Һәдия беркетмә язып барды, үзе бер сүз дә сөйләмәде, тыйнаклыгы белән аерылып торды. Әхмәтов Абдулла абый кызып китүчән кеше икәнлеген күрсәтте. Хәтта үзенең фикерләрен әйткәндә, урынында утыра алмыйча, тиз генә торып, йөреп тә килгәләде. Хөснетдинов Лотфулла абый салмак кына, аз гына елмаючан кыяфәт белән, үзенең зур тормыш тәҗрибәсеннән чыгып, киңәшләр биреп утырды. Аны тыңлау миндә ул кешегә карата ихтирам уятты. Киләчәктә дә бу кеше белән киңәшләшкәләргә кирәк булыр дигән фикердә калдым. Ә хатын-кыз бригадирлар үз фикерләрен әйтә алмадылар, кушканны көтеп торган сыман, кулларын кушырып утырдылар.

Бу — минем беренче мәртәбә утырышта председательлек итүем иде. Куркыбрак башладым, андый җыелышлар белән эш итмәгәч, бераз шүрләтә иде. Шулай да, сугышка киткәнче, колхозның комсомол оешмасы секретаре булып эшләгәнлектән, комсомол җыелышлары алып баруда алган тәҗрибәм азмы-күпме ярдәм итте. Гомумән, комсомол тәҗрибәсе миңа нык булышты. Аннан соң, армиягә киткәнче, колхозда секретарь, кассир, баш хисапчы булып эшләгәндә, Сәлим абыйдан утырышларны үткәрү, алып бару буенча алган тәҗрибә дә бар иде миндә. Урып-җыю эшенә яхшы әзерләнү, аны оешкан төстә үткәрү өчен кирәк булган әйберләрнең барысын да эшләп куярга дигән фикергә килеп, беренче утырыштан таралдык. Идарә членнары таралып беткәч, без, Һәдия белән икәү генә калып, колхозның финанс хәлләрен сөйләшеп утырдык. Эш хөрти, банктагы счет ябылмасын өчен, ике счетта да 10—15 сум гына акча тотып торылганлыгы беленгәч, ул сүзне дәвам иттерүнең кирәге булмады. Кенәгәләргә караганда, бер центнер да ашлык юк иде. Чөнки орлыкка дигәне чәчелеп беткән, фуражлык юк. Мин Әтнә райсоюзыннан алып кайткан ике капчык оннан башка, бер нәрсә дә, хәтта бәрәңге дә юк. Завхоз келәтендә эремчек бар иде. Ул эремчекне мәктәп бинасында гомуми туклануга билгеләнгән кешеләргә бирергә куштым. Ферма һәм ат абзарлары янындагы келәтләрдә дә берни юк. Хәзер ничек итеп булса да акча табарга, урып-җыю машиналарын ремонтлау өчен запас частьлар алырга кирәк иде.

Ниһаять, бу көнне дә үткәреп, кичке караңгы төшкәч, өйгә кайтып киттек. Бүген безнең өйдә дә бераз ямь бар. Әни дә сүрелә төшкән, аш та пешкән, Әтнәдә колхозчыларга он сорарга кергәч, райбашкарманың шушы паеклар, икмәк карточкалары белән идарә итүче, безнең авыл кешесе Җәләлетдинов Гыйләҗ абый: «Энем, сиңа колхозныкыннан алырга ярамый, инде үзеңә дә сигез кило он ал»,— дип язу язып бирде. Ул минем үземнең дә хәл кыен икәнне сорашып белгән иде. «Әтиең белән күрешә алмадык, дус кеше иде, бик хөрмәт итә идем үзен»,— дип мине озатып калды. Шунысын да әйтим, колхоз председательләренә вакыт-вакыт районда 10—15 килограмм он биргәли торганнар иде.

Минем менә шундый юл белән алып кайткан арыш оныннан умач уып, аш пешерелгән иде. Әни үзе дә, энекәшләр дә ашны бик яратып ашадылар.

Шул рәвешле бүгенге көнне дә йомгаклап ятып йокладык. Инде без май аенда ук мунчадан чыгып, үзебезнең өйдә тора башладык, өйнең дә аркылысы-буе бишәр метр гына зурлыкта иде. Шулай да монда мунчада торган күк түгел иде инде.

Без барыбыз да тезелешеп сәкедә йоклыйбыз. Стена буенда мин, аннан Фирдәвес, аннан Рубис, аннан иң читтә кечкенә мич буенда әни иде. Өй суыграк булганда, балаларны мич буена сала идек.

23 июнь көнне иртән, әни уятканчы ук, караңгылы-яктылыда, сәгать өчкә торып, каты сукага баручы малайлар янына киттем. Ул Атау елгасы буенда иде. Бу елга авылдан ике чакрым ераклыкта. Сука сукалаучы малайлар атларын шуннан алып, басуга китәләр. Мин өйдән торып чыкканда, күрше малае Габделхәйдәр дә минем белән китте. Без Закир тыкрыгыннан менеп, җил тегермәненә таба атладык. Тегермән янына барып җитсәм, кемдер берәү, бәләкәй генә, ябык кына, кояш чыкканны карап утыра. Әйбәтләбрәк карасам, Хәлиуллин Мансур. «Фәйзерахман малай, мин бик арыдым, әле менә ял итеп утырам»,— ди. Чыннан да бик бетәшкән, күзләре ялт-йолт итеп тора, ул колакка да саграк иде. Мин Мансурны калдырып китә алмадым. «Син, эшли башламас борын ук арыгач, көне буе сука артыннан ничек йөрерсең соң?» — дидем. «Анда була ул, без анда баргач, елга буеннан кузгалак, акбаш җыеп, туйганчы ашыйбыз, тамак туйгач кына эшли башлыйбыз»,— диде Мансур.

Мәгъсүм абыйның утырышта сөйләгәннәре тагын искә төште.

Мансурларның тормышы авыр. Аның әтисе Габдерәфикъ абый да сугыш елларында үлеп киткән иде. Бу семьяда башка җирләргә йөреп ризык табарлык кеше юк. Алар барысы да тырыш, эш эшләп кенә көн итәләр иде. Авыл халкы Мансурның әбисе Сәрвәр апай хакында, бик булган кеше, дип сөйли иде. Элек, колхозлашканчыга кадәр, Сәрвәр апай иртән кырга чыгып, уракны ура, көлтәсен алып кайта, тәпәч белән суга, җилдә суыра, бер пот арышны җилкәсенә күтәреп, ике чакрымдагы Күшәр тегермәненә алып төшеп, тарттырып менгәч, камыр изеп, әчетеп, яңа он белән басып, кичке ашка ипине мичтән пешереп чыгара ала торган булган имеш. Мансурның анасы Фәйрүзә апай да — авылда беренче сыер фермасы төзелгәч, Мәхүп апай белән бергә бозауларны карап, беренче таналарны үстергән кеше. Бу семья белән мин үзем дә яхшы таныш, Мансур белән без малай вакыттан ук дус яшәдек. Аларның өй түрендә генә чана шуа торган идек. Бала вакытта Мансур бик каты авырды, мин аның хәлен белеп тордым. Авырудан ул начар ишетә торган булып калды. Мансурны мин бик хөрмәт итә идем, ничек алай булгандыр, әйтә алмыйм. Югыйсә, минем дус малайларым шактый, ләкин Мансур барыннан да якынрак иде. Ул эчкерсез, хәйләсез, үзенең фикерен яшермичә әйтеп бирүчән, гомумән, чын дус иде. Менә бу дустымны шушы хәлдә күреп кызгандым. Шулай да аның теләге эш ташлау түгел, хәл җыя-җыя булса да сукага бару иде. Мин шул чагында сукачыларга да аш пешерергә кирәк икән дигән фикергә килдем. Икенче көнне алар да кайнар аш ашый башладылар, бу эшкә алар әйтеп бетергесез сөенделәр.

Мансур белән без, сөйләшә-сөйләшә, Атау елгасы буена барып җиткәндә, башка малайлар атларын томырыктан алып, сабан сөрәсе урыннарына менеп баралар иде. Атау елгасы буенда куенлы бер җир бар, әнә шунда атлар томырыкта торган булганнар. Ат караучылар — Нигъмәтуллин Заһидулла абый белән Муллагалиев Мөхәммәтгали абый, төнне атларны көткән булганнар икән. Мансурның атлары шәп атлар түгел. Берсе Батман дигән зур корсаклы ат, икенчесе Матай дигән нечкә сыйраклы кара ат иде. Алар, без килгәндә, башларын селкеп торалар иде — үзләре генә калган. Мөхәммәтгали абый Мансурны: «Азрак

йокларга кирәк»,— дип усал чырай белән каршы алды. Өенә иртәрәк кайтасы килә иде бугай. Мансур атларны сүзсез генә алды, берсенә — үзе, икенчесенә мин атланып, сука җиренә киттек. Малайлар әлегә атларын җикмичә, йөгән балдагын тездән өстәрәк аякларына бәйләп җибәргәннәр, атлар ашап йөри иде, ә малайлар акбаш җыеп, шуны ашап йөриләр иде. Алар, мин килгәч, нишләп эшләмисез, дип шелтәләвемнән шикләнгәннәрдер, ахрысы, тиз генә атларына бара башладылар. Мин ашыкмаска куштым. Аларның кемнәр икәнен карап чыктым: Хәлиуллин Мансур, Ганиев Габдерәкыйп, Ганиев Габделнур, Гыймадиев Гарәфи, Кашшапов Хәйдәр, Заһитов Фәрит, Шәрипов Әхәт, Ганиев Кави, Юсупов Самат. Алар барлык бригадалардан да җыйналып, бу кишәрлекне бетерү өчен кергән булганнар. Шуның белән бер атнадан каты сука бетәргә тиеш икән. Барысы да кечкенә генә битле малайлар, үзләре җитез, эшләргә генә торалар. Алар мине председатель итеп сайлаганда да җыелышта иделәр. Мин аларның сукада икәнлекләрен белә идем, ә басуда эшләүләре белән беренче очрашуым иде. Яшьләр, без бер атнадан пландагы җирне сукалап бетерербез, диделәр.

Бу җирләрдән узып, басуның югары ягына күз салсам, исем китте: өч карама һәм куаклыклар янын, зур карама җирләрен — барысын да әрем баскан. Димәк, алар инде ничә ел буе сөрелми ятканнар.

Фермада мөдир мәшәкатьләре өскә өелгәнгә басу ягына юньләрәтле чыккан да юк, ерак басуда эшләр бармагач, ул якка баруны кирәк дип тә санамый идек. Әнә шул кысыр яткан җирләр җанымны әрнетте. Колхоз басуының өчтән береннән дә артыграк булып чыга түгелме соң болар? Авылга кайткач, идарәдә белештем, чыннан да, 700 гектарның 400 гектары гына эшкәртелә, калганнары гел дә буш ята икән.

Мин колхоз председателе булып эшли башлаган дәвердә кешеләр үзләренә ягулык өчен дип иңбашына күтәреп яки кул арбалары белән шушы буш калган җирләрдән әрем алып кайтып, киптереп куялар иде. Ә кайбер урыннардан, инде башка төрле үләннәр үсә башлаган җирләрдән печән җыялар иде. Ә бит шушы җирләрдә кайчандыр сука сукалап, чәчү чәчеп йөргән кешеләрнең күбесе инде юк, нәкъ менә алар өлешенә тигән җирләр эшкәртелми, алар урынына калган малайлар белән хатын-кызларның моңа көче җитми...

Әнә шундый моңсу уйлар белән әремлек арасыннан авылга таба атладым. Кечкенә карама янына утырып, ял итеп алдым. Чабатамның олтырагы никтер авырттырган кебек тоелган иде, шуны төзәтеп, тузанын кагып, инеш буенда юандым.

Ул арада көн матураеп китте. Мин туктаган урыннан авылга таба арыш басуы башлана, арыш инде баш чыгарган, акрын искән җил белән башаклар башакка бәрелеп чыңлый, сары тузан очып киткәндәй була. Баксаң-күрсәң, арышның өлгергәнрәкләре серкә очыра башлаган икән. Баш өстендә тургайлар моңлана, үлән араларында чикерткәләр сайрый, басу табигатьнең үз табигыйлеге белән матур иде. Матурын матур, миңа аның белән ләззәтләнергә иртәрәк иде. Чабатамны бәйләп, яңадан авылга таба атладым.

Арыш басуы күңелне бик сөендерерлек түгел, шулай да басуда икмәк бар иде.

Кайтышлый бер уңайдан әвеннәрне дә карап чыктым. Әвеннең түбә саламы юк, әмма бәбкәләре, баганалары таза, өстендәге чыбыгы җитәрлек иде әле. «Өстен салам белән яптырасы булыр»,— дип уйлап, тимерчелеккә юл тоттым. Анда Барый абый белән Миңлехәй абый бар иде. Бергәләшеп, тимерчелектәге иген коралларын карап чыктык. Өч бригаданың да лобогрейкалары әзерләнеп бетеп килә икән инде. Платформадагы такталарын гына алыштырасы калган. Тимерчеләр такта юк-

лыктан зарландылар. Аннан ике әвендә эшләү өчен, өч җилгәрү машинасы кирәк иде. Ашлык бер әвеннең ике башында ике атлы машина белән суктырыла иде. Ашлык сугу машиналары да тимерчелек янында тора. Алар да ремонтлана башлаган, шулай да әле аларның эше күп иде. Ике триер, өч «змейка» бар иде, аларны да карап чыктым, аларга күп ремонт кирәк түгел. Иң авыры — җилгәрү машиналарының иләкләре булмавы икән. Колхозчыларның уракларын тешәтә башларбыз инде. Тимерчеләр белән сөйләшкәннән соң сугу һәм урып-җыю машиналарына нинди әйберләр кирәклеге тәмам ачыкланды. Ләкин колхозда акча юк, акча табу мәшәкате алга килеп басты. Шул хакта сөйләшкәннән соң, лобогрейкаларның платформасына һәм әвернәләренә кирәкле тактаны әҗәткә тимерче Барый абый бирде.

Колхоз идарәсенә кайткач, Зарипов Усман абыйдан акча алып торырга булдык. Усман абыйга баргач, ул авырыксынып булса да, бер мең сум (шул вакыттагы исәп белән) акча биреп торды. Аннан Усман абыйның үзен Киров өлкәсе, Рожки шәһәренә ат җиктереп чыгарып җибәрдек. Усман абый, анда элек тә бер барып кайткан булганга, карышмый-нитми китте. Ул кыска буйлы, йөрәкле кеше. Гомумән, аны соңыннан да күп урыннарга әйбер эзләргә җибәрергә туры килгәләде. Ул сугышка кадәр сельпога йомырка җыя иде. Мәзәк сүз дә сөйлиләр иде аның хакында. Алардан әллә ни ерак тормаган, Шайтан Кәриме дигән шаян кеше безне болай дип көлдергән иде. Имеш, беркөнне иртән торып ишегалдына чыкса, капка астыннан тавыклар бәрелә-сугыла килеп кергәннәр дә, келәт артына посып, күзләрен акайтып карап тора башлаганнар. «Нәрсә булды, эт-фәлән куркыттымы әллә?» — дип аптырап торганда, кәрзинен күтәреп, Усман абый килә икән. Ә тавыклар, ул кәрзинне ничек тутырырбыз, дип куркып чабалар икән.

Менә шул кеше бер сугу машинасында барабанчы булып та эшли торган иде.

Мин үземнең бу истәлекләремдә электәге хәлләргә күбрәк тукталырга уйладым. Чөнки сугыш вакытында колхоз председателе булып эшләү авырның да авыры иде. Колхозда бер төрле белгеч тә юк. Колхоз председателе үзе агроном, үзе зоотехник, үзе ветврач, үзе төзүче, үзе экономист, үзе укытучы, үзе тәрбияче, үзе игенче, үзе терлекче иде. Мисал өчен әйтик, безнең Әтнә районында техникум бетергән бер агроном бар иде, ул район җир бүлегенең баш агрономы булып эшләүче Ибәтуллин Габделхәй иде. Туберкулез белән авырганлыктан, ул армиягә китми калган. Орлык лабораториясендә Нурмөхәммәтова Сәрби эшли иде. Бердәнбер ветеринария врачы Сидниев Дмитрий бар иде. Районда башка белгеч юк иде. МТСта тракторлар бик аз, барлык эшләрне дә колхозның үз көче белән үтәргә туры килә иде. Барлык максатлар республика оешмаларыннан алган күрсәтмәләрне тормышка ашыруга юнәлдерелгән иде. КПСС райкомының беренче секретаре Шакиров Сабир исемле иптәш иде. Ул Ютазы ягыннан килгән бер куллы кеше иде, бик кырыс йөзле, көлгәнен беркайчан да күргәнебез булмады. Районда партия дисциплинасы сугыш вакытында йомшарган булган, аңа кадәр беренче секретарь булып эшләгән, шушы районның Ары авылы кешесе Хәсәнов иптәш йомшак холыклы иде. Ул бик авыр чорда, сугыш башланганнан алып өч ел буе беренче секретарь булып эшләгән. Менә шул иптәшне алмаштырып, районга килгәннән соң Шакиров Сабир иң элек партия оешмасының ролен күтәрде, аның белән нык исәпләшә башладылар дип искә ала торганнар иде. Менә шул вакыттан башлап партия оешмасының роле районда бик югары күтәрелде. Ачыграк аңлату өчен, колхозыбызга кагылышлы бер вакыйганы искә алып китәргә кирәк дип саныйм.

Мин эшли башлаган елның икенче елында минем тормышым өчен бик борчулы бер хәл булды. Сугыш елларында җыйналган ашлыкның

13 проценты орлыкка калдырыла торган иде. 15 процентын колхозның эчке кирәкләренә тотарга рөхсәт ителә иде. Шул 15 проценттан колхозчыларга эш көненә бүленә, фуражга-да калдырыла иде. Безнең колхозда ул вакытта 400—500 гектар чамасында бөртекле ашлык игелә иде. Һәр гектардан 6—11 центнерлап (елына карап) уңыш алына. Иген уңышы барысы 3—4 мең центнер җыела иде. Без, шул 15 процент хисабына кертеп, 12 центнер солыны идарә атларына, ерак урманга баручыларга бирергә дип фураж өчен аерып куйган идек. Көннәрдән бер көнне безгә районның милиция начальнигы ярдәмчесе Гарәпшин фамилияле иптәш килә. Ул безгә килгәндә, Сәмигуллин Фәтхулла абый, атка 16 кило солы салып, үлчәргә бара икән. Аны шушы иптәш күреп ала да шундук амбарга пломба салдыра. «Биргән солыларыгызны кире җыйнап алыгыз!» — дип боерды ул миңа. Ерак урманга баручы кешеләр янына киттем. Алар Мари АССР ягындагы урманда эшләү өчен, бер айлык печәннәрен олауга төяп, солыны чананың төбенә үк салып куйганнар. Ул солы атларга бик авыр килгән чакларда гына ашату өчен бирелгән иде. Авыл советы председателе Кави абый белән икебез печән олавын яңадан сүттереп, солы капчыгын күтәреп идарәгә алып килдек. Фәтхулла абый Сәмигуллиннар сүгенә-сүгенә, олауны яңадан төяргә калдылар. Шул сәбәптән иртә таңнан кузгалырга тиешле кешеләр чыгып китә алмаганнар, ни өчен китмәдегез, дип сорагач, Сәмигуллин Фәтхулла абый, бик уңайсызланып, энем, минем аркада булды бу, дип сөйләп китте. Сез килгәнче мин урманга алып бара торган пешкән бәрәңге боламыгын шар күк түгәрәк итеп, катыру өчен тактага тезеп, өй түренә куйган идем. 60 тан артык шарымны, печән төяп ятып, онытып җибәргәнмен, капка төбеннән керсәм, бернichә эт минем бәрәңге боламыгымны ашап бетереп ята. Менә бүген Мәхмүзә апагыз яңадан бәрәңге пешерә, кичкә чыгып китәрбез инде, диде. Аларның барысыннан да бу көнне сорау алып, Гарәпшин җил тегермәненә пломба салды, амбарга пломба салды, ревизия ясатты. Анда үлчәсе әйбер күп түгел иде. Барысын үлчәп бетергәч, амбарчы Галимҗанова Гөлчирәне, тегермән контролеры Хәкимова Равияне, әвен бригадиры Галиев Шәңгәрәйне, бухгалтер Җәләлиева Һадияне сак астына алып, Әтнәгә алып китеп, ябып куйдылар. Аларның өйләренә кереп, тентү ясап чыктылар. Ул вакытта кыш көне әвендә бодай сугалар иде. Әвен бригадиры Шәңгәрәй абыйларда мичкә бер калай җамаяк белән бодай боткасы пешерергә куйган булганнар. Ул аны кесәсенә салып, балаларына ашатырга дип, әвеннән алып төшкәндер инде, аның биш баласы бар иде. Башкаларыннан тентү вакытында бер нәрсә дә таба алмаганнар. Шәңгәрәй абыйның бер җамаяк бодай боткасы идарә өстәленә куелды. Гарәпшин шул җамаякка төбәлеп, мине сүгә башлады: «Син нәрсә карыйсың? Үзең дәүләттән яшереп солы урлагансың, амбардан читкә алып, яшереп куйгансың. Менә яңадан фронтка китә торган бодайдан ботка пешереп ашап симереп яталар...»

Ул мине, ямьсез сүзләр әйтеп, озак хурлады. Күңелемнән бу кешегә рәнҗедем. Гарәпшинны атка утыртып озатып җибәргәч, авыл советы председателе Кави абый белән икебез идарәдә калдык. Шуннан мин бик каты борчыла башладым, бу хакта милиция начальнигы белән сөйләшәсем килде, мине дә гаепләрләр инде, дип уйладым. Бер генә килограмм ашлыкны да рөхсәт ителгәннән артык тотмаганлыгыбызга ышансам да, минем күз алдымда эштә артка калган өчен яки югалтуларыгыз күп, дип тә председательләрне хөкемгә тартканнарын белә идем. Безнең Күшәр авылындагы колхоз председателе Камалов Галәү абыйны ашлык югалткан өчен дип хөкем иттеләр.

Бу төнне мин бер дә йокламадым, борчылып чыктым. Мин тәмәке тартмый идем, армиядән паек итеп биргән тәмәкеләрне алып кайткан идем, шуларны табып алып, тәмәке дә тартып карадым, файдасы ти-

мәде. Гомумән, безнең семьяда зур борчу иде. Әле күпме колхозлардан килгән бухгалтерлар бар, һаман да ревизия ясыйлар иде. Аларның бер нәрсә дә таба алмасларына ышанам, чөнки колхозчыларга дигән икмәкне онлата гына биреп бардык, чөнки урланган ашлык өйләрдә булса табарга мөмкин булыр, дидек. Тентү вакытында да кешеләребезнең ашлык урлау белән шөгыльләнмәгәнлеге ачыкланды, тентүгә мине дә алып йөрделәр. Һәр йортта биш-алты чиләктән дә артык он чыкмады. Әле дә хәтеремдә: Мәүлиев Минһаҗның йортына кергәч, озын тимер таяк белән идән астына төшеп, бәрәңгене тишә-тишә икмәк эзләп йөрүләре. Шулай итеп тикшереп бетерделәр. Ревизорлар материалларны алып, Әтнәгә милиция бүлегенә киттеләр. Шул көнне һәм иртәгесен миңа да хәбәр килер, мине дә алырлар дип, бик борчылып яшәдем. Өч көннән соң, сак астына алынган авылдашларымның хәлен белү өчен, милиция бүлегенә бардым. Башта мине ишегалдына да кертмәделәр. Рөхсәт бирелгәч, иң элек ишегалдында милиция атларын караучы Зәкәрия атлы кешегә кердем. Хәкимова Равия бер тәрәзәдән: «Фәйзи абый, мин монда»,— дип, кычкырып елап җибәрде. Зәкәрия абый мине рөхсәтсез генә булса да Равия белән сөйләштерде. Милиция өенең түбәнге катында колхоз бухгалтеры — бер бүлмәдә, амбарчы Гөлчирә апай — икенче бүлмәдә, алар белән тәрәзәдән сөйләштек. Аннан чиләк тотып чыгып барган җирендә Шәңгәрәй абыйны очраттым.

— Энем, минә безнең хәлләр шушы инде,— диде төссез чырай белән.

Ул суырылып киткән, ябыккан, сакаллары үскән. Ул үзе өчен борчылмый, балаларым ятим кала инде, мин аннан исән-сау кайта алмам инде дип борчыла иде. Чөнки ул сәламәт түгел, бөкре булганы өчен армиягә дә алмаганнар иде үзен. Аның белән дежурный милиционер янында сөйләшеп утырдык. Хәзер фамилиясен белмим, сөйләшсәгез, сөйләшегез, дип, чыгып китте.

Аларны күреп бетергәч, Гарәпшин янына кердем. Ул мине, төбәп карамыйча гына, каршы алды, минем белән сөйләшәсе дә килмәде, тикшереп бетергәч, судка бирәм, диде.

Мәсьәләне хәл итү өчен мин туп-туры райкомга киттем. Чөнки ревизияләр үтте, үзебезнең гаепсез икәнлегебезгә чыннан да ышанган идем инде. Райкомга бик куркып бардым. Секретарь бүлмәсе янына килгәч тә ике мәртәбә кире киттем. Шулай да ярдәмче секретарьга үземнең Сабир абый янына килгәнемне әйтеп, мине кабул итмәс микән, дип сорадым, ул, секретарь яныннан чыккач, миңа керергә кушты. Башта, каушавымнан, фикерләремне төгәл генә әйтә дә алмадым, бераздан, зиһенемне җыеп аңлатып бирдем. Ул мине игътибар белән тыңлады. Соңыннан үзенә генә хас кырыслык белән миңа чыгып торырга кушты. Милиция начальнигы белән аның ярдәмчесе Гарәпшинны безнең делолар белән райкомга чакыртканын белдем. Алар ике сәгать чамасы райкомда утырдылар. Аннан алар чыгып киттеләр, миңа күтәрелеп тә карамадылар. Бераздан райком секретаре: «Сезнең кешеләрегезнең гаебе булмаган, аларның гамәле дөрес»,— диде. Минем киләчәктәге эшемә киңәшләр бирде. «Сезнең кешеләрегезне милициядән чыгарып җибәрерләр, синең атың бармы, аларны алмага шунда бар, утыртып кайтырсың»,— дип, минем белән саубуллашты.

Мин секретарь яныннан җиңеләеп, анадан туган шикелле, дәртләнеп чыгып киттем. «Милиция бүлегенә төшәргә кирәк инде»,— дип уйлап та бетермәдем, күрәм: авылдашларым тезелешеп менеп киләләр. Иң алдан Равия кызу-кызу атлый, бераз баргач, йөгереп тә куя, ул райком бинасына якынлашканда, Һадия белән Гөлчирә апалар таш кибет янына җиткәннәр иде инде. Ә Шәңгәрәй абый Әтнә авылы уртасындагы күперне чыгып, банк бинасы яныннан килә иде. Равия: «Фәйзи абый, безне чыгардылар, председателегез райком бинасында, шу-

ның янына барыгыз дип әйттеләр»,— дип, сөенече эченә сыймыйча, кычкырып җибәрде.

Атны бәйләгән урыныннан чишеп алдым. Гәнгәрәй абый белән мин кашовканың түренә кереп утырдык. Гөлчирә апа белән Һадия алга чүмәштеләр, Равия чананың артында чыгып торган табаннарына басып, кайтырга чыктык.

Кайтканда, ел буе аерылып торган кешеләр кебек, авыл хәлләрен сораша башладылар. Мин аларга авыл хәлләрен дә, райкомдагы әңгәмәне дә бәйнә-бәйнә сөйләп бирдем. Менә миндә, яшь кешедә, гомеремдә онытылмаслык булып, партиягә карата хөрмәт-ихтирам уянды, райком секретаре Сабир абыйның кешелеклелеге, гаделлеге хакында юл буе уйлап кайттым.

Шуннан соң миңа райком секретарьлары белән байтак эшләргә туры килде. Мин аларны Сабир абый белән чагыштыра торган булдым.

Озак еллар колхоз җитәкчесе булу дәверендә миңа төрле-төрле холыктагы кешеләр белән очрашырга туры килде. Райбашкарма председателе булып Нурулла абый Зарипов эшли иде. Нурулла абый бик гадел кеше, колхозларга чыкканда сумкасына үзенең ризыгын салып йөри торган иде. Безнең колхозга килгәч тә сумкасыннан алып, уртасына май сылап каплаган ике сынык ипине ашап утырганын хәтерлим.

Озакламый мине район советы сессиясенә чакырдылар. Бу сессиядә кичергәннәрем күңелемдә әле дә саклана. Чөнки район күләмендәге зур җыелышларда беренче мәртәбә катнашуым. Көн тәртибенә урып-җыюга әзерлек мәсьәләләре куелган иде. Бу сессиядә райбашкарма председателе Зарипов Нурулла абый озак итеп доклад ясады. Миңа, яшь кешегә, ул чамадан тыш озын булып тоелды. Шуннан соң депутатлар сөйли башлады. Күбесе үзләренең ниләр эшләвенә хисап бирде. Миндә баштарак булган киеренкелек, кешеләр сөйли башлагач, бетә барды. Ахырдан райкомның беренче секретаре иптәш Шакиров чыкты. Ул салмак кына итеп, төгәл-төгәл генә итеп фикерләрен әйтте. «Үскән игенне җыеп алу, дәүләт алдындагы планны үтәү белән без илебезгә басып кергән ерткыч фашистларны җиңүне якынлаштырырбыз»,— дип сүзен бетерде. Шуның өчен барыбызның да тырышып эшләвебезне таләп итте. Сессиягә без авыл советы председателе Кави абый Галиев белән барган идек. Кайтканда үзебезнең колхоз алдында торган бурычлар хакында сөйләштек. Печән өсте җитеп килә иде, хатын-кызларга чалгы тотарга булышырга, чалгыларны кайрап торучы картларны эшкә җигәргә кирәк. Ул көнне соң гына кайтып җиттек. Без кайтканда, бригадирлар нәрәт көтеп утыралар иде инде.

Колхозда эшне алып бару, төрле кампанияләрне башлап җибәрү шушы нәрәттә билгеле була торган иде. Мин берничә колхоз председателенең җитәкчелек итү ысулларын күреп белә идем. Алар арасында Сәлим абый Әхмәтов эшне алып баруы, нәрәтләрне алдан яхшылап уйлавы, идарә утырышларын мәгънәле итеп үткәрә белүе белән минем өчен үрнәк булып тора иде. Сәлим абыйда барлык бригадаларны, колхозчыларны ышандыру, тыңлата алу сәләте бар иде. Тәҗрибәм булмаганлыктан, мин үземә кадәрге председательләрнең уңай сыйфатларына карап, шуңа нигезләнеп эш башлап җибәрдем. Һәм моның дөреслегенә аеруча ышандым. Әгәр өлкәннәр тәҗрибәсенә таянмасам, ихтимал, мин байтак ялгышлар җибәргән булыр идем.

Сәлим абыйга охшарга тырышып, мин нәрәт бирү тәртибен бер журналга яза барам, анда өч бригадага өч графа ясыйм, бит буенча түбәнгә эш төрләрен, ничә кеше, ничә ат катнашырга тиешлеген теркәп куям. Икенче көнне һәр бригаданың үзенә бирелгән эшне ничек үтәвен кичке нәрәт вакытында кабат тикшерәм.

Сәлим абый нәрәт биргән кенәгәне чиста-пөхтә саклый, ел буена

ничәмә-ничә мәртәбә тотылуына карамастан, бу кеңәгә бер дә керләнми, таушалмый иде.

Сугыш алды елларында, колхозда эшләп алган икмәкләренең артыгын дәүләткә саттыру өчен кешеләр белән сөйләшеп, икмәк әзерләү гадәте бар иде. Менә шушы вакытта Сәлим абый иң беренче булып үзе кул куя торган иде. Үзенә авыррак килсә дә, башкаларга үрнәк булсын өчен, ул күбрәк сатарга тырыша иде.

Сәлим абыйның гаделлеге, янып-көеп йөрүе, партиялелеге, авылның беренче коммунистларыннан берсе булуы миңа җитәкчелек эшендә шактый зур ярдәм итте. Нәрәт биргәндә дә, кешеләр белән сөйләшкәндә дә, бу очракта Сәлим абый нишләр иде икән, дигән фикер минем уема гел килеп торды. Колхозчыларның гомуми җыелышында, ел азагында хисап биргәндә, ел буена башкарган эшләр онытылып китә. Ә шул вакытта нәрәт кенәгәсенә бер күз төшерү дә колхозның кайчан, ни башкарганлыгын, бригадирларның нәрәтне ничек үтәтүен ачыкларга мөмкинлек бирә, журналны уку белән һәммәсе күзгедәге кебек күренә. Менә шулай итеп, мин аз-азлап председательлеккә өйрәнә башладым. Һәр кешенең, тармак җитәкчеләренең эшен төгәл исәпкә алып бару, гомуми сүз сөйләмичә, конкрет таләп кую миндә шушы үрнәктә формалаша башлады. Җитәкчелектә, бүген булмаса — иртәгә, дип юану — иң начар гадәт. Менә шул «иртәгә» харап итә дә инде. Авыл хуҗалыгында бүгенге эшне иртәгә калдырырга ярамаганлыгына үз тәҗрибәмдә йөз мәртәбә ышандым мин. Чөнки авыл хуҗалыгында иң мөһиме — эшнең үз вакытында үтәлүе. Әйтик, чәчүдә соңга калу — уңышның кимүе, уракта соңга калу — өлгергән ашлыкны әрәм итү дигән сүз.

Бер көнлек нәрәтне мисалга алыйк. Буш калган җирләрдән һәм көтү керә алмаган елга башындагы җирләрдән үләннәрне чабып, силос салуны планлаштырдык. Силосны камыш үсә торган дымлы, сулы урыннардан салам таяклары белән чыгарырга кирәк. Ат җигүче малайлар печәнне ташырга тиеш. Хатын-кызларны чабарга чыгару күздә тотылды. Печәнгә беренче июль көнне төшәргә булдык. Миңа кадәр эшләгән председатель Сәлим абый һәр елны беренче июльдә печән чабуны башлый торган булган. Печәнгә төшкәнче, кешеләрне җыйнап, җыелыш үткәрергә дигән фикер туды. Төрле мәшәкатьләр белән ул көн килеп тә җитте. Ә миңа, тәҗрибәсез яшь председательгә, колхозчылар алдына чыгып, бурычлар куярга кирәк. Нәрсә сөйләргә, ничек сөйләргә икәнне көне-төне уйлап йөрдем, сүзләрем әзер иде, әмма халык алдына чыккач, бик дулкынландым. Менә шушы дулкынлану минем күңелемәнык сеңеп калган. Соңгы елларда да колхозчылар җыелышына ныклап әзерләнәбез, хәзер дә дулкынлану көчле. Халык бит — председатель өчен түгел, председатель халык өчен эшли. Сүзебез дәлилле, кыска, төгәл булса гына кабул күрә халык.

Җыелышны иртәнге дүрттә үткәрергә планлаштырган идек, иртәнге өчтә үк йокыдан торып, урам буйлап түбән төшә башлаганга, авыл көтүен көтүче Фәтхулла абзый үзенә генә хас бер тавыш белән: «Чыгарыгыз, чыгарыгыз!» — дип сузып-сузып кычкырып килә иде. Фәтхулла абзый мине күргәч, хайваннарга ашатырга Өҗмән елгасы буенда үлән бетүе хакында зарланып алды. «Зиярәт артыннан җир бүлеп булмас микән, анда кеше эштән кайтканны карап торырга да уңай, кеше кайтмыйча, көтүне кайтарырга ярамас ич инде»,— дип сөйләнде.

Ул арада капкалардан сыерлар, сарыклар чыга башлады. Сыерлар мөгрәп, берсен-берсе иснәшәләр, кайберләре агачларга ышкына. Яңа гына йокыдан торган яшь киленнәр, япь-яшь тол хатыннар ялан аякларына юкә башмак кигән көенчә, сыер-сарыкларын чыгарып җибәреп, карап калалар иде. Фәтхулла абзый артыннан ук казларын көтүгә

куа баралар, бу эшне күбесенчә балалар, карчыклар башкара. Менә шул көннән башлап мин төне буе тып-тын торган авылның иртән иртүк уянуына шаһит булып яшәдем.

Авыл уянганда, аның матурлыгы төн караңгылыгыннан калкып чыккан кебек. Озак та үтмәде, авыл урамында чалгы тапаган тавышлар ишетелә башлады. Яшь председатель, колхозчылар белән очрашу өчен, күңеленнән үтемле сүзләр эзли-эзли, авыл урамыннан атлады. Җыелышның урыны авылның түбән башындагы зиярәт буена билгеләнгән иде. Ул арада миңа Габдрахман абый, Галиәкбәр Фәйзие, Зыя Шакиры иярде. Алар чалгы тапарга кирәкле сандалларын алып килгәннәр иде. Озак та узмады, дүртенче яртыда печән чабучы хатын-кызлар да килә башлады. Иң элек Әхмәтова Файзә, Шагалиева Фатыйма, Дәүләтгәрәева Зарифа апалар килде. Алар белән бераз сөйләшеп утырдык. Кешеләр җыелып беткәч, мин эшне ничек башлау, районның безнең алга куйган бурычлары хакында сөйләдем. Звеноларга бүленеп эшләү тәртибе кирәкләгенен әйттем, күңелегезгә ошаган кешеләр белән үзегез сөйләшегез, дидем. Чөнки төрле кешенең сәләте төрлечә була, аны исәпкә алмыйча һич мөмкин түгел. Печәнчеләргә, 10 сотый чапкан саен, 100 әр грамм он бирелеп барылачагы әйтелде. Чалгыларны төзәтеп, тапап тору өчен билгеләнгән кешеләр белән таныштырдык. Бригадаларга печәнлек инде бүленеп куелган иде. Таяк тотышканнан соң авылга иң якында — Мәгъсүм абыйның беренче бригадасы, ат чыга торган җирләрдә — өченче бригада, Мәймүнә апай — яңа урам; иң еракта — икенче бригада, Рәхимә бригадасы эшләргә тиеш булып калды. Болында ашарга пешереп тормаслар, кулга бирерсез, диделәр. Оннан балаларына да өлеш чыгарырга телиләр иде. Бу чорда инде Әтнә авылының бер кешесеннән әҗәткә биш пот он алып кайткан идек. Шуның өстенә районнан биш центнер он биргәннәр иде. Менә шушы байлык белән без печән чабарга керештек.

Җыелышта мин бик дулкынланып, каушап булса да сөйләп бетереп, үз фикерләремне әйткәч: «Сездә нинди фикерләр бар, кемнәр сөйләргә тели?» — дип сорагач, Таҗиева Гөләндәм апа урыныннан сикереп торды.

— Звено булып чабарга дидегез, мин кеше белән чапмыйм,— диде. Ул авылда кырыслыгы һәм эшчәнлеге белән аерылып тора иде. Кая куйсаң да, нинди эш тапшырсаң да, ул һәммә кешедән яхшырак эшли. Беренчеләрдән булып ул ат җигеп капчык ташый, сугу вакыты җитсә, ашлык суктыру машинасында барабанчы булып тора иде. Менә печән чабуда да ул үзе генә эшләргә уйлады. Аңа каршы килмәдек. Гатауллина Шәрифә, Галләмова Майсәрә, Шагалиева Фатыйма, Әхмәтова Файзә икешәрләп бергә чабарга уйладылар. «Печән чапканда, ашауны яхшыртсагыз, әйбәт булыр иде»,— диделәр. Шуннан без аларга бер мәртәбә итле аш пешерергә дигән фикергә килдек. Кеше саен бер йөз граммнан ит салып аш пешерә башладык. Ун сотый чапкан өчен тиешле онны да ала бардылар.

Бу көннәрдә мин печән чабучылар янында булырга тырыштым. Җыелыш барган җирдән ике йөз метрлар арырак Шәрифә апа Гатауллина, Майсәрә апа Галләмова селтәнеп-селтәнеп чабарга керештеләр. Аларның утыз-утыз биш яшьлек вакытлары иде. Печән чабу кешедән көч-җегәр таләп итә. Шәрифә апаларның печән чабуына килгән саен, сокланып карап тора идем. Адымнарын киң алдырып, ир-егетләрчә селтәнүләре әле дә күз алдымда. Алар бу бригадада иң яхшы, иң күп эшләүчеләр иде.

Өченче бригадада беренче булып Гөләндәм апага юлыктым, ул басу буеннан Ашытка таба беренче пакусын чыгып килә иде. Ул, Шәрифә апаларга караганда, кызурак бара, чалгысы да зур, ә үзе гәүдәгә алар-

дан кечерәк иде. Бригаданың башка хатын-кызлары янында да булдым, кайберләренең чалгыларын янап бирдем. «Яшь кенә булсаң да, яный беләсең, әйбәт булып китте әле»,— дип мактап, минем күңелне дә күтәрделәр.

Казак тугае дигән җирдән узып, икенче бригадага килдем. Монда Файзә апа Әхмәтова белән Фатыйма апа Шагалиева, нәкъ Шәрифә апайлар шикелле, киң-киң алдырып чабалар иде. Көч-куәтләре дә пакуслары киңлегеннән күренеп тора. Алардан ерак кына түгел Гайшә апа Габдрахманова белән Марзия апа Абдуллина чаба, алар да яхшы эшләүчеләр рәтенә чыкканнар иде.

Бригада саен унбиш-егерме хатын-кыз болынга төшкән, исләрең китәрлек! Сугышка кадәр чалгы дигән нәрсәне тотып та карамаган, ирләре чапкан печәнне тырма белән кабартып кына, иркә, кадерле хатыннар булып кына яшәгән, ирләренә матур-матур балалар табып, аларны сөендереп, алар эштән кайтышка тәмле ашлар пешереп, аларны хатын-кызларга гына хас булганча назлап яшәгән яшь-яшь хатын-кызлар, зур-зур чабаталар киеп, кайвакыт аларны салып ташлап, яланаяк килеш печән чабалар! Дөньяга бары тик нәфислек өчен генә яратылган хатын-кызны дәһшәтле сугыш нинди авыр эшләргә өйрәтте! Кырык-иллеләп хатын-кыз, күбесе — солдат хатыны, 120 гектарлы Түбән Шашы болынын чабып чыкты. Кеше саен сезонга өч-дүрт гектар җир чабып бардылар. Гөләндәм апаның 70 сотыйга кадәр чапкан көннәре булды. 30—35 сотый гадәти норма иде.

Чалгы тотарга сәләтсезләр, үсмерләр, олырак яшьтәге апалар печәнне кабартып тордылар. Чабу беткәч, таза, көчле хатын-кызлар кулларына сәнәк тотып чүмәлә өйде, эскерт салды. Чүмәләләрне яшүсмер малайлар сыер-үгезләр белән эскерт янына ташый. Сыер, үгез җигү, аларны тыңлату аеруча кыен иде. Шулай бер көнне чүмәлә тарттыручы Әдһәмнең сыеры, чүмәләсен таккан килеш, су эчәргә, Ашыт суына төште дә китте. Су эчте-эчте дә суга ятты. Малай елый башлады. Эскерт салучы хатын-кызлар сыерны көч-хәл белән чыгарып бирделәр. Мондый очраклар күп була, арбага җигелгән сыер, күпер янына килеп җитүгә, инеш буена төшеп китә дә, арба аны артыннан этеп, тирәнгә кертә, тиз генә туарып алмасаң, сыер тончыга, бата торган иде.

Шушындый авырлыклар булуга да карамастан, печәнгә матур киемнәрен киеп төшәләр: чабата — тугыз юкәле, оекбашлар нечкә итеп ап-ак йоннан бәйләнгән була иде. Кыскасы, сугышка кадәрге гадәт буенча печән өстен бәйрәм кебек каршы ала торганнар иде.

Авыл халкы элек печән өстенә алдан ук хәзерләнә, егетләр гармун уйнап, җыр җырлап, атларга төялеп, чалгыларын кулларына тотып, хатыннары ирләре белән янәшә утырып, урам әйләнеп йөри торганнар иде. Сугыш вакытында гармун уйнап йөрүләр булмады, гармунчылар сугышка китеп беткән иде. Ә матур киенеп бәйрәмчә йөрү кешенең канына сеңгән бит ул. Шулай да печән өстендә, бик нык кызып эшләгән вакытта, мин, яшь кеше бит инде, уйлап бетермичә, Галимҗанов Миңлехәйне болынга гармун белән төшүен үтендем, ул мине тыңлады. Тимерчелек эшләмәгәндә, кешеләр белән бергә атка утырып, Миңлехәй абый гармун уйнап узды. Кешеләрне сугышка озатканнан соң бу беренче мәртәбә гармун тавышы чыгару иде. Авылда эшкә бара алмый калган карчыклар белән бала-чага урамга чыгып, печәнчеләрне озатып калдылар. Балалар авылны чыкканчы озаттылар. Печәнлеккә җиткәнче без алдан бардык, аңа-моңа игътибар итмәдек. Әлеге гармун тавышы кешеләрнең күбесен сагышка салды. Ирләре сугышта үлгән хатыннар бик каты дулкынланып, үксе-үксе еладылар. Яшьли тол калган авылдашларын кызганып, алар белән эшләүчеләр дә елады. Шулай итеп, мин уйламастан, хәсрәтне арттыруга сәбәпче булдым.

Шулай да моңсу тойгыларга бирелеп, елашып кына утырмадылар, йөрәксенеп эшләделәр. Хатын-кызлар печән беткән көнне: «Миңлехәйне чакыр әле, энем, болыннарны яңгыратып бер уйнасын әле, ирләребезнең шушы хәтфә болыннарда йөргән чакларын искә төшереп алыйк әле, безнең елаганга карама син»,— дип үзләре үтенделәр.

Печәнне чабып, җыеп, эскертләргә салып куйдык. Шаулап торган болын чоп-чуар печән эскертләре белән тулды. Чаба башлаганчы болын үзенең чәчәкләре белән матур иде. Ә менә эскертләү вакыты җиткәч, печәннең күп икәнен күргән крестьян күңеленә шатлык тулды. Мин дә беренче зур эшнең нәтиҗәсен күреп шатландым. Күңел бик тулган иде. Миңлехәй гармунын күтәреп килде, төштән соң печән эше беткәч, сәнәкләрне, тырмаларны җыйнап, барыбыз бергә Ашыт елгасына су коенырга киттек. Ир затлары, малайлар — бер җирдә, үсмер кызлар — икенче якта, олырак киленнәр, хатын-кызлар башка урында коендылар. Болын шаулап торды, алар берсен-берсе батыргалап та шаяргаладылар. Хатын-кызның чинап, чырылдап кычкырган тавышлары әллә каян ишетелә иде. Озаклап су коенганнан соң, бөтен колхоз Ашыт буена җыелып, гармун уйнаганны тыңладык. Миңлехәй абый бик матур итеп халык көйләрен уйнады.

Кызлар гармунга кушылып җырлады, мин дә җырладым. Бераздан хатыннар да җырлады. Җырлар күз яшьләре белән катнаш иде, ирләренең үлү хәбәрен алган хатыннар гел күзләрен сөртеп утырдылар.

Тыңлаучыларга Гани абый кызы Нәсимә җыры бик ошады. Ул өмә җырын моңлы итеп, барлык бармалары белән җырлады, аны бөтен халык ихлас күңелдән тыңлады. Күп җырлар тыңлап, күп вакыйгалар турында сөйләшеп, кичкырын гына олауларга төялеп кайтып киттек...

Көннәр узды. Сугыш барган яклардан безнең солдатларыбызның дошманны кысрыклавы хакында хәбәрләр килеп торды. Сугышның җиңү белән бетәчәгенә кешеләрдә зур ышаныч ныгыды. Халык өмет белән яши башлады.

Авыл халкы печән эшен бетергәч, иртәгесен ял итәргә тиеш иде. Мин аларга ул хакта болында хәбәр иткән идем. Кешеләр мунча ягып, балаларын тәртипкә кертеп, урып-җыйнау эшенә әзерләнә башладылар. Мин дә чиста киемнәремне киеп, кич урамга чыктым. Идарә бинасы янына килсәм, Гыйбадуллина Мәдинәләр капка төбендә бер төркем кыз кич утыра. Анда Мәдинә, Фоадия, Нәсимә бар. Күпергә җиткәндә үк мин аларның көлешкән тавышларын ишеттем. Башка урамнарда да яшьләрнең капка төбендә кич утырганлыклары, көлүләре ишетелә иде. Ул да түгел, Пләтән урамыннан бер төркем яшьләр, мәктәп ишегалдына килеп, уен уйнап, җырлап җибәрделәр. Мәдинәләр белән бергәләп мәктәп ишегалдына бардык. Уен ике сәгать чамасы дәвам итте. Яшьләр төрле уеннар уйнадылар, миңа да катнашырга туры килде. Яшьләр тарала башлагач, без Мәдинәләр капка төбендә Мәдинә, Фоадия, Нәсимә белән бергә озак кына кич утырдык. Авылның ул көнге төне бик матур иде. Мин армиягә киткәнче булган вакыйгалар турында сөйләштек. Кышкы кичләрдә кызлар җыелып утырган аулак өйләрдәге төрле уеннарны, нинди җырлар җырлаганны искә төшердек. Төрле-төрле вакыйгаларны да күңелдән уздырдык. Нәсимә: «Таң ата башлады, әни ачуланыр инде»,— дигәч, дүртебез дә кайтып киттек.

Яшьлек — яшьлек инде ул, сугыш дип тә тормый, авыр дип тә тормый, үзенчә яши. Авылның җәйге, матур кичләрдә, капка төбендә утыру кебек матур бер гадәте бар. Соңыннан, үзләренең яшьләренә карап, уен оештыра торганнар иде. Олырак кызлар-егетләр мәктәп ишегалдында, үсмерләр кибет тавы башында. Сугышка кадәр безнең авылда клуб юк иде, концерт булса, үзешчән коллектив театр куйса яки кино күрсәтсәләр, мәктәп бинасына җыела торган идек. Кызлар, ата-анала-

ры кунакка киткән чакта дус кызларын җыеп, үзләрендә кич утыру үткәрә торганнар иде. Ә авыл яшьләре аларны белә. Чөнки аулак өйнең кызы үзенең дус кызларына әйтеп, дусларының дусларына ишеттереп, хәбәр шундук бөтен авылга тарала торган иде. Без дә яшьлегебезне авылда сакланган шул тәртип буенча үткәрдек. Авыл яшьләре аулак өйләрдә төрле уеннар уйнап, җырлап утыра иделәр. Бу — әхлакый саф, рухи матур кичләр иде. Яшьләр бер-берсен якыннан белеп, күреп үсәләр иде. Шулай да аулак өйләр сирәк була, шуңа күрә төрле буш өйләрендә уку йорты ясап, китап укырга йөри торганнар иде. Клуб салабыз дип, мәчет бинасын сүткәннәр дә иде, сугыш башлангач ул эш ярты юлда торып калды.

Сугыш чыкканда бала гына булганнар өч ел эчендә 17 яшькә житеп, Күнгәр авылына, клублы авылга киногa йөри башладылар. Безнең авыл кызлары Мәдинә, Фоадия, Нәсимә төрле авылларда укытучы булып, яшьләрнең уеннарын оештырып йөри иделәр.

Печән эшен уңышлы тәмамлау бик әйбәт булды. Колхозчылар шул дәрт белән урып-җыюга керешеп киттеләр. Иң элек Дусым авылы янындагы Тузлы имән җире дигән урынга чыктык. Арыш ул вакыт өчен уртача гына уңган иде. Кешеләр, уракка чыгу белән, башак уып, озак кына арыш ашадылар. Ул вакытта арыш ашау бик көчле иде. Басудагы хатын-кызлар ялга утырган саен, учларында арыш башагы уып, тамак ялгап ала торганнар иде. Печән чапкан вакытта алъяпкычларын кирегә әйләндереп, билгә бәйләп куеп, чабып барган урыннарында очраган ат кузгалакларын шунда салып барып, кичен колхоз биргән он белән бергә балаларына аш пешерәләр иде, менә хәзер арыш өлгергәч, авылның барлык балалары арыш басуында арыш уып ашый торган булдылар. Алар арыш арасына кереп утырып, арыш җирен таптый да торганнар иде. Без, җитәкчеләр, баштарак аларны күрмәмешкә салындык. Шулай да, күлмәк чабуларына салып арыш алып кайтулары сизелгәч, балаларны бераз куркытырга туры килде. Ул арада борчак кузагы күренә башлады. Монысы бигрәк куркыныч булып китте. Борчак җиренә йөзәр бала җыйналып, эченә үк кереп, игенне нык кына таптыйлар. Борчак мәйданы зур да түгел, 25—30 гектар чамасы гына иде. Борчак җирен саклау өчен каравылчы куярга мәҗбүр булдык. Малайлар бездән дә хәйләкәррәк икән. Алар Дусым авылы буендагы елга инкеленнән килеп, каравылчы юк җирдән ашый башлаганнар. Бер көнне шулай атка атланып басуларны карарга дип чыксам, борчак җирендә — көтүе белән бала-чага.

Һәр чорның үз авырлыгы булган шикелле, сугыш елларында басудагы игеннәрне саклау авыр иде. Борчак басуыннан әллә ни уңыш җыелмады. Кузакларның күбесе балалар тарафыннан ашалган була, өстәвенә — таптаган җиргә тилә төшеп аптырата иде. Борчак сабагын таптасаң, аңардан баллы сыекча чыгып, тилә тиз үрчи икән. Болай да юк уңыш, гектарыннан өч центнерга гына калды.

Басудагы игеннәр башта урак белән генә урылды, өч-дүрт көннән лобогрейкалар белән чыктык. Монда ат белән яшүсмер малайлар идарә итә, ә учмаларны платформадан хатын-кызлар ике япьле агач сәнәк белән төшерә иде. Лобогрейка белән уруда Ганиев Кавый, Ганиев Габдеррәкыйп, Шәрипов Әхәт, Хаҗиев Равил, Васильев Нурмөхәммәт, Газизова Асия, Абдуллина Мәрзия, Габдрахманова Әминә, Газизова Фатиха, Фаяз абыйларның катнашканнары хәтеремдә. Урак уру — авыр эш. Лобогрейка белән урылган учмаларны көлтә итеп бәйләп, чүмәләләргә сала барырга кирәк. Колхозның иң уңган киленнәре һәм кызлары башкара иде бу эшне. Иртән сәгать өчтән эш башланып, караңгы төшкәнче басуда була иде хатын-кыз. Көндез аларга да кайнар аш пешерә башладык. Көндез алар чүмәлә төбендә ял итеп алалар. Кайбер-

ләре хәтта ял да итмичә, тамак ялгауга янә эшкә тотына торганнар иде. Күненә берәр мең көлтә бәйләүчеләрне дә күрдем. Ә 500—600 көлтә бәйләү гадәти хәл иде. Урак белән уру нормасы 12—15 сотый иде, шуңа карамастан, 20—30 сотый уручы хатын-кызлар була торган иде. Урак эше көзнең соңгы көннәренә кадәр бара. Бераз ургач, кешеләрне әвендә эшләү өчен кайтарырга туры килә иде. Башта ике атлы перевод белән сугабыз, басуда эшләр җиңеләя төшкәч, алты атлы суктыру машинасын да эшләтә башлый идек. Ә орлыклар агач ыстаннарда, тәпәч белән сугалар иде. Кичен, суккан ашлыкны көрәк белән чөеп, җилгәреп, келәткә тапшыралар. Тәпәч белән сугудан калган көлтәне малайлар арбага төяп, сыер җигеп, суга манып, көлтә бәйләү өчен сабан ашлыгы урган җиргә ташыйлар. Басуда, көлтә бәйләүче хатын-кызлар янында, камыл эчендә яшь балалар йөри, чүмәлә төбендә, көлтәләр арасында сабыйлар йоклап ята. Аналар, ерак басудан кайтып-китеп йөрү авыр булганлыктан, имчәк балаларын үзләре белән ала, аны карау өчен олырак балаларын да ияртә торганнар иде.

Председатель булып эшләгәндә, төрле елларда күп төрле вакыйгаларга очрый идем. Шулай бер вакыт, мин басуда чакта, яңгыр ява башлады. Чүмәлә төбенә кереп, яңгырдан ышыкланып торырга туры килде. Икенче чүмәләдә бер хатын-кыз кечкенә арба тирәсендә маташа. Карасам, Гайшә апа Габдрахманова, арбада яткан баласын көлтә белән ябып маташа, алай гына булмагач, үзе арбага йөзтүбән ятты да, балага су төшермәс өчен, гәүдәсе белән каплады... Яңгыр һаман туктамый, апа манма су булды. Мин, аны кызганып, янына килдем. Көлтәләрне өеп, куыш ясап бирдем. Гайшә апа баласын алып, шул куышка кереп утырды. Гайшә апаның ул улы Фирдинант хәзер шәһәрдә эшли. Әнисенең аны җил-яңгырдан ничек саклаганын ул беләме икән?! Фирдинантны күргән саен, мин шул вакыйганы искә төшерәм. Фирдинант әнисенә карата начарлык эшләсә, эчеп-исереп йөрсә, күңел рәнҗер иде. Шөкер, алар, Гайшә апаның олыгайган көнендә матур яшиләр. Гайшә апа килене белән бик тату, оныкларын үстерә.

Мондый мисалларны күпләп китерергә булыр иде. Сугыш вакытында тол калган аналар сабый балаларын барысы да менә шулай күз карасы кебек саклап, тәрбияләп үстерделәр.

Әвендә сугу эшендә, берсендә — Усман абый Зарипов, икенчесендә — Гөләндәм апа Таҗиева, өченчесендә Галимҗанова Галия эшләде. Җилгәргечләрне көне буе кул белән әйләндерәләр иде. Хатын-кызларның куллары ойый, бармаклары кабара, сытылып сулар чыга иде.

Җилгәргечтә эшләгән вакытта, әни, өйгә кайтып, аш пешереп ашый башлагач, әллә нишләде. Тәлинкәдән ашын ала да алдына сала, ала да алдына сала, үзе авызын ачып тора. Мин бик аптырап:

— Әни, нишләп син ашыңны алдыңа саласың?— дип дәшкән идем, сискәнеп башын күтәрде. Ул йоклап киткән булган икән.

Авылыбызның барлык хатын-кызлары да менә шулай эшләделәр. Көлтә бәйләүдә, лобогрейкада эшләүчеләр, өйгә кайткач ашарга да утыра алмыйча, бусаганы атлауга, юынмыйча-нитмичә егыла торганнар иде. Арыш суга башлау белән көзге чәчүгә тотынабыз. Бригада саен берәр чәчү машинасы, икешәр кеше тубал белән кырга чыкты. Василов Садыйк абый бер көнне җиде гектар җир чәчте. Ә Ганиев Кавилар чәчү машиналары белән 10 гектар җир чәчә алдылар. Көзге чәчү эше бик озакка сузылды, соңгылары хәтта тишелеп тә өлгермәде, сыерлар бик акрын йөргәнлектән орлыклар күмелеп бетмичә өстә кала иде.

Эш бик тыгыз, уру-сугу да, көзге чәчү дә, бәрәңге алу да — барысы бергә барды. Бәрәңге мәйданы болай зур да түгел, 25 гектар гына иде. Шулай да бу эш белән бик соңга кадәр шөгыльләнергә туры килде. Кайбер көннәрне туң туфракны ватып булса да бәрәңгене алып бетердек. Яңа ел алдыннан, бик зур авырлык белән, сугу эшен дә төгәллә-

тек. Дәүләткә дигән икмәкне Корткачык станциясенә атлар белән ташыдык. Атларның сугу машинасына бирелгәннән калганнары барысы да икмәк чыгаруда иде. Сигез-ун ат көн саен йөреп торды. Әтнәдә глубинка бар иде, Арча заготзерносының бер пункты иде ул, сыерлар, үгезләр ашлыкны шунда ташыды, соңга таба Күшәр авылында, аннан да соңрак Күнгәр авылында амбарларга ташып куярга туры килде. Глубинкаларга салган ашлык атларны, сыерларны кирәгенчә файдалану мөмкинлеге бирде. Дәүләткә ашлык тапшыру, транспорт җитмәүдән бигрәк, киптерү аркасында озакка сузыла иде. Җәй айларында кояшта, ындыр табакларында киптереп була, яңгырлы көннәрдә дымлы ашлыкны сушилкаларда киптерергә туры килә. Аның кырыенда саманнан салынган мич башы сушилкасы бар иде. Мин шул сушилканы көнен-төнен эшләтә торган идек. Анда Сибгатуллина Шәһәрбану, Әхмәтова Хәерниса апалар эшләде. Колхоз активы көне-төне дежур торды. Мин дә төннәрен күп мәртәбә шунда дежур булдым. Сушилкаларга ягу өчен утын җитмәү өстәмә уңайсызлыклар китереп чыгара иде. Салам яктык, буш калган басулардагы әремне җыеп яктык, иске каралтыларны сүтеп-сүтеп яктык. Безнең колхозның саман кирпечтән салынган сыер абзары җимерелгән иде. Беренче ел уңышын киптерергә дип, шуның агач әйберләрен җыйнап куйган идек. Мин шуны ягып бетердек. Урманга барып утын алып кайтыр мөмкинлек юк иде. Ашлык тапшыру заданиеләрен менә шундый шартларда үтәп бардык. Игелгән икмәкнең 13 проценты — орлыкка, 15 проценты эчке кирәкләргә тотылды. Колхозчыларга онлата бирдек. Халык бик сөенде.

Игеннәрне урып-җыю башлану белән колхозчыларның ашау-эчүләре көйләнеп китте. Хуҗалык бакчаларында яңа бәрәңге җитеште. Печән чапкан вакытта бер мәртәбә кайнар аш ашату, эшләгән өчен 10 сотыйга 100 грамм хисабыннан он бирү, ярдәмгә мохтаҗ булган семьяларга мәктәп бинасында пешерә торган ашлар кешеләрнең рухын күтәрде.

Колхозыбызда эшләрнең җайга салына баруы минем дә җитәкче була алуыма ышаныч тудырды. Баштарак нык икеләнгән идем, чөнки көн саен миңа гына бәйле булмаган мәшәкатьләр чыгып тора, әледән-әле фронттан авылдашларыбызның үлгән хәбәре килә иде.

Кышка кергәч, үгезләр җигеп, Мари урманыннан утын әзерли башладык. Урман чанасына җигәрлек ат дирбиясы юк иде. Мин урманчылыкка барып, колхоз өчен делянка алып кайттым. Аны кызлар кисте. Ул елларда урманны гел кызлар кисә торган иде. Без ул эшкә игътибар итеп җиткермәү аркасында, бер кызыбызны — Мөхәммәтҗанов Сабир абый кызы Һиндияне — агач басып үтерде. Бик кызганыч булды. Шуннан соң без бу эшкә җитдирәк, саграк карый башладык. Әлеге делянкадан киселгән агачны Әтнә базарында саттык. Шуның акчасына Казан кибетләреннән ат дирбиялары өчен әйберләр алып кайттык. Иң элек юкә камыт бавын, юкә аркалыкларны, юкә дилбегәләрне ташлап, каеш камыт баулары, каеш аркалыклар, каеш дилбегә, тасма постромка баулары булдырдык, камытларга да ремонт ясаттык, хәтта шлеялар алып җибәрдек. Икенче чиратта үгез, сыер камытларын ремонтлап, аларны да үзгәрттек. Хуҗалыкларга да утын алып кайта башладык. Урманга беренче мәртәбә киткән яшүсмер малайлар өчен дә борчылдык. Алар бер көн баралар, икенче көнне генә кайталар иде. Бу малайлар киткән көннең иртәгесен 30 градустан артыграк суык булды. Ярый әле җиле булмады. Аларны каршы алырга ат белән үзем чыгып киттем. Кышлау авылының фермасын узгач, карасам — авылга таба, кыр казлары шикелле тезелеп, безнең малайлар кайтып килә. Иң элек санадым, уникесе дә исән. Боларны күргәч, шулкадәр сөендем, йөгереп барып кочаклап аласым килде. Исең китәр: берсе дә өшемәгән, күбесе телогрейка өстенә капчыктан башлык ясап, шлем шикелле итеп кигән-

нәр. Аякларында оекбаш белән чабата. Һәркайсы, олы кешеләр шикелле, олау артыннан җәяүләп атлый. Үгезләр узганчы карап тордым. Үгезләр кайта торды, малайлар минем янга җыелды. Хәл-әхвәлләрен сораштым. Авылга кайтып кергәндә, бу малайларның әниләре каршы алырга чыккан иде. Әле дә хәтеремдә, Гарәпшин Әдһәмнең әнисе хәтта авыл башына ук килеп торган иде. Малайлар идарә капкасы төбенә утыннарын бушаттылар. Унике олау — ул вакыт өчен бик күп утын иде. Кабыгы кибеп төшеп беткән чыршы утыны капка төбендә өелеп калды.

Бу малайлар сугыштан соң да бер биш еллап үгез җиктеләр. Чөнки атлар тиз үрчемәде. Ә авыл малайлары барысы да үгез җигеп эшкә өйрәнде. Аннары гына атка күчтеләр.

Колхозчыларның җыелышларын үткәргәннән соң, яшьләр калып, мәктәп бинасында төрле җырлар җырлый торганнар иде. Хатын-кызлар Бибинурны җырлаталар иде. Ул моңлы итеп җырлый белә иде. Аның бер җыры сугыш вакытында авылда яшәгән кешеләрнең күңеленә аерата сеңеп калды. Ул — «Юксыну» җыры иде. Бибинур Шәмсетдинова шушы җырны җырлагач, залдагы бөтен хатын-кыз тып-тын кала, әкрен генә елый да иде. Бибинур бу җырны үз тормышын чагылдырган бер әсәр итеп таныйдыр кебек тоела иде безгә. Чөнки сугышка кадәр ул Салих абыйга кияүгә чыкты, өйләнешкәннәренә бер ел тулар-тулмаста, ире Кызыл Армия сафына алынды, шул ук елны сугыш башланып, ил чигендә булган Салих абый хәбәрсез югалды.

Язга таба бездә клубны ремонтлау һәм культура чаралары үткәрү фикере уянды. Ләкин өлгерә алмадык. Нәкъ шул вакытта районда зур җыелыш булды, райком Пленумына мине дә чакырып, язгы чәчүгә хәзерлекнең барышы хакында сөйләргә куштылар. Куркып калдым. Җыелышларда ул вакытта кәгазьдән укып чыгыш ясау гадәте юк иде. Мин бер бит кәгазьгә чыгышымның планын теркәдем. Әтнә клубы халык белән тып-тулы иде. Сүз бирелгәч, тез буыннарымның хәле китте. Әкрен генә чыктым, сәхнәгә мендем, трибуна янына бастым. Каушау зур. Күңелдә: «Минс, 19 яшьлек үсмерне, кем тыңлар?» — дигән уй бөтерелә иде. Үзем сөйлим, үзем залга колак салам, тыңлыйлар. Бу миңа ныклык бирде. Фикерләремне кыюрак, төгәлрәк әйтә башладым.

Колхоз председательләре — Дусым авылыннан Шәфикъ Нигъмәтуллин, Җигелдә колхозыннан Муллагали абый Муллахмәтов: «Әйбәт сөйләдең, болай булгач була, энем, өйрәнәсең»,— диделәр.

Пленум беткәч, Әтнә ашханәсенә кердек. Мин түрдәге өстәл янына ук барып утырганмын икән, районның иң алдынгы председателе, Татарстан АССР Верховный Советы депутаты Рауза Касыймова:

— Син, Фәйзерахман, бүген бик шәп сөйләгәч, столовойда түргә үк кереп утырырга ярый дип беләсең ахры, башка вакытта ишек янында гына утыра торган идең,— дип, халыкны көлдереп тә алды.

Пленум эшенә йомгак ясаганда, райкомның беренче секретаре безнең колхозның эшенә уңай бәя бирде. Чөнки әле бу вакытта да ашлык сугуы бетмәгән колхозлар бар иде.

Урып-җыю вакытында безгә райком секретаре килгән иде. Тарантаска зур гына тимер-күк ат җиккән. Аның белән басуларда, әвендә булдык. Чәчелгән җирләрне карадык. Бик игътибар белән күзәтеп йөрде, кешеләр белән әңгәмә үткәрде. Мине дә сөйләштерде, планнарыбызны сорашты. Ахырдан идарәгә кайткач, күргәннәре хакында фикерен әйтте, киңәшләр бирде. Һич онытмыйм, конторага кергәч, ул: «Барысы да бик әйбәт, тик бер генә кимчелегең бар, әвен янындагы казларың су эчәргә чишмә буена йөриләр икән, тагарак белән су да куйсаң, көлтәдән бөртек чүпләп чыккач, еракка йөриселәре булмас иде»,— дип кырыс кына карап куйды. Бу Пленум азагыннан да: «Аш-

лык суккан әвеннәре янында тәкә хәтле казлар ята, колхоз икмәген ашап, тәмам симергәннәр»,— дип, теге чактагы хәлләрне искә төшерде.

Колхоз председательләренә таләпләр дә бик югары иде.

Күәм авылында колхоз председателе Зарипов Абдулла абый иде. Шул председатель авыр хәлгә дучар булды. Хәтеремдә, бернечә председательне, район прокуроры янына, печатьләрне саклау буенча сөйләшергә чакырдылар. Без Комургужа авылы «Шахтер» колхозы председателе Әхмәтгалиев Гани абый белән менгән идек. «Следователь» дип язган бер ишекне ачсак, ул вакытта прокурор ярдәмчесе Гибадуллина Разия янында Карл Маркс исемендәге колхоз председателе Абдулла абый Зарипов утыра. Аның янында, өстәл өстендә, капчыкларга тутырып алып кайткан башаклар ята. Абдулла абый борчылган, агарып киткән, чырае калмаган. Бераздан, председательләр җыелышында, Абдулла абыйның хөкем ителүе хакында ишеттек. Сәбәбе — колхоз басуында урак урганда башак югалтуга юл куйганы һәм шуның аркасында дәүләткә ашлык тапшыру планын үти алмаганы өчен, дип игълан иттеләр. Сугыш чорының законнары кырыс иде...

Минем өчен беренче яз башланды. Яз гадәттәгечә килде. Атларны, үгезләрне сабан эшенә яхшы итеп әзерләдек. Аларга кыш буе бәрәңге пешереп ашаттык. Дирбиялары да бик матур, аларга беркетелгән үсмер егетләрнең дә күңеле көр иде.



## Сугыштан соңгы еллар

Сугыш чоры барлык хәсрәтләре, авырлыклары белән артта калды. Хәзер сугыштан соңгы илне аякка бастыру чоры башланды. Бу чорның да үз авырлыклары безнең Түбән Шашы авылы — «Чулпан» колхозы алдына килеп басты. Колхоз эшләрен алып бару белән бер рәттән, Украина, Белоруссия, Балтик буе, Кавказ, Россиянең көнбатыш өлкәләрендә бик зур төзелеш эшләре башланды. Иң элек йортсыз-жирсез калганнарны түбә астына алып бетерү кирәк иде. Эвакуациядән кайткан кешеләрне туган-үскән җирләрендә кабул итү, аларны урнаштыру, сугыш вакытында Уралга, Идел буена, Себергә күчерелгән заводлар урынына яңаларын төзү, армиядән кайткан солдатларны эш белән тәэмин итү иң беренче бурыч булып тора иде. Материаль байлыклар шул районнарга киткәнлектән, безгә күбрәк үзебезнең мөмкинлекләрдән чыгып эш итәргә туры килде. Шуның өстенә, сугыш җимергән колхозларга без ярдәм оештырырга да тиеш булдык. Белоруссия колхозларына сыерлар җибәрдек. Дәүләткә икмәк тапшырган чакта, шул районнарда чәчәргә дип, яхшылап чистартып, сортлы орлыкларны озаттык. Үз колхозыбызда да көзге чәчү, урак уру, ындырда сугу, терлекләрне тәрбияләү эшләрен вакытында башкарып чыга алдык. Илне аякка бастыру чорында без иң әүвәл чәчелми калган җирләрне чәчеп бетерүне бурыч итеп куйдык. Бу эш ансат кына бармады. Безнең колхозыбызга МТС хезмәт күрсәтми иде. Атлар аз, үгезләр белән сука тарттырып булмый, алар тырма тырмалауга гына файдаланылдылар. Әрем баскан җирләрне бу елны көздән бераз сукалап калдыра алдык. Бу эшне башкару өчен атлар кирәк иде. Атлар сугыш елларында байтак кына кырылдылар. Миңа хәзер ат үрчетү бурычы алга килеп басты. Байтал атларга бик нык игътибар итәргә кирәк иде. Моның өчен район буенча аерым чара үткәрдек. Буаз бияләрне соңгы көннәренә кадәр җиккәнлектән, колын төшерү очраклары күп иде. Шуны булдырмау өчен бу тирәдәге дүрт колхозның байтал атларын җыеп, Күшәр авылы болынында аерым көтүләр оештырылды. Атларны һәр авыл көтүчеләре чиратлап көтә торган булдылар. Безнең колхоздан Мөхәммәтгали абый йөрде.

1946—47—48 елларны колхозларда тайлар саны арта төште. Атларның нәселен яхшыртуга да игътибар иттек. Шул максаттан чыгып, нәсел фермасы булган Иске Мәңгәр авылыннан бер айгыр-тай сатып алдык. Ул айгыр бик яхшы булып үсте. Ул айгырга башка авыллардан да байталларны алып киләләр иде.

Атлар тәрбияләү колхоз идарәсенең төп эшләренең берсе булып калды. Атларны ашату тәртипкә салынды, алар көрәйделәр, матурландылар. Яхшы дирбиялар, чаналар алдык. Тимерчелектә агач арбаларны азлап-азлап тимер күчәрлегә алыштыра башладык. Бу әйберләрне булдыру өчен әлеге дә баягы урманнан алып кайткан утынны, акча кирәк саен, Әтнә базарына чыгарып сата идек. Байтал атларның колынлавы колхозда зур вакыйга була иде.

Колхоз эшен алып баруга инде төшенә башладым бугай, дип йөргәндә, миңа таныш булмаган эшләр килеп чыга торды. Халыкның тормышы әле һаман да авыр, яңа уңыш җитәр-җитмәстә ашарга бетү, ачлыктан иза чигеп, берсенең берсе әйберенә тигәлиләр. Бу очракларны булдырмау, халыкка тәрбия бирү эшләре дә минем өстә иде. Чөнки авыл советы безнең авылда түгел иде. Көннәрдән бер көнне Галимҗанова Афтап апай, кәҗәм югалды, дип килде. Нишләргә, каян табарга, дип аптырап торганда, бер иптәш безгә әйтә, менә Ганиев Кави үзен бик шикле тота, анда түгелме икән, ди. Кави — минем яшьлек дустым, үзем аннан шикләнмим дә, шулай да күңелдә уй бар: бу малай үткен, әллә ялгышты микән, дим. Шуннан соң, Кави белән сөйләшеп, өйләренә барып кәҗәне эзләдек. Берни дә чыкмады. Гафу үтендек. Менә шундый законга каршы килгән ялгышлыклар да ясалгалады. Ахырдан үземне Кави алдында гел уңайсыз сизеп йөрдем. Ул аңа берничек тә үпкәләмәде. Бәлки үпкәләгәндер, миңа гына сиздермәгәндер. Авылдашыма, дустыма карата шулай ялгышлык кылу, киләчәктә кешеләр белән сак эш итәргә кирәклеге хакында зур сабак булып калды.

Кәҗә икенче кешедән табылды...

Һәр чорның үз яңалыклары, үз авырлыклары була. Алар вакытлар узганнан соң гаҗәп тә тоелыр. Ул чакта исә, җитәкчеләр кисәтә бармаса, шактый зур күңелсезлекләр чыгарырдай хәлләр дә туарга мөмкин иде. Мин белэм: безнең күрше Яңа Шашы авылында революциягә кадәр бер кешенең сарыгы югала. Авыл халкы бер гаиләдән шикләнә, ире белән хатынын тереләй җиргә күмеп үтерәләр. Өч көннән соң, сарык, икс бәтиен ияртеп, кайтып килә, баксаң-күрсәң, сарык, качып китеп, елга буенда яткан икән. Ә теге гаилә, ирле-хатынлы, үлгән, аларны казып алып булмый. Яңадан икенчеләре, теге үлгән кешеләрнең туганнары, яла яккан өчен, сарык хуҗасын җиргә күмәргә, дип ярсыналар. Ярый әле, авылда бер акыллы кеше була: җәмәгать, бер ялгышлык ясадык, икенчесен ясамыйк инде, ди. Ут чыгарган кешеләрне утка салып яндыру очраклары да элек аз булмаган.

Авылыбызга сугыш афәте китергән авырлыклар гел туып торды. Аталарыннан калган балалар гел үсә баралар. 10 яшендә калучылар хәзер — 15—16 да, 5 яшендәгеләр — 10—11 дә, туып кына өлгергәннәренә дә 5—6 яшь тулып килә. Әнә шул балаларны тәрбияләргә ата кулы җитмәгәнлеге сизелә башлады. Бу очракта җитәкчеләрнең дә, аналарның да кимчелеге булды. Чөнки без сугыш авырлыгы тудырган көндәлек мәшәкатьләр белән аларның эчке дөньясын онытканбыз, аларга якын килергә вакыт та булмаган. Менә шул хәл хәзер беленеп өскә чыга башлады. Балаларның әниләрен тыңламау очраклары, тавык оясыннан йомырка урлап эчү кебек күңелсезлекләр ешайды. Тукта, нигә болай булды соң әле, дип, уйга калдым.

Беренче сәбәп. Балаларның әтисезлеге аналарда балаларга карата мәрхәмәтлелекне тагын да арттырды. Иренә бирергә өлгермәгән ягымлылыгын әни кеше баласына күчерә. Минем ятимем, балам-җанашым,

дип, үзләре эштән кайтканда урамда алар каршына йөгереп килгән балаларын күтәреп алып сөя торган булдылар. Тигез гаиләләрдәге педагогик такт бозылды.

Икенче сәбәп. Бөтен хуҗалыкны әни кеше бер үзе алып баргач, бала тәрбиясе белән махсус шөгыльләнергә вакытлары калмады, көнетөне эшләделәр. Алар чыгып киткәндә, балалар йоклап калды, алар эштән кайтканда, кечерәкләре йоклап киткән була, зурраклары гына әниләрен каршы ала иде. Шул балаларның күп йөри торган вакытларында — көндез — ана күзе тимәде.

Өченче сәбәп. Җитәкче буларак, мин ачтан интеккән балаларны күреп кызгандым. Башта арыш, аннан борчак, аннары бодай басуларында икмәк уып ашаганнарына күз йомып карадым. Алар анда үзләре туена, ахырдан кесәләренә тутырып, сеңелләренә, энеләренә алып кайтып ашата торган булдылар. Урлашу гадәте нормага керә башлады.

Менә бу сугыш вакытының яшь буынны үстерүгә тискәре йогынтысы иде. Мин әнә шул кимчелекләргә бәйле төрле мисаллар, хәтта фаҗигале хәлләрне дә китерә алыр идем. Әлеге өч сәбәпне бетерү өчен, без, колхоз идарәсе членнары, комсомоллар, әвеннәрдә, кыр станнарында ул темага сөйләшүләр үткәрә башладык. Гомумән, аналарга кулдан килгәнчә ярдәм иттек. Колхоз идарәсе исә мәктәпкә таянды. Укытучылардан Фатиха апа, Мәймүнә апа, Бибинур белән бу хакта бик озак сөйләшү булды. Алар бик зур тырышлык куйдылар. Менә минем хәтеремдә — Васильев Ильяс, Габдрахманов Габделхак, Габдрахманов Гани белән әңгәмә үткәрдек. Мәктәптә, урамда культурасыз җырлар җырлаганнары, үзләреннән кече балаларны, кызларны рәнҗеткәннәре, тәмәке тартканнары, хәтта үзләреннән кечкенәләрне, алып кереп, үз йортларында, сәкегә ятып, тәмәке тартырга өйрәткәннәре өчен, озак итеп, нигытып сөйләштек. Авылның комсомол оешмасы, аның секретаре Шәмсетдинова Бибинур, укытучылар, колхоз идарәсе бу эш белән берничә ел рәттән шөгыльләнде.

Юк кына акчалардан мәктәп ишегалдына уен мәйданчыгы ясадык. Турник уены әйберләрен төзәттек. Үсмерләрне теләсә кайда, әйтик, кичләрен мунчаларда җыелып, карта уйнау шикелле «һөнәрләреннән» биздердек. Моның өчен иске мәчет бинасын комсомоллар көче белән ремонтларга кирәк иде. Миңа прораб булырга да туры килде. 1945 елның көзендә бу бинаның бер ягындагы тәрәзәләрен, арасына вак печән тутырып, томаладык. Ул яктагы пыялаларны алып, урам ягы тәрәзәләрен рәтләдек. Такталар табып, идәнен җәйдердек. Шулай итеп, анда кич саен уеннар оештырылды. Салкынайткач, мичсез булганлыктан, яшьләр килми башлады. Акча юнәтеп, Ташчишмә авылыннан кирпеч сатып алып, Фаяз абый Газизовтан мич чыгарып бирүен үтендек. Фаяз абый, лампаны биеккә куеп, мич чыгара, яшьләр уйныйлар, җырлыйлар, биилэр. Фаяз абый аларга мәзәк сүзләр әйтә, кайсысына, ялгышкан булып, балчыклы су чәчрәтеп җибәргәли. Бер көнне Фаяз абыйның балчыгын, комын таптап бетергәннәр, яшьләрнең чабаталары, кызларның ап-ак оекбашлары кызыл балчыкка буялган. Караңгы булганлыктан, аяк асты күренми, бердәнбер лампа Фаяз абый янында, мич буенда иде. Хәзерге ял-якты, иркен клубларга карыйм да шуларны сагынып искә алам. Нинди ихлас заманнар иде! Икенче елны янадан бер мич чыгардык. Аннан соң атна саен бер мәртәбә кино куела башлады. Киноны безнең авылның Сибгат Сөнгатенең малае Гарифулла куя иде. Бераздан авыл яшьләре театр уйный башлады. Бик күп спектакльләр куйдык. «Хаҗи әфәнде өйләнә», «Беренче театр», «Ак калфак», «Хафизалам иркәм», «Ташкыннар». Шулар арасыннан Мирхәйдәр Фәйзинең «Галиябану» пьесасын авылыбыз халкы аеруча яратып карый торган иде. Без аны 1945—46—47—48 елларны ел саен куйдык. Һәр куйганыбызда клуб тул-тулы була. Халык елый-елый карый. Спектакльнең

һәрберсендә дә төп рольләрне мин һәм комсомол секретаре Бибинур уйный идек. Фатиха апай — Галимәбану, Юсупов Самат — Бәдри карт, сугыштан яраланып кайткан Галимулла Хәйруллин — Исмәгыйль, мин Хәлил булып уйныйм. Беренче куйган вакытта клубта халык бик күп, залда эссе, ишекләр ачык, коридорга да халык тулган. Хатын-кызлар балаларын да алып килгәннәр иде. Исмәгыйль, пистолетны күтәреп, Хәлилгә төбәүгә, Кави, сәхнә артына кереп, ау мылтыгыннан атып җибәрде, зал Хәлилне кызганып елый башлады. Шулар арасыннан берсе бик кычкырып елый. Галиябану, Хәлил өстенә ятып, җырлап бетергәнче, ул елау ишетелеп торды. Бу минем кече энем Рубис тавышы иде. Ул мине, абыйсын, чыннан да атып үтерделәр дип елаган икән. Без, «артистлар», торып баскач, залда җанлану туды, Рубис та, авызын ерып, миңа карап, көлеп тора. Аның янында — энем Фирдәвес, тик ул, зуррак булгангамы, еламаган иде. Бу спектакль белән Күнгәр, Югары Шашы, Күшәр һәм башка авылларга барып йөрдек. Аулак өйләрдәге яшьләр клубка күчте.

Уку йорты мөдире Абдуллина Гөлзадә, яңа китаплар сатып алып кайтып, кычкырып укулар оештырды. Әле дә хәтеремдә, Габдрахман Әпсәләмовның «Алтын йолдыз» китабын бик яратып укыдык, бу безнең заман кешеләренең тормышы булганлыктан, бик яхшы кабул ителде.

Суфлер булып утыручы Җәләлиева Һәдия һәм без үзебез куйган спектакльләргә кешеләрдән асылмалы лампа, өс-баш киемнәре, чаршаулар җыя торган идек. Утызлы лампаны Фатиха апай Шакировадан алып тора идек. Җиңсез кәзәкине — Фатиха апайның атасы Лотфулла абыйдан, киң төпле ыштаннарны да, Бәдри карт өчен, Лотфулла абыйдан алдык, чаршауларны Бибинур, Фатиха апайлар алып килә иде. Халыкны клубка йөрергә өйрәттек. Спектакльләр, концертлар беткәч, авыл халкы өенә кайтмыйча, залда утыручыларны берәм-берәм уртага чыгарып җырлата иде. Аннан соң, яшьләргә кичә игълан итеп, яңадан җырлап, биеп туйгач, таралыша торганнар иде. Яшьләр, төркем-төркем кызларны озатып, төрле урамнарга тарала иде. Сугыш вакыты малайлары үскәне бер туган колхозларында эшкә кала тордылар. Елдан-ел эшче көчләре арта барды. Мин үзем дә, өйләнмәгән булганлыктан, гел яшьләр арасында идем. Кичен клубта, уку йортларында, эш вакытында да һаман бергә, уй-тойгыларны уртаклашып яшәдек.

Шулай бер вакыт, язгы чәчү башланган көннәрне, ат абзарына ат алырга төшкән егетләр, шыпырт кына сөйләшәләр... «Нишләп чыкмыйсыз инде?» — дип сораган идем, Равилне көтәбез әле, диделәр. Ул арада Шагалиева Фатыймалар турысында бер кыз тавышы ишетелә. Үсмер егетләр бер-берсенә карап елмаешырга тотындылар. Тавыш ишетелгән якка мин дә карап тора башладым. «Равил жаным, зинһар үтермә, кызган»,— дигән кыз тавышы ишетелә. Нәрсә бу, дип сорагач, сөйләп бирделәр. Равил Кәүсәрия белән дуслашып, яратышып йөри иде. Кәүсәрия белән Кадрия янына Күшәр авылы егетләре менгән икән. Егетләрне кызлар озата барган, инеш аркылы, басма салып, чыгарып җибәргәннәр. Равил шуларны күргән дә тиз генә йөгереп барып, кызларны суга төртеп төшергән, басманы да алып киткән. Кадриясе, талга ябышып чыккан, ә Кәүсәриясе талга тотынган саен, егет аның кулын ычкындыра икән. Мин егетләрне шунда җибәрдем. Шуннан соң ике кыз, манма су булып, өйләренә кайтып киттеләр. Бу иртәнге сәгать өчләр тирәсендә иде. Яшьләр, авылны чыгу белән, җырлап киттеләр, алар арасында Әхәт Шәрипов бик матур җырлый торган иде. Иртәнге тынлыкта бу хәл мине күп уйларга салды. Егетләрнең кызларга булган мондый рәхимсезлеге миңа ошамады. Бу вакытта житкән кызлар күп булганлыктан, балигъ яшүсмерләрдә ялгыш караш туган. Кайберләре

үзләре танышкан кызлар турында ямьсез сүзләр сөйләп йөриләр, алар да хатын-кызны кимсетү гадәтләре сизелә башлаган иде.

Үсмерләр белән бу хакта да тәрбия эше алып барырга туры килде.

Менә 1946 ел да җитте. Бу елны сугыштан соң беренче мәртәбә татар халкының милли бәйрәме сабан туе көне билгеләнде... Бу вакытка авылыбыз кешеләреннән әсир төшкән кешеләр дә кайтып бетте, үлеп калганнар да ачыкланды. Әмма тол калган хатын-кызлар, аерата, хәбәрсез югалган, дигән хәбәрне алучылар әле һаман ирләрен көтәләр иде. Кайдадыр, ерак бер авылда, үлгән хәбәре килгән кеше кайткан икән, дигән сүзләр ишетелеп торды. Мондый сүзләр тол калган хатыннарның көтү хисләрен кабат калкытып чыгарды. Исән калганнар, кайтасылар кайтып бетте. Сафиуллин Гарифҗан, Хәйруллин Сәхибулла, Хәйруллин Галимулла, Галиев Кави инвалид булып кайттылар. Минем дә сул кулым һаман күтәрелми иде әле. Үзем өченче группа инвалид булып тордым, алты ай саен комиссия үтә идем. Сугыштан кайткан кешеләрнең гаиләләре дә, өйләнмәгәннәре дә бар. Кайта алмаучылар хакында истәлекләр сөйләргә генә калды...

Күңелсез вакыйгалар да булгалады. Көннәрдән бер көнне Сабиров Салих кайтып төште. Ул армиягә киткәндә бер бала белән калган хатыны Галия апай Сабирова, иренең үлгән хәбәрен алгач, Галимҗанов Миңлехәй абыйга кияүгә чыгып куйган иде. Авыл халкы Салихны бик кызганды. Өстәвенә, аның торыр урыны да юк иде, Гарифә апайга өйдәш булып керде. Бераздан Салих абый авылдан китәргә уйлаган. Ул гармунчы иде. Таң алдыннан, гармунын алган да, җырлап урам әйләнгән. Авылның барлык тол хатыннары капка төбенә чыгып, хәтта картлар, карчыклар да, елап, озатып калдылар. Галия апай яшәгән йорт яныннан берничә мәртәбә җырлап, уйнап киткән, ул турыдан үткәндә, хәтта елаган да иде, күзләрендә яшьләре бар иде, дип сөйләделәр. Күрәсең, Галия апайны бик яраткандыр, яратмаса, алай йөрмәс иде. Салих абый авылыбыз халкына сугыш салган яраны янә дә яңартып китте.

Ул елның сабан эшләрен уңышлы гына бетердек. «Чулпан» колхозы район җыелышларында уңай яктан телгә алына башлады. Ул елны районда беренче мәртәбә алдынгылар слеты үткәрелде. Районның кырчылык һәм терлекчелек алдынгыларын чакырганнар иде. Слетта районның 54 колхозыннан унлап колхоз председательле катнашты. Шулар арасында мин дә бар идем. Бу елны безнең колхоздан иң яхшы чәчүче булып Ганиев Габдерәкыйп саналганлыктан, минем белән ул да барды. Җыелыш миндә дә, Габдерәкыйптә дә бик зур тәэсир калдырды. Чөнки минем дә, Габдерәкыйпнең дә мондый тантанада беренче катнашуы иде. Соңыннан үзешчәннәр көче белән концерт куелды. Концерттан соң алдынгыларны кунакка чакырдылар. Ашханәдә райком бюросы членнары, район җитәкчеләре бар иде.

Райком секретаре Сабир абый Шакиров барыбызны да тәбрикләде. Аннан башка да сөйләүчеләр булды. Тамак ялгап алгач, ашханәнең өстәлләрен җыйнап, бер почмакка этеп куйдылар да, әйлән-бәйлән уйналылар. Башта бер әйләнгәнче барлык кешеләр дә, хәтта райком секретаре да түгәрәккә кушылды. Соңыннан алар читкә чыгып карап тордылар. Шунда бер кызыклы вакыйга күңелгә сеңеп калган. Менә колхоз председателе итеп сайлаткан райфо мөдире Галиәхмәтов Габдрахман абыйны уртага алып җырлаттылар. Ул: «Их, колхоз мунчасы, көн дә шулай булсачы!» — дип җырлап бетерде дә биеп китте. Биегән чакта, өстендәге кожанга охшаган плащ кесәсеннән берничә кабартма, кешеләр кул чәбәкләп җырлап торган арада, идәнгә чәчелеп китте. Халык шаулап көлә башлады. Шул хәтле ихластан көлделәр, безнең көлүгә райком секретаре да кушылды. Бу көнне ашханәдә өстәлгә күп

итеп кабартма пешереп куйганнар иде. Габдрахман абый: «Балаларга күчтәнәч дип алган идем, хур булдым лабаса!» — дип, үзе дә көлде. Соңыннан ул үзе дә колхоз председателе булып эшләде.

Иртәгесен безне Каенсарга район сабан туена чакырдылар. Сабан туен ачып җибәргәч, миңа сүз бирделәр. Мин шушы мәйдан алдында үзебезнең авылдашларыбызның яхшы эшләүләрен әйттем, исемнәрен санап чыктым. Аларга бүләк итеп өчәр килограмм тары ярмасы бирелү хакында игълан иттек. Тарыны читтән кайтарткан идек. Ул бик кадерле, кыйммәтле ризык санала иде. Алдынгыларны шушындый тантанада игълан итү кешеләрне тырышып эшләргә рухландырды.

Сабан туйларын матур итеп үткәреп, печәнгә төштек. Ашыт елгасында су коенып, рәхәтләнеп яшел үлән өстендә тәгәрәп йөрдек. Яңадан сугышка кадәрге гадәтне, аталарының гадәтен малайлары кабатлап, гармуннар белән җырлап йөри башладылар. Бу елның көзге эшләрен дә уңышлы башкардык. Барлык эш беткәч, кыш көне республика күләмендә алдынгылар җыелышы узды. Районнан җиде кеше идек. Җыелыш Татар академия театрында булды. Безгә, анда катнашучыларга, бүләкләр бирделәр. Тантана ике көн барды. Шунда беренче мәртәбә партиянең өлкә комитеты беренче секретаре Муратовны, ТАССР Министрлар Советы Председателе Шәрәфиевне, Авыл хуҗалыгы министры Ганиевне күрдем. Концерт булды, буфетлар бар иде, өйгә бүләкләр алып кайттык. Без районның баш агрономы Ибәтуллин белән утырдык. Ул мине таныштырып торды. Менә шулай итеп, авылдашларымның хезмәте яңадан республика күләмендә бәяләнде, дип исәпләп, аларның хезмәте өчен горурландым. Кайткач, иптәшләргә күргәннәремне сөйләдем.

Сугыштан соңгы елларны халык бик тырышып эшләде. 1947 елның язгы көне бик матур булды, уҗымнар бик яхшы тишелеп чыкты. Язгы культуралар да әйбәт кенә үсте. Атларның да саны артты, әмма үгез җигү дәвам итә иде әле. Уңышны җыеп алу элекке елларга караганда кыенрак булачак. Беренчедән, колхозның буш яткан җирләре барысы да чәчелеп бетте дип әйтерлек. Икенчедән, иген каерылып уңган иде. Кул белән бик яхшы уручы Фатыйма, Файзә апалар, Фәсәхәт, Шәрифә, Мәгъмүрә, Гайшәләр дә 15—16 сотыйдан артык ура алмадылар. Башта алар 10—12 сотый гына урдылар. Урак башыннан ук шундый авырлык килеп басты. Лобогрейка урдыручы яшьләргә, хатын-кызлардан Хәернисა апай Сәлимовага, Газизова Асия, Газимова Әминә, Ганиев Рәкыйп, Шәрипов Әхәт, Хаҗиев Равилгә бик авырга туры килде. Платформадан төшереп йөрүчеләр итеп икешәр кеше куйдык. Әхәтләр, басудан кайтмыйча, куышта яшәп урдылар. Равил, Әхәт, Кәүсәрия, Асия ерак басуда бик озак эшләделәр. Уракка бик күп кешеләрнең кулы тиде. Ирләрнең дә кул белән ура белгәннәре чыкты. Сафиуллин Хафиз абый бер төркем ирләр белән кулдан уруда катнашты.

Шулай итеп, бу елның кыр эшләрен тәмамладык. Иген уңышы әйбәт булды. Дәүләткә планнан артык икмәк тапшырдык. Нињаять, сугыштан соң беренче мәртәбә хезмәт көненә кило ярым ашлык бирдек. Колхозчыларыбыз бик сөенделәр. Фураж да күп калды. Шул елны ук хайваннарның баш санын сугышка кадәргедән арттырып җибәрдек. Ферма торакларына ремонт ясарга керештек. Җимерекләрне төзәттек. Колхозда такта яра башладык. Беренче такта яручылар булып сугыш елы малайларыннан Газизов Абдулла, Шагалиев Зөлкәрнәй булдылар. Аларны Гыйлемханов Закир абый өйрәтте. Закир абый, Котдусов Кашшафлар, хезмәт армиясенә алынып, Казандагы хәрби заводларда эшләгәннәр иде. Менә бу тәҗрибәле кешеләр безнең яшьләргә үрнәк булды. Закир абый агач мастерскоеның хуҗасы иде, ул арба, чаналарны төзәтеп торды. Егетләр күп итеп такта ярып бирделәр. Шул такталар белән ферма каралтыларына сайгаклар җәелде. Аннан пекар-

ня янындагы элеккеге тайлар торагы дип йөртелгән бинаны ремонтлап, хәзерләп бетердек. Ат абзары янына үгезләргә урын әзерләдек.

Дәүләткә авыл хуҗалыгы продуктларын ел саен күбрәк сату колхоз кассасына акча керүне дә арттырды. Хәзер көндәлек кирәк өчен үзебезнең акчабыз бар. Инде ссуда алмыйбыз, элеккеләрен түләп бетерү чарасына керештек.

Колхозчының тормышы да яхшыра башлады: тамагы туйды, өсте бөтәйде. Казанның Сорочи базарында резинадан койган аяк киемнәре сатыла. Халык җәйге эш вакытында гына чабата кия, а авылда йөргәндә, шундый резина аяк киеме, ирләр шахта резинасы дигән резина аяк киеме кияләр иде. Аннан соң кирза итекләр киң таралды. Авылда ботинка һәм сандаллар, ялтыравыклы резина аяк киемнәре дә күренгәли башлады. Сабан туйларына чабата киеп чыккан кешеләр сирәк иде инде. Ниһаять, мин дә яз көннәре кирза итек, җәй көннәрне брезент туфли киям, чабатаны салдым.

Авыл кешеләре сугыш вакытында зур өйләрен бүлеп алып, яртысында гына, кайберләре хәтта мунчада гына тора башлаганнар иде. Хәзер барысы да зур өйләренә күченделәр. Бу елны салам күп булгач лыктан, хуҗалыкка салам бирелде. Башта саламны лапасларына салып, сарыкларына чүпләтәләр иде, соңыннан көлтә итеп бәйләп өйгә кертеп ягалар иде. Саламның җылысы бик мамыклы, дип, сөенеп яшиләр иде. Менә шулай тормышлары рәтләнгәч, сугыштан ирләрнең кайту ышанычы беткәненә инанып, хатын-кызларның кайберләре буйдак ирләр, хәтта хатынлы ирләр белән дә чуала башлады. Авылда ирләр бик аз, кая барсаң да хатын-кыз иде.

Безнең авылда авыл советы да булмаганлыктан, ирләре чит хатынкызлар янына барып йөреп, семья бозылу хәлләренә килеп җиткәч, минем ярдәмем кирәк иде. Минем өчен монысы бигрәк тә авыр. Үзең — өйләнмәгән егет, башкага акыл өйрәтергә ничек кыюлык итәсең?! Баш тартсаң да яхшы түгел, ул, җитәкче итеп, синнән ярдәм өмет итеп, семьяны саклап калыйк, дип, киңәшкә килгән. Менә шундый хәлдән соң, бик иплəп кенә бер яшь хатынга, эш урынында, киңәш бирергә тотынган идем, син кеше тормышына тыкшынма, бозма аларның тормышын, дигән идем, ул шаркылдап көлде генә. «Әй, Фәйзи,— диде.— Сиңа нәрсә, син ир кеше, менә минем ирем дә, балам да юк, миңа нишләргә соң? Ул минем янга килә, нишләп мин аны куалыйм, килсен, миңа аның семьясы кирәкми, семьясы да яшәсен, ул миңа үзе генә кирәк. Син менә, хатынлы кешене янына китермә, дисең, андыен каян алыйм? Алар бит юк, аларның кайда калганын үзең беләсең бит. Менә син хатынсыз, буш кеше, мин сине бик чакырыр идем дә, син килмисең ич, әле дә чакырам, кил алайса! Менә шулай, дус, башка хәсрәтең булмаса, кысыр хәсрәт белән башыңны катырып йөрмә»,— диде дә, минем башка әкрен генә сугып китте дә барды...

1948 елның эшен башлап җибәрдек. Минем инде дүрт еллык председательлек тәҗрибәм бар. Белем аз — шул борчый. Таләп арта. Авыл халкы да үзгәрә, аның таләпләре дә арта. Бу елда элекке елга караганда иген уңышы түбәнрәк булды. Ә колхозның хәле элекке елга караганда күп тапкыр яхшырды. Җитәкчелек итү кыенлаша төште. Мин еш кына белемемне арттыру хакында уйлый башладым. Ул чорда колхоз председательләренең белем яклары гомумән дә түбән иде. Чөнки крестьян эшен белүчеләр, армиягә китеп, күбесе үлеп калды. Ә колхозларга председательләр, бригадирлар сайлап алу, аларны өйрәтү өчен вакыт та юк иде. Колхоз председательләрен алмаштырып торуга юл куелды. Берәр эшне вакытында башкарып чыга алмадымы, яки нинди дә булса өстән кушылган чараларны хәл итә алмадымы — аларны шундук алмаштыралар иде. Бу хәл исә гомумән дә председательгә ышануны бетерде. Бу постка теләп баручылар калмады. Райондагы

председательләр составына карасаң, күбесе — Ватан сугышыннан инвалид булып кайтучылар. Кайберләре картлар, чукраклар, хатын-кызлар да бар иде. Хәзер, ул вакыттагы колхозлар белемсез, талчыккан кешеләр белән ничек эш алып барды икән, дип гаҗәпләнәсең. Райондагы җыелышларда аякларын, кулларын, башларын уып утыручылар еш очрый торган иде. Колхоз председательләре арасында иң яше мин идем. Норма дигән авылдан бер председатель килеп йөри, эшләпә кигән, карт. Шәкәнәч авылыннан Гатият абый килә, зур гына түрепкәсен тартып, сирәк сакалын ышкып утыра. Мин Дусым авылыннан Шәфикъ Нигъмәтуллин, Җилгелдедән Муллагали абый Муллахмәтов белән утыра торган идем. Аларның колхозлары барлык эшләрне дә иң беренчеләрдән бетерә, мин күп чакта алар белән киңәшеп тора идем. Ул вакытларда колхоз председательләренең эш ысуллары барысыныкы да бер төсле, наряд бирү юлы белән башкарылды. Мөстәкыйль эш итә алырлык тармак җитәкчеләренең булмавы колхоз председательләренең эш стилен шул юнәлешкә керткәндер. Икенчедән, колхозлар кечкенә иде. Бу хәл колхоз председательләренә барлык тармаклар белән дә идарә итәргә тулы мөмкинлек бирә. Колхозчыларга тегермәнгә, урманга барып кайтуга, салам китерүгә атларны да председатель үзе бүлеп утыра иде. Аның транспорты да санаулы гына. Мин ул вакыттагы атларның, үгезләрнең төсләрен, башлары, мөгезләре нинди, алар күпме йөк тарта алалар, чабышканда кайсысы уза ала — барысын белә идем. Шуннан чыгып, кайсы юлга кайсы атны, кемне җибәрергә кирәклеген дә, күз йомып, әйтеп бирә идем.

Председательләрне ел саен алмаштыруны мин ул чорның иң зур хатасы дип саныйм. Безнең Түбән Шашы авылында 1930 елда колхоз төзелгән. Колхозда 1944 елның 20 июненә мин сайланганчыга кадәр председатель булып 14 кеше эшләгән: беренче председатель Валиев Гани абый, аннары Мөхәммәтгалиев Вәли, Галиев Фатих, Гайнуллин Әүхәт, Әхтәмов Сәлим, Габдрахманов Шәрип, Гыйлемханов Закир, яңадан Әхмәтов Сәлим, Халиков Вәли, Галиев Җаббар, Газизов Фаяз, Һадиев Бари, Котдусов Нуриаздан. Ел саен бер председатель. Ә менә сугыш вакытында, Сәлим абый 1942 ел башында киткәннән соң, 1944 елның 20 июненә, ягъни мин эшли башлаганчы, ике ел эчендә алты председатель алмашкан, бер елга өчәр туры килә! Мин алтынчы председатель!

1944—48 елларда без үзебезнең авыл тормышын ике чорга бүлеп, бурычлар куеп эшләдек. Беренчесе — Бөек Ватан сугышы чоры, икенчесе — сугыштан соңгы чор.

Авылыбыз кешеләре белән кулга кул тотынып, бик тату аңлашып эш иткән бер вакытта, райком секретаре Җәләлетдинов Гыйләҗ абый мине Әтнәгә чакырып, укырга китәргә тәкъдим итте. Мин шатландым. Дөрес, минем шәхси хуҗалыгым да авыр иде. Ике энем әле яшь, әни авыр эшләрдә эшли алмый иде инде. Шулай да риза булдым. Ул вакытта Казанда колхоз председательләре хәзерләү буенча ике еллык мәктәп ачылган иде. Мин бит — әле өйләнмәгән 23 яшьлек егет. Башка яшьләрнеке шикелле минем дә таныш кызым бар. Кичен караңгы төшкәч, Күнгәр авылына киттем. Ул вакытта Күнгәрнең тулы булмаган урта мәктәбендә укытучы һәм мәктәпнең укыту бүлеге мөдире булып эшләүче Биктаһирова Сарага бардым. Аны квартирыннан чакырып чыгардым. Без мәктәпкә укытучылар бүлмәсенә кереп бик озак сөйләшеп утырдык. Укырга баруымны Сара яклады. Сүз арасында шаяртып та алды: укып, кешe булгач, син мине онытырсың инде, диде... Мине укырга җыелыш җыеп озаттылар, юлга бүләк итеп 200 сум акча бирергә карар чыгардылар. Минем урынга Шәрип абый Габдрахмановны сайладылар. Шәрип абый турында башта әйтеп киткән идем инде. Ул минем эти белән бер елгы, 1898 елда туган кеше. Аңа ул вакытта

50 яшь иде. Армиядән кайткач та ул колхозда агротехник булып эшли башлаган иде. Бу иптәшне райкомда үзем тәкъдим иттем. Шәрип абый миңа ошый иде, гадел, эшчән, һәрвакыт шат күңелле. Аннан соң авылыбызга сугыштан партиягә кереп, партия члены булып кайтучы бердәнбер кеше иде. Менә шул кеше бер көнне:

— Энем, хәзер син инде зур эштә эшлисең, син партиягә кер, мин сиңа рекомендация бирермен, тагын берсен комсомолдан бирерләр, өченчесен Күнгәр мәктәбендә директор булып эшләүче Гали абыең Мөхәммәдиевтән сорарбыз. Синең атаң мине партиягә керергә кыстаган иде, сугыш башлану сәбәпле мин авылда керә алмадым, әтиең сүзен тыңлап, фронтта, окопта партиягә кердем. Менә мин, окоп коммунисты, сине шуңа өндим. Синең атаңның бөтен теләге авылда партия оешмасы булдыру иде. Алар Сәлим белән икәү генә коммунист иде, өченчесенә мине чакырдылар, ә ул эш өзелеп калган иде. Әйдә, энем, тагын бер кешене партиягә алабыз да, өч кеше булгач, үзебездә партия группасы булыр иде,— дип, мине күндерде һәм рекомендация язып бирде.

...Авылдан китү көне бик моңсу булды. Дүрт ел, дүрт авыр ел мине авылым кешеләре белән туганлаштырган икән.

Сара мине Әтнәгә кадәр озата барды. Атлы олау күздән югалганчы, ул Әтнә авылының хәзерге пекарнясы яныннан, Шәкәнәчтән Комургуҗага китә торган Чыпчык юлына карап, кул болгап торды. Мин аның үзем өчен кадерле кеше булуын аңладым.

Казанга барып төшкәч, туп-туры Авыл хуҗалыгы министрлыгының кадрлар бүлеге дип язылган бүлмәсенә кереп, тамгаланып чыктым. Анда миңа мәктәпнең адресын биреп, юлын өйрәтеп җибәрделәр. Ул «ферма № 2» дигән җирдә, аның өйрәнү-тәҗрибә хуҗалыгында булып чыкты. Иң элек дүртенче трамвай белән Суконный бистәсен узып, аның ахыргы тукталышына кадәр бардык та, шуннан җәяү киттек. Тимер юлы дамбасы астыннан чыккач, сул якта питомник җире — агачлар үсеп утыра. Ә хәрби танк училищесына кадәр бер бина да юк иде. Шуннан узуга, сул якта — «Архиерей дачасы», дип йөртелгән селекция станциясе, уң якта — Кабан күле. Фермага җиткәнче су буеннан бардык. Столбище юлыннан менеп, чирәм баскан ташландык җирләрдән үтеп, билгеләнгән урынга килеп җиттем. Бу 1948 елның октябрь башы иде. Кабул итү комиссиясенә документларымны тапшырып чыкканнан соң, имтихан вакытын билгеләделәр. Инде укучыларның күбесе килгән иде. Бездән имтихан алдылар. Татар телендә иде — алай читен булмады. Мин үзем — 23 кенә яшьтә, Ватан сугышы инвалиды, дүрт еллык председательлек стажым бар. Комиссия председателе, мәктәпнең директоры Габдуллин миңа күтәрелеп бер карап куйды. Ягымлы иде карашы...

Дүрт катлы институт бинасының аскы катына, тулай торакка, егермеләп караватлы бер бүлмәгә кереп урыннар алдык. Бүлмәләр салкын. Укырга килүчеләрнең 90 проценты сугыштан кайткан солдатлар иде. Бик тырышып укыдылар. Бу мәктәпнең укытучылары да бик әйбәт иде. Без биредә авыл хуҗалыгы фәненең нигезләрен үзләштердек. Үзебез кызыксынган аерым темалар буенча укытучылардан үтенеп, дәресләрдән соң кичләрен дә лекцияләр тыңлый торган идек.

Каникулга кайткач белдем, мине озатып калган Биктаһирова Сара Күнгәр авылыннан киткән. Аны бездән шактый ерактагы Ары авылына, җидееллык мәктәпнең завучы итеп җибәргәннәр. Ул вакытта семьяга бәйле булмаган укытучыларны авылдан авылга, кирәк урынга күчереп йөртә торганнар иде. Сагынган идем Сараны, танышым аркылы Әтнә базарына чакырдым. Очраштык. Ларекларны, чабата базарын карап йөрдек. Базар янында күп итеп өеп куелган бүрәнәләр бар иде. Кеше йөрми торган якка чыгып, озак кына сөйләшеп утырдык. Минем

дә аерылып китәсем килми, ул да, кайтам, дигән сүзне әйтми. Минем бу вакытта инде өйләнү хакындагы фикерем өлгергән иде, әниләр белән дә сөйләшеп куйган идем. Ничек итеп сүз кушарга белмичә, икеләнеп кенә йөри идем. Шунда төрле сүзләр сөйләшеп утырган булып, мин уены-чыны белән: «Әгәр мин, сиңа өйләнәм, дип әйтсәм, син нәрсә дияр идең?» — дип сорадым. Ул көлеп җибәрде дә: «Мин риза, дип әйтер идем», — диде.

Шуннан безнең телләр ачылды.

Иртәгесен Гарифҗан абый Сафиуллинны яучы итеп җибәрдем. Ул өченче октябрьга кызны алмага килергә, көндезге сәгать 12 гә, дип сөйләшеп, вакытын билгеләп, хәл итеп кайтты.

Ниһаять, өченче октябрь көнне колхоз председателе җигеп йөри торган кара айгырны тарантаска җигеп, тәңкә-чуклар белән бизәп, мин — кияү, Юсупов Самат — ат тотучы, Садриев Рафаэль — гармунчы егет, өчебез, кыз алмага чыгып киттек.

Саралар йортына якынлашканда, капкадан бер төркем хатын-кыз килеп чыкты. Өйдә безне татар халкының гореф-гадәтләре буенча мендәр салып каршы алдылар. Хатын-кызлар Сараның бармакларын онга тыгып, төрле йолалар үтәп маташтылар. Аннары без кайтып киттек. Ул көнне минем туганнар, якын кешеләр белән киленне каршы алу тантанасы ясадык. Кыскача гына әйткәндә, мин менә шулай өйләндем һәм хатынлы кеше булдым.

Өч көннән соң мин — укырга, Сара, караңгыдан торып, Ары авылына эшкә китте. Туйны Октябрь бәйрәмендә ясарга булдык.

## Туйдан соңгы тормыш

Туй булачак көн шундый матур, шундый аяз иде. Мин Казаннан кайтып төштем. Аягына яңа чабаталар киеп, аллы-артлы туй кирәк-яракларын асып, Сара килде. Октябрь бәйрәменә кадәр ике көн бар иде әле... «Аякка җиңел булсын дип әйттем»,— дип, Сара, чабатасына карап, көлә-көлә сөйләнде.

Бәйрәмдә туй ясадык.

Сараның әти-әнисе килгән иде. Якын туганнарыбыз җыелды. Бәйрәм табынында сугышка кадәрге рәхәт тыныч заманнарны, бәйрәм-сабантуйларын искә төшердек.

Менә шулай итеп, минем семья тормышым башланды. Тормышны алып бару, мин укыган вакытта Сара өстенә калды. Ул Арыдан Күнгәргә күчеп кайтты. Бер төрле ыңгырашусыз, зарланусыз эшләп йөрде Сара. Ул вакытларда барлык кешеләр дә хуҗалык бакчасын, көрәк белән казып, кул тырмасы белән тырмалап, бәрәңгене кул белән утырталар иде. Ул эшләрнең һәммәсе дә аңа калды. Минем укучы энеләремә күз-колак булу да аның өстендә иде. Мин кайткалап йөрдем. 1950 елның беренче январена Сара Казанга килгән иде. Аның белән күп җирләрдә булдык. Спектакльләр карадык, музейларга кердек. Аннары мин аны озаттым. Бик салкын көн иде, аны тимер юл вокзалына төшереп, поезд киткәнче, көтеп тордым. Ул Чыпчык станциясеннән авылга кадәр җәяү кайтырга тиеш иде. Биштәре дә шактый ук авыр иде. Мин аны кызганып карап калдым.

1950 елның сентябрь аенда безнең уку бетте. Мин үзем өчен кирәкле бик күп мәгълүмат алдым дип исәплим. Миңа таныш булмаган әйберләрне белдем. Укудан кайткач, төннәрен, бик күп әдәби, фәнни китаплар белән танышу мөмкинлеге дә тиде. Бу елны мин ВКП(б) членлыгына кабул ителдем. Казанның Свердлов райкомы бюросында расландым. Мәктәпне «Отлично»га бетерде дигән диплом алдым. Август

аенда олы улым Фаил туды, мин эти кеше булдым. Болар гади бер авыл малае өчен бик зур вакыйгалар иде.

Райкомда миңа колхозларның отчет-сайлау җыелышларына кадәр район җир бүлегендә агроном булып эшләргә тәкъдим иттеләр. Анда 1951 елның 4 январена кадәр эшләдем, көн саен алты чакрым җәяү барып, җәяү кайтып йөрдем. Бу миңа районның башка колхозларының хәлен белергә мөмкинлек бирде. Җир бүлеге мөдире Хәйруллин Хәллә абый иде. Ул колхозда — бригадир, зур бер колхозда председатель булып эшләгән, райбашкармага шуннан күтәрелгән. Колхозларның хәлен яхшы белә. Холкы да әйбәт: тиз аралашучан, шат күңелле. Без аның белән бер бүлмәдә утырып эшләдек, район җир бүлегендә башка бүлмә юк иде. Миңа авылларда авыл хуҗалыгы буенча укулар алып баруны йөкләделәр. Казанда алган белемемне ныгытырга, үзлегемнән өйрәнергә җай чыкты. Ләкин миңа бу эштә озак калырга туры килмәде. Көннәрдән бер көнне райкомга чакырып: «Хәзер колхозларны эреләндерү политикасы бара. Син председатель булып эшләгән «Чулпан» колхозын, Күнгәр авылындагы — «Удар», Югары Шашы авылындагы — «Марс» колхозы белән берләштерүне планлаштырып, председательлеккә сине тәкъдим итәргә уйлыйбыз, бюроның фикере шундый»,— диделәр. Миңа ризалык бирүдән башка чара калмады. Мине шуңа махсус укыттылар.

Бу урында, яңадан ничек колхоз председателе булып китүемне яза башлаганчы, икенче бер мәсьәләгә тукталып узыйм. Казанда мин укыган мәктәп 1951 елны өч еллык итеп үзгәртелде һәм агроном дипломы бирел чыгара торган булды. Миндә бу мәктәпнең төгәл курсын тәмамлау теләге туды. Мин 1952 елның көзендә председатель булып эшли башлаган җиремнән, укып бетереп кайтырга рөхсәт алдым да, яңадан Казанга китеп бардым. Мине мәктәпнең өченче курсына бик теләп кабул иттеләр. Янә бер ел укып, урта белемле агроном дипломы алып кайттым. Безнең районның бу мәктәпне минем белән бергә Этнә авылыннан Җиһаншин Усман Шаһиевич, Бәрәскә авылыннан Акбиров Гыйльметдин бетереп кайттылар. Мин турыдан-туры үз урыныма кайттым. Җиһаншин «Коммунизм таңы» колхозына председатель булды. Бакчаты Яңа Бәрәскә дигән авыл белән берләшкән иде, Гыйльметдинне шуңа председатель итеп куйдылар. Шул рәвешле, колхоз председательлегенә белемле кешеләр килә башлады. Ул елларны партия Үзәк Комитетының колхозларга 30 мең кешене җитәкче итеп җибәрү хакындагы карары чыкты.

1951 елның 10 январь көнне мин авылга кайтып төштем. Өч авылда да берләштерү җыелышлары булырга тиеш иде. Икенче көнне 11 январьда, мин билгеләнгән вакытта, Күнгәр авылына җыелышка килдем. Берләштерелгән яңа колхозның идарәсен сайладылар. Аның председателе итеп минем кандидатура күрсәтелгәч, Түбән Шашы кешеләре кул чапты, миңа күңелле булды, мине яклаучы авылдашларым бар дип уйладым. Авырлык килсә, аларга таянырга була.

Берләштерелгән зур колхозга «Удар» исеме бирелде. Иртәгесен бригадирлар барысы да килгәннәр, өч авылга тугыз бригадир. Тугызы белән дә озаклап сөйләштек. Түбән Шашы белән Югары Шашыда иген сугылып беткән, Күнгәрдә сугасы иген күп иде әле.

Иртәгесен Күнгәр авылына юл тоттым. Бу электән үк зур авыл булып, безнең өч авылның авыл Советы да шушында урнашкан иде. Башка авылларда — клуб, уку йортлары юк чакта да, аларда — булды. Үзешчән театр, концертлар да беренче шушы авылда оешкан иде. Анда тулы булмаган урта мәктәп бар, анда күп кенә укытучылар эшли. Югары һәм Түбән Шашыга МТС хезмәт күрсәтми, бу авылга МТС хезмәт күрсәтә иде. Сугыш башлану белән армиягә китәргә повесткаларны да безгә шушы авыл Советыннан китерделәр. Сугыш елында Күнгәр

бик күп авырлык кичерде. Хәлсезләнде. Карап торырга ул бик ярлы. Кешеләрнең киемнәре начар, каралтылары да бик тузган иде. Сугыш вакытындагы тормыш авырлыгыннан туеп, арып-алҗып беткән кешеләр читкә китеп бардылар. Сугышка кадәр бу авылда 240 хуҗалык яшәгән, ә мин колхозны кабул иткәндә, нибарысы 97 хуҗалык торып калган иде. Югары Шашы авылында сугышка кадәр 105 хуҗалык булган, мин кабул иткәндә, 67 хуҗалык иде. Түбән Шашыда, ягъни минем туган авылымда да кимү бар, шулай да сугышка кадәр бу авылда 170 хуҗалык булып, сугыш беткәндә 110 хуҗалык калган иде әле. Иң мөһиме — Түбән Шашыда үсеп килә торган яшь буын бар, ә менә Күнгәрдә яшьләр аз, эшкә яраклылары авылдан китә торган. Шул сәбәпле булса кирәк, бу авылның бер елны да үз вакытында эше бетә алмады. Мин кечкенә колхозда эшләгәндә дә, социалистик ярдәм, дип, катып калган бәрәңгеләрне алу өчен, ломнар күтәреп килә идек. Барыбер алынып бетмичә кала иде.

Менә шушындый хәлдәге колхозны сөйрәргә тиеш идек без. Өстәвенә бит әле берләштерелгән колхозның исеме дә шушы колхоз исеме белән «Удар» булып калды. Иң элек мин үземә кадәр председатель булып эшләгән Абдулла абый белән атлар хәлен карарга бардым. Атларның хәле бик начар иде. Бездә инде атлар ярсып, кешнәп тора, боларда әле күтәрәмгә калганнары да бар. Нык куллы булырга кирәк иде. Төннәрен атлар янына дежур куйдык. Бер ай эчендә атларны аякка бастырдык.

Ләкин әле шуңа кадәрге бер вакыйганы сөйләп бирми хәлем юк. Без ат абзарларына кергәндә, анда Нәҗип абый Гарипов — ат караучы — бар иде. «Нигә атлар бу хәлгә төште?» — дип соравым булды, ат караучы ярсый-ярсый элекке председательгә ташланды:

— Син инде аны, энем, менә бу бозык адәмнән сора! Атта кайгысы булдымыни аның?! Хатын-кыз артыннан чапты бит ул, җир бит, мөрәвәтсез, мир үгезе!

Мин инде ник сорау биргәнемә үкенә үк башлаган идем, әмма элекке председатель Абдулланың берни булмагандай, авызын ерып елмаеп торуы мине уйга калдырды. Һәм мин Күнгәр халкының йөрәк бәгырендә утырган Абдулла-председательнең бирелгәге тормыш-көнкүрешен өйрәнеп чыктым.

Ул Мамадыш ягыннан икән. Авыл халкы бу кешене бер дә җитәкче итеп танымаган. Хатын-кызга азгын карашы аркасында аңа: «Үлеп калган солдатларның намусын таптаучы син!» — дип күзенә карап әйтә торган булганнар. Ә Нәҗип абыйның кызып китүен мин аңладым. Ул атларны бик яратучы кеше булып чыкты. Крестьян бит элек атка туйдыручысы итеп караган! Ул шуңа күрә бик әрнеп кычкырган икән.

Бер рәттән мин фермада да булдым. Анда Хәтәм абый Саммасов мөдир иде. Җайлап кына сөйләшә. Ферма хәлләрен дә иплән кенә аңлатып бирде. Фермада сыерлар да, сарыклар да, дуңгызлар да әллә ни мактанырлык түгел. Шулай да, фермадагы шартларга караганда, тәртип канәгатьләнерлек иде. Тәрәзәләрдән җил өрми, ватык тәрәзәләр иске такталар белән пөхтә итеп кадакланган иде. Торакларда, караңгырак булса да, тәртип бар. Без килгәндә Хәтәм абый иске кадаклар турайтып утыра иде. Күзлеген кигән, сакалы җиткән, башта мин аның хакында бик таркау ахрысы дип уйлаган идем. Ә торакларга кереп карап чыккач һәм үзенең сөйләвен тыңлагач, ул фикерләремнән кире кайттым. Ул бик тәртипле, итәгатьле, гадел кеше булып чыкты. Соңыннан Күнгәр авылындагы хәлләрне Хәтәм абый аркылы белеп тора торган булдым. Ул һәркайчан гадел итеп эчкерсез сөйләп бирә иде. Нинди дә булса карар кабул итәргә туры килгәндә, аның фикеренә таяну дөрескә чыга иде. Сыер савучылардан Мөкәррәмә Гарипова, Фазылова Разия апалар Хәтәм абыйны бик ихтирам итәләр, сүзен тыңлыйлар

иде. Ә минә элеккеге председатель Абдулла белән кергәндә, хатын-кызлар да, Хәтәм абый да аңа күтәрелеп тә карамадылар. Әйтерсең, бирәдә ул бөтенләй дә юк. Соңыннан Хәтәм абый белән без озак-озак сөйләшеп утыра торган булдык. Минем өчен Күңгәр авылы халкының үткәнен һәм хәзергесен белү бик мөһим иде. Кешеләрне аңламый торып, аңа нинди эш кушарга икәнен дә белмисең. Җитәкченең ялгышы менә шуннан — барлык кеше дә бер чыбыктан дип уйлаудан башлана. Хәзерлексез кешегә тапшыру аркасында, күп кенә җаваплы эшләрнең җимерелүен мин аңлаган идем инде. Ә бу өлкәдә миңа Хәтәм абый бик зур ярдәм итте. Шулай бер көнне сөйләшеп утырганда:

— Хәтәм абый, син теге вакытта, мин беренче килгәндә, элекке председателегез Абдулла абыйга бүрегә караган кебек карадың, нишләп алай эшләдең? Аның сәбәбе нәрсәдә? — дип сорадым.

— Энем, сәбәбе күп инде,— диде ферма мөдире. — Менә безнең хәлебезне күрәсең бит, терлекләребез начар, продукция юк, ул аның белән кызыксынмый. Авылда кеше калмады, яшьләр качып бетте,— ул аларның тормышы белән дә кызыксынмый. Анысына да исем китмәс иде, сугышта үлеп калган кешеләрнең хатыннарына үрелә. Безнең арада акыллылыгы белән аерылып торган, эти-әнинең иң яраткан улы булган Искәндәр энемнең хатынын да юлдан яздырды. Хәзер менә шул киленне күргән саен йөрәгем әрни. Ул да миңа очрамаска тырыша, мин үткәндә, урамда булса, бер сәбәпсез икенче кеше капкасына кереп, качып кала. Энем Искәндәрнең инде кайтмаячагын да беләм. 30 яше дә тулмаган баласыз хатынның сугышта үлгән кешене көтеп торырга тиеш түгел икәнлеген дә, икенче берәү белән тормышын башлап җибәрергә хаклы икәнен дә беләм, әмма бу азгын белән буталуын күтәрә алмыйм. Ул бит семьясын, балаларын ташлаган кеше, икенче семьясын да бер дә чирканмыйча ташлавы мөмкин. Киленебез әйбәт иде, шуны-сы кызганыч...

Шул беренче көнне без дуңгызларга бәрәңге пешерә торган җиргә кердек. Анда Бәдриева Әнвәр апаны очраттым. Шулкадәр фәкыйрьлек булса да булыр икән, киемнәре кырык ямаулы, хәтта башындагы яулыгына кадәр ямаулы иде. Кечкенә генә мунча бинасы, анда төтен чыккан, пар күтәрелгән, кеше күренми. Әнвәр апаны чакырып алып кына хәлләрен сорап киттек. Соңыннан, бәйрәм көннәрендә, матур, чиста киенгән вакытларын күргән саен, Әнвәр апаның фермадагы кыяфәте күз алдыма килеп йөдәтте. Беренче тапкыр чиста киемнәр киеп йөри башлагач, урамда күреп, нинди чибәр хатын икән, теге вакытта кот чыгарлык хәлдә иде бит, дип уйладым...

Менә шушы хәлләрне карап чыкканнан соң, элеккеге председатель Абдулла абыйны, сез миңа бүтән кирәкмисез, калганын бригадирлар белән карап бетерермен дип кайтарып җибәрдем. Ул озак та тормады, яңа хатынын алып, каядыр читкә чыгып китте. Дөрес эшләде, аңа бу авылда яшәү бик авыр булыр иде.

Күңгәрдә минем өчен икенче мөһим эш — сугыласы ашлыкны сугып бетерү иде. Әвенгә менсәм, ни күрим, сәгать бер тулган, әле сугу машинасы тик тора. Бу эшләр белән әвен бригадиры җитәкчелек итәргә тиеш булса да, ындырчылар белән эшләү фактта двигательче Вәлиев Рәхимгә йөкләнгән. Аны авыл халкы тыңлый, чөнки ул Ватан сугышында яраланып кайтканнан соң, ватылып яткан двигательне көйләп, шуның көче белән сугу машинасын әйләндереп, авыл халкының хезмәтен җиңеләйткән булган. Председатель килде — ындырчылар юк. Нинди зур авыл, бер сугу машинасын эшләтерлек кеше җыйнап китерә алмыйлар! Өч бригадир, бер-берсенә салынып, бу эшне таркалу хәленә җиткергәннәр. Өстәвенә ашлык сугу, җилгәрү, салам селкетүдә катнашучылар, өйләренә киткәндә, көндез һәм кич салам алып кайталар икән. Дөресен әйткәндә, алар, ашлык сугудан бигрәк, салам алып кай-

тырга киләләр. Ферма янында салам юк, әвен янында да салам эскертләре күренми. Эчем «жуу» итеп китте. Хәзер сугасы ашлык та бик аз, ә салам бер дә юк. Колхоз терлекләренә нәрсә бирербез? Ә бит Күнгәрдә тайлары белән 45 ат, 80 ләп сыер (аның 30—40 башы савым сыерлары), 100 гә якын сарык, 25 дуңгыз бар, нишләргә? Чарасына керешергә кирәк. Рәхим абый белән шул хакта сөйләштек, безнең сүзне бригадирлар да тыңлап торды. Сәгать икенчедә генә Рәхим абыйның малае Рүзәл кечкенә генә бер кара ат белән беренче чүмәлә саламны әвен алдыннан тарттырып чыгып китә алды. Барабанда ашлык сукты-ручы Хәдичә апа Хәсәнова да бу хәлдән бер дә риза түгеллеген сөйләп торды. Икенче көнне үк тәртип урнаштырырга керештек. Мин үзем башка эшләрне ташлап булса да, бер атнага якын әвеннән чыкмый яттым. Иң элек бригададагы барлык хатын-кызның исәбен алдык, ындыр сугуны ун көнне — бер бригада, икенче ун көнне — икенче, өченче ун көнне өченче бригада башкара торган итеп көйләдек. Башта кеше җитмәс дигән шикләнүләр булган иде. Бригадир Вәлиев Габдрахман: мин башлап карыйм, алайса, диде.

Беренче ун көндә үк бик күп ашлык сугылды. Әвен янына эскерт салына башлады, ферма янына, яз өчен, дип, салам китерергә тотындык. Ындыр сугучыларның өйгә салам ташуларын туктаттык. Төннәрен, саламны саклау өчен, каравылчы куйдык. Икенче ун көнлектә Мәҗит бригадасы эшне бик әйбәп башлап җибәрде. Безнең кулга кергән саннарга караганда, сугу эше инде бетәргә тиеш иде. Фактта әле сугыласы ашлык күп булып чыкты. Басудагы кибәннәрне барлап, гектарын чамалап кердек. Идарәгә ялгыш мәгълүмат бирелгән. Сугасы ашлык чынбарлыкта, дүрт-биш мәртәбә күбрәк булып чыкты. Бу үз чиратында салам кайгысын алып ташлады. Озын-озын дүрт эскертне әвен янына салып куйдык. Басудан кайтасы, сугыласы ашлык саламыннан хуҗалыкларга бирү өчен өлеш чыгару мөмкинлеге туды. Күздән бирле хуҗалыкка салам өләшенмәгән икән. Иген суккан җирдән урлап ташып, хайван ашатканнар, калганы белән өйләрен җылытып яшәгәннәр. Хәзер исәпсез ташуны туктаткач, кешеләр борчуга төшкән иде. Аларга, эшләгәннәренә карап, хезмәт көненә исәпләп, атларга төяп, олаулы саламнар өләшә башладык. Кешеләр күңеленә тынычлык керде. Эшкә тәртип салынды. Хезмәт көне белән исәпләшмичә йөргән, төрле сәбәпләр табып, ындыр сугудан качканнар үкенә башлады. Алар арасында иң явызы Галиева Мәргубә иде. Дөресен генә әйткәндә, болай кеше өстендә яшәргә, урлашырга ярамаганны аңа кат-кат әйткәннәр, тыңламаган. Бәрәңге алганда, бәрәңгене казып чыгармыйча, сабагын көрәк белән генә чабып өзеп, аягы белән таптап кына барганлыгы билгеле булды. Шулай ук Ширияздaнова Шәкәр, Вәлиуллина Мәрьямнәр эшкә бик салкын карадылар. Аларны гел басым ясап кына эшләтергә туры килде. Боларның тискәре мисалы гадел эшләүче башка кешеләрнең ачуын чыгара торган иде. Яхшы эшләүче кешеләр: «Менә шуларга бер җитәкче дә йогынты ясый алмады, колхозга кертегез әле шул сөрхәнтәйләрне!» — дип әйтә торганнар иде. Ләкин аларга да чара табылды. Галиева Мәргубә бер төнне сәгать берләрдә әвенгә салам урларга менеп, бауга төяп күтәреп алып чыккан да авылга төшә башлаган. Бу елларда без, авыл Советы активлары, төнге дежурлыкны көчәйткән идек. Менә бу көнне авыл Советы секретаре Мөбарәкшин Госман, Мәргубәне сагалап тора да, артыннан барып җитеп, саламына сизмәстән генә ут төртә. Бара торгач, кинәттән салам гөлт итеп кабынып китә, Мәргубә апа бу хәлдән коты чыгып, саламны ташлап, авылга чаба...

Дәүләт заданиесе үтәлү белән, кешеләргә икмәк бирдек. Әле бу вакытка кадәр аванс тәртибендә генә бүленгән булган. Бөртекләр бозлы булса да, тырышып эшләгән кешеләр бик сөенде.

Хәзер мин үзем генә түгел идем инде. Колхозыбызда партия оешмасы, авыл Советы, комсомол оешмасы булды. Күп әйберләрне алар белән киңәшеп алып бардык. Күрәсең, булсынга йөрүче тырыш җитәкчегә алар да мохтаҗ. Минем үтенечемне бер вакытта да кире какмадылар. Колхоздагы агитация эше, газета чыгару, кешеләргә газета уку шикелле эшләр «Чулпан» колхозында чакта минем өстә иде. Партоешма секретаре Гали абый бу эшләрне үзенә алды. «Син, энем, производство белән шөгыльлән, без анда бик кереп йөри алмабыз, бездән ярдәм кирәксә, тартынма, сора»,— дип әйтә торган иде. Гали абый укытучым да, мине партиягә керергә рекомендация бирүче дә булганга, аңа ихтирамым зур иде. Ләкин ул кеше миннән алдарак председатель итеп сайланып куелган, ул эшне тарта алмаганлыктан, дисциплина йомшарган, ул эштән бушатылгач, дәрәҗәсе бераз кимегән иде. Алай булуга да карамастан, аны бик тә үз иттем.

Авыл Советы председателе Абдулла абый Гатауллин ерак урманнарга агач кисәргә баручыларны оештыруда ярдәм итә иде. Ул вакытта ерак урманда эшләү, электр станцияләренә торф хәзерләргә кеше табу бик авыр иде. Бер мәртәбә барып кайтканнарның барасылары килми, бала-чаганы урманга җибәреп булмый. Ерак урманнарга егермешәр атлы кеше, утызар җәяүлене оештырып чыгара торган идек. Мин элек эшләгән колхозда хәл җиңелрәк иде. Бергә аунап үскән кеше булгангадыр, алар мине тыңлыйлар. Мин үзем дә алар янына урманнарга барып, хәлләрен белеп, ашарларына илтеп йөри торган идем. Алар еракта мари урманында, Арча ягында Гөберчәк, Сикертән, Күлтәс дигән авылларда эшләп ятсалар да, үз авылы, үз колхозы җылысын тоеп яшиләр иде. Менә бу өч авылның кешеләрен оештырганда да, Түбән Шашы кешеләренә таянып: «Егетләр, сез хәзерләнеп чыгыгыз инде, сез кузгалгач, теге авыллар да китми булдыра алмый»,— дип, алар үрнәгендә ике авылның икесен дә оештырып җибәрә торган идек. Яңа председательне белеп җиткермиләр, колхоз җитәкчесенә карата ышанычлары беткән, чөнки аларны вәгъдә биреп тә алдап калдырганнар. Менә шушы факторлар ерак урманнарга кеше җибәргән вакытта, бик тискәре йогынты ясый иде. Күңгәр авылыннан ерак урманга кеше җибәрү өчен Рәхмәтуллин Равилне иртәдән кичкә кадәр үгетләп утырдык. Бер якка да килми, әйбәтләп әйтеп карадык, тиргәп-ачуланып карадык, булмады,— ахырдан, идарә утырышы җыйнап, мәҗбүри генә җибәрә алдык. Әхмәтов Булат, Галәвиев Равил, Дәүләтшин Ихсаннар чыгып китте, ә бу уйлап та бирми. Ике көн соңга калып кына кузгалды. Шулай да андый тискәре кешеләрне үз киреләкләре белән ярты юлда калдыруга ирек куймадык. Мин башлаган эшемне азагына илтеп җиткерергә өйрәнгән идем инде.

Юл уңаенда мәктәпкә кереп чыгарга булдык. Мәктәпнең бинасы искергән, без укыган класслар тәбәнәкләнеп калган кебек тоелды. Шушы мәктәптә мин 1937-38 елларда укыдым. Беренче укытучым Күлле Киме авылыннан килеп эшләгән Әхмәдуллина Мәйсәрә апа искә төште. Ул вакытта үзебезнең авылда мулла йортында укыталар иде. Соңыннан ул йортны сүтеп, мәктәп ясадылар. Икенче, өченче, дүртенче классны мин Югары Шашы авылында укыган идем. Менә бу ике авылның балалары ул вакытта бер классны — бер авылда, икенчесен икенче авылда укыйлар иде. Югары Шашыда безнең классны Чымбулат авылында Фазылҗанов Рәхим абый укытты. Соңыннан ул Күңгәр мәктәбенә директор булды. Шул Рәхим абый бервакыт, Кызыл Армия көненә, безнең Түбән Шашы авылына җыелыш үткәрергә килде. Мәктәп бинасында җыелыш бара, без сәхнәгә ошатыбрак ясалган җирдә, президиум өстәле янында утыра идек. Сәхнәнең алгы өлешендә балалар, яшь кызлар утыралар. Шунда Гыйльметдинова Фәридә дигән кыз җәелебрәк утыра, бик шаян бер малай, Садриев Ильяс, шул кызга чыбык белән

төртеп тора. Шуңа эче пошкан Рәхим абый үрелеп Ильясның башына төртмәкче иде, президиум өстәлендәге кызыл тукыма җыерылып, ияреп килде дә, өстәл өстендәге лампа авып китте, керосин түгелеп, сәхнәгә ут капты, сәхнә ярыгыннан идән астына түгелгән керосин дөрләп, янгын куркынычын тудырды. Кешеләр ишеккә тыгылдылар. Рәхим абый аптырап калмады, иңбашына салган яшел шинелен утка каплады да ут шуның белән тынды. Кешеләр яңадан керделәр, докладтан соң балалар концертын рәхәтләнеп карадылар. Иске мәктәп бинасын карап йөргәндә, әнә шул истәлекләрем яңарды. Моңсу да, рәхәт тә булып китте. Рәхәт — күңелдә балачак яңарды, моңсу — мәктәп бинасын яңаны салырга кирәк...

Колхоз белән тулысынча танышып чыккач, берләштерелгән зур колхозның беренче идарә утырышын җыйдык. Көн тәртибенә тармак җитәкчеләрен раслау куелган иде. Ферма мөдирләре, бригадирлар, амбарчылар, колхозның агрономы, ветеринария фельдшерлары — санитарлары, бухгалтеры билгеләнде. Ферма мөдирлегенә, ат карауга кешеләрне аеруча җентекләп тикшереп куйдык. Бригадалар санын кыскарттык. Алда язгы чәчүгә нык итеп әзерләнү бурычы тора иде. Тәртипсезлекне бетерү хакында күп сөйләштек.

Аннары эшкә чумдык. Элек мин үзем кушып, үзем оештырам, үзем контроль ясый идем, хәзер бу эшләрнең барысына да өлгерү мөмкин түгеллеге сизелә башлады. Иң элек контрольгә кереп бетми торган эшләр күзгә чалынды. Атлар Күнгәрдә һәм Югары Шашыда ат җигүчеләрнең ишегалдында тугарыла, ат абзарына буш атны гына китерә торган булганнар. Без Түбән Шашыда атны колхоз абзары янында тугара идек. Контрольлек итү өчен уңай иде ул. Менә бу авылларда да шул тәртипне кертә башладык. Аны оештыру җиңел булмады. Иң элек җитәкчеләр, өлкән ат караучылар, атлар кайтып беткәнче көтү, дир бияларын төзәтеп тору бурычын йөкләгәч, уңайсызланып, өстәмә хезмәт хакы турында фикер йөртә башладылар. Аларны ышандырырга, хәтта мәҗбүр итәргә туры килде. Ә ат җигүчеләр һич тә риза булмадылар. Без бу эшне Түбән Шашыда бик ансат кына эшләгән идек. Бер көнне әйттек, икенче көнне барлык егетләр белән җыйналдык та беттек. Ә монда авыр иде, аркалык-түшлекне, камыт бауларын кисеп китү, чананың тәртә бауларын чабып өзү, җәй көне арбаларның кеше утырып йөри торган урыннарына дегет сылап калдыру кебек хәлләр булгалады. Ә ат җигүчеләр, моны сәбәп итеп, арбаларны, чаналарны өйләренә алып кайтуны, элеккечә эшләүне таләп иттеләр. Монда төп сәбәп — һәр көнне өйгә кайтканда, чана, арба төбенә печән, салам, бәрәңге, хәтта икмәк тә салып кайта алу. Гомумән, колхозда кешеләргә гарантияләнгән хезмәт хакы бирелмәгәнлектән, урлау гадәте таралган иде. Менә шуңа күрә безнең яңа тәртипне авыр кабул иттеләр. Шул уңайдан ат җигүне ташлаучылар да булды. Әмма безнең тәртипне Күнгәрнең алдынгы кешеләре, коммунистлары якладылар. Алар арасында Сәләхи абый Шиһапов та бар иде. Аны колхоз идарәсендә ашлык амбарына мөдир итеп куярга тәкъдим иттеләр. Чөнки ул гаделлек белән авылда дан казанган кеше икән. Тик Сәләхи абыйның үзен чакырып сөйләшә башлагач, ризалашмады. Сәбәбен әйтмәде, миннән булмый ул эш, дип кенә куйды. Шул вакытта Куәм МТСының директоры Ибраһим Ишниязов килеп чыкты, тракторларны эштә ничек файдалану хакында минем белән киңәшергә килгән. Ул Сәләхи абый белән сөйләшкәнне тыңлап утырды: «Энем, бик дөрес эшләгәнсез, мин белгәннәрдән бу авылда моннан да гадел кеше юк. Сәләхи, син элекке үпкәләреңне оныт, яшь җитәкчеләргә кулдан килгәнчә ярдәм ит», — диде. Азактан ул миңа Сәләхи абыйның нигә үпкәләвен дә сөйләп бирде. Бу кеше шундый гадел, элек амбарда мөдир булып эшләгән, өенә кайтканда, чабатасына кергән ашлык бөртеген дә амбарда кагып калдыра икән. Ревизия ва-

кытында аның күпмедер тарысы житмәгән, әрәм-шәрәм иткән, дип эшеннән чыгарганнар, идарәгә куеп, судка бирәбез, дип куркытканнар. Шуңа бик нык хәтерә калган.

МТС директоры Ишниязовның ярдәме белән Сәләхи абый орлык амбары мөдирлегенә риза булды. Алар МТС директоры белән Этнә МТСында бергә эшләгәннәр икән. Сәләхи абый, рабфак бетереп кайткач, МТСта партоешма секретаре булган. Гомумән, аның тәҗрибәсе зур, яше ягыннан да, ул минем әти кебек, безгә, яшьләргә, мөнәсәбәте белән дә, әти булырлык кеше иде. Колхоз аңардан бик күп игелек күрде.

Менә мин, берләштерелгән зур колхозда хезмәт дисциплинасын урнаштыруыбызны язган чакта, партия Үзәк Комитетының 1982 елгы ноябрь Пленумы карарларын уйлап утырам. Игенче өчен дә, эшче өчен дә бик кадерле бу карарларда илдә тәртип булдыру, хезмәт дисциплинасын ныгыту мәсьәләсе алгы планга чыгарып куелган. Без, игенчеләр, колхоз житәкчеләре, моны хуплыйбыз, чөнки без өч дистә ел буена хезмәт дисциплинасы өчен жан аямый эшләвебезнең әрәмгә китмәвен, кайбер жилкуар бәндәләр тарафыннан юкка чыгарылмавын телибез.

...Көннәр язга авыша башлады. МТСтан чаналарга төяп тагылма машиналарны алып кайтырга керештеләр. Зур-зур агрегатлар күрү минем өчен бик сөенечле булды. Ул вакытта чәчү машиналары да анкерлы сошниклар белән иде. Тракторларның күбесе — көпчәкле «СТЗ»лар, арада бер генә «НАТИ» бар иде. Аннан, язга чыкканда гына Дусым авылы кешесе Фазылжанов Иосыф «ДТ-54» тракторын алып килде. Трактор өр-яңа иде, МТСка дүрт кенә трактор кайтуына карамастан, Ишниязов аларның берсен безнең колхозга бирде. Күрәсең, сүзендә торган: мин сезгә ярдәм итәрмен, дигән иде бит! Телефоннан шалтыратып та әйтте, МТСның иң яхшы тракторчысын жибәрдем, аңа булдыклы берәр алмашчы куегыз, диде. Сүзен тыңлап, Иосыфка алмашка армиядән кайткан, трактор йөртергә укыган Галимулла Хәйруллинны билгеләдек.

Зур колхозны житәкләгәндә, механизаторлар булмауның уңайсызлыгы нык сизелде. Үзебезнең кадрларның осталыклары шәптән түгел иде. Яхшы тракторчылар үз авылларыннан читкә чыкмыйлар. Көн тәртибенә механизаторлар әзерләү килеп басты. Үз авылыбыз кешеләреннән Нәбиуллин Ярулла, Мөбарәкшин Абдулла, Гыйлемханов Гаяз «НАТИ» тракторын өйрәнделәр. Тракторлар, комбайннар күбәйгән саен, бу яңа эш кадрларны күбрәк таләп итте.

МТС белән ике араны дустанә тоту шактый авыр иде. Трактор бригадалары үзләренә жайлы жирләрне генә сукалап, уңайсыз жирләрне ат белән эшләргә калдыралар иде. Шулай бер көнне Югары Шашы басуында чәчү бетмәс борын, күлнең теге ягында чиста пар жирендә яңа тракторның жир сөреп йөргәнен күрдем. Эңгер инеп килә. Атны борып шунда кердем. Тракторчы Галимулла Хәйруллинны кабинасыннан чыгардым. Безнең арада менә мондый сөйләшү булды:

— Нишләп әле син иртә культуралар чәчә торган борчак жирен ташлап, чиста пар жирен сукалыйсың? Кем кушты?

— Трактор бригадасы бригадиры Гыйлемханов Нури кушты.

— Борчак жирен иртә өлгертергә кирәк, хәзер үк шунда күч!

— Юк, мин бригадирдан башка бер кая да күчмим, ул миңе бик каты кисәтте.

Ул арада, трактор туктаганны ишетеп, икенче тракторны да сабан жиреннән пар жиренә күчерергә дип барган трактор бригадиры Гыйлемханов Нури абый килеп чыкты. Мин аңа әйттем:

— Нури абый, бу жиргә керергә кем кушты?

— Мин куштым,— дип Нури абый горур гына жавап бирде.

— Нишләп, минем белән киңәшмичә, сабан эшен бетермичә торып, пар сукаларга тотындың?

— Калган җирләрегезне ат белән бетерерсез, анда тракторга уңайсыз, мин монда эшләтүне яхшы санадым, монда алар күбрәк сукалый алалар.

— Язгы чәчүнең вакыты бик кыска бит, атларга калса, яңадан бер атналык эш туа, әгәр тракторлар эшләсә, ике көндә чәчүне бетерергә мөмкин.

Нури абый кул гына селекте:

— Синең белән файдасызга көн үткәреп торырга вакыт юк минем, энекәш,— диде. Гөрләп торган тракторга. — Әйдә, сукалый башла! — дип боерык бирде. Тракторчы, газга басып, әкрен генә кузгалып китте. Ләкин мин бирешергә теләмәдем, тиз генә атны бордым да, буразнага аркылы куйдым. Тракторчы, атка җиткәч, тагын туктады. Шуннан Нури абый, йөгереп килеп, атны йөгәненнән тарта башлады, мин икенче якка тарттым. Тартыша торгач, мин аны этеп җибәрдем, ул чалкан әйләнеп төште. Шуннан ул тракторчыга әйтте, тракторны сүндер дә кайтып кит, диде. Миңа бик каты янады. «Кара аны, малай, җавабын үзең бирерсең, иртәгә мин МТС директорын чакырам»,— диде. Шулай итеп, ул көнне трактор эшләмәде. Иртәгесен МТС директоры Ишниязов килде. Без аның белән трактор янына таба машинага утырып конторадан чыгып киттек, Нури абыйны басуда очраттык. Ул колхоздан җигеп йөрергә алган атының аркалыгын ычкындырган, йөгән балдагын дугадан җибәргән, тимер хут арбасының бау белән мичәләгән араларыннан аягын асылындырып утырган, дилбегә урынына әллә нинди иске баулар тагып куйган иде. Шушы кыяфәте белән МТС директорыннан үзен кызгандырырга уйлады булса кирәк. Без килеп җитү белән, хәлсезләнгән булып, читкә барып утырды.

— Мин бу колхозда эшли алмыйм, миңа ирек юк, миңа начар дирбиялар белән начар ат бирә председатель. Кичә мине төртеп екты, менә кул башым әле дә авырта,— дип зарлана башлады. Ишниязов аны сабыр гына тыңлап торды. Аннары миннән сөйләтте, соңыннан болай диде:

— Шушы хәлгә төшүгә син үзең гаепле. Ни өчен син, «Удар» колхозында язгы чәчү бетмәс борын, үз белдегең белән, тракторларны башка басуга күчердең? Ни өчен татулыкны боздың? Хәзер үк тракторны сабан җиренә күчерт! — диде.

Трактор шундук кузгалып китте.

Трактор бригадиры, колхоздан колхозга күчеп, ни теләсә шуны эшләп йөрергә өйрәнгән. Бездә аңа юл куелмауны, гомумән, горурлыгына кимчелек килүне бик авыр кичерде. Әле идарәгә кайткач та директор аңа гел бер сүзне тукыды: «Тату эшләргә кирәк. Сез элекке председательләрне җиңел өйрәнгәнсез. Хәзер колхозга укыган кешеләр килде. Алар безгә басуда хулиганланырга ирек бирмәсләр»,— дип шелтәләде.

Үзенең турыдан-туры җитәкчесеннән яклау тапмагач, Нури абый, уф йөрәгем дип, идарә бинасыннан чыгып китеп, ишегалдындагы чирәмгә ятты, су сорап алды. Шул вакытта идарәгә килгән Таҗиева Гөләндәм апа аңа стакан белән су чыгарып бирде. Бригадир, шуннан соң тынычланып киттем, дигән булып, торып утырды. Соңыннан МТС директоры, ул шундый спектакльләр куя белә, җитте, шамакайланма, әйдә, эшкә кит, диде.

Нури абый анда да үз дигәнен итәргә тырышты. «Мин бу хәлдән соң трактор бригадиры булып эшли алмам инде, мине эштән бушатыгыз»,— дип ишекне каты ябып чыгып китте.

Бер җирдә ике хуҗа булуның уңайсызлыгын беренче мәртәбә мин үз җилкәмдә татыдым.

Илленче елларны безнең колхозыбыз район күләмендә яхшы колхозлар рәтенә керде. Элек гектардан 4—6 центнер гына икмәк үстергән колхоз хәзер 8—11 центнер ала башлады. Колхозчыларның ышанычы артты. 1954 елларда өлкәннәргә алмашка өр-яңа буын килде. Яшьләр аталарыннан калган йортларны үзгәртеп, яңа йортлар сала башладылар. Бу безне бик сөендерде. Чөнки авылда калырга теләге булган кеше генә мондый зур эшләр кузгатырга уйлый. Шуны аңлап, колхоз идарәсе мөмкин булган ярдәмнән бер семьяны да ташламады. Тракторлар, машиналар арткач, МТСлардан сорап, иң элек механизаторларның йорт салу өчен булган бүрәнәләрен кайтартуны, колхозда яхшы эшләгән башка кешеләргә дә транспорт бирүне гадәткә керттек. Бу үз чиратында, әгәр әйбәт эшләсән, безнең колхоз ярдәм итүдән бер вакытта да баш тартмый, дигән яхшы фикергә китерде.

1955 елны безнең колхоз зур уңыш үстергән өчен СССР авыл хуҗалыгы күргәзмәсенә катнашу хокукы алды, диплом һәм бронза медаль белән бүләкләнде. Шул исәптән мине дә бронза медаль белән бүләкләделәр. Шул ук елны мине партиянең өлкә конференциясенә делегат итеп сайладылар. Колхозның исеме район күләменнән республика күләменә килеп чыкты. Финанс якларыбыз да җайлана төште. Терлек продуктларын җитештерү һәм сату шактый артты. Колхозда яңа абзарлар, әвеннәр, амбарлар төзелә башлады. Шәһәр белән район арасында автобуслар йөри, яшьләр юк-юк та шәһәр ягына күз салгалыйлар. Әле бу вакытларда без колхозда иртәнге сәгать өчтән кичке тугыз-уннарга хәтле эш таләп итә идек. Ә шәһәрләргә сугыш вакытындагы торгынлыктан күтәрелү чоры килде, төзелеш киң җәелеп китте. Шәһәргә эшче куллар бик кирәк булып чыкты. Кешеләрне Волгоград, Саратов, Донбасс, Кузбасс, Сахалин кебек җирләргә өндәп йөрүче вәкилләр дә күбәйде. Авыл кешеләре үзләренең искергән, җимерек йортларын сипләүгә караганда, вербовщиклар белән китеп, әзер торакларда яшәүне кулайрак күрделәр, «ничегрәк булыр икән?»— дип, минем янымa киңәшкә килделәр. Минем хәтеремдә калган кешеләрдән Галиева Кәримә биш баласы белән, Җәләлиева Бәрия өч баласы белән Каракалпакка күчеп киттеләр. Югары Шашы, Күнгәр авылларыннан да берничә семьяның тәвәккәлләве хәтеремдә калган. Без колхоз идарәсендә, күченеп йөрүчеләрне булдырмас өчен, ипләп кенә, ыгы-зыгы тудырмыйча гына эш итә башладык. Шушы елларны өч авылга да радио керттек. Аны халык бик сөенеп каршы алды. Радио авыл өйләренә җырчыларыбыз исемен ишеттерде. Шуның өстенә ул вакытта республика күчмә театры белән безнең ара яхшыланып китте, без аларның кабат килүләрен бик үтенеп сорап кала торган идек. Алар безнең сүзебезне бер вакытта да читкә какмадылар. «Тормыш җыры», «Изге амәнәт», «Шәмсекамәр» кебек бик яхшы әчтәлекле, халыкның элекке һәм хәзерге тормышын күрсәткән спектакльләрне елаша-елаша карый торган идек.

Материаль яктан да файдалы эшләр эшләнде. Сугышта ирләре үлеп калган киленнәр арасында кайнаналарын карауны авырыксынучылар да табылды. Шуны исәпкә алып, колхоз картларының киләчәген бәхетсез итмәү өчен, колхоз хисабына Картлар йорты ачтык, тәрбиячеләр билгеләдек. Авыл халкы бу эшне дә бик хуплады. Читтән караганда, гади генә эш булса да, ул колхозга карата кешеләрдә җылы фикер уятырга ярдәм итте. Шул елларда ук авылда медицина пункты ачып җибәрдек. Алар авыл халкының сәламәтлеген күзәтеп торып, зур эш башкардылар.

Ул чорда авыл халкы өчен кибеткә промышленность товарлары бик аз кайта торган иде. Тора-бара бу товарлар күбәйде. Кибеткә кайткан товарларга урын җитми башлады. Өч авылда да кибетләргә ремонт үткәрдек. Өч авылның уртасына, басуга промтовар кибете салдык. Төзү

материалы табу ансат түгел иде. Биектау районындагы ташландык таш келәтне сүттек. Шулай итеп, авыл уртасында бердәнбер мәһабәт таш бина барлыкка килде. Өч авылга да уңай булсын дип, басуга колхоз идарәсе бинасы ясаттык. Яңа бина бик матур иде. Шуның янына 16 гектар җирдә алма, кара карлыган бакчасы утыртып җибәрдек. Аны рәшәткәләр белән әйләндереп алдык. Әйләнәсенә агачлар утыртып чыктык. Басуда яңа урам барлыкка килде. Күнгәр авылындагы мәчетне, шул ук колхоз идарәсе каршына китертеп, клуб итеп салдык. Соңыннан ул бинага өстәп, агачтан фойе һәм артистлар бүлмәләре эшләттек. Авылга тавышсыз кино килә иде инде, шул уңайдан тавышлы кино өчен шартлар булдыру кирәклеге сизелә иде. Безнең колхозчылар җылы бинада тавышлы кино карый башладылар. Ул чорда Бөек Ватан сугышы батырлары турындагы фильмнар күп чыга иде. Суык клубларда, киноаппаратын хәрәкәткә китерү өчен эчке ягулы двигательләр белән азапланып эшләүләр артта калды.

Бу елларны идарә колхозчыларның шәхси йортларын ремонтлау һәм яңаларын салуны җәелдереп җибәрде. Бер елга егерме-утыз йорт салган чаклар була иде. 1954 елда миңа да яңа йорт салырга чират житте. Төзелеш башланган илленче елларда үземә йорт сала башлау уңайсыз иде. Иң алдан землянкаларда, аварияле йортларда яшәүчеләрне чыгарырга кирәк иде. Ахырдан колхозчылар да, минем белән ачыктан-ачык сөйләшеп йөри торган дусларым: «Фәйзи, синә да йортыңны сала башларга вакыт җиткәндер, өең, җимерелеп, өстеңә ауганны көтмәсәң бит инде,— дип әйтә башладылар. — Үзеңнең вакытың булмаса, без ярдәм итәрбез»,— диделәр Ганиев Кави белән Хәйруллин Галимулла. Дөрестән дә, алар мин җитешә алмаган вакытта, миңа материал табып, алып кайтып биреп, зур ярдәм иттеләр. Әзер бураны Мари АССРның Комургужа авылыннан сатып алдым. Тактаны Кенәр артеленең такта яру заводы сатып бирде. Райбашкармада колхозчыларга бирелә торган агач фондыннан сорап алырга уңайсызландым. Чөнки бу вакытта йортлары минекеннән дә начаррак кешеләр бар иде әле. Шуннан чыгып, кыйммәтрәк булса да, документлы әзер бураны сатып алуны кулай күрдем. Бу хәл минем хакта колхозчыларда, эшкә гадел карый, дигән әйбәт фикер тудырды. Башка чакта да үземнең шәхси хуҗалыгымны кешенекеннән артык итмәскә тырыштым.

Безгә, колхоз җитәкчеләренә, игенченең ышанычын казану бик кыйммәт иде.

Менә колхоз идарәсе, партия оешмасы, авыл советы тарафыннан үткәрелгән югарыда санап киткән чаралар, кешеләрнең алга баруына, үсүенә йогынты ясады. Ул чорда җитәкчеләрнең үзләренә дә күп нәрсәгә өйрәнергә кирәк иде. Авылга кайткан яңа машиналар — трактор, комбайн, автомашина механизатор кадрларын булдыруны таләп итте. Авылга иң беренче «ГАЗ-51» машинасы 1951 елда кайткан иде, аны колхозда ак май ясап, май талонына алдык. Ул машинаны йөртерлек кеше безнең авылда юк иде. Кызыл Юл районы Ташчишмә авылы кешесе Закиров Шәйдулланы яллап куярга туры килде. Шуннан соң, колхозга бер «ЗИС» машинасы, яңадан бер «ГАЗ-51» машинасы кайтты, болар барысы да дәүләткә ак май сату хисабына бирелделәр. Аларны йөртергә Галиев Җаббар, Газизов Абдуллалар өйрәнде. Үзебездә кадрлар булу белән, ялланган шоферны җибәрдек. Аның машинасына Мөбарәкшин Камил күчте. Хәзерге көндә безнең колхозда 45 автомобиле булган машина паркы бар икән, ул һәрвакыт шулай түгел иде бит. Паркның беренче көннәре бик аздан башланды. Әмма шул аз гына машиналар да, көне-төне эшләп, колхозга һәм хуҗалыкларга бик күп агач материалы ташыдылар. Шоферларына да, машиналарына да рәхмәт әйтәм мин аларның.

Колхозларга куәтле тракторлар кайта башлагач, тирән сөрү ысулы килеп чыкты. Иген уңышын күтәрү өчен бик файдалы, дип, кызыктыргач, югарыдан да кәгазьләр килгәч, МТС житәкчеләре бу эшне авылларда үткәрергә гаять зур дәрт белән тотынды. Чыннан да ул вакытта Үзәк Комитетның бер Пленумында тирән сөрү хакында күрсәтмә булды. Ә бу эш безнең район житәкчеләренең төп бурычына әйләнде. Кесәләренә сантиметрлы линейкалар тыгып, басуга барган саен, сукалаган җирнең 22 сантиметр булуын таләп итеп йөрделәр. МТСтан барлык тракторлар да шулай сөрергә тиеш дип, бик каты кисәтү җибәрелде. Ә без, авылдагы элекке житәкчеләр, агротехник Садыйков Абдулла, Габдрахманов Шәрип, Шиһапов Сәләхи, гомере буена жир сөргән тракторчы Нәбиуллин Ярулла, яшьләрдән Абдуллин Харис, Ганиев Габдерәкыйп, Вәлиев Габдрахманнар белән сөйләшеп, жир өстенә кызыл балчыкны чыгармаска, әрләнь балчыгы күренеркүренмәс кенә тирәнлектә сөрергә кирәк дип фикер йөрттек. Сай сөрүне бигрәк тә Садыйков Абдулла белән мин якладым. Шул фикерне трактор бригадасы алдында, механизаторлар жыелышында күтәрдек. Алар, без бер нәрсә дә белмибез, безгә 22 сантиметр тирәнлектә сөрергә куштылар, без шулай эшлибез, әгәр без шулай эшләмәсәк, безне бүләктән мәхрүм итәчәкләр, дип, безгә каршы төштеләр. Озак сөйләштек, төпле бер фикергә килдек: сөрү катламы тирәнлегендә генә сөрергә. Ә бездә сөрү катламы 11 сантиметрдан 18 сантиметрга кадәр генә иде. Тракторчылар бригадиры Хәкимжанов Гадел дә, механизаторлар да риза булдылар, шулай эшләдек тә.

Әмма чәчү бетәр алдыннан бер көнне МТСтан һәм районнан вәкилләр килеп төште. «Сез 12 сантиметр тирәнлектә генә сөрәсез икән, шуны тикшереп, сезне райком бюросына әзерләргә килдек»,— диделәр.

Болар Кышлау авылы янындагы 50 гектарлы жирдә Мөбарәкшин Абдулланың борчак чәчү өчен сукалаган жиренә баруны таләп иттеләр. МТС машинасына утырып, шунда киттек. Ул вакытта баш агроном Ситдыйков дигән иптәш иде. Барсак, Абдулла сукалап ята, үлчәделәр — 13 сантиметр тирәнлектә. Мин тыныч идем. Әрләнь балчыгы зәңгәрсу булып күренеп тора. Участокны карадылар, кайтып акт яздылар. Миңа кичен райком бюросына килергә куштылар. Райкомнан килгән вәкил Гафиуллин Гариф абый иде. Ул үзенең тәгаллеге, күргән вакыйгаларны түкми-чәчми алып кайтып житкерә алуы белән безгә, колхоз председательләренә, билгеле иде. Мин, өйгә кайтып тамак ялгап алдым да, ат җигеп, Әтнәгә киттем. Барып коридорда йөрим. Мин тәрәзә буена сөялеп торганда, райкомның беренче секретаре Шакир Садыйков килде. «Исәнмесез!» — дип дәштем, жавап ишетмәдем. Бик караңгы чырай белән, миңа дәшмичә дә, кабинетка кереп китте. Бераздан мине чакырдылар. Бюро членнары өстәлнең ике ягына тезелеп утырганнар, барысы да түбән караганнар. Ишектән кереп бастым, аягүрә торам. Секретарь әйтте:

— Я, сөйлә, ничек итеп син агротехника кагыйдәләрен боздың? Үзәк Комитетның тирән сөрү турындагы карары белән исәпләшмичә, ни өчен үз белдегең белән эшләдең? — диде.

— Үзәк Комитет безнең өчен генә карар чыгармый бит, бәлки ул Украина, Кубань жирләренә карата булгандыр, безнең жир 22 сантиметр тирәнлекне күтәрә алмый бит. Бездә сөрү катламы сай, өскә кызыл балчык чыгарсак, жир бик тиз ката, йөзәр ел буена крестьянның авыр кул хезмәте белән булдырылган кара туфракны кызыл балчык белән бутап бетерә алмыйбыз бит инде,— дип, юл буе уйлап килгән

сүзләремне әйтә генә башлаган идем, райком секретаре Шакир Садыйков шалт иттереп кулы белән өстәлгә сукты да: «Житте! — дип кычкырды. — Синең хәлең обкомга барып житте, миңа ул эшең өчен җавап бирергә кирәк булачак. Ә син, мальчишка, акыл сатып, безне өйрәтеп торасың, элек борыныңны сөртергә өйрән, аннары безне өйрәтерсең!» — дип кызып китте. Миңа шелтә белдерделәр, 22 сантиметр тирәнлектә сөрергә дигән күрсәтмә биреп, кайтарып җибәрделәр.

Мин бик хурландым, гарьләндем, күңелем бик төште. Ләкин, кайткач, бу хәлне берәүгә дә әйтмәдем. Гомумән, үземә килгән авырлыкны кешегә бервакытта да күчерми торган идем мин.

Райкомның бу секретаре колхоз председательләре белән бик дорфа эш итә иде. Бу хәл Казанга барып җитеп, анда тикшерелеп, Садыйков кадрлар белән эшләүдәге кимчелекләре өчен, эшеннән бушатылды. Ләкин ул безгә кыйбатка төште. Шул елны барлык колхоз председательләре дә куркып яшәүчән булдылар, минем башым сызлый башлады, кан басымым күтәрелде, баш сызлау өянәге биш ел буена сузылды.

Садыйков эшеннән алынганнан соң, нәкъ шул чорда республикада зур бер киңәшмә булды. Анда партия Үзәк Комитетының тирән сөрү хакындагы карарын дөрес аңламыйча, сөрү катламы сай булган урыннарда гасырлар буена булдырылган уңышлы катламны әрлән балчык белән бутау аркасында, җирнең структурасы бозылуын сөйләделәр. Ялгышлыкны төзәтү юллары билгеләнде. Зур күләмнәрдә органик ашлама кертмичә торып, әлеге ялгышны төзәтеп булмаячак, дигән фикергә киленде. Әле менә утыз елдан соң да шул ялгышлыкның зыяны авыл хуҗалыгында сизелеп тора. Менә шул киңәшмәдә миңа да катнашырга туры килде. Үч иткәндәй, Садыйков та килгән иде, ул МТСта эшли иде. Ике арадагы булган хәлне онытмаган икән. «Кара әле, ул вакытта син бит дөрес эшләгәнсең, ә без ялгышканбыз»,— дип әйтергә ихтыяр көче җитте.

Бу хәлләрне колхозыбызның тарихына кертүемнең сәбәбе шул: колхоз җитәкчеләренең чын җитәкче булып өлгерүендә, формалашуында югары оешмаларның да рольләре зур. Алар җитәкчегә илһам, канат биреп җибәрергә мөмкин, алар аның канатын сындырып, эшкә булган инициативасын бетерергә, гади йомыш үтәүче генә итеп калдырырга да мөмкин.

Илленче-алтмышынчы елларны колхоз идарәсе үзенең төп эше итеп җирдән дөрес файдалануны алгы планга куйды. Шуннан чыгып җирне саклау, аның мөмкинлекләрен өйрәнү, кайсы басуда нинди культура ничегрәк үсә, шуларны өйрәнә барып, табигатьнең көйсезлекләренә җайлашып, алдан чамалап, уңай якка үзгәртү буенча чаралар күрә башладык. Без иң әүвәл сугыш вакытында тегеннән-моннан кайтып калган ашлыктан җыйналган орлык фондын яңартырга тиеш идек. Шул нигездә әкренләп яңа чыккан сортларның үзебезгә охшаганнарын сайлап алдык. Бәрәңгенең дә Алат спирт заводына кайдандыр читтән кайткан «лорх» сортын утырта башладык. Күп еллардан бирле җыелып килгән тиресне кырга чыгардык. Торф белән ашлауны практикага керттек.

Терлекчелек өлкәсендә дә элеккеге крестьян сыерын бетереп, аны Холмогор токымына алмаштыру өчен Архангельск өлкәсенең Холмогор районыннан таналар, үгезләр алып кайттык. Сыерларны Түбән Шашы авылына тупладык. Савымчылар 10 кешедән 16 кешегә җитте, савым сыерлар саны да 200 гә якынайды. Дуңгызларны, сарыкларны Күнгәр авылына китердек. Мөгезле эре терлекләрнең яшьләрен Югары Шашы авылында калдырдык. Атларны да бергә җыйнап, өч авыл уртасына ат абзары салдык. Түбән Шашы, Югары Шашы авылындагы вак амбарларны җыйнап, зур амбарлар җитештердек, түбә-

ләрен калай белән яптырдык. Ул чорда безнең колхозыбызда калай түбәләр кибеттә дә, шушы амбарларда гына булып торды. Алар авылыбызның йөзен үзгәртеп, матурландырып җибәрделәр. Терлекчеләрнең төзек бер шәһәрчеге барлыкка килде. Мал-туарга су эчертү, сыерларның тиресен чистартуга асылмалы юллар куя башладык. Түбән Шашыда сыерлар өчен агачтан ике абзар салдык. Күнгәрдә сарык тораклары булдырдык.

Колхоз белән идарә итүдә элекке алымнарның искергәнлеге сизелә башлады. Нәрәт биреп утыру, колхозчыларга атны председатель рөхсәте белән генә бирү бик күп вакытны ала иде, бу эшләр бригадирларга йөкләнде. Бригадирлар да үзләренә йөкләнгән эшкә җаваплы карарлык булып өлгерделәр.

Колхозчыларның хезмәтенә акчалата гарантияле түләү мөмкинлеге туды. Аннан икмәкләтә, печәнләтә, саламлата бирүне колхозга авырлык булган елларны да эшләми калмадык. Ә бу үз нәүбәтендә колхоз җитәкчеләренә ышанычны ныгытты. Аерата урак ура башлагач, дәүләт заданиеләрен үтәгән көнне, колхоз идарәсе ишегалдына авыл халкын җыйнап, күпме икмәк биреләчәген, аның тантаналы көнен билгеләп, колхозчыларны өметләндерә идек.

Аннан мин, колхозлар берләшкәч, ике арада дошманлык чыгуга сәбәп калмаса ярар иде, дип курка идем. Аерата Түбән Шашы кешеләреннән сүз булмагае, хәзер без азрак уңыш алабыз, дигән сүзләр чыкмагае, дип шикләнә идем. Чөнки һәр авылның үз гадәте, үз карашы, әйләнә-тирәсенә йогынты ясый белә торган кешеләре бар, алар нинди якка таба борып җибәрәләр бит әле. Менә шушы үзенчәлекләрне истә тотып, Түбән Шашы халкы белән аерым сөйләшергә туры килде. Алар мине аңладылар, колхозның авыр эшләрен күбесенчә үз өсләренә алдылар. Рәхмәт аларга! Әмма бер көнне басуга баргач, язгы чәчү вакытында тракторга ягулык салырга тиешле кеше Нигъмәтҗанов Газизнең килмәгәне билгеле булды. Мин тракторчылар белән сөйләшеп тора идем. Муллагали абый Кәбиров Күнгәр авылыннан бер кешегә әйтте, кем икәнен хәзер хәтерләмим, «әсәнәй» тагын килмәгән ич әле, диде. Мин моңа игътибар итмәдем, тик ул сүзне яңадан ишеткәләргә туры килде. Һәм ул, халык арасында таралып, Түбән Шашы халкына карата кимсетү сүзе урынына кулланыла башлады. «Әсәнәй» дигән кеше (чын исеме Йосыф) Түбән Шашыга Әтнә авылыннан килеп тора башлаган. Бик ярлы булганлыктан, кешедән хәер җыйнап яшәгән. Менә шул кешенең исеме Түбән Шашыларга кимсетү итеп әйтелә булып чыкты бит әле. Янә дә колхозлар зураеп, Күшәр авылы белән кушылгач, бу исем, бу өч авылга да тагылып, аннан Ташчишмә авылы белән кушылгач, дүртенче авылга да тагылып, барысы да «әсәнәйләр» булып киттеләр. Аны туктату өчен күп көч куярга туры килде.

Ахырдан бу өч авыл бер-берсенә ияләштеләр. Бер авыл кешеләре кебек яши башладылар, авыллар арасында ызгыш-мазар чыкмады. Җәмәгать биналарын, кибет, янгын сарае, колхоз идарәсе, клуб, китапханәләрне өч авылның берсендә дә калдырмыйча, тигез итеп, метр белән үлчәп, арадагы басуга салу да уңай нәтиҗә бирде.

Колхозларның эреләнүен үзләштереп, әйбәт кенә эшләп йөргәндә, 1957 елның көзендә миңа бу колхоздан китәргә туры килде.

Көз көне район партия оешмасының конференциясендә мине райком члены, ә пленумда райкомның авыл хуҗалыгы эшләрен башкаручы секретарь итеп сайлап куйдылар. Аннан элекке көнне мине обкомга Харитонов дигән иптәш янына чакырганнар иде. Ахырдан, килмәсен, конференция үткәрергә Әтнә райкомына Татарстан АССР Верховный Советы Президиумы Председателе Низамов иптәш бара, аның белән сөйләшерләр, дигәннәр. Шул көнне безнең колхозга Ни-

замов иптәш килеп, минем белән сөйләшеп китте, ни өчен сөйләшкәнен аңламый калдым. Конференция вакытында гына эшнең нидә икәнен аңлап, уңайсызланып утырдым, күңелемнән риза булмасам да, чынбарлыкта каршы килә алмадым.

Сайланып эш беткәч, колхозчылар алдында җыелыш үткәреп, председатель сайлатырга райкомның беренче секретаре Әхмәтов Хаммат килде. Җыелыш кичкә кадәр азапланды, мине бушатырга дип кул күтәрүче булмады. Җыелышны ачык калдырып таралыштык. Иртәгесен тагын дәвам ителде, бу юлы кешеләр бик аз килгән иде. Авылга активлар таратып, кешеләрне җыйдык. Янадан бушатырга кул күтәрүче булмады, тагын ачык калдырып таралыштык. Өченче көнне коммунистларны җыеп, авыл советы депутатларын чакырып, авылларга бүленеп, кешеләрне җыелышка хәзерләргә, ә коммунистларга чыгышлар ясарга задание биреп, яңадан җыелдык. Бик озак аңлату алып барганнан соң, тавышка куйдылар. Мине председательлектән бушатырга коммунистлар, авыл активы кул күтәрде, каршылар булмады. Каршы булмагач, Галиев председательлектән бушатылды, дип игълан ителде. Колхоз председателе итеп, колхозга КПСС Үзәк Комитетының колхозларны житәкче кадрлар белән ныгытырга дигән карары нигезендә, колхоз председателенең ярдәмчесе булып кайткан, Күнгәр кешесе, элек Әтнә банкында управляющий булган Дәүләтшин Шәүкәт абый сайланды. Бу кандидатураны мин үзем тәкъдим иткән идем. Ул иренмичә, кулыннан килгәнчә тырышучы кеше иде.

Шулай итеп, мин райком секретаре булдым. Миңа, иртә таңнан кичке караңгыга кадәр колхозчылар арасында йөрергә өйрәнгән кешегә, монда бик тын булып тоелды. Докладлар, карар проектлары, партия оешмаларына төрле хатлар язу миңа йөкләнде. Бу эштән бик аерылганмын икән инде, минем өчен алар бик читен шөгыльләр булып чыкты. Төрле оешмаларга, җыелышларга йөрергә туры килде. Башта гел кабинетта утырып, көн үтми йөдәтте, эш белән күмелгәч, көн житми башлады. Колхозларга вәкил булып барырга туры килә иде. Менә монысын яратып башкара идем. Башка кешеләрнең эшләрен күреп, үзем председатель булган дәвер белән чагыштыру мөмкинлеге туды.

1958 елны колхозларга техниканы сатып бирү буенча мин дәүләт комиссиясе члены булып, Күәм МТСы тракторларын колхозларга озатуда булыштым. Шул эш беткәч, Ибраһим абый Ишниязов Күәм авылына председатель итеп куелды. Элек эшләгән Җамалиев китте. Ибраһим абый характеры белән кырысрак кеше булса да, мин аны бик хөрмәт итә идем, ул да мине ихтирам итте. Язгы чәчүдә мин колхоз председателе булып эшләгәндәге ысулларны аның колхозында кулландык. Урак өстендә дә күбрәк мин шул колхозда булдым. Колхоз ул елны иген уңышы буенча районда беренче урыннарның берсен яулады, яңа эшли башлаган председательнең ул бик зур казанышы иде. Ул үзен хәзер МТС директоры итеп түгел, колхоз председателе итеп сизә башлады. Ул елны аеры уру бик нык пропагандаланды, без аеры уруның вакытын билгеләп, игеннәр өлгереп житүгә, уракка төштек, ашлыкны югалтусыз җыеп алдык, дәүләткә икмәк тапшыруны да үз вакытында бетердек...

Ул вакытта безнең райкомга беренче секретарь булып Ибраһимов Мөнәвир Гәрәевич сайланган иде. Көннәрдән бер көнне ул миңа обком секретаре белән сөйләшергә кушты. Ул вакытта Семен Денисович Игнатьев иде. Ул бер хат алганлыгы хакында әйтте. Авыл халкы имза җыйнаган, колхозга синең яңадан кайтуыңны сорыйлар, диде. Аңарчы да бер хат булды. Райком секретаре авылга барып, әңгәмә үткәреп, кешеләрне тынычландырып кайткан иде. Бу юлы ул: «Син ничек карыйсың? Сине бер районга райбашкарма председателе итеп җибәрергә ният бар»,— диде. Мин, күчеп йөрмим, шушында гына эш-

лим инде, дип калдым. Ул, ярый алайса, диде, шуның белән сүз бетте. Ә менә бу соңгы хатта имзалар бик күп булган, алар минем кабаттан колхоз председателе булып кайтуымны сораганнар.

Мөнәвир Гәрәевич, син әгәр райбашкарма председателе булып башка районга китмәсәң дә, бер исемлеккә кергәч, сине борчу дәвам итәр инде, ярый, әйдә, менә бу колхозны тагын эреләндерү планлаштырыла. Шул үзең эшләгән колхозыңа председатель бул, диде. Мин бик теләп ризалаштым.

1959 елның февраль аенда мин Югары Шашы, Күнгәр, Түбән Шашы, Күшәр, Мөндеш авылларыннан торган зур колхозның председателе итеп сайландым. Гомуми җыелыш «Удар» колхозы клубында булды. Зал шыгрым тулы иде. Күп кешеләр арасыннан үземнең авылдашларымны шәйләп алдым, аларның күңеле шат, күләч. Үзебезнекен иттек бит, кабаттан кире кайтардык бит, дип әйтүләре сизелеп тора. Җыелыш озакка бармады, идарә членнары 11 кешедән 13 кешегә җиткерелде. Колхоз председательлегенә мине тәкъдим итү белән өч авыл халкы, аягүрә басып, кул чаба башлады. Ә Күшәр авылы кешеләре мине ишетү буенча гына беләләр иде. Алар да, залга кушылып, алкышладылар.

Күшәр авылы кешеләре җыелышка ат җигеп килгәннәр иде. Киемнәре чиста, матур. Күбесенең туганнары бар икән, кунак булып, кич кенә кайтып киттеләр. Аларны өч авыл халкы, җыелыштан чыгып, җыйналып, матур итеп озатып калдылар. Беренче очрашу миндә канәгатьләнү хисе уятты.

Тагын мәшәкатьле, борчулы эшләр — ашлыкны һәм терлекләрне, амбар һәм келәтләрне, җәмәгать каралтыларын карау-барлау башланды...

Иң беренче эш итеп миңа Күшәр авылы кешеләре алдында җыелышта чыгыш ясарга туры килде. Күз күне колхозчыларга ашлык өләшү ведомосте төзелгән булган. Аны сугылачак ашлык бәрабәренә чыгарганнар. Фактта ул ашлык көтелгән күләмдә җыйналмаган. Нәтиҗә ясап әйткәндә, юк ашлыкка ведомость төзелгән. Бу хәл берничә ел кабатланып килеп, колхозның колхозчыларга бирәсе әҗәте җыелган иде. Боларның барысын списать итүне колхозчылар алдына куйдым. Бик озак аңлаштык. Күп аңлата торгач, риза булдылар. Шул рәвешле кенәгәләрдәге алачак-бирәчәкләрне чистарттык.

Төп эшебез язгы чәчүгә әзерлеккә әйләнеп калды. Начар әзерләнмәдек, кыр эшләрен әйбәт үткәрдек. Тик бирегә күңелгә ошамый торган бер нәрсә килеп чыкты. Бу колхоз элек барлык эшләрне дә бик иртә бетерергә гадәтләнгән икән. Язгы чәчүгә дә ашыгыбрак чыгу кешеләрнең гадәтенә әйләнгән. Шулай бер көнне иртүк басуга барсам, трактор бригадиры Ибраһимов Гариф басуда Шәрипов Габдрахманны сүгеп ята. Егетебез күл буенда эшләгән җиргә бара алмаган, тракторы белән иңкүлеккә баткан, су эчендә утыра... Бу минем өчен бик зур сабак иде, басуга, өлгерүен бик җентекләп карагач кына, чыга торган булдык.

Ләкин мәшәкать бетмәгән иде әле. Озак та узмый, безгә Ташчишмә белән Мокшы авыллары кушылды. Җиде авыл булдык. Хәзер колхоз җирләренең буе — 24, иңе 15 километрга җитте.

Ниһаять, колхозның бүген йөртә торган исеме «Искра»га килеп җиттек.

Ике колхоз берләшкәнгә әле бер ел да үтмәгән вакытта өченче колхозны берләштереп кую минем өчен бик авыр йөк булды. Кешеләрен әлерәк кенә белә башлаган Күшәр, Мөндеш авылларын бер читкә куеп торып, Ташчишмә, Мокшы авылын өйрәнергә тотындым. Иртәгесен Ташчишмә авылына бардым. Үзем белән идарәне дә алып килдем. Иске мәчеттән кормаштырган клуб бинасына халык җыйналган иде.

Бер генә таныш кеше дә юк дип әйтер идем, Түбән Шашы авылында ялланып эшләгән шофер Шәйдулла абый Закировның хатыны Мәһирә апа залда утыра икән. Аның белән ияк кагып кына исәнләшеп алдык. Ул да күңелгә җылы булып китте.

— Иптәшләр, җыелыш председателе сайлап тормыйбыз, колхоз идарәсенең җитәкчеләре белән сезне таныштырырга дип килдек. Идарәгә барган вакытларыгызда, керәге чыгар, аларны танып калсыннар, дибез. Аннары — сезнең колхоз эшенә һәм үзегезнең тормышыгызга кагылышлы нинди үтенеч-сорауларыгыз бар, шуларны белеп кит у дә бик мөһим. Иң элек үзем әйтим. 1925 елда туганмын. 1944 елдан бирле колхоз председателе булып эшләдем. 15 еллык председательлек стажым бар. Шушы колхозның Түбән Шашы авылында туып-үстем. Ватан сугышында катнаштым, яраланып кайттым, өч балам бар, әнием минем белән тора, хатыным тулы булмаган урта мәктәптә укыта,— дип кыскача гына сөйләп бирдем.

Башта тыныч кына тыңладылар. Аннары яннарында утырган иптәшләре белән пышылдашып сөйләшеп алдылар. Аннан авыл советы председателе Фәттиев Фәйзи абый белән таныштырдым. Мин таныштырганда, ул басып торды. Без сәхнәгә менеп, озын өстәл янына тезелеп утырган идек. Шуннан ревкомиссия председателе Камалов Сабир абый, колхозның председатель ярдәмчесе — баш зоотехник Дәүләтшин Шәүкәт, баш хисапчы Җәләлиева Һәдия, аннан колхозның баш механигы Насретдинов Гарифҗан, баш агроном Фирдәвес Галиев белән таныштырып чыктым. Аннары: «Безгә сорауларыгыз бармы?» — дип сорадык та, колхозның идарә утырышы карары буенча Ташчишмә авылына бригадир итеп Гарипов Шамилне, элек шул ук эшне башкарган иптәшне билгеләп, үтенечләрегез булса, үзегез колхоз идарәсенә килеп тә тормастан, шул иптәш аша хәл итә аласыз,— дип аңлатып чыктык.

Җыелыш бетүгә, элек колхозда икенче хисапчы булып эшләгән Зәйтүнә безне чәй эчәргә чакырды. Аларга кереп, бәрәңге ашап, кайнар чәй эчеп чыктык. Шуннан рәхмәт әйтеп, ике атка төялеп, Мокшы авылына барып, алар белән дә таныштык. Бу авыл Ташчишмә бригадасының бер звеносы булачак инде. Аның җитәкчесе итеп Гарипов Шамилнең ярдәмчесе Сираҗиев Фаяз билгеләнде. Ике авыл да үз теләкләре белән кушылганга күрә, үзләрен тыенкы тоттылар. Шулай да ахырдан Ташчишмә тегерменәнә он тарттырырга барган кешеләргә Ташчишмә авылыныкы бер хатын: «Бер төркем кеше сәхнәгә менеп утырды, алар арасында безнең авылдан бер Шамил гына бөрешеп утыра, кызганып куйдык үзен»,— дип әйтеп җибәрде. Күрәсең, бригадир, барлык җитәкчеләр дә башка авылныкы булганлыктан, үзен уңайсызрак тоткандыр. Алга таба да ул бик батыраеп китмәде. Беренче елларда бик сак булды, кыю сүз әйтергә шикләнеп йөрде. Бәлки, безгә карата, боларга ышанырга ярыймы, нинди кеше болар? — дигән уй да аны борчыгандыр. Авылның җитәкчеләрен алмаштырып бетерү дә Шамилнең характерына йогынты ясамый калмагандыр. Соңыннан ул, әлбәттә, кыюлана төште.

Бер ел эшләгәннән соң, 1960 елның исәп-хисап җыелышын җыйдык. Үзәк клубка Ташчишмә авылыннан бик әзерләнеп килгәннәр иде.

— Без еракта яшибез, безне кимсетәсез, безнең хуҗалыкларга яңа машиналарны, яңа тракторларны бирмисез,— дип бик кинәт һөҗүмгә күчтеләр. Бу җыелышта Абдуллин Тимери, Әхмәтгалиев Мөбарәкша, Сәгдуллин Гарифлар берничә мәртәбә чәчрәп чыгып сөйләделәр. «Сигез аяклы сарык буламы?» — дип, әллә ниткән сораулар бирделәр. Мин тыныч кына аңлатырга тырыштым, ләкин алар барыбер аңламадылар. Шуннан соң Күшәр һәм Күнгәр авылыннан килгән кешеләр

дә шул сүзне кабатлагач, торып: «Сез, егетләр, тыңлап-тыңлап торабыз да, һаман шул сигез аяклы сарык хакында сөйлисез, башка сүзегез булмаса, җитте сезгә!» — дип әйтсәк тә, кул күтәртеп, сөйләүләрне туктаттык, җыелышның карарын укып ябып та куйдык. Ташчишмә авылыннан килгән иптәшләр зур колхоз җыелышында теләсә нәрсәне көчләп тагу политикась үтмәгәнлегенә инанып кайтып киттеләр. Башка бер вакытта да андый авантюрага бармадылар. Җитәкчеләргә карата яла ягуны кабатламадылар. Ә җыелышта: «Сигез аяклы сарык буламы?» — дип биргән сорауларның мәгънәсе шул: механизаторларга гомуми туклану өчен сарыклар суйган идек. Ташчишмә авылына җибәргән сарык итендә сарыкның бот ягы күбрәк булган, итен башка бригадалар ашап, безгә сыйрак кына җибәрәсез, дип үпкәләп әйтүләре булган икән. Чыннан да шулай булгандырмы, завхоз, алай түгел, тигез бүләргә тырыштык, дип акланды. Әмма бу идарә өчен сабак булып калды. Шуннан соң бригадаларга бирелә торган әйберләрне күздән үткәрү гамәлгә керде, машиналар җибәргәндә дә, эш күләменнән чыгып бүләргә тырыштык. Ә бу җыелыштан соң Ташчишмә авылыннан килгән кешеләрне «Сигез аяклар килде!» — дип үртәп сөйли торган булдылар. «Әсәнәй» урынына яңа кушамат тагылды. Төрле-төрле холыктагы Җиде авылны үзләренә генә хас кире гадәтләреннән арындыру, гомуми гадәткә нияләндерү өчен, бик күп көч түгәргә кирәк иде.

Ташчишмә авылы кешеләре соңга таба үзләрен бик яхшы тоттылар, әштә дә, җыелышларда да әдәп саклап, уйлап кына сөйли торган булдылар.

Җиде авылны бер колхозга берләштерү ашыгыбрак, уйланылмыйчарак эшләнгән булып чыкты. Шуның аркасында колхозның партия оешмасына, идарәсенә көтелмәгән мәшәкатьләр өстәлде.

Тәртипләрне санга сукмау Күшәр авылында аеруча сизелде. Бу авылның үз тәртипләре, күрәсең, аларга ошаган, аны үзгәртү аларга килешмәде. Алар юк ашлыкка төзелгән ведомостьны, җыелыш карары нигезендә, юкка чыгаруны да яратмадылар. Икенчесе — бу авыл территориясендә 200 гектарлы куаклык булган, шуның чыбыгын, ел да саен бүлеп, бүлмәгәне, теләгәнчә, теләсә кайсы вакытта ташыган, чөнки колхоз аты һәркемнең ишегалдында тугарылган. Без куак кисеп ташуны туктаттык. Өченчесе — атларны колхоз ихатасына туплап, нык контроль астына алдык. Дүртенчедән, бу авылда җир, болынлык, елгалар күп булганлыктан, аның печәнен колхоз чабып, җыйнап бетерә алмаган. Шуннан файдаланып, каян теләсә, шуннан җәй буена печән әзерләгән кешеләр күп итеп хайван асрап, башка авылларга печән сатып яшәргә көйләнгәннәр. Гомумән, колхоз буенча тәртип кerткәч, елга буйлары, чабылып бетмәгән җирләр чабылып бетә башлагач, печән хезмәт хакы бәрабәренә бирелә башлагач, эшләмичә йөрергә өйрәнгән кешеләрнең эче пошты. Атларның исәбе булгач, теләсә кая, теләсә кайсы вакытта чыгып та китә алмадылар. Бишенчедән, колхозда дисциплина бозып, үзенә тапшырганны начар башкаручы, шуңа бик нык нияләшеп, аннан усал ният белән файдаланучылар эшләреннән бушатылды, алар урынына булдыклы, сәләтле, намуслы кешеләр сайлап алынды. Болар барысы яңа председательгә карата ризасызлыкны көчәйттеләр. Ә колхозда тырышып эшләүче кешеләр: механизаторлар, терлекчеләр бу яңалыкны бик яратып, теләп кабул иттеләр. Шул рәвешле Күшәр авылында, колхоз җитәкчеләренә карата ике фикерле ике төркем барлыкка килде.

Бу эшләрне тәртипкә кертүдә конкрет чаралар күрдек. Колхоз берләшкәннән соң, берничә көннән мин төннәрен атларны барлый торган булдым. Саныйм, бер ат юк. Аны бригадир Корбанов Сабир җигеп урманга киткән. Гомуми җыелыш җыеп тикшердек. Рөхсәтсез,

үз белдеге белән ат алып киткәне өчен ул эшеннән бушатылды, ат хакы түләтелде.

Ферма мөдире Кәбиров Идрис февраль аенда, кыш буена житәрлек печәнне терлекләргә ашатып, әрәм-шәрәм итеп бетергән булып чыкты. Хәтта яңа туган бозауларга ашатырлык та печән калмаган иде. Ферма атын жигеп, теләсә кая барганы, эшкә салкын караганы өчен, бу иптәш урынына да икенче кешене куярга туры килде. Кәбиров Идрис, колхоз идарәсенең карарыннан риза булмыйча, югарыда санап киткәннәрне тискәре якка күпертеп, элек милициядә эшләү аркасында законны күп белеп, остарып йөри башлады. Авыл хужалыгы артеле Уставы буенча колхозчылар таләп иткән теләсә нинди мәсьәлә, алар теләгән вакытта гомуми жыелышка куела ала дигән дәгъва белән, үзенә бернечә кеше ияртеп, Ташчишмәгә килә. Отчет-сайлау жыелышын Күшәр авылында үткәрик, ди. Ташчишмә белән Мокшы авылы кешеләре бу авантюраны аңлап, аларның таләбенә каршы чыгалар. Ә тегеләрнең план гади: жыелышны Күшәрдә үткәрсәләр, анда Күшәрнең бөтен халкы катнаша ала, янәсе, каршылар күпчелек тавыш ала, шулай итеп, мине председательлектән тәгәрәтәләр булып чыга... Бу эшне сизгән Ташчишмә һәм Мокшы авылы кешеләре, барасы юлларын үзгәртеп, Күшәр авылы аша килмичә, туптуры болын аркылы гына үзәк клубка бик күп булып килеп төштеләр. Ә Күшәр авылыннан колхоз житәкчеләре һәм ревизия комиссиясе председателе Камалов Сабир абый, Мөндеш авылы вәкилләре, үзәк клубка жыелгач, мәкерле планны безгә житкерделәр. Күпчелек халык килү белән жыелышны башладык. Көн тәртибе буенча отчет докладының яртысына житкәндә, Күшәр авылының вәкилләре дә жыелышка килеп керделәр. Алар арасында да ике фикер туган: колхозда намус белән эшләүчеләр, без жыелышка барабыз, дип кузгалып китә башлагач, калганнары да кушылганнар. Менә бу очракта да Ташчишмә, Мокшы, Мөндеш авылы кешеләренең акыллы гамәлләре мине сөендерде. Алар шушындый кыска вакытта колхоз идарәсенең тоткан юлын танып, аның белән килешеп, аны яклаучы булып әверелгәннәр иде.

Ә Күшәр авылыннан менгән Кәбиров Идрисләр колхоз идарәсенең «кимчелекләренә» киң тукталдылар, безнең авыл кешеләренә карата идарә каты кул белән эш итә, гөнаһсыз кешеләрне эштән ала, дип сөйләделәр. Ләкин бик каты отпор алдылар.

Колхозның баш зоотехнигы Дәүләтшин Шәүкәт болай диде: «Идрис, үзен эштән бушаткан өчен, колхоз житәкчеләрен гаепләде. Синен каныңда үч алу теләге ята бит, Идрис. Слушай, колхоз идарәсе, малларга ел буена ашатасы печәнне февраль аенда ашатып бетергәнең өчен, рәхмәт әйтеп, март аенда саламны да бетергәнеңне көтеп ятсынмыни?! Хайваннарның үлеп бетүенә шаһит булып торсынмыни?! Исән-сау котылганыңа колхоз председателенә рәхмәт әйт әле, ул сине бәладән коткарды. Син котылдың, менә мин тотылдым. Хәзер икенче ферма мөдирләренең саклап тоткан эконом печәннәреннән, саламнарыннан өзеп алып, Күшәр фермасындагы малларны туйдырабыз. Бу чыгышың белән син бик зур оятсызлык эшләдең!» — диде Кәбировка ияреп йөргән башкаларга да усал сүзләр әйтелде.

Бу жыелыш минем өчен дә, колхоз идарәсенең башка членнары өчен дә зур сабак булды. Киләчәктә жыелышларны үткәрүгә алдан ук әзерләнергә, колхозчыларның фикерен алдан ук белеп эш итәргә кирәклеге күңелемә бик нык сеңеп калды. Бу жыелышта безнең кимчелекләребез дә әйтелде. Аларын намуслы колхозчылар әйтте. Колхозчыларның шушындый авыр оешу чорында безнең эшебезне үзләренекедәй кабул итүләре, булышчыларыбызга әйләнүләре киләчәктә эшебезне дәвам иттерү өчен этәргеч булды.

«Язмышлар» дигән сүзем иң әүвәл председательләргә кагыла. Әйтик, 1930 елдан алып 1959 елга кадәр, егерме ел вакыт эчендә, Күшәр авылында 22 кеше председатель булып торган. Шуларның алтысы судка бирелеп, төрмәгә утыртылган. Бу кешеләрнең мондый язмышка дучар булуында алар үзләре генә гаепле түгел дип исәплим. Сүз дә юк, гаеплеләре дә булгандыр, ләкин һәммәсе дә алай булмас. Сүзем бушка чыкмасын өчен беренче председательләре Мөслихов Сәләхине алам. Ул — 1930 елларда, кулаклар котырынган дәвердә, кыска мылтыклар хутка киткән чагында, бик авыр заманда эшләгән. Авыл аны яраткан, әмма аерым кешеләрнең башбаштаклыгына киртә куймаган. Мөслиховны, болында яңгыр астында печән бозылган өчен, жалоба язып, авыл халкы исеменнән куллар куйдыртып, хөкемгә тарттырганнар. Камалов Галәүнең дә, Камаев Бакыйның да язмышы шулай бетә.

Бу ни хәл бу? Димәк, авылда кемнәрдер атаманлык итә, башкалары бөтен авылы белән, алардан куркып, өркеп, алар кубызына биеп яши. Ямьсез күренеш. Социалистик демократияне тупас рәвештә боза торган хәл. Мин яшь идем, сугыш давылын узган идем. Күшәрне тәрбияли алачагыма нык ышанып тотындым.

Тотынуын тотындым, ләкин бик авыр көннәр кичерергә туры килде. Мин председатель булганнан башлап, биш ел эчендә, барлык эш-гамәлемне кәгазьгә теркәп, аны бозып, күпертеп, жалоба тәртибендә югары оешмаларга, хәтта «Правда» газетасына кадәр язып тордылар. Нәкъ менә Күшәр авылыннан яздылар, калган алты авылдан бер генә жалоба да булмады. Ахырдан Күшәр авылының мәсьәләне дөресрәк аңлаган кешеләре, мәсәлән, Әскәров Малик абый: «Житәр инде, егетләр, кешене нахакка күпме азапларга була инде, монысыннан да язмакчы буласызмыни? — дип жыелышта әрнеп чыгыш ясады. — Ул мәгънәсез хатларның күбесе расланмады бит, эшләгән кешедә кимчелек булмый калмый, кимчелекләре дә булыр, бергәләп төзәтик, дуслыкка-татулыкка ни житә соң?!» — диде.

Миңа, колхоз председателе булып эшли башлагач, шул авылда яшәгән, абыйсы ике мәртәбә колхоз председателе, энесе авыл советы председателе булган бертуган Галиев Хәким, Галиев Әхмәтләр бик зур ярдәм күрсәттеләр. Әхмәт бригадир иде. Бик игътибарлы, тырыш, жиренә житкереп эшләүче булды. Мин ул авыл кешеләрен белми идем, кадрларны сайлауда да алар миңа ярдәм иттеләр. Кырларга, элекке агротехник тәртипләрне бөтенләй сүтеп, яңасын керттек. Һәр культураны кырда сынап карап, кешеләрне ышандыру юлы белән зур эш башкардык. Фермада нәселле эре терлекләр булдыруда, терлек азыгын вакытында әзерләүдә дә бу иптәшләр бик тырышып эшләделәр.

Күшәрдәге тәртипсезлекләрне гел алгы планга чыгарып кую, жыелыш саен аларны тикшерү күңелсез нәтиҗәләргә китерәчәген мин сизенә идем инде.

Конфликт чыганагы булган 200 гектарлы урманны — колхоз урманын хужалыкларга бүлмәскә булдык, аннан алына торган төзү материалын да киметтек. Шуның белән төрле низагларга нигез булган бу участокны да тынычландырдык. Анда яшь хайваннарны көтә башладык.

Киләчәктә авыл кешесен бер тирәдәрәк йөртә торган чаралар да күрдек. Шуннан чыгып, иң элек авылларны бергә тоташтыра торган участок сайлап, машина паркы төзүне планлаштырдык. Терлек комплекслары берләштерүне планлаштырдык. Каралтыларның үзәктә, урталыкта булуы бик мөһим иде.

Менә шушы таләпләрне һәм зур колхозның ихтыяжларын күздә

тотып, колхозда бик киң мәйданда төзелеш алып бару планлаштырылды. Колхозчыларның шәхси тормышларын яхшырту йөзеннән иң беренче чиратта торак йортлар төзү кирәк булды. Колхозның дәүләткә бирергә тиешле элекке бурычларын алтмышынчы елларда тулысынча түләп бетердек. Төзү эшен алып бару мөмкинлеге туды. 1960—70 елларда хуҗалыклар элекке йортларының 90 процентын алыштырып бетерделәр. Хәзер аларда торак янына кухня ясау модага кереп китте. Аннан соң авылларда капка-койма һәм ак мунча салу, базларын таштан индерү киң күләмдә алып барылды. Гомумән, авылның сугышка кадәрге йөзе бөтенләй үзгәрде. Такта түбәләрнең бик күбесе калай түбәгә әйләнде. Элек барлык хуҗалыкта да лапаслар салам түбәле булса, хәзер алар шифер, калай, такта белән ябыла башлады. Карап йөргәндә дә авыллар бик матур. Ташчишмә ягыннан кайтканда Күшәр авылы саламга күмелгән бер авыл булып тора иде. Хәзер гел дә шәһәр төсле: калай да шифер!

Колхозда бик күп төзелеш эшләре эшләнде. Күшәр авылында иске хуҗалык амбарларын җыеп, таш фундаментка куеп, калай түбәләр белән 50×11 метр зурлыгында ике амбар салынды. Бәрәңге өчен ике базны таштан индердек, җир стеналы элекке иске базлардан чыгып беттек. Дуңгызларга — кирпечтән 14×55 метрлы өч абзар төзелде. Сыерларга — кирпечтән 18×80 метрлы дүрт абзар, бозауларга 80×9 метрлы абзар салынды. Элеккеләренә капитал ремонт ясалды. Терлекчеләр йорты кирпечтән 11×8 метрлы итеп төзелде. Ике коескважина казылды. Колонкалар куеп, дүрт километр озынлыгында сууткәргечләр ясадык. Авыл халкына культура хезмәте күрсәтү өчен яңа клуб салынды, үзәктән җылыту системасын яңарттык. Киң экранлы киноаппарат алдык. Медпункт, китапханә бинасы салдык. Авыл уртасында, үзәк бригада урнәгендә, кирпечтән промтовар кибете, азык-төлек кибете калкып чыкты. Авыл балалары өчен 8 еллык типовой мәктәп төзелде. Ел буена эшли торган балалар бакчасы (25 урынлы) ачылды. Гомумән, берләшкән авылларда, үзәк усадьба урнәгендә, төзелеш эшләре киңәйтелде, тормыш өчен кирәкле булган биналар гамәлгә керде...

Ташчишмә авылында мең баш мөгезле эре терлек өчен абзарларны күчереп, яңадан эшләтеп чыктык. Терлек азыгы әзерләү цехы һәм мал караучылар өчен яңа кирпеч йорт салынды. Тракторларны кыш саклау өчен Күшәр авылында да, Ташчишмәдә дә биналар төзелде. Ташчишмәдә гараж, тимерче алачыгы һәм агач мастерское салынды. Ат абзары, икенче урынга күчерелеп, терлекчелек шәһәре итеп төзелде. Хәзер Ташчишмә авылының таркау каралтылары: тимерчелеге, мастерское, ат абзарлары, ашлык чистарту сарае, трактор паркы бер урынга тупланып, рәшәткә һәм койма белән әйләндереп алынды. Халык ихтыяҗын истә тотып, бу авылда да 25 урынлы балалар бакчасы, кирпечтән 120 урынлы башлангыч мәктәп салынды. Иске клубны сүтеп, капиталь ремонт ясап, фойелар өстәп, киң экранлы кино күрсәтелә торган итеп төзедек. Китапханәгә, промтовар һәм азык-төлек кибетләренә дә ремонт ясаттык. Шуның өстенә, район юл төзү идарәсе белән бергәләп, Әтнә — Ташкичү юлының 14 километрын безнең колхоз эшләде. Колхоз күләмендә агачтан 8 күпер салынды. Бу күперләрнең 20—30 метрлылары да булды.

Үзәк усадьбада төзү эшләре киң җәелдерелде. 1950—60 нчы елларда 18×80 метрлы дүрт рәтле бер торак, 18×72 метрлы бер бетон торак, терлекчеләр йорты төзелде. Аның өстенә 50×9 метрлы 4 агач торак эшләнде. Бу елларда үзәктә 400 урынлы, ике катлы типовой урта мәктәп төзелде. Аңа терәп спортзал кордык, үзәктән җылыту системасы керттек. Күнгәр авылында 1500 башлык сарык абзарына капиталь ремонт үткәрелде. Өч авылда да кибетләр ремонтланды.

Авыл халкы өчен 35 койкалык больница төзелде. Мәктәпне һәм больницаларны, алдан планлаштырып, бик тантаналы итеп ачтык.

Яңа берләшкән авыллардагы ятим картларны Картлар йортына урнаштырдык. Шушы чорда Ташчишмә, Күшәр, Түбән Шашы, Югары Шашы авылларында барлыгы 11 километр озынлыгында суүткәргеч уздырылды.

1962 ел бик истәлекле булды. Авылыбыз мәңгелек караңгылыктан чыкты, йортларга Ильич утлары керде. 1965 елда авыл халкы өчен утыз урынлы автомат телефон станциясе төзелде, радиоузел эшли башлады. Өйләргә телевизор килде. Иң элек телевизорны авыл клубларына куйдык. Халык бик ихласланып телевизор карый башлады. Шул ук елларны Күнгәрдән Әтнәгә кадәр 11 километр озынлыгында таш юл эшләнде.

1966 елда авылларга газ керттек. Бу эш тә җиңел генә булмады. Авыл халкына 600 данә газ мичләре белән плитәләр, 1900 данә баллоннар сатып алдык. Барлык авылларда да газны кешеләр кабул итеп алдылар, ә Күшәр авылына дигән 200 данә баллон тик ята, алучы юк. Ахырдан ачыкланды: аларда, газ баллоннары шартлый, кешене үтерә, дигән хәбәр таралган, авыл халкы шуңа күрә баллоннарны алмый тора икән.

Күшәр авылында, әле әнә абруйлы кешеләр Камалов Сабир, механик Насретдинов Гарифҗаннар да алмый, алар белми эшләмиләрдер, дигән хәбәр ишеттек. Шуннан, ул иптәшләрне идарәгә чакырттык та: «Иртәгә үк алып, өйләрегезгә газ куегыз. Кирәкмәсә кире алырбыз, колхоз хисабыннан булыр»,— дип катгый рәвештә кисәтеп куйгач, икесе дә шаркылдап көлделәр дә, менә халык шулай инде, үзенең куркуын кешегә сылтый, иртәгә үк алып куябыз, дип кайтып киттеләр. Ике көннән ике йөзгә якын газ плитәсе таралып бетте.

Шушы чорда төзүчеләр әзерләү бурычы алга килеп басты. Агач эшенә элекке балта осталарыннан яшьләребез бик тиз өйрәнделәр. Ә менә таш, кирпеч салу, бетон ясау шикелле эшләргә өйрәтүче табып булмады. Белгечне читтән ялларга туры килде. Шулардан белемле егетләр кирпеч салу, бетон ясау, калайдан түбә ябу кебек эшләргә өйрәнделәр. Аннан шәһәрдән ГПТУда укыган егет-кызларыбыз кайтты. Алар безгә төзү культурасы алып кайттылар.

Менә шушы чорда бик яхшы төзүчеләребез үсеп чыкты. Госманов Равил бригадасында Гарифуллин Хафиз, Әхмәтшин Ахун, Гарипов Шамил, Хәбибуллин Шәрифулла, соңыннан аларга кушылучылардан — Шагалиев Динияр, Шәмсетдинов Шамил, Мәгъсүмов Мөнир кебек иптәшләр колхозыбызда зур төзелешләрнең нигезен салучылар булып торалар. Аерата Госманов Равилнең хезмәте күп керде. Ә агач эшләрендә Фәзуллин Гыйбадулла, Галиев Һади, Гыйлемханов Закир, Җиһаншин Шәйхелислам, Камалиев Хәйретдиннәр яшьләрне өйрәтүдә нык ярдәм иттеләр.

Ә Күшәр авылын яңабаштан төзеп чыгуда, колхоз һәм авыл төзелешен бергә алып баруда яшьләр белән җитәкчелек иткән Галиев Хәкимҗан һәм звено җитәкчесе Әюпов Рафаэльнең хезмәте зур булды. Бу иптәшләр тәрәзә рамнары ясый, пыяла куя, калайдан түбә яба, асфальт сала, бетон идән җәя, таш һәм кирпеч түши белә иде. Күшәр авылында элек-электән йортларны гел марилар килеп эшли торганнар иде. Әюпов Рафаэльләр буыны үсеп җиткәч, төп эшне алар башкарды, яшьләр салган йортлар матур-пөхтәлекләре белән аерылып тордылар.

Яшьләрнең югары уку йортларында укуына нык игътибар иттек. Бу елларда колхозның унлап егете читтән торып институтларда уку-

дылар. Алар колхоз производствосына кайтып керә башладылар. Шулай итеп, терлекчелекне дә югары продуктлылык дәрәҗәсенә күтәрү өчен шартлар әзерләнде.

Авыл хуҗалыгында КПСС Үзәк Комитетының 1965 елгы март Пленумы карарлары безнең тормышыбызга уңай йогынты ясады. Авылга техника күп кайтты. Җитәкче кадрларның, колхозчыларның хезмәт хаклары гарантияләнде. Колхозыбызда акчалата түләүгә күчтек. Кешеләрнең сатып алу мөмкинлеге дә артты. Кооперация халык өчен кирәкле бик күп эш башкарды.

Колхозыбыз бу чорда республика күләменә чыкты. 1967 елда безнең колхозыбыз ирешкән уңышлары өчен бер колхозчыбыз Татарстан АССР Верховный Советына депутатлыкка сайланды. Ул ышаныч мина күрсәтелде.

Колхозыбыз 1966 елны Татарстан АССР Верховный Советы Президиумының Почет грамотасы белән бүләкләнде. Аннары без, 1966—1969 елларда югары күрсәткечләргә ирешкәнебез өчен, СССР авыл хуҗалыгы күргәзмәсенә катнашучылар дипломы алдык. Төрле елларда КПСС райкомы һәм район советы башкарма комитетының Почет грамотасы белән алты мәртәбә бүләкләндек.

Октябрь социалистик революциясенең 50 еллык бәйрәмендә колхоз КПСС райкомы һәм район советы башкарма комитетының истәлек байрагы белән бүләкләнде. Бу елларда колхозчылар исеменнән мин— өч мәртәбә, колхоз агрономы бер мәртәбә республика агрономнары конференциясендә чыгыш ясадык. Безнең кешеләребез хакында республика радиосы, газеталары, район газеталары еш яза башладылар.

## Җаваплылык хисе

1961 ел. Урак өсте. Партия өлкә комитетының беренче секретаре иптәш Табеев килде. Бу безнең колхозчылар өчен дә зур дәрәҗә иде. Ул халык белән бик әйбәтләп сөйләште, аларны тыңлады. Шул вакытта минем өчен бик күңелсез бер вакыйга булды. Без, колхоз идарәсендә әңгәмә корып алганнан соң, колхозның алма бакчасын карарга киттек. Фикрәт Әхмәтҗанович «золотая китайка» дигән алма турысына туктап, бер алма алып ашады да: «Алмасы бик тәмле икән, ләкин бакчасы ташландык икән»,— дип нәтиҗә ясады. Бакчада чүп үскән иде. Миңа бик уңайсыз булды.

Юлның икенче ягында азык чөгендере бар иде. Аның уңышы ул елны күп иде, яфраклары көр, карап торуы ук күңелле иде. Иптәш Табеев чөгендерне ошатты. «Гектарыннан күпме чыгар, Тимерхан?— дип райком секретарена карады. «600—700 центнер чыгар»,— диде Борһанов.

Авыл янында гына кукуруз басуы бар иде. Кукуруз биек булып үскән, озын буйлы Фикрәт Әхмәтҗановичтан да бер ярты метрга биегрәк иде. «Чүбе дә юк, уңышы мул булыр»,— диде иптәш Табеев. Шундук аргы яктагы тавышка игътибар итте, анда комбайннар борчак суга иде, инде бетерергә тиешләр иде. «Әйдә, шуны карап килик әле»,— диде обком секретаре.

Кукуруз басуын үтеп, Түбән Шашының борчак басуына килдек. Тау башында бер комбайн торып калган. Янына барып туктасак, бер гектар чамасы җир бар, җир өсте — ап-ак борчак. Өстәвенә, машиналар килеп җитә алмау сәбәпле, биш урынга бункердан борчак бушатканнар. Шулар чүмәлә-чүмәлә булып агарып тора. «Бу нәрсә?» — диде Фикрәт Әхмәтҗанович. Мин кып-кызыл булдым. Әлеге комбайн суккан җирдә бер колхозчы үзенә бүлеп бирелгән участокны вакы-

тында чабып бетерә алмаган, кибеп өлгергән борчак, чалгы кагылуга шаулап коела икән. Читкәрәк китеп карадык, җирдә борчак юк. Райком секретаре Борһанов: «Бу егетне нишләтәбез инде, иртәгә радиодан перекличка вакытында тәнкыйтьләрсез»,— диде. Мин: «Бу безнең колхозга хас нәрсә түгел, моңа артык басым ясамавыгызны сорар идем»,— дип кенә әйтә алдым.

1967 елда колхозыбызда Октябрь революциясенең илле еллыгын зур бәйрәм итеп үткәрдек. Һәр авылда җыелышлар уздырдык. Ул җыелышларда Октябрь революциясе яктылыгында колхозыбызның үсеш юллары хакында доклад ясап чыктык. Моңарчы колхоз төзелешендә яхшы эшләгән кешеләрне өч дәрәҗә мактау кәгазе белән бүләкләдек, кыйммәтле бүләкләр тапшырдык. Бер мең биш йөз кеше бүләк алды. Утыз мең сум акча тоттык. Иртәгесен Күшәр авылы урманының бик матур бер аланлыгына җыелып, ял бәйрәме үткәрдек. Анда Казан опера театрының бер төркем артистларын чакырып, концерт куйдырдык. Халыкны аланга машиналар ташып торды. Кичкә кадәр халык ял итте. Төрле уеннар уйнады, кибетләрдән тәм-том алды. Үзебезнең үзешчәннәр авыл клубларында куйган концертларын кабатлап чыктылар. Кич белән генә таралыштык. Халык колхозның 37 ел яшәве тарихында булып үткән көннәрне янә дә бер мәртәбә исенә төшерде...

Шулай итеп, колхозыбыз берләшүгә ун ел тулганда, безнең инде телгә алып сөйләрлек уңышларыбыз бар иде. Иң мөһиме — киләсе елларга нигез салдык. Колхозчыларыбыз күтәренке күңел белән тугызынчы бишьеллыкны башладылар.

«Җаваплылык хисе» дигән төшенчәгә тагын бер мәртәбә әйләнеп кайтам. Алтмышынчы еллар башында район структурасында зур үзгәрешләр булып торды. Колхоз җитәкчеләре өчен бу чор бик уңайсыз булды. Авыл хуҗалыгы идарәсе җитәкчеләре алты районга йөреп, бушап җитә алмадылар, колхозлар белән элемтә өзелде. Әле яңа гына үзгәреш булган район җитәкчеләренең җитәкчелек итүдәге бурычлары да, безгә, колхозларга, кемнең нинди тармакны җитәкләве дә аңлашылмый иде. Өзлексез үзгәреп торган хәлләр вакытында район хезмәткәрләре яңа тәртип белән танышып та өлгерә алмыйлар, ул арада икенче үзгәрешләр башлана. Алты райондагы авыл хуҗалыгы идарәләре яңадан өчкә бүленде. Без, Балтач-Арча-Әтнә районнары, бер авыл хуҗалыгы идарәсенә әйләндек. Шуннан озак та тормады, яңадан Балтач районы үзе мөстәкыйль район булып аерылып чыгып китте. Арча һәм Әтнә районнары бер район булып калдылар.

Илленче-алтмышынчы еллар арасында колхозларга көчләп тагылган тирән сөрү кагыйдәләре шикелле, күпьеллык үләннәрне сөреп бетереп, бөртекле ашлык мәйданын арттыру башланды. Бу елларда кукуруз игү, аның квадратын булдыру, бәрәңгене квадратлап утырту, аеры уруны кирәк булган-булмаган очракларында файдалану алтмышынчы елдан алтмыш бишенче елга кадәр дәвам итте. Без, колхоз җитәкчеләре, бу эшләр буенча бер төрле дә фикер әйтә алмадык.

Безнең колхозда үлән җирләрен сукалау буенча бирелгән планны без үтәп бетерә алмадык, зур тәнкыйтькә эләктек. Шулай да берьеллык үлән исәбендә йөртеп, бер йөз гектар күпьеллык үләннәребезне саклап кала алдык. Күпьеллык үлән басуларын бетерү табигый болыннары булмаган колхозларга аерата авыр тәэсир итте. Язга таба бер көнне Камил Якуб исемендәге колхоз председателе Фәхретдинов килгән. «Фәйзи, зинһар, бер генә ат олавы печән бирә күр, сарык бәтиләренең эче китә, врачлар печән чәе эчерергә кушалар. Үлә торган бәтиләрне кызганып булса да, буш җибәрмә безне»,— дип үтенеп, биш центнер печән алып китте. Шул вакытта ул, үлән басуларыбызны, районнан килеп, сөрдереп бетерделәр, дип, бик әрнеп сөйләде.

Алтмыш бишенче елдан соң, бу ялгышлыклар төзәтелде. Производство планнарын да ачыктан-ачык күрсәтеп, күпьеллык үләң чәчә башладык.

1965 елларда район аппаратында да җитәкчеләр яңадан үзгәрделәр. Райкомның беренче секретаре итеп Усман Җиһаншин сайланды. Икенче секретарь булып Зәйнуллин Харис эшли башлады. Райбашкарма председательлегенә Тимерхан Бәрһанов килде. Бу җитәкчеләр райком бюросын җыеп, авыл хуҗалыгы производствосында моңарчы яшәгән кимчелекләрне бетерү буенча зур сөйләшү үткәрделәр. Безнең, председательләрнең күңеленә җылы иңде. «Бу көннәрне дә күрәсебез бар икән!» — дип җиңел сулап куйдык.

Усман Шаһиевич Җиһаншин Арча районында туып үскән. Шуның өстенә, шушы район колхоз бригадиры, колхоз председателе, МТС директоры, авыл хуҗалыгы инспекциясе начальнигы, райкомның икенче секретаре булып эшләгән. Зур идарәләр оешкан чорда көньяк районда авыл хуҗалыгы идарәсе начальнигы булып эшләгән, бик күп тәҗрибә туплаган кеше булып чыкты. Бу районның кадрларын белүе аңа партия дисциплинасын күтәрергә ярдәм итте. Ул кадрларга ышана, сөйләгән чакта фактларга таяна, тыңлаучыларны ышандыру сәләте дә зур иде. Иптәш Җиһаншин үзалдына билгеле бер максат куя, максатын безгә ачыктан-ачык әйтә торган иде.

Колхозлар эреләнде, без үз алдыбызга яңа бурычлар куеп эшләдек:

элекке авылларны, халыктагы тәҗрибәне өйрәнеп чыгу, шул юл белән сәләтле кадрларны сайлап алу;

МТСлар бетеп, колхозларга техниканы сатып алу уңае белән машиналарны лаеклы кешеләргә тапшыру, техника белән идарә итү ысулларын булдыру;

колхозда механизатор кадрлары үстерү. Берләштерелгән зур колхозда нәрәт бирү тәртибен бетерү, тармак җитәкчеләрен үз участокларында мөстәкыйль эшләргә өйрәтү;

колхозчыларга төзелә башлаган йортларын, каралтыларын эшләп бетерүдә төрле ярдәмне күрсәтү;

авыл кешеләрен аралаштыру юлы белән аларда бер-берсенә карата дуслык хисе тәрбияләү. Колхозда басу эшкәртүнең бердәм агротехникасын булдыру. Һәр культурага карата аерым караш тудыру;

һәр авылда да культура учаклары булдыру, сәүдәне киңәйтү, колхозчыларны көндәлек кирәк-яраклар белән тәэмин итү.

КПСС Үзәк Комитетының 1965 елгы тарихи карарын тормышка ашыру чорында шушындый җитәкчелек булуы безгә, колхоз председательләренә, бик зур җиңеллек тудырды. Бу чаралар үз чиратында колхозларның продукция җитештерүенә дә уңай йогынты ясады.

Кешеләргә әйбәт мөнәсәбәт белән бергә техникага да игътибар заманы килде. Иң элек, барлык авыллардан да йөреп эшләргә уңай булсын өчен, тигез урталыкка машина-трактор паркы урнаштыруны күздә тотып, бик кыска гына вакыт эчендә ягулык-май склады, машина-тракторлар ремонтлау мастерское, техникага ярдәм күрсәтү пункты, автомобильләр өчен 80×11 метрлы ике җылы гараж салдык. Комбайннар һәм авыл хуҗалыгы машиналарын саклау өчен каплаулу лапас-сарай ясап, барлык комбайннарны түбә астына куйдык. Шунда ук механизаторлар өчен, ике катлы бер бина салып, өске катында — гостиница, аскы катында ашханә ачтык. Механизаторлар бу эштән канәгать калдылар. Кышның нинди суык көне булуга карамастан, машиналарның суын агызмыйча калдыра башладылар. Иртән 15—20 минутта 30—40 машина юлга чыгып китә ала торган булды. Безнең машиналар, бәрәңге заданиесе тапшырган вакытта, Казанга ике мәртәбә барып кайтуга өлгерште, ә Арчага иртән сәгать дүрткә үк

барып җитәләр иде. Озак еллар машина йөртеп, бик яхшы эш үрнәкләренә ирешкән шоферларыбыз күбәйде. Колхоздагы 35 йөк машинасына һәм махсус машиналарга сиксәннән артык шоферыбыз булды.

Бу өлкәдә озак еллар колхозда автомобильләр буенча механик булып эшләүче Бариев Давыт бик күп хезмәт куйды. Машинаны яхшы белүе, яшь шоферларга ярдәм итүе аркасында коллективта хөрмәт казанды. Ул машина паркының төзек булуын да кайгыртып торды...

Язгы кыр эшләрендә — тракторчыларыбыз, үстерелгән игеннәрне җыеп алуда комбайнчыларыбызның зур бер отряды үсеп чыкты.

Урып-җыюда безнең үз тәртипләребез бар. Эшне вакытында башкарып чыгу өчен кул көчләренә дә мөрәҗәгать итәргә туры килде. Колхозчылар безне аңлыйлар. Соңгы елларда яңгырлар күп булу сәбәпле, күп кенә кыен хәлләр алдында калгаладык. Андый чакта борчакны чалгы белән чабарга, саламны сәнәк белән эскертләргә туры килде. Шундый чакларда колхозчылар, аларның мәктәпләрдә укучы балалары, авыл интеллигенциясе ярдәм итте.

Терлекчелектә дә зур үзгәрешләр булды. Иң элек терлек караучылар, укып чыгып, промышленностьтагы кебек, мастерлар дигән таныклык алдылар. Аларның белемле булулары терлекләрне белеп тәрбияләүгә юл ачты. Терлекчелектә кыш айларында өч йөзгә якын кеше эшләп килде. Эш беткәч, ел азагында, аларга бүләк бирү, эшкә йомгак ясау матур гадәткә әйләнде. Соңгы елларда колхозыбызда терлекчелек өлкәсендә генә түгел, башка өлкәләрдә дә яңа гадәтләр урнаша башлады. Колхоз идарәсе аларны һәрвакыт яклап килде. Токымлы терлек үстерүгә игътибар артканнаң артты. Соңгы елларда мөгезле эре терлекләрнең барысы да чиста канлы холмогор нәселле сыерларга әйләндерелде. Үзебезнең колхозны тәэмин иткәннән соң, ел саен 200 баш нәсел таналарын башка колхозларга сату мөмкинлеге туды. Сөтнең сыйфаты буенча да бу елларда күп кенә чаралар уздырдык. Хәзер дәүләткә сатылган сөтнең 90—95 процентлабы беренче сортлы.

Хезмәткә түләү, колхоз байлыгыннан файдалану өч төрле юл белән алып барыла. Эшне үз вакытында башкару, аның сыйфаты, күләме исәпкә керә. Бәрәңге алу вакытында иртәнге караңгыдан кичке караңгыга кадәр эшләделәр. 1976—78—80 еллардагы бәрәңге алу мәңгегә истә калды. Гел яңгыр астында эшләргә туры килде, шулай да бер бәрәңге дә җирдә калмады. Безнең «Искра» колхозы тугызынчы, унынчы бишьеллыкларда авыл хуҗалыгы продуктлары тапшыру буенча уңышка ирешкән икән, алар барысы да колхозчыларыбызның фидакарь хезмәте нәтиҗәсе булып торалар.

Колхозыбызда кешеләр өчен тудырылган уңайлыкларны бер зур закон итеп, идарәдә раслап, аның белән барлык кешене таныштырдык, бу тәртип буенча менә нинди эшләр каралды:

колхоздан хезмәт хакына бирелгән авыл хуҗалыгы продуктларын: икмәк, салам, печән, бәрәңгене алып кайту, тегермәнгә бару өчен трактор, автомашина, ат түләүсез бирелә;

бакча сукалау, автовокзалдан һәм шәһәрдән кешеләр алып кайту, илтеп кую, кунак алып кайту, илтү өчен, ягулыкка күмер, утын китертү, төзү материаллары ташу өчен трактор, машина, ат түләүле тәртиптә бирелә;

больницага, нинди ераклыкта булуына карамастан, трактор, машина, ат түләүсез бирелә;

яшьләр өйләнешкәндә туй өчен кирәкле машина яки ат түләүсез бирелә;

колхоз квартираларында тора башлаган, башка чыккан колхоз члennары беренче елны квартир хакы түләмиләр, икенче елыннан гына түли башлыйлар.

колхоздан хезмәт хакына бирелә торган акчалардан бер төрле дә налог тотып калынмый. Колхозчыларның эшләгән акчаларыннан 70 процент күләмендәгесе ай азагында бирелә, ә 30 проценты ел ахырына кадәр сакланып, натуралата бирелгән әйберләр: икмәк, бал, сөт, салам, печән өчен, машина, трактор, аттан, газдан файдаланган өчен тотып калына. Андый чыгымнардан артканы колхозчыга кайтарып бирелә...

Колхоз җыелышында расланган кагыйдәләрнең тагын 18 пункты бар. Колхозчы семьяларга, аларның гаризалары нигезендә, колхозда эшләү, түләү мөмкинлекләре булса, йорт салу, сыер алу өчен чикләнмәгән күләмдә ссуда акчасы биреп торыла.

Электр энергиясеннән, газ баллоннарыннан файдаланганда хәвефсезлек кагыйдәләре нык сакланырга тиеш.

Кагыйдәләр пенсия бирүне, өстәмә түләүне, ялга чыгуны кайгырта. Колхозда бер урында 30 елдан артык бик яхшы итеп эшләгән, үз-үзен тотуы үрнәк булган, яшь буынны дөрес тәрбияләүдә күп көч салган колхозчыларга, пенсия вакыты җиткәч, әгәр дә аның «Атказанган колхозчы» исеме булса РСФСР һәм ТАССР Верховный Советы Президиумының Почет грамотасы белән, орден-медальләр белән бүләкләнгән булса, дәүләттән алган пенсиянең 50 проценты күләмендә өстәмә билгеләнә.

Бала-казага тару, сыеры үлү, яшен сугу яки янгын чыгу очраклары аерым карала, санаторийләргә путевка бирү, юл чыгымнарын колхоз исәбенә түләү, үрнәк төстә эшләгән егетләрне, Совет Армиясенә китәргә әзерләнгәндә, бүләк биреп озату, Совет Армиясеннән колхозга эшкә кайткан егетләргә түләүсез 150 килограмм икмәк бирү, Бөек Ватан сугышы инвалидларына семьясында яккан алты баллон газның 50 процентын колхоз хисабына түләү һ. б. һ. б. уңайлыклар кертелде.

## Хезмәт һәм хөрмәт

Ил күләмендәге социалистик ярышта яхшы күрсәткечләргә ирешкәне өчен, 1972 елны безнең «Искра» колхозы РСФСР Верховный Советы Президиумы, РСФСР Министрлар Советы, ВЦСПСның юбилей Почет грамотасы белән бүләкләнде.

1974 елда колхоз КПСС Үзәк Комитеты, СССР Министрлар Советы, ВЦСПС һәм ВЛКСМ Үзәк Комитетының күчмә Кызыл Байрагы белән бүләкләнде.

1977 елда СССР Авыл хуҗалыгы министрлыгы, Авыл хуҗалыгы работниклары профсоюзы Үзәк Комитетының Кызыл Байрагына лаек булдык.

1978 елда КПСС Үзәк Комитеты, СССР Министрлар Советы, ВЦСПС һәм ВЛКСМ Үзәк Комитетының күчмә Кызыл Байрагы белән икенче мәртәбә бүләкләндек.

1976, 1977, 1978 елларда, югары уңыш алган өчен, Татарстан АССР авыл хуҗалыгы күргәзмәсендә диплом белән бүләкләндек. Шушыларның барысы өстенә «Искра» колхозы КПССның Арча райкомы, райбашкарманың күчмә Кызыл Байраклары белән унөч мәртәбә бүләкләнде, аңа өч ел рәттән «Югары культура колхозы» дигән исем бирелде.

1979 елның март аенда безнең колхозчыларыбызның хезмәте илебез күләмендә бик югары дәрәҗәгә лаек булды. Шушы колхозда 35 ел буе колхоз председателе булып эшләгән Галиев Фәйзи СССР Верховный Советына депутат итеп сайланды. Бу безнең колхозчыларыбызның хезмәтен бик зурлау иде. Шуның белән бергә бу дәрәҗәне

саклау һәм аны аклау безнең коллектив алдына бик зур бурычлар куйю да иде.

1979 елның 5 январь көнендә КПССның Арча райкомының оештыру бүлеге мөдире Хафизов, бездә гомуми җыелыш җыйнап, СССР Верховный Советына депутатлыкка кандидат күрсәтү кирәк булуы хакында әйтеп, шул җыелышны хәзерләргә килде. Халык бик күп җыйналган иде. Җыелышка КПСС райкомының беренче секретаре Харис Зәйнуллин килгән иде. Ул җыелышны ачып, көн тәртибен игълан иткәч, беренче сүз колхозның партком секретаре Хөснетдиновка бирелде. Ул СССР Верховный Советына депутатлыкка КПСС Үзәк Комитеты Политбюросы члены, Үзәк Комитет секретаре К. У. Черненко кандидатурасын күрсәтте. Көчле алкышлар белән каршыладык. Икенче итеп колхозның баш зоотехнигы Сабировка сүз бирелде. Ул К. У. Черненко кандидатурасын яклап, үзебезнең колхоз председателе Галиев Фәйзине күрсәтәм, дип әйтүгә, зал тагын кул чабарга кереште. Халыкның минем кандидатурамны шулай туплавы минем өчен иң зур бүләк булды...

...Мине җиде авылдан җыелып килгән халыкның пөхтә-матур киемнәренә, якты чырайларына карап, алар белән бергә узган утыз биш елымны, бик авыр чакларны искә төшердем. Әнә шул көнне мин «Игенче язмалары»н язарга ният кылдым. Менә җылы кулдан ул язмаларны мин укучы карамагына тапшырам. Кешеләрдә безнең эшебезгә карата ихтирам уята алса, мин максатыма ирештем дип уйлар идем.

---

## *Бер сорауга — бер җавап*

*СОРАУ:*

*— Сез хәзер нинди әсәр язасыз?*

*ШАМИЛ РӘКЫЙПОВ:*

*— Тарихи шәхесләрнең тормышын өйрәнү мине һаман ныграк били бара. Хәзер Минзәлә районында туып үскән батыр якташыбыз Советлар Союзы Герое Василий Николаевич Гордовка багышланган «Берәү дә мәңгелек түгел» исемле тарихи әсәр өстендә эшлим. В. Н. Гордов, хәрби биографиясен 1915 елда гади солдат буларак башлап, генерал-полковник дәрәҗәсенә күтәрелгән полководец. Ул Ватан язмышы хәл ителгән иң авыр көннәрдә Сталинград фронтының командующие итеп билгеләнә һәм, табигый ки, И. Сталин, Г. Жуков, И. Конев, В. Чуйков һ. б. шундый зур хәрби талантлар белән янәшә басып, фашистларга каршы көрәшә. Әсәрнең беренче яртысында исә революция давылларында чыныккан каһарманнар В. Азин, Я. Юдын (Юдин) һәм бүтән батыр латыш укчылары, алар арасындагы татарлар, руслар сурәтләнә.*

*Билгеле инде, әсәрдә мәхәббәт тә бар. Ул — латыш кызы революционерка Майганың беренче саф мәхәббәте. Майга, башкала эшчеләре өчен азык-төлек хәзерләү отрядында чакта, Идел буе авылларының берсендә, кулаклар тарафыннан мыскыл ителеп, җәзалап үтерелә. Элеккерәк язган хатлары, озын юлларны урап, һаман егетенә килә торалар...*

*Бер генә кеше дә мәңгелек түгел, ә хакыйкатькә тугры калып, Ватанны, бердәнбереңне сөю — мәңгелек... Болар — кешенең үзеннән соң да яшәүче черемәс-таркалмас төшенчәләр.*

*Әсәр фашистик Германияне җиңүнең 40 еллыгына багышлана. Кулъязманы киләсе ел башларына редакциягә тапшырырмын дип өметләнәм.*

---

# Ренат Харис

## АТ ИЯРЛӘҮ

ПОЭМА

*Ир-егетнең йөрәгендә*
*Иярләгән ат ятыр.*

Татар халык мәкале

*Кырык бернең җәе иске төшә*
*Туғайлардан атлар кайтканда.*
*Кешеләр генә түгел, ул елны бит*
*Армиягә китте атлар да.*

Рәшит Гәрәй

Качып кайтты Кәрам аты...
Киткәннән соң ун көн узгач...
Кайтып җиту шатлыгыннан
шартлар хәлгә килеп, шашып,
йоклаган өйгә кешнәде —
тынының кайнарлыгыннан
тәрәзәләрдә ут кабынды...
Китереп типте капкага —
суырылып чыкты келә
кертим дип тизрәк шатлыкны...
Атылып керде кайнар ат,
ишек алдын урап чыкты
чәчрәтә-чәчрәтә күбек,
кеше кебек, хуплау көтте
караңгы болдырга карап...
«Кем бар анда?» — дип кычкырды
йокыдан карлыккан Кәрам.
Кара төн пошкырып куйды.
«Кем ул анда?» — дип кычкырды
кемне дә көтмәгән Кәрам.
Кара төн янә пошкырды,
кара төннең ялтырап китте
коточкыч таныш күзләре...
«Синме?.. Ничек?» — диде дә
Кәрам
ат муенын кочып алды,
улын кочаклаган кебек...
Күзләре кизләү булдылар,
сүзләре — сыктау...

*
* *

Әй, малкаем, малкаем,
болыт ялкаем минем,
җитмеш биш чакрым җирдән
син ничек кайтып җиттең?
Син ничек юлны саптың?
Ничек таптың авылны?
Әй, малкаем, малкаем!
Ульянга үзем илттем,
үзем керттем вагонга —
башка атлар янына,
солдат атлар янына.
Бик күп йөргән ул вагон,
ядрәләр зилзиләсен
күргән ул көрән вагон
сине миннән аерып
алып киткәнне күрдем.
Яру җигеп йөргән ат,
Харис җигеп йөргән ат,
Фәтхи җигеп йөргән ат,
Гата җигеп йөргән ат,
Җанша җигеп йөргән ат
кердeләр, күмелделәр.
Син ишек аратасын,
түш белән бөгә-сыга,
миңа таба тартылдың...
Әй, малкаем, малкаем,
юеш ялкаем минем.

Шул чагында күзеңнән
ак томан агып чыкты,
ул җәелде, куерды,
вокзалны күмеп китте,
бугазыма төелде,
күзләрне ачыттырды...
Һәм томан таралганда
перроны бушап калган,
ә күңелдә авыр таш —
таш әле дә авырта...
Әй, малкаем, малкаем,
кашкалы башкаеңа
йөгәнне дә мин салдым,
кыз биледәй кытыкчан
сыртыңа ыңгырчакны
җайлап-майлап мин салдым,
бөгәлҗә муеныңа
камытны мин кигерттем,
тәртә арасына да
мин керттем сине, малкай,
сөрербез дип кырларны,
урманга йөрербез дип,
кунак озатырбыз дип,
туйлар чаптырырбыз дип...
Пушка тартып йөрергә,
кеше канын күрергә,
керергә янган утка
китәрсең дип белмәдем,
әй, малкаем, малкаем.
Мин сине биш ел җиктем...
Капкамнан кермәгән көн
һич кенә булмагандыр...
Инде бер атна була,
колхоз башка ат бирде —
шуны җигеп йөримен.
Алаша да әйбәт ат.
Синең кушамат белән
эндәшеп аптыратам —
ул шомарта колагын,
хатыны авызыннан
сөяркәсе исемен
ишеткән ир шикелле...
Синең эшлеяң эшсез,
рәеш йөгәнең чөйдә —
җиз тиен-төймәләрнең
ялтыраулары саргайды...
Син төшемә керәсең...
Синең янында — улым...
Аның юлы киселде...
Сине озатан көнне
аңардан хәбәр килде.
Түш кесәмдә тозланып
беткәндер инде хәбәр.
Серемне сиңа чиштем...
Әнисе берни белми,
берни белми хатыны...
Син кайттың, ә ул гүрдә
Украина җирендә...
Әй, малкаем, малкаем!
Өйнең серен беләсең,
агын, керен беләсең,
лапас түрен беләсең,
әткәй гүрен беләсең,
улым җырын беләсең,
әнисе моңын белерсең,
хатыны моңын белерсең,
ә мин сиңа ачылдым
дус итеп, сердәш итеп.
Күземнән яшь агылды,
күңел күгем ачылды
төтеннән, болытлардан.
Ә йөрәктә авыр таш,
шул таш ай-һай авырта.
Әйдә, малкай, лапаска —
үзең ташыган печән
сихәт бирсен үзеңә.

*
* *

Ат өстенә чыпта ятты...
Наз күп күрде, мондыйны — юк:
Кәрам җан җылысын япты.
Әллә нәрсә булды атка...

Колагына сихер-тылсым
агып керде аның кинәт.
Әллә нишләп, әллә нишләп
китте йөрәге атның...

Ни күрмәде башы! Әмма
кашкасына кеше башы
терәлгәнне хәтерләми.
Мие аша яшен үтте...
Ни кермәде күзләренә —
юл тузаны, күк тамчысы,
буранның энәле кары!..
Әмма кешенең күз яше
тамгач аның күзләренә
әллә нәрсә булды атка —
адәм аңы, хайван җаны
аңлашырлык тел таптылар.
Әллә нәрсә булды атка!
Ат түзмәде — телгә килде...

*
* *

Поезд куып барган мәлдә
араталы ишек аша
сикереп калдым... Мәтәлдем...
Сагындым кулың җылысын,
сагындым шушы лапасны,
үзем тартып алып кайткан
печән исе, аркан булып,
мине монда тартып торды.
Поезд алга чапкан саен,
шушы аркан тартыла барды,

һәм, ахырда, сөйрәп алды
мине көрән ул вагоннан.
Суырылып чыктым аннан —
башка атлар арасыннан,
читлектән кабат ирекә
очып чыккан бер кош сыман.
Бераздан сусыным кипты —
танавыма килеп керде
ышкыла-ышкыла көйгән
имән кучәрләрнең исе...
Бөтен эчемә ут капты...
Зәя суын эчеп кенә
янгынның сүнәсен сиздем.
Зәя исе, аркан булып,
мине монда тартып торды,
минем башымны каерды.
Поезд кызуланган саен
катырак тартылды аркан
һәм, ахырда, сөйрәп алды
мине көрән ул вагоннан.
Суырылып чыктым аннан —
башка атлар арасыннан,
ярдан яңадан дулкынга
эләккән бер балык сыман...
Безне саклап барган солдат
гармунын тартып җибәргәч,
искә төште шушы җәйдә
синең улың өйләнгәне,
аннан — сугышка киткәне
яшьтәш иптәшләре белән.
Дугамда кып-кызыл башлы
ак сөлгеләр җилфердәтеп,
Казманың бөтен урамын,
Черкеннең бөтен урамын
җиз кыңгырау, көмеш телле
гармун тавышына күмдек...
Шул тавышларның бер башы
йөрәгемне чолгап алган,
ә бер башы калган аның
синең капкаңа бәйләнеп.
Шул тавышлар аркан булып
мине монда тартып торды.
Поезд алга чапкан саен,
Катырак тартылды аркан
һәм, ахырда, сөйрәп алды
мине көрән ул вагоннан.
Суырылып чыктым аннан —
башка атлар арасыннан,
янгын сүндерергә кереп
исән чыккан адәм сыман.
Мин тезләрем, янбашларым
уелган-суелган килеш
юл буенда аунап калдым,
кызыл-көрән поезд китте,
йөзләгән аттай пошкырып,
ара-тирә моңлы кешнәп.
Вагонның һәр тактасыннан
дары исе килә иде,
канга батып үлгән атлар:
көчле айгырлар, яшь бияләр,
дәртсез алашалар исе...
Мин кергәч үк чамаладым
кая китеп баруымны
Зәя суларын калдырып,
ташлап сутлы болыннарны,
көчле, дәртле бияләрне...

Минем бил — ыңгырчак өчен,
минем сырт — эшлея өчен,
минем көчем — кырлар өчен,
урманнар, болыннар өчен!..
Мин сугыш айгыры түгел —
сугышмадым җайлы урын,
җайлы камыт, азык даулап,
бия аулап талашмадым —
булса — булды, булмаса — юк.
Мин — эш аты, хезмәт аты,
көндәлек ат, бәйрәм аты —
сука тартып, сабан тартып
кешегә шатлык бирергә
яратылган затлардан мин!..
Мин кергәч үк чамаладым
поездның кая барганын —
үр күтәрелгән чагында
вагоннан сикереп калдым.
Ә башка атлар киттеләр
өч-дүрт айлар гына элек
синең улың киткән якка...
Күрәсең, инде үлгән дә
бер атырга өлгермичә...
Дөрес иттем, дөрес иттем —
язмыш аратасы аша
сикерергә көч табалдым.
Көч тапмаган атлар калды...
Минем тез генә ярылды,
янбашым гына канады.
Көне-төне чаба-чаба
мин синең яныңа кайттым,
җилне иснәп, йолдыз карап
дөрес сукмак таба-таба.
Ничә тапкыр адаштым мин —
җилдән янгын исе килә,
җилгә дары исе сеңгән,
җилне кан исе исерткән.
Мин ачлык татырга риза,
чыбыркы ашарга риза —
дары гына көйдермәсен,
тик ярчык яраламасын,
тик ядрә җанны алмасын!
Мин иртә үлүдән куркам.
Сал ыңгырчак, кидер камыт,
сал авызлык, алаша ит,
керт тәртәләр арасына —
сугышның иң авыр йөген

тартыйм тыныч юллар буйлап
монда гына...
Синең кебек...

* * *

«...Синең кебек...
Синең кебек...
...Минем... минем...
Минем кебек...»
Кәрам аң-исенә килеп,
үзенә-үзе караса —
печән кочаклап лапаста
миңгерәп тора лабаса!..
Кочагыннан учма-учма
йолкып алып әллә печән,
әллә хисләре кәлтәсен,
әллә йөрәгенең итен
ат чәйнәп тора лабаса!..
Ә йөрәге чәйнәлгәндә
кеше бик тиз аңга килә.
Егерме өч яшьлек улын —
беренчесен һәм соңгысын —
сугышка озаткан чакта,
стансага барганда да,
перронында торганда да,
улын кочаклап елаган
хатынына бакканда да,
бер ай гына торып калган
килененә бакканда да
шушындый сүзләрдән торган
шөбһәле авыр өермә
өтте Кәрамның йөрәген.
Ул чагында да әллә ат
телгә килгән булды микән,
әллә кеше хайван белән
хайван булып аңлаштымы?..
Ә йөрәге өтелгәндә
кеше җавапны нык эзли...
«Тукта, тукта: куйыйк нокта —
бер-беребезне аңлагач,
ат та, мин дә бер үк заттан
булып чыга түгелме соң?!»
«Тукта, тукта: куйыйк нокта —
кайсыбыздан чыксалар да,
ул сүзләр күңелгә якын,
аларны кире какмыйм ич —
килешәм, димәк, килешәм,
димәк...»

Йөрәгеннән кан саугандa
кеше җавапны тиз таба...

«Малы иясенә охшар!—
дип әйткәннәр борынгылар.
Димәк, мин дә аңа охшаш!
Бу ат, димәк, ат кына түгел,
бу ат, димәк,— минем күңел!..»
Һәм Кәрамның кочагыннан
печәне коелып төште.
Һәр сабак бүрәнә булып
Кәрамның аягын сытты.
«Үлемнән курку кешедә
һаман булган, һаман булыр...
Афәт килгән көннәрдә дә
тын, ләззәтле төннәрдә дә
буар аңны, бутар җанны,
җебетер рухның нигезен,
изеп, колга әйләндерер...
Ә Ватан алдында бурыч?!
Ә халык алдында бурыч?!»
Һәм Кәрамның бавырына
ноябрьның салкын дымы
эрегән тоз булып акты —
ул оят төсле кызарды,
аптырау төсле агарды.
ул хурлык төсле күгәрде,
ачу күк чатнап яктырды —
лапастагы караңгылык
ярыклардан чыгып очты
иксез-чиксез киңлекләргә,
кара төннең караңгысын
тагы да каралта төшеп...

Күзләреннән шатлык аккан,
аңладылар дип куанган
малкаен үтәли күреп,
Кәрам кычкырып җибәрде:
— Юк! Юк!—
Минем йөрәгемдә
син түгел, ә башка бер ат...
Иярләгән... Иярләгән...
Әйе, әйе! Иярләгән!
Өзәңгеләре асылган,
тезгене ияр өстендә...
Юк, юк! Минем йөрәктәге
ат түгел син — югал! Югал...

Ә ат печән кимерә бирде
җәннәттәй җылы лапаста.

* * *

Йөрәге өзгәләнгәндә
кеше артык күп эзләнми —
карар кыла, катгый карар,
акыл белән киңәшмичә,
тыны белән сөйләшмичә,
алда туачак көн белән
мәслихәтләшмичә генә...

Һәм Кәрам да карар кылды...



Әгәр төн белән киңәшсә,
шәт, төн аңа әйтер иде,
кереп йокла, көнне җиткер —
көн киңәше төплерәк, дип...

Әгәр көн белән киңәшсә,
шәт, көн аңа әйтер иде,
авыл белән киңәшеп ал,
гавам киңәше төпле, дип.
Ә авыл белән киңәшсә,
нәрсә әйтер иде авыл?
Мал иясенә охшар дипме?

Һәм Кәрам карарын кылды
йөрәге телгәләнгәндә...

Малкайны нукталап алып,
салып бәсәргән авызлык,
алып чыкты ишек алдына,
уң кулына уннан үргән,
тисә, тәнне ярып кергән
каеш чыбыркысын алды,
сул кулы белән малкайның
тезгененнән урап тотты...

*
* *

Бар көченә бер кизәнеп
сыдырды Кәрам атына...
Чыбыркыдагы ун төен
кызарды җилгә ышкылып,
ялтырады утлы куздай —
төнге күктә әйтерсең лә
койрыклы йолдыз янды,
эзле пулялар өере
атның тәнен өтеп алды.

Ә Кәрамның җаны пеште...

Уннан үргән уң чыбыркы
атның арткы бәкәлләрен
урады ут-елан булып,
чакты төклетура булып —
биетеп хурлыклы бию
ишек алды уртасында...

Ә Кәрам үзе биеде
иле, җире каршысында...

Уттан үргән уң чыбыркы
ялмап алды атның ялын,
йолкып атты бер көлтәсен
ите-ние белән бергә.

Атның тәне җыерылды,
Кәрамның тартышты җаны...

Уннан үргән ут чыбыркы
атның алгы тезләренә
утлы кыршау булып ятты.
Үрә басты шашынган ат,
маңгаен, чалу сөяген,
чигәләрен япмак булды
бу хурлыклы өермәдән,
тешләре белән болытка
ябышып качмакчы булды
бу мәхшәрдән, мәсхәрәдән.
Һәм гөрселдәп килеп төште
түше белән туң кантарга.
Йөрәгенә үтте сызлау
атның да... һәм Кәрамның да...
Уннан үргән канлы каеш
атның маңгаена сызды.

Ишек алды уртасында
шартлады коточкыч аваз —
әллә инде кешнәү булды,
әллә шашынган Кәрамның
җан өзгеч ыңгырашуы —
лапас түбәсе каерылды,
койма ауды, капка ауды,
пыялалар зыңладылар.
Өйдән атылып чыктылар
котлары очкан әнисе,
хатыны белән килене.
Ябыштылар, асылдылар
ярсыган ир кулларына.
Селтәнеп кенә җибәрде —
өчесе дә өч тарафка
тәгәрәште өч хатын-кыз:
берсе каравыл кычкырып,
берсе тотып канлы кашын,
берсе — дүрт айлык көмәнен...

Ауган капкадан агылды
ярты авылның ир-аты —
асылдылар, ябыштылар
ярсыган ир кулларына.
Селтәнеп кенә җибәрде —
урам буйлап тәгәрәшеп
киттеләр аптыраш ирләр,
агачларга, коеларга,
ташларга бәрелә-бәрелә...
Бик күп тапкырлар шартлады
авыл өстендә ул тавыш —
кешене кем туктаталсын,
кешене ни туктаталсын
үз күңелен кыйнаганда,
утлар белән өтә-өтә,
яше белән тозлый-тозлый,
каны белән юа-юа
үз намусын пакьләгәндә?!.
Замананың үткәнеме?
Замананың киләсеме?—
Кешене кем туктаталсын,
кешене ни тыя алсын
йөрәге капкасын ачып,
иярсез алаша урнына
иярле айгыр керткәндә!?.

*
* *

Йоклап та тормады Кәрам,
бозлы су белән йөрәге
тозларын иплән юды да,
өс-башларын алыштырды,
әнисен кочаклап үпте,
Хатынын суырып үпте,
киленен кочаклады да
илле бере тулган көнне
ил явына чыгып китте...

Малкайны тотып чалдылар...

Рейхстагның диварына
кызыл кирпеч чаты белән
авылы исемен язып,
күкрәк тулы орден тагып
кайтты Кәрам-доброволец...

## Зөфәр Фәтхетдинов

# АЧЫЛГАН СЕРЛӘР

МАҖАРАЛЫ ПОВЕСТЬ

### XVI бүлек

Сәгать нәкъ тугызда Эдуард Тренькин Метелева ята торган шифаханәгә килде. Ул анда урология бүлегендә ятучы бер хатынның колбаса ашап агулануы фактын тикшерергә тиеш иде. Шифаханә кешеләре колбасаның кемдер тарафыннан Метелевага дип китерелгән булуын әйттеләр.

Тренькин килгәндә бүлекчә мөдире палаталарда иртәнге обход ясап йөри иде. Ул авыруга тапшырылырга тиешле төргәк эчендә бер язу да булуын, әмма кемнеңдер ул язуны югалтуын әйтте. Язуда әлеге төргәкнең нәкъ менә Метелевага тапшырылырга тиешлеге әйтелгән, әмма әйбер китергән кешенең фамилиясе аермачык куелмаган иде, диде. Ашамлык китерүче ир кеше иде, дип тә өстәде.

— Һәм сез шул нәрсә аркасында бөтен республикага шау-шу куптардыгызмы?— диде Тренькин ачуын яшермичә.— Бүтән эшегез юк икән.

Ул өстәл янына килде һәм Метелева квартирының телефон номерын җыйды.

— Алло!— дип кычкырды ул трубкага.— Кем әле бу?.. Надежда Петровна?.. Миңа сез кирәк идегез дә!— Тренькин урындыкка утырды.— Сезнең күршегез кичә кайттымы? Әйе, әйе, күршегез! Кычкырыбрак сөйләгез әле, берни ишетелми!

— Әкренрәк сөйләшегезче, зинһар, монда авырулар ята,— диде врач, ризасызлык белдереп.

— ...Кайткан бугай дисезме? Ә нигә алай уйлыйсыз?— Тренькин врачның кисәтүенә игътибар итмичә, кычкыруын дәвам итте.— Биштәре белән эшләпәсе коридорда эленеп тора?.. Аңлашылды...— Һәм ул трубканы элеп куйды.

— Менә күрәсезме!?— Ул бүлекчә мөдиренең өстенә үк килә башлады.— Сез монда эш юклыктан интегеп утырган арада хатынның күршесе кайтып та җиткән. Шулай булгач, бирегә ашамлыкны кем китергән булуын аңлау кыен түгел ләбаса. Трубканы алырга да шалтыратырга иде... Ә сез тиктомалга разбой саласыз. Ашамлык белән агулану була торган хәл инде ул. Бигрәк тә колбаса — бозылучан нәрсә,— дип, Тренькин, саубуллашып та тормастан, чыгып китте.

Бер сәгать үтәр-үтмәс ул тикшерү нәтиҗәләрен Чурбановка җиткерде. Тегесе докладны тыңлагач:

---

Ахыры. Башы 7 санда.

— Ә сез үзегез бүген Метелевалар квартирында булдыгызмы соң?— дип сорады.

— Ничек булмаска инде!— дип ялганлады Эдуард.— Геологның әйберләрен үз күзем белән күрдем.

— Ә аның үзен?

— Күрмәдем. Әлеге әбекәй... Метелеваның апасы әйтеп тора бит инде, кайтты ул кеше, ди, ниндидер ашамлык илтеп йөрде, ди...

— Кая илтеп йөргән? Ачыграк сөйләгезче.

Нәкъ шул вакытта бүлмәгә Галләмов килеп керде. Өстәл янындагы урындыкка утырды да Тренькинга мәгънәле караш ташлады. Тегесе нидер булганын шунда ук сизеп алды.

— ...Теге карчык... әнә шул Метелеваның апасы инде... әйтте... күршеләре Нигъмәтуллин кучтәнәчкә азык-төлек алып шифаханәгә барды, диде.

— Димәк, сез үзегез Нигъмәтуллинны бөтенләй күрмәдегез?..

Тренькин Галләмовка күз ташлады, иңбашларын сикертеп куйды.

— Монысы инде, минемчә, хәлиткеч нәрсә түгел...

Ул арада Галләмов папкасын ачты да Чурбанов алдына өстәлгә берничә кәгазь куйды.

— Әгәр Нигъмәтуллин дигән кеше бөтенләй булмаса?— диде подполковник, шиген уртаклашып.

— Ничек инде?..— Тренькин аптырап калды.— Ул бит анда пропискада тора, анда яши...

— Анысы билгеле. Бәлки Нигъмәтуллин хәзерге вакытта бөтенләй безнең шәһәрдә түгелдер, диюем. Ә бәлки ул бирегә бөтенләй кайтмагандыр да. Сез шундый мөмкинлекнең булуына ышанасызмы?

— Ничек инде, ә әйберләре... күктән иңмәгән ич инде алар...

— Аңлыйсызмы,— диде Чурбанов,— ул әйберләрне юри китереп куйган булулары да ихтимал. Әйе, әйе, юри. Күрәм, сезне менә мондый фактлар бер дә сагайтмый: командировкага килгән ниндидер бер кеше конструктор Әхтәмов квартирын күзәтер өчен уңайлы булган йортта урнаша. Аннары бу кеше кинәт юкка чыга, көтмәгәндә үлеп китә, ул яшәгән квартир хуҗабикәсе Метелевага бирелергә тиешле ашамлыктан икенче берәү агулана. Шикләндерә торган нәрсәләр түгелмени болар? Бу вакыйгалар арасында ниндидер бәйләнеш барлыгы сизелеп тормыймыни? Ә менә мин, лейтенант, аларның барысының да Метелева белән бәйле булулары очраклы хәл түгеллеккә ышанам. Сез исә, кызганычка каршы, ул вакыйгаларны нечкәләп, бәйнә-бәйнә тикшерергә тырышып та карамагансыз!

Ләкин Тренькин өчен күңелсезлекләр моның белән генә бетмәгән, бу әле башы гына булган икән. Ул начальнигының кабинетыннан чыгып китәргә җыенган гына иде, Чурбанов Галләмов китергән кәгазьләргә күз йөртеп чыкты да, тавышын үзгәртеп, аңа тоткарланырга кушты. Аннары, күзләрен кәгазьдән алмыйча гына, милиция лейтенанты Герасимов «Йөнтәс» кушаматлы куркыныч җинаятьчене кулга алган вакытта Тренькинның ни өчен читтә кеше сыман ерактан гына күзәтеп торуын сөйләп бирергә кушты.

Тренькинның эче жу итеп китте. Бетте баш, дип уйлап алды ул, чөнки мондый очракларда куркаклык өчен НКВД органнарыннан куулары ул яхшы белә иде.

Ул ык-мык итте, акланырга, булган хәлне бөтенләй бүтәнчә итеп сурәтләргә маташып карады. Ләкин берни дә ярдәм итмәде. Ахыр чиктә ул барын да расларга мәҗбүр булды.

— Сезнең, лейтенант, үз хатагызны танырлык та кыюлыгыгыз юк икән,— диде подполковник.— Совет кешесенә хас элементар намуслылык житенкерәми сездә, үз-үзеңә тәнкыйть күзлегеннән карау дигән нәрсәне белмисез сез.

Бу сөйләшүдән соң бүлек җитәкчеләре Тренькинны НКВД органнарыннан чыгару турында тәкъдим керттеләр. Ләкин кемдер кулын йөртте булса кирәк, бүлекнең бу таләбен тормышка ашыру тоткарланды. Кадрлар бүлегенең җавабы шундыйрак булды: янәсе, Тренькин әле яшь, төзәлер янәсе, яшьләрне тәрбияләү эшен яхшыртырга кирәк...

Ул арада озак дәваланганнан соң Александр Жуков та эшкә чыкты. Мария Петровна Метелева тирәсендәге вакыйгаларны тикшерү вакытында ул аның квартиранты Нигъмәтуллин командировкадан бөтенләй кайтмаган булуын һәм, табигый ки, бу авыру ханымга шифаханәгә бернинди ашамлык илтмәгәнлеген ачыклады. Ләкин аны кем илткәнлеген беркем дә белми иде. Метелеваның апасына килгәндә, ул Тренькинга Нигъмәтуллинның шифаханәгә ашамлык илтүе турында берни әйткәнем юк, дип барды, ул көнне, гомумән, Тренькинны да, Нигъмәтуллинны да күргәнем булмады, дип өстәде. Шулай итеп Тренькинның ялганы тотылды. Тиздән Халык комиссарының приказы белән ул эшеннән алынды.

Чираттагы сорау алу вакытында Фроловтан: Древцов квартирында кайда нәрсә барын сез ничек алай яхшы белдегез, дип сорадылар. «Иөнтәс» мыскыллы елмаеп: «Оптик приборлар барында чит кеше квартирында нәрсәнең кайда ятуын белү өчен анда үзеңә кереп йөрүнең һич кирәге юк,— дип җавап бирде.— Үз тормышыңны куркыныч астына куймыйча гына, моның өчен бинокльдән яисә трубадан файдаланырга да мөмкин». «Без теге кәкре борынлы карт белән алдан сөйләшеп куймыйча да, бу мәсьәләдә бер үк «ачыш»ны ясаганбыз,— диде ул.— Мин үз фатирымны ишегалды ягыннан, дөресрәге чардактан күзәттем, ә ул үзенекен — Әхмәтов квартирын — икенче яктан, урам ягыннан күзәткән. Менә шулай, нәчәльникләр, моннан болай тәрәзә пәрдәләрегезне калынрак нәрсәдән тегегез. Куркынычсызлык техникасы турында да онытып бетермәгез. Юкса, киштәгә кунаклаган әтәчләр төсле, югары катларга менеп урнашасыз да, сезнең шмоткаларга күз салучы булмас дип уйлыйсыз. Ялгышасыз, нәчәльникләр. Минем кебек кеше...»

— Сезнең кебек кешеләр күп түгел,— дип Жуков аның сүзен бүлдерде.— Сез, Фролов, шуны онытмагыз. Никадәр генә озын-озак булмасын, һәр юлның азагы була. Ә җинаять юлы — юлларның иң кыскасы. Һәм ул бер нәрсә белән — суд эскәмиясе белән тәмамлана! Менә сез тимер юлда вак-төяк нәрсәләрне чәлдерүдән башлаган идегез. Ә иң ахыргы станциягә бик авыр йөк белән — коточкыч җинаятьләр йөге белән килеп төштегез. Сезгә шуннан ары юл юк — үзегезне нәрсә көткәнен бик яхшы беләсез!

Фролов, һич исе китмәгәнгә салышып, кулын селтәде:

— Миңа ни чәпәячәкләрен синнән башка да беләм. Бүгенме, иртәгәме — кайчан да бер үләсе ич! Ә үлгән кешегә барыбер...

— Аның каравы тере кешегә барыбер түгел. Синең туганнарыңа барыбер түгел. Синең черек философияң буенча барыбер бер үләсе булгач, кешегә бу дөньяга туунын да хаҗәте юк, яшәүнең дә, эшләүнең дә... Хәер, син үзең дә моны бик яхшы аңлыйсың. Тик үзеңне үзең тынычландырырга, кылган барлык явызлыкларың өчен үз-үзең алдында акланырга гына телисең... Ниһаять, мине киләчәктә нәрсә көтә икән дип бик куркасың. Әллә шулай түгелме? Шулай, әлбәттә. Бу дөньяда үлемнән курыкмаган кеше юк. Сиңа: Камчаткага тикле яланаяк барсаң гына үзеңә котылу табачаксың, дигән шарт куйсыннар әле, син аяк табаннарың коры сөяккә калганчы, тәмам хәлдән таеп егылганчы чабачаксың. Юк, Фролов, сиңа барыбер түгел, барыбер булса үзеңнең бүгенге хәлеңне җиңеләйтердәй әллә ниткән теорияләр эзләп маташмас идең...

Аннары Фролов үзенең элегрәк качмавына үкенә башлады: «Теге

чакта, мине эзләп тапкач, Чмо әйтте бит миңа, НКВД койрыгында утыра, диде. Ә мин ышанмадым,— ул ике куллап башын кысты,— поселокта кеше күзенә чалынып, буталып йөрүемне теләми инде бу бәндә, шуңа күрә котырта, дип уйладым».

— Нигә алай уйладыгыз? — дип сагаебрак сорап куйды подполковник Чурбанов.

Фролов башын күтәрде, аркасы белән стенага терәлде һәм сагыш катыш:

— Бервакыт мин очраклы рәвештә генә Моратовны күрдем. Чүл бүреседәй койрыгын кыскан, монастырь тирәсендә бутала бу. Аннары зиратка таба сыпыртты. Ул көнне минем янга килеп тә карамады. Иртәгесен генә миңа Светлогорскига шылырга кушты. Тик бу андый-мондый гына кушу түгел — боерык иде. Менә мин шунда сизендем: минем турыда кайгыртулары түгел бу боларның, монда икенче сәбәп булырга тиеш. Шунда уй төште минем башка: әллә, мин әйтәм, кемгә дә булса комачаулыйммы мин монда. Шул уй харап итте дә инде мине, сизгерлекне югалта төштем...

— Чмо һәм аның хуҗасы, кирәгегез калмагач, үзегезне дә дөмектерерләр дип курыккансыздыр әле?— диде Чурбанов.

— Син мине тинтәккә санама, начальник. Шөрепләр эшли әле хәзергә.— Фролов бармагы белән маңгаена сугып алды.— Алар бит тәгәрмәчсез арба кебек: минсез беркая да бара алмаячаклар иде. Ә берәр атнадан алар әйтмәсә дә моннан үкчә ялтыратырга исәп иде.

Чурбанов папкасыннан бер бит кәгазь чыгарды да Фроловка күрсәтте:

— Бу янаулы хатны Кәрим авылыннан җибәргәннәр. Кемнән икәне әйтелмәгән. Сез ул авылда булгансыз. Сезнең эшме бу?

— Булмаганны үз өстемә алыр хәлем юк, начальник. Гомумән, андыен трахтатлар язып маташмыйм мин.

Сак астында бүлмәдән чыгып барганда Фролов ишек төбендә туктап калды һәм Жуковка мөрәҗәгать итеп:

— Сине кайдадыр күргәнем бар шикелле, начальник,— диде.— Тик менә кайда икәнен һич хәтерли алмыйм. Әле шул турыда баш ватып утырдым.

Җавапны Чурбанов бирде:

— Хәтерең какшый башлаган. Өлкән лейтенант синең тырышлык белән теге дөньяга китә язып калган кеше ләбаса.

Фролов гаҗәпләнеп Жуковка текәлде.

— Юкка баш ватма, Фролов,— диде Жуков.— Оныткансыңдыр, мөгаен: май ае кичәсе, ресторан, аркылы үтмәле ишегалды һәм... утын пүләне.

Җинаятьче, «кирәкми, хәтерләдем», дигәнне белдереп, кул селтәде.

— Бу вакыйга да синең гаепләр исемлегенә керәчәк,— диде Чурбанов тыныч кына.

Фролов, берни әйтмәстән, борылды да ишек бусагасыннан атлады.

Чурбанов шунда ук Святовский поселогында эшләүче ике сотрудникка моннан ары монастырьны бик нык күзәтү астына алсыннар, дип әйтергә кушты. Элек монастырь башлыгы торган өйдә һәм элекке хөҗрәләрдә хәзер берничә йөз кеше яши иде. Нигездә, гражданнар сугышыннан соң бирегә читтән күчеп килгән кешеләр иде алар.

— Җинаятьчеләрнең Әхтәмов квартирындагы сейфны ничек күргән булуларын Закиров дөрес чамалады булса кирәк,— диде подполковник.— Шуңа күрә бу квартирны күзәтеп торырга мөмкин булган йорттагы игътибарга лаек хәлләрнең барын да бик ныклап, җентекләп өйрәнергә. Икенче каттан башлап түрттенчесенә кадәр яшәгән һәр кешене энә күзеннән үткәргән кебек бик нык тикшерергә,— диде ул һәм, үзенең урынбасары майор Галләмовка мөрәҗәгать итеп, приказ

төсендә өстәде:— Марс Әхмәтович, моның өчен ике-өч кеше билгеләгез. Бик ашыгыч рәвештә шуны ачыкларга кирәк: нинди бәндә ул Нигъмәтуллин? Метелеваның элекке фатирчысы тәэминатчы Постновның биографиясен дә тикшерегез. Метелевага дигән ашамлыктан Тараткина дигән икенче бер хатынның агулану сәбәбе дә әле һаман томан эчендә. Үзегез күрәсез, эш тавык чүпләп бетермәслек.

Жуков үзе Магнитогорскига барып, үлгән Постнов турында барын да белеп кайтырга булды. Юлга өч көннән чыгасы булганга, аңа кадәр кичектермәстәй эшләрне тәмамларга кирәк иде. Ә бүген, шимбә көн, Александр шәһәр китапханәсенә керергә һәм анда азык матдәләрендә, аерым алганда колбасада хасил була торган агулар турындагы китапларны караштырырга булды. Аның фикеренчә, бу китаплардан алган мәгълүматлар шифаханәдә булган агулану очрагына бераз ачыклык кертергә тиеш иде. Ләкин кичен ул китапханәгә килгәч, аңа кирәкле китапның кулда икәне мәгълүм булды. Бу хәлдән кәефе китеп, күзенә ак-кара күренмәс хәлдә, ул чыгу ягына таба борылды.

Шул хәлендә ул янышнан үтеп киткән сары чәчле чибәр кызга да, аның үзе белән баш иеп исәнләшүенә дә, бераз киткәч туктап калып, аны көтеп тора башлавына да игътибар итмәде.

— Гафу итегез...

Александр ашыкмый гына артына борылды һәм баскан урынында катып калды: аның каршында теге чакта Ключищи пристанендә очратып, таныша язып калган кыз басып тора иде.

— Тагын бер талкыр гафу үтенәм...— дип пышылдады сары чәчле кыз.— ...Әгәр ялгышмасам, теге вакытта... чаңгыда... сез идегез бугай...

Егетнең төксе чыраенда, ниһаять, елмаю билгесе күренгәч кенә кыз ялгышмаган булуына ышанды.

— ...Теге чакта хулиганнардан йолып калуыгыз өчен сезгә рәхмәт тә әйтә алмый калдым. Мин сезнең алда бурычлы...

Әмма Александр кызның сүзләрен ишетер, аңлар хәлдә түгел, моннан бер ел элек булгандагы кебек, кызның ниндидер бер җылылык сирпеп торучы зур зәңгәр күзләренә кереп чумгандай сизә иде ул үзен.

Кыз сүзен бетергәч тә, Александр аңа ни әйтергә белмичә, сүзсез басып тора бирде.

Кыз да аның карашындагы серле мәгънәне төшенеп алды булса кирәк, уңайсызланды, кызарды:

— Ә сез... бөтен кешегә шулай карыйсызмы?..

— Юк,— диде Александр кырт кисеп. «Гомеремдә беренче тапкыр»,— дип тә өстәмәкче иде, кыз моны шаярту гына дип кабул итәр дә шуның белән эш бетәр, дип әйтер сүзен йотып калды. Теге чакта кызның аңа артык күп нәрсәне белергә теләгәне һәм күп сүзлелеге өчен шелтә белдергәнен исенә төшереп, эндәшмәде. Ләкин аңа артык озак сүзсез торырга да ярамый иде: кызның моны үзенчә аңлап, китеп баруы да бар. Ә аның бу чибәркәйне җибәрәсе килми, һич югында исемен белеп калырга тели иде. Бу форсатны да ычкындырсаң, аны тагын кайда һәм ничек очратасың?

— Ә сез чаңгыда бик әйбәт йөрисез,— диде кыз гафу үтенгән сыманрак итеп.— Мин дә шулай шуарга өйрәнергә хыялланып йөрим, ләкин барып чыкмый, булдыксыздырмын инде, күрәсең...

Кыз аның белән тик болай гына, хәтерен калдырмас өчен генә сөйләшә кебек тоелды Александрга. Һәм шунда ук кәефе кырылды. Әлбәттә шулай. Юкса, ни дип ул ачык йөз белән такылдап торыр иде? Теге вакытта Ключищида аңа игътибар итәргә дә теләмәгән иде бит. Һәм нигә дип кыз аңа игътибар итәргә тиеш ди? Аның чибәррәк егете бар бугай бит. Дөрес, ул егете аның хулиганнар кызга килеп бәйләнә башлагач җебеп тик басып торды. Ләкин монысы инде вак нәрсә. Ки-

ресенчә, хәзер бу интеллигентлыкны күрсәтә торган бер сыйфат итеп кенә карала бугай.

Кыз аңарга китапханәдә еш булуын, бигрәк тә шимбә көннәрне кулайрак күрүен әйтте...

«Миңа да бер шимбә көн килергә кирәк әле»,— дип күңеленә сеңдереп куйды Жуков һәм сәгатенә күз төшереп алды.

— Мин сезне тоткарлыйм ахрысы, ай, гафу итегез, зинһар...

— Зарар юк,— дип кул селтәде Жуков.— Уңышлар телим.— Һәм тиз-тиз атлап ишеккә таба юнәлде.

Бу китү чын мәгънәсендә кыздан качу иде. Ләкин болай китеп бару Александрны кыз турындагы уйларыннан йолып кала алмады. Ул төне буе диярлек караватында кыбырсып, әйләнгәләп ятты, исемен дә сорап калмавы өчен үзен-үзе битәрләп бетерде. Таң алдыннан гына йокыга китте.

Якшәмбе көнне Жуков белән Закиров ял итәргә шәһәр читенә чыгарга булдылар.

— Син Элеонораны да чакырыр идең,— диде Александр дустына.— Бик уңай форсат бит...

Илдар кызга шалтыратты.

— Эдик, сезме бу?— дигән тавыш Илдарны сагаерга мәҗбүр итте. Аның белән Эляның сеңлесе сөйләшә иде булса кирәк.

— Эляны чакырыгызчы.

Трубкада тынлык. Бераздан Эляның ягымлы тавышы ишетелде:

— Әйе, мин тыңлыйм, Эдуард.

Илдар башта трубканы элеп куярга теләгән иде дә кире уйлады.

— ...Хәерле көн, Эля,— диде ул.

Тынлык.

— Ә-ә, бу синмени әле, Илдар.— Эляның каушаганлыгы сизелеп тора иде.— Эшләрең ничек?

Эш турындагы соравына җавап биреп тормастан, Илдар аны шәһәр читенә чыгарга чакырды.

Кыз баш тартты, һич вакытым юк, диде.

Закиров ашыкмый гына трубкасын элде. Аның башында бер сорау бөтерелә башлады: «Кем соң ул Эдик дигәннәре?» Күңеленең бер почмагында «бәлки Тренькиндыр?» дигән уй да йөгереп үтте. Ләкин ул уй шунда ук сүнде: «Булмас ла, Эля андый буш куык белән аралашамы соң? Моның булуы мөмкин түгел».

Илдарның кәефе кырылды, күңелен, корт кимергәндәй, нәрсәдер кымырҗытып, борчып тора башлады. Каты авырудан яңа терелгән кеше кебек — аяк атларлык та хәле юк иде. Шәһәр читенә чыгу теләге дә каядыр очты. Ул Александрга таба борылды:

— Бары да җимерелә, ахрысы. Аның ниндидер Эдуарды бар.

— Бәлки алар эш буенча гына танышлардыр...

Илдар иңбашларын җыерып куйды.

— Шулайдыр, мөгаен, эш буенча гынадыр,— дип Александр аны һаман тынычландырмакчы булды.— Юкса Эля — житди кыз бит ул...

Алар көн уртасы җитәрәк кенә Аккош күле буена киттеләр. Күл өсте, яр буйлары ял итүчеләрнең күплегеннән мыж килеп тора иде. Кояш бер урында хәрәкәтсез калган да ел буе туплаган җылысын бер көн эчендә кешеләргә биреп бетерергә маташа сыман иде. Эссе, яфрак селкетерлек тә җил юк.

Сөйләшми-нитми генә кояшта кызындылар. Ниһаять, Закиров түзмәде.

— Саша, әйт әле шуны: мәхәббәттә психик авыру галәмәтләре бармы?— дип куйды.

Жуков бер мәл сүзсез ятты, аннары, башын бормый гына:

— Сиңа карап торсаң, бар төсле тоела,— дип куйды.— Дөрес, мә-

хәббәт авыруы күбрәк синең физик халәтеңә йогынты ясый — син чүпрәккә әйләнәсең. Ә гомумән әйткәндә,— дип дәвам итте ул, бу юлы инде дустына йөзе белән борылып,— җавапсыз мәхәббәт — чыннан да каты авыру, бер сүз белән әйткәндә — газап. Кеше җәфалана, кеше йокыдан кала, кеше үзен һәм башкаларны каргый башлый, кеше елый, нәфрәт кичерә һәм... берни дә эшли алмый. Көн саен шулай. Менә моннысы инде психика өлкәсеннән. Син шуның белән килешәсеңме?

— Әй-й-й-е... Син минем киләчәкне матур сурәтлисең...

— Бер дә кайгырма, картлач, бары да рәтләнер,— диде Александр. Әмма аның тавышында әллә ни ышаныч юк иде. Үзе дә шуны сизде булса кирәк, катгыйрак тон белән кырт кисеп әйтте: — Тынычлан. Үз-үзеңне кулга ал...

Алар шәһәргә кичкырын гына кайтып киттеләр.

## XVII бүлек

Дүшәмбе көнне Закиров белән Жуковны берьюлы ике яңалык көтә иде. Радистлар ике шифровканы кулга төшергәннәр. Аларны Чурбанов үзе укыды.

Мефодийга.

Сез биргән мәгълүматлар таркау. Алар буенча изделиенең техник күрсәткечләрен билгеләп булмый. Розаны активлаштырыгыз. Розалардан букет булгач, Йөнтәсне юк итегез. Рация җибәрелде. Элемтә элеккечә.

Штольц.

— Гадәти радиоалгыч белән кабул итәләр. Тегеләр 41 метрлы диапазонда, кыска дулкында эшли,— дип аңлатма бирде подполковник.— Ә бередәге агентларның теге як белән элемтә чарасы сезгә моннан элекке шифровка буенча мәгълүм. Менә шулай. Без хәзергә гади статистлар ролен генә уйныйбыз.

Чурбанов, ризасызлыгын яшермичә, бүлмәдә арлы-бирле йөрергә тотынды.

— Без бу кәгазьне Йөнтәснең үзенә дә күрсәттек,— дип подполковник радиограммага тагын бер тапкыр күз төшереп алды.— Ошамады ул аңарга.

Чурбанов арыган кыяфәт белән күңелсез генә елмаеп куйды:

— Төгәлрәк итеп әйтсәк, элекке дуслары ошамады аңа. Һәм ул шуннан соң безгә бик тә кызыклы бер фактны ачып салды. Дөресрәге — ике фактны. Беренчедән, ул моңарчы безгә менә нәрсәне әйтми яшереп калдырган икән: аңа акча бәрабәренә информация биреп торырга сеңелесен күндерергә кушкан булганнар. Ул вәгъдә иткән. Менә шуңа күрә ул үзен үтермәячәкләренә ышанып йөргән дә. Моннан нәрсә килеп чыга? Без элек кулга төшергән шифровкада телгә алынган Роза — ул әле Йөнтәснең сеңелесе түгел. Анысы икенче бер ханым. Бу нәрсә соңгы радиограмма белән дә раслана: анда бит: «Розалардан букет булгач»,— диелгән. Димәк, алар үз эшләренә тагын бер Розаны тарталар да, шуннан «букет» хасил була. Шуннан соң инде аларга Йөнтәснең кирәге калмый.

Подполковник бүлмәдәгеләргә игътибарлы караш ташлады.

— Ә икенче факт менә мондый. Йөнтәс, мин ачкычларны ике данә итеп ясадым, диде. Беренчесен ул, безнең аңа ясаган визиттан ике көн элек үк, тиешле кешесенә биреп өлгергән булган.

Бу сүзләрне ишеткәч, Закиров хәтта урыныннан ук кузгалып куйды һәм, бу ачкычны подполковникның өстәле өстендә күрергә ниятләп, муенын сузды.

Чурбанов моны күреп:

— Ачкыч монда юк. Хәер, хәзер аның кирәге дә калмады инде.

Закиров үз начальнигына гаҗәпләнеп карап куйды.

— Җинаятьче, соңрак ачыклаганча, гаҗәп шәп хәтерле кеше булып чыкты. Ул үзе ясаган ачкычның өлгесен ясап та күрсәтте. Аннары без аңа өлкән лейтенант Закиров алып кайткан чын ачкычлар бәйләмен күрсәттек. Ышанасызмы шуңа, ул шунда ук Моратов кушуы буенча аңа ясап биргән ачкычның төп нөсхәсен эзләп тапты. Без, бәлки бу кеше ялгышадыр, дип ачкычны ул ясап күрсәткән эскиз белән чагыштырып карадык — чат килеп тора!

— Ул ачкыч кайсы сейфныкы булган соң?— дип түземсезләнеп сорады Закиров.

Подполковник ачкычның Роза Зеленская эшли торган конструкторлык бюросындагы сейфларның берсенеке икәнлеген әйтте. Һәм, Закиров белән Жуковка мөрәҗәгать итеп, шаяртта төшеп өстәп куйды:

— Менә, кадерле иптәшләр, якшәмбе көнне сез йокы симерткәндә һәм тән шәрифләрегезне кояшта җылытып ятканда без майтарган эшләр шулар. Сезне дә чакырмакчы идек тә, әмма сезне эт белән дә табарлык түгел иде.

Жуков бүген Метелеваның шифаханәдән чыгачагын һәм хәл тәмам ачыкланганчыга кадәр аның квартирына кемне дә булса урнаштырып торырга кирәклеген подполковникның исенә төшерде.

Бераз уйланып торгач, Чурбанов:

— Миңа ошамый андагы хәлләр,— диде.— Мөгаен, сез хаклыдыр — анда сак куярга кирәк. Дөрес, кеше табу кыен: бер сотрудникны икегә бүләрлек булып утырам.— Ләкин үзе шунда ук тиешле күрсәтмәләрне бирде.

Ул көнне Жуков Метелева яши торган өйдә торучыларны тикшерү белән мәшгуль булды. Эшен Метелеваның үзеннән сорау алудан башлады, әмма аңардан яңа бер нәрсә дә ишетә алмады. Үз бүлегенә эш көне тәмамланыр алдыннан гына кайтты: сишәмбе көн Магнитогорскига китәсе булганга, командировка кәгазьләрен алып калырга кирәк иде.

Бүлмәсендә кәгазьләргә чумып утырганда, аның ишеген шакыдылар. Ул, башын күтәрмичә генә, гадәтенчә: «Әйе, керегез!» — диде.

— Мөмкинме?! Сез белмисезме, капитан Нәҗметдинов кайда икән?

Жуков башын күтәрде һәм гаҗәпләнүеннән катып калды. Ишек бусагасында басып торган кыз да шул ук хәлдә иде.

— ...Сез?! — диде кыз.— Сез... ничек монда?!. Әллә биредә...

Жуков та урыныннан кузгалды һәм:

— Ә сез ничек?— дип сорады һәм шунда ук, яңа аңына килгәндәй, өстәп куйды:

— Рәхим итегез, узыгыз, утырыгыз...

— Рәхмәт,— диде кыз.— Тик миңа капитан Нәҗметдинов кирәк иде. Бүлмәсе бикле, ә үзе кайдадыр шушы тирәдә булырга тиеш, диделәр.

— Ә сез... монда көтеп торыгыз... ул килер.

Кыз утырды.

— Ничектер сәер килеп чыга,— дип куйды ул, нидер уйлап.

Ә Александр аңардан күзен ала алмыйча карап тора һәм балаларча елмая иде.

— Димәк, сез монда эшлисез? Тикшерүче булыпмы?

Александр, әйе дигәнне аңлатып, ияк какты.

— Ә мин — судмедэксперт. Менә капитан Нәҗметдиновка тикшерү нәтиҗәләрен китергән идем,— ул аз гына чытлыкланып егеткә таба борылды:— Ә сезнең фамилиягез, иптәш Жуков, миңа күптән таныш.

— Шулай ук мыни? Монысы минем өчен яңалык... Ә кайдан беләсез?..

— Ә сезнең Галина Ивановна Галахова үткәргән судмед тикшерүләренең нәтиҗәсен алганыгыз булмадымыни?

— Ә-ә!.. Сез шул Галаховамыни инде?!

— Нәкъ үзе,— дип елмайды сары чәчле чибәр.

— Ә минем исемем Александр. Калганын үзегез дә беләсез.

— Белмим, белмим, серле егет. Инде дүртенче тапкыр очрашабыз, ә миңа хәзергә сезнең тикшерүче Александр Жуков булуыгыз гына билгеле.

Жуков исә, аның матур зәңгәр күзләреннән аерыла алмыйча, басып торуында булды.

Кыз да бер аңа, бер аяк очларына карый иде.

— Нәҗметдинов килгәндер инде?— дип Галина урыныннан кузгалды.— Ә сез, Александр, кыю һәм әйбәт кеше. Андыйлар...— Ул «хатынкызга ошый»,— димәкче иде, ләкин үзен «Андыйлар хәтергә сеңеп калалар»,— дияргә мәҗбүр итте.

— Китәсез дә мени?— диде Жуков. Ул бөтен гәүдәсе белән алга омтылып куйды һәм:— Үтенәм сездән, тагын бераз гына торыгыз инде,— дип ычкындырганын сизми дә калды. Ә кызның икеләнеп торуын күргәч, өстәде:— Китмәгез инде. Мин... минем сезнең белән сөйләшәсем килгән иде...

— Аннары сез минем турыда нәрсә уйларсыз? Мин сезнең бүлмәгә бәреп диярлек кердем...

Жуков кыз янына килде һәм шыпыртлап кына:

— Сез хәзер ашыкмыйсызмы?.. Мондагы эшегез беткәч, диюем?..

— Юк, ашыкмыйм.

— Рөхсәт итсәгез, мин сезне көтеп торыр идем. Бу бинага керә торган ишек төбендә. Ә аннары бераз озатып куяр идем?..

Кыз, берни әйтмичә иңбашын җыерып куйды да, чыгып китте. Коридордан ишек ябылган тавыш ишетелде. «Нәҗметдинов кайтты»,— диде Жуков эченнән генә һәм тиз-тиз җыена башлады.

Аңа озак көтәргә туры килмәде. Кыз тышкы ишекне сак кына япты да баскычтан күбәләктәй очып диярлек төште. Аның күңеле шат икәне әллә кайдан күренеп тора иде.

— Я, кайсы якка юл тотабыз?— диде ул һич тартынмыйча.

— Әйдәгез Идел буена,— дип тәкъдим ясады Жуков.— Мин пароходларга, баржаларга карап торырга яратам.

— Ул яктан без охшаганбыз икән. Җәйге сессия вакытларында имтиханга әзерләнергә дип гел яр буена йөгерә идем...

— Ә сез, Галя, биредә укыдыгызмыни?

— Ярославльдә.

— Менә шуңа мин сезне бу көнгә тикле бер дә күрмәгәнмен,— диде Александр елмаеп.— Юкса күптән танышкан булыр идек. Идел буенда.

Алар бераздан Идел причаллары янына килеп чыктылар һәм күләгәле аллеядагы зур урындыкка килеп утырдылар.

Көн җылы, җилсез. Кызарып тулган кояш офыкка төшеп килә. Причалда торган пароходларның тәрәзәләре шәфәкъ нурыннан кызгылт-сары учак булып яналар иде.

— Елганың текә ярында үсеп утырган агачларга карап торганда шундый уйлар кузгала. Яшь чагында...

Ул кызның ирексездән елмаеп куюын күрми калды.

— ...Миңа әйтерсең лә ул агачлар төн караңгылыгыннан файдаланып су буена йөгерешеп төшкәннәр дә, анда рәхәтләнеп су коенганнар һәм, артык мавыгып китеп, таң атуын шәйләмичәрәк калганнар.

Аннары, судан йөгереп чыкканнар һәм, төнге шуклыкларын беркем дә сизмәсен өчен, шулай катып калганнар кебек тоела иде.

— Гафу итегез, сез яшьлегегез турында бик күптән булган нәрсә кебек итеп сөйлисез. Ничә яшь соң сезгә?

— Абзагыз инде чирек гасырдан артык яшәгән кеше.

— Шаккатмалы хәл!— Кыз көлемсерәп башын селкеде.— Пенсиягә чыгарга да күп калмаган икән... Ә миңа егерме өч,— диде ул гади генә итеп.— Элегрәк бу бик тә күп төсле тоела иде.

— Шулай була шул,— диде Александр.— Унҗиде яшемдә чакта миңа егерме биш яшьлекләр инде ир уртасы булып күренә иделәр, ә утыздагыларны инде әйткән дә юк. Менә хәзер миңа егерме алты яшь, ә мин үземне әле генә яши башлаган кеше итеп хис итәм. Ә тагын дүрт елдан... Хәер, берни үзгәрмәячәк. Ун елдан соң да. Кыскасы, олыгая барган саен кешенең яше яшәрә димме? Аның психологиясе шундый.

Тора-бара тартыну-оялу юкка чыкты, алар, күптәнге танышлардай, иркенләп сөйләшеп киттеләр. Үзләре дә сизмәстән театр һәм кино турында сүз башладылар. Аннары ирләрнең һәм хатын-кызның җәмгыятьтә тоткан урынына күчтеләр, дөресрәге шул турыда бәхәсләштеләр. Александр ирләрнең җәмгыятьтә тоткан ролен аларның дәүләт һәм гаилә алдындагы бурычларын үтәүләренә кайтарып калдырды.

— Минем балалык дустым бар,— диде ул.— Илдар Закиров. Аның белән дә бу темага күп тапкырлар гәпләшкәнем, бәхәсләшкәнем бар. Бу бәхәсләр икебезне дә бер үк нәтиҗәгә китерде.

— Бу бик тә кызык!— диде Галя шаян тавыш белән.— Я, я, сезнең ул формулагыз нинди соң?

Александр каядыр еракка текәлде, кашларын җыерды һәм җитди итеп:

— Ләкин сез миннән көлмәгез, ямә? — диде.

— Юк, юк, нигә көлим ди.

— Ир кеше туганда ук бурычларга батып туа. Бу бурычларның икесе — туган ил һәм туган ана алдындагысы — мәңгелек. Алардан ул үлгәч кенә котыла. Калган икесен — үзенең токымын дәвам иттерү һәм хезмәтендә уңышларга ирешү бурычларын ул аңлы гомере буе исендә тотарга, үтәргә тиеш.— Жуков кызга күз төшерде. Ул бик җитди кыяфәттә утырганга күрә, егет шаярту тонынарак күчеп, дәвам итте:

— Ир кешенең соңгы ике бурычына килгәндә, аларына инде кемнең бәхете ничегрәк...— Һәм ул Галяга мәгънәле генә итеп карап куйды.— Мин токымны дәвам иттерү турында әйтәм...

— Бу мәсьәләдә ир-атның хәле хатын-кызларныкына караганда җиңелрәк.

— ...Белмим... мәхәббәт һәм өйләнешү — болар авыр проблема... Ир кеше бит яше арткан саен сайлаучанрак була бара. Ә югары интеллектлы кешегә әйләнүе аерата кыен.

— Сез үзегезгә өйләнүе бик кыен димәкче буласыз инде, шулаймы? — Галина күзләрендә шаян очкыннар чыгарып елмайды.

Александр аның кинаясен аңлады һәм тагын да җанлана төшеп:

— Мин, Галина, интеллектым артык югары булудан җәфаланам, дип әйтергә теләмәдем. Мактавыгызны, комплимент әйтүегезне дә көтмим.

— Анысын әйтмәгез инде, ирләр үзләренең акыллырак булулары белән мактанырга яраталар.

Ләкин Жуков акланып маташмады һәм әңгәмәне элекке юнәлешенә борып җибәрергә ашыкты:

— Мин бит гаилә һәм мәхәббәт турында...

Ул арада «Писемский» пароходы причалдан аерылып, ераклаша башлады, металл чыңлавы, пароход тәгәрмәчләренең шап-шоп суга бәрелгән тавышы, озатырга килгән кешеләрнең хәерле юл теләп кыч-

кырулары ишетелде. Ярдан шактый ераклашкач, пароход озак кына итеп саубуллашу гудогы бирде.

Алар пароходны күзләре белән озатып калдылар. Галина уйчан гына:

— Бәхетле кешеләр. Каядыр ял итәргә баралар. Пароходта бару үзе бер хозурлык бит ул,— дип көрсенеп куйды.— Сез, Александр, мәхәббәт турында нидер әйтә башлаган идегез дә бүлендегез...

Жуков эндәшмәде, аның бөтен игътибары дулкын өстендә күбекле эз калдырып ераклаша барган пароходта иде.

— Мәхәббәт турында әйтүе җиңел түгел...— диде ул, ниһаять,— бигрәк тә сезгә...

— Нигә алай?— диде кыз көлемсерәп.— Әллә сез мине ул хисне аңлый алырлык кеше түгел дип саныйсызмы?

Александр чарасыз калды: ачыктан-ачык сөйләшүгә чакыруымы бу аның, әллә инде аңардан көлүе генәме? «Юк, ашыгырга ярамый, төп башына утырып калуың бар. Бәлки ул болай гына әйткәндер, ә син үзеңнең хисләрең белән тыгыласың. Юк, монда кавалеристларча һөҗүмгә бару урынсыз булыр», — дип уйлады ул һәм, үзе дә сизмәстән, кызның кулын учына алды. Галинаның кулы салкын иде.

— Туңмагансыздыр бит?— диде ул, кинәт йокысыннан уянгандай, һәм як-ягына каранды.

— Юк,— дип пышылдады кыз.

Кояш баеган иде инде. Җир өстенә эңгер иңеп килә. Елга ягыннан салкынлык бөркелә. Егет өстендәге пиджагын салып, кызның иңенә япты.

— Дөресен әйтим, минем әле беркемне дә яратканым юк һәм бу хиснең кешегә йогынтысын китаплардан укып кына беләм.

— Чынлап әйтүегезме бу? — диде кыз һәм егеткә сәерсенеп карап куйды.— Ә болай караганда сез күңел аздыручы роленә дә яраклы кеше төсле күренәсез: бар яктан килгәнсез... Ә гомумән алганда,— Галина җитди тонга күчте,— үземнең ир-атка карата булган хисләремне үлчәп карага теләсәм, мин бу кешене дошман пулясыннан үз гәүдәм белән саклап кала алыр идемме, дип уйлыйм. Бәлки мондый чагыштыру уңайсызрактыр, әмма ул дөрес.— Кыз Жуковка карап алды да өстәп куйды:— Менә шунда инде төп-төгәл белеп була: син бу кешене яратасыңмы — юкмы?

— Сез үзегезне уегызда гына булса да зур сынауга дучар итәсез ләбаса... Ә соң сезгә шулай пуля астына керергә күп тапкырлар туры килдеме?

Кыз мондый сорауга үпкәләмәде, сүзне шаянгарак борырга тырышты:

— Шундый бер хәл була язган иде дә, хәзер үтте инде,— диде.

Егет шатлыгыннан нишләргә дә белмәде. Димәк, бу кызыйның бер кеме дә юк! Аның йөрәге татлы бер сулкылдау белән тибә башлады, һәм ул, үз-үзен белештермәстән, әйтә салды:

— Ә менә мин сезнең өчен хәзер үк утка да, суга да керер идем...

— Ничек инде ул алай? Без бит әле беренче тапкыр гына күрешәбез.

Егет башын чайкады:

— Юк, дүртенче тапкыр. Теге вакытта Ключищеда, аннары пристаньда,— дип санап китте ул карлыкканрак тавыш белән.— Шуннан бирле оныта алмыйм...

— Бәлки бу шулай тоела гынадыр? Мин бик гади бер кыз...

— Юк, минем өчен сез гади түгел. Мин әле дә сезнең минем янәшәмдә икәнлегегезгә ышана алмыйм, Галя. Бу бик матур бер төш кенәдер шикелле. Ишетәсезме, Галя, кадерлем?!— Һәм ул кызны күкрәгенә кысты.

Галя аңа, бу үтәчәк дип, егетләрдә андый хәлләр була инде, дип, тагын әллә нәрсәләр дип әйтеп-әйтеп карады. Ләкин Жуков аны тыңламады, кызны аның саен катырак кочты һәм үбеп тә алды. Галя тартылып караса да, егет кочагыннан ычкына алмады.

— Алай ярыймы соң...— дип пышылдады Галя, ләкин Александр аның саен катырак итеп үпте.— Сез чыннан да күңел аздыручы,— дип пышылдады кыз дулкынланган тавыш белән.— Нишләвегез инде бу? Оят түгелме сезгә? Ярамый бит алай... Үзегез карап торышка җитди генә кеше төсле...

Ә егет һаман аны күзләреннән, иреннәреннән, яңакларыннан үпте.

Чиксез күк гөмбәзенә зур-зур ноктала булып йолдызлар сибелде. Салмак кына җил исеп куйды. Борыннарга су исе бөркелде.

— Ой,— диде Галя, кинәт аңына килеп,— караңгы төшкән ләбаса. Кайтырга да вакыт.

Алар урыннарыннан кузгалдылар.

Александр Жуков өчен шул тикле бәхет китергән көн үтеп тә китте.



## XVIII бүлек

Июльнең бу якшәмбесе лейтенант Мотыйгуллин өчен гадәти эш көне иде. Ул Чехов урамында заводның конструкторлык бюросы сызымчысы Роза Зеленская яши торган өй янында дежур торды. Ул күзәткән арада шик тудырырдай берни булмады. Хәер, бүгенге көнгә кадәр дә Зеленскаяның шикле элемтәләре сизелгәне юк иде.

Чекистларның белүенчә, элегрәк Зеленская — кәеф-сафа коруларга, күңел ачуларга ифрат та хирес бер ханым иде. Мәҗлесләрнең дә ни җиттесе генә түгел, «табан астыннан очкын чыгара торганы» кирәк иде аңа. Тик соңгы вакытларда ул мондый нәрсәләргә кинәт сүрелде, тыйнак кына көн күрә башлады: өеннән эшенә бара, эшеннән туры өенә кайта...

Контрразведчиклар алдында шундый сорау туды: әллә мондый тормыш аны чыннан да туйдырдымы, әллә ул нидер көтәме? Бәлки аңа берәрсе шулай кушкандыр? Әгәр кушучысы Варев булса, ул ханымның кәеф-сафага омтылуларына болай кинәт кенә чик куймас иде. Андый зур үзгәреш күзгә ташлана бит ул. Ә Варев — тәҗрибәле агент. Алайса, Зеленская артында кем тора соң? Әгәр беркем дә тормаса, әгәр Зеленскаяның бу эшләргә бернинди катнашы булмаса?..

Бу сорауларга җавапны ныклы күзәтү генә бирә алачак иде. Һәм менә Таһир Мотыйгуллин хәзер шуның өчен чиллә кояшы астында пешәргә тиеш. Ярый әле мәктәп бакчасында күләгәле урын тапты, койма ярыгыннан каршыдагы бинаның ишеген күзәтеп торырга мөмкин. Куе үләнлек аны чит күзләрдән саклый. Әйләнә-тирәдә умарта кортлары безелди — якындарак кына яшь натуралистларның умарта оялары күренә. Чикерткәләр сайраша. Эчпошыргыч чебеннәрне куллары белән куа-куа, ул әлеге ишектән күзен алмады.

Роза Зеленская кичке бишләрдә генә күренде. Як-ягына карамыйча, тиз-тиз атлап, базар ягына таба борылды. Аннары, трамвайга утырып, шәһәр үзәгенә кадәр килде һәм ресторанга таба юнәлде.

«Менә сиңа мә!— дип үзалдына көрсенеп куйды Мотыйгуллин.— Уразасын бик тиз бозды әле бу».— Биш минуттан, шау-шулы төркемгә кушылып, ул да ресторанга керде.

Зеленская түр почмактагы өстәл янында, ишеккә аркасы белән утыра иде. Лейтенант як-ягына каранып алды. Халык күп түгел иде әле. Кисия пәрдәләр аша залга төшкән кояш нурлары күзләрне камаш-

тыра иде. Бу яктылыкның залда утыручыларга комачау тудыруын күреп-сизенепме, әллә вакыты җиткәнгәме, метрдотель калын пәрдәләрне дә төшерде. Шунда ук бөтен зал караңгыланып китте. Тонык кына булып утлар кабынды. Баядан бирле ишетелгән музыка да бөтенләй бүтән яңгыраш алгандай булды.

Мотыйгуллинга Зеленскаяның йөзе күренми иде. Болай гына, ял итеп алырга гына килүе микән? «Бәлки бу безнең игътибарны читкә юнәлтү өчен генәдер?— дип баш ватты лейтенант.— Әгәр шифровкада телгә алынган Роза шушы булса,— завод турындагы информация ничек читкә китә соң? Бәлки аларның үзләренә күрә почта ящигы сыманрак берәр нәрсәләре бардыр? Шайтан белсен. Хәер, булуы бик ихтимал. Ләкин кайда?»

Ул, бутербродны иренеп кенә чәйни-чәйни, шуларны уйлап утырды. «Тукта әле, әгәр?..» Лейтенант капыл гына урыныннан торды, официантка түләде дә тизрәк чыгып китү ягын карады. Бүлеккә шалтыратып, Розаның кайда икәнен әйтте. Үз урынына бүтән кеше җибәрүләрен үтенде.

Мотыйгуллин трамвайга йөгерде. Егерме минуттан Чехов урамындагы таныш өй янына килеп тә җитте. Зеленская яши торган подъездга керде. Җеп кәтүге кадәр генә нәрсәне яшерердәй урынның кайда булуы ихтималын ачыклау өчен баскыч басмаларын, култыксаларны бик җентекләп тикшерә-тикшерә, ашыкмый гына өскә күтәрелде. Бу яшертен урын чит кеше һич күрмәслек, шул ук вакытта анда куелган әйберне ансат алырлык булырга тиеш бит. Роза икенче катта яшәсә дә, лейтенант, шул рәвешчә эзләнеп, бишенче катка кадәр күтәрелде, әмма шик уятырдай берни тапмады.

Менә астан ашыкмый гына атлаган аяк тавышлары ишетелде. Мотыйгуллин баскычны, бу юлы инде кире юнәлештә, тагын бер кат тикшереп чыгарга булды. Ләкин чит кеше барында, ул үтеп китмәс борын, моны эшләргә теләмәде, көтәргә карар итте. Ә түбәннән менүче кеше ашыкканга ошамый. Лейтенант аска күз ташлады. Ул — кичке почтаны өләшеп йөрүче хат ташучы иде. Шактый өлкән яшьтәге бу кеше ешеш сулый, әледән-әле туктап тын ала иде.

«Чит кеше күзенә чалынмавың хәерле»,— дип, Могыйгуллин стенага сыенды. Хат ташучы, пыш-пыш сулап, дүртенче катка кадәр менде дә кинәт кире борылды.

«Ни булды моңа?— дип уйлап алды лейтенант.— Бер катка артыграк менде түгелме? Алай дисәң, өлкән яшьтәге кешеләр этажларны саный-саный менүчән булалар». Һәм ул картны бераз күзәтеп торырга булды.

Таһир түбәнгә карады. Карт, туктамый-нитми, аска таба төшеп бара иде. Тавышсыз атларга тырышып, лейтенант та аның артыннан иярде. Өченче катта әлеге карт ишеккә кадаклап куелган ящикка хат салды һәм, артына борылып карамыйча гына, тагын төшеп китте. «Күрәсең, чыннан да бер катны артыграк менгәндер»,— дип уйлады Мотыйгуллин. Шулай да картны күзеннән ычкындырмады.

Менә карт Зеленскаяның квартиры ишеге янында туктап калды, ашыкмый гына сумкасыннан открытка чыгарды, як-ягына каранып алды, аннары сул кулы белән ян кесәсеннән юка гына металл линейка алды һәм аны ишек белән почта ящигы арасына тыкты. Аннан көрән төстәге конверт килеп чыкты. Шуннан соң почтальон, фокусчыга хас җитезлек белән, линейкасын кесәсенә яшерде, открыткасын почта ящигына ташлады һәм, конвертны сумкасына салды да, тиз-тиз атлап, баскычтан төшеп китте.

«Менә, иптәш лейтенант, сиңа табышмакның чишелеше!— дип уйлап алды кыска гына бер мәлгә чарасыз калган Мотыйгуллин.— Конверты да бит нәкъ ишек төсендә. Бер катка артыграк менүе ялгышу булмаган

моның, кеше-кара юк микән дип тикшерүе булган. Теге нәрсәсе дә шомарган, каһәр: юри ресторанга киткән. Элемтәче бу тирәдә маташкан арада «койрыкны»,— әгәр ул була-нитә калса,— читкә алып китү өчен шулай иткән. Ә картның открыткасы нигә? Шифровканы алдым, дигән бирәр сигнал түгелме?..

Хәзер үк картны куып җитәсе, көрән төстәге конвертны кулга төшереп, картның үзен дә шунда ук кулга аласы килде лейтенантның. Ләкин ул моны эшләргә ярамаганлыгын да, алай итсә шундый зур кыенлык белән кулга төшерелгән җепнең тагын өзеләчәген аңлый иде.

Хат ташучы күршедәге өйгә таба китте. Мотыйгуллин исә, карт почта тараткан арада, телефон будкасына кереп, идарәдәге дежур офицерга шалтыратты һәм хәлне аңлатып бирде.

Бер сәгатьтән кайбер нәрсәләр ачыкланды. Хат ташучы карт Шәүкәт Шугаев озак вакыт 14 нче номерлы ЖЭКта урам себерүче булып эшләгән һәм моннан бер атна элек кенә аннан киткән икән. Ул җыештырырга тиешле участокка конструктор Әхмәтов яши торган өйнең ишегалды да керә торган булган.

«Менә нәрсәдә икән хикмәт!— дип уйлап алды майор Галләмов, элемтә бүлекчәсендә яңа хат ташучының документлары белән танышып чыккач.— Ишегалды себерүче — күзгә ташлана торган кеше түгел. Шуңа күрә алар без андый кеше белән кызыксынырбыз дип башларына да китермәгәннәр. Ә бит конструктор Әхмәтовның ганләсе кайда икәнлекне нәкъ менә ул хәбәр иткән. Алай булмаса, Варев белән «Иөнтәс» аның квартирында үзләрен шулай иркен тота алмаган булырлар иде. Соңыннан, хат ташучылар җитмәүдән файдаланып, Шугаевны тиз генә монда күчергәннәр. Барысы да дөрес».

Ә тагын бер сәгатьтән телеграф аша Шугаев турында шундый запрос тапшырылды:

Оренбург. НКВД начальнигына.
1891 елда Оренбургта туган, 1902—1916 елларда Оренбург тимер юл станциясендә обходчик булып эшләгән Шәүкәт Шугаев турында мәгълүматлар бирүегезне үтенәм.

Автономияле республиканың Эчке эшләр халык комиссары З. Рәхмәтуллин.

*
* *

Заводның конструкторлык бүлегендә гадәти булмаган тынлык хөкем сөрә иде. Ял көне. Ләкин якты гына зур бер бүлмәдәге тынлык өстәл тартмаларын шак-шок ачкан, кәгазь кыштырдаган тавышлар белән бүленә. Закиров үзенең ярдәмчеләре белән сызымчы Зеленскаяның һәм конструкторлык бюросы работникларыннан берсе булган инженер Чревовның эш урыннарын тикшерәләр. Үзара сөйләшмичә генә эшлиләр.

Закиров заводка контрразведчиклар элемтәче Зеленскаяның эзенә төшкәч үк килде. Конструкторлык бюросының партбюро секретарен, бюроның начальнигын һәм махсус бүлекнең җитәкчесен дә чакырттылар.

«КБ» башлыгы Шөгеров — яшь күренә торган ир уртасы чандыр кеше бу хәлләргә берни аңламыйча карап торды. Зеленскаяның кеше тормышындагы иң коточкыч җинаятькә — шпионажга, ватанга хыянәт итүгә барган булуына һич ышанасы килми иде аның. Шөгеровның мондый кешеләр турында китапларда укыганы бар, ләкин алар бөтенләй башкача булалар, үзе белән рәттән берничә ел эшләп килгән, күрер күзгә бер дә алай куркыныч булып тоелмаган, мөлаем гына бу ханымнан бөтенләе белән аерылып торалар төсле иде аңа.

Зеленская кем белән якыннан аралаша, дигән сорауга каршы Шөгеров бу ханым урынсызга кызып китүчән, шикләнүчән, тотнаксыз, гади генә итеп әйткәндә — кеше белән тыныша алмаучан, тар холыклы бер кеше — инженер Валентин Чревов белән якын мөнәсәбәттә булуын һәм моның сәер булуын сөйләп бирде.

— Инженер Чревовка производство буенча күп кенә бик җитди заданиеләр бирелде, шуңа күрә ул күп нәрсәне белә. Информация чыганагы ягыннан карасаң, бик тә кирәкле кадр,— дип тәмамлады сүзен Шөгеров.

Закиров өстәл тартмасыннан тышына «Валентин Чревовның 1940 елгы көндәлек дәфтәре» дип язылган калын бер дәфтәр тартып чыгарды.

Көндәлекнең битләрен актарганда Закиров кашын җыерды: аның авторы, елап-сыктап, мәми авызланып, аны кемнәрнеңдер тешләргә теләүләре, шуңа күрә сабырлыкның төкәнүе, үзенең дә ырылдый башлаячагы турында яза иде.

«Уналтынчы апрель,— дип кычкырып укый башлады Закиров һәм бүлектәгеләргә күз төшереп алды.— Мин күңелемнән «караул» кычкырыр хәлдә! Ярдәм ит миңа, Яков Михайлович. Җыен чүп-чар яшәргә бирми. Монда, КБда миннән көнләшүчеләр, кабәхәт җаннар бер төркем булып оешканнар да тәмам котырганнар. Мөгаен миңа, үз командамны оештырып, кайбер кабәхәтләрнең каннарына тоз сала башларга вакыттыр? Киңәш бир миңа, Яков Михайлович, ни эшлим?»

«Унҗиденче апрель. Хатымны Яков Михайловичка җибәрдем. Анда кичә көндәлегемә язылган фикерләрне тагын да киңәйттем. Күңелем җиңеләеп калды».

Бүлмәдәгеләр, Закировка игътибар белән текәлгән хәлдә, аның көндәлектән тагын нәрсәдер укуын көтәләр иде. Закиров бер битне әйләндереп куйды, икенчесенә күз йөртеп чыкты да укый башлады:

«Егерме өченче апрель. Яков Михайловичтан хат алдым. Ул яза: «Җүләр син, Валька, ди. Башында мие булган кеше үз тирәсендә интеллектуаллар дип аталып та, чынлап карасаң акыл ягыннан чикләнгән, бернәрсәгә дә яраксыз адәм актыклары җыелганны күрә алмыймыни инде?! КБда ике ел буена утырып та, коллективтагы атмосфераны белә алмагансың! Ул кешеләр арасына килеп керү белән син, давыл башланыр алдыннан тәҗрибәле синоптик үзен ничек тотса, үзеңне шулай тотарга, көчле җил астында калмас өчен, аның кайсы яктан исәчәген алдан ук шәйләп торырга, кирәк икән — таракан кебек якындагы ярыкка кереп посарга тиеш идең. Шул ярыкта утырган килеш башта мыекларыңны гына селкетергә, анда да бөтен коллектив хоры җырлаган, дөресрәге, ул коллективта өстенлек иткән бер төркем җырлаган көйгә генә селкетергә. Әгәр син беренче атналарда ук коллективтагы климатны сиземли һәм үзеңне ничек тотарга икәнен чамалый алмасаң,— бик күп хата эшләп ташлавың бар! Соңыннан сиңа бу коллективта үз кеше булу өчен күп еллар кирәк булачак. Ә менә синең кебекләр өчен ул гына да җитмәячәк. Бу еллар эчендә сиңа әледән-әле бетле хәшәрәтләр белән чукышырга туры киләчәк. Һәркем, бусага төбенә җәелә торган паласка сөрткән төсле, сиңа аягын сөртергә тырышачак. Коллективта үзеңә кирәкле мөнәсәбәтләр урнаштыру — ул үзе бер фән. Һәм, күренүенчә, син әле бу фәндә бер нәрсә аңламыйсың. Шуны исеңдә тот — катлаулы коллективта үзеңә ориентир табу — тайгадагыга караганда кыенрак. Хатын-кызга таянырга тырыш. Үзеңнең мин-минлегеңне помой чиләгенә ташла».

Мин, мөгаен, бу кешенең киңәшен тотармын — бүтән чарам калмады. Чаңгы очын Роза Зеленскаяга таба юнәлтеп карыйм әле. Аның

ярдәме белән кайбер кешеләрнең борыннарына чиертергә мөмкин булачак. Ә кайберләрен аның нурлы күзләре эретер. Моның файдасы исә миңа да тими калмас».

Закиров Чревовның көндәлеген өстәлгә куйды һәм уйчан гына:

— Менә бу дуслыкның чишелеше. Тик мин аның бәясе генә билгеле түгел,— диде.

— Димәк, сез бу адәм актыгы Зеленскаяның илтифатын КБдагы эшләрне белүе белән яулаган, дип уйлыйсыз?

— Бик ихтимал. Көмнәндер үч алу өчен Чревовның Зеленская аркылы аңа кирәкле информацияне биреп барган булуы бик мөмкин, чөнки коллективка булган үпкәсе аны бөтенләй сукырайткан.

— Менә мерзавец!— диде Шөгеров түземен җуеп.— Кара син аны, ничек итеп безгә, бөтен коллективка пычрак ата!

— Ә без монда күпме көч түктек!— дип тегесенең сүзен җөпләп алып китте партбюро секретаре.— Тәрбияләргә маташтык, үгетләдек, санаторийларга беренче чиратта путевкалар бирдек. Ә ул шуларның барысы өчен рәхмәтен менә ничек белдергән...

Закиров заводтан шәфәкъ сүнгәч кенә китте. Биналардан һәм агачлардан төшкән күләгәләр җир өстенә тиздән эңгер иңәчәген хәбәр итәләр иде. «Нигәдер өйгә кайтасы килми,— дип уйлады Закиров.— Эля белән сөйләшәсе иде. Шалтыратыргамы, әллә туп-туры өенә барыргамы?» Илдар барырга булды. Ни булса да булыр, дип уйлады.

Дөнья шаулатып, тузанга күмелеп барган трамвай Эля яши торган өйдән ерак түгел генә туктагач, ул тагын икеләнә калды: төшәргәме, юкмы? Нәкъ шул вакыт тукталышта Элеонораның үзен күрде һәм чыгу ишегенә таба ашыкты.

Аны күргәч, кыз гаҗәпләнде, тәмам каушады.

— Нинди җилләр ташлады сине безнең якларга? — дип сорады Бабанина.— Эш белән түгелдер ич?..

— Юк ла, эш буенча түгел...— диде Илдар ашыкмый гына, аның үзе янына килгәнлеген әйтергә кыймыйча.

Кыз кинәт Илдардан сорап куйды:

— Әйт әле, син Эдуардка ничек карыйсың?

— Тренькингамы?

— Әйе, Тренькинга.

Илдар җилкәсен җыерып куйды: «Тренькинның монда ни катнашы бар? Ә-ә, димәк ул Эляга шалтыраткалап тора...» — дигән уй аның бөтен күкрәген өшетеп алгандай булды.

— Гаҗәеп бер кеше ул, шулай бит? — дип сорады Элеонора.

Илдар берни әйтмәде, тик уйсыз-фикерсез, курчак сыман башын гына изәде.

— Әйтүләренә караганда, бөтен бүлекнең эшен ул алып бара...

Илдар барын да аңлады. Кызның монда кемне көтеп торуын да. Ләкин егетнең һаман ышанасы килми иде әле.

— Хәзер алып бармый инде,— диде ул, авызын көч-хәл белән ачып.— Ул хәзер бездә эшләми.

— Ничек инде эшләми?— диде Элеонора гаҗәпләнеп. Аннары борчулы тавыш белән өстәп куйды:— Ул яраланганмы? Әллә үтерделәр дәме үзен? Син миңа шуны әйтер өчен килдеңме?

— Юк, ул исән-сау. Тренькин барын да үзе сөйләп бирер дип уйлыйм.

Еракта шалтыр-шолтыр итеп трамвай килгән тавыш ишетелде. Бабанина тиз генә шул якка карап алды да, ашыга-тотлыга сөйләп китте:

— Аңлыйсыңмы, Илдар. Мин бер кешене сөйгән идем. Бу хис әле һаман да минем йөрәгемнән китми. Барысы да онытылсын өчен вакыт

кирәк, янсә миңа гадәти булмаган бер кешенең очравы кирәк. Бу кешенең нинди булырга тиешлеген мин үзем дә тәгаен генә белмим. Һәрхәлдә ул акыллы, чибәр булырга тиештер, мөгаен. Минем көнелемдәге бушлыкны биләрлек булырга... миңа яңадан бәхет алып килерлек булырга...

Кызның соңгы сүзләре трамвай тормозының шыкырдавына күмелеп калды. Закиров аңа кызыксынып карап торды.

— Менә мин күптән түгел Эдуардны очраттым. Һәм шунда ук: «Менә ул кеше!» дип уйладым. Минем шуңа ышанасым килә. Аңлыйсыңмы син мине — ышанасым?! Син миңа үпкәләмә. Кыскасы, гафу ит.— Кыз гаепле кешедәй елмаеп куйды.— Беләсеңме, минем иптәш кызым Фәридә бик ошаткан сине...

Шул чак Илдарны кемдер тәкәллефсез генә төртеп җибәрде, аның колагына Тренькинның дорфа тавышы ишетелде:

— Синең вакытың бетте, Закиров. Әйдә, бар, үкчәңне күтәр моннан,— диде Тренькин, кыз белән Илдар арасына килеп басып.

Аннары ул Илдарга таба борылды. Аңардан аракы исе аңкый иде.

— Моннан болай безнең аяк астында буталып йөрмә, ишетәсеңме?

— Нигә инде син шулай, Эдуард?!— диде Эля.

Закировта бу мактанчыкның ипи шүрлегенә менеп төшү теләге уянды. Ләкин ул, бар ихтыярын җыеп, үзен тотып калды.

Тренькин исә шунда ук бар нәрсәне тупас шаяртуга кайтарып калдырырга ашыкты:

— Менә сиңа мә! Нинди кызу канлы хәзер кешеләр. Ысылдарга гына торалар. Кая китте сезнең түземлелегез, коллега?

— Элекке коллега!— дип кырт кисте Илдар.

Тренькин бер мәлгә аптырап калды һәм шунда ук сүзне икенчегә борырга ашыкты:

— Сине анда балаларың көтә, ә син монда җилләнеп йөрисең!— һәм ул Эляга таба борылды.

— Алар минем балаларым түгел, подшефныйлар. Хәзер алар каникулда. Ә менә синең улың сине чыннан да көтеп тора булыр.

Тренькин бер кавымга тораташ булып катты, аннары әкрен генә Закировка таба борылды да, аңа ачудан сытылган чырае белән карап торды һәм, ярым пышылдап, теш арасыннан гына:

— Хайван!— диң куйды.

— Бәхетең, без монда икәүдән икәү генә түгел.— Закиров үзен көчкә белән тыярга тырыша иде. Шулай да кайдадыр күңел түрендә: «Димәк, ул өйләнгән кеше булуын яшереп йөргән, һәм мин үзем дә теләмәстән әләкче булып чыктым. Әйдә ярар, кадалып китсен шунда. Мин бит Эляны яратам һәм аның язмышына битараф кала алмыйм»,— дигән уй йөгереп үтте.

Егетләрнең якага-яка килергә әзер торуларын күргәч, Элеонора бөтенләй каушап калды:

— Сез нәрсә?! Акылдан яздыгызмы әллә?! Әтәчләр дип белерсең!

Аннары Тренькинга таба борылып:

— Димәк, сез, Эдуард,— өйләнгән кеше? Балагыз да бар?..

— Ләкин... мин... без... инде судта аерылышу турында эш кузгаттык...— дип мыгырданды ни әйтергә дә белмәгән Тренькин.

— Ниемә кирәк иде бу алдашу?— Эля битен куллары белән каплады.— Я хода! Нинди әшәкелек!— Һәм кыз, мәрткә киткән кешедәй ак-караны күрмичә, алпан-тилпән килеп, китеп барды.

— Эля! Мин сезгә барын да аңлатып бирермен! Сез мине аңларсыз! Сез минем өчен бик кадерле кеше! Минем сезгә кадәр беркемне дә...

Кыз адымын әкренәйтте һәм ярсу белән:

— Калдырыгыз мине! Минем сезне бүтән күрәсем килми!— диде.

Күп еллар буе хыялында йөрткән изге хиснең шулай һич көтмәгәнчә чәлпәрәмә килүенә ышанырга теләмичә, Илдар Эляның артыннан карап калды. Кызның Эдуардтан гына түгел, аңардан да китүе икәнен ул яхшы аңлый иде.

## XIX бүлек

Мария Петровна Метелева шифаханәдән чыккач аның буш бүлмәсенә фатирчы булып икенче бер кеше — лейтенант Измайлов керде. Ул әле күптән түгел генә кинәттән үлеп киткән тәэминатчы Постнов яшәгән бүлмәгә урнашты. Мария Петровна ул кеше турында әйбәт фикердә калган, андый хәлләр нәкъ менә шундый яхшы кешеләр белән була да инде дип сөйләнә иде.

Хуҗабикә бүлмәсеннән бик сирәк чыга, урамда исә бөтенләй булмый диярлек, чөнки үзен һаман начар сизә иде әле. Аның эшләрен апасы башкара иде.

Соңгы вакытларда Мария Петровна йокысызлыктан интегә башлады. Төннәрен аның ялкынсынган миендә күптән булып үткән вакыйгалар яңара торган булып китте. Ә менә бүген аның башында сугышта һәлак булган улы турындагы хатирәләр тулып ташыды. Бу хатирәләр тора-бара эчке бер сыкрауга, йөрәк әрнүенә әверелде. Ул Измайловның күршедәге бүлмәдән ишек бикләрен тикшерү өчен коридорга чыгуын да, аның папирос төтененә чәчәп ютәлләвен дә, кухняда нидер хәзерләүче апасының коридорда арлы-бирле йөрүен дә ишетмәде.

Ниһаять, бар нәрсә тынды. Коридорда тынлык урнашты.

Күрше бүлмәдә сәгать төнге икене сукты. Мария Петровна күзен йомды, ләкин аны йокы алмады. Дөрес, ул өстәл лампасын сүндермәгән, шуңа күрә бүлмәдә ярым караңгылык хөкем сөрә иде. Ул һәрвакыт шулай, ут сүндермичә йокларга күнеккән. Менә, ниһаять, аның йокысы килә башлады, газаплары кимегәндәй булды. Ә бераздан ул борчулы, сизгер йокыга талды. Күпме йоклагандыр, ул үзе дә белми. Ниндидер тавыштан уянып китте. Кемдер ишек шакырга теләп тә (ул Измайлов киңәше буенча ишеген эчтән бикләгән иде) соңыннан кире уйлагандай тоелды аңа.

Менә нидер кыштырдаган тавыш ишетелде. Ул ишеккә күз төшерде һәм тәмам өнсез калды: ишек белән ишек яңагы арасында хасил булган ачыклыктан еландай боргаланып әкрен генә эчкә таба үрмәләүче ябык кына ап-ак кул күренде. Метелеваның исе китте: тукта әле, ул ачкычын йозакта калдырган иде бит, ишекне ничек ачтылар икән соң?! Бармагына бриллиант кашлы зур йөзек киертелгән кул ишек чылбырын капшап тапкач, курку, өшеткеч салкындай, аның бөтен тәнен һәм миен куырып алды. Аның кычкырырлык та, лейтенант Измайлов кушканча, стена кагарлык та хәле юк иде.

Метелева, гипноз тәэсирендәге кешедәй, әлеге кулга карап торды һәм ишеккә бөтенләй ачылып китәргә ирек бирми торган чылбырның ычкынып китүен көтте. Коточкыч бу халәттән аны йөзек кашының идәнгә төшкән кандай кызыл шәүләсе чыгарды. Аның томаланган аңын: «Соң бу үлгән фатирчы Постновның йөзеге ләбаса!— дигән уй яшендәй ярып үтте.— Кулы да нәкъ аныкы!»

Куе тынлыкны, ниһаять:

— А-а-а!!! Ярдәм итегез!!! — дигән ачыргаланып кычкыру авазы ярып үтте.

Куркуыннан акылдан язарга җитешкән, чәче-башы тузгыган хатын тәрәзәгә ташланды, аны үзенә таба тартты, ләкин бикләнгән тәрәзә

тиз генә ачылмады. Мария Петровна тәрәзәгә китереп сукты, аска чылтырап пыяла ватыклары коелды.

Стена аша ату тавышы яңгырады. Тик шунда гына Метелева Измайлов турында исенә төшерде. Ул, кабаланып, тәрәзә яныннан стенага таба килгәндә коридорда тагын ату тавышы ишетелде. Мария Петровна ишек аша үзенә атуларын төшенә алмады. Ул канга буялган куллары белән Измайлов йоклый торган бүлмә стенасына бар көченә сугарга тотынды.

Кычкыру тавышын ишетү белән Измайлов ишеккә ташланды, ләкин ишек ачылмады. Ул, бар көчен җыеп, аны үзенә таба тартты, ләкин ишек йозагы нык иде. Шуннан ул кесәсендәге «ТТ»ны чыгарып, ишек тупсасына атты. Шул чак коридорда да ата башладылар, һәм контрразведчик стенага сыенды. Ату тавышлары аша ул стенага шакуларын ишетте.

Измайлов ишекнең икенче тупсасына төбәп атты, ишек өстендәге ярыкка бармакларын тыкты да аны бар көченә яңадан үзенә таба тартты. Ишек тупсасыннан ычкынды, идәнгә шөрепләр чәчелде.

Шул чак лейтенант коридор ишегенең шапылдап ябылуын ишетте. Ул коридорга йөгереп чыкты, күз ачып йомган арада йөгереп баскыч мәйданчыгына чыкты, як-ягына каранды һәм баскычларның икесен бер итеп аска таба ташланды.

Измайлов урам караңгылыгы эченә кереп чумды. Туктады, бер мәлтын алды. Урамда салмак кына җил исә, бер рәт булып тезелеп киткән каеннарның шаулавы ишетелә иде. Төннең караңгы пәрдәсе әйләнәтирәдәге бар нәрсәне каплап тора сыман. Измайлов өйнең якындагы почмагына таба йөгерде. Ләкин анда да шул ук бушлык, шул ук тынлык хөкем сөрә иде.

Эт ияртеп килеп җиткән оператив группа күп нәрсәне ачыклады. Алар билгесез кешенең квартирга ачкыч яратып кергәнлеген, ә тышкы ишек чылбырының ничектер алдан ычкындырылган булуын белделәр. Ләкин дошман квартирда чит кеше барлыгын кайдан белгән соң дип озак баш ваттылар.

Лейтенант Зарипов бер нәрсәгә игътибар итте. «Бу квартирга килеп керү белән мин тәмәке исе сиздем,— дип уйлады ул.— Тәмәкене үзе тартмаган кеше ул исне бер тәүлек үткәч тә сизә. Ә бирედә, минемчә, тик хатын-кыз гына яши. Шуннан нәтиҗә ясавы кыен түгел».

Эт эзне шунда ук алды. Измайловның гаҗәпләнүенә каршы эт үзенең хуҗасын югарыга алып менеп китте. «Мин тинтәк, акылдан шашкан кешедәй түбәнгә йөгергән чакта, җинаятьче мыскыллы елмаю белән миңа югарыдан карап торган»,— дип уйлады ул.

Эзләр чардакка менә торган баскыч янына алып килделәр. Моннан элек кенә Измайлов бу баскычны тикшергән һәм люкның зур йозак белән бикләнгән булуына игътибар иткән иде. Ә хәзер ул ачык булып чыкты. Тузан баскан чардак идәнендә аяк киеме эзләре бар иде. Майор Стеклов чүгәләде һәм линейка белән шул эзләрнең берсен үлчәп карады һәм, үзенә-үзе ышанмыйча, сызгырып җибәрде.

— Утыз җиденче размер. Димәк ул — хатын-кыз!.. Булмас ла, бәлки ул иске эздер?— дип ул эт иясенә карады.

Тегесе катгый рәвештә баш селкеде:

— Бу яңа ис, иптәш майор. Юкса «Кобик» аны ала алмас иде.

Әлеге эз аларны чардак тәрәзәсенә алып килде. Чекистлар түбәгә чыктылар, аны кырыйлатып барып, икенче бер өй түбәсенә күчтеләр. Аннары эз буенча янгын баскычына җиттеләр, шуның буенча түбән төшкәч, эт озак иснәнеп тормыйча, яңадан эзне тапты, аларны тыкрыкка кадәр алып барды һәм чатта бер урында әйләнә башлады. Ком өстендә шул ук хатын-кыз эзләре ярылып ята иде.

— Күрәсең, машинага утырып киткән,— диде эт хуҗасы, тәгәрмәч эзләренә күрсәтеп.

Моннан соң инде төнлә Метелева янына хатын-кыз килгәнлегенә беркемнең дә шиге калмады.

— Метелеваны үтерү нигә кирәк булды икән аларга?— диде Галләмов подполковник бүлмәсенә кайткач.

— Әйдә, күрәзәлек итеп тормыйк инде, Марс Әхмәтович,— диде тегесе.— Метелева белән тагын бер кабат сөйләшсәк, күп нәрсә ачыкланыр дип уйлыйм. Шулай да, минемчә, безгә хәзер бер нәрсә тәгаен билгеле: теге хатынның шифаханәдә агулануы очраклы хәл булмаган. Кемдер, бик тырышып, үзен куркыныч астына куя-куя, шушы Метелеваны юк итәргә йөри. Ул ханым кемнедер бик нык куркыта торган берәр нәрсәне белә булса кирәк.

— Бу «нәрсә» дигәнебез аның элекке фатирчысы түгелме икән?— диде Галләмов.

— Шулай да булуы ихтимал... Жуковның Магнитогорскига баруы бу версиягә бераз ачыклык кертергә тиеш.

Иртәнге тугызларда Стеклов килде. Һәм бүлмәгә керүгә үк:

— Әллә нинди кызыклы хәлләр бар бу дөньяда,— диде, Чурбанов һәм Галләмов белән кул биреп күрешә-күрешә. Аннары урындык читенә килеп утырды, папкасыннан нидер язылган кәгазьләр чыгарды һәм дәвам итте:— Менә теге хатыннан сорау алу протоколы.

— Хәле ничек аның? Бер ярдәм кирәк түгелме үзенә? — дип сорады Чурбанов.

— Хәле ярыйсы. Кулы гына нык яраланган. Без аны аерым палатага урнаштырдык...

Майор кәгазьләрне Чурбанов каршысына салды һәм аңлатырга тотынды. Үткән төн әлеге серле кулның бармагына киертелгән йөзек Метелеваның элекке фатирчысы Постновныкы икән. Һәрхәлдә аның ул йөзекне Постновта күргәне булган. Бер көнне ул ниндидер ашыгыч йомыш белән, шакымый-нитми, Постнов бүлмәсенә керә һәм тегенең өстен алыштырып маташкан вакытына туры килә. Постнов эскәмия аркасына эленгән чалбарын ала да шуның белән тиз генә тәнен каплый. Шул чак чалбар кесәсеннән тамыр сыман кызыл сызыклар төшкән зур кашлы йөзек төшә дә идән буйлап тәгәрәп китә. Метелева шунда ук бүлмәдән чыгып китәргә ашыга. Ә бу вакыйгадан элегрәк Метелева Постновның сул кулында зур кара миң күреп калган була. Менә узган төнне шул ике нәрсәне берьюлы күргәч, үлгән кеше терелгәнме әллә дип, аның коты чыга.

— Ә ул Постновның нинди аяк киеме киюен хәтерләп калмаганмы?— диде подполковник, кәгазьләреннән аерылып.

— Юк, хәтерләми, протоколда бу турыда әйтелгән,— диде Стеклов.— Мин менә нәрсә турында уйлыйм: Кайчандыр атаман Мефодий йөрткән йөзек шул үзе түгел микән? Гурьевтагы бер дустым кандай кызыл шәүлә төшереп тора торган бриллиант кашлы зур йөзек турында һәм бу йөзектә ниндидер зур бер сер яшерелгән булуы турында сөйләгән иде.

— Андый йөзекләр сирәк очрый,— диде Галләмов.— Тикшерүче булып эшләү дәверемдә миңа кыйммәтле ташлар һәм затлы бизәнү әйберләре белән эш итәргә туры килгәләде, ләкин андый ювелир изделиене беркайчан да күргәнем булмады. Мин бу турыда белгечләр белән сөйләшеп карарга кирәк, дим.

— Әйе, мондый белешмә безгә зыян итмәс иде,— диде Чурбанов, аның сүзен җөпләп.— Менә атаман Мефодий белән Метелева күргән йөзек арасындагы элемтәгә килгәндә,— бу әле безгә ачык түгел. Шул ук вакытта мондый элемтә юк дип тә әйтә алмыйбыз,— диде ул һәм,

Галләмовка мөрәҗәгать итеп өстәде:— Ә Викентий ата турындагы задание нинди хәлдә?

— Костромадан җавап алдык. Викентий Александрович Волковский 1892—1894 елларда Кострома губернасының Галич өязендә приход башында торган, диелә. Моннан соңгы ике елда Костроманың Ипатьевский монастырендә хезмәт иткән. Ике баласы: улы һәм кызы булган. 1896 елда Изге синод карары белән Святовск шәһәренә, Идел буе монастырена настоятель итеп җибәрелгән.

— Балаларның туган вакыты һәм урыны билгелеме?

— Юк, Михаил Иванович, билгеле түгел.

— Бу гына аз. Һәрхәлдә безгә аның Костромада яшәгән булуы билгеле. Бәлки шифрларның ачкычы да шул шәһәрнең тарихы белән бәйледер? Менә әле тагын йөзек мәсьәләсе калкып чыкты...— диде Чурбанов уйланып.

Шәһәрдәге ювелирларның иң өлкәне Касиев, гадәттә бриллиант ташларга буяу яисә төсле эмаль катнаштырмыйлар, диде. Мондый асыл ташларның кысасы гадәттә алтыннан эшләнә, ә бриллиант ташлар астына төсле фон куеп калдырылмый. Андый кыйммәтле асыл таш өстәмә буяуларга мохтаҗ түгел, дип санала.

— Сез сурәтләп биргән төсле бриллиант кашлы йөзекләрне минем күргәнем юк, Марс Әхмәтович,— диде ювелир сүзенең ахырында. Дөрес, ювелирлык сәнгатенә багышланган борынгы бер китапта минем урта гасырларда католик чиркәвенең бер епископы өчен кырлы-кырлы табут формасында итеп эшләнгән бриллиант кашлы йөзекнең ташы астына тәре сурәте төшереп калдырылган булган, дип укыган идем.

Ювелир чыгып киткәч, Галләмов, Стекловка мөрәҗәгать итеп:

— Мөгаен, безгә атаман Мефодий йөзегенең хәзергә безгә билгесез юл белән Постнов кулына күчкән булуына бөтенләй үк күз йомарга ярамас.

— Әйе... Ул йөзек миңа Гурьевтан бирле тынгылык бирми инде,— диде Стеклов.— Жуковтан киләчәк хәбәрне көтик инде. Метелевага куркудан гына шулай күренгәнме, әллә юкмы икәнлеге шуннан соң аңлашылыр.

Төштән соң Жуковтан телеграмма килеп төште:

Иптәш Чурбановка.
Авырып киткән танышыбыз исән.
Тәрбиягә мохтаҗ.

Жуков

Телеграмманы укыгач ук Чурбанов шундый әмер бирде: һич кичекмәстән Постновның сүздән битен-сынын сурәтләргә һәм бу язу белән тикшерү эшенә катнашы булган барлык кешене таныштырырга. Аның сул кулында беләзек сөягеннән чак кына югарырак булган кара миңе бу портретның аерым билгеләреннән берсе иде.

Кич кырын кетмәгәндә давыл купты, тузан болытлары бөтерелә башлады, баганалардагы чыбыклар шауларга кереште. Кайдадыр еракта күк күкрәгәне ишетелде. Ачык тәрәзәләрдән кергән җил пәрдәләрне җилкән сыман кабартты. Подполковник тәрәзәләрне япты, сәгатенә күз төшереп алды. Ул. 17.30 ны күрсәтә иде. Аннары доклад өчен Закировны чакыртты.

Закиров вакытында килеп җитте, ләкин бите кызарынган, үзе сулышын көч-хәл белән ала иде.

— Я, Илдар Гарәфович, ни белән шатландырмакчы буласыз?— диде Чурбанов елмаеп.— Бар карап торган кешебез сез хәзер.

Закиров бераз уңайсызланды һәм сөйләргә тотынды. Шугаев көрән конвертны сумкасына салган мизгелдән бирле аны күздән ычкындыр-

мадык, диде ул. Ул бу хатны гадәттәге юл белән почтальон буларак үз кулы белән иясенә тапшырыр дип тә көткән идек. Дөрес, шигебез дә бар иде: информация чыганагының да, ул информацияне кабул итеп алырга тиешле кешенең дә бер үк хат ташучы хезмәт күрсәтә торган кечкенә генә микрорайонда яшәүләренә ышанасы килмәде. Әлбәттә, ул кешенең кайчандыр шул ук микрорайонда торган булуы ихтимал, әмма Зеленская агент булып эшли башлаганчы, ягъни, яз айларына тикле. Шуңа күрә язын ул районга кемнең килеп урнашкан булуын да тикшереп карадык. Эзләнүләрне икенче юл белән дә алып бардык, бу районда кемнең икенче кварталдан газета алдыра башлавы белән дә кызыксындык. Газета бит ул хат түгел — көн саен диярлек килә, аның белән бергә информацияне дә бирүе ансат. Ниһаять, Шугаевның нинди өйләргә хезмәт күрсәтүен дә ачыкларга туры килде. Кем белә, бәлки ул үз участогына кагылмаган өйләргә дә кереп йөри торгандыр? Кыскасы, безнең барлык бу юнәлешләрдәге тырышлык файдасыз булып чыкты,— диде Закиров, докладын тәмамлап.— Иллә мәгәр Шугаевның хәрәкәтләрендә бер нәрсә безне сагаерга мәҗбүр итте. Уйлап карагыз: көннең көн буена эш белән өйдән-өйгә йөреп тәмам арый торган карт кешегә тагын әллә нинди ерак араларга ялыктыргыч прогулкалар ясаунигә кирәк? Ул бит чыннан да арый һәм прогулка вакытында берничә тапкыр утырып хәл ала. Тагын шунысы бар: йөрергә ул һәрвакыт таяк алып чыга.

— Ә газета-хатларны таратканда?

— Ул чакларда кулында таягы булмый. Минемчә, таякның аңа бөтенләй кирәге юк.

Чурбанов картның мондый прогулкаларны кайда ясавы һәм кайчан чыгуы белән кызыксынды. Кул таягы турында да бик җентекләп сорашты. Хат ташучы утырып ял иткән урыннарда аерата сизгер булырга кушты.

— Бәлки ул шундый утыргычлардагы яшертен бер җиргә информациясен куеп калдыра торгандыр,— диде ул.— Аннан килеп кул таягы турында: алар да бит күп төрле була. Ата торганы, әйбер яшерер өчен җайланганы, пычак итеп кулланып була торганы...

Аннары подполковник өстәл тартмасыннан телеграмма алды һәм Закировка бирде:

— Менә танышыгыз.

Өлкән лейтенант ярым шыпыртлап укып чыкты:

«Автономияле республиканың Эчке эшләр халык комиссары иптәш З. Рәхмәтуллинга.

1881 елда Оренбургта туган Шәүкәт Шугаев 1900 елдан 1916 елга кадәр тимер юл станциясендә обходчик булып эшләгән. 1916 елның июлендә хәрәкәттәге армиягә алынган. Элекке хәрби ведомство архивының мәгълүматларына караганда, 1916 елның 11 декабрендә һәлак булган.

Оренбург шәһәренең Эчке эшләр идарәсе начальнигы А. Григорьев».

— Димәк, уналтынчы елның декабрендә үлгән Шугаевның тере шәүләсе пәйда булган?— дип куйды Закиров, телеграммадан күзен алмыйча гына.

— Нигә декабрьда? Үлгән кешенең документларыннан шактый соңрак та файдалана башлаулары ихтимал.

Закиров чигәсен кашып куйды.

— Әй-йе... Нindирәк кеше соң бу хат ташучы? Бәлки «унөченче» дигәннәре нәкъ үзедер? Мефодийга җибәрелгән телеграммада шундый номерлы агентны файдаланырга кушылган бит.

— Бәлки шулайдыр да...— диде подполковник уйчан гына.— Ләкин

безгә үлеп терелгән Постнов турында да онытырга ярамый. Ул бик актив бәндә — карт бүре төсле эшен бик оста йөртә.

— Иптәш подполковник, биредә кем агентурасы эш итә соң?

— Германиянеке булырга охшый.

— Хәзер, иптәш подполковник, күпләр, немец Ла-Маншка җиткәннән соң тәртәсен көнчыгышка, безнең илгә таба бормагае, дип шикләнәләр,— дип куйды Закиров көтмәгәндә.

— Фашизмны хәзер, туганкай, бары тик көч белән генә туктатырга мөмкин,— диде Чурбанов.— Ә Европада фашизмга каршы торырдай бердәнбер реаль көч — без.

— Димәк, мәсьәлә шунда гына — кайчан?..— диде Закиров, кашларын җыерып.

— Әйе, шунда гына... Ләкин монда, бездә ул сугыш бара инде, Илдар Гарәфович. Шуңа күрә хәзер безнең һәммәбездән максимум тырышлык сорала.— Чурбанов телеграмманы алып яңадан өстәл тартмасына салды, урыныннан торды һәм өстәп куйды.— Хәер, сезгә моны әйтеп торуның кирәге юк.

Тышта яктырып китте һәм шунда ук каты итеп күк күкрәде.

— Тагын менә нәрсә, Илдар Гарәфович.— Вак-төяк нәрсәләргә тикле барысын да минем үземә хәбәр итеп торыгыз.

## XX бүлек

**Мефодийга.**

**Операцияне ашыктырыгыз. Контрразведканың кулга эләккән җинаятьчеләр аша Үнөченченең яисә хатын-кызның эзенә төшүе ихтимал. Бәлки инде төшкәннәрдер дә. Тикшерегез.**

**Штольц.**

Бу шифровка бөтенесе өчен, шул исәптән Чурбанов өчен дә яңалык иде. Аның болай да электр чыбыгы төсле тартылган киеренке нервларына бу көнне аерата көч килде. Үзе күзгә күренми торган ниндидер Штольц мондагы хәлләрнең барын да белеп тора бит.

Чурбанов бүлмәсендә ишекле-түрле йөренде. Башында корт иледәй уйлар кайнады.

18.45 тә аңа шундый хәбәр китерделәр: «Зеленская үз квартиры ишегенә беркетелгән почта ящигы арасына конверт кыстырды».

19.07 дә: «Хат ташучы Шугаев конвертны алды. Шунда ук ящик эченә калын гына,— акча булса кирәк,— икенче бер конверт салды».

19.35 тә: «Зеленская почтаны алды».

20.10 да Закиров шалтыратты: «Зеленскаядан алган конвертны Шугаев кесәсенә салды һәм почта өләшкәндә кесәсеннән чыгармады,— диде һәм: — Димәк, бу конвертны алырга тиешле кеше ул эшләгән микрорайонда тормый. Шулай булгач, Шугаев яшерен информацияне хезмәт вазифаларын үтәгәндә түгел, эштән буш вакытларында тапшыра булса кирәк»,— дип өстәде.

21.40 та техник бүлек хезмәткәре Хәйретдинов Шугаевка кемнеңдер (әллә хатын-кыз тавышлы ир кешенең, әллә ирләрчә тавышлы хатын-кызның) телефоннан шалтыратуын хәбәр итте. Шалтыратучы кеше Шугаевның сәламәтлеге белән кызыксынган һәм иртәгә дүртенче номерлы аяк киеме мастерское янындагы «Родина» кинотеатрына унсигез сәгатьтәге сеанска барырга кушкан. Автовокзалдагы автоматтан шалтыратканнар.

Бу хәбәрне тыныч кына тыңлап торган подполковник Чурбанов кинәт телефон янына килде:

— Автовокзалның справочныемы? Әйтегезче, 21.30 белән 22 сәгать арасында Святовскига автобус китәме?

— **21.45** тә.

Чурбанов сәгатенә карап куйды: «Инде кузгалып киткән. Әллә артыннан куа барыргамы? Юк, соң инде. Ул арада агент поселокка барып җитәчәк».

**23.10** да республиканың Эчке эшләр халык комиссары генерал Рәхмәтуллин шалтыратты. Чурбанов аңа хәлне аңлатып бирде. Халык комиссары Чурбановка ике оператив работникны утыртып Святовскига кичекмәстән машина җибәрергә киңәш бирде. Ул кешеләр төне буе монастырьның үзендә дежур торсыннар, диде. Ә көндезләрен монастырьда реставрация эшләре алып баручы кешеләр арасында лейтенант Денисов эшли иде.

Икенче көнне Шугаев эшенә шалтыратты һәм авырып киткәнлеген әйтте. Сәгать икеләр тирәсендә өеннән чыкты һәм, таягына таянып, поликлиникага юнәлде. Аннан ул автовокзалга юл тотты. Бер сум ун тиенгә билет, аннары, азык-төлек кибетенә кереп ярты литр аракы һәм колбаса сатып алды.

«Билетны кемгә дип алды икән инде бу?» — дип эченнән генә үз-үзенә сорау бирде Закиров.

16.30 лар тирәсендә Шугаев Святовск поселогына бара торган автобуска кереп утырды.

«Менә сиңа кирәк булса! — дип куйды Закиров гаҗәпләнеп. — Димәк, ул үзе бармакчы була. Алай дисәң, театрда очрашуны ничек аңларга? Тукта әле... Телефон алган кеше дүртенче аяк киеме мастерскоен телгә алган иде бит. Димәк, дүртле сан очрашу урынының шифры булырга тиеш. Я ярар, күз күрер...»

Закиров, пассажирларга ияреп, автобуска таба китте.

Шугаев Святовск поселогында төшеп калды.

Хат ташучы Идел буе монастыре янындагы чирәмлектә урнашты, бутылкасын ачып, тулы стакан аракыны бер күтәрүдә эчеп бетерде, ашап алды һәм, эленке-салынкы гына атлап, монастырьга таба юнәлде. Калын стеналы крепость-монастырь янәшәсендәге торак йортларның нәкъ каршысындагы урындыкка килеп утырды. Шунда ким дигәндә бер сәгать утырганнан соң, әледән-әле як-ягына карангалап, монастырь йортына кереп китте.

Монастырьның шактый зур йортында ак таштан эшләнгән монументаль соборлар, чаң кагу манаралары калкып тора. Шундый манараның иң зурысы, монахлар яшәгән корпус каршында җиргә сеңеп бетә язган кечкенә генә бер урындык бар. Шугаев менә шунда килеп утыруны кулай тапты. Пиджагын салды, башланган шешәсен чыгарды, әле генә үзе кергән, ике якка ачыла торган Екатерининский капкага күз төшерде дә тагын салып эчте. Инде томалана башлаган карашы белән яшел башняны, архиерей корпусын айкап чыкты, реставрация-ремонт эшләре алып баручыларның вагончыгына шактый озак карап торды. Аннары шул вагончык янына килде, асылмалы йозакка игътибар белән карап алды да туктап калды. Як-ягына каранды. Кесәсеннән ниндидер төргәк чыгарды һәм аны әле сагыз исе дә бетмәгән калын такта астына яшерде. Аннары яңадан урындык янына килде, бер кавым утырып торды, бераздан елга буена төшеп китте һәм сәгать сигездә су трамвае белән Светловолжскига кайтып китте.

Архитектура памятнигы итеп саналган Идел буе монастырен ремонтлау эше 1939 елда ук башланып, алдагы көзгә тәгәлләнергә тиеш иде. Ремонт вакытында монахлар корпусының хөҗрәләрендә яшәгән кешеләрне яңа өйгә күчереп торганнар иде. Архиерей корпусында яшәгәннәр, поселокта болай да торак мәсьәләсе кыен булганлыктан, шунда яши бирделәр.

Дошман агентларының поселок һәм Идел буе монастыре тирәсендә кайнаулары сизелгәч үк контрразведчиклар архиерей корпусында яшәүче элекке патша армиясе офицерларына һәм чиновникларга ныграк игътибар итә башладылар. Нәтиҗәдә, бу кешеләрнең кайберләре чит ил разведкалары белән элемтәдә түгелме икән, дигән шик уятты. Менә шуннан соң монастырьның үзендә реставрация белән шөгыльләнүче эшчеләр составына оператив работник кертү кирәк табылды. Күпмедер шик уяткан Варевның бу тирәләрдә булу-булмавын ачыкларга кирәк иде аларга.

Ә инде Постновның «яңадан терелүе» беленгәч, ул кешенең дә поселокка яисә монастырьга килеп чыгуы бик мөмкин иде. Шуңа күрә кичәге көннән башлап монда һәр төнгә дежур торуны кирәк дип санадылар. Моның өчен уңайлы урыны да табылды: реставрация эшләре алып баручыларның инструментлар һәм кыйммәтле төзү материаллары саклый торган вагонның кирпеч зурлыгындагы гына ике тәрәзәсе ике якка карый, өстәвенә ишек ярыгыннан да күзәтү алып барырга мөмкин. Бу төнне дежур торган Мотыйгуллин белән Вильданов Шугаевның кечкенә генә төргәкне такта астына яшерүен күрделәр. Шугаев урыныннан кузгалган вакытта таягының сабы ничектер нечкәреп калган төсле тоелды Вильдановка.

— Тикмәгә түгел бу, әй! — дип пышылдады ул Мотыйгуллинга.

Мотыйгуллин җилкәсен генә селкетеп куйды.

— Бәлки аның такта астына нәрсәдер яшереп маташуы күз буяу өчен генәдер? — Вильданов һаман үзенекен тукыды. — Ә чынлап яшергән нәрсәсе бәлки урындык астындадыр?

Мотыйгуллин:

— Күрербез,— дию белән чикләнде. — Безгә аннан да, моннан да күзне алмаска кирәк.

Монастырь йортына эңгер башта теләр-теләмәс кенә иңде: кичкә таба күк йөзе кинәт аязып китте, офык артына яшеренгән кояш нурлары каурый болытларга ябышып калырга телиләр сыман иде. Ләкин тиздән алар да төпсез күк караңгылыгында эреп юкка чыктылар. Зәгыйфь кенә җемелдәп йолдызлар күренде. Төн урталары тирәсендә күк йөзенә әллә кайдан түм-түгәрәк ай тәгәрәп чыкты. Соборларның һәм манараларның төрле сурәттәге озын-озын күләгәләре белән нискәләнгән монастырь йорты тынып калды. Ара-тирә генә бу тынлыкны әле анда, әле монда җыр сузучы чикерткәләр генә бозгалый иде.

Контрразведчиклар монастырь йортын чиратлашып күзәттеләр. Ләкин урындык тирәсенә дә, такталар янына да килүче булмады.

Лейтенант Мотыйгуллин изрәп кенә киткән иде, Вильданов аның янтыгына төртте:

— Таһир, ишетәсеңме, чаң кагу манарасыннан сәер тавыш ишетелә?!

Таһир сискәнеп уянды, колак салып бер мәл тыңлап торды да:

— Берни дә юк,— дип пышылдады...

— Син уян әле башта,— диде Вильданов. — Колагыңны ярыкка куеп тыңла.

Мотыйгуллин тагын бераз тыңлап торды:

— Тимер шыкырдый димме?..

— Шуңа охшаган шул.

— Каян ишетелә соң ул? Кем шыкырдата?

Вильданов эндәшмәде. Тик бераздан гына шыпыртлап:

— Берәү пычкы белән нидер кисә бугай. Тавыш монастырьның төп чаң кагу манарасы ягыннан килә,— диде.

Бераздан бары да тынды.

Вильданов манараның тимер рәшәткә куелган ян тәрәзәсенә күз төшерде һәм гаҗәпләнүеннән тораташ булып катып калды: анда ялкын шәүләсе күренә иде.

— Син манарага кара әле,— диде Вильданов. — Яна бит. Ут каидан килгән анда. Аңа менү ишеге бикле ич!

Вильданов, капшана-капшана, ишеккә таба китте:

— Син кая?! — диде Мотыйгуллин гаҗәпләнеп.

— Ничек кая?— дип пышылдады тегесе. — Тикшерергә кирәк. Җеннәр түгел ич инде анда. Димәк, кемдер кергән...

— Чыгарга ярамый! Бәлки юри шулай эшлиләрдер: күзәтү-мазар юкмы икән дип тикшерү өчен.

Ул арада тәрәзәдә ут тоныкланды, тагын бераздан бөтенләй сүнеп калды. Оперативниклар, чаң кагу манарасына алып менүче тимер ишектә авыр йозак эленеп торуын белсәләр дә, күзләрен караңгылык эченә текәгән килеш, аннан берәрсе чыкмасмы дип көттеләр, билгесез кешенең бикле манарага күзгә күренмичә генә менә алуы турында баш ваттылар. Төн уртасында монастырьның ул корылмасында ни калган ул кешегә?

Ай, күк йөзеннән ярым әйләнеш ясады да, юкка чыкты. Тиздән яктыра башлады. Берәм-берәм эшчеләр күренде. Алар арасында лейтенант Денисов та бар иде.

Төшке аш вакытында вагон эчендә Вильданов кына калды, ә Мотыйгуллин ремонтчылар белән ашханәгә китте. Аннан ул төнге күзәтү нәтиҗәләре турында Галләмовка хәбәр итте.

— Бәлки сезгә генә шулай тоелгандыр? — дип шик белдерде майор. Елмая төшеп өстәп куйды: — Курыкканга куш күренү генә түгелме икән?..

— Сез бигрәк инде, иптәш майор! — диде Мотыйгуллин, борчуга төшеп. — Үз күзебез белән күрдек ләбаса. Ишеттек тә...

— Я, ярар. Барысы да сез әйткәнчә булган дип саныйк. Ә хәзер кайтыгыз, ял итегез: ни генә әйтсәң дә, төне буе йокламадыгыз бит.

— Иптәш майор! — диде Мотыйгуллин ялынып,— миңа бүген дә төнгә калырга рөхсәт бирүегезне сорыйм!

Ләкин майор, дежур тору график буенча бара, диде, рөхсәт итмәде. Мотыйгуллинның кәефе китүен күреп, болай коры гына холыклы булган майор ничектер йомшый төште һәм һич көтмәгәндә бөкре ат турындагы экиятне сөйләп китте.

— Әнә бит экиятләрдә дә чиратлашып торалар, иптәш лейтенант, ә сез бөтен кеше өчен берүзегез эшләмәкче... — Аннары бераз уйланып торды да өстәп куйды: — Я, ярар. Алайса әзер булып торыгыз, ял итегез, ә төнлә Жуков белән монастырьның тышкы ягында, зират тирәсендә торырсыз.

Алар янына Стеклов килде. Исәнлек-саулык сорашкач, ул аларны шушы поселокта бабалары белән яшәүче үз кызы янына чакырды. Мотыйгуллинга кереп, йоклап алырга куштылар. Стеклов тәрәзә янына килеп утырды да:

— Кайбер мәгълүматлар бар, Марс Әхмәтович,— диде. — Михаил Иванович кушуы буенча без монда Светловолжск архивларында казындык, архиерей корпусында яшәүчеләрнең кайберләре белән кызыксындык. Дүртенче катта, егерме дүртенче квартирда үткән ел гына Себердән күчеп килүче Григорин дигән бер кеше яши. Шундый бер урынлы сорау туа. Яңа гына килгән кеше ничек итеп квартир ала алган? Анда ничәмә-ничә ел чиратта торучылар да күп бит әле. Үзе Светловолжскида эшли. Эш урынын еш алыштыра, төрле шәһәрләргә йөри. Кыскасы, шикле кеше.

Аннары ул папкасыннан архиерей корпусының 1764 елгы планын чыгарды. Аның фикеренчә, бу корпуска берничә тапкыр үзгәреш кер-

телгән, ләкин алар бинаның эчке интерьерларына гына кагылган: кайбер урында бүлмәләр үзгәртелгән. Кыскасы, ул үзгәрешләргә кадәр дә, алардан соң да архиерей үзе яши торган бүлмәләр элекке хәлендә калганнар. Ә архиерейлар барысы да икенче катта яшәгәннәр. Стеклов планга бармагы белән төртеп күрсәтте:

— Архимандрит Викентийның торган урыны менә шушы. Анда хәзер — бишенче квартирда — Розова һәм Коләхмәтова дигән ханымнар тора.

Майор кәгазьләрен кырыйгарак этеп куйды:

— Без ул кешеләрне дә тикшереп карарга булдык. Розова дигәне анда егерме бишенче елдан бирле яши икән. Ә менә Коләхмәтовасы— утыз сигезенче елның азагыннан гына. Ул Мәскәүдәге ике бүлмәле квартирын коммуналкадагы менә шул ике бүлмәгә алмаштырган. Ниемә кирәк булган аңа болай эшләү? Ул үзенең Мәскәүдәге квартирын Светловолжскиның үзендә дә теләсә нинди әйбәт пулатка алмаштыра алган булыр иде.

— Ә үзе кайда туып-үскән соң ул? — дип сорады Галләмов кинәт җанлана төшеп.

— Уралда, Нижний Тагилда.

— Димәк, бу алмашуны туган җирләренә кайтырга теләве белән аңлатып булмый?

— Шулай килеп чыга. Өстәвенә, христиан динендә булмаган кешегә рус монастыре территориясенә көчеп килү нигә кирәк булган икән?

— ...Әйе,— дип куйды Галләмов уйчан гына, монастырь манараларыннан күзен алмыйча.— Ул Коләхмәтованы хәзер үк күзәтү астына алырга кирәк.

Икесе дә бер кавымга сүзсез калдылар. Һәм икесе дә, үз уйларына чумган килеш, тәрәзә аша монастырьның биек-биек корылмаларына карап тордылар.

Идел буе монастыре һәм аның янындагы Святовск поселогы елга ярының шактый калку төшенә урнашкан. Монастырьның алтынланган гөмбәзләре, кояш нурлары астында маяктай янып, бик ераклардан күренеп торгандыр. Революциягә кадәр зур дини бәйрәмнәрдә, бигрәк тә пасха вакытында бирегә күрше губерналардан кунаклар төяп пароходлар килеп туктаган. Петербургтан дин әһелләре дә килгән. Монастырь тирәләре һәм ул чакларда өяз үзеге саналган поселок урамнары бәйрәмчә киенгән халык белән тула торган булган. Монастырьның үзе белән бер үк яшьтә булган ике йөз потлы чаңының сузынкы тавышы басу-кырларга, Идел киңлекләренә таралган, урман эчләренә үтеп кергән, күпмедер вакытка дога уку һәм көлүләрне, җыр һәм сүгенүләрне күмеп киткән. Бәйрәм үтү белән кунаклар таралышкан, һәм Святовск яңадан Россия империясенең чит-чатларында бик күп булган, бер-берсенә бик охшаган, урамнары кәкре-бөкре, өйләре кыйшаеп җиргә сеңгән, пычрак, тузанлы, айну белми торган исерекләр белән тулы гадәти бер торак пунктына әверелә торган булган.

Стеклов — боларның күбесен үз күзе белән күргән кеше. Поселокка килгән саен ул еракта калган балачагын, гражданнар сугышы елларын исенә төшерә. Хәзер дә ул шул хатирәләргә чумган иде. Менә уйлары тагын бүгенге көнгә кайттылар. Ул көрсенеп куйды:

— Бу монастырь минем күңелдә каршылыклы уйлар кузгата. Бер яктан ул миңа үткәннәрнең хатирәсе буларак, ата-бабаларым тормышы белән бәйле урын буларак кадерле, ә икенче яктан йөрәккә кадалган шырпы төсле... диде ул. — Я, ярар, чәнчелеп китсен. Сөйләп тә торасы килми. Әйдәгез, кешеләрне ничегрәк урнаштыру турында уйласак яхшырак булыр. Монастырь бит ул әнә нинди зур...

Кич җитү белән барысы да үз урыннарында иделәр. Вагонда бу юлы Денисов белән Измайлов калды. Рәфкать башта анда саклана

торган буяу исенә күнегә алмый интекте, башы авыртуга зарланды. Әмма тора-бара нервларның киеренкелеге бар нәрсәне онытты́рды.

Караңгы төшеп, болытлар артыннан ай калыккач, вагонда да җиләсләнеп китте. «Менә хәзер рәхәт,— дип куйды ул. — Эсселек белән бергә буяу исе дә очты. Ис дигән нәрсә ул төннән курыкмый куркуын, шулай да монастырь төне аңа да тәэсир итми калмагандыр, күрәсең». Ул тагын нәрсә турындадыр пышылдады, ләкин Денисов аны тыңламый иде инде: аңа чаң кагу манарасы тирәсендә нәрсәнеңдер югарыда шапылдап килеп төшкәне ишетелде. Икесе дә шул якка таба карап тора башладылар. Үч иткәндәй, нәкъ шул мәлдә ай болытлар артына кереп чумды.

Менә ниндидер бөкрәйгән кара шәүлә манара яныннан үтте дә, тавыш-тынсыз гына утыргычка таба юнәлде. Измайлов пистолетын кысыбрак тотты. Денисов аның җилкәсенә орынды:

— Киттек.

Идәндәге люк аша чиратлашып вагоннан чыктылар. Ул арада беленер-беленмәс төсмерләнгән күләгә утыргыч янына ук килеп җиткән иде инде.

Денисов, иелә төшеп, монастырь стенасы буйлап чаң кагу манарасына таба атлады. Ул, манара янына әлеге төнге өрәктән алданрак килеп җитеп, аның юлын кисәргә тиеш иде. Ә Измайловның бурычы— шпионны Екатерининский капка аша чыгармау һәм архиерей корпусына таба җибәрмәү. Нәкъ шул мизгелдә ай яңадан килеп чыкты һәм монастырь корылмаларын битараф яктылыкка күмде. Карачкы утыргыч яныннан архиерей өенә таба йөгерде.

Денисов сизеп алды: аны күрделәр! Һәм ул, сакланып торуның инде кирәге калмаганлыкны аңлап, бар көченә карачкы артыннан йөгерә башлады:

— Тукта! — дип кычкырды ул. — Тукта! Атам!

Измайлов та дошманга таба ташланды. Мондый хәлдә шпионның барыр урыны калмады: бары тик уңга таба гына йөгерергә мөмкин иде, ә анда чиркәү һәм биек кенә монастырь стенасы. Башына кепка кигән, битен кара яулык белән каплаган карачкы Преображение чиркәвенә таба ташланды.

Качып баручы дошман, түзәп тормыйча гына, тавыш килгән якка атып җибәрде. Денисов сөрлегеп китте, җиргә егылды. Измайлов, йөгерүченең аягына тидерергә тырышып, караңгыда ике тапкыр пистолеттан атып җибәрде. Ләкин теге бәндә ул арада чиркәүгә йөгереп барып җитте дә ишектән кереп чумды. Контрразведчик, аңа каршыга атарлар дип уйлап, боргалана-боргалана йөгерде. Ләкин теге атмады, һәм Измайлов исән-имин чиркәү ишегенә кадәр килеп җитте. Ләкин ишекне ачып җибәрүе булды,— колак очыннан гына пуля сызгырып үтте.

Измайлов таш идәнгә егылып тезен авырттырды. Чиркәү эчендә куе караңгылык тантана итә иде. Тик чиркәүнең тимер рәшәткәле кечкенә тәрәзәләреннән эчкә үтеп кергән тоныкай нурлары гына идәндә беленер-беленмәс сары таплар булып җәелгән. Күз бер нәрсә дә аермый. Измайлов шуышып алга хәрәкәт итмәкче булган иде дә, нәкъ шул вакыт таш гөмбәзләр астында ату тавышы яңгырады. Пуля, чаткылар көлтәсе хасил итеп, стенага килеп бәрелде.

«Хәзер беркая да китә алмыйсың инде,— дип уйлап алды Измайлов идәндә яткан килеш. — Ишек берәү генә бит».

Нәкъ шул вакыт залның түреннән тегермән ташлары әйләнгәндә була торган шыгырдауга охшаш сәер бер тавыш ишетелде.

«Монысы нәрсә инде тагын? — дип исе китеп уйлады Измайлов.— Әллә соң тавыш галлюцинациясе башланамы миндә? Бәлки монда

беркемгә дә билгеле булмаган чыгу юлы бардыр?» Һәм ул тавыш ишетелгән якка таба шуышып китте. Аның башында һаман бер уй бөтерелде: «Нәрсә чыгара соң мондый авазларны?» Шул чак ул кесәсендә фонарь барын исенә төшерде. Ул аны баш өстенә күтәрде. Якты нур каршы стенадагы изге апостоллар сурәтләрен яктыртты. Һәм ул нәкъ шул мәлне, үз күзенә үзе ышанмыйча, катып калды: апостолларның берсе — иң кырыйдагысы салмак кына хәрәкәтләнә башлады!

Тагын ату тавышлары яңгырады. Лейтенант фонарен сүндерде дә урынын үзгәртер өчен, идән буйлап тәгәрәп китте. Беренче мәлдә ул боларның барысын да башына сыйдыра алмады. Хәтер түрендә монастырьда булып үткән әллә нинди серле вакыйгалар, төннәрен чаң кагу урынында ниндидер тәхетнең пәйда булуы, зираттагы өрәкләр, атаман Мефодийның бик сәер генә юкка чыгулары, бу чиркәүдә кызыл разведчикның һәлак булуы турында күптән ишетелгән нәрсәләр калыкты.

«Тузга язмаган нәрсәләр лә болар»,— дип уйлады Рәфкать, элек ишеткәннәрне кире кагудан бигрәк, үзен тынычландыру өчен.

Измайлов бар күргәннәренең серенә төшенүгә бик якын иде инде, ләкин нәкъ шул вакыт артта шапылдап ишек ябылганы ишетелде. Измайлов артына борылды һәм фонарь нурын шул якка юнәлтте. Бу аның зур хатасы иде: шул рәвешчә ул үзен дә яктыртты һәм дошманга төзәп атып җибәрергә мөмкинлек бирде.

Ату тавышы бөтен тәнне куырып алган авырту белән бергә кушылды. Аның томалана башлаган аңында гарьләнү һәм ачу катыш: «Тагын ычкындырдым бит! Тагын оттырдым! — дигән уй йөгереп үтте. Күрку юкка чыкты. — Ахмакларча! Бернинди файдасызга! Файдасызга, дисеңме? — Измайлов бөтен тәне белән талпынып куйды. — Булмый гына торсын әле! Мин ул кабәхәтне барыбер тотарга тиеш! Тиеш!» — һәм ул, бөтен көчен туплап, аягүрә басты һәм, алпан-тилпән килеп, берничә адым алга атлады. Кинәт аның күзләренә көчле яктылык китереп бәргәндәй булды. Тик яктылык нуры ни өчендер стенаның теге ягыннан, дөресрәге, сагыш өртелгән йөзле унике апостол сурәте төшерелгән стенада хасил булган тишектән төшә иде. «Димәк, апостолларның берсе яшеренү урынына керү юлын каплап тора,— дип уйлады ул, аңының һаман томалана баруын сизеп. — Атаман Мефодий менә шулай күздән югала торган булган икән!»

Измайлов Денисовның: «Ят тизрәк!» — дип кычкыруын ишетмәде, качып-посып та тормады, чөнки алай итсә, стена буена барып җитә алмаячагын сизә иде. Ә барып җитәсе бик килә иде аның. Үзенә барыбер атачакларын сизеп, ул инде тәмам зәгыйфьләнгән кулындагы пистолетын күтәрде һәм стенадагы тишеккә таба атып җибәрде. Аңа җавап итеп ату тавышы яңгырады. Һәм Измайловка нәрсә беләндер күкрәгенә китереп бәрделәр төсле тоелды. Лейтенантның башында нигәдер бик тә ачык булып: «Менә бары да бетте. Үтерделәр. Әнием нишләр икән инде?! Бу кайгыны ул ничек күтәрер? Әй, әнием, бәгърем! Гафу ит син мине, мин бит синең турыда бөтенләй онытканмын, бөтенләй уйламаганмын. Ләкин мин бүтәнчә булдыра алмый идем шул, әнием...» — дигән уй үтте.

Ул стена буена килеп җитте һәм андагы тишектән аска таба мәтәлде. Инде тәмам сүнеп баручы аңына хатын-кыз кычкырган тавыш барып җитте. «Хатын-кыз?.. Ул монда кайдан килгән тагын?.. Ә-э, бу минем әниемдер әле. Минем әни... Елама, бәгърем...»

Измайлов кайдандыр югарыдан өстенә зур сәнәк сыман тимер рәшәткә килеп төшүен һәм япьләре белән аның бөтен тәнен тишеп үтүен дә, кайдадыр еракта, җир астында озын-озак итеп чаң кагуларын да ишетмәде — ул инде җан биргән иде.

Күк йөзеннән, айны бер каплап, бер ачып, болытлар йөзә. Менә айның тонык яктылыгы аерым агачларны, куакларны, монастырь корылмаларын тоташ боҗра итеп урап алган калын таш стенаны күпмедер вакытка караңгылык эченнән тартып алгандай итте. Каравыл башнялары, экиятләрдәге алып-батырлардай, монастырь-крепостьның бу стеналарын бар куәтләренә терәтеп торалар төсле.

Монастырь диварыннан бераз читтәрәк, түбә җирдә ай яктылыгында әледән-әле кабер калкулыклары һәм тәреләр чалынып китә. Бу борынгы зиратның зурлыгына карап, үткән гасырларда монастырьда ни тикле күп алла бәндәсенең дөнья куйган булуын чамаларга мөмкин. Жуков белән Мотыйгуллин зират белән дивар арасындагы зирек куаклары эчендә утыралар иде. Төн уртасы инде күптән авышкан. Озак ятудан аяк-куллар оеп авырта. Төнге дым һәм черегән яфрак исе белән төнәтелгән салкынча һава тәнгә үтеп керә башлаган иде.

Бу уңайсызлыкларны җиңелрәк кичерер өчен Жуков Галина турында уйлана башлады. Бу кыз белән бәйле булган вакыйгаларны, вокзалда каршы алганда ул әйткән сүзләрне, аның елмаюын, үбүләрен тәсбих тарткандагыдай берәмтекләп исенә төшереп ятты...

Монастырь йортыннан тонык кына булып ату тавышы ишетелде. Алар бер-берсенә карашып алдылар һәм, алда нәрсә буласын көтеп, катып калдылар. Төнге тынлыкны ярып, яңадан ату тавышлары яңгырады. Мотыйгуллин урыныннан тора башлады:

— Бәлки безгә ярдәмгә барыргадыр?

Хәвефкә төшкән Жуков баш селкеде:

— Безнең урын монда. Як-ягыңны күзәт.

Күп тә үтмәде, тонык кына булып чаң тавышы ишетелде. Аларның бу монастырьда берәр кеше һәлак булганда һич көтмәгәндә җир астында аваз сала торган серле чаң турында Светлов сөйләгәннәрне ишеткәннәре бар иде.

— Әллә бу шул чаң микән? — дип куйды Мотыйгуллин.— Кайсысы булыр? Денисовмы, әллә Измайловмы?

Жуков монастырьда бик җитди вакыйгалар баруын яхшы аңласа да, шиген-хәвефен сиздермәде, «юктыр ла, нишләп алай булсын»,— дию белән генә чикләнде. Якын дусларыннан берсенең һәлак булуына ышанасы килми иде аның.

Алар, монастырьның биек диварларыннан күзләрен алмыйча, шылт иткән тавышка да игътибар итәргә тырыштылар. Ләкин никадәр тыңласалар да ул-бу ишетелмәде, тирә-якта тынлык иде.

Төнге сәгать икеләрдә ярыйсы ук өшетә башлады. Ай күк гөмбәзенең уң як яртысына күчкән. Болытлар арасындагы ерганакларда эре-эре йолдызлар җемелди. Һәр ике контрразведчикның күңелен билгесезлек тырный иде.

Кинәт Жуковка кабер калкулыкларының берсе селкенеп киткәндәй булды. «Әллә күземә шулай күренәме инде?!» — дип уйлады Жуков беренче мәлдә, ләкин зират ягыннан күзен алмады, күзәтүен дәвам иттерде. Кинәт кабер калкулыгы сизелер-сизелмәс кенә чайкала башлагандай булды, дөресрәге кабернең күләгәсе чайкала иде. Александр Мотыйгуллинның җилкәсенә орынды:

— Кара әле...

Әмма Мотыйгуллин юньләп күзәтә башларга да өлгермәде, ханнар-патшалар таҗын хәтерләткән гаять зур болыт айны каплап китте. Тирә-юньдәге бар нәрсә тагын караңгылык эченә күмелде. Кинәт исә башлаган җил тавышы кыштырдаган тавышларны күмде. Әмма җил шунда ук янә тынды.

— Анда нәрсәдер кыймылдый бугай,— дип пышылдады Таһир.

Һәр икесе, сагаеп, тыңлап тора башладылар. Менә, ниһаять, ай нуры җир өстен тагын яктыртты. Ниндидер карачкы нәкъ аларга турылап килде дә, карт нарат күләгәсенә яшеренеп, тынып калды.

— Нидер көтә бугай,— диде Александр шыпыртлап.

Җир өстенә яңадан караңгылык иңгәч, карачкы тагын хәрәкәткә килде. Менә төнге кыштырдаулар эчендә ишетелер-ишетелмәс аяк тавышларын аерырга мөмкин була башлады. Ниһаять, карачкы бөкрәеп атлаучы карчык рәвешен алды.

«Ярабби! — дип куйды Мотыйгуллин, кораллы кулын төшереп.— Хатын-кыз ич бу!»

Бик нык алга сөрлегеп атлаучы бөкре хатын-кыз алардан бер-ике генә адым ераклыкта үтеп китте. Аннары сулга борылды һәм монастырь дивары буйлап салынган сукмактан поселокка таба китте.

— Син монда калып тор, ә мин аның артыннан барам,— диде Александр, куаклык эченнән чыгып. — Тик кара аны, нык күзәт!

Поселокта хатын почта ящигы янында туктап торды да (Жуков аның ящикка күпме хат салуын күрми калды) шунда ук кире борылды.

Ярты сәгать үтәр-үтмәс Мотыйгуллин яңадан шул бөкре хатынны күрде. Әледән-әле артына әйләнеп карый-карый, ул Таһир яныннан ашыгып үтеп китте. Бу юлы лейтенантка ул әллә ни карт түгел кебек тоелды. «Бик сәер, нигә соң әле ул каберлеккә кире килде? — дип уйлады ул. — Ни калган аңа бу дөм караңгыда? Күзгә төртсәң күренмәслек төн бит инде хәзер».

Тиздән, җир астыннан үсеп чыккандай, аның янында Жуков пәйда булды. Ул иелә төшеп, әледән-әле чүгәләп, күзгә күренми торган җепләр белән карчыкка бәйләнгәндәй, аның артыннан иярде. Мотыйгуллин сораулы караш белән Жуковка текәлде: «Ә миңа нишләргә?» Жуков: «Урыныңда кал», дигәнне аңлатып, кул гына селтәде. Карчык киткән сукмагыннан кире кайтыр, дип исәпләп, Жуков аңардан бераз арттарак, яннан атларга булды. Каберлек уртасына җиткәч, карчык як-ягына каранды, җиргә чүгәләде һәм кабер калкулыгы артына яшеренде. Александр ул күздән югалган урынга якынрак килде. Жуковка каберлектәге тереләрнең берсе хәрәкәтләнә, дөресрәге, үз күчәре тирәсендә әйләнгән сыман тоелды. Карчык күздән югалган урыннан бераз гына сулдарак, кабер калкулыгында иде ул тәре. «Инде монысы нәрсә тагын?» — дип баш ватты контрразведчик, урыныннан торып. Әкрен атлап шул кабер янына барды. Әмма, аның гаҗәпләнүенә каршы, анда беркем дә юк иде. «Кая олакты соң бу?» — дип уйлады Жуков. Ул әлеге серле тәре янына килде. Кабернең өстенә «Бирегә алла колы Онуфрий күмелгән» дип язу төшерелгән мәрмәр таш куелган иде. Жуков як-ягына каранды. Беркем дә юк. Кире кайтып, Мотыйгуллинны чакырып килде, һәм алар икәүләп карчык юкка чыккан урынны җентекләбрәк тикшерергә керештеләр. Тегесенә охшаган, шундый ук мәрмәр таш куелган берничә каберне әйләнеп чыктылар. Жуков тагын таныш язулы кабер янына килде, аягы белән ташка басты да тәрене бормакчы булып карады. Тәре хәрәкәткә килде. Аны үз күчәре тирәсендә бераз борган иде,— егыла язып калды: кабер өстендәге плитаның бер очы аска иңә башлады, ә икенче очы өскә күтәрелде. Борынга күгәрек исе бәрелде.

Мотыйгуллин гаҗәпләнүеннән сызгырып куйды.

— Нинди кыямәт көне булды бу? Әллә яшертен төрбәме?

— Хәзер күрербез, — диде Жуков һәм кесәсеннән фонарь чыгарды.

Ул фонаре белән кабер эчендә хасил булган кара бушлыкны яктыртты. Аста кое кебек тирән, стеналары калын ташлар белән тышланган бер чокыр иде. Чокыр авызыннан ук аска таба таш баскыч алып төшә. Жуков шуннан атлап төште дә стеналарны тикшерергә тотынды. Ләкин бу сәер чокырдан тагын кая да булса чыгып булуын күрсәткән билгеләр күренмәде.

Жуков чокырда маташкан арада Мотыйгуллин тирә-якны күзәтүен дәвам итте. Кабер эченнән, таш плита астыннан шомлы тоныкъ яктылык төшкәндәй булды. Әгәр шундый куркыныч хәлне моннан унбиш еллар элек, малай чакта күрсәң, котың алынудан үләр идең, дип уйлап алды Мотыйгуллин.

Шактый вакыт үткәч кенә Жуков чокырдан башын суздь.

— Я, нәрсә? — диде Мотыйгуллин, аның янына килеп. — Таптыңмы?

— Таптым ди, тот капчыгыңны. Әйдә төш әле бирегә!

Мотыйгуллин чокырга төште һәм таш плита белән керү юлын каплады. Александр иелде һәм стена янында гына идәннән зур йомры таш алды. Хасил булган тишеккә терсәк тиңентен кулын тыкты дә бик эшермәсе ролен үти торган металл таяк тартып чыгарды, ә икенче кулы белән стенага басты, һәм аның бер кисәге салмак кына артка чигенә башлады. Нәтиҗәдә сыра мичкәсе зурлыгында ишек сыман бер нәрсә хасил булды. Жуков электр фонареның утын шул якка юнәлтте дә, иелә төшеп, ишектән кереп китте.

— Саграк була күр,— дип пышылдады Таһир. — Ашыкма! Минем кергәнне көт.

Коралларын әзер килеш тоткан хәлдә алар кеше биеклегендәге тар гына коридор буйлап киттеләр. Бу коридор аларны таш түшәмле шактый зур бүлмәгә алып чыкты. Анда, кирпечтән эшләнгән тәбәнәк кенә калкулыкта, такталары инде каралып беткән өч табут тора иде. Тузанлы идәндә хатын-кыз аяк киеме эзләре ярылып ята. Үлчәп карадылар: нәкъ утыз җиденче размерга туры килә.

— Ә бит Метелева яши торган өйнең түбәсендә дә шундый эзләр табылган иде,— диде Мотыйгуллин, табутның капкачын ача-ача. Ә ачкач, кычкырып ук җибәрде: — Оһо, кара әле бирегә!

Табут эчендә кеше сөякләре арасында рация белән антенна бар иде.

Александр аларны тартып чыгарды да:

— Әйбәт табыш,— дип куйды. — Тик менә карчыкны гына ычкындырдык.

— Килә әле ул бирегә. Кая китсен килмичә? Менә шунда без аны эләктерәбез.

— Шулаен шулай. Тик менә ул биредән ничек кача алды икән соң? — дип үзалдына сөйләнде Александр, бинаның стеналарын тикшерүне дәвам иттереп. — Монда, туган, җир асты юлының дәвамын табар өчен тәүлек буе эзләнергә кирәк.

— Ә син андый юлның булуына ышанасыңмы?

— Сине чакырырга барган арада гына моннан чыгып ычкынырга өлгермәгәндер бит инде ул карчык?!

— Ә син менә мондый нәрсәгә игътибар итмәдеңме, иптәш өлкән лейтенант,— диде Мотыйгуллин, шаярта төшеп: — Рация бит монда яшерелгән. Әгәр бу тирәдә тагын яшертен урын янсә җир асты юлы булса, ул аны шунда качырмас идемени?

— Алай да булуы мөмкин... Ләкин аның бу төрбәне дә чит кеше таба алмаслык дип уйлаган булуы да ихтимал бит... Кыскасы, күз күрер...

Төнге 1.35 тә шундый шифровка кулга төшерелде:

Штольцка.
«Сәүдәгәр» күзәтү астында. Аның эзенә Роза аркылы төшкәннәрдер дип уйлыйм.
Күрсәтмәләр көтәм.

Мефодий.

2.10 да подполковник Чурбановка телефоннан монастырьда булган хәлләрне хәбәр иттеләр.

4.00 дә подполковник Чурбанов үзе Святовский поселогына килде һәм төнлә булган вакыйгалар белән танышты. Шунда ук ул Преображение чиркәвенә китте. Бу вакытка Измайловның үле гәүдәсен чокырдан чыгарганнар иде инде. Подполковник Чурбанов өстенә шинель ябылган мәет янына килеп чүгәләде, аның инде суынган кулын учына алды да аңа озаклап карап торды. Бүтәннәр кайгылы кыяфәт белән аның артында басып тордылар.

— Син безнең барыбызны да гафу ит, кадерле дустыбыз, Рәфкать, саклый алмадык үзеңне... — диде Чурбанов әчке әрнү белән. — Без сине һәрвакыт истә тотарга ант итәбез...

...Санитар машинасы һәлак булган чекистны алып киткәч, Галләмов кайгы катыш:

— Менә бит ничек тә була! — диде.— Дөньяда ике аерылгысыз дус — Севчук белән Измайлов яшиләр иде, һәм икесе дә бер елны һәлак булдылар. Тыныч-имин елны һәлак булдылар. Акылга сыймаслык хәл!..

Аягы яраланган Денисовны вакытлыча поселок шифаханәсенә салып тордылар. Китәр алдыннан ул подполковникка Измайлов чиркәү эчендәге стена буена килеп житәрәк анда хатын-кыз тавышы ишетелүен әйтте. Ләкин шуннан соң яшертен урыннан беркем дә чыкмады, шуңа күрә хәзер шпионның кайда икәнен белмим, диде.

Иртәнге сәгать бишләр тирәсендә Чурбанов дежурдан буш булган чекистларның барысын да поселок милиция бүлекчәсенә җыйды. Беренче чиратта төрбәдә засада кую турында күрсәтмә бирде. Жуков белән Мотыйгуллинны бүтәннәр алмаштырды, һәм хәзер алар биредә иделәр. Жуковка теге сәер карчык төнлә салган хатны почта ящигыннан алу йөкләтелде (моның өчен прокурордан рөхсәт алынган иде инде).

Тиешле күрсәтмәләр бирелеп беткәч, Чурбанов:

— Безнең карамакта ике сәгать вакыт,— диде. — Сәгать җидедә халык эшкә җыела башлый. Кайберләре иртәрәк тә килә. Ә безгә монастырьдан беркемне дә чыгармаска кирәк. Мин ышанам: Измайловны үтергән шпион шунда булырга тиеш.

5.25 тә Светловолжскидан шифрлы телеграмманың эчтәлеген китерделәр. Чурбанов аны кычкырып укыды:

«Мефодийга
Йөзекне файдаланыгыз.

Штольц

Бүлмәдә тынлык урнашты. Һәркем «йөзекне файдаланыгыз» дигән сүзләрнең мәгънәсенә төшенергә тырышты. «Йөзек» дигән сүз, мөгаен, Шубаев белән резидент арасында бер буынны тәшкил иткән агентның яисә бөтен агентура челтәренең эшен ашыгыч туктатуны күздә тоткан шартлы бер операция булырга тиеш, дигән гомуми фикергә килделәр. Ничек кенә булмасын, дошманны уздырыр өчен ашыгырга кирәк иде.

Чурбанов сәгатенә карады:

— Хәзер 5.50., иптәшләр. Без Преображение чиркәвеннән башлана торган яшертен юл аша чит ил агенты өстенә барып чыгарга тиеш,— диде ул һәм, Галләмовка мөрәҗәгать итеп өстәде: — Марс Әхмәтович, кешеләр алыгыз да эшкә керешегез.

Чиркәүдә калган чекистлар табылган яшерен җирнең кирпеч стенасын бик җентекләп тикшереп чыктылар. Ләкин Галләмов кул астындагы кешеләр килеп җиткәндә җир астына керү юлын һаман таба алмаганнар иде әле.

Эшне унике апостолдан берсенең сурәте төшерелгән яшерен ишекнең хәрәкәт итү механизмын өйрәнүдән башладылар. Апостол әйләнә башласын һәм шул рәвешчә стенада яшерен урынга төшә торган ярык хасил булсын өчен, ул ишектән ике метр ераклыктагы кирпечләрнең берсен тартып чыгарырга, шул бушлыкка кулны тыгарга һәм этәргечкә басарга кирәк иде. Апостол сурәте төшерелгән әлеге ишек шул этәргечнең басымы астында, тегермән ташлары әйләнгәндәге төсле тавыш чыгарып, салмак кына хәрәкәтләнә башлый. Чит кеше яшерен ишектән килеп керү белән андагы тозак-басмага басмый калмый. Кеше авырлыгы астында басма хәрәкәткә килеп, махсус җайланманы эшләтә һәм очлары сөнгедәй үткен авыр тимер рәшәткәне ишек өстендә тотып тора торган сумалаланган бауны әлмәгеннән ычкындыра. Рәшәткә аска таба төшеп китә һәм басмадагы кешенең тәнен үтәли тишеп чыга. Шулай итеп, бу яшерен юлның серен ачкан кеше үзенең тормышы белән саубуллашырга тиеш була.

Контрразведчиклар шул ук рәшәткәгә бәйләнгән икенче бер бауның чиркәү идәне астына төшерелгәнлеген һәм андагы унбиш потлы зур кыңгырауга беркетелгән булуын да белделәр. Рәшәткә төшеп киткән вакытта кешенең һәлак булуын хәбәр итә торган коточкыч тонык авазларны әнә шул кыңгырау чыгара икән.

Боларның барысы да тикшереп чыкканнан соң майор Стеклов:

— Бу кыңгырау монастырь башлыкларына кемнеңдер биредәге серләрне ачарга маташуы турында хәбәр сала торган булган,— диде.

Әгәр берәрсе мондый үлемнән очраклы рәвештә котыла алса һәм яшерен урынга исән-имин төшеп җитә алса да барыбер һәлак булачак: ишеге-тәрәзәсе булмаган таш капчык эчендә мәңгегә бикләнеп калачак икән. Һәм чекистлар берничә сәгать буе кысан куыштан чыгу юлын — дошман агенты файдаланган юлны эзләп азапландылар.

Менә Галләмов стенадан чыгып торган чуен шәмдәлләргә игътибар итте. Аларда тузаннан каралып беткән шәм төпчекләре сакланып калган иде. Майор шәмдәлләрнең һәркайсын бик җентекләп карап чыкты һәм берсендә тузанның бөтенләй диярлек булмавына игътибар итте.

— Бу нәмәрсәкәйгә кем дә булса кагылдымы? — дип сорады ул, шәмдәлгә күрсәтеп. Чокырдагыларның берсе дә аңа тотынмаган иде. Галләмов төрле сырлар төшереп эшләнгән бу зур шәмдәлне тотып карады, аннары үзенә таба тартты. Кул сәгатенең телләрен күчерергә кирәк булганда тартып чыгарыла торган түгәрәк бөтергечтәй, шәмдәлнең беркадәр өлеше стена эченнән чыкты. Майор бер кавым уйланып торды да шәмдәлне борырга тотынды.

— Карагыз әле, кара! — дип гаҗәпләнеп кычкырып җибәрде Закиров. — Стена хәрәкәтләнә башлады!

Чыннан да стенаның бер өлеше артка таба шуыша иде. Барысы да майор янына ташландылар. Идән белән стена арасында ярык хасил булды. Ул кеше сыярлык булып ачылгач, якынрак килеп, фонарь белән яктыртып карадылар.

— Бик тә хикмәтле эшләнгән бу,— диде Стеклов. — Күгәнгә утыртылган кирпеч ишек.

Закиров нелде һәм әлеге яшерен ишектән аска төшеп китәргә әзерләнде.

— Тукта! — диде Стеклов, аны кулыннан тотып. — Саграк булырга кирәк, башта тикшерик, юкса бәлки безне монда да үлем каравыллап тора торгандыр. — Ул фонарен алды да монастырь идәне астына төшә торган ишек янына килде. — Болай да инде бу монастырьның сере күпме кеше гомерен корбан итте: Мефодий бандасына каршы көрәштә дә, бүген дә. Ә инде үткән гасырлардагы корбаннар турында әйтеп тә торасы юк. Шактый кыйммәткә төшкән сер бу.

Бу монастырьның тарихын яхшы белүче кеше булганга, барысы да Стекловны зур игътибар белән тыңладылар.

— Эх, Измайлов кызганыч! — диде ул авыр көрсенеп. — Аның урынында мин — карт кеше булсам, әйбәтрәк булган булыр иде. Мин бит инде шушы монастырьның серенә ахырынача төшенү хакына гомеремне бирергә әзер идем. Ә эш менә ничек килеп чыкты.

Майор шактый ук тирәнгә төшеп китә торган таш баскычны җентекләп тикшереп чыкты, аннары саклык белән беренче басмасына, икенчесенә басты. Бер мәл туктап торды, як-ягына каранды.

Тирә-якта боз сөңгеләренә охшаган пәрәвез җепләре асылынып тора, муртайган ис килә. Баскыч басмаларында — төссез келәм булып җәелгән калын тузан катламы. Һәм кеше аяк эзләре ярылып ята иде.

Галләмов үз кешеләренең берсенә, Чурбанов янына барып, булган хәлләрне сөйләп бирергә кушты.

Стеклов баскычтан аска таба төшә башлады. Аның артыннан Закиров, Галләмов һәм Герасимов иярделәр. Төшеп җиткәч, аста туктап калдылар. Закиров өскә карады:

— Оһа! Менә бу баскыч дисәң дә баскыч! Утыз метрлар булыр!

— Шуннан ким түгел,— дип мыгырданды Стеклов һәм фонареның нурын коридор буйлап юнәлтте. Җир асты юлы зур-зур йомры ташлар белән түшәлгән иде. Коридорның биеклеге башны имичә иркенләп атларлык. Борылышка җиттеләр. Майор туктап калды, чүгәләде һәм аяк астында нәрсәнедер бик җентекләп тикшерә башлады. Закиров фонарь нурын коридорның аргы очына таба юнәлтте һәм катып калды: анда кара мантия һәм эшләпә кигән бер кеше басып тора иде. Закиров кесәсеннән пистолетын чыгарды һәм, теге кеше сыныннан күзен алмыйча, алга атлады. Ләкин шунда ук аның аяк астында җир упкандай булды. Ул хасил булган упкынга очып төшеп барышлый ниндидер могҗиза белән ярым борылыш ясады һәм, бар көчен җыеп, таш идән почмагына тотынып кала алды. Аста фонарь төшеп ватылган тавыш ишетелде.

Герасимов белән Галләмов шунда ук аңа ярдәмгә ташландылар һәм кулыннан тотып алырга өлгерделәр. Ул арада Стеклов та килеп житте. Өчәүләп Закировны чокырдан тартып чыгардылар. Идәннән аның пистолетын алдылар.

— Ниемә дип шул тикле ашыгасың?! — диде Стеклов ачусыз гына. Чокырны фонаре белән яктыртып карады да өстәп куйды: — Әнә күрәсеңме, сине нәрсә көтә иде анда?

Закиров аска күз ташлады һәм гаҗәпләнүеннән өнсез калды, маңгаена салкын тир бәреп чыкты. Биш-алты метр тирәнлектәге чокырның төбендә тимер сөңгеләр калкып тора, иң аста кеше склеты ята иде.

— Менә, кабәхәтләр! — диде Герасимов түзмичә. — Монда да тозак корып куйганнар!

Ул арада чокырның капкачы яңадан үз урынына кайтып утырды. Ул идәннән бер нәрсә белән дә аерылып тормый: чуерташ һәм зур-

зур яссы ташлар белән түшәлгән, сумала сеңдерелгән калын такталардан эшләнгән иде.

— Күрәсезме,— диде Герасимов,— ташлар тактадан купмыйлар?

— Такталарны эшкәрткән вакытта таш кайнар чәер катламына салынган, шуңа купмый,— дип аңлатты Стеклов.

— Шәп уйланылган! — диде Галләмов. — Ә җир астына очраклы рәвештә эләккән кешенең игътибарын тозактан читкә юнәлтү өчен коридор азагына мантия һәм эшләпә киертеп муляж куйганнар.

Стеклов тозакны бик җентекләп өйрәнде, аннары чокырның капкачын күтәрә төште, стенага яшерелгән юан таш борысны тартып чыгарды да капкачны шуның өстенә төшерде.

— Менә хәзер аның өстенә курыкмыйча басарга мөмкин,— диде ул. — Ләкин бу әле алда шундыйрак нәрсәләр булмас дигән сүз түгел. Шуңа күрә капшанып барырга кирәк.

Муляж янына мажарасыз гына барып җиттеләр.

— Бу карачкы модадан артта калган,— диде Закиров шаяртмакчы булып. — Тәэсир көче әллә ни зур түгел. Аны шайтан итеп янсә жандарм итеп киендерергә кирәк иде. — Куркуның беренче шаукымы инде үткән булса да Закиров үлемгә ни тикле якын торган булуын бөтен тәне белән сизә иде. Шаян сүз әйтүе шушы халәтеннән котылырга теләвеннән иде.

Җир асты юлы бер тупикка алып килде. Чекистлар яшерен ишекне эзләргә тотындылар һәм тиздән аны шырпы кабызып таптылар. Яшерен ишекнең сере ачылгач, Стеклов стенада хасил булган бушлыкка кереп китте, һәм аның күз алдында шактый озын бормалы баскыч пәйда булды. Шул баскыч буенча әкрен генә югарыга күтәрелделәр. Стеклов авыр сулый иде.

— Менә могҗиза. Хәзер кая килеп чыктык икән инде? Әллә ходай тәгаләнең мунчасынамы? — Баскыч түшәмгә барып төртелде. Люкны ачтылар да стеналары кирпечтән салынган ишексез-тәрәзәсез кечерәк кенә бер бүлмәгә килеп чыктылар. Бүлмәнең бер почмагында табут тора. Аның янында сумала тутырылган чаң. Шунда ук очларына сумалаланган чүбек уралган озын таяклар аунап ята.

— Карале, монда факел яндырганнар! — дип кычкырып җибәрде Закиров. — Гаҗәп. Нигә кирәк булды икән бу аларга?

— Менә сиңа мә,— дип гаҗәпләнде Герасимов үз чиратында.— Монда тагын ниндидер чыгырлар.

Стеклов аның янына килде, күгәреп каралган тимер тоткычны шыгырдатып әйләндерергә тотынды. Шул вакыт бүлмәнең түшәме икегә аерыла башлады. Борынга саф һава килеп бәрелде. Түшәмдә дүрткел бушлык хасил булды. Тиздән чекистлар баш өстендә гаять зур гөмбәне хәтерләткән җиз чаң күрделәр.

— Менә могҗиза! — дип кычкырып ук җибәрде гадәттә сабыр Стеклов. — Соң бу монастырьның зур чаңы лабаса. Менә бит без кая килеп чыктык!

Герасимов югарыга күтәрелмәкче иде дә, Галләмов аны тотып калды.

— Архиерей өеннән күреп алулары бар. Үзебезнең кайда икәнне кирәгеннән иртә сиздермик торыйк.

Закиров Стекловның шушы монастырьда пономарь булып торган бабасы турында күптән сөйләгәннәрен исенә төшерде.

— Иптәш майор, димәк бабагыз чаң кагу урынында күргәннәрен дөрес сөйләгән?

— Әйе, шулай килеп чыга. Ләкин ул чакта мин үзем ишеткән риваятьләрнең барысын да сөйләп бетермәгән идем. Хәлбуки, шулардан берсе менә нәрсә ди: гүя үткән гасырларда шушы чаң кагу урынында төннәрен, әллә ниткән нурлар белән яктыртыла торган серле табут

күренә торган булган. Ерактан караганда бу табут һавада асылынып тора төсле тоела икән. Тагын шунысы да бар: әлеге табут, зур кайгы килүен хәбәр иткән кебек, Святовск поселогында яшәүчеләрдән берәрсенең үлеме алдыннан гына пәйда була икән. Ә поселокта ул чакта чиркәү әһелләре белән элемтәдә булган кара җанлы бернича кеше яшәгән, һәм алар монастырь түрәләренең күңеленә хуш килмәгән кешеләрне үтерә торган булганнар. Менә шундый шартларда күктә йөзеп баручы табутның күренүе поселок халкының йөрәгендә нинди курку уятканын күз алдына китерү кыен түгел. Өстәвенә тагын табутның пәйда булуына халыкның игътибарын җәлеп итәр өчен нәкъ төн уртасында чаң тавышы яңгыраган.

Майор бик юка такталардан каккалап ясалган җиңел табутның астын өскә әйләндерде, һәм барысы да табут төбендә кеше йодрыгы зурлыгындагы бер тишеккә игътибар иттеләр. Аннары Стеклов шунда якында гына ятучы озын таякны алып, әлеге тишеккә тыкты да табутны бик ансат кына югары күтәрде.

— Чаң кага торган җирдә бу ящик менә ничек пәйда булган. Ә аны астан, менә бу тишектән факеллар белән яктыртып торганнар. Шулай итеп, коточкыч тамашада нибары ике кеше катнашкан.

— Ә билгесез кеше чаң кагу манарасының эченә ничек керә алды икән соң? Кичә төнлә дә бит аның тәрәзәләрендә ут күргәннәр.

Стеклов бар нәрсәне үз урынына куйды, чалбарындагы тузанны какты да кыю адымнар белән люкка таба китте.

— Бу мәсьәләне чишү кыен булмас дип уйлыйм. Минемчә, ул бинага баскычтан башлана торган яшерен юл илтергә тиеш.

Ул чыннан да хаклы булып чыкты: баскыч килеп терәлгән стенаның нәкъ почмагында җентекләп карамаганда күреп тә булмый торган бәләкәй генә ишек бар иде. Шул баскыч буенча чаң кагу манарасының бинасында, ә аннан шактый киң икенче бер кирпеч баскыч буйлап аска төшкәч, алар теге билгесез кешенең төнге эшен — дугасы урталай киселгән йозакны күрделәр.

Серле җир асты юлын табудан башлап шушы урынга килеп җитүгә кадәр күп сәгатьләр үткәндер кебек тоелган иде Закировка. Әмма сәгатенә күз төшерү белән шаккатты: бу сәяхәт нибары ярты сәгать дәвам иткән иде.

— Әллә инде шпион Преображение чиркәвеннән яңадан бирегә кайтып, шушыннан качарга да өлгергәнме? — дип куйды Закиров.

Майор Стеклов аның бу фикере белән килешмәде:

— Монастырь йорты һәрвакыт күзәтү астында булды. Бу бер. Ә икенчедән, әле генә без үткән җир асты юлы биредәге яшерен юлларның берләнбере булырга тиеш түгел. Юкса безнең төнге качкыныбыз кая олага алыр иде? Безнең егетләр тапкан төрбә дә икенче юлның булырга тиешлеген раслый. Чөнки ул төрбә һичшиксез җир асты юлы белән тоташкан булырга тиеш. Теге карчык нәкъ шунда пәйда булган һәм нәкъ шунда юкка да чыккан бит.

Галләмов майор Стекловның бу фикеренә кушылды һәм күпләр өчен һич көтелмәгән нәтиҗә ясады:

— Зиратта күренгән карчык һәм төнге качкын — бер үк кеше. Үзегез уйлап карагыз: Преображение чиркәвендәге атыш вакытында хатын-кыз тавышы ишетелә. Бер сәгать чамасы үткәч, төнге икеләрдә аны ук карчык кыяфәтендә каберлектә күрәләр. Ул элемтәчесенең күзәтү астында булуын кемгәдер почта аша хәбәр итү өчен поселокка барып килә.

...Подполковник Чурбанов Галләмовның бу фикерләренә шунда ук кушылды һәм аңарга карандаш белән нидер язылган дәфтәр бите тоттырды. Кәгазьгә тиз-тиз күз йөртеп чыкканнан соң майор:

— Михаил Иванович, без икебез дә бер үк вакытта, бер үк нәтиҗәгә килгәнбез икән, — дип канәгатьләнү белдерде.

Чурбанов елмайды:

— Кешеләр бер төсле уйласалар, эшләве дә җиңелрәк шул.

Иртәнге сәгать җиделәр тирәсендә Метелева да килеп житте. Чурбанов, дулкынлануын яшерергә тырышып, бу ханымга берничә фоторәсем тоттырды. Алар арасында кирпеч заводы эшчесе Коләхмәтова фотосы да бар иде.

— Мария Петровна, бик зур үтенеч сезгә: менә шушы кешеләрне бик җентекләп күздән кичерегез әле. Араларында таныш кеше табылмасмы?..

Чират Коләхмәтова карточкасына җиткәч, Метелева ничектер үзгәреп киткәндәй булды:

— Менә бу хатынны кайдадыр күргәнем бар төсле. Ләкин кайда икәнен һич хәтерли алмыйм.

Чурбановның бөтен барлыгын шатлык биләп алды. Димәк, ул уйлаган нәрсә раслана. Метелеваның фоторәсемдәге ханымның исемен һәм аны кайда күргән булуын әйтә алмавы аны хәзергә борчымый иде.

— Петр Прохорович,— диде ул, Стекловка мөрәҗәгать итеп,— Коләхмәтованы хәзер үк кулга алыгыз. Үзегез белән берничә кеше ияртегез, ә без тиздән килеп җитәрбез.

Бухгалтер Коләхмәтованың эш көне иртәнге сәгать сигездә башлана, гадәттә ул өеннән ярты сәгатькә алданрак чыга иде. Аны монастырь капка төбендә көтеп тордылар. Ләкин ул күренмәде. Сәгать сигез туларак Стеклов һәм аның ярдәмчеләре Коләхмәтованың квартирына киттеләр.

Өйне чолгап алып, икенче катка күтәрелделәр һәм бишенче квартир ишеге янында тукталдылар.

— Күршесенә шалтыратыгыз. Ике тапкыр... — дип пышылдады Стеклов.

Закиров, ишектән күзен алмыйча: «Менә хәзер «Иөнтәс»нең ярдәме ярап куяр иде безгә,— дип уйлап алды. — Хәер, теге вакытта Древцовның ишеген ул да ача алмаган бит. Ләкин монда йозак артык катлаулы түгел бугай».

Закиров звонок төймәсенә басарга дип кулын гына сузган иде, нәкъ шул мәлне ишекне кемдер эчтән ача башлады. Стеклов, «таралыгыз!» дигәнне аңлатып, кулын селтәде һәм ишек катында бер үзе генә калды. Бусага төбендә кулына чиләк тоткан карчык күренде.

— Мин янгынга каршы көрәшү җәмгыятеннән,— диде майор. — Безгә мич торбаларын һәм электр челтәрен тикшерергә куштылар.

Карчык берсүзсез читкәрәк тайпылды.

— Ә күршегез өйдәме соң?

— Өйдә бугай. Авырып киттем, дигән иде.

Стеклов папкасыннан нидер чыгарды да карчыкка сузды:

— Менә бу чакыру кәгазен күршегезгә бирегез. Ә мин ул арада мич торбасын карый торам.

Карчык чиләген идәнгә куйды да, лыштыр-лыштыр атлап, күрше бүлмә ишегенә таба китте.

Стеклов кулы белән ишарә ясады: «Барыгыз да бирегә!»

Розова ишекне шакыды:

— Наилә Габдулловна! Менә янгынчы ниндидер кәгазь калдырды. Укысаң икән...

— Ә ул үзе кайда соң?— дигән тавыш ишетелде эчтән.

— Монда гына, мичне карап маташа.

— Соңрак алырмын,— диде Коләхмәтова. — Мин йоклыйм әле.

Ул арада карчык, бүлмәсенә килеп кергән ирләрне күреп, каушап калды.

— Болар минем ярдәмчеләрем. Сез борчылмагыз,— диде Стеклов шыпыртлап.

Карчык баш изәде, сүзсез генә чүп чиләген алды да бүлмәдән чыкты. Стеклов йозак тишегенә күз салды һәм, үз-үзенә ышанмыйча, катып калды: хуҗа хатын урындыкка баскан да түшәмдәге күгәргән кандильне борып маташа иде.

«Нигә алай итә икән ул?» — дип уйлады майор. Аннары лейтенант Вильдановка:

— Бар, тиз генә лом алып кил! — дип пышылдады.

Коләхмәтова кандильне ашыкмый гына һаман бора, үзе сагаеп кына ишеккә карап ала. Бер мәл эшеннән тукталып тыңлап та торды.

Ул арада, кулына лом тотып, Вильданов йөгереп килеп керде.

Стеклов ишек шакыды. Хатын җавап бирмәде, тәрәзәгә таба ашыкты.

— Ачыгыз, НКВД! — дип кычкырды майор.

Тавыш бирүче булмады.

— Лом белән каерыгыз тизрәк! — диде Стеклов, эшнең яхшыга бармавын төшенеп.

Вильданов ломны ишек яңагы арасына кыстырды да каерырга тотынды. Ишек ярыгыннан Стеклов Коләхмәтованың тәрәзә төбенә килеп басканын күрде. «Әллә тышка сикерергә уйлыймы?» — дигән уй йөгереп үтте аның башыннан.

Вильданов белән Герасимов ломга тагын да ныграк ябыштылар. Идәнгә ватылган йозак кисәкләре чылтырап коелды. Ләкин калын корыч чылбыр ишекне тулысынча ачарга ирек бирми иде. Ул арада бер метр чамасы киңлектәге тәрәзә төбендә басып торган хатын чекистлар күз алдында тәрәзә яңагы булган урында әллә ничек кенә хасил булган бушлыкка кереп югалды. Кирпеч яңак шунда ук яңадан элекке хәленә килде.

— Чылбырны өзегез! — дип кычкырды майор.

Бөтен көчкә тагын бер каерганнар иде, чылбыр йолкынып чыкты. Барысы да тәрәзәгә ташландылар. Яшерен юлны ачмакчы булып карадылар, ләкин яңак-ишек бирешмәде. Лом да ярдәм итә алмады.

— Кача бит инде ул! — диде каушап калган Герасимов.

Стеклов як-ягына каранды һәм:

— Герасимов монда кала, калганнарыгыз минем арттан! — дип әмер бирде.

Ишек төбендә алар Галләмов белән күзгә-күз очраштылар.

— Ни булды?!

— Коләхмәтова качты! Яшерен юл белән.

— Кайчан?

— Менә әле генә.

— Нишләмәкче буласыз? — дип сорады Галләмов.

— Монастырьны камап алырга.

— Менә нәрсә,— диде Галләмов катгый тон белән. — Ике кешене Преображение чиркәвенең җир асты юлын капларга җибәрегез. Берегез чаң кагу мәйданчыгына менсен. Йортны даими күзәтү астында тотыгыз. Калган барлык кеше монастырьны тышкы яктан күзәтәчәк. Бигрәк тә зираттан һәм су өстеннән күзне алмаска!

— Нәрсә өстеннән дидегез? — дип кайтарып сорады Стеклов.

— Җир асты юлларыннан берсенең суга килеп чыгуы бик ихтимал.

— Аңлашылды! — диде Стеклов, баш изәп.

— Барыгыз да урыннарыгызга! — дип боерды Галләмов.

Бөтен операция белән, милициянең поселок бүлекчәсе дежурные бүлмәсеннән торып, подполковник Чурбанов җитәкчелек итә иде. Менә аның бүлмәсенә сулышы кысылган дежурный йөгереп керде һәм Коләхмәтованың яшерен юлдан файдаланып, юкка чыгуын хәбәр итте. Чурбанов, ул хатынны кулга алу өчен урындагы милиция работникларын да файдаланырга кирәк, дигән карарга килде. Аларга җинаятьченең фоторәсемен күрсәтте.

Чурбанов хәзергә әле чекистлар таба алмаган җир асты юлының монастырьдан берничә йөз метр читтә салынган булуын да мөмкин дип саный иде. Шуңа күрә ул юкка чыккан хатынны нәкъ менә шул радиуста эзләргә булды. Ләкин подполковник аның җир өстенә көн яктысында чыгачагына шикләнә иде.

Аннары Чурбанов төнлә почта ящигына ташланган хатлар турында фикер йөртә башлады. Ул конвертларда бернинди бармак эзләре юк иде. Агент хатларын ике төрле адрес белән җибәргән. Берсе Печән базары урамында яшәүче Никита Лукич Рассохин дигән кешегә, ә икенчесе — Главпочтамтка. Серафим Тимофеевич Колегановка адресланган.

**8.05.** тә Чурбановка архиерей корпусына әле күптән түгел генә килеп урнашкан Григорин дигән кешенең өенә таң аткач кына кайтуын хәбәр иттеләр.

**10.00.** дә лейтенант Закиров хәбәр китерде: «Чаң кагу манарасына илтә торган җир асты юлында көтмәгәндә ниндидер кеше күренде. Хатын-кызмы, ир кешеме икәнлеген ачыкларга ара булмады. Бу билгесез кеше җир астына әле безгә билгеле булмаган яшерен юлдан төшкән булырга тиеш. Засадага эләгүенә ышангач, берничә тапкыр атты да юкка чыкты.

**10.30.** да Чурбановка Стеклов белән Герасимовның теге хатын файдаланган яшерен ишекне тапканлыкларын хәбәр иттеләр. Майор Стекловның башына түшәмдәге кандильне, нәкъ Шәрәфетдинова эшләгәнчә, борып карарга кирәк, дигән уй килә. Чыннан да, алар кандильне штурвал тәгәрмәче төсле итеп боргаларга тотыналар, һәм тәрәзә янәгы да үз күчәре тирәсендә борылып, калын стенада ачыклык хасил итә. Башта яшерен юл тәрәзә төбе белән бер тигезлектә бара, аннары бик тирәнгә аска төшеп китә һәм шактый зур бер бүлмә белән тәгәлләнә. Контрразведчиклар, бүлмәдән чыгу юлын таба алмыйча, туктап калалар.

**12.15.** тә Светловолжскидан хәбәр алынды: Рассохин — җитмеш яшьлек карт, гражданнар сугышында актив катнашкан кеше. Ялгызы гына яши. Күршесе — Семен Абрамович Фирсов фамилияле пенсионер белән аралашалар, еш очрашалар.

**12.50.** дә элемтәче Шугаевның Рассохинга телефоннан шалтыратуын хәбәр иттеләр. Алар арасында булган сөйләшүне икесе ике кешегә адресланган өлешләргә бүләргә мөмкин. Беренчесенә гадәти сүзләр, хәл-әхвәл сорашулар, ә менә икенчесендә «ягъни» дигән сүздән соң тоташ саннар башлана.

**13.05.** тә Жуков телефоннан хәбәр итте: «Үзәк почтадан хат алырга тиешле булган Колеганов фамилияле кеше Светловолжскида бөтенләй яшәми. Фирсовны күзәтү астына алдым».

Шпионка җибәргән хатларның эчтәлеге нык кына шик уята — алар шартлы текст белән элемтәче Шугаевның тозакта икәнлеген хәбәр итәләр иде. Ә Шугаев, турыдан-туры булмаса да, Фирсов белән бәйле булганлыктан, бу соңгысының эз яшерергә маташуы бик ихтимал иде. Шуңа күрә, барлык уңай һәм каршы дәлилләрне без-

мәнгә салып караганнан соң, Чурбанов Фирсовны кичекмәстән кулга алырга әмер бирде.

18.45. тә Чурбанов һәм Стеклов Светловолжскига киттеләр, ә монастырьдагы операцияне дәвам иттерү Галләмовка йөкләтелде.

19.45. тә Чурбанов хәлнең торышын Халык комиссары Рәхмәтуллинга бәйнә-бәйнә сөйләп бирде. Комиссар Фирсовны кулга алу турындагы карарны хуплады һәм шулай ук Шугаев белән Зеленскаяны да сак астына алырга кушты.

20.20. дә Фирсовны кулга алдылар. Бик нык каршылык күрсәтте, бер чекистны яралады. Тентү вакытында аның квартирында корал һәм күп кенә акча табылды. Аның бүлмәсеннән Рассохин квартирына идән плинтусы астыннан чыбык сузылган һәм ул яшерен рәвештә андагы телефонга тоташтырылган иде. Шунысы ачыкланды: димәк, Шугаев, Рассохин белән сөйләшкән булып, телефон аша Варевка шартлы билгеләр белән кыска донесениеләр биреп торган.

Кичке сигезләр тирәсендә Шугаев белән Зеленская да кулга алындылар.

Шугаевның кушаматы — Сәүдәгәр. Революциягә кадәр ул чыннан да икенче гильдияле сәүдәгәр булган. Үгерелгән бер кешенең документларын үзләштергән. Бу хәлне кайзер Германиясе разведкасы белеп алган һәм аны шантаж ярдәмендә немецлар файдасына эшләргә мәҗбүр иткән. Разведка үзәгенең күрсәтмәсе буенча, Сәүдәгәрнең үз сүзләренә караганда, 1939 елда аны Мефодийга буйсындырганнар. Шугаев әлеге Мефодийны нибары өч тапкыр, — анысында да төнлә генә күргән. Шуңа күрә аның йөз-кыяфәтен хәтерләми. Элемтә өчен яшертен урыннардан — почта ящикларыннан файдаланганнар. Ә Рассохин белән ул, шул ук Мефодий кушуы буенча, аның телефоныннан файдалану өчен танышкан, ә танышыр өчен сәбәп итеп шахмат уенын сайлаган. Әмма Шугаев бу телефоннан бик сирәк очракларда гына файдалана икән. Күп вакыт аңа «шеф» үзе шалтырата торган булган. Мефодийның төгәл адресын Шугаев белми. Кулга алган вакытта аның квартирында хикмәтле кул таягы табылды. Тоткасын ныгытып кысканда таяк эченнән микропленка салынган кечкенә генә кассета килеп төшә икән. Алдан килешенгән урында Шугаев җир төсендә кеше күзенә һич чалынмый торган шундый кассеталар калдыра торган булган. Ә инде үзе артыннан күзәтү барлыгын сизә-нитә калса, күзәтүченең игътибарын башка нәрсәгә юнәлтү өчен, үзенә кирәкмәгән берәр нәрсәне юри читкә ташлый яисә яшерә торган булган. Монастырь йортында утырганда да ул шулай итә: азык калдыкларын юри такта астына яшерә.

Зеленскаяга килгәндә, ул менә нәрсә сөйләде. Барысы да 1940 елның январенда кичен ресторанда оештырылган эчү мәҗлесеннән башлана. Күрше өстәлдә утыручы мәһабәт кыяфәтле, илле яшьләрендәге бер кеше аны танцыга чакыра. Ул чакта ире ниндидер районга командировкага киткәнлектән, Зеленская ялгызы була. Рестораннан соң әлеге ир кеше аны озата бара. Роза аны чәйгә чакыра, ә тегесе аңа асыл кашлы йөзек бүләк итә, аннары кунарга кала. Зеленскаяның Альфред исемле бу яңа танышы төрле бүләкләргә акчасын бер дә кызганмый. Баштарак берни сизенмәгән Роза аңа эшендә булган хәлләрне бик теләп сөйли. Ә бераздан теге кеше зур акча бәрабәренә аңардан яшерен информация табуны таләп итә. Зеленская башта куркуга төшә, бу тәкъдимнән баш тарта. Ләкин тиздән ул үзенең бик оста куелган тозакка эләгүен аңлый һәм, бүтән чарасы калмагач, риза була. Үзенә күптән күз атып йөргән Федорукның ачык авызлылыгыннан файдаланып, җыю цехы сейфы ачкычының күчермәсен кулга төшерә. Бөтен дөньяга үчле булып йөргән конструктор Чревовтан шактый күп информация ала. Тегесе, үз дошманнарына зыян китерәм

дип белеп, алардан үч алу өчен, бу чибәр ханымга бар белгәнен сөйли тора. Ул үзе катнашында эшләнгән хәрби разработкалар турында мәгълүматлар шул рәвешчә «югарыга», зур башлыкларга барып ирешерләр дә, тегеләре моның сәләтен, бу хезмәтләрдә аның зур роль уйнавын күрерләр, дип ышанып йөри, шуның өчен тырыша...

Альфредка килгәндә, ул тиздән күздән югала, ә Зеленскаяны Шугаев кул астында калдыра. Соңыннан ачыклангача, Альфред ил чиге аша чыгарга маташкан вакытта атып үтерелә.

**21.00.** дә сорау алыр өчен Фирсовны китерделәр. Аңа беренче карау белән Стеклов үз күзенә үзе ышанмыйча торды: аның каршында Варев басып тора иде. «Нинди молодчина син, Жуков! — дип уйлап алды ул. — Нинди зур канәчкеч ерткычны эләктергәнсең бит!»

— Мәнә бу очрашу дисәң дә очрашу! — диде Стеклов урыныннан ук торып. — Безнең тарафка Вячеслав Мефодьевич үзе килгән түгелме соң?!

Ләкин тегесе салкын гына җавап бирде:

— Сез ялгышасыз, гражданин тикшерүче. Андый исемне беренче ишетәм. Мин — Фирсов.

— Шулай, Варев, әлбәттә шулай. Әгәр сез беренче минутта ук кем икәнегезне әйтеп бирсәгез, бу бик сәер булыр иде. Я ярый, артык борчылмагыз, без сезнең хәтерне яңартырга тырышырбыз.

Бу очрашуны сүзсез генә күзәтеп торган Чурбанов тыныч кына сорады:

— Агент буларак кушаматыгыз нинди?

— Кайдан килгән агент ул тагын? Карак мин! Законлы карак! Ни пычагыма сез мине бирегә китердегез? Минем белән уголовка шөгыльләнергә тиеш!

— Сез «Мефодий» кушаматлы агентны беләсезме? — дип сорады подполковник.

Шпион, һич уйлап тормастан:

— Ишеткәнем дә юк! — дип җавап бирде.

— Сезгә бу кушаматны әтиегезнең исеме шулай булганга бирделәрме, әллә бу төбәктә эш иткән бандитлар шайкасы башлыгы истәлеге итепме?

— Нәрсә турында сүз барганын аңламыйм!

— Сүз менә нәрсә турында бара,— дип тыныч кына дәвам итте Чурбанов: — Сез Сәүдәгәргә, ягъни Шугаевка үзегезне Мефодий дип танытkансыз. — Подполковник Варев янына килде. — Сез оттырдыгыз бит, Вячеслав Мефодьевич. Һәм шул нәрсәне танырлык дәрәҗәдә генә булса да кыю булырга тиешсез. Теге вакытта Святовск янындагы урманда сез истәлек өчен дип безгә чыршы күркәләре тулы кәрзин калдырып качкач, без бит үзебезнең төп башына утырып калганыбызны таныдык.

Варевның төсе үзгәрде, ул арыган кыяфәт белән урындыкка утырды.

— Мин Шугаевка үземне Мефодий дип түгел, ә Мефодьич дип таныттым. Ул, мөгаен, куркуыннан шулай ишеткәндер.

Подполковник аңа бер кәгазь сузды:

— Менә монда экспертиза нәтиҗәләре язылган. Сез урманда яшергән рациядә калган бармак эзләре сезнең бармак эзләре белән тәңгәл.

Варев документка күз төшереп кенә алды:

— Минем фамилиям Фирсов,— диде ул. — Кушаматым-фәләнем юк. Әйе, мин радист. Бары тик радист кына. Кеше үтергәнем дә, нәрсәдер шартлатканым, кемгә дә булса яшерен информация биргәнем дә юк. Мин тик кушканны эшләүче генә.

— Алайса сез — Унөченче..

Варев калтыранып китте.

— Үзегезгә бәхетсез сан сайлап алгансыз. — Подполковник аның алдына шифр белән тапшырылган телеграмма кәгазе куйды. — Күрәсезме, монда Унөченче турында сүз бара. Ә төп фигура — Мефодий. Шуларның кайсысы соң сез, Варев-Мефодиймы, әллә Унөченчеме?

— Мин сезгә әйттем бит инде, минем бернинди кушаматым юк, дип. Мине бу эшкә моннан өч ай элек тарттылар. Калганы сезгә болай да мәгълүм. Өстәвенә, мин инде сезгә тулы анкета тутырып бирдем. Шуны укыгыз. Анда барысы да әйтелгән.

— Ә сез Йөнтәс кушаматлы Фроловны беләсезме?

Варев җилкәсен генә җыерды:

— Ишеткәнем дә юк.

Бүлмәгә Фроловны китерделәр. Аларны бер-берсенә кара-каршы утыртып сорау алу башланды. Йөнтәс июнь азагында бу кеше белән бергәләп конструктор Әхмәтов квартирына кергән, аның кушуы буенча квартирдагы сейфны ачуын әйтте. Бу кеше сейфтагы нинди дер сызымнарны фотога төшереп алды, диде.

— Ә сез,— диде Чурбанов шпионга текәлеп,— яшерен информация урлаганым юк, дигән буласыз.

Шулай итеп, Варевтан сорау алу яңа нәтиҗәләр бирмәде. Бу кешенең чынлыкта резидентмы әллә контролер-радист кынамы булуы ачыкланмый калды.

Святовский поселогының зираты гранит һәм мәрмәр кабер ташларының салкын ялтыравы белән, кошлар тавышы белән яши иде. Әмма кич житү белән бу тормыш та сүнеп, тынып калды. Зиратта тик әле бер баштан икенчесенә йөгереп үтүче, әле тәбәнәк куаклар арасында тоткарланып калучы эчпошыргыч җил сызгыруы гына ишетелгәләп ала иде. Лейтенант Закиров, барлык тавыш-кыштырдауларга колак салып, яшерен төрбәдән ерак түгел генә ята иде. Менә мәрмәр таш кыйшайды һәм кабер калкулыгында Вилдановның башы күренде. Вилданов аңа кул изәде. Закиров якын килгәч:

— Син анда төш, ә мин монда калып торам,— дип пышылдады ул. — Майор шулай кушты.

Закиров аска төште һәм, җир асты коридорының стенасы буйлап капшана-капшана, андагы бүлмәгә барып җитте.

Кемдер аның иңбашына кагылды.

— Сез монда өлкән кеше булып каласыз,— дип пышылдады Галләмов,— ә мин барып, белеп килим әле: монастырьда ниләр бар икән?

Майор китеп барды. Җир астында күзгә төртсәң күренмәслек караңгылык һәм тынлык. Сөйләшү һәм тәмәке тарту катгый рәвештә тыелган. Закиров сәгатенә күз төшереп алды: фосфор төшерелгән циферблат төнге унберне күрсәтә иде.

Ким дигәндә бер сәгатьтән Галләмов әйләнеп килде һәм шыпыртлап кына:

— Анда бар да элеккечә,— диде. — Монастырь башлыгының йокы бүлмәсеннән җир астына төшү юлын һаман тапмаганнар. Шуңа күрә теге карчыкны безгә монда күтәргә кирәк.

Закировка ни өчендер дошман яшерен бер ишектән килеп чыгар төсле тоела иде. Тик менә кайсы яктан? Ул, стенага колагын куеп, тыңлап карады, ләкин берни дә ишетә алмады.

Кинәт, сизелер-сизелмәс кенә булып, кемнеңдер аяк тавышы ишетелгәндәй булды. «Егетләрнең түземлеге җитми»,— дип уйлады ул.

Аяк тавышлары тынды. Бер биш минутка колак чыңлаткыч тынлык урнашты.



*Т. Хаҗиәхмәтов рәсеме*

Менә тагын нидер кыштырдаган тавыш ишетелде. Бу юлы ул кайдандыр җир астыннан килә иде. Бүлмәнең нәкъ уртасында, табутлар торган урында, иске шкаф ишеге ачылгандай шыгырдау ишетелде. Аннары өстәл тартмасы ачылган кебек булды. Закиров, аяк очларына гына басып, шикле тавышлар ишетелгән урынга килде һәм чүгәләде.

Тагын тынлык. Бер-ике минут барысы да тын алырга куркып утырдылар. Көтмәгәндә уртадагы табутның капкачы чак кына күтәрелде һәм хасил булган тар гына ярыктан электр фонаре яктысы бәреп чыкты. «Менә серле юлның очы ничек яшерелгән икән! — дигән уй йөгереп үтте Закировның башыннан. — Шуңа да башыбыз җитмәгән бит!»

Ул арада табутның капкачы һәм андагы кеше скелеты әкренләп күтәрелә башлады, яктылык бөтен төрбә эченә таралды. Закиров кеше скелетын һәм табутны күтәрүче кулларны да күреп алды. Менә баш та күренде.

«Хәзер безнең монда икәнне сизә дә, кире чума инде бу,— дип уйлап алды Закиров. — Аннары тот син аның койрыгын. Юк, хәзер үк алырга кирәк!»

Контрразведчик, пружинадай кинәт тураеп, табут янына сикерде һәм күз ачып-йомган арада серле кешенең кулыннан эләктереп алды. Кул аска тартылды. Табут капкачы һәм скелет чекистның җилкәсенә килеп төштеләр. Ул арада Мотыйгуллин йөгереп килеп җитте һәм тегенең нягеннән тотып алды. Тиздән Галләмов белән Зарипов та килеп җитештеләр.

Майор скелетлы табутның капкачын читкә алып ыргытты, ә Зарипов төнге «кунак»ны култык астыннан тотып алды. Аның ярсулы каршылык күрсәтүенә дә карамастан, контрразведчиклар дүртәүләп, тирән кагылган юан кадакны суырып чыгаргандай, шпионны өскә тарта башладылар. Еландай бормаланган бу кеше гәүдәсен тартып чыгарулары булды, җир астындагы төрбәдә ачыргаланып кычкырган хатын-кыз чинавы яңгырады:

— А-а-а!!

Галләмов ирләр киеме кигән бу хатынга шактый озак карап торды:

— Коралың бармы?

Шпион хатын эндәшмәде.

— Чалбар кесәгездә нәрсә ул? — Һәм тегенең җавап бирүен дә көтмичә, Мотыйгуллинга ишарә ясады: — Тентегез!

Лейтенант тегенең кесәсеннән учка сыярлык кына кечкенә браунинг чыгарды.

— Агулы елан!— диде ул, ачуыннан ярсып. Измайловны үтерүче һәм Денисовны яралаучы шул кабәхәт булган икән! Табылган гильзалар нәкъ шушы калибрдагы браунингныкы.

— Я, ярый, лейтенант. Ул үзенә тиешлесен алыр. Ә хәзергә саклык белән генә аска төшегез дә тирә-юньне җентекләп тикшерегез.— Майор шпионка менгән ярыкны фонарь белән яктыртты. — Монда таш баскыч. Ләкин шул баскычтан ары бер адым атлыйсы булмагыз!

Мотыйгуллин, тиз-тиз атлап, җир асты баскычыннан төшеп китте. Ләкин шунда ук яңадан күренде:

— Баскыч шундый тирәнгә китә, җәһәннәмнең үзенә алып бара дип белерсең,— диде ул.

— Баскычтан ары беркая бармаска! — дип кабатлады Галләмов.— Юкса, тозакка эләгеп, харап булуыгыз бар.

— Иптәш майор, монда нииндидер сумка...

Галләмов аның кулыннан шактый авыр юл сумкасы алды. Аны ачып җибәрүе булды, фонарь яктысында Николай патша сурәте төшерелгән алтын акчалар ялтырап китте. Галләмов шулар арасыннан тагын нәрсәдер эзләде дә шпион хатынга карады:

— Йөзек кайда?

Ләкин тегесе җавапсыз гына читкә борылды. Идәндәге ярыкта тагын лейтенантның башы күренде:

— Менә нәрсә таптым! — дип ул Галләмовка зур бриллиант кашлы йөзек сузды.— Баскычта ята иде.

— Ташларга өлгергән дип уйлаган идем аны,— дип куйды майор, табылган йөзекне җентекләп карый-карый. — Бу нәрсәкәй безгә күп әйберне аңларга ярдәм итәр, дип уйлыйм.

Шпионка агарынды һәм йөзен куллары белән каплады.

— Иптәш майор,— диде Мотыйгуллин ялварулы тавыш белән, — җир асты юлының бу башын гына булса да тикшереп чыгарга рөхсәт итегез. Анда, зур тирәнлектә гаҗәеп озын коридор сузылган, ян-якларында ниндидер ишекләр...

— Анысы соңыннанрак, лейтенант. Тиздән бар нәрсәнең очына чыгарбыз. Ә хәзергә — барыбыз да Светловолжскига.

Җир өстенә чыккач, Галләмов Вильдановка урынында калып торырга әмер бирде. Алар шәһәргә төнге сәгать икеләрдә генә кайтып төштеләр. Чурбанов аларны үз бүлмәсендә көтеп тора.

Шпионка җавап бирүдән баш тартты. Сорау алуны иртәгәгә кадәр кичектереп торырга булдылар. Җир астында табылган сумкадагы әйберләрне тикшереп чыктылар: анда Николай акчаларыннан тыш, чит ил валютасы һәм алтын бар иде.

Подполковник йөзекне лупа аша җентекләп карап чыкты. Шактый зур бриллиант каш астында, уптай янып, тәре ярылып ята иде. Тиздән ул йөзекнең бриллиант кашын алу әмәлен тапты. Аның астындагы юка гына алтын кисәгендә ниндидер саннар һәм кызыл эмаль белән инструкцияләп ясалган тәре тирәсенә тезелеп киткән кечкенә-кечкенә рәсемнәр бар иде.

— Ифрат та нәфис эшләнгән бу,— диде, ниһаять, подполковник.— Оста ювелир кулы сизелеп тора. Бу йөзеккә караганда, монастырьдагы җир асты юлларының схемасы тәре рәвешендә. — Ул яңадан кулына лупа алды. — Менә монда безгә инде таныш булган кандиль һәм тәрәзә яңагы, ягъни элек монастырь хуҗасы яшәгән бүлмәдән башлана торган яшерен юл билгеләнгән. Шунда янәшәдә үк баскыч бусагаларының берсенә «66»лы сан язылган. Димәк, безгә шуннан соңгы юлның башын алтмыш алтынчы басмада эзләргә кирәк булган икән...

Алтын кисәгенә зираттагы яшерен төрбә дә төшерелгән иде.

Чурбанов йөзекне Галләмовка бирде:

— Ә елга өстен без тикмәгә күзәтмәгәнбез: яшерен юлларның берсе нәкъ елга астына чыга, ул монастырьдан Идел ярына төшә торган таш баскыч астыннан үтә...

— Ә менә тозаклар биредә баш сөяге сурәте белән билгеләнгәннәр. Аларның саны унөчтән артып киткән,— диде Галләмов. — Монда әле тагын әллә никадәр сан бар...

— Аларын инде урынга барып тикшерергә кирәк булыр,— диде Чурбанов. — Ул саннарның күпчелеге бик җентекләп яшерелгән ишекләрнең һәм бүлмәләрнең урынын күрсәтә. Анда бер-берсеннән аерым булган коридорлардан һәм бүлмәләрдән торган бөтен бер җир асты шәһәрчеге. Кыскасы, бу йөзек — Идел буе монастыреның серләрен аңлата торган хикмәтле ачкыч.

— Атаман Мефодийның да бу йөзекнең серле булуы турында әйтеп калдыруы тикмәгә булмаган,— диде Стеклов. — Викентий-атаның хәзинәләре дә шул җир асты шәһәрчегендә яшерелгән булырга тиеш. Ә менә алтынның бер өлешен бу хатын әләктергән...

Икенче көнне иртән шпион хатыннан сорау алырга керештеләр. Кулга алынган ханым үзен кирпеч заводы бухгалтеры Коләхмәтова дип танытты. Шуннан соң аны Метелева белән күзгә-күз очраштырдылар. Коләхмәтованы күрү белән Метелева бөтенләй гаҗәпкә калды:

— Господи, святая богородица... — Мария Петровна чукынырга ук тотынды һәм лап итеп урындыкка утырды. — Тукта әле, минем үлгән фатирчым Постнов яңадан терелгән димме... Ничек инде...

— Бу провокация! — Шпионка урыныннан сикереп торды. — Минем бу карчыкны күргәнем дә юк. Мин — хатын-кыз, ир кеше түгел. Мин таләп итәм: алып китегез хәзер үк бу кортканы!..

Метелева, берни аңламыйча, шаккатып карап тора иде.

— Анатолий Семенович Постнов түгелмени соң бу? — диде ул каушаган хәлдә. — Ә шул тикле охшаган...

Чурбанов аңа элекке фатирчысының ул белгән аерым билгеләрен әйтергә кушты. Метелева аның сул кулында миңе булуын исенә төшерде.

Шпион хатын кул гена селтәде:

— Алып китегез кортканы. Үзем сөйлим...

Ул Магнитогорскидан килгән тәэминатчы Постнов исеме астында Метелева квартирында яшәвен раслады, ләкин шпионлык эше алып баруын кире кагарга маташты. Үзен караклык белән шөгыльләнүче итеп күрсәтергә тырышты, йөзекне дә очраклы бер кешедән урлавын әйтте. Ә браунингтан куркудан гына аттым, беркемне дә үтерергә теләмәгән идем, диде...

Бу сүзләрне тыныч кына тыңлап торган Чурбанов көтмәгәндә аны бүлдерде:

— Җитәр инде, күп ялганладыгыз, Волковская!..

Хатын кинәт катып калды, бөтенләй телдән язды. Йөзеннән каны качты, агарынды, яңагында саргылт таплар пәйда булды.

Подполковник тыныч тавыш белән гади генә итеп:

— Наталья Викентьевна, абыегыз атаман Мефодий кайда үтерелгән иде? — дип сорап куйды.

— Әстерханда,— дип җавап бирде хатын, уйлап та тормыйча.

— Димәк, аның конспиратив квартирында булган егет — сез?

Волковская ияк какты.

— Поручик Шергинны белә идегезме?

Шпионка бу сүзләрдән соң сискәнеп киткәндәй булды, күзләренә җан керде:

— Менә кем аркасында кулга алынган икән минем абый! Кабәхәт! Шунда ук күңелем сизгән иде аны!.. Алайса сез барысын да беләсез,— диде ул төшенке тавыш белән. — Башка сыймаслык хәл: Шергинны тапкансыз... — Ул башын кулы белән кысты. — Бар нәрсәне белә торган бердәнбер кешене...

Волковская алтын йөзекне аңа һәлак булыр алдыннан абыйсы биреп калдырган булуын әйтте. Революциягә кадәр Казан театрында актриса булган идем, төрле кыяфәткә керергә шул чакта өйрәнеп калдым, диде.

— Мефодий дигән кушаматны сез абыегыз истәлеге итеп алдыгызмы? — дип сорады Чурбанов.

Шпионка бөтен тәне белән тартышып куйды һәм башын чайкады:

— Алайса сез — Унөченче, һәм төрбәдә сезнең рация яшерелгән?

— Әйе, мин радистка.

— Алайса миңа шуны әйтегез: радиограммадагы «йөзекне файдаланыгыз», дигән сүзләр нәрсәне аңлаталар?

— Алар радистка бирелгән боерык. Эшегезне туктатыгыз, ягъни качыгыз, дигән сүз.

— Расшифровка ясалган радиограммаларыгызны сез кемгә тапшыра идегез? Аларны сезгә кем китерә иде?

Волковская бер мәл уйланып торды, аннары сөйләп китте:

— Мин мәгълүматларны монастырь ишегалдындагы зур урындык астыннан, яшерен урыннан ала идем. Ә алынган радиограммаларны зиратта, төрбәдән ерак түгел урында яшерә идем. — Һәм ул бу урынның кайда икәнен аңлатып бирде.

— Әгәр резидентка, ягъни Мефодийга бик ашыгыч донесение кирәк булса? — диде подполковник, ә үзе телефон трубкасын алды. — Разведка эшендә резидентка үзәктән бик ашыгыч боерыклар тапшырырга кирәк була бит.

— Әйе, әлбәттә була...

Барысы да Волковская тагын ни әйтер икән дип көттеләр. Ә аның башында газаплы бер уй: куркыныч янавы турында кисәтүе Варевка барып җиттеме икән? Ул качып өлгердеме икән?

Ул арада Чурбанов бишенче камерадагы тоткынны китерергә боерды. Аннары урынына утырды да кабатлап сорады:

— Я, ничек?

— Мин Светлогорскига, Рассохинга шалтырата идем...

— Димәк, ул резидент?

Волковская баш изәде.

Чурбанов аның фикер йөртү юнәлешен аңлап алды. Әгәр Варев сигналны алмаган булса, чекистлар аның көрәшесе белән шөгыльләнгән арада, ул эшнең нәрсәдә икәнен аңлап алыр. Волковская әле һаман Варевның эзенә төшмәгән булуларына өметләнә иде. Әгәр дә ул качып өлгерә алган булса,— ул чак бик күп нәрсәне әйтми калдырырга, күп вакыйгаларны һәм фактларны бүтәнчә аңлатырга, барысын да Варев өстенә аударырга мөмкин булачак.

— Әтиегез алтынын кайда яшерде?— дип сорады Стеклов.

— Минем әти бай кеше түгел иде. Мин аның алтыны турында берни белмим,— диде Волковская. — Ә инде минем сумкадагы алтыннарга килгәндә, әтидән калган бар байлыгыбыз шул.

Ул арада ишек ачылды, һәм бүлмәгә Варев килеп керде. Волковская, Метелева белән очрашкандагы төсле, тагын тораташ булып катып калды.

— Нервларыгыз какшаган, Наталья Викентьевна,— диде Галләмов. — Бик тә зарарлы профессия сайлагансыз шул.

Уенны оттырганлыкларын аңлаган Варев барын да әйтеп бирде: Коләхмәтова, шул ук Постнов — Мефодий кушаматлы резидент, ә мин утыз тугызынчы елда аның карамагына җибәрелгән идем, диде.

— Ялган!— дип кычкырып җибәрде Волковская. — Ул түгел, мин үзем аның карамагында идем. Ул резидент! Аңа кушаматны әтисенең исеменнән чыгып бирделәр. Варев — тәҗрибәле шпион һәм кеше үтерүче.

Һәр ике агент, үзләрен акларга омтылып, бер-берсен «батырырга» тотындылар. Варев шушы хатын кушуы буенча Мәскәүгә баруын, анда Маяковский метросында бер агент белән очрашуын сөйләп бирде.

— Юк, Мәскәүгә ул түгел, мин бардым, анда кулына Дашков китабын тоткан кеше белән очраштым. Ул миңа рация тапшырды,—дип кычкырды Волковская.

«Димәк, шифровкаларның берсендә телгә алынган «З-М» — ул «Мәскәү, Маяковский метросы» дигән сүзләр булган икән,— дип уйлап алды Чурбанов.— Ярар, бу мәгълүматтан да тиешле нәтиҗә ясарбыз. Теге рация алып килгән агентны да кулга алырбыз».

Стеклов агентларның үзара ызгышуын берни аңламыйча тыңлап торды. Чурбанов төймәгә басты. Бүлмәгә дежур офицер кергәч:

— Унөченчене алып китегез,— диде.

Варев белән Волковская икесе берьюлы торып бастылар.

— Ә сез, резидент, калып торыгыз,— диде Чурбанов, Волковскаяга мөрәҗәгать итеп.

— Ялгышу бу! Мефодий — мин түгел. Ул бит ир кеше исеме. Ничек инде сез шуны аңламыйсыз?!

— Кичә әле мин барысын да аңлап бетерми идем, гражданка Волковская,— диде Чурбанов, Варев чыгып киткәч. — Эш шунда ки, резидент булган кеше һәрвакыт монастырьда торырга тиеш булган. Үзегез уйлап карагыз. Шугаевның күзәтү астына алынуы сезгә өченче көн төнлә, ягъни сез монастырь йортында засадага эләккәч билгеле булды. Һәм шуннан соң бер сәгать үтәр-үтмәс, төгәлрәк итеп әйтсәк, бер тулып егерме минутта, үзәккә Сәүдәгәрнең «батуы» турында шифровка җибәрелде. Әгәр резидент монастырьдан читтә булса, сез бер сәгать-сәгать ярым вакыт эчендә аның белән элемтәгә керергә өлгерә алмаган булыр идегез. Шул вакыт эчендә бит әле тагын шифровка язарга, рация янына барып җитәргә, аны зиратка алып чыгып урнаштырырга, радиограмманы тапшырырга да өлгерергә кирәк. Аның монысы өчен генә дә кимендә бер сәгать вакыт сорала.

Подполковник урыныннан торды һәм бүлмәдә ишекле-түрле йөренә башлады.

— Шифровкага Мефодий дип кул куелган. Ә сез разведкада радистның бер вакытта да резидент өчен кул куя алмаганын бик яхшы беләсез. Әгәр бу шулай икән, димәк — резидент — я сез үзегез, я Григорин дигән икенче берәү. Ләкин Григорин өченче көн монастырьда булмады. Урта кул спекулянт кына булып чыкты сезнең ул кешегез. Төнлә поселоктан сез җибәргән хатлар да бу фикерне раслыйлар. Менә шулай, Волковская!

Волковская урыныннан сикереп торды һәм, үз-үзен белештермичә, кычкырырга тотынды:

— Күрә алмыйм мин сез кабәхәтләрне! Изәргә, таптарга кирәк сезне! Ишетәсезме, таптарга! Шунысы кызганыч — бик аз үтердем мин сезнең кебекләрне! — Волковская шаркылдап көлеп җибәрде: — Ә алтынны сез барыбер таба алмыйсыз. Аның серен мин үзем белән кабергә алып китәм, әмма сезгә әйтмим!

Аны алып чыгып киттеләр.

Подполковник Чурбанов үзенең хезмәттәшләренә арыган караш ташлады:

— Менә, туганнар, операция тәмамланды,— диде ул. — Идел буе монастыреның сере ачылды. Серне ачу өчен без иң кадерле иптәшләребезне — Измайлов белән Севчукны югалттык. Ләкин алар — бушка бирелгән корбаннар булмады. Алар ничәмә-ничә еллар явызлык чыганагы булып торган серне ачарга ярдәм иттеләр. Бу явызлык безнең кешеләргә тыныч яшәргә комачаулый иде. Ә моның өчен тормышыңны бирү дә кызганыч түгел.

— Иптәш подполковник,— диде аңа Мотыйгуллин,— ә Викентий атаның хәзинәләре кайда соң?

— Менә иртәгә монастырь астындагы серле юлларны тикшерергә тотынабыз. Һичшиксез тапмый калмабыз!

# Рөстәм Мингалим

## Өстәлеңә ак чәчәк

Туган көн бәйрәмеңә
Очып килдем, Рузилә.
Сора әнә кешедән,
Ышанмасаң сүземә.
«Кая оча бу?» — диеп, —
Карап торды барсы да.
Очып килдем кош сыман,
Очып килдем җил сыман.
Инде сиңа үземне
Телим бүләк итәргә...

Тик әнием килер шул
Мине алып китәргә.
Күкне кулъяулык итеп
Бирер идем үзеңә,
Аның белән борын да
Сөртеп булмас, Рузилә.
Бирер идем Иделне,
Ул да агып китәчәк.
Минем сиңа бүләгем:
Өстәлеңә — ак чәчәк.

*1983*

## Авыл буендагы чишмә рәсеме

Безнең якта
Чишмә бар.
Андый чишмә
Сездә юк.
Чишмәбезнең
Тавышы — су,
Теле — су,
Теше — суык.

Сөйли белә —
Сөйләсә
Тешли белә —
Тешләсә.
Әй, сөенә
Улагына
Тезелеп, атлар
Кешнәсә.

*1981*

## Отып кына калырга

Дусым китә күршедән,
Чакыру булган аларга,
Әй, көлүе дусымның! —
Отып кына калырга!?
Ул шулай көлә белә,
Яктырып килә белә.
Көмеш тәңкә сипкәндәй,
Тавышын сибеп көлә.

Җыя алсаң көлүен —
Учка җыеп торырлык;
Кесәңә тутырырлык,
Куенга тутырырлык:
Тәнең шуны сизәрлек
Рәхәтләнеп бервык.
Аның гына көлүе
Шундый тере матурлык.

Аның гына көлүе —
Шундый рәхәт түгелү.

Тик отарлык түгел ул...
Онытырлык та түгел ул!

*1983*

## Бездә шулай

Безнең авыл кечкенә,
Исме аның Дәүйолдыз.
Ярты авыл бездә кыз,
Ярты авыл — малай,
Бездә шулай.
Мин дә кечкенә малай,
Өстемдә яңа күлмәк,—
Ул апам биргән бүләк,
Түш кесәсе дә бар,
Әйе, шулай.
Кесәсендә күлмәкнең
Нәрсә бар, беләсезме?
Әллә үзем әйтимме? —
Нәни генә бер эт, —
Менә шулай!

Ул ник анда, димәгез,
Минем янымда йөрер.
Дошманым килсә, өрер,
Дусларыма өрмәс. —
Шулай, шулай.
Өргәне дә юк аның,
Бүредән дә усал эт!
Өрер сәбәп тапмый бит,
Бөтен авыл дусым, —
Бездә шулай.
Этне үзем ясадым,
Әйе, кәгазьдән генә:
Кесәмдәге кәгазь эт
Шуны үзе дә белә,
Менә!

*1982*

## Үтте яңгыр

Үтте яңгыр, чыкты кояш,
Кырларым кибә җилләп.
Чәчкәле кырлар учыннан
Табып алдым бер җиләк.
Эре түгел, вак та түгел,
Тел өстендә ул җиләк.
Ул җиләк бу дөньядагы
Бар җиләктән тәмлерәк.

Кемдер тәмен белми аның,
Миңа бары ул кирәк...
Ул җиләк бөтен конфеттан,
Шоколадтан тәмлерәк.
Бу тәм белән бер тәмне дә
Куеп булмый янәшә.
Чиксез тәмле ул җиләкме?!
Ул җиләк — җирдә яшәү.

*1983*

## Кайтырмын

«Йөзеп кенә кайтырмын!
Очып кына кайтырмын!»
Бу тавышны әнкәсе,
Әткәсе дә бик белә.
Бу колакка ишетелә,
Бу йөрәккә ишетелә.
Бик ерактан ишетелә:

«Йөзеп кенә кайтырмын!
Очып кына кайтырмын!»
Яңа гына, югыйсә,
Агач өй-диңгезендә
Йөзә иде бит әле
Ул агач бишек белән!?
Кай арада тавышы
Һай, ерактан ишетелә:

Океаннардан ишетелә,
Йә күкләрдән шетелә.

«Йөзеп кенә кайтырмын!
Очып кына кайтырмын!»

*1982*

## Яфрак хәтле генә ярату

Нәни яфрак хәтле ярату
Урнаша да кереп күңелгә,
Яшел куак булып куера —
Бөтен күңел шуңа күмелә.
Бөтен җаның шуңа күмелә.

Яфрак хәтле генә ярату! —
Әнкәңнеме шулай яраттың?
Яфрак хәтле генә ярату! —
Әткәңнеме шулай яраттың?
Мәктәпнеме шулай яраттың?

Укытучыңнымы яраттың?
Сабакташыңнымы яраттың?
Кемне шулай кинәт яраттың?
Мин үзем дә шулай яраттым, —
Шулай була икән ярату...

Яфрак хәтле генә ярату! —
Урнаша да кереп күңелгә,
Яшел урман булып куера,
Бөтен дөнья шуңа күмелә.
Мин дөньяны шулай яраттым.

*1982*

## Күңелсез малай

«Ул аз сүзле малай», — диләр,
Хәтта «телсез!» диләр иде.
«Уйнамыйбыз аның белән,
Ул күңелсез»,— диләр иде.
Шулай кызлар ялгышкандыр,
Малайлар да белмәгәндер,
Күңелсезнең күңелендә —
Сөйләр сүзе гөрләгәндер.
Яктыргандыр әйтер сүзе —
Күзләрендә күлдәй тулып.
Бер-бер сәбәп аркасында
Әйтмәгәндер тик оялып.
Инде кара шул малайны,
Белгән хәйлә кулланырга!
Җилдәй җиңел скрипка
Кысып алган кулларына.
Кыллар аша, моңнар аша.
Сөйләп китә, сөйләп китә:
Яфрак итеп йөрәгеңне
Йә тирбәтә, йә биетә...
Йә каршыңда бер мәл көе
Елый башлый сулгып-сулгып.
Һәм тыңлаучы кала шунда
Күңелсез бер малай булып.

*1982*

## Ишеген шакыйм

Бер ялгызым өйдә калдым,
Ятам сузылып, рәхәт инде.
Сизәм шунда, мыштым гына
Минем янга кемдер килде.
Кем икән дип күзем ачсам,
Күренә миңа борын гына.
Әллә юри, мыш-мыш итеп,
Кагыла борын борыныма.
Аннан борын юкка чыга,
Ике матур ирен күренә.
Карап торам, кинәт ирен
Тел күрсәтә, ирештерә.
Аннан ирен юкка чыга,
Ике туфли йөреп тора,
Әйе, килгән бик шат кеше,
Ике туфли биеп тора!
Оста бии, тыпыр-тыпыр,
Чәчәк кенә чигеп куя!
Минем янга җитте дигәч,
Бераз гына чигенеп куя.
Танып булмый, кем туфлие?
Аннан туфли юкка чыга.
Күренә кашы, керфекләре
Һәм кап-кара күз ачыла:
Искә төшә шунда борыны,
Туфли, ирен, күз карашы!
Әһә, кызый, әләктеңме?!
Син шулаймы? Шаярамсың?!
«Шаярам!— ди,—
тоталмыйсың!»
Аннан кызый юкка чыга.
«Таяк сыман ник ятам соң?!»—
Дим дә йөгереп йортка чыгам.
Аннан минә ишеген шакыйм,—
Үз өенә кызның килдем...
Мин үземчә керәм хәзер,
Ул кыз кебек керә белмим.

*1982*

## Рамазан Байтимиров

### Сигезьюллыклар

●

Тәлгәш-тәлгәш җыеп кайта идек
Туган якның миләш-баланын.
Суларында маймыч сөзә идек
Җылым итеп ыштан балагын.

Тубал тутырып, җиләк җыя идек
Урманында, яшел аланда...
Ялан тәпи туп уйныйсы килә
Тугайларга чыгып һаман да.

●

Җимешне мул бирмәгәнгә микән,
Йолкып, чия ярдан ташланган.
Яр ишелеп күмгән тамырларын,
Ул чәчәккә төренә башлаган...

Дошман куллар яман кагылсалар,
Моңа артык исең китмәсен;
Тик тамырлар җиргә нык берексен,
Тамыр булсын. Тамыр кипмәсен.

●

Бу дөньяда акыл таулары бар,
Мин бер нокта алар янында.
Тауга карап бер тау булмасам да
Кимсену юк минем җанымда.
Урындагы нокта мәгънәләрен
Аңлатырга нинди сүз белән?
Нокта-өтерләрне онытканга
Газиз башлар кайчак өзелгән.

●

Гел беркатлы булып яшәдем дә,
Һәр әйтелгән сүзгә ышадым.
Шуңа җуйдым күпме җан дусларны,
Сәбәп булды телем-дошманым.
Чын сөюне таптым туган якта,
Моңа шаһит кырда кушкаен.
Сөю таптым, тагын дуслар таптым,
Сәбәп булды телем-дускаем.

●

— Әйтче, гармун, нигә көйләмисең,
Син торасың тынып почмакта?
Сихри моңнарыңны тыңлап үстем,
Гашыйк идем сиңа яшь чактан.
— Кайгы-моңнарымны сөйли алмыйм
Зәңгәр кичтә искән җилләргә.
Яшь уйнаучым көрәш кырларыннан
Кайтмый калды туган җирләргә.

●

Яр буена барып чишенде дә
Колачларын җәеп бер мәлне,
Йөгереп барып суга ташланды кыз,
Көмеш күлдә дулкын тирбәлде.
Күңел дәрья, ул гүзәл кыз, гүя,
Күңелемә минем сикерде.
Тынгы белми хәзер дулкынланам,
Давылдагы диңгез шикелле.

●

Әйтер сүзләремне әйтә алмыйм...
Кыюланган булып килә дә.
Гүя, син җир, ә мин юлдашыңмын,
Кая барма, йөрим тирәңдә.
Ераклаша алмыйм, якынаймыйм,
Якын килсәм... (Ах, бу мөмкинме!)
Ялкынланып янар идем кебек...
Атылып янган йолдыз шикелле.

## *ЛӘБИБӘ ИХСАНОВАГА 60 ЯШЬ*

# ИХЛАСЛЫК



Әгәр дә без, балачак тәэсирләрен күңелебездә якты яисә яман истәлекләр сыйфатында гына саклап йөрү белән чикләнмичә, аларны көндәлек тормышыбызда сабак итеп, урыны һәм вакыты белән кирәгенчә куллана белсәк, балалар тәрбияләгәндә үзебезне дә, сабыйларыбызны да никадәрле хатадан йолып кала алган булыр идек.

Ләбибә Ихсанова үзенең иҗатында менә шушы хакыйкатьне тирәнтен аңлап эш итә. Ул табигый рәвештә сабыйлар дөньясына кайта белә. Аның әсәрләрендәге геройлар нәкъ үз дөньяларында яшиләр, үз холыкларына ятышлы рәвештә хәрәкәт итәләр. Ә бит чыннан да, балаларның һәр кыланышында, олылар күзләгәннән караганда беркатлырак күренсә дә, самими бер логика, ихласлык була. «Космонавтлар урамы» дигән повестьның төп геройларыннан берсе Алик, мәсәлән, үскәч космонавт булырга хыяллана. Җиденче класс малае инде хәзер үк үзенең бөтен тырышлыгын шушы максатка юнәлтә. Физкультура түгәрәгенә йөри, космонавтикага кагылышлы әдәбият белән кызыксына, Юрий Гагаринга хат яза... Кыскасы, аның өчен хәзер космонавтлыкка әзерләнүдән дә мөһимрәк шөгыль юк. Классташлары пыр тузып өмәдә йөргән бер вакытта ул, ялгызлыкка, тынлыкка күнегәм дип, караңгы бүлмәләргә кереп бикләнә, сәгатьләр буе шунда утыра. Дөрес, ул моның бик үк килешә торган эш түгеллеген дә аңлый. Тик биредә бит әле икенче төрле логика да бар — балалар логикасы: шундый матур кояшлы көндә үз теләгең белән ябылып ятуы әллә ансатмы? Моның өчен дә батырлык, түземлек кирәк ич.

Әсәрдән күренгәнчә, бу һич тә Аликның ялкаулыгыннан яисә кирелегеннән түгел, ә балаларча гөнаһсыз бер адым гына. Язучының «Саралан малайлары» дигән повестендагы Нияз белән дә шундыйрак хәл. Ләкин аның характеры катлаулырак, фикер сөрешләре һәм шуннан килеп чыккан үзенчәлекләре дә каршылыклы.

«Саралан малайлары» Ләбибә Ихсанованың иң уңышлы әсәрләреннән берсе булганлыктан, аңа киңрәк тукталу да зыян итмәс кебек.

Әдәбият матур итеп хыяллана белүче, шигъри күңелле иҗат кешеләре тәрбияләргә тиеш, дибез. Ләбибә Ихсанованың бу повесте да, башка әсәрләре кебек үк, нәкъ менә шушы максатка хезмәт итә. Ниләр генә эшләмиләр дә, нинди генә хәлгә тарып бетми Саралан малайлары! Алар Шәймәрдән картка бакча каравылларга да булышалар, печән дә чабалар, колхоз байлыгын сакларга дип куелган каравылчыларның уяулыгын да «сыныйлар», трактор йөртергә өйрәнәләр, хәтта үзләренә мөстәкыйль бер колхоз да төзиләр. Болар барысы да чын күңелдән, ихластан эшләнә. Бер үк вакытта уен да, күмәк хезмәт тә булган шул вакыйгалар кочагында малайларның моңарчы тирәнгәрәк яшереп йөрткән холыклары калкып чыга, характерлары төсмерләнә башлый. Укучы күз алдыннан һәрнәрсәне төптән уйлап, җае белән хәл итәргә яратучы тыйнак табигатьле Шамил, авылдагы бөтен хәлне белеп, минуты-сәгате белән иптәшләренә җиткереп торучы һәм шуның өчен «Соңгы хәбәрләр» дигән кушамат алган Фәрит, аю күк көчле, әмма аумакайрак холыклы Сәлмән, тәвәккәл, бул-

дыклы, ләкин үзсүзле, өстенлек дәгъвалаучы Нияз һәм башкалар уза. Шулар белән янәшә бригадир ярдәмчесе, Шамилнең апасы Кәримә дә матур гына чагылып үтә, һәркайсының үз йөзе, үз сурәте.

Әйе, тегеяки бу сыйфаты, үзенчәлекле характеры белән укучы күңелен җәлеп итәрдәй геройлар байтак бу әсәрдә. Шулай да йөкнең иң авырын, вазифаларның иң катлаулысын язучы Нияз җилкәсенә салган. Ул повестьның буеннан-буена күздән югалмый, оеткы, катализатор хезмәтен үтәп, әсәрдәге конфликтны куерта һәм шуның белән «Саралан малайлары»ның тәрбияви әһәмиятен бермә-бер арттыра, уку өчен кызыклы итә. Бу уңайдан французларның юморист һәм сатирик художнигы Жан Эффель рәсемнәре хәтергә килә. Аның рәсемнәрендә Иблис, ходайның бөтен эшенә тыгылып, атлаган саен зыян китереп йөри. Ниязның да кайбер кыланышлары әнә шуны хәтерләтә.

Печәнчеләр бригадасына җитәкче кирәк булгач, кыюлыгы, җитезлеге белән масаеп йөргән Нияз үзен бригадир итеп сайларлар дип өметләнә. Әмма эш ул уйлаганча барып чыкмый. Шуннан соң малай, ике кулын чалбар кесәсенә тыгып, ялыныр-сыз әле дигәндәй, эре генә атлап иптәшләре яныннан китеп бара.

Әмма малайлар Ниязга ялынмыйлар, эшләре аннан башка да гөрләп бара. Шәймәрдән бабайдан чалгы тотарга да өйрәнәләр, печәнен дә рәхәтләнеп чабалар. Тик соңрак бер хәл борчый башлый аларны: печәнчеләрдән кала бүтәннәргә, бигрәк тә кызларга эш юк. Уйлана торгач, укучылар местәкыйль бер колхоз төзергә булалар. Чыннан да, колхозда эш күп ич ул. Тик нидән башларга? Әлбәттә инде, идарәдән! Шамилләр бакчасындагы корт өе идарә өчен суйган да каплаган ич...

Ә Нияз? «Ул да төшеп калганнардан түгел, колхоздан да болайракны уйлап табар әле ул. Барысының да исе китәр». Шулай дип хыялланып йөри торгач, чыннан да, башына бер тәвәккәл уй килә моның. Әгәр колхоз милкен каравыллаучының уяулыгын тикшерсә, Шамилләрнең печән чабуына тормасмыни? Бу эшкә ул печәнчеләр бригадасында әйбәт кенә эшләп йөргән Сәлмәнне дә күндерә, һәм алар икәүләп төнге походка чыгып китәләр. Әмма авантюра барып чыкмый, Сәлмән яшелчә бакчасын каравыллаучы Шәймәрдән бабай кулына эләгеп, хур була, ә Нияз үзе чак кына качып котыла.

Ләкин Нияз барыбер бирешергә теләми, берничә көннән соң, батырлык күрсәтергә теләп, авылдан шактый ерактагы кара урманга барырга уйлый. Иптәш тә, минем батырлыкка шаһит та булырлар дип, күршеләрендәге игезәк малайлар Илдус белән Рафаэльне дә ияртә. Бер уңайдан укучыларның колхоз идарәсенә барометр урынына элеп куйган компасларын да алып китә, урманда кирәк булуы бар бит...

Тик малайлар адашалар. Төрле мәҗараларга тарып, ике тәүлек буталып йөргәннән соң гына, нефть эзләүче геологларга очрап, зур бәлаләрдән котылып калалар.

Ниһаять, инде Нияз да уйга кала, кылганнары өчен үкенә башлый. Әнә шулай әкренләп, реаль тормышның ачы сабакларын татый-татый, иптәшләре йөргән сукмакка төшә һәм инде аңлы рәвештә коллектив ихтыярына буйсына.

Үсмерләргә сабырсызлык хас. Аларга яшьтәшләре арасында тизрәк танылу, шәхес буларак үзен тизрәк раслау вәсвәсәсе тынгы бирми. Әлеге тыелгысыз омтылыш аркасында ни хәтле конфликт, хата килеп чыга, акылга бик сыймый торган ни кадәрле күңелсез нәрсәләр эшләнә. Язучы Нияз образы аша әнә шуны ышандырырлык итеп күрсәтә.

Ләбибә Ихсанованың күпчелек әсәрләре кеше гомеренең мәктәп елларына туры килә торган чорына багышланган. Бу аңлашыла да. Чөнки әлеге чорда балалар һәм үсмерләр аеруча актив, көчләре, ни дә булса майтару теләге һәркайсында ташып тора. Ләкин бу активлыкның кыйбласы төрле балада төрлечә. Аны баштан ук дөрес билгеләргә кирәк. Ә үсеп килүче яшь кеше өчен бу бер дә җиңел түгел. Язучы, үрнәк һәм маяк булырдай геройлар иҗат итеп, яшь буынны коммунистик тәрбияләүгә зур хезмәт куя.

«Саралан малайлары» шикелле үк отышлы һәм күләмле тагын бер әсәргә тукталасы килә. «Гөлләр кояшка үрелә» дип атала ул. Язучы «Көмеш елга», «Җир астында җиде көн» дигән әсәрләре белән татар әдәбиятында сәяхәтләр жанрын тудырган иде. «Космонавтлар урамы», «Саралан малайлары», «Авылдашлар», «Үкенү», «Тал бөгелә» һәм башка күп кенә повестьлары, хикәяләре белән ул, Гайдар һәм Алиш традиция-

[т]арен дәвам итеп, дуслык, иптәшлек, батырлык, намуслылык, табигатькә акыллы мө[на]сәбәт, хезмәткә мәхәббәт темаларын үстерүгә зур өлеш кертте. «Гөлләр кояшка [т]арый» дигән әсәре белән исә Ләбибә Ихсанова үзенең иҗат диапазонын тагын да [к]иңәйтеп җибәрде.

Повесть революция алды елларын, Казанда Октябрь көннәрен һәм революциядән [с]оң татар милләтчеләренең, дин башлыкларының үзара берләшеп, Советларга каршы [ф]етнә оештырып йөргән вакытларын сурәтли. Әсәрнең яшь геройлары — Мәтали, [Г]азизә, Гапсаттар, Закирәләр дә революция дошманнарына каршы алгы сызыкта то[р]ып көрәшүче әтиләренә, абый һәм апаларына кулларыннан килгәнчә ярдәм итәләр. [Б]алалар шушы кырыс елларда да, кояшка үрләгән гөлләр кебек, яктыга, белемгә [о]мтылалар, революция алып килгән саф җилләрдән, совет власте биргән игелекләрдән [к]анатланып, революциянең чын солдатлары, илнең ышанычлы хуҗалары булып үсәргә [х]ыялланалар. Әсәрне укып чыкканнан соң, язучының вакыйгаларны, геройларның ки[ч]ерешләрен оста тотып алган детальләр аша сурәтләве аркасында, аларның бу ка[н]атлы, изге хыяллары тормышка ашачагына шик калмый. Әнә шундый ышандыру [к]өченә ия булганлыктан, Ләбибә Ихсанованың бу повесте татар совет балалар про[з]асында тарихи-революцион теманы яктырткан иң яхшы әсәрләр рәтеннән урын [а]лды. Ул СССР язучыларының VI съездында да югары бәяләнде.

Балалар әдәбиятының үзенә генә хас үзенчәлекләре бар. Шуны сизмәгән әдип балалар язучысы була алмый. Ул теләсә нинди вакыйга, кешенең теләсә нинди кат[л]аулы кичерешләре турында бала дөрес аңларлык итеп, ятышлы алымын һәм фор[м]асын табып сөйли белергә тиеш. Бу да аз, син әле тагын шул сөйләгәннәрнең артына яшеренә дә бел, укучы сине күрмәсен, вакыйгалар, вакыйгалардан алынган тәэсирләр үзләре турында барысын да үзләре сөйләсеннәр. Моның өчен балалар психологиясен тирәнтен аңлау таләп ителә икән, кыланып түгел, ә чын мәгънәсендә, табигый рәвештә сабыйлыкка яисә үсмерлеккә кайта белергә кирәк. Ләбибә Ихсанова хәзер совет язучыларының әнә шундый осталыкка ирешкәннәре сафында атлый. Аның әсәрләре үзәк матбугатта да, әдәби мәҗлесләребезнең зур трибуналарыннан да югары бәяләнде.

Әлбәттә, язучы бу уңышларга кинәт кенә ирешмәде. Без дә биредә аның иң өлгергән, язучы буларак инде тәмам җитлеккән чорда иҗат ителгән яисә кабат кайтып эшләнгән әсәрләре турында сүз алып бардык. Ихсанованың иҗатын даими күзәтеп барган кеше «Саралан малайлары»ның «Нияз», «Нияз мәктәптә» дигән повестьларын берләштереп, яңадан язып чыгу нәтиҗәсендә туганлыгын сизми калмас. Заманында (1948 ел) Мәгариф министрлыгы, китап нәшрияты, Татарстан Язучылар союзы үткәргән конкурста һәм Бөтенсоюз конкурсында бүләкләнгән «Көмеш елга» хикәясе, аннан соңрак иҗат ителгән «Җир астында җиде көн» повесте белән дә шундый ук хәл. Ләбибә аларны да өр-яңадан язып чыкты һәм дөрес эшләде. Югыйсә ул, «Көмеш елга»дагы Зөфәргә, «Җир астында җиде көн»дәге Шәүкәткә унбер-унике яшьлек малайларның хәленнән килмәслек йөк күтәртеп, белемнәрен, тормыш тәҗрибәләрен искә алмыйча, олылар гына әйтерлек сүзләр сөйләтеп, әсәрләрнең ышандыру көчен шактый киметкән иде. Болар барысы да язучының үз иҗатына карата таләпчән булуы турында сөйли.

Ләбибә Ихсанова иҗатында татар балалар прозасының бөтен уңышлары һәм кимчелекләре белән, кырык еллык тарихы, үсеш этаплары чагыла. Әйтик, шул ук «Көмеш елга», «Җир астында җиде көн» һәм тагын кайбер әсәрләренең беренче вариантларын, хәзерге үлчәүгә салып карасак, ничек булыр иде икән? Аерма шактый булачак. Шуңа күрә Ләбибә Ихсанова иҗатына багышланган махсус бер хезмәт язылса, анда бик кызыклы күзәтүләр керер иде. Үзенең иҗатын тулысы белән диярлек балалар һәм үсмерләр прозасына багышлаган бердәнбер язучыбыз бит ул хәзер.

Ә гомумән алганда безнең балалар прозасы шактый бай. Аның тарихы бик еракларга килә. Шуңа карамастан, әлеге көнгә кадәр балалар прозасына атап язылган бер генә хезмәт тә юк. Илебездәге күпчелек әдәбиятлар белән ярышырдай әдәбиятыбызның зур бер тармагы булган балалар әдәбияты моны кичерә алмый, әлбәттә.

...Сүзне балачак хатирәләреннән, балачакта сеңеп калган тәэсирләрнең кеше өчен ни дәрәҗәдә әһәмиятле булуыннан башлаган идек. Ул хатирә-истәлекләргә, тәэсирләргә тора-бара белем, тормыш тәҗрибәсе дә өстәлә һәм алар язучының бөтен

иҗатын бизәп, туендырып киләләр. Болар Ләбибә Ихсанова иҗатына да хас нәрсәләр. Аның биографиясе белән азмы-күпме таныш булган кеше моны бик ачык сизә.

Авыл баласының иң зур бәхете — табигатькә якын булуындадыр. Бусага атлап чыгу белән аны, яшел яфраклары белән лепердәп, ботакларын киң җәеп утырган өянкеләр, ак күбеккә күмелгән шомырт, миләш, баланнар көтеп тора. Шунда ук уйнак-шаян бәтиләр, яшь бозаулар, бибиләре белән каз-үрдәкләр, мәмәйләр һәм тагын әллә ниләр... Болар инде сиңа китап битләренә төшерелгән рәсемнәр генә түгел, һәркайсының җаны бар, теле бар... Авылны икегә ярып инеш агып ята. Анда исә үзенә бер дөнья. Авыл очыннан ук куе әрәмәлекләр башлана. Шуңа ук ялганып диярлек тайга урманнары китә. Ерак та түгел Вятка суы... Ләбибә Ихсановага табигатьнең әнә шундый бай һәм ямьле бер почмагына утырган Түбән Шөн авылында (Киров өлкәсе) үсәргә насыйп булган. Ул, телдә генә түгел, ә чын мәгънәсендә сәләтле, тирән белемле, сабыйлар күңелен бик нечкәдән аңлаучы педагоглар булган Ленин орденлы Гыйлембану апа һәм Хезмәт Кызыл Байрагы орденлы Фаиз абый гаиләсендә тууы белән дә бәхетле.

Ишле һәм тату гаиләдә, киң карашлы ата-ана кулында тәрбия алгангадыр, Ләбибә хезмәт сөючән, тыйнак, сабыр, әмма максатка омтылучан кыз булып үсә. Югары классларга күчкәч ул пионер вожатые булып эшли. Унынчы классны тәмамлау белән аны бригадир ярдәмчесе итеп куялар, комсомол оешмасы секретаре итеп сайлыйлар. Шунысы гыйбрәтле, ул сайланганда, егетләр сугышка киткәч, кызлар кайсы кая таралышкан, оешмада барлыгы өч кенә кеше калган була. Комсомол оешмасы эшен яңабаштан торгызырга туры килә. Һәм ул торгыза да. Ел тулыр-тулмаста оешмада комсомоллар саны егерме биш кешегә җитә. Сугыш чорында, берне биш итәргә кирәк чакта, бер йодрыкка тупланган бу көч колхоз өчен нык терәк була.

Булачак әдипнең тормыш юлы әнә шундый җитди сынаулардан башлана. Аннары Казан дәүләт университетының география факультетындагы студент еллары, шул ук чорда әдәбиятка таба ясалган беренче адымнар... Беренче булсалар да, ышанычлы — «Көмеш елга», «Җир астында җиде көн», кебек өметле адымнар иде алар. Әсәрләрнең һәр икесе балачагында, мәктәп һәм студент елларында язучы үзе кичергән вакыйгаларга, шул вакыйгалардан алган тәэсирләргә нигезләнеп язылган. Аларда сурәтләнгән табигать күренешләре дә Л. Ихсанованың туган авылы Түбән Шөн тирәләрен хәтерләтә. Көмеш елга буена практикага килгән шигъри күңелле студент кыз Саниядә Ләбибәнең үз чалымнарын сизәсең. «Саралан малайлары» повестендагы бригадир ярдәмчесе Кәримә образыннан да без авторның үзен таныйбыз.

Язучының башка әсәрләрендә дә биографик моментлар бик оста файдаланыла. Алар күзгә әллә ни бәрелеп тормыйча, вакыйгаларга табигый рәвештә үрелеп, сабыйларның, үсмерләрнең үзләренә хас дөнья тудырырга ярдәм итәләр. Шуңа күрә балалар әлеге хикәя һәм повестьларны бирелеп укыйлар да.

Ләбибә Ихсанова әсәрләрен башка милләт балалары да бер үк дәрәҗәдә яраталар. Алар йөзләрчә мең тираж белән рус, украин, эстон, башкорт, чуваш телләренә тәрҗемә ителделәр. Ул хәзер утыздан артык китапның авторы. Һәм аларның барысын да диярлек тормыштан аерылмыйча кайда да булса эшли-эшли язды. Аның бай хезмәт биографиясе бар. Университетны тәмамлагач та Ихсанова Татарстан радио комитетының балалар өчен тапшырулар редакциясендә, «Татарстан яшьләре» газетасында, китап нәшриятында эшләде. Ул «Пионер» (хәзерге «Ялкын») журналының баш редакторы һәм озак еллар «Казан утлары» журналының җаваплы секретаре булды. Шуның өстенә Ләбибә Ихсанова җәмәгать эшләрендә дә актив катнашып килә. Ул Татарстан Язучылар союзы идарәсе члены, Язучылар союзының партоешма секретаре булды, РСФСР язучыларының оештыру съездында, СССР язучыларының IV, VI съездларында делегат булып катнашты. Ике тапкыр рәттән Халык депутатларының Казан шәһәр Советына сайланды. Озак вакытлар Язучылар союзының балалар әдәбияты секциясен җитәкләде. Хәзерге вакытта Ләбибә Ихсанова СССР Язучылар союзының балалар һәм яшүсмерләр әдәбияты буенча Совет члены буларак зур эшләр алып бара.

Ләбибә Ихсанованың публицистика өлкәсендә күрсәткән хезмәтләре дә мактауга һәм зур игътибарга лаек. Ул иҗтимагый-политик темаларга, әдәбият һәм сәнгать мәсьәләләренә, көндәлек вакыйгаларга кагылышлы бик күп мәкаләләр, очерклар,

каләмдәшләренең аерым әсәрләренә рецензияләр язды һәм яза, заманыбызның актуаль проблемаларына карата радиодан, телевидениедән чыгышлар ясый. Болар барысы да язучының, коммунистның иҗтимагый йөзен күрсәтүче, тормыштагы активлыгын раслаучы күркәм сыйфатлар.

Язучының иҗтимагый тормыштагы активлыгы, әдәбият өлкәсендәге уңышлары югары бәяләнде. Ул В. И. Ленинның тууына 100 ел тулу уңае белән «Хезмәттәге батырлык өчен» медаленә, ТАССР Верховный Советы, КПСС өлкә комитеты һәм ТАССР Министрлар Советының Почет грамотасы, Татарстанның атказанган культура работнигы дигән мактаулы исемгә лаек булды.

Ләбибә Ихсанова хәзер дә бик бирелеп, колач җәеп иҗат итә. Күтәренке, романтик рухлы, балалар күңеле кебек якты әсәрләре белән яшь дусларын өледән-өле сөендереп тора ул. Аларны гына түгел — безне, өлкәннәрне дә, кайчандыр үзебез яшәгән сабыйлар дөньясына алып кайтып, гомербезнең иң шатлыклы, иң самими чорында кичергән куанычларны кабат яңартып бик еш шатландыра язучы.

ГАБДУЛЛА ШӘРӘФИ.

## Ләбибә Ихсанова

# СӘГАТЬ

ХИКӘЯ



Физкультура дәресендә Гөлгенәнең сәгате югалды.

Күңеле сизгәндәй, өстен алыштырып килгәнче үк, алъяпкыч кесәсенә кулын тыгып караган иде — әче жу-у итте. Тыны кысылып, күз алдында яшелле-сарылы бөҗралар әйләнде, чигә тамырына кан бәрә башлады, тәне бер кызды, бер калтыранды. Аннары, тын алыр хәлгә килгәч, ашыгып-кабаланып эзли башлады. Спорт залының швед стенкасы куелган ягына каршы кыска аяклы эскәмияләр тезелгән иде. Дәрескә кергәч, укучылар киемнәрен шунда куялар, талчыгып китсәләр, утырып ял итәләр. Гөлгенә чишенер алдыннан сәгатен кая куярга белми аптырады. Гөл яфрагы кадәр генә кулъяулыгына төреп, алъяпкыч кесәсенә салган кебек иде. Күңелгә килгән алга килә, диләр бит, кулъяулыгы шунда, ә сәгате юк. Аның үзеннән-үзе төшеп югалуына ышанмады Гөлгенә, шулай да эскәмия асларын тикшереп чыгасы итте, бала-чага аягы белән тапталып, урыны-урыны белән пеләшләнеп беткән келәм читен дә күтәреп карады, салып куйган аяк киемнәренә хәтле урыннарыннан кузгатты. Ике-өч көн буена җыелмаган залның мамыклы тузаныннан башка кулына берни дә эләкмәде. Кызның күңеленә башта ук кереп утырган әшәке уй тәмам төпләнеп, тамыр җәеп өлгергән иде инде. Башкача булуы мөмкин дип уйламады да, уйларга да теләмәде Гөлгенә. Баш миен бораулап, һаман бер сүз әйләнде дә әйләнде: алганнар! Алганнар, алганнар!..

Тотып кына кайсысыннан шикләнергә дә белмичә, классташларының барысына да ачу белән карады. Ә тегеләрнең анда-монда эшләре юк, алдагы дәрескә җитешергә дип, ашыга-ашыга киенеп яталар. Физик күнегүләрдән кайнарланган каннарын тыя алмыйча, бер уңайдан

төрткәләшеп алырга да өлгерәләр, кулларын йодрыклап, бокслашкан да булалар, ә кызлар, чытлыкланып, уч төбе кадәр күзгедән чиратлашып карый-карый, кашларын, күзләрен төзәтеп маташалар, үзләре чыркылдап көләләр, кычкырып сөйләшәләр. Гөлгенәнең кайгысымыни соң аларда.

Фәридә инде киенеп өлгергән, дымлы маңгаена сибелеп төшкән аксыл-сары чәчләрен кайнар сулышы белән өргәләп, җиң очы сәдәфләрен төймәләп тора иде. Гөлгенәнең:

— Сәгатемне күрмәдеңме? — дигән соравына шаярып җавап кайтарды:

— Күрдем, ишектән чыгып бара иде.

— Ахмак!

Ул шуннан соң гына кызның йөзенә игътибар итте һәм урынсыз шаяруын аңлап:

— Нинди сәгать? — дип сорады.

— Нинди, нинди,— диде Гөлгенә үртәлеп, — сәгатемне алганнар!

Гөлгенәнең беләгендәге алтын сәгатьне күргәне бар иде Фәридәнең. Ләкин аны кемнең дә булса алу ихтималын башына да китермәде.

— Кемгә кирәк ул. Идәнгә төшкәндер, яхшылап кара.

Аның гөнаһсыз күңеле тыныч иде әле һәм, үзенең шушы тынычлыгын Гөлгенәгә дә бирергә теләгәндәй, салмак кына аңлатырга керешге:

— Әллә берәрсе шаярып яшергәнме? Теге вакытта Алик химия дәфтәреңне алып ни эшләтте...

Дәфтәр битен тутырып шигырь язып бирде, дип әйтергә теләгән иде, өлгерә алмый калды. Үзе янганда башкалар да борчак кебек куырылырга тиеш, дип уйлаган кызның бу сабырлык ачуын гына кабартты. Кыпкызыл булып бүртенгән Гөлгенә:

— Сөйләп торган булмасана! Дәфтәрмени ул, сәгать бит, алтын сәгать! — дип, үзен-үзе белештермичә кычкырып җибәрде.

Фәридәнең яңагына чалтыратып суктылармыни, ике бите, колак яфраклары ут булып яна башлады. Җыерылган кашларының шәүләсе төшкәндәй, күзендә нурлар сүнде. Гөлгенәнең тавышына тирә-юньдәгеләр дә әйләнеп карады, ни булганын белергә теләү нияте белән якынрак елыша башладылар. Фәридә, елап җибәрүдән куркып, иренен тешләде, үзе Гөлгенәгә әйтергә ачулы сүзләр эзләде, тик башына берни килмәде, телен әйләндереп сүз әйтә алмады.

Ул арада Гөлгенә йөгереп барып ишек янына басты да, берегезне дә чыгармыйм дигәндәй, кулларын як-якка җәеп җибәрде.

— Туктагыз!

Кызның тавышы каты иде, колак пәрдәләрен ертып керерлек ачы иде, спорт залының тимер челтәр корылган тәрәзәләренә бәрелеп, бик озак чыңлап торды. Классташлары шаулашудан туктадылар, нәрсә булырын көткән кызыксыну белән кызның шашкан кыяфәтенә аптырап карап тордылар. Аптырарлык та иде шул Гөлгенәнең кыяфәте. Яңаклары, муены тимгел-тимгел булып кызарган, шар ачылган күзләрендә яңгыр алдының караңгылыгы бар.

— Туктагыз! — дип кабатлады ул, каты кычкырудан тамагы карлыгып. — Мин... минем алтын сәгатем югалды. Шул табылмыйча, берегез дә моннан чыкмыйсыз!

Гөлгенәнең сүзе залдагыларны әйтерсең лә йокыдан уятты. Башта берсе, аннан икенчесе, өченчесе тавыш бирүгә кинәт кенә бака түе башланды.

— Оһ-һо!

— Безнең ни гаебебез бар?

— Югалткан кеше үзе эзләсен.

— Шаярып алсагыз, бирегез, егетләр! Звонок булды.

— Тарихка соңга калабыз.

— Тарихка керәбез дә керәбез инде болай булгач.
— Кит ишек янында. Әллә тентергә торасыңмы?
— Бирмәсәгез, тентермен дә.
— Вот еще!
— Позо-ор!

Әле генә ишеткәннәренә ышанмыйча, уенын-чынын бер итеп, җинелчә генә сүз атышкан егетләр-кызлар Гөлгенәнең авызыннан шундый сүз чыккач, кинәт кенә бик тә хурланып, моңа кадәр күрелмәгән, алар арасында һичкайчан булмаган, әгәр шушында ачыкланмаса, барысына да кара тап булып төшәчәк аяныч бер хәл алдында торганлыкларын абайлап, җитдиләнеп киттеләр. Кая ул шаярып сүз кату, алар хәтта берберләренә күтәрелеп карарга да уңайсызланалар, ялгышып кына берәрсенең күз карашын тотып алсалар, сынап карамыймы дип шикләнәләр иде. Һәм менә шушы минутта әле генә гөж килеп торган залда шундый тынлык урнашты ки, Гөлгенәнең сәгате аяк астында текелдәп ятса, берәү дә ишетми калмас иде мөгаен. Шул вакыт Фәридә үзенең янәшәсендә басып торган Аликның, буыла язып:

— Гөлгенә-ә! — дип пышылдавын ишетте.

Баскетбол командасына яраклык озын буе белән иптәшләреннән аерылып торган егетнең кыяфәте әле генә йокысыннан уянган көйсез баланы хәтерләтә иде. Фәридә аңламады: Гөлгенәне яклый идеме ул, әллә аның калын иреннәре хурланудан шулай дерелди идеме. Кызның уенча, Алик хәзер Гөлгенә янына барып басарга тиеш иде. Әгәр шулай булса, әгәр дә Алик шушы күңелсез мәсьәләне чишәргә булышса, Фәридәнең үзенең дә, башкаларның да баш очында асылынып торган болыт кебек кара шикне алып ташлар, яшен яшьнәп, күк күкрәми калуына шатлангандай, барысы да җиңеләеп китәр, бер-берсенең күзенә сынап караулардан котылыр кебек иде. Уйлавын шулай уйласа да, аның бу егетне бер генә дә Гөлгенә янына бастырасы, шушы эшәке эшкә катнаштырасы, түбәнсетәсе килми иде. Каш астыннан сөзеп карап торган егетнең эре-эре атлап килүен һәм әле һаман ишеккә аркылы торган Гөлгенәнең кулын ансат кына сыпырып төшерүен күргәч, җиңел сулап куйды.

— Гөлгенә! Син нишлисең? Акылыңа кил! — диде егет ачыргаланып. Аликның тавышыннан кызның бу эшенә гаҗәпләнү дә, шушы хәлдән аны ничек коткарырга белмичә аптырап калу да, иптәшләреннән гафу үтен дип, ялыну-ялваруны да аңлап булыр иде. Аликны тынычландыру өчен Гөлгенәнең бер жылы сүзе, алай да булмаса, ишек янынннан бер адым, бары бер генә адым читкә атлавы кирәк иде. Ләкин Гөлгенә аны эшләмәде, киресенчә, ачудан шартларга җиткән күзләрен төбәп:

— Ә нигә сәгатьне бирмиләр! — дип кычкырды.

Алик ярсып кулын күтәрде. Барысы да, суга инде бу дип көтеп торганда, кыз, куркынып, читкәрәк тайпылды. Ләкин егет үзен тыеп кала белде, кызга булган ачуын алырга теләгәндәй, бар көче белән ишеккә китереп типте. Өч метрлы авыр ишек, тупсасыннан атылып чыгардай булып шартлап ачылды, һәм Алик, коридордагы балаларга бәрелә-сугыла, китеп барды.

Алик артыннан ишек ябылгач, иптәшләреннән гафу үтенгәндәй, якягына карана-карана Рәсим дә чыгып китте. Берәүнең дә моңа исе китмәде. Киресенчә, җан дусты артыннан иярмичә биредә торып калса, бу үзе гаҗәп тоелыр иде. Шуның өчен артыннан:

— Атла, атла, адьютант, сыпырт! — дип кенә калдылар.

Ләкин буа ерылган иде инде. Нинди дер кодрәт белән генә тыелып торган көчне хәзер берәү дә тотып тора алмаячак. Залдагылар берьюлы хәрәкәткә килделәр, менә-менә ярылырга тиеш булган бомбадан качкандай, ишеккә ташландылар. Килеп тыгылган төркем астында

изелмәс өчен, Гөлгенәгә ишек янынннан китүдән башка чара калмаган иде. Минут та үтмәгәндер, зыңгылдап торган буш залда, кеп-кечкенә булып, үз кайгысына буылып, Гөлгенә япа-ялгызы басып калды.

Фәридәнең аны юатасы, хәтта сәгатен эзләшәсе килгән иде. Кешечә иплэп кенә әйткән булса, башкалар да аның хәленә керерләр иде, мөгаен. Шундый кыйммәтле әйберне югалту уен эш түгел. Гөлгенәнең унынчы классны бетергән көненә бүләккә дип алып куелгаң сәгать икәнен дә, түземсез кызның ул сәгатьне әти-әнисеннән яшереп тагып йөрүен дә, хәзер менә шул табылмаса, җавап бирергә кирәклеген дә белә иде Фәридә. Ә җавабы, аның уенча, җиңел булмаска тиеш. Чөнки Гөлгенәләр гаиләсе аңа бик билгеле, бу гаиләдә сәгать хәтле сәгать түгел — җитмәсә алтын сәгать әле — энә дә санаулы икәнен белә ул. Алар күршеләр, ишекләре ишеккә орынып кына тора. Әллә ни керешеп йөрмиләр йөрүен, дөресрәге, бөтенләй керешмиләр. Шулай да күп кирәкмени кемнең кем икәнен белергә.

Була бит шундый кешеләр, гомер буе бер йортта яшәсәләр дә, күршеләренең исемен белмиләр. Ишегалдының бер үк ташларын шомартып бетерсәләр дә, узганда-барганда, ичмасам, баш кагып кына да да исәнләшмиләр. Гөлгенәнең әти-әнисен дә аларның биш катлы, дүрт подъездлы йортларында бик аз гына кеше белә, белгәннәре дә аларны исемнәре белән түгел, чит кешеләр кебек итеп, Касыймовлар дип йөртәләр. Касыймовлар берәү белән дә аралашмый, күршегә йомышка керми, үзләре дә йомыш бирми торган карун кешеләр иде. Бүтәнне әйтәсе дә юк, Фәридәнең башкалар турында гел яхшы уйда гына булган әнисе, мәсәлән, шырпы-тоз ише вак-төяк кирәк булганда бишенче катка хәтле менсә менеп китәр, кыенсынмас, әмма орынып торган Касыймовларга кагылмас.

Фәридәнең генә ишегенә бишәр йозак салган «оҗмах»ның эчен кереп күрәсе килгән чаклары бар иде. Әмма ике яктан да тыю катгый булды. Бердән, кызның әнисе кеше йөдәтеп йөрмәскә кушты, икенчедән, Гөлгенәнең үзенә «бала-чага аягын бастыру» ник тыелды. Күршедә генә яшәсәләр дә, ун ел буе бер класста укысалар да, Фәридәнең Гөлгенәләр өенә кереп караганы булмады. Хәер, аның алдында да бер ачылды бу серле ишек. «Мең дә бер кичә» әкиятендәге кебек «сим-сим, ач!» дип әйтмәсә дә, ачылып китте. Тормыштагы гап-гади бер сәбәп булды аның ачкычы. Җиденчедәме-сигезенчедәме укыган чаклары иде. Гөлгенә дәрескә килмәде. Ни өчен килмәвен белүне укытучы Фәридәдән үтенде.

Биш йозакның бишесен дә челтерәтеп борып бетергәнче, ишек артында шактый озак басып торырга туры килде кызга. Бераздан аркылы салынган чылбыр киңлегендә генә ишек ачылды. Шушы тар ярыктан озынча булып хуҗа хатынның кырыс йөзе күренде. Бигрәк тә аның без кебек чәнчеп караган күзләре күңелдә, нигә килдем, дигән үкенечле уй кузгата иде. Әгәр укытучыга биргән сүзе булмаса, Фәридә кермәс, кире чигенер иде бу ишектән. Шундый теләк булса да, кире борылмады ул, юкка йөрмим бит, классташым хәлен белергә керәм, шикле күз белән карарга ни хакы бар дигәндәй, чылбыры ычкындырылган ишекне зори зур ачып, кыю атлап керде. Хуҗа хатын исә кызны ишектән уздырса да, ялгышып та алга атлама дигәндәй, олы гәүдәсе белән каршында басып калды. Гөлгенәне чакырып китергәч кенә, озын халат итәкләрен җилфердәтеп, залга кереп китте. Ишек төбендәге трюмодан залның бер почмагы күренеп тора иде. Фәридә үзе Гөлгенә белән сөйләшә, үзенең күзе көзгедә. Салават күперенең җиде төрле төсен балкытып янган бәллүр люстраны, инкрустацияләп эшләнгән затлы шкафның бер бүлемен, идәндәге һәм стенадагы чәчәкле зур келәмнәрне исе китеп карап торды ул. Күзне иркәләгән шушы матурлыктан аерылырга

теләмичә, Гөлгенәне озаграк сөйләштерергә теләде. Ләкин төсле телевизор каршындагы креслога чумып утырган Касыймова кызын бик тиз чакырып алды:

— Урыныңа кереп ят, Гөлли, өзлегерсең.

Өзлегерлек каты авыру түгел иде Гөлгенә. Иртәгесен үк укырга килде. Әнисенең сүзе кызым сиңа әйтәм, киленем син тыңла дигәндәй, Фәридәгә чыгып китәргә кушуы иде.

«Урыныңа кереп ят, Гөлли!» Шушы сүз белән генә озаткан булсалар, ул хәтле үк хурланмас иде әле Фәридә. Ишеккә таба борылганда тагын бер тапкыр көзгегә караган иде, Касыймованың сәер кыланышын күреп алды: кершән-пудра, затлы духи шешәләре белән тулы трюмо алдына ишарә ясады ул һәм, утырган җиреннән үрелеп, күзен алмыйча кыз артыннан карап калды. Моның мәгънәсен бик яхшы аңлады Фәридә. Ай ул чәнечкеле күз карашлары! Фәридәне айлар буе эзәрлекләде, артыннан карап торгандай, көтмәгәндә исенә килеп төшә дә жилкә тамырларын сызлап куя. Гомергә кичермәм, дип уйлаган иде, эчендә кер саклый белмәгән кыз әкрен-әкрен тынычланды тагын. Күңел ярасы да төзәлгән кебек булды. Җөе генә, чак кына кагылсаң да, әрнеп сызлый иде. Бүген дә искә төшерде ул үзен. Бу юлы «син» дип, турыдан-туры әйтмәделәр аңар. Гаепләү бу юлы бөтен класс өстенә ташланды. Аңар карап кызга җиңел булмады. Әгәр сәгать табылмаса, бу кара шик алар өстендә мәңге торып калачак бит. Сәгать нәрсә, берсе югалса, икенчесен алырлар. Гөлгенәләрнең аңлык кына хәле бар. Яман атны яхшыга алыштыруы гына кыен. Озакламый укулар бетәр. Фәридәләр төрлесе төрле якка таралырлар. Шушы көе аерылышырлармы инде алар? Бер очрашмый тормаслар бит, очрашырлар. Шул чакта күңелләрдә һәм күзләрдә бер үк сорау булмасмы? Очрашмаган тәкъдирдә дә, мәктәптә үткән ун ел гомерне сагынып искә алганда, кара шәүлә булып, шушы вакыйга арага килеп кермәсме?

Укучы балаларның классларга таралышып, коридорлардан кабинетларга күчеп, тавышларының ябык ишекләр аша тонык гөжләү булып ишетелгән чагы иде. Укытучыдан алда дәрескә кереп өлгерер өчен, ике басманы бер итеп сикерә-сикерә, Фәридә үзләре укый торган катка менеп килә иде. Баскычның урталыгына җиткәндә колагына ниндидер ят аваз килеп керде, тик ашыгуы белән аңа игътибар итеп тормады. Сулкылдап чыккан аваз яңадан кабатланмаса, шул көе үтеп тә китәр иде. Очкылык тотуны хәтерләткән тавыш кызны туктарга һәм сак кына кире төшәргә мәҗбүр итте.

Баскыч астындагы ярым караңгы урында Алик белән Рәсим басып тора икән. Алик йөзе белән стенага капланган да йодрыклап стенага суга, суккан саен бер сүзне кабатлый:

— Ник... Ник... Ник ул алай...

Рәсим дәшми. Дустын юатырлык сүзләр табылмый, кайгысын бүлешер иде, аңысы да мөмкин түгел. Ничек ярдәм итәргә белмәүдән гаҗиз булып, көтә генә ала ул. Дустының бераз бушаганын, сүрелә төшкәнен көтәргә сабырлыгы җитә Рәсимнең.

Алар Фәридәне күрмәделәр. Кыз үзе дә, аяк очларына басып, артка чигенә-чигенә килде дә әкрен генә югары катка менә башлады.

Аликның авыр минутына тап булган Фәридә аңар карата һич кенә дә битараф һәм чит булып кала алмады. Чөнки Алик Фәридә өчен көн дә күрешеп торган классташларының берсе генә түгел, башкалардан үзгәрәк иде ул аның өчен. Гөлгенәнең дус кызы буларак, егет Фәридәне дә якын итә һәм бу өч яшь кешенең дуслыгы соңгы елда һич аерылмаслык булып ныгыган кебек иде. Моңар хәтта Аликтан бер адым да

калмый йөргән Рәсимнең булуы да, аның кызлардан бераз гына күңеләве дә комачау итмәде.

Аерыласы көннәрнең һаман саен якынлаша баруыннанмы, Алик Гөлгенәгә шигырь белән хат артыннан хат яудыра башлады. Кыз ул хатларга шатлануын яшерми, сердәше итеп сайлаган Фәридәгә дә укый. Ләкин үзе җавап бирми. Кызлык горурлыгымы бу, әллә хисләрнең әле уянып җитмәвеме. Хатларны укыганда Фәридә тыныч кына утырып тора алмый, хискә бирелеп китеп, Гөлгенәне кысып-кысып кочаклый, син чыкмаска кердең уема... сөенеч идең, инде сагышыммы... дип, шигырь юлларын кабатлый. Ә Гөлгенә елмая гына. Бу хатларны ул Фәридәдә саклый, өйләрендә тотса, әниләре күрер дип шикләнә. Фәридә кайчагында уйлап та куя: Касыймовларның музей кебек өйләрендә шушындый кыйммәтле әйбергә ничек урын табылмый икән. Гөлгенәнең бу хатларны кат-кат укыйсы, күкрәгенә яшереп җылытасы, битенә куеп иркәлисе килмиме икәнни? Фәридәгә калса, ул үзе кәгазь битен яндырырлык бу сүзләрне укый-укый ятлап бетерде инде. Аларның бүтән кешегә атап язылганын, үзенеке түгеллеген дә белә, барыбер рәхәт аңар. Бу юлларны нәкъ менә аның үзенә атап язганнар кебек тоела.

Фәридәнең кинәт дәрескә керәсе килми башлады. Тарих кабинетының ишеген ачарга үрелгән кулын кире алды. Әрле-бирле сугылып коридорны бер әйләнгәч, укытучылар күзенә күренмәс өчен, аскы катка төште. Анда да җанына тынычлык тапмады. Гөлгенәне кызгана да ул, аңа ачуы да килә иде. Бу сәгать чыннан да табылмаса, зур каза, билгеле. Ләкин Фәридә классташларына үзеннән артыграк ышана иде. Әгәр алар син шундый да, син тегенди, дип төрле яктан әйтеп торсалар, тузан бөртеге хәтле дә гаебе булмаган кеше, әллә мин чыннан да шундый микән, дип уйлавы мөмкин, ә иптәшләре турында... юк!

Ә шулай да ниләр бар икән хәзер класста?

Җыргән укытучы классның гадәттән тыш тәэсирләнгән булуына сәерсенсә дә, дәресен тыныч кына башлап җибәрде. Ләкин укучыларның чыш-пыш сөйләшкәләп алулары, бер-беренә кәгазь язып ыргытулары игътибарны ала, дәреснең ритмын боза, эчне пошыра иде. Аның шелтәле карашына буйсынып, класс тора-бара тынычланды да кебек. Әмма Гөлгенә, күңеле белән әллә кайларда йөргәндәй, әле дә булса тәрәзәгә карап утыра. Шундый да тирән уйга баткан, хәтта укытучының кисәтүен, янына килеп басуын тоймый калды.

— Китабыңны ал, Касыймова, эшкә тотын,— диде укытучы, кызның иңбашына йомшак кына кагылып.

Гөлгенә сискәнеп китте, ашыгып сумкасына үрелде, каушавы белән кулыннан ук төшереп җибәрде. Сумка эчендәге әйберләр шапылдашып идәнгә коелды. Җыеп алырга иелгән кыз өнсез калды, үз күзенә үзе ышанмады, иреннәре «сәгать!» дип пышылдады. Китап-дәфтәрләр арасында, көзге кояш кебек салкын нур балкытып, сәгать ята иде. Гөлгенә аны чылбырыннан тотып алды да, барысына да күрсәтергә теләгәндәй, кулын югары күтәрде.

— Сәгатем табылды! — дип кычкырды ул, дәрестә утыруын да онытып. Ләкин аның шатлыгын күтәреп алучы булмады, кызыксынып башта аңа, аннан бер-берсенә караштылар.

Эшсезлектән каңгырып йөргән Фәридә бу турыда берни белми иде әле. Ул Аликларны калдырып киткән җирдән тагын бер әйләнеп килде. Анда егетләр юк иде инде. Кызны бераздан Рәсим үзе килеп тапты.

— Алик кайда? — дип сорады Фәридә.

— Өенә кайтып китте,— диде Рәсим һәм Фәридәнең күзләренә карап: — Гөлгенәңә әйт, йөрмәсен безнең белән буталып.

казан утлары
АЭС
әдәби пост

**Марат Әмирханов,**
әдәби постның штаб члены

# ТАРИХКА КЕРГӘН БЕР КӨН

Без Татарстан атом электр станциясе төзелешенә 1983 елның 10 февралендә килдек. Аннан соң инде шактый вакыт узды, зур үзгәрешләр дә булды. Шуңа күрә бу көнне гаять мөһим саналган проблемалар, бүген ирешелгәннәр биеклегеннән караганда, ихтимал, алай ук искитәрлек тә тоелмас. Ләкин зур төзелешнең тарихында әнә шул беренче адымнар да бик мөһим.

## Иртән

Юл кешесенең иң зур борчуы — транспорт. Дөрес, рәсми эштәгеләргә һәркайда ярдәм итәргә әзер торалар. Ләкин машина — үз кулыңда, үз яныңда булмагач, барыбер шикләндерә: вакытында килеп җитмәс тә, сөйләшенгән, килешенгән җиргә өлгерә алмассың кебек. Бу юлы да партиянең Түбән Кама шәһәр комитетында кичтән вәгъдәләшеп куйган идек. Бүлек мөдире Камил Баһаутдинов үзе дә безнең белән йөреп кайтырга булган иде. Бу инде ышанычны бөтенләй гарантияли. Ләкин иртәнгә планнар үзгәргән булып чыкты. «Нефтехим» берләшмәсендә яңа завод сафка басу уңае белән зур митинг буласы икән, мөдиргә шунда барырга кушканнар.

— Сезнең белән райбашкарма комитеты председателе иптәш Тимофеев барачак, хәзер килеп җитәр,— диде ул, шикләнергә һичнинди урын калдырмыйча.

Үзе, телефоннан тоташып, председатель турында белеште.

— Александр Васильевич атомчылар янына китте,— диде мөлаем тавышлы хатын-кыз.

— Ул горкомга керергә тиеш иде...

— Анысы миңа билгесез, Камил Сәлимович!

Пычаксыз сую, дип, халык шушындый халәтне әйтәдер, мөгаен. Мөдир, борчылуын күрсәтмәс өчен, нинидер мәзәк сөйләп алды. Ләкин икебезнең дә кәеф кырылган иде инде. Тиздән ул үзе дә китеп барды, коридорда ялгызым басып калдым. Ни эшләргә, бердәнбер юл — олы юлга чыгып, шул якка баручы машинаны тоту.

Кабаланып киенергә тотындым. Шул чак кемдер җилкәдән какты.

— Казан журналисты сез буласызмы?

— Сез — Тимофеевмы?

— Бераз тоткарландым, гафу итегез.

Кая ул гафу итмәгән, бу минутта мин аны кочаклап үбәргә әзер идем.

Һәм менә без юлда. Кичтән җепшек кар яуган иде. Иртәнгә бераз суытып җибәргән. Шуңа күрә юлга урыны-урыны белән ак кар сагыздай ябышып каткан. Өсте күзгә шикелле ялтырап тора. Кайбер урыннарда хәтта юл чистартучы зур-зур машиналар да канау читенә борыннарын төртеп, хәрәкәтсез калганнар. Ә без әлдертәбез генә. Шофер мондый юлга күнеккән, күрәсең, машинаны зур осталык белән алып бара.

Ниһаять, Кама Аланына килеп җиттек. Беренче күзгә ташланган нәрсә: актарылып ташланган тау-тау балчык өемнәре. Бер-берсенә сыенышып утырган тәбәнәк вагоннар бу өемнәр арасына кысылып калган кебек. Җир селкетеп машиналар үтә, сварка утлары җемелдәшә, торна борын-краннар бөтерчектәй әйләнә: «Майна!» «Вира!»

Һәркем үз эше белән мәшгуль, килгән-киткән кешегә игътибар итүче дә юк. Нәкъ КамАЗдагыча, 70 елларда анда да шушындый ук шау-шу иде.

Александр Васильевич авылда машинадан төшеп калды, без юлны станция салыначак якка таба дәвам иттердек.

— Сессиягә кайтып җитегез,— дип озатып калды ул.

Бу маршрутны безгә төзеләә торган атом электр станциясенең бүлек начальнигы Анатолий Павлович Кротов өйрәткән иде.

— Һаман шул бер балык башы: Камполяна да, Камполяна,— диде ул,— АЭСнең үзе турында да язарга вакыт.

Ул стенаның буеннан-буена эленгән зур схемага озын бармагы белән төртеп күрсәтә-күрсәтә станция, аның объектлары турында рухланып сөйләде. Сусаклагыч үзе генә ни тора. Камадан ике-өч мәртәбә киңрәк! 3 мең гектардан артык мәйданда җәйрәп ятачак ул. Зәй ГРЭСы сусаклагычыннан ике тапкыр диярлек зуррак булачак. Тимер юл, автомобиль магистральләре, причал — ни генә юк?!

Моннан аз гына алданрак «Татэнерго» идарәсе управляющие Николай Александрович Баныкин белән очрашып сөйләшкән идек. Кайбер кешеләр: Татарстанның энергия базасы болай да җитәрлек, АЭСне республика территориясендә төзү шул кадәр үк зарур идемени, дип сорыйлар. Бу хакта матбугат органнарына да күп кенә хатлар килә.

Чыннан да хәзер бездә көн саен 90 миллион киловатт-сәгать электр энергиясе җитештерелә. Бу — җан башына күчереп исәпләгәндә, Англия, ГФР, Франция һәм Италия кебек алга киткән капиталистик илләрдә җитештерелгәнгә караганда шактый күп. Унберенче бишьеллыкта гына да Татарстанда файдалануга тапшырылачак энергетика куәтләре ГОЭЛРО планы буенча 10—15 ел дәвамында бөтен илдә сафка кертелгән куәтләргә тиң.

Шуңа күрә әлеге сорауны укучылар исеменнән Николай Александровичка без дә бирдек.

— 60—70 елларда Кама аръягында зур индустриаль үзәк барлыкка килде,— диде ул, — бу төбәкне экономистлар «Түбән Кама йолдызлыгы» дип атыйлар. Республика промышленностенда гына түгел, бөтен илебез экономикасында зур роль уйный. Мондагы предприятиеләргә бик күп электр һәм җылылык энергиясе кирәк. Шуңа күрә энергетиканы үстерүгә игътибар арткannan-арта бара. Мәсәлән, КамАЗда — бер, Түбән Камада ике ТЭЦ эшли. Зәй ГРЭСы һаман камилләшә. Түбән Кама ГЭСының II энергоблогы ток бирә. Уйлап карагыз, бу бит бер төбәктә! Энергиягә ихтыяҗ да арта бара. Аннан соң, Татарстан электр энергиясен башка өлкәләргә дә чыгара. Бу — бер. Икенчедән, безнең республикада теләсә нинди бурычларны да уңышлы хәл итә алырлык көчле төзелеш оешмалары бар. Ленин орденлы «Камгэсэнергострой» берләшмәсе әнә шундыйларның берсе.

Ягулык-энергетика ресурслары елдан-ел кими барган бу чорда атом станцияләре төзү — иң перспектив юнәлеш. КПССның XXVI съездында ул шулай дип билгеләнде дә. «СССРның Европа өлешендә электр энергиясе җитештерүнең үсешен нигездә атом һәм гидроэлектростанцияләр куәтен арттыру исәбенә тәэмин итәргә», диелә «Төп юнәлешләр»дә. Хәер, дөнья масштабында да хәл нәкъ шулай тора. Ник дисәң, традицион энергия чыганаклары булып саналган нефть, газ, ташкүмер запаслары һич тә чиксез түгел. Кайбер галимнәрнең исәпләвенчә,

мәсәлән, энергия куллану бүгенге дәрәҗәдә генә калганда да АКШтагы нефть һәм газ чыганаклары чирек гасырга гына җитәчәк.

1972 елда җир шарында 123 АЭС бар иде. 1980 елда исә АЭСларда электр энергиясе җитештерү ун мәртәбә артты. Атом энергиясен беренче булып тыныч максатларда кулланган безнең илдә үсеш аеруча зур. Ләкин алга китеш шактый булса да, бу юнәлештә күп эшләр башкарасы бар икән шул әле. «Төп юнәлешләр»дән күренгәнчә, мәсәлән, СССРда 1985 елда 1550—1600 миллиард киловатт-сәгать электр энергиясе эшләп чыгару билгеләнә, шуның 220—225 миллиард киловатт-сәгате генә — атом электр станцияләрендә җитештереләчәк.

— Татарстанда АЭС төзелү бик урынлы,— диделәр безгә дирекциядә. — Атомны кеше ихтыярына буйсындыру чын мәгънәсендә Казанда башланган бит. Сугыш чыккач, Ленинградның физика-техника институты вакытлыча Казанга эвакуацияләнә. Мәшһүр атомчы галим Курчатов 1942—1944 елларда шушы институтта атомны «йөгәнләү» ысулларына өйрәнә.

...Без станция төзеләчәк урынга барабыз. Анатолий Павлович дөрес әйтә, моңа кадәр матбугатта, башлыча, Кама Аланы турында гына язылды. Ә анда, билгеле булганча, АЭСнең шәһәрчеге корыла. Ә станциянең генподрядчысы — «ТатАЭС» төзелеш идарәсе. Моңа кадәр ул Зәйдә ГРЭС, шәһәр күтәрде, КамАЗ объектларын төзеште. Быел ул бөтенләйгә монда күчеп киләчәк.

Беляхча авылы — «Шешминец» совхозының бер бүлекчәсе. Кечкенә булу сәбәпле Татарстанның административ картасында да күрсәтелмәгән. Һәм ул билгесез килеш бу урыннан мәңгелеккә күчәчәк. Чөнки АЭС нәкъ шул авыл урынында салыначак.

Участок начальнигы Миңлекасыйм Салихович Садыйков та шунда иде. Үзеннән көч ташып тора. Аны күрүгә, күңелдә ышаныч арта, җиргә ныграк басып йөрисе килә башлый.

— Авыл күчерү — бик мәшәкатьле эш,— диде ул,— алай да куелган бурычны үтәми калмабыз!

Әйтәсе дә юк, мәшәкатьле эш. Кешеләрне туган-үскән нигезләреннән капылт кына күчереп кую җиңел түгелдер, әлбәттә. Бигрәк тә өлкәннәр авыр кичерә. Дөрес, берәү дә аяк терәп каршы килми икән. Төзүчеләр йорт саен кереп һәркем белән сөйләшеп чыкканнар, кешеләрнең уй-фикерләрен, теләкләрен исәпкә алганнар. Яшьләр хәтта күчүне хуп күрә. Алар аңлый: яңа Беляхча заманча корылачак, йортларында бөтен уңайлыклар булачак.

— Каралты-куралары белән барысы 80 йорт төзиячәкбез,— ди участок начальнигы. — Быел шуның 34 ен салу планлаштырыла.

Идарә начальнигы Михаил Вайнер сүзләренә караганда, авыл бик әйбәт урынга күчерелә. Совхозның үзәгенә дә якын була. Беляхчаның яңа тарихы әнә шулай башлана.

— Станция үзе кайчан төзелеп бетәчәк соң? — дип сорыйбыз.

— 1988 елда беренче реактор энергия бирә башларга тиеш, — диде Михаил Исаакович көр тавыш белән.

АЭС — бик катлаулы, дәвамлы корылма. Төзүчеләрнең аны мөмкин кадәр тизрәк төзеп бетерергә тырышуы шуңа күрә аеруча мактаулы да.

## Көндез

Сессия сәгать 1 гә билгеләнгән иде. Без Беляхчада вакытта Александр Васильевич Тимофеев шул мәшәкатьләр белән йөргән икән. Тик сәгать угы бергә якынлашып килсә дә, кеше-фәлән күренми. Председатель дә, оештыру группасы әгъзалары да борчылып, сәгатькә еш-еш күз төшереп алалар.

— Барысы да беләләрме?— диде Тимофеев сабырсызланып.

— Белдерүләр эленгән...

— Белдерү — белдерү, чакыру хатлары җибәрергә иде, төзүче халкын беләбез...

Шул чак коридорда аяк тавышлары ишетелде.

— Килделәр!

Депутатлар чишенеп залга узды.

— Шиккә салдыгыз, валлаһи...

— Һәр минут исәптә, төш вакытын сессиягә туры китереп үзгәрттек, өс-башны алмаштырасы да бар бит,— диде участок начальнигы Рәис Сәләхов һәм өстән куйды. — Сессиягә кем эш киеменнән килә инде.

Төзүчеләр бер-берсенә карашып елмаештылар. Аларның күбесенең монда кешелеккә кия торган киеме дә юк, гаиләләре кайсыныкы — кайда яши. Әмма йөзләрдә — шатлык: халык аларга зур ышаныч күрсәткән ич, 6 нчы февральдә генә оешкан Кама Аланы поссоветына сайлауларда депутат итеп сайланганнар! Барысы 30 депутат. Алар арасында Александр Федоров та бар.

Без аның белән моннан берничә көн элек танышкан идек. Махсус урта белемле бригадир. Була бит шундый кешеләр, беренче карашка алар игътибарны җәлеп итмиләр: ни йөзләре, ни буйлары дигәндәй. Александр да юка сынлы, кечкенә гәүдәле. Җитмәсә, юашрак та кебек күренә. Ирексездән: кешеләрне тыңлата ала микән бу, дип тә уйлап куйдым. Баксаң, бик абруйлы икән үзе.

— Таләпчән, гадел, мәрхәмәтле,— диделәр аның турында хезмәттәшләре.

— Мәрхәмәтле булганга да бригададагы 26 кешедән яртысы китте,— дип көлде ул.

— Ничек китте?

— Мондагы тәртипкә, эш ритмына түзә алмадылар. Җиңел кәсеп эзләп килүчеләрне, акча артыннан куучыларны, эштән эшкә күчеп йөрүче җилбәзәкләрне җаным сөйми.

Бу сүзләрне Александр Константинович цехком председателе буларак та әйтә. Дисциплинаны ныгытуга монда зур игътибар бирәләр. Бу аңлашыла: тәртип юк икән, анда эш тә юк.

Александр Федоров АЭСка гаиләсе белән Казаннан килгән. Аңа кадәр Братскида чыныгу үткәннәр. Хатыны Наташа тәрбияче булып эшли. Алик исемле уллары, Лариса исемле кызлары бар. Исәпләре — Кама Аланында төпләнеп калу.

... Залга шаулашып тау ягы төзүчеләре килеп керде. Кама Аланы ике тау куенына сыенып утырган. Менә мин кем дигәндәй кәперәеп утырганы — авылны сул яктан, Уратма елгасы ярыннан башланган сөзәге Ширәмәт ягыннан кочагына алган. Таулар бер-берсе белән очрашмый. Биеге, Кама буена җитәрәк, бөтенләй өзелеп кала, сөзәге, тора-бара тигезлеккә әверелеп, елга буена җәелә. Зәйлеләр тау ягында эшлиләр. Шуңа күрә аларны «тау ягы кешеләре», дип йөртәләр дә.

— Бетон кортлары килде,— дип көлде кемдер.

Тау ягы вәкиле бу сүзне үзенчә аңлатып бирде.

— Михаил Исаакович, шушылар гаебе белән безгә беренче сменага да, икенчесенә дә измә эләкми, берәр чарасын күрәсе иде,— дип шаярткандай идарә начальнигына мөрәҗәгать итте ул.

— Завод ни карый?

Бетон заводы кешесенең җавабы әзер иде.

— Кем алдан җитешә, шул ала.

— Иртәрәк торырга кирәк, димәк!..

Сүзне уенга борсалар да, бетон — АЭСта бик мөһим проблема. Чөнки бу көннәрдә бер генә завод эшли иде, икесе әлегә әзер түгел. Башка материалларны да Брежнев, Түбән Кама, Зәй шәһәрләреннән ташыйлар. Аралар ерак: 50—100 километр.

Гомумән, төзелештә хәл итәсе мәсьәләләр бик күп. Безгә тау ягында участок начальнигы урынбасары Григорий Захарович Сало вагонында түбәндәге сөйләшүнең шаһиты булырга туры килде.

— Мин монда гына яшәр идем,— диде табак битле шофер егет күзләреннән ут чәчеп.

— Урын юк!

— Мин — командировкадагы кеше, урын табыгыз!

— Акчасын аласың бит.

— Акча белән генә булмый, минем адәм төсле эшлисем килә!

Әйе, кайсы гына темага кагылма, һәрберсе проблема! Торак урыннар җитми, материалларга кытлык, ә кешеләрнең колач җәеп эшлисе килә. Ләкин башлангыч чорның үз кыенлыклары, үз мәшәкатьләре бар шул. Әйтик, шоферлар командировкада саналсалар да, Түбән Камага, Зәйгә кайтып йөрергә мәҗбүрләр: күпме вакыт уза, күпме ягулык тотыла. Элементәне әйтеп тә торасы юк. Беразалгарак китеп булса да үзебезнең баштан кичкән тагын бер вакыйгага тукталыйк.

Ширәмәт тавына җитәр-җитмәс шофер машинасын туктатты.

— Нәрсә бар? — диде Александр Васильевич Тимофеев.

— Алга карагыз!

Тау үзе генә түгел, аның итәкләре дә машиналар белән чуарланган иде.

— Телефонга! — дип әмер бирде Тимофеев.

Ләкин эш, председатель уйлаганча, җиңел генә барып чыкмады. АЭС белән дә, Зәй, Брежнев белән дә туры элемтә юк икән. Сузсаң, кем әйтмешли, кул җитәрлек ара, ә сөйләшеп булмый. Түбән Камага шалтыратып, аннан рация аша Зәйгә хәбәр иттеләр. Анда кирәкле кеше урынында юк иде. Әле ярый совхоз ярдәмгә килде. Ә бит бызылдап яткан машиналар төзүчеләрнеке. Алдан кайгыртып, тауга ком сибеп чыгучысы гына табылмаган.

Бердәм җитәкчелек булмавы әнә шулай адым саен үзен сиздереп тора. Әйтик, КамАЗ бер район җирлегендә, бер учка йомарланган төзүчеләр көче белән салына башлады. Ә монда хәл бөтенләй башка. Кама Аланы — «Прикамский» совхозының ерак бер бүлекчәсе генә. Авыл Советы Ширәмәттә, аңа 12 километр. Төзүчеләр үзләре дә, гәрчә «Камгэсэнергострой» берләшмәсенә карасалар да, инде әйткәнебезчә, төрлесе төрле җирдән. Аларның һәрберсе үз ягын гына каера. Шуңа күрә Кама Аланында поселок Советы оешу бик вакытлы һәм кирәкле чара иде.

Безгә беренче, оештыру сессиясендә катнашу бәхете туры килде. Аны мәктәп директоры Алексей Федорович Зимин ачты.

— Без тарихи көннәр кичерәбез,— диде ул, — Кама Аланы поселок Советы төзелү бу төбәкнең йөзен тамырдан үзгәртәчәк. Күп тә үтмәс, Кама буенда тагын бер матур шәһәр үсеп чыгар. Быел ук инде 250 урынлы ике ашханә сафка басачак. Мәктәп, балалар бакчасы биналарына нигез салынырга тиеш. Гомуми мәйданы 20 мең квадрат метр булган торак йортларны файдалануга бирү планлаштырыла...

Депутатлар бертавыштан поселок Советы председателе итеп Рәхимов Рәшит Габделхаковичны сайладылар. Ул Горький шәһәрендә партиянең югары мәктәбен тәмамлаган. «Родина» колхозында җиде елдан артык партком секретаре булып эшләгән. Тәҗрибәле, эзерлекле кеше. Сессиядә даими комиссияләр төзелде, халык контроле группасы оештырылды.

Поссовет оешу белән генә мәсьәләләр үзеннән-үзе хәл ителмәячәк, билгеле. Барыннан да элек, инициативалы эш таләп ителә. Партия һәм совет органнарына тәрбия чараларын да бик белеп алып барырга туры килә. Бигрәк тә төзүчеләрдә җиргә сакчыл мөнәсәбәт булдыру мөһим. Инде хәзер үк теләсә кайсы урыннан юл яру, урман-болыннарны таптау очраклары бар.

Төзелеш 5 мең гектар җирдә алып барылачак. Монда уңдырышлы, мамыктай йомшак кара туфраклы басу-кырлар да, хәтта сугарыла торган җирләр дә әләгә. Җыен кына исәпләгәндә, яңа корылмаларга бер совхоз биләмәсе кадәр мәйдан бүленгән.

— Ләкин моңа карап, без авыл хуҗалыгы продуктлары җитештерүне киметергә тиеш түгел,— диде үзенең чыгышында Александр Васильевич Тимофеев.— Сүз фәкать уңышны арттыру турында гына барырга мөмкин.

Депутатлар һәр мәсьәләне дәүләткүләм күзлектән карап чишү ысулларын эзлиләр.

Шәһәр-авылларның да язмышы, кешеләрнеке кебек үк, төрлесенеке төрлечә. Әйтик, моңа кадәр Мари авылы Помарыны үз тирәсендәгеләр генә белгәннәрдер. Хәзер ул бөтен дөньяга билгеле. Аның исемен мәшһүр газ магистрале күтәрде. Кама Аланы да тиздән картага гына түгел, калын энциклопедияләргә дә керер. Поссовет оешу — әнә шул зур киләчәкнең тәүге адымы. Алай гынамы, бүгенге депутатларны мәктәпләргә, клубларга чакырып, истәлек-хатирәләр дә сөйләтерләр әле. Әйе, андый вакыт та килеп җитәр. Хәзергә алда зур эшләр тора: станцияне, шәһәрне төзергә кирәк. Һәм алар, парадтан фронтка киткән солдатлар кебек, сессиядән туры төзелеш объектларына таралдылар.

## Кич

Без, эшкә барам, өйгә кайтам, дип сөйләшергә гадәтләнгән инде, һәм бу бик табигый. Рәис Сәләхов җитәкчелегендәге 172 төзүченең исә эше дә, тору урыны да бер җирдә: барасы да, кайтасы да юк. Нәкъ курсантлар кебек көнгә өч мәртәбә ашханәгә йөриләр. Эш вакыты белән шәхси вакыт арасында аерма юк диярлек. Аларның тормышы Ш. Камалның «Матур туганда» әсәрендә сурәтләнгән коммунаны хәтерләтә. Чөнки бөтен кеше бер уй, уртак хыяллар белән яши, яшерен нәрсә юк, һәммәсе күз алдында. Монда икейөзле була алмыйсың: яманмы-яхшымы, хәзер беленә. Бәйрәмнәр бергә уза, туган көннәр...

Яшь йөрәкләрне ашкындыра торган романтика, мөгаен, шушыдыр инде ул. Мондый тормышның үз яме, үз бизәкләре бар. Рәис исә аны икенче мәртәбә кичерә.

Хәтердә. 1970 елның язы иде. КамАЗ төзелешенең гөрләгән вакыты. Безне «Кама» кунак йортыннан ерак түгел биш катлы бер төзелешкә алып бардылар. Тик төш вакытына туры килгәнбез икән, аны бригада вагонына кергәч кенә белдек. Төзүчеләр уртага сузылган озын такта өстәл янына түгәрәкләнеп утырганнар, алларында ашамлык, шешәләр...

Түр башында кара чәчле, мөлаем йөзле чибәр егет утыра. Менә ул эчемлек салынган кырлы стаканны кулына алып, урыныннан торып басты.

— Туган көнең котлы булсын, Валя,— диде ул янында утыручы кызга. — КамАЗ өчен!

Күзләр маңгайга менде. «Уттай эш вакытында җыелышып мәҗлес уздырырга кем рөхсәт биргән боларга?» Шешәдәге «Шифалы су» этикеткасын күргәч кенә борчылу басылды.

Рәис Сәләхов белән беренче күрешүебез иде бу. Моннан соң Рәиснең исеме газета-журнал битләреннән төшмәде. КамАЗда иң беренче ярыш инициаторы булды ул, Алексей Стаханов янына да барып кайтты. Бергә төшкән рәсемнәре хәзер уникаль рәсемгә әверелде. Шуңа күрә аны АЭСнда очратуыбызга бер дә гаҗәпләнмәдек. Ник дисәң, давыл хәбәрчесенең урыны һәрвакыт күктә, биектә.

Җитәкче булу, кешеләр язмышын үз кулыңда тоту өчен белем генә җитми, табигый сәләт, талант та кирәк. Иң әһәмиятлесе, синең башлык икәнлегеңне башкалар танысын. Монысы төзелештә аеруча мөһим. Чөнки төзүчеләр «коммуна»сында участок начальнигы иң зур җитәкче, кемгә дә булса аркаланырга, югарырак баскычтагыларга сылтарга урын юк. Һәр мәсьәләне үзеңә шунда ук һәм дөрес хәл итәргә кирәк.

Вагон эчендә кеше өзелми. Һәрберсенең үз гозере. Ләкин алар барысы бергә коммуна гозере дә.

— Кабель җылына, Рәис Сәләхович, нагрузка зур,— диде монтер. Борчылу йөзенә чыккан. — Нишлибез?

— Кешеләрне караңгыда утыртып булмый бит инде.

— Ә тикшерү килсә?

— Әнә телефон бөтенләй кулны пешерә,— дип көлде Рәис,— Брежнев белән бердәнбер линия, ул да өзелсә, кая барырбыз?

Берничә минуттан шулай ук телгенә иреште.

— Сүзеңдә торасыңмы син, юкмы? — дип ачуланып кычкырды ул трубкага. Сөйләшкән кешесе танышы иде булса кирәк, тегесе озаклап нидер аңлатты.

— Безнең күтәргә чама юк,— диде Рәис ачуланып һәм трубкасын урынына куйды. Тик куюга ул тагын шалтырый башлады.

— Тыңлыйм. Кем бу? Хәйләкәр кеше син, Леонид Иванович. Тавышыңнан таныйм, яшермә. Ә? Гаебең бәр, шуңа фамилияңне әйтмисең. Сүтелергә тиешле йорт хуҗасына акча түләмәгәнсең бит, дустым. Әйе, әйе. Акча алмыйча, өйдән чыкмыйм, ди. Ә безгә мәйдан кирәк. Тизрәк, дускай, тизрәк.

Сәләхов шома маңгаена бәреп чыккан тир бөртекләрен кульяулыгы белән сөртеп куйды да монтерга карады.

— Энергетиклар безнең йортны планга кертмәгәннәр, дустым, шуңа күрә колак яфраклары да селкенми. Курыкма, без дә юлын табарбыз.

Ишек уемында цехком председателенең куян бүреге пәйда булды.

— Һич тынгы бирмиләр, теге мәгълүматларны җыюыңмы? — дип түземсезләнеп каршы алды аны участок начальнигы.

Председатель сүзсез генә аның өстәленә шап итеп яшел тышлы дәфтәр ташлады. Жиленнән отчет саннары язылган юка шытырдык кәгазьләр кош канатлары кебек җилфердәшеп куйдылар.

— Доклад бит бу!

— Башта эчен ачып кара.

— Хуҗа Насретдин, ике җөмлә белән өч санны ярты бит кәгазьгә дә төшереп була ләбаса.

Рәис, ак тигез тешләрен ялтыратып, туйганчы көлде.

— Мин контор күсесе түгел, балта остасы.

— Тешең сызлый иде әллә синең, Саша.

— Теш түгел, йөрәк... Бетончылар ярты көн буе идән себереп йөрделәр, эшме бу?

— Җә, гел бер сүз сөйләмә әле. Миннән генә тормый.

— Тәртип шуннан башлана, Рәис Сәләхович.

— Берәрсе безнең шартларга риза булмыйча эштән киттеме? Юк.

— Илле кеше эштән чыгарылды.

— Алары — Ляля клиентлары.

Сәләхов миңа карап елмаеп куйды. Бу вакыйганы ул миңа сөйләгән иде инде. Авылның кибетчесе, тәзүчеләр килгәч, эш хакын ике-өч мәртәбә артыграк ала икән. Аракы яратучылар өчен гаять уңайлы булган ул. Исерткечләрне тәүлекнең теләсә кайсы сәгатендә алалар икән.

Ләлә урынына башка кибетче китерткәннәр. Тәртип өчен көрәш чын мәгънәсендә шуннан соң башланган.

— Балалар бакчасы белән ни эшлибез, менә шуны әйт син, председатель,— диде Рәис.

— Вакытлыча вагоннарны көйләргә туры килер.

— Теш врачы ничек урнашты?..

Мәшәкатьләр, мәшәкатьләр! Аларның монда иге дә, чиге дә күренми. Бер карасаң, тормыш мәшәкатьле булганда гына кызыклы да инде ул.

Соңгысы мастер Пилал Фәизов фикере. Ул поссовет урнашачак бүлмәнең ачкычын тотып, кемгә бирергә кеше тапмый йөри иде, шул чакта тап булыштык. Сүз башлауга, монысы да бетон, такта, юл, дип зарланырга тотына инде, дип уйлап алдым. Ләкин Пилалның башында бөтенләй башка нәрсә икән.

— КамАЗдагы кебек язучылар, артистлар белән очрашулар үткәрүне көйләп җибәрәсе иде. «Казан утлары» журналының төзелешне шефка алганын ишеткәч, бик куандык,— диде ул,— хәзергә әле кино карыйбыз да, кино карыйбыз...

— Филармония артистлары булып киткән ич.

Мастер озын кара керфекләрен сирпеп миңа карады.

— Система турында әйтәм мин, традиция турында.

Пилал үзе дә каләм тибрәтергә ярата икән. Төзелештә мондый кешенең булуы бик яхшы. Чөнки аңа безнең кебек «тормышны өйрәнү өчен» командировкага барасы юк. Ул аның эчендә кайный. Кем белсен, бәлкем, хезмәттәш замандашлары турында китап язарга да уйлыйдыр.

АЭС төзүчеләргә культура хезмәте күрсәтүгә килгәндә исә, ул чыннан да вакытлы чара гына түгел. Һәм алай була да алмый. Чөнки төзелеш озак барачак. Мастерның бу хакта борчылуы бик урынлы. Уйландыра.

Төзелеш әле генә башланган кебек иде, инде балалар бакчасы кирәк. Инде ТатАЭСнең үзендә туган, тарихка теркәләчәк бәхетле нәниләр дә бар икән. Саша Смирнов — төзүчеләр поселогында дөньяга килгән беренче бала. Үсеп буй җиткергәч, кем булыр, монда төпләнерме, башка төбәкне сайлармы, анысы әле билгесез. Тик ул кайда гына булса да бу якларга сагынып, ашкынып кайтыр. Кеше өчен, әнисе һәм туган җирдән дә кадерлерәк тагын нәрсә бар?

Сашаның әнисе бизәүче, әтисе электр белән эретеп ябыштыручы. Яшьләр бәхетләрен гүзәл Кама буенда тапканнар: тәүге бала, беренче квартира, яраткан шөгыль. Шушы түгелме бәхет?

— Поселокта өч бала туды инде,— диде безгә цехком председателе. — Биш төзүчебез декрет ялында, ишәябез!

Бүлмәгә берьюлы өч кеше килеп керде. Тау ягыныкылар икән. Яңа өлгергән йорттан аларга ордер биргәннәр. Исәпләре — квартираларны карап, ачкычларын алу. Дәгъвалары да бар сыман тоела, бик үк ачылып сөйләшмиләр, төрттергәләп куялар, янәсе, кемнең кулында, шуның авызында. Өметләре күбрәккә булган, күрәсең.

Безне юл көтә, кузгалырга вакыт. Аңлашсыннар, әйдә, иркенләп, андый вакытта чит кеше комачау гына.

— Балык кайтарткан идем, уха пешерербез, куна калыгыз, — диде Рәис озата чыккач.

Килгән кешегә кунакчыл булу, табыныңны аның белән бүлешү — халкыбызның бик матур гадәте. Шуңа күрә сыеннан битәр игътибары сөендерде. Вакыт юклыкка, мәшәкатьләргә дә сылтый ала иде бит, югыйсә. Рәис кебек җитәкчеләре булганда, бу күркәм гадәт яңа җирдә дә ныклы тамыр җибәрер шәт.




## Роберт Әхмәтҗанов

# «ИШЕГАЛДЫМ ЯШЕЛ ЧИРӘМ...»

Туган йортның ишегалды! Ул инде шәхси төшенчә генә түгел, ә бәлки иҗтимагый әһәмият ала бара. Ишегалды — хуҗалык көзгесе ул. Кешенең үз йортына, йорт тирәсе участогына мөнәсәбәте исә аның иҗтимагый карашына барып тоташа. Статистика да бүгенге крестьян табышының шактый өлешен йорт тирәсе участокларыннан җыеп алуын күрсәтә. Бу өлеш аз түгел. «Иш янына куш» дигәндәй, бу да халыкның экономикасына саллы байлык булып өстәлә.

Шунлыктан ишегалды, каралты-кура тирәсе участокларына партиябез кабул иткән Азык-төлек программасында да җитди әһәмият бирелә. СССРның 1990 елга тикле чорны эченә алган бу мөһим программасында һәр гаиләгә йорт-каралты тирәсе участокларында эшләргә, кош-корт, мал-туар асрарга бөтен шартлар булдыру кирәклеге ассызыклап әйтелә. Шуның өстенә ишегалды, каралты-кура тирәсендәге бакча-участоклар крестьян көнкүрешендә гомер-гомердән зур практик әһәмияткә ия булып килде: аларда бил бөгеп, казынып, булачак игенчеләр, терлекчеләр буыны тәрбияләнде, бу бүген дә үзенә бер лаборатория, өйрәнү, тәҗрибә-сынау мәйданы булып тора. Бусагадан үрмәләп чыккан сабый да иң беренче булып дөнья белән шунда таныша бит...

«Ишегалдым яшел чирәм»,— дип тә җырлаганнар элек. Әмма халык җырындагы бу сүзләрне бүген инде хуплап булмый: ишегалдында ургып үскән яшел чирәм — муллык билгесе түгел. Без бүгенге авылларның күпчелек ишегалларында рәшәткәләп алынган яшелчә һәм җиләк-җимеш бакчаларын күреп куанабыз. Карашка нур өстәгән муллык билгеләре болар!

Шулай да әле күп кенә йортларның капкаларын ачып керүгә, яшеллек урынына кош-корт кына тибенеп йөргән кап-кара бушлыкны күреп, күңелсезләнеп тә каласың. Күршесенең ишегалды гөлбакчага охшап тора! Юкса күршеләр генә бит!... Ә менә элек файдаланылып та хәзер алабута, кычыткан басып киткән уем-уем буш мәйданнар күпме? Юкса, хезмәт куйсаң, бу җир кысыр ятмас, табынга сый-нигъмәт биргән булыр иде...

Җирнең кадерен беләбезме без? Хуҗалыкларда аңардан тулы файдаланалармы? Шунысы хак: әлегә буш яткан, әрекмән, кычыткан каплаган мәйданнар да шактый.

Мисалга ерак барасы юк. Элек безнең су тегермәне янында яшелчә бакчасы бар иде. (Каравылчысының куганын да хәтерлим әле балачакта! Чәнечкеле кыярлары изүдән сукмакка коелып калган иде). Кәбестә, кыяр, кишер аеруча мул булып уңа иде анда. Хәзер су тегермәне дә (анысының, хәер, инде хаҗәте беткән), яшелчә бакчасы да юк. Ул урында алабута, ат кузгалагы котырып үсә...

Күмәк хуҗалыклар, билгеле, иң беренче чиратта иген ашлыгын, бөртеклеләрне җитештерү белән мәшгульләр. Чөнки сер түгел, планны да үтәргә, арттырып үтәргә кирәк. Хуҗалыкның нигезе — иген ашлыгы һәм бәрәңге. Шулай да... бу юнәлештә авыл җитәкчеләренең кайгыртучанлыгы кирәктер. Кызыксынган якларда бит, әнә, бер икмәк белән генә бармый хуҗалыклары,— буа-плотиналарда көмештәй хәзинә үтеп балык та үрчетәләр, яшелчәчелек өчен дә мәйдан һәм игътибар табыла. Алма бакчалары да шаулап үсә. Бу мәсьәләләр, әлбәттә, яңа нәрсә түгел, моның белән

мин, кем әйтмешли, бернинди дә «Америка ачарга» җыенмыйм. Уртага салып сөйләшердәй булгач, шуны гына өстисе килә: хәзер азык муллыгы өчен көрәшү өстенә, аның төрләрен дә арттыру, ягъни «аш төрләндерү» ягына да игътибар итү хаҗәте туды түгелме? Бу үзенә бер проблема — производство эстетикасы дигән сыман...

«Аш төрләндерү» дигәндә, мин тагын табыннар бүгенгедән күпкә «такыр» булган балачакка кайтам. Әбинең югын бар итеп пешергән бәйрәм сыйларын күз алдыма китерәм. Ниләр генә пешерми иде ул! Менә кайберләре: тулма, бәлеш, киндер пәрәмәче, ясмык ашы, әлбә, дурчмак, көлчә, кабак бөккәне, кыстыбый, катлама, сосла, кабартма, коймак, тары боткасы, борчак чумары, уртасына ак май салган арыш боламыгы... (Аның тамак төбен кытыклап төшүен бүген дә тоям кебек!) Әйе, әбиләр иренми иде шул безнең!.. Ничә төрле аш! Әле ул чактагы юклык белән бит болар!.. (Бу «меню»га хәзер республикабызның иң мәшһүр аш осталары да көнләшеп карарлар иде кебек!) Ә ул чактагы технология? Киле-кисап, бүкәнне кисеп ясалган яргыч — «кул тегермәне»! Тарыны урак белән уру, чабагач белән сугу, җилпуч белән җилгә тотып җилгәрү, килегә салып кизәү... Карабодай һәм солы ярмаларын җиткерү эше тагын да мәшәкатьлерәк иде. Хәзер инде болар бар да бәлки кулинария һәм этнография өчен генә кызыклыдыр? Шул өлкәләр өчен генә әһәмиятледер? Ләкин истәлекләр безне бүгенге белән дә бәйли бит. Алар бүгенгә тоташ.

Хәзер авыл җирендә яшәүчеләрнең җир мәйданнары җитәрлек, практик яктан чикләнмәгән диярлек. Ә менә шул җир участокларын бар урында да тоташ дип әйтерлек иңеннән буена бәрәңге биләп тора. Кайбер авылларда яшел суган да булмый. Яшелчә утыртуга никтер игътибар ителми.

Юкса бит бүгенге авылларда көнкүреш шартлары камилләшә бара. Авыл тормышы яңача төсмерләргә байый. Кешеләре исә һәрберсе — үз эшенең галиме. Җитәкче һәм белгеч кадрларның хәзерлекле булуын әйткән дә юк инде! Күбесе махсус белем алган. Заманча уйлый, фикер йөртә. Шулай булгач...

«Гигант» колхозының еллык гомуми отчет-сайлау җыелышында колхозчыларның, күмәк хуҗалыкка кагылган олы мәсьәләләрне зурдан күтәреп, чыгыш ясаулары күңелгә кереп калган. Колхоз зоотехнигы, мәсәлән, терлекче хезмәтенә фәлсәфи, төпле якын килеп, конкрет рәвештә аның өч асыл сыйфатын билгеләп үткән иде: «1) Авылда иң беренче булып, терлекченең капкасы ачыла; 2) Мал-туарны ярату хисе уку белән генә бирелми; 3) Таудан-тауга чабып кына көтүчедән хасият юк: аннан гына терлекләр тук булмый»,— дигән иде ул.

Тоем һәм тәҗрибә өстенә бүгенге Игенче-Терлекче фәннең иң яңа казанышларына, дөньякүләм ачышларга да таяна ала. Болар аның үз кулында. Шулар өстенә радио, телевидение, әдәбият. Ниһаять, буыннар тәҗрибәсе... Мин балачактан игенчеләрнең һава хәлләренә, туфракка, елның дүрт фасылы билгеләренә җете игътибарын күреп-тоеп үстем. Бабам минем фенолог түгел иде. Заман карты. Кулыннан бөтен эш килгән хезмәт сөючән карт. Иртәнге чәйгә чаклы ул ишегалларын йөреп керер дә, күзлеген киеп, тәрәзә өстенә кыстырып куелган дәфтәрен алыр иде. Бу — аның һава хәлләре көндәлеге. Аның арасына ярты бармак озынлыгында шәмәхә карандаш та кыстырылган булыр иде. Аннан, тәрәзәдән тышка карап, аз гына калтыраган куллары белән язып куяр: «Бүген искечә беренче дикәбер. Хәйран карлы булды... Фәлән-фәлән...» һ. б. Ел әйләнәсе шулай. Елы елга туры килмәсә дә, үзәйрәнчек «фенолог» бабамның күп кенә күрәзәлекләре дөрескә чыга иде. Ул кеч-кенә генә җирне дә бушка яткырмады. Файдага җикте.

Мәгълүм булганча, колхоз һәм совхозлар шәхси хуҗалыкларга зур ярдәм күрсәтәләр: бөртеклә тә дә, терлек азыгы да бүлеп бирәләр. Мал-туар асрар өчен зур мөмкинлекләр тудырылды. Бу шартлар исә безнең крестьян агай-эненең кулларын ишегалды, каралты-кура тирәсендәге участокларда бүтән файдалы эшләр белән шөгыльләнү өчен дә азат итә. «Синдә булса, миндә дә булыр» дигән сүзләр реаль мәгънәгә ия. Билгеле, әлбәттә: шәхси хуҗалыкларда җиләк-җимеш, яшелчә үстерүне мәҗбүри иткән карарлар юк югын. Бу һәркемнең үз ихтыяҗыннан тора, әмма шулай да иске җырның: «ишегалдым яшел чирәм» дигән сүзләрен көнкүрешебезчә үзгәртеп, яңартып җырлау яхшырак булыр иде.

Ишегалды — йортның күрке. Ишегалды — хуҗалык көзгесе. Өстәмә муллык мәйданы.

*Балык Бистәсе, Иске Арыш авылы.*

Нил Юзиев

# ӨЧ НӘСИХӘТ

Күренекле галим, РСФСРның һәм Татарстанның атказанган фән эшлеклесе, филология фәннәре докторы Мөхәммәт Гайнуллинга 80 яшь тулды. Ул — СССР Фәннәр академиясе Казан филиалы Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм тарих институтының иң өлкән фәнни хезмәткәрләреннән. Гомеренең яртысын дип әйтерлек шушы институтта үткәргән: биредә ул 1945 елдан башлап эшли, хәзер профессор-консультант вазифаларын башкара.

Мөхәммәт ага яңарак Мәскәүдәге Бөтендөнья әдәбияты институтына «СССР халыкларының Октябрь революциясенә кадәрге чор әдәбиятлары» күп томлы тарихы өчен XIX йөз татар әдәбияты турында бүлек язып тапшырды. Ул яңа, зур иҗат планнары белән яши: XIX йөз татар поэзиясе антологиясен хәзерләүгә җитәкчелек итә, Гыйльми совет утырышларында докладлар сөйли, коллегаларын яңа табышлары белән таныштыра, шәкертләре белән әңгәмәләр алып бара. Аның тормыш тәҗрибәсе гаять бай, әйтер фикерләре гаять күп. Шуңа күрә дә остаз-галимнең нәсихәтләрен аның коллегалары да, шәкертләре дә зур игътибар белән тыңлыйлар. Бу юлы остаз-галимнең өч нәсихәтенә генә колак салыйк...

## Беренче нәсихәт

**«Остазы нинди — шәкерте дә шундый. Шәкертсез галим — бәхетсез галим».**

Укучы — остаз мөнәсәбәтләренә Мөхәммәт ага үзенең әңгәмәләрендә шактый еш кагылып уза. Бер уңае — үзенең остазларын искә алганда. Әңгәмәнең нигезе остаз-тәрбиячененең укучыны тәрбияләүдәге роле, җаваплылыгы кебек җитди темага барып тоташа:

— Остазы нинди, укучысы да шундый,— дип сөйли Мөхәммәт ага.— Укучының бәхете укытучыдан тора. Мин үземне бәхетле язмышлы дип саныйм. Гади балта остасының малае әтисе хыялына да китерә алмаган мәгърифәт тавының биек үрләренә менсен әле — бу бәхет түгелмени! Шушы юлга этәрүчеләр — беренче укытучыларым, остазларым. Минем бәхеткәдер инде, мәктәпкә укырга кергән елны авылыбызга яңа мөгаллим килеп, бөтенләй яңача укыта башлады. Соңыннан без аның Җаек шәһәрендә (Уральскида) «Мотыйгия» мәдрәсәсендә Габдулла Тукай белән бергә укыганлыгын белдек. Исеме хәтердә бик тирән уелып калган — Зәки Рәмиев. Үз тормышы турында әллә ни кайгыртмый иде — мәктәпнең бер бүлмәсендә генә тора, бар белгәне — китаплар, бар кайгысы — авыл балаларын белемле итү, аларда әдәбиятка мәхәббәт тәрбияләү иде. Тукай шигырьләре белән дә безне беренче булырак ул таныштырды.

Мөхәммәт Гайнуллин соңыннан, әдәбиятчы-галим булып киткәч, үзенең тикшеренүләрендә Тукай иҗатына һәм шул чор әдәбиятын, публицистикасын өйрәнүгә киң урын бирә. Тукайга булган шушы олы мәхәббәтенең бөреләнүе, ихтимал, шул Зәки Рәмиевтән тыңлаган беренче дәресләрдән үк башлангандыр. Ул сабаклар исә Казандагы Көнчыгышны өйрәнү институтының филология факультетында укыганда (1928—1931) һәм аспирантура үткәндә (1931—1934) тагы да тирәнәяләр. Институтта ул Х. Бәдигый, Г. Сәгъди, Г. Шәрәф, Җ. Вәлиди, Г. Нигъмәти кебек күренекле галимнәр-

нең лекцияләрен тыңлый, алардан әдәбият фәненең күп серләренә өйрәнә. Аспирантураны Г. Нигъмәти җитәкчелегендә үтүе дә аның күңелендә тирән эз калдыра. «Татар әдәбиятында интернационализм мотивлары», «Г. Камалның тормыш һәм иҗат юлы» исемле башлангыч фәнни хезмәтләре профессор Г. Нигъмәти кебек остазларының әдәбият фәнендәге юлын дәвам итеп китә, үзе остаз булып әверелә.

— Галим кешегә белем байлыгын җыя белү генә җитми. Ул үзендәге хәзинәне башкаларга кызганмыйча өләшә белергә дә тиеш!— дип саный Мөхәммәт ага. Бу юлда ул үзенең остазлары шикелле эш итә: күңел байлыгын, белем хәзинәсен мәкаләләренә, күп санлы фәнни хезмәтләренә күчерә. Шушы төп эшеннән тыш ул педагогия институтында һәм университетта студентларга лекцияләр укый, радиодан чыгышлар ясый.

«Шәкертсез галим — бәхетсез галим»,— дигән гыйбарәне Мөхәммәт ага урыны килгән саен куллана. Ул үзе бу яктан да бәхетле. Аның шәкертләре гаять күп. Ул уннан артык аспирант тәрбияләп, фән юлына озатты, дистәләгән фән докторларына һәм кандидатларына оппонент булырак фатиха бирде. Аның турында «Укытучыларның да укытучысы» дип исемләнгән мәкаләләрнең басылуы һич тә очраклы түгел.

— Минем иң олы куанычым әдәбият булса, аннан кала — укучыларым, шәкертләрем. Юлымны дәвам итүчеләрем бар...— ди Мөхәммәт ага.— Шәкертләрем миннән уздырсалар, мин шуңа шат!

Болай дип күп шәкертләр тәрбияләгән бәхетле галим генә әйтә ала...

## Икенче нәсихәт

**«Бүлмә саклап утырмагыз, алып китмәсләр... Яңаны, беренче кул чыганакларны эзләгез...»**

Профессор Мөхәммәт Гайнуллин үзенең әңгәмәләрендә, чыгышларында еш кына галимнең яшәү рәвеше, эшләү принциплары турында да сүз кузгата. Бу мәсьәләдә дә аның үз карашы, үзе инанган, яклаган концепциясе, шәкертләренә әйтергә теләгән нәсихәте бар.

— Мин эзләнә торган, бар булганы белән канәгатьләнми торган тынгысыз галимне яратам,—ди ул үзенең шәкертләренә нәсихәтләрендә.— Галим кеше һәрвакыт эзләнергә, яңалыкка омтылырга тиеш. Белгечлегең әдәбият тарихчысы дип атала икән, миеңә иң беренче киртеп куй — тарих өчен иң кирәге — беренче кул чыганаклар. Шулардан башка тарих язып булмый, язылса да ярты-йорты гына килеп чыга...

Карт профессорның озак еллар дәвамында шушы өлкәдә эшләү тәҗрибәсеннән туган фикерләре бу. Мөхәммәт ага үзе шундый: тынгысыз, эзләнүчән.

— Кызганычка каршы, хәзер врачлар ерак юлга чыгарга рөхсәт бирмиләр. Әле дә өйдә утырмас идем, тотар идем дә ерак юлга чыгар идем. Менә, карагыз, тагын хатлар алдым. Мәскәүгә, Оренбурга, Әстерханга чакыралар...— ди ул өстәлдәге хатларга ишарә ясап. Аннары беравык тынып кала: үткәндәге озын һәм ерак сәфәрләрен искә ала булса кирәк.

— Баштарак мин китапханәләр белән генә чикләнә идем,— дип сүзен дәвам итә ул.— Үземнең китапларым үземә үк бик гыйбрәтле сабак бирделәр. Әдәбият тарихы буенча беренче китабым басылгач, Касыйм шәһәреннән Бәширова фамилияле бер карт укытучыдан хат алдым. Ул минем китапта Закир Һади биографиясе тулы күрсәтелмәүне, туган һәм үлгән еллары дөрес бирелмәүне тәнкыйтьли, язучының кызлары исән булуын хәбәр итә. Шушындый хатлар минем күземне ачты. Карасана, безнең уйламаган булышчыларыбыз да бар икән ләбаса! Әдәбиятчы өчен архивта казыну гына җитми, киң җәмәгатьчелеккә дә таянырга кирәк икән! Әлеге хатлар минем эзләнүләр мәйданын бик нык киңәйтеп җибәрделәр.

М. Гайнуллин гыйльми эшчәнлек юлына баскан вакытларда татар әдәбиятының тарихын яңа нигездә һәм фәнни итеп язу көн тәртибенә иң актуаль мәсьәлә буларак куелган була. Моңа 20—30 нчы елларда тәнкыйтьтә нык тамыр җибәргән вульгар-социологик тайпылышларның әдәбият тарихын язуда шактый нык авырлыклар тудыруы да сәбәпче иде. Аерым язучыларның иҗатын бәяләүдә бердәм фикер юк иде. Шуңа күрә дә 40—50 нче елларда әдәбият фәненә килгән галимнәргә әдәбият тарихын яңа

шундый тайпылышлардан арындырып, язучыларны беренче чыганаклар буенча барлап чыгу буенча ифрат зур һәм җаваплы бурычлар йөкләтелгән иде. М. Гайнуллин нәкъ менә шушы катлаулы эшкә алына. Ул төп объекты итеп XIX гасыр һәм XX гасыр башы әдәбиятын сайлый, К. Насыйри, З. Һади, З. Бигиев, М. Акъегет, Дәрдмәнд, С. Рәмиев, Ш. Мөхәммәдов кебек күренекле язучыларның тормышы, иҗаты турында архивлардан, китапханәләрдән, әдипләрнең туганнарыннан, дусларыннан, кыскасы, киң җәмәгатьчелектән бик күп материаллар туплый, аларны фәнни кулланылышка кертә, язучыларның әсәрләрен барлый, аларны туплап, текстологик яктан хәзерләп, матбугатка тәкъдим итә.

Мөхәммәт ага Гайнуллинның фәнни-тикшеренү орбитасы гаять киң булган кебек, аның эзләү-тикшерү мәйданы да күп төбәкләрне, шәһәрләрне эченә ала. Мәскәү, Ленинград архивларында булып, ул татар язучыларының цензурада тоткарланып калган кульязмалары яки әсәрләренең беренче басмалары белән таныша. Үзәк тарих архивында ул, мәсәлән, цензура тарафыннан тыелган XIX гасыр әсәре «Мәкарҗә бәете»нә тап була, З. Бигиевнең «Катилә» романын бастырырга сорап язган гаризасын һәм цензор Смирновның кире бәяләмәсен очрата, Риза Фәхретдиновның «Китабэл-интисар лил-игътибар» исемле кульязмасының цензор тарафыннан бастырылмыйча калган нөсхәсе белән таныша. З. Бигиевнең «Меңнәр, яки гүзәл кыз Хәдичә» романы элек 1896 елда язылган дип йөртелсә, галим аның 1887 елда инде басылган булуын дәлилли. М. Акъегетнең биографиясен ачыклау нияте белән ул Пензага барып чыга, шәһәр архивыннан әдипнең тормыш юлын тулыландырырга ярдәм иткән яңа материаллар таба. Мәсәлән, шулардан берсе: элек аны Акъегет авылында туган дип язсалар, галим аның Чембар шәһәрендә тууын ачыклый.

М. Гайнуллин Заһир Һади биографиясендәге төгәлсезлекләр турында язган адресатның сүзен тыңлап, Оренбурга юл тота, анда әдипнең кызларын эзләп таба, алардан З. Һади тормышына, иҗатына караган күп материаллар алып, аларны фәнни кулланылышка кертеп җибәрә. Шул рәвешчә галим Ш. Мөхәммәдев, Дәрмәнд, С. Рәмиев, Г. Колахметов һ. б. әдипләрнең биографиясенә, иҗатына кагылышлы күп яңа материаллар туплый. Шундый яңа фактлар, чыганаклар әдип биографиясен генә түгел, шул чор татар әдәбияты тарихын да тулы итеп анализларга, татар әдәбиятын бөтен байлыгы белән күрсәтергә ярдәм итәләр.

— Бүлмә саклап утырмагыз, егетләр! — ди ул яшьләргә мөрәҗәгать итеп.— Бүлмәгезне алып китмәсләр. Ә менә әдәбиятка кагылышлы кыйммәтле документлар, чыганаклар югала тора. Мин шундый аянычлы фактларга аз очрамадым. Уральскида да, Сәмәркандта да, Ташкентта да, Әстерханда да миңа: «Их, берничә ел алданрак килеп чыксагыз икән!» — дигән сүзләрне ишетергә туры килгәләде. Дәрдмәнднең кызы Зәйнәп ханымны, улы Җәгъфәр Рәмиевне эзләп табып, мин алардан Дәрдмәнднең мирасы ни рәвешле әрәм-шәрәм ителүен, бер сандыкка тупланган кульязмалары поездда эзсез югалуын ишетеп, бик тә әрнедем. Югалмасын иде алар! Аерым кеше хәзинәсе генә түгел, бөтен халык байлыгы бит алар! Эзлик, табыйк, китапларга теркик, дәүләт архивларына — ышанычлы урынга тапшырыйк шул тапкан хәзинәләрне!

Үйнап түгел, уйлап әйтелгән сүзләр... Мондый сүзләрне халык байлыгы турында чын күңелдән кайгырткан галим генә әйтә ала.

## Өченче нәсихәт

**«Атлап үтмәгез, аңлатып үтегез...»**

Әлеге гыйбарәне Мөхәммәт агадан шактый еш ишетергә туры килә. Бу нәсихәте дә аның үз иҗат лабораториясе белән аерылгысыз бәйле, үзенең фәнни эшчәнлеген ачу өчен ачкыч ролен дә үти. Шушы фикер аның кырык елга якын сузылган фәнни эшчәнлегенең нәтиҗәсе, йомгагы буларак туган диярга була.

М. Гайнуллин язучыларның биографияләрендәге, иҗатларындагы «ак тап»ларны ачыклау буенча алып барган эзләнүләрен әдипләрнең иҗат портретларын һәм әдәбият тарихын язу белән бергә тыгыз үреп бара. Озак еллар дәвамында китапханәләрдә, архивларда эзләнүләре, мәсәлән, аңар XIX гасыр татар әдәбияты панорамасын элекке дәреслекләр, тикшеренүләр белән чагыштырганда тулырак һәм баерак итеп

күрсәтергә мөмкинлек бирде. Шушы өлкәдәге беренче хезмәтләре 40 нчы елларның урталарында ук дөнья күрәләр. («М. Горький һәм татар әдәбияты», 1944; «Каюм Насыйри», 1945). Профессор Л. Климович яшь авторның К. Насыйри турындагы китабын укыгач: «М. Гайнуллин К. Насыйри турында архив һәм әдәби чыганаклар туплау буенча зур һәм катлаулы эш башкарган»,— дип билгеләп үтә, аңа шушы өлкәдәге тикшеренүләрен тагы да тирәнәйтә төшәргә киңәш бирә. Күренекле рус философларының җылы карашлары һәм киңәшләре белән рухланып, галим татар әдәбиятының катлаулы мәсьәләләрен чишү эшенә тагы да кыюрак алына. Тырыш хезмәт үзенең уңдырышлы нәтиҗәләрен бирә: 1947 һәм 1954 елларда аның «XX йөз татар әдәбияты», 1957 һәм 1968 елларда «XIX йөз татар әдәбияты» дәреслек-хрестоматияләре басыла, рус телендә «К. Насыйри һәм татарларда мәгърифәтчелек хәрәкәте» (1955), «XX гасыр башы татар әдәбияты һәм публицистикасы» (1966), «XX гасыр татар әдәбияты» (1975) монографияләре дөнья күрә.

Бу хезмәтләрне берләштергән уртак сыйфатлар бар. Барыннан да элек, галимнең әдәбиятны шул чорның иҗтимагый-политик тормышы, фән-культура хәрәкәте белән тыгыз бәйләнештә каравы. Мөхәммәт ага татар әдәбияты үсешен мәгърифәтчелек һәм революцион-демократик хәрәкәт, китап басу һәм матбугат тарихы, публицистика һәм әдәби тәнкыйть, эстетик фикер үсеше белән аерылмас бердәмлектә карый. Тарихка әнә шулай комплекслы якын килү галим өчен өстәмә авырлыклар тудырса да, әдәбият тарихын төпле, нигезле һәм масштаблы итеп аңлату өчен киң мөмкинлекләр ача.

М. Гайнуллин татар әдәбиятын үз алдына аерып, үз эчендә генә түгел, ә башка халыкларның әдәбиятлары белән дә тыгыз бәйләнештә өйрәнә. XIX йөз татар әдәбияты тарихын яктыртканда, мәсәлән, рус прогрессив культурасының, галим һәм әдипләрнең татар әдәбиятына шифалы йогынтысы, рус ориенталистларының татар әдәбиятын өйрәнүдәге хезмәтләре бай фактик чыганаклар җирлегендә күрсәтелә. Пушкин, Чернышевский, Некрасов, Горький, Гоголь кебек атаклы рус әдипләренең татар культурасы белән тыгыз бәйләнешләрен ачу буенча да ул әһәмиятле тикшеренүләр язды.

Бу хезмәтләрне характерлаучы тагын бер сыйфат — авторның тарих юлында туган катлаулы мәсьәләләрне, иҗатлары каршылыклы булган әдипләрне атлап үтмәве, ә аңлатып үтәргә омтылуы. Хәзер, мәсәлән, М. Акъегет иҗатының татар әдәбияты тарихында яктыртылуы бернинди бәхәс уятмый. Ә менә 50 нче елларда, Мөхәммәт ага үзенең китапларын чыгарган вакытларда, байтак рецензентлар М. Акъегет иҗатын уңай бәяләүгә, хәтта иҗатын дәреслекләрдә өйрәнүгә кертүгә каршы килләр. М. Гайнуллин үз карашын яклауда ныклык һәм принципиальлек күрсәтү нәтиҗәсендә генә «Хисаметдин менла» повесте һәм аның авторы әдәбият тарихында үзенең тиешле урынын ала. З. Бигиев, С. Рәмиев, Дәрдмәнд иҗатларын, XX гасыр башында чыга башлаган төрле газета-журналларны бәяләүдәге берьяклылык һәм чикләнгәнлектән арынуга да галим күп көч һәм тырышлык куя.

Риза Фәхретдинов һәм Фатих Кәрими кебек әдипләрнең иҗатлары байтак еллар бәхәсле булып килде. Кайберәүләр мәсьәләне җиңел генә хәл итү ягын якладылар: аларның каршылыклы дөньяга карашларын, иҗатларын атлап, сикереп кенә үттеләр. М. Гайнуллин шундый караш белән килешмәде. Ул аларның иҗатларын җентекләп өйрәнде, иҗтимагый фикер үсеше, матбугат һәм әдәбият тарихындагы рольләрен ачыклап, «XIX йөз татар әдәбияты» дәреслегенең 1968 елгы татарча басмасында һәм русча монографиясендә (1975) Р. Фәхретдиновка да, Ф. Кәримигә дә принципиаль бәя бирүгә иреште. Мөхәммәт агага кадәр татар хатын-кыз язучыларының иҗатларын да атлап кына үтәләр иде. Галим әлеге юнәлештә дә җентекле тикшеренүләр алып барды, хатын-кыз язучыларның иҗатларына, әдәбият тарихында, беренче буларак, тиешле бәяне бирде.

— Әдипнең дөньяга карашы һәм иҗаты нинди генә каршылыклы, катлаулы булмасын, әдәбиятчы аны атлап, сикереп үтәргә тиеш түгел, ә аңлатып үтәргә бурычлы. Ленин тәгълиматы әдәбиятчыга әллә нинди чишелмәс кебек тоелган төеннәрне дә чишәргә булыша,— дип сөйләргә ярата Мөхәммәт ага нәсихәт-аңгәмәләрендә. Әлеге сүзләр галимнең иҗат кредосын ачарга да, аның кыюлыгын һәм принципиальлеген аңлатырга да булышалар.

Мөхәммәт Гайнуллин

# ТАТАР ХАТЫН-КЫЗ ЯЗУЧЫЛАРЫ

Унтугызынчы йөзнең соңгы чирегендә аеруча үсеп киткән татар мәгърифәтчелек әдәбиятына хатын-кыз язучылар әсәрләре үзенчәлекле аваз булып кушыла. Үзләренең уй-кичерешләрен, теләк һәм омтылышларын белдереп, матбугат мәйданына чыккан Галимәтелбәнат Биктимерова, Хәнифә Гыйсмәтуллина, Галимә Рәхмәтуллина, Хәбирә Насыйрия һ. б. язучыларның китап һәм шигъри парчаларында ир белән хатын арасында тату-тигез тормыш идеалы, кыз балаларны укыту зарурлыгы, бала тәрбиясе кебек заманының актуаль мәсьәләләре күтәрелә.

Татар мәгърифәтчеләре милләтне агарту, алга җибәрүдә хатын-кыз язучыларның зур урынын аңлыйлар, аларның матбугатта чыгуларын хуплап каршы алалар. Р. Фәхретдинов Г. Биктимерованың 1897 елда басылган «Мөгашәрәт әдәбе» (Тереклек итешү әдәпләре — М. Г.) китабына язган сүз ахырында: «Язучы Галимә ханым бер әй әһеленә аналык хезмәте итдеке кеби — нә кадәр кыз балаларга мөгаллимәлек һәм итмәктәдер... Гүзәл хезмәттер»,— дип югары бәя бирә.

Г. Биктимерова аңлаешлы әдәби телдә, публицистик рухта язган әлеге китабында гаилә мөнәсәбәтләренең күп якларына туктала, андагы аңлашылмау очракларын бетерү юлларын эзли[1]. Фикерләрен куәтләү өчен ул күп кенә әдәби үрнәкләр китерә һәм үзе дә аерым шигъри парчалар иҗат итә.

Бу чорда матбугатка килгән хатын-кыз язучыларның бер өлеше традицион стильгә таяналар, үзләренең мәгърифәтчелек фикерләрен куәтләү өчен Көнчыгыш әдәбиятыннан файдаланып хикәяләр иҗат итәләр. Мәсәлән, Галимә Рәхмәтуллинаның «Иҗмагъ ишеге» (Бер фикергә килү юлы) дип исемләнгән хикәясендә вакыйга һәм персонажлар чит географик җирлектән алынган. Туренка тавында бик күп еллар гомер итүче бер шәех янына өч мөсафир килеп туктый. Аларның исемнәре үк нәрсә эзләп йөрүләре турында сөйли. Картракларыннан булган Гакыл исемлесе мең елдан бирле Хакыйкать дип исемләнгән атасын эзли һәм барча кешеләрнең дә акыл белән эш итүләрен, бер-берсенә дус булып яшәүләрен күрәсе килә. Ләкин ул эзләгәнен таба алмый: «Галим-голәмә мине дошман күреп үз яннарыннан сөрделәр... Дөнья халкы ерткыч хайваннарга әйләнеп беттеләр... Әгәр бер кавем вә милләт икенче кавем вә милләттән куәтле булса, шул кавемне җәбрән тәләф итә[2]...»,— ди.

Шуңа кушылып, Каһәреттин исемлесе: «Мин дә кардәшем Гакыл кебек... куылдым... Патшалар вә аларның янында вәзирләр вә мәмләкәт хөкемендә, казыйлар вә мөрит тәрбиясендә, ишаннар, мәхәллә тәрбиясендә муллалар сәбәбе илә дөнья халкы бозыклык дәрьясына гарык булды»,— дип өсти.

Шул рәвешчә, язучы әкият геройлары авызыннан үз вакытының гаделсезлекләрен ачы тәнкыйть итүне максат итеп куя. Әсәрнең ахырында өченче персонаж Гаделетдиннең түбәндәге сүзләре китерелә: «Адәм балалары бердәй күрелеп, бәндә үзен башка милләтләрдән вә яки фирка, җенесләрдән артык күрмәсен. Мәгыйшәт, дөнья тереклегендә аларга якын, дус булсын... Нәсел аермасы вә җенес үзгәлеге игътибарга алынмасын. Мәгәр хезмәт ияләре йөзендә аларның күркәм сыйфатлары, ягъни иҗтиһат, ният, гамәлләре — халык файдасына хезмәтләре игътибарга алынмак лазим». Бу инде әсәрнең заман сулышына авазаш булуы турында сөйли.

1905 ел революциясе тудырган шартларда, татар телендә матбугат барлыкка килгәч, татар хатын-кызлары тагын да активлашалар, үзләренең хокукларын даулап, газета-журналларда ялкынлы публицистик мәкаләләр язып чыгалар.

Беренчеләрдән булып хосуси имтихан тотып, укытучы исемен алган Зөһрә Таһириянең «Бәнем фикерем» дип исемләнгән зур публицистик мәкаләсе «Казан мөхбире»

[1] «Мөгашәрәт әдәбе», С. Петербург, икенче басма, 1898.
[2] Тәләф итә — бетерә, юкка чыгара.

газетасының 1905 ел, 28 ноябрь санында басыла. З. Таһирия күтәргән мәсьәләләрне бик күп хатын-кызлар (Суфия Коләхмәтова һ. б.) яклап чыга. «Укып гаять шатландым»,— дип яза Г. Камал бу мәкалә хакында. Чөнки, аның карашынча, Зәһрә ханым «...артта калуыбызның сәбәпләрен бик яхшы аңлатып яза... байлардан ярдәм көтеп тормыйча, ачык фикерле яшьләрнең эшкә алынуларын таләп итә».

Шул көннәрдән башлап татар телендә чыккан барлык газета-журналларда «Хатыннар галәме», «Хатын-кызлар тавышы», «Хатын-кызлар дөньясы» дигән бүлекләр оештырыла. Бу бүлекләрдә басылган мәкалә һәм шигырьләрдә татар хатын-кызларының патриархаль семья коллыгыннан котылып, иҗтимагый көрәшкә катнашырга омтылулары, кешелек хокукларын таләп итүләре чагыла. Бу яктан «Фикер» газетасы, «Әл-гасрел-җәдит» журналы, соңрак «Әл-ислах» газетасы битләрендә басылган публицистик мәкаләләр аеруча игътибарга лаек. Мәсәлән, Фәрханә Алушева (1886—1958) «Фикер» газетасының 1906 ел, 26 нчы санында басылган социаль эчтәлеге мәкаләсендә инде хатын-кызларны азатлык өчен актив көрәшкә ачыктан-ачык чакыра. «Хәр булуын теләсәгез, вакыт кичекмәстән, үзегез иркенлек алырга тырышыгыз. Патша думасыннан, буржуазиядән азатлык көтү ялгыш хыял ул. Дума депутатларыннан азатлык турында һичбер нәрсә күтәргә ярамый, бай хезмәтчесенең файдасына вә һичбер бояр крестьян тормышының яхшыруына тырышмый!»— дип хатын-кызларга мөрәҗәгать итә ул. Бу фикерләр шул ук елларда Г. Тукайның «Әл-гасрел-җәдит» журналында басылган «Мәхарәбә вә государственная дума» дигән мәкаләсенә аваздаш булып тора.

Редакция баш күтәрә башлаган елларда да татар хатын-кызларының мәкаләләре, шигырь һәм хикәяләре ялкынлы публицистик рухын җуймый. Шундый шигырьләрнең берсен укыгач, Сәгыйть Рәмиев «Юк, үлмим! Торам әле» дигән лирик прозасын (1907) язып, «Әл-ислах» газетасында бастырып чыгара. Шунда: «Барча кызыктан бизгән, барча өметләремнән кул селтәгән, барча галәмнән аерылган, тик үләсем генә... килә иде. Кинәттән күзем бер шигырьгә төште. Шигырьнең башы «Мәшһүр хатыннар» дип башлап, ахыры «Әл-иҗтиһат мәктәбе мөгаллимәсе Маһруй Мозаффария» дип беткән иде... Монда бу көнгә хәтле колакка да алынмый торган хатыннар сүзләре, хәзер инде, гади генә ташны түгел, иң каты ташлардан катырак булган татарларның чуеннан каты бәгырьләрен дә меңгә кисәрлек, үткен кылыч булып... ишетелеп тора... иде.

...Монда бу көнгә хәтле «ирләр шул инде алар, ирләргә каршы бер сүз дә әйтергә ярамый» дип торган хатыннар фахиранә сурәттә бер мәһабәт белән күкрәкләрен киереп:

**Сездә Сәмин булса, бездә Сәминә бар,**
**Сездә Әмин булса, бездә Әминә бар.**
**Мөселманда булмаса да булмас, әмма**
**Башкаларда «бог»ка каршы богиня бар!»—**

диләр алар.

Шул рәвешчә, беренче рус революциясе чорында татар хатын-кызлары арасында башланып киткән уяну хәрәкәте авыр реакция елларында да сүнми, яңа революцион күтәрелеш елларында тагын да җанлана. Бу чакларда әдәбиятта, вакытлы матбугатта яңадан-яңа хатын-кыз язучылары (Зәйнәп Сәгыйдә, Гыйффәт туташ — Заһидә Бурнашева, Рокыя Ибраһимия, Хәдичә Шаммасова, Мәфтуха Вәлидова, Әминә Мөхетдиния, Заһидә Байчурина, Әминә Мотыйгия һ. б.) исемнәре еш күренә. Аларның Тукай поэтик мәктәбе традициясе рухында язган шигырьләре, заман темасына караган хикәя, очерклары һәм публицистик мәкаләләре үз вакытының танылган газеталарында, зур күләмле әдәби журналларында («Шура», «Аң», «Сөембикә») Мәҗит Гафури, Галимҗан Ибраһимов, Шәриф Камал, Мирхәйдәр Фәйзи әсәрләре белән беррәттән басыла барлар.

Бу чорда матбугатта актив катнашкан алдынгы татар хатын-кыз язучылары арасында Мәхбүпҗамал Акчуринаның әдәби-культура эшчәнлеге аеруча игътибарга лаек. Ул 1896 елның мартында элекке Саратов губернасы Димау (Демино) авылында туа. Башлангыч белемне үз атасы Әхмәр мулладан ала. Үсә төшкән, шунда ук үзе дә кыз балалар укыта.

1892 елда, кияүгә чыгу сәбәпле, Мәхүпҗамал Самара губернасы Савинка авылына күчеп килә. Шунда ул берничә еллар аерым укытучыдан дәресләр ала, белемен үстерә, төп игътибарын рус телен һәм әдәбиятын өйрәнүгә бирә. Соңыннан бөтен гомерен яшь балаларны һәм хатын-кызларны тәрбияләү-агарту эшенә багышлый. Аның 1908 елдан башлап «Шура» журналында басылып чыккан мәкаләләре («Хифзе сиххәт» — 1908, «Багучылар»— 1910, «Аталар һәм балалар»— 1910, «Аналар дикъкатенә», «Карья күренешләре», «Тәрбия вә җәза» — 1911, «Балаларның уеннары һәм уенчыклары»— 1913 ел) шактый әһәмиятле мәсьәләләрне күтәрүе белән характерлы.

М. Акчуринаның хикәяләре дә тормыштан алынган булулары белән үзенчәлекле. «Мишәрләр тормышыннан бер ләүха» дигән очерк-хикәясендә автор үзе бала чакларында күргән бер фаҗигале вакыйганы тасвирлый.

Хикәя иске гореф-гадәтләрнең, ырымнарга ышануның авырлыгы, беренче чиратта, капитализм чорында бөтен хокукларыннан мәхрүм ителгән хатын-кызлар өстенә төшүен бик ачык күрсәтә. Әсәрдә сурәтләнгән вакыйга әллә ни катлаулы түгел. Майның урталарында кырау төшеп игеннәргә тия. Мәчет янына җыелган авыл картлары, куштаннары: «Я кырда үлек ятадыр, я ураза тотмый торганнар бардыр!»— дип шомланып сөйләнә торгач, гаепне дүрт бала анасы булган Хәбибҗамал исемле хатынга ташлыйлар. Имеш, ул күрше авылга кунакка барган вакытында Исмай улы исемле авылдашы белән икәүләп ураза вакытында көндез чәй эчкәннәр. Шуның шомлыгы кырау төшүгә сәбәп булган.

Бу коткыга, беренче нәүбәттә, Хәбибҗамалның ире Камал һәм халыкның бер өлеше ышана, алар, җыелып, хатынның өенә килеп, аны, мич башында авырып яткэн хәлендә булуына да карамастан, сөйрәп төшереп, урамга алып чыгалар. «Исмай улы» белән бергә икесенең кулларын бәйләп, өсләренә салкын су сибеп, битләрен карага буяп урам әйләндерә башлыйлар.

Бу темага якынрак әсәрләр татар әдәбиятында совет чорында да күп языла. М. Галиненң «Яңгырсыз елларда» хикәясе (1921), М. Гафуриның «Кара йөзләр» повесте (1926), Н. Исәнбәтнең «Миркәй белән Айсылу» драмасы (1931) әнә шундыйлардан. М. Акчурина хикәясе (1914) бу теманы башлап күтәрүе белән һәм реалистик планда яктыртуы белән дә әһәмиятле. Шунысы характерлы, язучы халыкка толпа итеп карамый, алар арасында коткыга бирелүчеләр белән беррәттән мәсьәләгә аек караучылар булуына да ишарә ясый. Котырынган толпа «гаеплеләрне» урам йөрткәндә, аларның каршыларына ак чәчле карчык килеп чыга да, ике кулын алга сузып: «Әй җәмәгать, туктагыз, бу кадәр шауламагыз! Инде бу хурлык җитмәгән, тагы да бөтен авылны йөртмәкче буласыз... Шундый изге рамазан аенда кеше рәнҗетәсез!.. Әй, акыллы картлар! Дөньяда моңарга кадәр кырау төшмәгән идеме?.. Староста, син үзең авыл башы! Көчлеләр көчсезләргә җәбер иткәндә булышасың... Күрмисеңме ул бичара хатын ничек калтырый. Әгәр авырып үлә калса, үзем гуаһ булып барырмын»,— ди.

Бу сүзләр халыкны беркадәр аңга китерә, берәм-берәм таралышалар. Язучы әле моның белән генә әсәренә нокта куймый, тормыш дәреслегенә турылыклы булып кала. Әлеге җәберләнгән хатынның, үзен хаксызга мәсхәрә иттергән, ерткычларча кыйнаган иреннән аерылуны сорап, мулла нигеге төбенә кат-кат баруын ачынып хикәя итә. Аерылу актын язу вакытында марка өчен кирәк булган бер сумны ире бирмәгәч: «Хәбибҗамал, кулындагы беләзеген салып: «Анамнан калган сагынмалык иде, хезмәт иткәч йолып алырмын, кайсыгыз булса шуңарга бер сум акча бирә торыгыз!»,— дип өзгәләнеп үтенгәч, шаһитларның берәве бер сум акча чыгарып бирде».

Менә шул рәвешчә, бу хикәядә иске авыл тормышы, андагы хатын-кызлар язмышы көзгедәге кебек күз алдына килеп баса. Хикәягә алынган вакыйганы тормышчан нигезе, әтрафлы тасвирлануы, социаль эчтәлеге (авыл куштаннары, мулла һәм старостаның йөзен ачып күрсәтүе) ягыннан М. Акчурина әсәре гаять отышлы. Мәсхәрәгә тартылучының ир хатыны булуы, халык арасыннан чыгып, аек фикерне әйтүче карчык образы — шул типиклыкны, тормышчанлыкны тагын да тулыландыралар.

Мәхбүпҗамал Акчуринаның шундый ук фаҗигале вакыйгаларны сурәтләүгә багышланган «Шәфкатьсез ата яки мишәрләр тормышы» дип аталган икенче озын хикәясе 1914 елда аерым китап булып Оренбургта басыла. Монда да әсәрнең баш

героинясы итеп хаксызга мәсхәрә ителгән авыл кызы — Гарифә алына. Хикәя түбәндәгечә башланып китә:

«Сентябрь аеның икенче атнасында сишәмбе көн сәгать 6 да Зарифә самовар куйды. 18 яшьлек үги кызы Гарифә өйне җыештырып, чынаякларны хәзерләде. Күрше рус авылларында базар булганга, тирә-яктагы татар һәм рус авылындагы кешеләр җәяүлесе, атлысы бер туктамый үтәләр. Һәр атнада шулай базар булганга, бу бер дә гаҗәп эш түгел. Ләкин ни өчендер бүген һәрбер үткән кешеләр боларның капкасына карый-карый, берәүләре куллары илә ишарә дә кыла иделәр. Зарифә, шәбһәгә төшеп, бер сүз әйтмичә урамга чыкты. Ни күзе илә күрсен, капканың яртыдан күп җире кап-кара, дегет илә буялмыш, Зарифә хәйран калып өйгә керде.

— Гарифә кызым, харап булдык. Капкабызны буяганнар. Инде атаңа ни җавап бирербез?— дип хәлдән тайган төсле урындыкка утырды.

Гарифә яшен суккан кеби калтырап китте».

Гарифәне бу хәлгә төшерүче — фәкыйрьләрнең «актык каннарын суыра торган Шәмси куштан улы Гайнулла». Ул авылның иң матур кызы Гарифәне үзенә карата алмагач, шул чакларның бозык гадәтләренә таяна. Бу чакларда кызның атасы авылларыннан ерак түгел фабрикада эшли, яман хәбәр аңа да барып ирешә. Кайткач, үзен-үзе белештерми, башта хатынын сугып ега, аннан кызын имгәткәнче кыйнап, өй алдына чыгарып, ябып куя. Бичара Гарифә бу кыйналудан беркадәр терелсә дә, салкын идәндә ятып алган чире — чехотка авыруы аны бик яшьләй кабергә илтә.

Мәхбүгҗамал шушы фаҗигале вакыйгаларга бәйләп, кешеләр арасындагы мөнәсәбәтләрне, авыл кулакларының халыкка китергән зарарын ачынып сурәтли. Хикәядә ерткычлыгы белән күрсәтелгән Шәмси Куштан улы Гайнулла М. Фәйзинең «Галиябану» драмасындагы Исмәгыйль образын хәтерләтә.

Хикәя шул чор мишәр авылларының этнографиясен, туй йолаларын төрле яктан күрсәтүе белән дә кызыклы.

М. Акчуринаның сезонлы эшчеләр тормышын чагылдырган, русчадан файдаланып язган «Хәммал Ягъкуб» (йөк ташучы Якуб — М. Г.) дип исемләнгән бер хикәясе 1915 елда аерым китап булып басыла. Ул чордагы эш шартларын, эшчеләр белән приказчиклар мөнәсәбәтен, гомумән, эшчеләрнең үз араларында төрле характерларның булуын күрсәтү ягыннан бу әсәр Ш. Камалның «Козгыннар оясында» хикәясенә аваздаш.

Авторның «Көчсезләр, мәэюс вә пессимистларга гыйбрәт» хикәясе оптимистик рухта язылган булуы белән әһәмиятле. Анда язучы үз кул көче белән көн итүче Бикмәй картның башыннан бик күп авырлыклар кичереп тә, төшенкелеккә бирелмәвен башкаларга үрнәк итеп куя.

М. Акчурина халык әкиятләреннән файдаланып та яза. Мисал итеп, «Таш кием» дип исемләнгән, әкият стилендә язылган бер әсәрен алырга мөмкин. Менә шушы әсәрләр Мәхбүпҗамал Акчуринаның революциягә кадәрге татар демократик прозасына шактый зур өлеш кертүен раслыйлар.

М. Акчурина хикәяләрендә генә түгел, мәкаләләрендә дә үз вакытының социаль тигезсезлек күренешләрен басым ясап күрсәтә. Мәкаләләренең берсендә ул либерал буржуа хатыннарының хезмәтчеләргә карата булган «гадел мөнәсәбәтләрен» фаш итеп: «Бу асраyларга ни мөкяфәт (хезмәт бәрабәренә бирелгән бүләк — М. Г.) бирәмез?— Еллык яки айлык хак, ашарга азык, йоклар өчен нинди булса бер почмак! Кулымыздагы хезмәтчеләрне коллар рәвешендә тотасыбыз килә. Менә моны инде гадәләт димез»,— дип көлә. Икенче бер урында зур тетрәнү белән: «Толстойның «Воскресенье»сен укыганда, йөрәкләр кысылып, гәүдә кырмыскалар йөргәндәй була. Андый Катюшалар бездә аз түгел. Тик аларның хәлләрен матбугат галәменә куючылар күренми»,— дип яза («Шура», 1911, 15 сан).

Башта искә алганыбызча, Мәхбүпҗамал Акчурина әдәби мирасны барлау, аны өйрәнү кирәклеге турында да мәкаләләр яза. 1911 елда «Шура» журналында басылган бер мәкаләсендә ул борынгы әдәби ядкарьләрдән «Сәйфелмөлек» һәм «Таһир илә Зөһрә» поэмаларына шактый тулы анализ ясый. Кешелекне күп гасырлар дулкынландырган саф мәхәббәт темасына багышланган бу әсәрләрнең эстетик, тәрбияви әһәмиятләре турында сөйли.

Мәкалә полемик рухта язылган. Ул чакларда яшь язучыларның бер төркеме дини эчтәлекле әсәрләр рәтеннән бу поэмаларны да татар хатын-кызларының гомерләрен бушка уздыруга сәбәп булган әсәрләр дип читкә кага башлаган. М. Акчурина әдәби мираска андый ваемсыз, берьяклы караш белән килешә алмый. «Кашки без, хатын-кызлар, бу китапларны укып, эчтәлекләрене аңлап, гомер сарыф иткән булса идек, без дә, бәлки, бу кадәр түбән, һичнәрсәдән хәбәрсез калмаган булыр идек. «Сәйфелмөлек»не аңлаган кызга башка китапларны аңлау да кыен булмас иде»,— дип яза. поэмадагы саф мәхәббәткә тугрылыклы геройларның эш-хәрәкәтләрен яшьләргә үрнәк итеп куя. Мәгъшукасы Бәдигыйҗамалны эзләгәндә нинди авырлыкларга төшүенә карамастан, Сәйфелмөлекнең юлыннан чигенмәвен сөйләп килә дә: «Безнең гасырның яшь каһарманнары, аз гына авырлык тою белән, кергән юлларыннан артка чигенүне бернигә дә санамыйлар»,— ди.

«Таһир илә Зөһрә» поэмасына М. Акчурина тагын да киңрәк туктала. Аның эчтәлеген, сюжет үстерелешен әдәби бер зәвык белән сөйләп чыга, поэманың конфликты нигезендә социаль тигезсезлек ятканын дөрес билгели. «Таһир күркәм, мәһабәт галим егет булса да, ятим вә фәкыйрьлегеннән, ханым (аны) үз кызына тиң күрмичә бар гомеренең җимеше булган бердәнбер кызыннан аерылз... Бу илла гыйбрәтле, күңелләргә тәэсир итә торган хикая нидән икән әхлак бозуга сәбәп була?»— дип яза.

М. Акчурина бу әсәргә кергән җырларның заманында үзләренә хас аерым көйләре булуы турында да искәртә. «Таһир илә Зөһрә» китабындагы җырларны борынгыдан калган көе илә җырлаганда, гаепләүче әфәнделәрнең күңелләре йомшарып, аркаларында кырмыскалар йөрүенә дә асла шөбһә итмим»,— ди. Шунда ук автор, киләчәктә «Сәйфелмөлек» һәм «Таһир—Зөһрә» кебек мәхәббәт поэмалары сюжетына опералар «куелуына өмет өзеп булмыйдыр» дип тә өсти.

Әдәбиятчы бу ышанычында ялгышмаган, «Таһир—Зөһрә» поэмасының татар һәм үзбәк поэзиясе антологиясенә кертелүе һәм аның сюжеты нигезендә кинофильм иҗат ителүе моны ачык күрсәтә.

М. Акчурина борынгы кулъязмалар арасыннан да әдәби кыйммәте булган җәүһәрләр табылу мөмкинлегенә тирәннән ышана. «Җәүһәр кадерен сарраф[1] белер» дигән мәкаль бар. Без шул сарраф булмый торып, асыл ташларны тикшерүгә керешеп, энҗене бисердән аера алмыйча ташладык... оят түгелме?»— ди ул «Шура» журналының 1917 ел, 7 нче санында басылган бер мәкаләсендә. Шунда ук борынгы әдәби ядкарьләрдән Суфи Аллаһиярның «Сәбател-гаҗизин» китабына тулы гына күзәтү ясый. Бу китапны элекке кадим мәктәпләрендә хәлфәләр, хәтта абыстайлар да укытканнар. М. Акчурина хаклы тәнкыйть иткәнчә, алар китапның мәгънәсенә үзләре дә төшенеп җитмәгән булганнар. Укытканнар, «...ләкин уку илә аңлау арасында бик зур аерма булганга, китапның әдәби файдасы яшерен калган. Билгеле, ул гаепне шәкертләр өстенә йөкләп булмый, остазы ни укытса, шуны укый биргән». Шул рәвешчә, халыкка әдәби әсәрләрнең чын кыйммәтен төшендерә алмауда төп гаепне М. Акчурина үзләрен галим-голамә дип санап йөргән хәлфәләргә һәм гомумән руханиларга йөкли. 1915 елның 15 мартында «Сөембикә» журналының 9 нчы санында басылган «Кемнән бу?» дигән мәкаләсендә дә автор халыкның артта калуына, бигрәк тә хатын-кызларның кол хәлендә изелеп яшәүләренә руханиларның бер сәбәпче булуларын күрсәтә.

М. Акчурина фольклор материалларын җыюга да зур игътибар биргән. Аның «Кыз елату» дигән бер мәкаләсе («Шура» журналы, 1911 ел, 20 сан) бу өлкәдә онытылып бара торган әдәби материалларны искә төшерә. Язучы, безнең татар хатын-кызлары арасыннан да сәләтле һәм батыр кешеләр булган дип сөйләп килә дә, шуны раслау өчен халык иҗатына мөрәҗәгать итә. «Борын заманда,— ди ул,— солдат кызга халык тарафыннан чыгарылган җыр (шигырь) исемә төшә. Борын заман булган Шәмсекамәр туташның зифа буйлы, озын чәчле, назакәтле сыйфаты күренгән төсле була. Моның соңында, аның солдат кимендә җәсарәтле[2] кыяфәттә солдатларга башлык итеп торуы күз алдыма килә...

---

[1] Сарраф — ювелир.
[2] Җәсарәтле — батырларча.

«Юк, юк, безне җәсарәтсез куркак иткән нәрсә тик наданлык. Наданлык богауларыны бозып ташласак, без дә башка милләт хатын-кызлары кыйлган мактаулы эшләрне кыйлырга ярарбыз».— дип, үземне юагам...

Шәмсекамәр туташ хакындагы җырларның исемдә калганнарыны җырлап җибәрәмен. Җырның мәфһүменә караганда: Шәмсекамәр туташ үзенең шәкерт энесене аяп, аның өчен солдатка китә. Бу эше өчен муллалар тарафыннан «шәригатькә хилаф» дигән сүзләрне дә ишеткән булырга охшый. Хәтта үзенең эшенә үкенүе дә аңлашыла. Тора-бара, җәсарәтле туташ, ир солдатлардан өстен чыгып, полковник дәрәҗәсенә ирешүе аңлашыладыр.

Иске җырларны сөюче ханым вә туташларга, үз каршымда кыйммәтле саналган җырның хәтеремдә калганнарын язып китүне мөнасип күрәм.

**Талибымны аядым, җанымны утка салдым,**
**Шәригатькә хилаф кылдым, военныйга тап булдым.**
**Кара каршы гурнича[1], уртасында кырлича[2]**
**Мин тугыйнча таш туса иде, кыздан солдат булгыйнча.**
**Тәрәзәдән карадым, майлап сачем тарадым,**
**Тал чыбыктай буй үстердем, падишага ярадым.**
**Җома[3] мәчет башында, ике асыл кош күк ала,**
**Кырык мең солдат арасында Шәмсекамәр чин ала.**
**Квартирам төбендә пар ат җиккән дружка,**
**Әтием майор, мин полковник, бергә чыгыйк орышка...**

Тәрәккый иткән милләтләр үзләренең каһарманнары, каһарманәләре хакында калын китаплар язып, исемнәрне мәңгегә калдырганнар. Безнең югары сыйныф саналган голамә кыйсмы андый «вак-төяк» нәрсәләр илә гомер зайыгъ итүгә кимсенгәннәр... Җырны, музыканы, «харам» дип күрсәтмәсәләр, җырларыбыз музыкага салына барса, бердән, югалмаслар; икенче(дән), үзләренең милли музыкаларны тыңлап, халыкта милли хисләр уяныр иде. Шул җырлар, музыка тавышы тәэсире илә йөрәкләр дулкынланып, башлар уйга чумса, миләребез бу кадәр оешып катмаган булыр иде» («Сөембикә» журналы, 9 сан, 1915 ел).

Бу мәкаләдән дә күренгәнчә, М. Акчурина кыю рәвештә реакцион руханиларга каршы чыга, халкыбызның тарихын, авыз иҗатын барлау ихтыяҗын искәртә. Шул рәвешчә, язучының иҗат интереслары гаять киң булган һәм ул үз чорының тормышын, үз халкының көнкүрешен нечкә күзәтеп барган, дигән нәтиҗәгә киләбез. Үз әсәрләрендә ул хатын-кызлар азатлыгы өчен генә түгел, гомумән, бөтен хезмәт халкының бәхетле тормышка чыгуы өчен көрәшкән.

Әсәрләрендә көткән шул бәхетле тормышны совет власте алып килгәнен язучы үз күзе белән күрә, 1929 елдан башлап 1948 елга кадәр — вафат булганчы Бакуда яши. 1934 елда М. Акчурина Азербайҗан язучыларының I съездына кунак итеп чакырыла һәм съездның утырышларында катнаша.

Күргәнебезчә, М. Акчурина — әдәби мираска зур ихтирам белән караган язучы. Үз чиратыбызда без аның күпкырлы иҗат мирасын игътибар белән өйрәнергә, реалистик хикәяләре һәм әдәби тәнкыйть мәкаләләре белән яшь буынны таныштырырга бурычлыбыз.

Зәйнәп Сәгыйдәнең[4] дә шигырь һәм хикәяләре социаль эчтәлекле булулары белән аерылып торалар. Ул яшәештә булган хаксызлыкларга протест белдереп чыга, укучыларны уйланырга, тигезсезлекләрнең сәбәпләрен эзләргә этәрә. «Нигә соң алай?» дип исемләнгән шигырендә:

**Ник табигатьтә тигез түгел икән бу дөньясы:**
**Берсе ярлы, берсе бай, берсенең юк анасы!**

---

[1] Гурнича — ак өй.
[2] Кырлича — баскыч.
[3] Җома — җомга.
[4] Зәйнәп Сәгыйдәнең шигырьләре вакытында өйрәнелмәгән булу сәбәпле, кызганычка каршы, «Татар поэзиясе антологиясе»нә керми калган иде. Хөрмәтле шагыйрәбез исән, 86 нчы яше белән бара, Ташкентта кызы Сөмбел белән яши.

**Бер ягында — анда җәннәт, анда нурлар ялтырый,**
**Бер ягында — ярлы мескеннәр елый, икмәк сорый...**

(«Шура» 1915, 12 сан, 375 бит)



Шагыйрәнең татар демократик прозасына керткән өлеше игътибарга лаек. Яшьтән үк хезмәт кешеләренә теләктәш булып үскән З. Сәгыйдә «Юләр егет» (1915) дигән әсәрендә беренче империалистик сугыш елларында сезонлы татар эшчеләре тормышыннан гаять характерлы бер эпизодны сурәтли. Хикәянең баш герое — тормыш авырлыклары алдында җиңелеп калырга теләмәгән, ял вакытларында башка эшчеләрнең дә күңелләрен ачарга сәләтле булган яшь эшче егет. Аның һәрвакыт уенчак табигатьле булуыннан чыгып, кайберәүләр «акылы ким, утыз тугыз кадак кына, бичара» дип саныйлар һәм аңа «юләр егет» дигән кушамат тагалар. Аның шундый характерыннан мойка приказчиклары да файдаланалар. Көннәрнең берендә, мойкада кызу эш барганда, җитмеш биш тиенлек тимер эш коралы суга төшә. Әлеге егет, иптәшләренең соравы, приказчикның кушуы буенча салкын суга чумып, шул тимер кисәген алып бирә.

Ә бервакыт су коенганда егет үзе бата башлый. Хикәядә яр башыннан хуҗаның, приказчикның һәм бик күп башка куштаннарның илтифатсыз гына аның батканын карап торулары ачы нәфрәт белән сурәтләнә. Тик шул вакытта эшче кызларының берсенең: «Нишләп торасыз, таш йөрәкләр!» — дип кычкыруына, араларыннан икенче батыр егет, уянып киткәндәй булып, тиз генә чишенеп суга ташлана һәм иптәшен коткара. «Яр читендәге халык «юләр»не чолгап алдылар, аның уңайсыз хәлдә булуына да карамый, суга төшкәнлеге өчен әрли башладылар. Халыкның әрләвенә каршы ул бары бер генә сүз әйтә иде:

— Кеше тимер артыннан суга төшә, ә кеше артыннан кеше төшми!»

Шул рәвешчә, хуҗа һәм ялчы-приказчикларның кешелексезлеге дә, капитализм чорында үз интересы белән генә яшәүче, иптәшлек хисләрен җуйган кайбер каты күңелле кешеләрнең хезмәт ияләренең үз араларында булуы да хикәядә нәфрәт уты астына алына. «Тормышыбызда көн дә диярлек көчләләр тарафыннан көчсезләргә ителеп торган мөгамәләләрне күреп уйга таласың да, ихтыярсыз: «Дөрес әйткән «юләр егет»,— дисең,— кеше тимер түгел — аның артыннан суга төшмиләр». Бу соңгы искәрмә З. Сәгыйдә хикәясенә ачык публицистик тон бирә, капиталистик мөнәсәбәтләрне гаепләп чыга.

Хикәядә икенче дәрәҗәдәге образларның характерларын ачу өчен дә кыска, ләкин бик тапкыр детальләр табылган, төрле социаль катлаудан туплана килгән сезонлы эшчеләрнең үзенчәлекле сыйфатларын ачып бирә алырлык бик матур картиналар иҗат ителгән: әнә «һаваның бозык, көннең эссе вакытларында өсләреннән карауччы приказчикларның тәрбиясез мөгамәләләренә игътибар итми җырлап йөри торган эшче кызлар... Әнә бәхетсез никах аркасында үзенең карт мөэзиннән ташлап, мойкага килеп кергән яшь хатын... Әнә, кеше барына-югына карамый, бертуктаумый сукранып йөри торган карчык... Менә тагы үзен ничектер Николаевский солдатлар җөмләсеннән саный торган каравылчы бабай да, скрипкасы кулында булса да, уйнамый, уйга чумган... Әнә гомеренең өчтән ике өлешен мәдрәсәдә үткәргән вә бертуктамый укып йөрүе белән «ишан» исемен алган шәкерт... һәм бер ахунның бик кадерле баласы булып үсеп тә, мәдрәсә почмагыннан мойкага ташланган мәхдүм...» З. Сәгыйдә эшчеләр сыйныфының төрле социаль катлаулар эченнән, беренче чиратта, изелүчеләр арасыннан чыккан кешеләр хисабына тулылана баруын күрсәтә. Хикәянең бер әһәмиятле ягы әнә шунда.

Татар хатын-кыз язучылары матбугат һәм, гомумән, әдәбиятның кешелек тормышында тоткан урынын аңлау һәм аңлатуга шактый кыю омтылыш ясыйлар. Хатын-кызлардан беренче буларак китаплары дөнья күргән Хәнифә Гыйлмәтуллина үзенең 1895 нче елда басылган «Тәргыйб» (кызыксындыру — М. Г.) дип аталган китабында: «Матбугат җөмлә кавемнәрнең (барлык халыкларның — М. Г.) тәрәккыйләренә хезмәт итә. Бер-беремезнең сүземезне икенчегә ирештермәк хосусында олуг васыйта»,— дип матбугатның зур аралашу чарасы булуына һәм прогресска хезмәт итүенә игътибарны юнәлтә.

Татар шагыйрьләренең поэзиянең тәэсир итү көчен дә тирәннән аңлап эш итүләре күренә. Мәсәлән, Мәфтуха Вәлидова 1915 елда басылган «Күңел бүләкләре» дип аталган җыентыгының керешендә: «Шигырь инсанның иң нечкә хисләрен кузгату илә бәрабәр, инсанга икенче рух тәэсир иттерә... Шуның өчен дә иң хәзин (кайгылы — М. Г.) адәмнәр дә шигырь укысалар, яхуд тыңласалар, күңелләре нечкәреп үзләрендә бер төрле шатлык хис итә башлыйлар вә башка эшләргә дә рәгъбәтләре (дәртләре — М. Г.) артадыр»,— дип ассызыклап күрсәтә.

Хатын-кыз язучылар Габдулла Тукайның үзләренә ясаган бәрәкәтле тәэсире турында гына язу белән чикләнмичә, аның иҗатына объектив бәя бирүдә дә актив катнашалар. Мәһруй Мозаффария «Габдулла әфәнде Тукаевның хатын-кыз галәменә тәэсире» дигән мәкаләсендә, беренчеләрдән булып: «Габдулла Тукай хакыйкый халык шагыйре иде...» — дип язып чыга. («Мәктәп» журналы, 1913, апрель).

Халык шагыйре иҗатына әтрафлы анализ ясаган хезмәтләр арасында Мәрьям Мөхетдиниянең 1916 елда, «Аң» журналының 6 санында басылган «Габдулла Тукаев әдәбияты» дип исемләнгән мәкаләсе аеруча үзенчәлекле. Тәнкыйтьче анда Тукай иҗатының гаять күпкырлы һәм социаль эчтәлекле булуына басым ясый: «Күп шагыйрьләр, тормышның бер генә ягын көйләүләре белән, хәят агымыннан аерылган бер зәгыйфь зат тойгысын бирәләр... Тукай... шигырьләрендә... искә төшерелмичә үткәрелгән хәятның һичбер тармагы юк...»,— ди. М. Мөхетдиния шул уңай белән Тукай иҗатының, Тютчев, Фет һәм Надсоннарга караганда, Лермонтовка якынрак булуын искәртә. Шагыйрьнең борчылулы уйлары халыкның авыр тормышына бәйле булуын әйтә, фикерләрен раслау өчен «Көзге җилләр», «Дин вә гавам» кебек социаль эчтәлекле шигырьләрдән мисаллар китерә. Мәкалә авторы Тукай иҗатының асылда оптимистик характерда булуын, аның яшьләргә һәм киләчәккә зур өметләр баглавын «Әдәбият ахшамы ясаучы яшьләр», «Сагыныр вакытлар», «Шагыйрь» кебек шигырьләреннән өзекләр китерү белән раслый. «Шунда ук ул шагыйрь иҗатын яшьләргә дөрес аңлатуның зарурилыгына да басым ясап күрсәтә, үзенең мәкаләсен Тукайның «калдырган бүләкләре хәзерге һәм киләчәк буын татар балаларының рухын тәрбия итәчәк, аның тирән мәгънәле шигырьләре күп кешеләрне якты яңа тормышка алып барачаклар»,— дип тәмамлый.

Күреп узганыбызча, XIX йөзнең соңгы чирегендә матбугатка килгән татар хатын-кыз язучылары 1905 ел революциясе чорында тагын да җанланып, соңрак зур әдәби эшчәнлек күрсәтәләр. Алар инде тәрбияви-педагогик эшчәнлекләре, үзләренә азатлык яулап язган ялкынлы публицистик мәкаләләре белән генә түгел, бәлки татар демократик поэзиясе, реалистик прозасы һәм өлешчә әдәби тәнкыйть үсешенә дә мәгълүм өлеш кертәләр.

Соңгы вакытта чыккан хезмәтләрдә әлеге исемнәр искә алынып, кайберләренең иҗат биографияләре белән таныштыру омтылышы булса да, әле һаман да революциягә кадәр иҗат иткән хатын-кызларның үз әсәрләре газета-журналларда яки аерым җыентыкларда гарәп хәрефләре белән басылган хәлендә генә саклана. Хәзерге укучыларның күпчелеге бу хәзинәдән тиешенчә файдалана алмый тора. Бернича шагыйрәнең аерым әсәрләре «Татар поэзиясе антологиясе»нә кертелү һәм Зәһирә Байчурина, Газизә Сәмитоваларның сайланма әсәрләре басылып чыгу гына әле ул бушлыкны тутыра алмый. Авыр елларда йөрәк җылысын салып, киләчәккә якты өметләр баглап иҗат иткән татар хатын-кызларының тарихи әһәмиятле әсәрләре белән яшь буынны киңрәк таныштыру безнең алда зур бурыч булып кала.

Фәрит Хатипов

# СОКЛАНАМ ҺӘМ УЙЛАНАМ

Бүгенге проза хакында бәхәс ачуга каршы килүчеләр булмады кебек. Чыннан да, эпик жанрларның хәзерге хәле, киләчәге, ил-көн алдындагы абруе мәсьәләсе укучыларны да, язучыларны да хәтсездән борчып килә. А. Гыйләҗевнең йөрәге янып, чаң сугуы бер дә юкка түгел. Ачыклыйсы, хәл итәсе нәрсәләр байтак җыйналган. Хәзер безгә прозаның уңышларын, иҗади казанышларын хуҗаларча барлап, кимчелекләрне ачып, үсеш юнәлешен төгәл билгеләргә кирәк. Уртага салып гәпләшүдән тик бер генә нәтиҗә көтелә — кимчелекләрнең сәбәпләрен ачыклап, яңа сыйфат сикереше өчен юл яру. Бу исә бик күп нәрсәгә: гомум иҗат атмосферасына, таләпләр бердәмлегенә, бәяләрнең төгәллегенә һәм, барыннан да бигрәк, талантның дәртләнеп, олы максатлар белән янып эшләвенә, яңа иҗат биеклекләренә омтылуына бәйләнгән.

Татар совет прозасының зур таләпләр куеп сөйләшерлек ныклы җирлеге бар. Ул «Хәят», «Фәтхулла хәзрәт», «Акчарлаклар», «Матур туганда», «Казакъ кызы», «Кара йөзләр», «Рәүфә», «Агыйдел», «Тапшырылмаган хатлар», «Маякчы кызы» тәҗрибәләренә таянып иҗат итә. Мәдәният тарихында һәркайсы зур урын алып торган бу әсәрләр әдәбиятыбызга югары художестволылык үрнәген алып килделәр, сәнгатьчә фикерләүнең яңа биеклекләрен тудырдылар, әдәбият сөючеләрдә югары зәвык тәрбияләделәр. Сугыштан соңгы елларда һәм безнең көннәрдә болар янына «Тукай», «Язгы җилләр», «Намус», «Йөзек кашы», «Җәяүле кеше сукмагы», «Онытылмас еллар», «Сүнмәс утлар», «Саз чәчәге», «Әйтелмәгән васыять», «Тынычлану», «Чын сөю бармы?», «Авылдашым Нәби», «Йолдызым», «Әтил суы ака торур» кебек гүзәл әсәрләр килеп кушылды. Алар укучыларны фикернең масштаблылыгы, проблемаларның җитдилеге, тормыш серләренә, кеше күңеленә үтеп керүнең тирәнлеге, образларның терелеге, характерларның ачыклыгы, телнең лиризмы, моңы белән — кыскасы, сәнгатьчә матурлыклары, бөтенлекләре белән сокландыралар.

Эпик хикәяләүнең күтәрелешендә өлкән буын язучыларының хезмәте зур булды. Аларның күбесе әдәбиятка тормыш төбеннән күтәрелеп, фронтлардан, завод-фабрикалардан, бураздадан килеп керделәр. Беренче адымнарын атлап киткәндә әле теоретик әзерлекләре дә юкарак, дөнья классикасы белән танышлык та чамалырак иде. Әмма тырышлык, эш сөючәнлек, сәнгать биеклекләренә омтылыш бик көчле иде. Шулар ярдәмендә сәләтләре, талантлары әсәрдән әсәргә ныграк ачыла барды, һәм тора-бара алар дөнья әдәбияты тиңендәге әсәрләр иҗат итү осталыгына ирештеләр. Әйбәт хикәя, повесть, роман язуны алар намус эше, тормышның, яшәешнең төп мәгънәсе дип карыйлар. Прозага керешкәнче Ш. Маннур шагыйрь буларак үзенең иҗат йөзен инде тәмам ачып җиткергән иде. Тәүге романында ул гаять киеренке, героик-драматик темага мөрәҗәгать итте. Дөнья әдәбиятында шуңа охшаш материал җирлегендә җанны тетрәтерлек көчле әсәрләр иҗат ителгәнлеге мәгълүм. Ш. Маннур исә, яңа жанрга күчү белән, әле тиз генә үз стилен табып җиткерә алмады, романдагы Муса образы тормыштагы реаль шәхестән кайтышрак булып чыкты. Бу тема әле прозада үзенең талантлы иҗатчыларын көтә. Әмма Ш. Маннур, өлкән яшьтә булуына да карамастан, прозаик буларак әсәрдән әсәргә үсә барды. Аның «Чын сөю бармы?» лирик повесте бөтен прозасының таҗын билгели.

«Чын сөю бармы?» повесте, чәчмә формада хикәяләнсә дә, матур поэма кебек укыла, яңгырашы, бөтен аһәңе белән шигъри поэмага якын тора. Анда хисләр, моңсу кичерешләр зур урын ала, кабатланмас язмышлар, гыйбрәтле хәлләр, ялгышулар, үкенечләр күрсәтелә, мәхәббәт тантанасы белән аның драмалары аралаша. «Безнең беренче сөюләр саф иде, якты иде, мәңге онытылмас җыр иде...»,— ди геройларның берсе. Бу сүзләр бөтен повестьның рухын билгелиләр. Автор сөю хисен кешенең бөтен табигате, әхлак йөзе белән бәйләнештә карый, еш кына мәхәббәт, тойгы каршылыкларының иҗтимагый конфликтларга барып тоташканлыгын, интим хисләрнең социальлеген күрсәтә.

Өлкәннәр турында сүз чыккач, Г. Бәшировның да яшьләрчә илһамланып, дәртләнеп язуын әйтеп китмичә булмый. Ул заман рухына аваздаш яңгырашлы, өлгергән фикерле, интеллектуаль бай, эмоциональ аһәңле «Җидегән чишмә» исемле кыю китап иҗат итте. Биредә тирән фәлсәфилек белән тойгы-кичерешләр муллыгы органик үрелеп бара. Аның шушы арада басылып чыккан «Сарут» хикәясе халык рухын үзенчәлекле яктан килеп яктырта, халык этикасына, әхлак нормаларына кизәнүнең драмасын чагылдыра.

Әңгәмәне ачып җибәргән мәкаләсендә А. Гыйләҗев хәзерге әдипләрдән аеруча Ә. Еники, Н. Фәттах, М. Мәһдиев әсәрләрен зур кызыксыну белән укуы, аларга кат-кат әйләнеп кайтуы турында яза. Р. Мостафин моның белән килешми. «Бу язучыларның бер генә әсәренең дә, әйтик, Ч. Айтматов, М. Кәрим, М. Слуцкис, А. Нурпеисов әсәрләре кебек, гомумсоюз күләмендә чын киң яңгыраш алганы юк»,— ди. Бу мәгънәдә, миңа шулай да Аяз фикере аңлаешлырак тоела. Әгәр дә мәсьәләне тәрҗемә сыйфатына, китапларның үзәктә басылып таратылуына гына кайтарып калдырмасак, объектив художество дәрәҗәсенә карап фикер йөртсәк, күренекле әсәрләребезнең сәнгатьчә фикерләү ягыннан гомум әдәбият казанышлары югарылыгында иҗат ителгәнлеге аңлашылыр. Ә. Еникинең кайбер гүзәл хикәя-повестьларын чын мәгънәсендә шедеврлар рәтеннән карарга була. «Әйтелмәгән васыять»не башлап җибәргән моңсу табигать күренешен генә күз алдына китерегез. Хрестоматияләргә кереп китәрдәй, шагыйрьләр игътибарын җәлеп итәрдәй андый чын поэтик юллар әдәбиятта күпләп очрамый. Аның әсәрләрендә һәр деталь сәнгатьчә камиллек дәрәҗәсенә җиткереп эшкәртелгән, мәгънәле, эстетик тәэсирле була. Ә. Еники тасвирлау өчен шактый кыен өлкәне — күңел тибрәнешен — үзенә бер төрле осталык, төгәллек белән сурәтләп бирә белә. Моңа тагын әдипнең тормыш сулышына үтә сизгерлеген дә китереп кушыйк. Ә. Еники — күп кенә якты образлар иҗат иткән язучы. Шулар белән берррәттән ул халыкның рухи-әхлакый байлыклары, югары идеал хакына мещанлыкка каршы көрәш турында менә дигән әсәрләр язып чыкты. Хәзер ул проблемаларны күп кенә танылган совет язучылары үз иҗатларында гәүдәләндерәләр. Турысын әйткәндә, без Ә. Еники әсәрләренең эстетик кыйммәтен дә башка халыкларда шундыйрак китаплар басылып чыккач кына ачыграк күрә һәм төшенә башладык. Аңа хәтле шактый гомерне Еники әсәрләре белән бәхәсләшеп үткәрдек, аларны кире кагуга байтак көч салдык. Язучы исә, шау-шулар, буш яңгыраулар аркылы күркәм сабырлык һәм түземлелек белән үтеп, акрын, ләкин тайпылышсыз рәвештә укучының җылы карашын үзенә җыя килде. Һәм тирән уйларга салырдай, хисләр ташкыны кузгатырдай сокландыргыч әсәрләре белән укучы күңелендә кадерле урын биләп алды. Р. Мостафинның «ул соңгы елларда иҗат активлыгын сизелерлек киметте» дигән, минемчә, хакыйкатькә туры килми. Дөрес, әсәрләрнең үрчемлелеге җәһәтеннән ул кемнәрдәндер бәлки калышадыр да. Ләкин шулай да мин Ә. Еникине пассивлашты димәс идем. 1979 елда ул — «Тынычлану», 1981 дә — «Соңгы китап»ның беренче өлешен, 1982 дә — икенче өлешен бастырды. Ә. Еники кабаланмыйча-каударланмыйча, җиренә җиткереп яза, шуңа күрә һәр әсәре зур кызыксыну белән көтеп алына, күзгә күренерлек була.

Инде Н. Фәттах иҗатының ил күләмендә яңгырашы мәсьәләсенә килгәндә, аның әле, беренче романыннан башка, күренекле әсәрләре тәрҗемәсенең үзәк матбугатка тәкъдим ителгәне юк. Тәкъдим ителсәләр, игътибардан бөтенләй үк читтә калмаслар иде дип уйлыйм. Татарстан китап нәшриятында йөз мең тираж белән русча басылган «Этил суы ака торур...» романы, кайнар комга сибелгән су кебек, күз ачып йомган арада сеңде дә бетте. Үзәк матбугат аны дөнья әдәбияты җәүһәрләре белән

бер рәткә куеп карады, классик традицияләрдә, Вальтер Скотт традицияләрендә язылган дип бәяләде [1]. Әдәбиятыбызны үстерү, зур максатларга рухландыру хакына аның аеруча зур казанышларын киң пропагандалау, ил бәясенә тәкъдим итү юнәлешендә иҗат оешмасыннан активрак, кыюрак эш алып бару сорала. Югыйсә бездә «Язгы җилләр», «Намус»лардан соң да күренекле әсәрләр иҗат ителде бит: «Онытылмас еллар», «Җәяүле кеше сукмагы», тиңдәшсез «Татар халык мәкальләре» китаплары... Алар нишләптер ил күләмендәге бүләкләргә тәкъдим ителми калдылар. Хәзерге көндә киң танылган әдипләрдән Ә. Еники, Н. Фәттах иҗаты да, минемчә, хуплауга, югары бәягә лаеклы.

Күптән түгел Н. Фәттах беренчесе кебек үк киеренке-мавыктыргыч сюжетлы, этнографик бай колоритлы, борынгы хәятның бик үзенчәлекле якларын яктырткан «Сызгыра торган уклар» исемле яңа тарихи романын бастырып чыгарды. Биредә автор төрки кабиләләренең моннан егерме ике гасырлар чамасы элек яшәгән дәверен җанлы картиналарда безнең күз алдына китереп бастыра. Сөн дәүләтенең ханы Туман каганның, мәкерле интриган Исәнтәй-Банхуа коткысына бирелеп, мәгънәсезгә яуга чыгуын, берничә йөз меңле гаскәрен һәлак итүен тасвирлый. Кайберәүләрнең тарихны искелек, арттальк дип карау ихтималын күздә тотып, автор: юк, тарих ул искелек, артталык кына түгел, ул барыннан да бигрәк гыйбрәт, акыл һәм тәҗрибә, дип раслый, үткәндәге, ерактагы гыйбрәтле сабаклар бүгенге тынычлыкның кадерен белергә өйрәтә, аны күз карасыдай актив сакларга өнди, дигән фикер уздыра.

Авторның бу концепциясе ил-дәүләт тормышындагы бик зур һәм дәвамлы вакыйгаларга корылган. Шуңа күрә алар бер генә китапка сыеп бетмәгән. Әсәр берничә китап рәвешендә уйланылган. Дилогия, трилогияләр язу омтылышы безнең әдәбият өчен дә бөтенләй үк яңа күренеш түгел, әлбәттә. Мондый теләк күренекле әдипләребездә инде гасыр башында ук туган иде. Ләкин шулай да чын сәнгать дәрәҗәсендә төгәлләнгәннәре күп түгел әле. Кайчак беренче китапта ук әсәрнең проблематикасы ачылып, чишелеп бетә дә, икенчесенә ясалма ситуацияләр генә кала. Аерым очракларда хәтта авторның бер китапта әйтердәй фикере дә булмый, ә ул әле шуның дәвамын язып чыга, «дилогия иҗат итә». Дилогия, трилогия, тетралогияләр — алар, әдәбият практикасы күрсәткәнчә, охшаш, якын темалы әсәр буыннары түгел, бәлки, бердәм организм кебек, катлаулы, киң масштаблы, ләкин бердәм темалы, бердәм ситуацияле әсәр. Бу мәгънәдә «Сызгыра торган уклар»ның дәвамлы булуы үзен тулысынча аклый. Беренче китап иң мавыктыргыч мәлдә, укучы дикъкатен үтә киеренке хәлгә куйган драматик вакыйга белән — баш герой Албуганың әсирлеккә төшүе белән тәмамлана, укучыда аның язмышы, Туңгак алыпның хәле, ил-көн язмышы турында зур кызыксыну хисе туып кала.

Биредә талантлы язучы һәм галим М. Мәһдиев стиленә дә аерым тукталып китәсе килә. М. Мәһдиев — шаян рухлы, шул ук вакытта моңсу-лирик әсәрләр иҗат иткән язучы. Ул бик үзенчәлекле, ачык төсмерләнгән характерларны сурәтләргә ярата, хәрәкәт дәвамында ук характерларның яңадан-яңа якларын ача килә. Аның әсәрләре безнең күз алдына характер, концепция повестьлары кыяфәтендә килеп басалар. Әдип стилендә кеше холкының индивидуаль чагылышын сурәтләгән картиналар белән гомумиләштерү рәвешендәге сөземтәләр аралашып баралар. Мондый үрелү, ихтимал, образлы һәм фәнни фикерләүнең кушылуыннан да киләдер. Кыскасы, аның роман-повестьларыннан үзенә бер төрле ягымлылык, җорлык, моң сирпелә.

Шул ук вакытта М. Мәһдиевнең файдаланып җиткерелмәгән ресурслары да бар кебек күренә әле. Еш кына ул әсәрләрен характерларга, мәзәкчел күренешләргә кора һәм, иҗади бәхәс ачкандай, тоташ сюжетның, бердәм ситуациянең ролен бик нык кимetә. Әсәр мәйданында аның әлеге ачык характерлы геройлары, үзенчәлекле вакыйгалар еш кына бәйләнешсез хәлдә яшиләр. Ф. Зөлкарнәев әйтмешли, алар җептән ычкынып киткән сәйләннәрне хәтерләтәләр. Мондый тәзелеш әсәрнең тотрыклылыгын, тәэсир көчен киметә. Матур әдәбиятта сюжет ярдәмче алым гына түгел, ул чынбарлыкны чагылдыруның төп чараларыннан берсе. Әдәбият тормышны хәрәкәттә, бары тик аның үз агышында гына күрсәтә. Ә сюжет — шушы процессны

[1] «Литературное обозрение», 1980, № 1, 82 б.

белдерү чарасы ул. Агачның яфраклары, ботаклары — кәүсәгә, ә кәүсә тамырлар ярдәмендә җиргә тотынып торган шикелле, әдәби әсәрнең барлык компонентлары да сюжетка берегеп торалар, алар хәрәкәт барышында гына әсәр мәйданына кереп урнашалар. Тәзүче кирпечләрне үзара измә белән ябыштырган шикелле, әдип ул компонентларны бердәм ситуациягә бәйли, бәйләнмәстәйләрен бу әсәренә керт-мичә калдыра. Үзенчәлекле характерлар белән киеренке тоташ сюжетның кушылуы нинди зур эстетик көчкә ия булганлыгы бөтен әдәбият тарихы белән генә түгел, М. Мәһдиевнең үзенең «Фронтовиклар»ы мисалы белән дә раслана...

Бүгенге әдәбият үсешенә урта буын язучылар сизелерлек өлеш кертәләр. Өлкән әдипләребездән үзгә буларак, урта буын язучылары әдәбиятка ныклы гына теоретик әзерлек белән килделәр, әдәби осталык серләренә җиңелрәк төшенделәр. Р. Төхфәтуллин, Н. Фәттах, Г. Ахунов, Ә. Баян, А. Гыйләҗев, М. Юныс, В. Нуруллин, Э. Касыймов, Х. Хәйруллин, Х. Камалов, Ш. Бикчурин, Г. Рәхим матур-матур роман, повестьлары белән укучы игътибарын җәлеп иттеләр, һичшиксез талантлы, сәләтле язучы икәнлекләрен расладылар.

Күптән түгел басылып чыккан әсәрләрдән тәнкыйть В. Нуруллинның «Аккан су юлын табар», «һәлакәт», А. Гыйләҗевнең «Җомга көн кич белән», «Әтәч менгән читәнгә» повестьларын уңай бәяләде. Минем үземә шулай да «Аккан су юлын табар», «Җомга көн кич белән» әсәрләре ныграк тәэсир итте, кыюлыклары, җитдилекләре, гражданлык позициясенең активлыгы һәм ачыклыгы, олы мәсьәләләрне яктыртулары белән ошадылар. Сүз, әлбәттә, шаян, җиңелчә рухтагы әсәрләрне өнәмәү турында бармый, һәрберсенең әдәбиятта үз урыны бар.

«Әтәч менгән читәнгә» повесте моңарчы җитди әсәрләре белән танылган әдипнең көлкеле повесть язарга да сәләтле икәнлеген күрсәтте. Бирердә автор шаян сүзләр арасына җитди-җитди генә фикерләр дә кыстырып бара. Язучы авыл тормышын, ике күрше йортның бозылышып китүен сурәтли, мөнәсәбәтләр кискенләшүенең сәбәбен бүгенге җитешле тормышта яшәүдә, көнчелек хисләренең баш калкытуында, саранлыкта, кирәк-яракны әрәм-шәрәм итмәүдә дип аңлата.

Алга чыгу омтылышын образлы рәвештә күз алдына китерү өчен булса кирәк, автор Хәйдәр белән Мидхәтне «Жигули» һәм «Москвич» машиналарында узыштыра. Иң зур тизлеккә җиткәч, «очып диярлек барган шәпкә ике машина икесе дә казылган җиргә борыннары белән барып төртелделәр». Автор, күрәсез, геройларына котылгысыз һәлакәт ситуациясе әзерли. Әмма нәтиҗә бу хәтәр ситуациягә тәңгәл килми: кешеләрнең өчесе дә исән кала, машиналарның берсе үз аягы белән китә, икенчесен бераз ремонтларга туры килә. Әлбәттә, геройларын хәвефле хәлдән җиңел котылдыру авторның үз иркендә. Әмма ул чагында әдип шуңа кулай ситуация төзергә бурычлы — артык та түгел, ким дә түгел. Сәбәп белән нәтиҗәнең ярашмау мисалларын без сәләтсез язучыларда күпләп очратабыз. Әллә соң бу җәһәттән алар талантлы язучыларыбызга да йогынты ясый башладылармы, дип уйлап куясың. Булыр да. Байтак эстетик грамотасызлык тәнкыйтьләнми калган кебек, сәбәп-нәтиҗә төгәлсезлекләренә дә тәнкыйть җитәрлек игътибар итмичә узып китә.

Сәнгать биеклекләренә күтәрелер өчен урта буын язучыларының иҗатына кайчак концепция, художество тигезлеге җитеп бетми, бер үк авторның әсәрләрендә бу җәһәттән шактый зур аерма күренә. Киң танылган язучыларыбызның илһамланып, тирән уйланып иҗат ителгән бер дигән әсәрләреннән соң ук әлеге авторларның иҗат мөмкинлекләреннән күп түбән, йомшак әсәрләре басылып чыкты. Х. Хәйруллинның «Канатлар талмасын» һәм аннан соң язылган «Картлык кемгә шатлык?» повестьларын күздә тотып, А. Гыйләҗев мондый хәлне тормыш тәҗрибәсенең, күзәтүләрнең сайлыгы, иҗат түленең юкалыгы, бер генә әсәргә җитәрлек булуы белән аңлата. Аерым авторларга карата бәлки бу фараз туры да киләдер. Ләкин контраст сыйфатлы әсәрләр бирүчеләр арасында иҗади бушанып калучылар, кризистан мантып китмәүчеләр генә түгел, бәлки бөтен тормышын әдәбият белән бәйләгән, анда үзенең лаеклы урынын тапкан күп кенә язучылар да бар бит. Әлеге уңышсызлыкларының нигезендә, минемчә, язу процессын җиңеләштерергә чамалау, рухи киеренкелекнең кимүе, иҗат ялкынының сүрелүе ята булса кирәк. Игътибар итегез: һәр яхшы әсәр күп көч куеп, тормыш закончалыклары,

кешеләр характеры турында тирән уйланып, озак вакыт язылган. Ә шулардан соңгы йомшаклары, төссез-чырайсызлары бик тиз арада, алдагыларына ябышып диярлек килеп чыктылар. Димәк, иҗат энергиясе төрлесенә төрлечә сарыф ителгән булып чыга: яхшыларына — күп, начарларына — бик аз. Кайчак язучыларыбыз үз әсәрләренә килешле, мәгънәле яңгырардай исем бирү турында да баш ватып тормыйлар, тоталар да калька кушалар.

Дөресен әйткәндә, әгәр дә бөтенсоюз әдәбиятыннан калышмыйк дисәк, әлеге язучыларыбызның яхшы, бик яхшы дигән әсәрләренең художество дәрәҗәсеннән дә беркадәр югарырак күтәреләсе бар әле. Соңгы утыз ел эчендә матур гына әсәрләр языла торды, әмма вакыйга булырлык, ил хуплавына лаеклы роман, повестьлар тумады. Озын тарихы, бай традициясе булган әдәбият өчен моны һич тә табигый хәл дип карау мөмкин түгел. Сәбәп нәрсәдә соң? Барына канәгать булу, беркадәр масаю, зур максатлар куймау, ватылмыйча, таушалмыйчарак, аяк өсте язарга җайлаша бару түгел микән? Җыелышларда күңелләрнең гел мактау дулкыннарына гына көйләнүе, кимчелекләрне аз гына күрсәткән тәнкыйтьнең дә хупланмавы әнә шул хакта сөйләмиме?

Күңел биреп, пөхтә итеп башкарсаң, теләсә кайсы өлкәдәге иң гади эш тә үзенең күркәмлеге белән кешеләрнең дикъкатен җәлеп итә, балкып тора. Сәнгать әсәре исә — хезмәтнең барлык төрләре арасында да аеруча түземле тырышлык сорый торган, иң зур камиллек, гүзәллек дәрәҗәсенә җиткереп эшкәртелгән нәҗат җимеше ул. Бары тик сокландыргыч нәфислеккә ирешкән хезмәт җимеше генә чын сәнгать әсәре булып санала ала. Иҗатның халыкчанлыгы, партиялелеге дә югары художестволылык белән тыгыз бәйләнгән. Әгәр кайчак бер тамчы да эстетик ләззәт бирми торган әсәрне тәнкыйть тартып-сузып, көчәнеп мактый икән, бу хәл авторга ярарга тырышудан гына түгел, бәлки критерийның түбәнлегеннән, сәнгатьнең сокландыру табигатен онытып җибәрүдән килә булса кирәк.

Яхшы сыйфат исә тир түгеп кенә хасил була. Хәзерге вакытта авыр физик эшләрне техника җилкәсенә йөкләү, хезмәтне җиңеләйтерү процессы бара. Моннан күреп, кайбер язучылар да иҗатны җиңеләйтергә омтылалар, әсәрләрен каралама хәлендә бастырып чыгаралар. Әмма чын сәнгать ачышлары бер вакытта да ансат юл белән генә килми. «Җиңел генә язып, яхшы әсәр килеп чыгуына мин үзем ышанмыйм,— ди Ә. Еники,— кайчагында ак кәгазьгә соңгы тамчы каныңны сыгып тамызырдай буласың». Шул ук фикерне Г. Бәширов та куәтли. «Җидегән чишмә» романында сурәтләнгән күренекле язучы Камил Дусаевның үз иҗатына ни дәрәҗәдә җаваплы, таләпчән каравы турында ул болай ди: «Бу әсәренә ул биниһая көч салды. Халкына җиткерәсе иң мөкатдәс, иң кадерле уйларын ул, тиен оясына чикләвек ташыгандай, шушы әсәренә ташыды, аларны халкына булган мәхәббәте белән җылытып, бер бөтен итәргә тырышты». И. Газиның «Онытылмас еллар»ын гомере буена диярлек язганлыгы, кайта-кайта эшкәрткәнлеге, сәнгатьчә камилләштергәнлеге билгеле. Зур художниклар иң гүзәл дип танылган әсәрләренә дә басмадан басмага ниндидер төзәтмәләр кертеп җибәрәләр, художество сыйфатын күтәрә төшәләр. Бу хакта Ф. Хөснинең «Урыннарындамы сүзләр-солдатлар?» мәкаләсендә үз тәҗрибәсе белән уртаклашуы бик гыйбрәтле. Дөнья классиклары үз әсәрләрен армый-талмый эшкәртү нәтиҗәсендә генә шедевр дәрәҗәсенә җиткергәннәр.

Бу җәһәттән урта буын язучыларыннан Н. Фәттахның эшләү рәвеше игътибарга лаеклы. Ул, яңа тарихи темага керешү белән, чынбарлыкны, кешеләрнең холыкфигыльләрен иң әүвәл галим, философ буларак өйрәнә, алар хакында хәзерге фән югарылыгындагы тирән эчтәлекле гыйльми хезмәтләр язып чыга, шуннан соң гына әдәби әсәренә тотына. Романга, әлбәттә, фәнни табышларның бик азы гына, сюжетка туры килгәннәре генә керә, бик күп өлеше читтә торып кала. Аның каравы тормышны бар нечкәлекләре белән белү язучыга иркен, ышанычлы иҗат итәргә, әйбәт роман тудырырга мөмкинлек бирә.

Сыйфат сикереше ясау өчен киләчәктә безнең бүгенге прозага иң якын үрнәк булып «Намус», «Җәяүле кеше сукмагы», «Онытылмас еллар» кебек әсәрләрнең идея-художество дәрәҗәсе хезмәт итә ала. Ким дигәндә шулар югарылыгында иҗат итүне һәр талант үз алдына максат итеп куярга, моны намус эше, партия эше

дип санарга тиешле. Прозаның абруен күтәрүгә хөрмәтле аксакалларыбыз да, урта һәм яшь буын язучылары да лаеклы өлеш кертә алалар, өлкән әдипләребезнең иң бай тәҗрибә туплаган, урта буынның — төпкә җигелеп тарта торган, яшьләрнең — дәртләнеп иҗат сәләтләрен ачып җибәрә торган чагы. Тик моңа язучылык хезмәтенә мөнәсәбәтне үзгәртеп, күбрәк тир түгеп, зуррак максат куеп эшләп кенә ирешү мөмкин.

Мостай Кәримнең әйткән сүзе бар: йөгереп куян куалар, утырып акыл җыялар. Әдәби әсәр — тулысы белән уй җимеше ул. Шуңа күрә аның художество дәрәҗәсе дә иҗатчының утырып акыл җыюына, фикерләү сыйфатына барып тоташа. Бөек язучыларның әсәрләре безне автор фикеренең, хыялының куәте, тирәнлеге белән сокландыралар.

Байтак гүзәл әсәрләрнең озак вакыт аралыгында иҗат ителгәнлеге билгеле. Шуның белән бергә шактый тиз язылган классик әсәрләр дә аз түгел. Димәк, әсәрнең сәнгатьчә сыйфаты вакыт факторы белән генә билгеләнми икән. Хикмәт нәрсәдә соң? Минемчә, әсәргә салынган рухи энергиядә, шуның сыйфатында. Ашыкмый-кабаланмый, һәр детальне үлчәп, уйлап, кат-кат төзәтеп, ювелирларча эшкәртеп язылган әсәрләргә нинди зур акыл көче сарыф ителгәнлеге болай да аңлашылып тора. Тиз язылган яхшы әсәрләрне иҗат итүгә дә чама белән шундый ук интеллектуаль энергия китә. Ләкин бу очракта инде иҗат киеренкелеге, фикерләү интенсивлыгы, анализлау, синтезлау куәте бермә-бер арта төшә. Кайчак без, әсәрне иҗат итүгә киткән вакыт турында сүз барганда, әдипнең өстәл янына утырып күренешләрне ак кәгазьгә төшергән чорын гына күздә тотабыз. Хәлбуки, иҗат процессына аңа кадәрге уйланулар да керә.

Бигрәк тә кече һәм урта күләмле әсәрләр чагыштырмача кыскарак вакыт эчендә язылырга мөмкин. Зур масштаблы жанрлар исә шулай да озаграк, җентеклерәк уйлануны сорый. Аннары бит әсәр бинасының төп төзү материалы — кирәкле сүзләр, тәгъбирләр дә хәтернең өске катламында гына сакланмый, аларны башка бик күп сүзләр арасыннан актарып чыгарырга, сайлап алырга туры килә.

Әгәр дә кайбер әсәрләр тоташы белән кызыксыз картиналардан, сүрән сюжеттан, ясалма интригалардан, үзара бәйләнешсез төрле темалардан укмаштырылган икән, художестволы нигезләүдән, элементар логикадан мәхрүм икән, сәбәп — бер якка, нәтиҗә — башка тарафка тарта. Раслау урынына кире кагу килеп чыга икән, бу — фикер үшәнлеге сөземтәсе, автор уенын өстән-өстән генә, су күбекләре арасыннан гына шуышып йөрүе, тирәнгә, тормышның, кеше табигатенең асылына барып җитмәү билгесе. Кайбер каләм ияләре үзләре төзегән гади генә ситуациядә дә адашып калалар, кая барып чыгарга белмичә аптырап бетәләр, вакыйгаларның очы очка ялганмый, эш-гамәлләр, мөнәсәбәтләр чынбарлыкка хилаф килә. Ул язмаларда ихлас ярату да, чын нәфрәтләнү дә юк, авторның ни-нәрсә раслаганлыгы, нәрсәне кире какканлыгы сизелми. Кайсыдыр ноктада конфликт төене бөреләнеп алгандай була да ачылып китмичә шиңә,— язучы аны я онытып калдыра, я кирәксезлегенә төшенә.

М. Хәбибуллинның «Сулар үргә акса да» романында Зөлфия «бер күрүдә гашыйк» итәрлек Бәхтияр дигән егет белән таныша. Егет кыз күңелен биләп ала. Казанка буенда Зөлфиянең икенче бер дус егете Барый һәм аның иптәшләре Бәхтиярне кыйнап, имгәтеп ташлагач та, Зөлфия Бәхтиярне оныта алмый. «Шул егетне очратырмын дип өмет итә» («К. У.» 8 сан, 35 б.). Беркадәр вакыттан соң Бәхтиярләр гаиләсе Зөлфияләр күршесендәге өйгә күчеп килә. Зөлфия, ике-өч ел буена аның янәшәсеннән көн саен үтеп-сүтеп йөрсә дә, нишләптер егетне танымый. Бәхтиярне имгәткән егет белән йөрүен дәвам иттерә, тик ике-өч елдан соң гына автор ихтыяры белән Бәхтиярне кинәт танып ала. Биредә шулай ук саклык кассасын баскан тәҗрибәле каракның, машинасы булган көе, милиционерларны үз өендә көтеп торуы, алар килеп җиткәч кенә кача башлавы да, җитешле тормышта яшәүче күренекле җырчы артистканың — пенсионер карчыкның япь-яшь күршеләренең идәнен юып йөрүе дә, квартира хуҗасы подполковник Якубның шуны табигый санавы да логик һәм сәнгатьчә нигезләнмәгән. Югыйсә, үз өен җыештыру өчен дә артист халкы кеше чакыртучан була бит.

Тел кытыршылыклары, тыныш хаталары да еш очрый әлеге әсәрдә.

Безнең кайбер әсәрләргә концепция бөтенлеге, проблемалар үткенлеге, образларның масштаблылыгы, характерлар ачыклыгы, хисләр кайнарлыгы, сюжет мавыктыручанлыгы, аргументлар куәте, каршылыклар кискенлеге, композицион төзеклек, тел җегәрлеге, ягъни һәрбер әдәби әсәрдә булырга тиешле элементар сыйфатлар җитешми.

Урта кул проза, гәрчә үзенең идея-художество осталыгын күтәрмәсә дә, дистәләгән еллар буена бер урында таптанып торса да, мәдәният тормышында үзенең позициясен тиз генә бирергә җыенмый, киресенчә, аны төрлечә ныгытырга тырыша: аерым әһелләре турында иҗат портретлары яздырта, әсәрләрен тәрҗемә кылуны оештыра, аларның тәрҗемәче тарафыннан кабул ителү фактын тәнкыйтьнең авызын томалау өчен файдалана. Тәрҗемәдән әсәр күпмедер дәрәҗәдә яхшырып та чыга, кеше күзенә күрсәтерлек хәлгә килә,— тәрҗемәче тырышлыгы автор казанышы дип йөртелә башлый. Бездә тәрҗемә эшен җайга салу, халтураның юлын бикләү өчен конкрет чаралар күрәсе бар әле. Минемчә, бары тик әйбәт әсәрләр генә тәрҗемә ителүгә, культурабызның абруйлы вәкиле буларак башка халыкларга тәкъдим ителүгә лаеклы. Моның өчен тәрҗемәне оештыру эше әвыксыз шәхес кулыннан тартып алынырга, авторитетлы комиссия карамагына тапшырылырга тиешле.

Прозадагы уртача сыйфатны зарарсыз, юаш күренеш дип санау, аның белән килешү һич тә коммунистик тәрбия эшенә хезмәт итми. Кызыксыз әсәрләр файдасызга матбугат мәйданын биләп кенә калмыйлар, укучыны әдәбияттан биздерәләр, талантлы язучылар иҗатын кысрыклыйлар.

Прозабызга хезмәт шигъриятен тойдыру юнәлешендә байтак тир түгәсе бар әле. Г. Бәширов, Ә. Еники, Р. Төхфәтуллин һәм башка язучылар иҗатка бик таләпчән, җаваплы караган кебек, үз әсәрләрендә дә хезмәтне күңел биреп, пөхтә башкаручыларны яратып тасвирлыйлар. Ләкин шулай да Фәйрүзә, Нәфисә, Миңлекамал, Уразмәт Сәләйманов, Базриев кебек характерлар прозабызга бик сагындырып кына киләләр. Кеше күзенә артык бәрелмичә, даими тигез, җай белән эшләүчеләр, төп материаль байлыкны тудыручы сабыр, тыйнак затлар күләгәдәрәк кала бирәләр, кайчак хәтта югары җитештерүчән, яхшы сыйфат белән эшләүче намуслы тырыш кешеләр дә, ничектер, берьяклырак яктыртылалар, профессиональ булдыклылыкның иҗтимагый әһәмияте тиешенчә бәяләнми, бары тик мул хезмәт хакы алуы гына басым ясап күрсәтелә. Аның каравы эпизодик югары күрсәткечкә омтылучы, дәвамлы тырыш хезмәткә сәләтсезләр, сыйфатны төшерү бәрабәренә эшне тизләтүчеләр, аварнягә юл калдыручылар, хуҗалыксызлык, оешмаганлык, аврал картиналары кайчак соклану объекты буларак тасвирлана.

Заман героен авылдан күчеп китүчеләр кыяфәтендә күрә Ф. Зөлкарнәев, ягъни алга таба образлар даирәсе аерым бер катлам белән генә чикләнер дип фараз итә. Килешәсе килми. Практика әдәбиятның офыгы, тематикасы тарая килүен түгел, бәлки, киресенчә, һаман да киңәя баруын күрсәтә. Борын-борыннан шәһәрдә яшәүчеләр дә, авылда басылып эшләүчеләр, урыннарыннан купмаучылар да прозаны киләчәктә дә илһамландырудан туктамас дип уйлыйм. Инде авыл чынбарлыгын, игенче рухын чагылдыруга килгәндә, моның шактый катлаулы икәнлеген онытмаска, кайбер төшенчәләрне кабат карап чыгарга, яңабаштан бәяләргә кирәк. Хәтсез вакыт әдәбиятыбыз авыл кешесен крестьян психологиясеннән биздерү эше белән шөгыльләнеп килде һәм кайбер нәтиҗәләргә дә иреште. Хәзер инде аны кабат җиргә якынайту, игенчелек, терлекчелек эшенә мәхәббәт тәрбияләү бурычын хәл итәргә кирәк.

Прозаның бер урындарак торуының сәбәбен кайбер иптәшләр аерым бер алымнарны, әйтик, шартлылыкны, фольклористик форма элементларын куллanмауда күрәләр. Художество-сурәтләү чаралары, әлбәттә, ишәя барырга тиешләр. Ләкин шулай да мәсьәләне аерым бер алымнар гына хәл итми. Әгәр әдип үзе сурәтли торган чынбарлыкның, кешеләр характерының асылына үтеп керә алмаган икән, бу кимчелекне бер төрле чара да яшереп кала алмый. Әдәбияттагы иң зур җиңүләр тормышны, герой күңелен тирән үзләштерү, шуны сурәтле рәвештә чагылдыру җирлегендә ирешелгән. Йомшак әсәрләрнең языла торуында һич тә иҗат

принциплары гаепле түгел, бәлки ул принципларны, художестволы фикерләү традициясен җитәрлек төшенмәү, ул мөмкинлекләрдән файдалана белмәү гаепле.

Әдәбиятның югары сыйфаты өчен көрәштә, әлбәттә, тәнкыйтькә зур бурычлар йөкләнә. Ләкин шулай да бу мәсьәләне киңрәк аңларга кирәк. Бөтен иҗат оешмасында, матбугат органнарында әсәр сыйфатына карата югарырак таләпләр куелганда гына, иҗатчы аларны норма дип кабул иткәндә генә реаль нәтиҗәләр туарга мөмкин. Мин прозабызның зур үсеш мөмкинлекләре бар дип уйлыйм.

## Әзһәр Габиди

# УҢЫШЛАРЫБЫЗНЫ ДА КҮЛӘГӘЛӘМИК...

Чыннан да, кем соң ул безнең замандашыбыз? Ул бар нәрсәдән пакь илаһи зат та, ниндидер күз алдына китерүе кыен булган абстракт шәхес тә түгел. Ул — материаль дөньяда кеше исемен бөек тотып яшәүче бүгенге көннең җанлы кешесе. Ул матурлыкка соклана, аны үзе иҗат та итә. Ул хезмәтне шатлыкка әйләндерә, тормышта үз урынын табу өчен көрәшә. Ул хаталана һәм газаплана, табигать белән гармонияле яшәргә омтыла, җир язмышы өчен борчыла. Ул сугышка үзенең нәфрәтен белдерә, аны булдырмау өчен хезмәте белән тынычлыкны ныгыта. Ул сөя дә, сөелә дә.

Ул — шушы тормышның законлы хуҗасы. Ә хуҗа кеше өчен гамьсезлек һәм битарафлык ят нәрсә. Ул безнең гүзәл тормышыбызны күләгәләп торучы кимчелекләргә, ямьсез күренешләргә түзеп тора алмый. Аларны үз вакытында юк итәргә омтыла һәм шуның өчен көчен, энергиясен аямыйча көрәшә. Ул олы җанлы, олы натуралы көрәшче.

Менә безнең бүгенге замандашыбыз нинди! Ә бу күркәм сыйфатлар югарыда телгә алынган характерларда тупланмаганмыни?! Минемчә, күбесе тупланган. Димәк, культура байлыгыбыздагы рухи хәзинәне күрә белергә кирәк.

Шул ук вакытта, прозабызның бай традициясен, зур уңышларын күреп куану белән бергә, яшәп килгән кайбер кимчелекләргә тукталып китәсе килә. Элегрәк язылган күп кенә роман, повестьларыбызда яшерелгән алтынны эзләүче геройлар сурәтләнә иде. Башта аны М. Әмир үзенең «Саф күңел» романында бәян итте. Аннан соң Г. Мөхәммәтшин («Йөрәктәге эзләр»), Ф. Хөсни («Алтын эзләүчеләр»), М. Хәбибуллин («Чоңгыллар»), Х. Хәйруллин («Картлык кемгә шатлык») геройлары алтын таба башладылар...

Бер эпидемия бетми, икенче эпидемия башлана дигәндәй, инде соңгы еллардагы әсәрләребезне «мәхәббәт өчпочмагы» басып китте. Кайсы гына романны, повестьны алма, анда «өчпочмаклы» мәхәббәт сурәтләнмичә калмый. Мисаллармы? Менә алар. Фирая белән Марат. Алар арасында Сәлим («Сагышлы кояш»), Фәләх—Роза—Гасимә («Һәлакәт»), Равил — Әлфия— Фәһимә («Тәвәккәл таш яра»), Якуб — Гөлбикә—Вәсилә, Гөлбикә — Якуб — Хәлил («Сулар үргә акса да»), Моратбакый — Зарема — Зәйтүнә («Ерактагы урман авазы»), Кадыйр — Шәрәфә — Кәлимә («Кышкы талпыну»), Камил — Йолдыз — Зөһрә («Үкенечкә калмасын»). Мондый өчпочмаклы мәхәббәт галереясын тагын да сузарга булыр иде...

Тагын бер нәрсәне әйтми булмый. Әсәрләргә прокурор образы килеп кердеме, ул һичшиксез, кешедән кер, гаеп эзләп йөрүче бәйләнчек кеше итеп сурәтләнер. М. Мәһдиевнең «Кеше китә — җыры кала», Г. Әдһәмованың «Үкенечкә калмасын» повестьларын гына алып карыйк. Алардагы Улибаева һәм Бикмуллин персонажлары шулай сурәтләнмәгәнме? Шулай бит! Әйдәгез, прокурор булган өчен генә аннан кире сыйфатлар эзләмик, бу һөнәр кешеләрен урынсызга рәнҗетмик һәм шуны да онытмыйк әле: җирдә гаделлек дигән бөек нәрсә бар бит. Ул хакыйкатькә тугры

һәм дөрес хөкем итә. Җинаять эшләдеңме, җәмгыять законнарын боздыңмы — кулың белән эшләгәнсең икән, иңең белән күтәр — тиешле җәзасын ал. Ул элек тә шулай булган, бүген дә шулай һәм киләчәктә дә шулай булачак. Монда прокурорның нинди гаебе бар? Юк! Шулай булгач, мондый хезмәт башкаручыларга карата укучыларда кире хис тәрбияләмик.

Тавыкның салган һәр йомыркасы алтын булмый, диләр. Шуның шикелле, язучының бар язганы да шедевр булып җитмәс, үзендәге мөмкинлекләрне тулысынча файдаланып бетмәгән, уртачалыктан әллә ни югары күтәрелмәгән кайбер әсәрләре дә очрар. Әмма моңа карап кына без үзебездәге уңышларны гел күләгәләп кенә күрсәтергә тиеш түгелбез. Кайбер тәнкыйтьчеләребез әдәбиятыбызның уңышларына күз йомып, кичерәйтеп күрсәтергә, укучыларыбызның зәвыгына хуш килерлек эзләнүле, проблемалы әсәрләрне урынлы да, урынсыз да юкка чыгарырга тырышалар. Алар үзләренең бу кизәнүләрен бөтенсоюз әдәбиятындагы традиция һәм тәҗрибәләргә нигезләнеп акларга тырышалар.

Инде бүгенге проза турында сөйләшүебезне башлап җибәргән «Тынычлану зарарлы» исемле мәкаләгә килик. Менә мәкалә авторының «Картлык кемгә шатлык» повестена биргән бәясе: «Бу повесть кулы азмы-күпме шомарган, сюжет төзә белгән, фабуланы, образлар системасын сиземли алган грамоталы кешенең гади язмалары булып чыкты. Әсәр әдәби тормышыбызда аз гына диярлек эз калдырмады, басылып чыкты да онытылды». Бу юллар белән берничек тә ризалашып булмый. Әсәрне укучылар җылы кабул иттеләр. Язучылар җәмәгатьчелеге дә уңай яктан гына бәяләп үтте. «Казан утлары»ның 1975 ел 1—6 саннарын тикшерүгә багышланган җыелышта язучы һәм галим Х. Сарьян докладында бик хаклы рәвештә «Повесть озын түгел, әмма бик тыгыз. Язу алымы да бик үк яңа булмаса да, үзенчәлекле: бүгенге белән үткәнне органик рәвештә үреп, ике сюжет, ике язмыш йомгагын тигез сүтеп бара... Повесть әдәби яктан да бик нык эшләнгән. Х. Хәйруллин гомере буена Татарстанның телгә аеруча бай, үзенчәлекле бер төбәгендә — Сарман ягында яшәгән кеше. Халыкның үз эчендә яшәгәнлектән, телне дә шул халыкның үз эченнән айкап алганлыктан, әдәби сүзе, тәгъбирләре, образлау рәвеше гел безнеңчә, татарча»,— дип әйткән иде. «Социалистик Татарстан» газетасында оештырылган «Бүгенге татар әдәбиятында заманчалык» дискуссиясендә тәнкыйтьче М. Вәлиев тә: «Повесть реаль тормыштагы олы матурлыкка баруның яңа юлларын, гадилектән башланган бөеклек эзләрен ачыклый»,— дип әсәрне бик хаклы билгеләп үткән иде. Тәнкыйтьче Э. Нигъмәтуллин да «Типиклаштыру турында уйланулар» («Казан утлары», 10 сан, 1980 ел) исемле мәкаләсендә әсәрнең төп геройларына карата: «Нәтиҗәдә Хәсән белән Асыл образлары бер-берсен тулыландырып, ике кеше бер язмыш белән яшәгәндәй тоела башлый» диган кызыклы һәм уңай фикере белән уртаклашкан иде. Әдәби җәмәгатьчелекнең фикере белән исәпләшмәү бер дә килешми инде.

Авторның Э. Касыймов иҗатына карата әйтелгән кайбер фикерләре белән дә килешеп булмый. Имеш, Э. Касыймов «Гомер ике килми» романы белән генә язучы булып торган, ә аннан соң язылган әсәрләр фикер, уй ягыннан чуалчыклар. Юк, мондый фикерне әйтергә ашыкмыйк. Бер селтәнүдә «Көмеш язулы кылыч», «Чулман — оныклар дәрьясы» шикелле әсәрләрне юкка чыгармыйк һәм ике китаптан торган соңгы әсәрнең эшче образларын тудырган әсәрләр ярышында Бөтенсоюз премиясе алуын да онытмыйк әле. Мондый премияне юкка гына бирмиләр. Шундый әсәрләр тагын да күбрәк язылсын да, шундый Бөтенсоюз премиясенә лаек булсыннар иде әле. Шатланып кына идек.

Иҗат — ул хезмәт, ә кеше хезмәтенә җиңел карамыйлар. Кеше хезмәтенә гадел килә белергә кирәк. Аннан соң безнең мәкаләләр укучы өчен дә языла. Алар язучының уңышларын билгеләргә, иҗади үзенчәлеген ачарга, кимчелекләреннән арынырга юл күрсәтергә, укучыга әсәрнең сәнгатьчә асылын төшендерергә булышырга тиеш. Әдәбият хакындагы мәкаләләребез дөрес һәм нигезле булсын. Әйдәгез, уңышларыбызны да күләгәләмик һәм яңа биеклекләр турында да онытмыйк. Юлларыбыз бөтенсоюз әдәбияты үрләренә сузылсын!

**ХӨРМӘТЛЕ УКУЧЫЛАР!**

**Бүгенге проза турында дискуссия дәвам итә. Сездән хатлар, фикерләр, мәкаләләр көтәбез!**

# ИКЕ ШАГЫЙРЬ



Бу фоторәсемдә ике шагыйрь— Сәгыйт Сүнчәләй белән Һади Такташ... Көтелмәгән табыш!.. Мондый фотоның барлыгын минем, мәсәлән, ишеткәнем дә юк иде.

Иң элек кайдан табылуы турында берничә сүз. Ленинградта яшәүче тау инженеры Әхәт ага Усманов күп еллардан бирле фоторәсемнәр җыю белән шөгыльләнә. Иске Казан, иске Уфа, хәтта Дәүләкән күренешләре төшерелгән йөзләрчә почта открыткалары җыйган ул. Шулай ук тарихи шәхесләр — язучылар, артистлар, музыкантларның да фоторәсемнәре бар аның коллекциясендә. Үткән көз мин Әхәт аганың әнә шул гаять бай һәм бик кызыклы коллекциясе белән махсус танышыр өчен Ленинградка бардым. Инде йөзләрчә открыткаларны карап утырганда Сәгыйт Сүнчәләй белән Һади Такташның фоторәсеме килеп чыкмасынмы?.. Әлбәттә, мин бу фотога шунда ук игътибар иттем һәм төпченеп сораша да башладым. Ләкин Әхәт аганың җавабы кыска булды: бу фотоны егерменче елларның ахырында аңа Һади Такташның хатыны Гөлчәһрә ханым Хәмзина биргән булган. Ике шагыйрь кайчан, кайда төшкәннәр — ул кадәресен Әхәт ага әйтә алмады. Фотоның артында да бернинди дата-мазар юк, кызганычка каршы... Билгеле, моның кебек бердәнбер кыйммәтле фотоны сорап булмый иде, шул сәбәпле Әхәт агадан күчермәсен төшертеп миңа җибәрүен үтендем. Ул бер сүзсез риза булды, вәгъдәсендә торды, җибәрде — моның өчен аңа, әлбәттә, бик зур рәхмәт!

Әмма фотоның тарихын ничек тә беләсе иде бит, бу — бик мөһим, чөнки Сүнчәләй белән Такташны бер фотода күрү ул, әйткәнемчә, көтелмәгәнрәк бер хәл. Иң элек алар бер үк шәһәрдә озак вакыт бергә яшәп, якыннан аралашкан кешеләр түгел — Сәгыйт Сүнчәләй гел диярлек Уфада торды, ә Такташ — Казанда. Шулай ук яшь ягыннан да аерма шактый зур, Сүнчәләй — Тукай замандашы, Такташ исә яңа заман шагыйре. Аннары әдәбиятта тоткан урыннары белән дә нык аерылалар: Сүнчәләй инде онытылып бара, ә Такташның иң популяр чагы. Кыскасы, болай өстән караганда, бер-берсеннән шактый ерак торган кешеләр... Ләкин бит чит-ят кешеләр бергә фотога төшмиләр, моның өчен бер-береңне яхшы ук белү кирәк, бер-

берекә ниндидер якынлык хисе тою, һич югы, хөрмәт саклау кирәк, шул чагында гына менә болай икәүдән-икәү генә рәсемгә төшеп була торгандыр. Сез аларга игътибар белән җентекләбрәк карагыз әле, нәрсә күрәсез, нинди уйлар уята алар сездә?.. Әйе, алар икесе ике дәвер кешеләре, моны үзләре дә белеп торалар, җитди уйчаннар, әмма шул ук вакытта алар бер-берсенә чит-ят түгелләр, киресенчә, аларның җаннарында ниндидер якынлык, шигъриятләрендә күпмедер охшашлык бар кебек — менә шулай күрәм мин аларны, дикъкать белән карагач...

**Ләкин шулай да алар кайчан, кайда болай фотога төштеләр икән соң?..** Мәгълүм ки, 1927—28 елларда Сәгыйть Сүнчәләй Казанда бер ел чамасы торып эшләп китте. (Татар мәдәнияте йортының гыйльми секретаре булып торды бугай). Мин үзем дә Сәгыйть абзыйны 1928 елның җәендә Казанда күргән идем. Димәк, Такташ белән очрашуы, аралашуы һәм фотога төшүе бары шул чакта, ягъни 1927—28 елларда гына булырга мөмкин. Аннары фотодагы уйчан-моңсу йөзе дә аның шул еллардагы кыяфәтенә һәм рухи хәленә бик туры килә, минемчә...

...Фоторәсемдә ике шагыйрь — караган саен уйландыра безне ул...

**ӘМИРХАН ЕНИКИ.**

# СОҢАРГАН ХАТ

*Киләчәккә хатлар барып җитә,*
*Ә үткәнгә хатлар бармыйлар...*

Хәсән Туфан

*Еллар үткән саен, Һади Такташны күргән, белгән кешеләр сирәгәя. Киләчәктә шагыйрь турында нәфис роман да, сәхнә әсәре дә язарлар. Аның тормышына бәйле һәр нәрсәне энҗе итеп эзләрләр, җыярлар. Әнә шул киләчәкне күздә тотып, «сәхнә арты» күренешләренә өзек-өзек булса да тукталырга теләдем.*

Автор

1924 ел. Җәйге каникул вакыты. Без — Спасс, Чистай шәһәрләрендә укучылар тын урам буйлап әкрен генә сөйләшеп йөрибез.

— Беләсезмé, егетләр,— диде озын буйлы, юка иренле, юаш холыклы бер шәкерт,— Тукайга алмашка Такташ килде бит! Такташ!— дип көйләп тә алды.

> **«Ишек шакыйм. Тыңлыйм — бер тавыш юк.**
> **Тагын шакыйм, тагын... тагын да...**
> **Төн уртасы; шундый, шундый шомлы;**
> **Берәү дә юк тирә-ягымда...**

Безне күзгә күренмәгән шигъри көч үзенә тарта, балалык елларына кайтара. Ә шәкерт салмак кына һаман көйли. Үзебез дә сизмәстән, шагыйрь турында бәхәсләшә башлыйбыз. Шулай сайраша-сайраша, бер әйләнәсе урамны ике әйләнеп, аккош атавына барып җиткәнбез...

...Коры Кәрнәле авылында (Алексеевский районы) Хафиз Хәмзин яши иде. Аны коеп куйган игенче дип булмый. Ул укымышлы кеше. Гомеренең күп өлешен Төркестан, Кавказ, Кырым ягында үткәргән. Рус һәм шәрык телләрен яхшы белә. Шул Хафизның кече яшьтән рус мәктәбендә укыган Гөлчәһрә исемле кызы бар иде.

«Әтием белән әнием турында» дигән истәлегендә Рафаэль Такташ берничә җөмлә бабасы турында яза.

— «Әнинең әтисе... рус әдәбиятын бик яраткан. Атаклы җырчы Федор Шаляпин белән якыннан таныш булган. Аның белән Париждан хатлар алышып торган».

Шуңа өстәп, Такташның бабасы булган Хафиз мәктәпләр ачты, приютлар оештырды, тәрбиячеләр, укытучылар әзерләде, мәгърифәт учаклары оештыручы, совет

кибетләре ачучы булды, дияр идем. Такташ даирәсенә якынрак килик. Хәтеремдә бер күренеш саклана.

Гөлчәһрә белән Спасстан авылга атта кайтабыз. Мөнә без бер тау янына килеп җиттек. Аста болынлык, елга, күпер.

— Апа, дилбегәне мин тотыйм. Алаша дулый.

— Утыр,— диде бу.

— Юк, апа, «утыр» түгел. Күпер баганасына китереп бәрсә, харап булабыз. Мин ир җенесе, бир дилбегәне.

— Куян! Куркак!

— Юк, апа, куркак түгел мин, крестьян малае, беләм. Арткы куласага таяк тыгыйк. Куласа әйләнмәсә дуламас.

Алаша тыпырчына башлагач, сикереп төштем дә, авызлык тимеренең каешына ябыштым. Тәртә башы җилкәгә томыргач, читкә тайпылдым, ә арба уңга-сулга чайкалып, Гөлчәһрәне тау астына алып очырды. Биш-алты минуттан мин дә күпер артында, арба янында идем.

— Утыр, куян!— диде апа.

Гөлчәһрә кискенрәк, тәвәккәлрәк җан иде шул.

Гөлчәһрәнең сагынып көтеп алган каникулы, Такташның җәйге ял ае да килеп җитә. Такташ һәм Гөлчәһрә Көрнәлегә юлга чыгалар.

Хафиз Мурзихага үзе барырга булды, миңа ышанмады. Сере бик гади: атның дулый торган гадәте бар. Арбаның күчәрләрен каен дегете белән майладык. Арба уртасына яшел үлән җәйдек, аны бизәкле келәм белән капладык. Арба абыстай түшәгеннән дә йомшак булды. Алаша яхшы. Сбруйлар, камыт, шлияләр тәңкәле, кара төстәге нечкә дуга кыңгыраулы. Хафиз төнлә Мурзиха пристанена юл тотты. Пароход таң атканда килгән. Такташ яр өстенә, такта кибетләр янына күтәрелгән. Иртәнге кояшның сызылып килүен, Кама ярларының агаруын кызыксынып күзәтә. Сәгать тугызлар тирәсендә кадерле кунаклар Озын Куак күле буйлап Коры Көрнәлегә керәләр. Аннан атау урамындагы урыс капкалы йорт каршына килеп туктыйлар. Бу — Хафиз йорты.

Бик тырышып, озын саплы себерке белән йорт себерә идем. Яртылаш себергән килеш себеркемне атып бәрдем. Утлы күмергә баскан кебек, йөгереп барып кабаланакабалана капканы ачып җибәрдем. Кунаклар арбадан төшкәннәр. Такташ чалбарына ябышкан үлән кыякларын бармак очы белән чүпләп җиргә ташлый. Йомшак кына елмая. Мин авыл малайларына хас беркатлылык белән: «Җизни килеп җитүдән шатлана, юл ерак шул. Әле ат та дулагандыр»,— дип уйладым. Соңрак белдем. Такташ, гомумән көләч, елмаючан икән. Нәни генә уңайлыктан тиз тәэсирләнүчән, шатланучан гади җан икән.

Мин себереп бетерергә өлгермәгән урыннарны күреп, ул: «Соңга калдың, егет. Без килеп җиттек»,— диде. Биш бармагын җилкәмә тидереп алды, аннан атның сыртын, җылы муенын, бит читләрен чәбәкләде. «Ат җанлы крәстиян егет, ахры»,— дип уйладым. Болдырга чыгып баскан хатын-кызлар Такташның калын чәчен күреп хәйран калдылар. Моңа кадәр мондый куе, озын чәчле ирне күргәннәре булмаган, күрәсең. Шагыйрь тиз генә өйгә кереп китмәде, кура тирәсендә үскән гөлләргә, кыр чәчәкләренә, бакчадагы яшел түтәлләргә күз төшерде. «Чеп-чи крәстиян, кырлар егете икән»,— дидем мин тагын эчтән генә.

Бәлки аны бу йортта үзе яшендәге һәм үзеннән яшь хатын-кыз чолгагангадыр, Такташ үзен гаять иркен, хәтта шаян, уйнакчан тотты.

Күпмедер вакыттан соң, йортка кул юарга чыгардылар. Ак комган, җиз түгәрәк таз. Шул тирәдә җәйлап кына кызыл башлы озын сөлгеләр эленгән. Такташ, җиңен сызганып, бер уч суны кул-битенә тидерә, икенчесен әмәллап, җәйлап Гөлчәһрәгә сирпеп җибәрә.

— Һади, җитәр инде, күлмәгемә чәчрәтәсең бит,— ди Гөлчәһрә. Шагыйрь туктамый, шаяруын дәвам итә. Соңыннан кыз һөҗүмгә күчә. Такташ көлә-көлә ике-өч адым читенә. Тагын кем комганга алдан өлгерә, шул бөрки.

Яшьлек — яшьлек инде. Ул бер генә килә. Гөлчәһрә, чиган кызы кебек туткыл йөзле, озын керфекле, ут чәчеп торган күзле, чем кара чәчле, зифа буйлы. Ике яшь кешенең бер-беренә гашыйк булулары әллә каян сизелеп тора.

Түр як өйдә — китаплар шүрлеге. Көзге, сәгать, зур өстәл. Яшел постаулы, челтәр артлы урындыклар. Ленин портреты. Такташ китаплар тирәсендә. Биредә рус, татар әдипләренең әсәрләре. Галимҗан Ибраһимовның яшькелт тышлы «Безнең көннәр»е, Габдулла Тукай шигырьләре...

Икенче көнне симез сарыкны көтүгә озатмадык. Бер сәгать тә үтмәде, зур пычагын тотып, Зариф бабай килеп керде. Җиңнәрен сызганды, кулларын беләгенә кадәр юды, бисмилласын әйтеп, кыйблага каратып сарыкны чалып та җибәрде.

Һади кояшта кызынып утырырга ярата иде. Бер көнне өй эченнән хатын-кызлар тәрәзәгә ябырылып, берсен-берсе этә-төртә Такташны күзәттеләр. Авызларын җыялмыйлар. Мин дә тәрәзәгә ябырылдым. Ни күзем белән күрим: Һади кыска җиңле күлмәген кигән дә, аклы-сорылы мәчене зур тагаракта юындыра. Бер кулы белән кысып тоткан, икенчесе белән суга чумдыра-чумдыра сыйпый. Песи ычкынырга тели, тыпырчына. Ниһаять, ычкынды. Кагынды, тибрәнде. Аннары, туктап, гаҗәпләнеп шагыйрьгә карады. Ә Такташ рәхәтләнеп бармак янап көлә, ягъни: «Кара, эләкмә бүтән миңа, тагы да чумдырырмын!..»

•
•   •

Бер кичне урамга чыктым. Чистай педтехникумында укучы Хәснелгата, Нургата Ризвановлар, Спасста укучы Габдуллаҗан Барышов, тагын берничә үсмер егет сырып алды. Әлбәттә, башка көннәрдә мин аларга ни дә тормыйм, ә бу кичне миннән дә шөһрәтле малай авылда юк.

— Әйдәле, утырыйк әле, сөйләле, Такташ нинди? Буйга озынмы, карсакмы, юанмы? Өстендә нәрсә, постаумы, ефәкме, ничек йөри, нәстәләр сөйли?

Мине чолгап алып, иң өске бүрәнәгә кадерләп утырттылар. «Һәй, егетләр, күрсәгез иде... Мужыт урамга чыкса, күрерсез дә, пәһлуан, малай, бер галәмәт. Чистайда да, Спасста да, Казан губернасында да андый кеше юктыр.

— Ну-у, зур, әйе?

Шунда инде бик юаш мөәзин малае Әхәт сүзгә кушылды.

— Бүлдермәгез, баштан сөйләсен, сөальларны соңыннан бирербез, йә, шуннан, Касыйм?

— Шуннан, егетләр, буйга алай озын түгел, уртача буй, уртача калын, аяк-кул, беләкләр таза, иман кебек. Әгәр дә урманда-мазарда бүре белән күзгә-күз очрашса, пычаксыз да җиңәчәк.

— Да-а,— диде кемдер, гаҗәпләнеп.

— Маңгай киң, баш зур, егетләр. Ихлас, менә. Күзләре зәңгәр, кичке күк кебек. Һәй, егетләр, чәче, әйтерсең чук башлы диңгез камышы, икегә аерылып кабарып тора.

— Ни, карале, өстендә нәстә, безнеңчә киенгәнме? Сәгате бармы?

— Сез нәрсә, егетләр, нишләп безнеңчә киенсен ул? Ефәк күлмәк, галстук, заграничный костюм. Бастон, американский сары штиблет. Хет патша сараена кер, һич сыната торган түгел. Сәгать, егетләр, бар. Шартлап ябыла торган капкачлы кесә сәгате .

— Карале, нәстә сөйли, күп сөйлиме?

— Әз сөйли, егетләр. Бик уйлап сөйли, салмак, ашыкмый, кабаланмый. Ну, шаян, песи кебек әкрен, йомшак атлап йөри...

Менә шулай тасвирладым Такташны авыл егетләренә.

Бу кичне миңа почет хәтсез зур булды. Нургата хәтта папирос та тәкъдим итте. Шул көннән башлап шөкертләр бер күрергә зар вә интизар булып, Такташның урамга чыкканын сагалап йөрделәр. Әмма Һади башка авыл урамнарында күренмәде.

Җәй матур килде.

Иртәнге якларда әрәмәдә күке моңайды, сандугачлар, тургайлар сайрады. Хафизның өе авыл читендә. Такташ һәр көн булмаса да, чәчәкле сукмак буйлап йөри,

бәлки аңа бу яшеллек, бу моңнар үз авылын — Сыркыдыны, яшел бакчаларны хәтерләткәндер.

Бәрәңге бакчасы дип аталса да, бакчада урыны-урыны белән утыртылган кәбестә, кыяр һәм саф-саф тезеп утырткан суган, кыр чәчәкләре, мәк һәм яшь агачлар күп иде. Бакча кояшка караган үрле, сөзәк таулы. Тау астында елга, күл, тал-тирәкләр, бакча уртасында чишмә бар. Тау өстендә чәчәкләр уртасында озын утыргыч. Күбәләкләр әйлән-бәйлән уйнаган шул чәчәкле, яшел бакчада әрәмә тавына карап Такташ белән Хафиз әңгәмә корып утырдылар.

Бу биек урын. Биредән күкеле, сандугачлы, куе яшел урманлы, ян-яктагы сөремле әрәмә күренә. Авыл читендәге кызыл ярлы тау өстендә, озын ботакларын сузып, җәйрәп карт каен үсә. (Бу каенны соңрак Такташ каены дип атарлар). Мин, я түтәлләргә су сипкән булып, я чәчәкләр караган булып, болар тирәсендә әйләнәм, утырып колак та салып алам.

Матур көннәрнең берендә Такташны уртага алып әрәмәгә күңел ачарга, кәеф-сафа корырга чыгалар. Көрнәле әрәмәсе шәп! Күрше авылларда андый әрәмә юк. Чын-чыннан, җәннәт диярсең! Киң алан. Чәчәкле, җиләкле яшел үлән, тирә-як сөзәк таулы урман. Миләш-шомырт, алма, кара карлыган. Бер төркем кунаклар шунда учак ягып, кичкә кадәр тамаша кылып уткәрәләр.

Мәҗлестә катнашкан шактый укымышлы Галия Рөстәмова менә нәрсә сөйләде:

«Без барыбыз да һадиның шигырь укуын үтендек. Укы һади, укы әле. Сорыйбыз! Сорыйбыз!

һади кеп-кечкенә яшел түмгәккә басты. Тынлык. Чәчен артка сыпырып җибәрде һәм Гөлчәһрәгә карап елмаеп куйды.

> **Пәри кызы! Ник чыктың юлларыма,**
> **Утлы кызыл гөлләр тотып кулларыңа,**
> **Гөлләреңне ыргытып бер елмайдың да**
> **Ник яшерендең, төренеп таң нурларына!**

Шагыйрьнең тавышы әрәмә тауларына бәрелеп яңгырый. Шигырь тургай сайравыдай киң болынга сибелә.

Гөлчәһрә кулына тоткан чәчәк бәйләмен яшел чирәм өстенә, үз алдына куя. әйтерсең лә, шигырь аңа юнәлгән.

> **Таң кызы, Гөл, ник чыктың да юлларыма,**
> **Бәхет гөлен тотып нечкә кулларыңа,**
> **Маңгаемнан үбеп мине, ник югалдың,**
> **Тагын кире төренеп таң нурларына!**

Дәррәү кул чабу. «Браво! Браво, һади! Тагын берне генә! Әй, укый да соң!..» Шагыйрь бу сәяхәттән соң дәртләнеп, ачылып кайта.

*
* *

1926 елны Хафиз, йорт-җирен акчага әйләндереп, җигүле килеш тарантасы белән алашаны Матак базарында сатып, яңадан Төркстанга күчеп китте. Шул елны татрабфакка укырга керү нияте белән Казанга юл тоттым. Бу уку йортына Татарстан авылларыннан гына түгел, Казахстан, Кыргызстаннан, Бакудан, Грозныйдан бик күп яшьләр килә иде. һәр урынга ике кандидат. Имтихан дигән сират күперен үтү җиңел түгел. Бигрәк тә авыл җиреннән килгән рәтле-юньле русча белмәгән яшьләргә кыен.

«Нишләргә?»— дидем үз-үземә. Исәп-хисап иттем дә, Такташ янына киттем. Әлбәттә, ул кочаклап каршы алды. Тамак ялгап алгач, мин үземнең нинди гозер белән килүемнең серен ачтым.

Бу көнне мин Такташның эш кабинетында, биек аркалы кара йомшак диванда ак җәймәле, бизәкле мендәрдә йокладым. Икенче көнне, иртәнге чәйдән соң, Такташ,

кызыл кара белән, гарәп хәрефләрен тезеп нидер язды. Язма зур түгел, бер бит кәгазьнең яртысы булыр. Кәгазьне миңа укымады. Өстәл тартмасыннан ак конверт алып пичәтләде һәм: «Менә шул конвертны рабфак директорына үзең тапшыр»,— дип миңа бирде. Киттем. Йөрәгем үз урынында түгел, әллә нишли, дулкынлана.

Икенче көнне уку-укыту бүлеге мөдире: «Сез кабул ителдегез!— диде. Менә шулай итеп, Такташ миңа уку юлын ачты.

•
• •

1929—30 нчы еллар булса кирәк. Җылы, уңай, дәртле сүзләр белән бергә шагыйрь җилкәсенә тәнкыйть тукмаклары да төшә тора. Я символист, я романтик, я казлар турында гына җырлый диләр. Болар табигый һәм әллә ни борчымыйлар. Менә һич көтмәгән, уйламаган җирдән әкәмәтләр килеп чыга.

«Такташның җәмәгате Гөлчәһрә Хәмзина чит элемент, ишан кызы икән. Мәскәү университетында аңа урын юк! Куарга!»— дигән хәбәр тарала. Такташ борчулы. Язарга атналар буе кулы бармый. Әле күптән түгел генә сеңелесен гаепләп борчыганнар иде, кирәк булса, менә сиңа өр-яңа хәбәр. Такташ Мәскәүгә хат артыннан хат яза. Мәсьәлә ачыкланганчы айлар үтә. Әлбәттә, гадел күңелле шагыйрь боларның барысын да авыр кичерә. Ә вакыйга болайрак була.

Хафиз Үзбәкстаннан Гөлчәһрәгә хат сала. Конверт эчендә истәлек-ядкарь итеп фоторәсемен дә җибәрә. Хафиз өстендә буй-буй тасмалы яшел ефәк чапан. Башында ак чалма, аякта ялт-йолт иткән озын балтырлы читек. Фасоны килсен өчен шома таяк та тоткан. Бу кыяфәттә Хафиз кышлак мулласы гына түгел, чын-чыннан ишан. Гөлчәһрә элеге фотоны дус кызларына күрсәтә. Карыйлар, мактыйлар. «Ай-һай шәп, ахун кебек, француз кардиналы кебек»,— дип тә җибәрәләр. Зур эш. Тикшерүнең бер очы Ташкент ягында, икенче очы Казан губернасында.

Бәхәс, әңгәмә күпме дәвам иткәндер. Ә Такташ борчулы, яхшымы-яманмы Гөлчәһрә аның сөйгән хатыны. Бала анасы.

«Галя!.. Син, сөеклем, бик бала табигатьчелерәк. Белсә идең, ничек авыр. Ачуланма, үпкәләмә, бәгърем... Кичер, Галям... Хат яз. Көтәм. Сагындым сине, бик сагындым үзеңне. Ә белсәң, ничек авыр. Сине үбеп, Һади». 7/II—1929 ел).

Бу хат шул айларга, борчулы көннәргә туры килгәнме, юкмы, эш анда түгел. Такташның гаилә башлыгы буларак саф мәхәббәт иясе булуын, бирелеп сөюен күрсәткән дәлил. Ә фото мәсьәләсе Гөлчәһрәнең укуда, партиядә калуы, Мәскәү университетының юридик факультетын тәмамлавы белән бетә.

•
• •

«Алсу» шигыренә карата бер фикер әйтәсе килә. Казанда шәрык педагогия институтының тулай торагында яшәгәндә Гөлчәһрәнең бертуган энесе Камил килеп керде. (Бу бина хәзерге Куйбышев мәйданында, балык кибетенең икенче-өченче каты). Камил үтеп барышлый гына ике кич кунды, студентларча гына кунак булды.

— «Алсу»ның ничек язылуын беләсеңме?— диде шул чакта.

— Юк, белмим, ничек?

Камилнең шатланып та, ләззәт табып та сөйләвеннән шуны аңладым. Гөлчәһрә Пушкинның «Евгений Онегин» романын укыган. Шул әсәрдәге хатын-кыз образларына, аларның сыйфатларына, бигрәк тә Пушкинның тасвирлавына гашыйк булган. Шуннан бу Такташка үпкәләгән, моңсуланып та йөргән.

— Пушкин Ольгаларны мәңгеләштергән, ә син үз Галяңны язмыйсың. Ә үзең сөям дигән буласың...

Такташ кәлә, шаярта, ялындыра, үрти, ниһаять, язарга вәгъдә бирә. Бу шигырьнең һәр юлында Гөлчәһрәнең холык-фигыле, шаянлыгы, «усаллыгы» җанлы картина булып килеп баса.

**Салкын карга басып Алсу килә:**
**Үзе көлә,**
**Үзе сөйкемле.**
**Үзе усал,**
**Үзе болай бер дә**
**Усал түгел кебек шикелле...**

Ул карга да батыра, профессорның карикатурасын да ясый, зачетка да әзерләнми кебек, ә үзе зачетларын иң баштан биреп бетерә, ул кәкре юллар белән хат та яза, эшкә дә, театрга да өлгерә, ачулана да белә. Санап бетергесез сыйфат. Хәзер Такташның Гөлчәһрәгә язган бер хатына игътибар итик.

«...Галя, мин әле сине бер вакытта да җиңә алганым юк... Аңлыйсыңмы, минем хыялымда яшәгән Галя, ул — усал түгел, ул мин теләгән минутларда мине яратып, чәчләремнән сөя. Ул хрусталь кебек саф, тормыштагы Галя кебек юк нәрсәләр өчен ачуланмый да, тиргәми дә...»

Бу юллар да «Алсу» шигыренең төп образы кем булуы турында сөйлиләр. Шигырьнең вариантлары күп. Шундый бер куплет бар:

**Күрмәде ул минем күкрәгемдә**
**Бөек җырлар таңы атканын,**
**Сизмәде ул күңлем сахрасында**
**Арысланнар йоклап ятканын...**
**Коммунизм килеп җиткәнгәчә**
**Тәүбә итәм кызлар сөяргә...**
**Ну, их к черту...**

Менә бу юллар ике арада кара мәче йөгергәч язылган куплет түгел микән дигән уй да туа. Һәрхәлдә «Алсу» әсәре олы сыйфатлы, нәфис реаль тормыш. Такташ иҗатында һәркем үзен күрә ала. Әлеге Камил дә: «Нәни разбойник» ул мин,— диде.— Әтәч суймадым, ну, кыяр бакчаларын утадым. Муллаларны каһәрләдем. Мөгаен, апа минем азгынлыгым турында нәрсәдер сөйләгәндер»,— дип өстәде.

*
* *

Без, авыл яшьләре, костюм дигән нәрсәне ишетеп кенә белә идек. Җиңсез казаки, кара кәләпүш, мөгезле яңа чабата безнең өчен иң затлы киемнәр. Такташ, башта әйткәнчә, Көрнәлегә кургаштай көлсу төсле костюмнан кайтты. Бу кием безнеңише ни егет, ни ир булмаган үсмерләргә хәйран тоелды. 1927 ел булырга тиеш, бер көнне әлеге Кооперативный урамга бардым. Тик кенә, үз итеп, туганнар, танышбелешләрчә, һичбер максатсыз. Нәкъ төшке ашка туры килдем. Гөлчәһрә аш пешергән, котлет кебек нәрсә дә әвәләгән. Мин рабфак студенты. Гаеп итү, аштан олы булу юк, әлбәттә, бигрәк тә шәкерт кешегә бу сыйфат хас түгел. Мин кулмәктән, чибәррәк күренү өчен чуклы пояс та таккан идем бугай. Өй хуҗалары ара-тирә минем өске киемемә, күлмәгемә күз төшерәләр дә серле итеп, һич сүз катмый, бербереснә караналар. Аларның күңелләре, күз карашлары нидер сөйләшә дә кебек, тик телләре әйләнми. Бер-ике мәртәбә икенче бүлмәгә чыгып керделәр.

— Ярар, мин тулай торакка кайтыйм инде,— дидем.

— Сабыр ит, Касыйм, хәзер кайтырсың,— диде Такташ. Һәм шунда ук әллә үз кабинетыннан, әллә башка бүлмәдән әлеге костюмны алып чыкты.

— Яле, киеп карале, бу сиңа ничек икән?— диде. Гөлчәһрә урындыкка утырган, сүз катмый, ә Такташ арлы-бирле әйләнгәләп миңа костюм кигерә. Оста тегүче шикелле, чабуын тарта, җилкәләрен капшап карый. Кыскасы, пөхтә һәм яраклы итәргә тырыша. Мин, шатлыктандыр инде, кызарам да, каушыйм да, авызны да җыеп булмый. Бу бит Көрнәлегә киеп кайткан Такташ костюмы.

Гөлчәһрә дә күтәрелде, ул да төймәләр тирәсендә бармакларын йөртә. Костюм

миңа зуррак, чумарлык, иркен, чабулар да озын, әмма шылт итмим. «Ничек Галя, килешәме?». «Хәзер бөтенләй икенче» — диде тегесе. «Рәхәтләнеп ки, бу хәзер синең костюм»,— диде Такташ. Хәтерләмим, ничек җавап биргәнмендер, нинди рәхмәтләр яудырганмындыр.

Шуннан соң Такташ инәдән-җептән чыккан өр-яңа көрән коричневый костюм киеп йөрде.

Рабфакта костюм киеп йөри башлагач, Бөгелмә ягыннан энесе янына рабфакка килгән бер агай: «Син, егет, я сәүдәгәр, я мулла малаедыр, әнә, нинди костюмнан йөрисең»,— дигәләде. Әмма мин аның яныннан тайдым, җавап-мазар кайтармадым. Нигә һәр очраганга эч сереңне ачарга? Кирәкми. Сабырлык сары алтын. Әйе, әлеге костюм институтка кергәнче, хәтта аны тәмамлаганчы Такташ төсе булып миңа җылысын бирде.

* * *

Август аеның ахырлары булса кирәк. Өйдә берәүнең иҗаты турында Такташ белән Гөлчәһрә өзек-өзек сүзләрдән бәхәскә күчтеләр. Тора-бара Такташның кәефе кырылды, чырае җитдиләнде, гадәти елмаюы сүнде, ярсуы йөзенә бәреп чыкты.

— Син бик простой нәрсәне аңламыйсың... ул минем школа! Ул минем школадан бара... Минем кадеремне илле елдан соң белерләр, аңлыйсыңмы, илле елдан соң!..

Бәхәс әкрен генә сүнде. Берничә минуттан урамга чыктылар. Уртак тел табып, бакыр бабай бакчасына (Державин бакчасына) табан юнәлделәр. Такташның әлеге сүзләре хәзергә кадәр түгелми-чәчелми көндәлегемдә саклана. Өлкән шагыйрьнең бу сүзләрен шахмат уйнаганда Шәйхи Маннурга да ишеттердем. «Ни өчен шулай әйтте икән? Ул бит күптәннән кадерле». Аннары үзебезчә: «Гомер үткән саен татар әдәбияты үз Такташын сагыначак»,— дип нәтиҗә ясадык.

Бәлки кечкенә нәрсәдер. Әмма зур шәхес турында сөйләгәндә нәни детальнең дә әһәмияте бар. Такташ олыга да, кечегә дә бертигез карады. Бу олы дип баш имәде, кечкенә дип тәкәбберләнмәде. «Мәхәббәт тәүбәсе» басылып чыкты, шагыйрьнең күңеле көр, йөзе ачык. Зәңгәр күзләре уйнай. Аның кәефе яхшы чак иде. «Мин «Мәхәббәт тәүбәсе»н өч көндә язып бетердем»,— диде.

— Ничек инде, шундый зур поэманы өч көндә?

— Һәр шигырь минем башымда йөргән чакта языла. Өстәл артында мин кәгазьгә әзер материал төшерәм, сүзләрне алыштырам, куәтлерәк, нәфисрәк, образлырак сүзләр сайлыйм.

* * *

Чернышевский урамы. Такташ университетны үтеп, Гастрономический урамы чатына якынлашып килә. Өстендә җәйге пальтомы, плащмы, якасын күтәргән (көзгә якын һава иде), яланбаш. Кулында таягы юк (таяк аңа килешә иде). Култык астында фасонын югалта төшкән кара портфель. Әкрен атлый. Башын игән. Гүя дөньяның бөтен мәшәкатен үз җилкәсенә утырткан. Тирән уйга чумган. Күңелсез. Мин урдән күтәрелә идем, маңгайга маңгай бәрелешә яздык.

— Апаң белән аерылдык. Зур хата ясады. Үз кадерен үзе белмәде...— диде борчулы, моңсу йөз белән.

Бу хәбәр аяз көндә күк күкрәү иде. Күп вакыт үтми, Гөлчәһрә Такташның әтиәнисенә үкенү, сагыну һәм зур ялгышуы турында хат яза. Ләкин инде соң була.

**КАСЫЙМ ХӘМЗИН,**

Ленинград.

# ТӨСЛЕ МОҢ

*София, Берлин, Монреаль, Вашингтон, Хьюстон, Милан, Гавана — бу соңгы елларда Казан авиация институты студентлары «Прометей» конструкторлык бюросының төсле музыка җайланмалары куелган күргәзмәләренең тулы булмаган географиясе. СССР Халык Казанышлары күргәзмәсендә «Прометей»чылар карамагына бөтен заллар бирелде. Анда алар төсле концертлар куйдылар. Ул концертларда зал буйлап хәрәкәт итүче авазларга корылган музыка сеанслары үткәрелде, көнкүреш автомат җайланмалары күрсәтелде. СКБның «күкрәгендә» СССР Халык Казанышлары күргәзмәсе медальләре генә дә — 35. СССР Югары уку йортлары Министрлыгының «Иң яхшы студентларның фәнни эше өчен» медале — 5, ВЛКСМ Үзәк Комитеты, ДОСААФ, фәнни-техник җәмгыятьнең уннарча Почет Дипломнары, 1980 елны СКБ Татарстан комсомолының Муса Җәлил исемендәге премиясенә лаек булды. Болар «Прометей» эшчәнлегенең тышкы дәрәҗәләре. Алар артында егерме елдан артык дәвам иткән киеренке хезмәт ята. «Прометей» СКБсы җитәкчесе, философия фәннәре кандидаты Б. М. Галиев мәкаләсе СКБ экспериментлары, бу проблемаларның бездә һәм чит илләрдә торышына һәм яңа төр сәнгатьнең тарихына, алгы көннәренә багышлана.*

Безнең гасыр башында «Прометей» дигән төсле музыка әсәрен язган рус композиторы А. Н. Скрябин дөньяны бөтенләй яңартып кору турында хыялланган. Аның фикеренчә, бу хәл социаль көчләр нәтиҗәсендә түгел, ә сәнгатьнең бик зур активлыгы аркасында хәл кылынырга тиеш була. Бу очракта сәнгать, гадәттәге төшенчәсендә калмыйча, бөтен кешелекнең гомум катнашында, рампасыз һәм рамкасыз, башкаручыга һәм иҗатчыга аерылмаган хәлдә күз алдында тотыла. Сәнгатьтә музыка, сүз, бию, драма, төс — бөтенесе бергә кушыла, имеш...

Әлбәттә, бу бөек, якты фикер, әмма хыялый фикер була. Гомум бәйрәм нечкә генә дирижер чыбыгы әмере белән килергә тиеш дип ялгышу иде бу. Бәлки, Скрябинның «һәркем өчен» сәнгать әсәре турындагы уйлануылары да хыялый гына булгандыр. Аныңча төс органнары чыгарган балкышлар чын кояш баешлары һәм яшен чарпылышлары белән кушылырга, ә зал ролен күк гөмбәзе уйнарга, хәрәкәтне сүз дәвам иттерергә, күк күкрәүләре хәрәкәтчән төсләр архитектурасы белән җайлашып яңгырарга, төсле линияләр бәйләме музыка партитурасы тукымасына полифоник рәвештә үрелергә тиеш була. Әле, гомумән дә, сәнгатьне бөтен җир йөзенә трансляцияләү реаль эшме соң ул?

Скрябин хыялларына тормыш төзәтмәләр кертте кертүен. Әмма бүген без моны реаль эш дип тә әйтә алабыз. Инде хәзер үк без ерак араларга тавыш һәм сурәт тапшыру заманында яшибез. «Радио кешеләрне бер җан итеп берләштерү, даими рәвештә рухи бергәлек дулкынына куярга тырышкан храмнар бурычын хәл кылды»,— дип радиолаштыру таңында ук хәйран калып язган иде шагыйрь Велемир Хлебников. Телевидение мөмкинлекләрен белгән булса, нәрсә дияр иде икән ул?

Хәзер төрле шәһәрләрдә бер-бер артлы төсле музыка концертлары бирүче иҗади оешмалар барлыкка килә (Казанда — «Прометей»—Студентларның Конструкторлык Бюросы (СКБ), Харьковта, Мәскәүдә — «Россия» һәм Октябрьский төсле музыка заллары). Икенче бер зур шагыйрь Валерий Брюсовның да алдан күреп әйткән сүзләре тормышка аша. «Яңа сәнгатьләр тууы мөмкин,— дип язган иде ул.— Мин ишетүгә корылган сәнгать кебек үк күз өчен дә сәнгать килер дип хыял итәм. Анда сурәт, төс һәм ут бергә сыешачак. Тойгылар хәзергә караганда бүтәнрәк чаралар белән биреләчәк». Соңгы елларда тәҗрибә тәртибендә генә булса да төсле музыка фильмнары төшерелә башлады. Аларда кино техникасы белән «төсле авазлар сәнгате» бурычлары хәл ителә. Мәсәлән, «Прометей», «Мәңгелек

хәрәкәт», «Нәни триптих», «Космик соната» — болары Казанда, «Музыка һәм төс» дигән фильм А. П. Довженко исемендәге Киев киностудиясендә эшләнде.

1970 елда Казанда ачык һавада илдә беренче буларак, «Аваз һәм яктылык» дигән театрлаштырылган тамаша күрсәтелде. 1975 елда Сәмәркандта даими эшли торган шундый комплекс булдырылды. Монда тамашачы тылсым сеансында катнашкандай була. Төн уртасында күк авазлары яңгырый башлый. Үткән заман шомнары, кыштырдаулар, кайчандыр бу ташлар, диварлар ишеткән сүзләр яңгырый. Үткән дәверләр авазларын кеше идарә итә торган музыка һәм төсләр озата килә.

Яктылык архитектурасы төнге шәһәрләрнең йөзен үзгәртә. Алар самолеттан караганда җемелдәп торучы тылсымлы паласны хәтерләтәләр. Ә яңа архитектураны гомумән яктылыктан аерып алып күз алдына китерүе кыен. Яктылык архитектурасының мөстәкыйль элементлары булып төрле хәрәкәтчән яктылык таблолары һәм гадәти (инде гадәти!) урам рекламалары, төсле музыкаль фонтаннар (болар хәзер СССРда дистәләрчә — алар Ереванда, Пятигорскийда, Мәскәүдә, Днепропетровскида) тора. Казандагы яшьләр үзәге янында да төсле музыка фонтаны булдыру планлаштырыла.

«Көнкүреш» төсле музыкасы җайланмалары хәзер иң киң таралышта, чөнки алар эстетик кына түгел, утилитар функция дә үтиләр. Алар зур булмаган интерьерларны бизәүче яктылык музыкасы җайланмалары. Хәзер безнең илнең кайбер заводлары андый җайланмаларны өйләр бизәү өчен дә чыгара башлады. Моңа шулай ук эшнең бертөрлелегеннән ялыгуны ала торган «функциональ» төсле музыка җайланмалары да керә (күз һәм колак гимнастикасы). Болар үзләренә күрә И. Ефремовның «Андромеда томанлыгы» повестендагы идеяне гәүдәләндерүче «төсле музыка индикаторлары» дигән нәрсәләр. И. Ефремовта төсле музыка космик корабль белән идарә итүченең информациягә «сусавын» басып кына калмый, ә бәлки үзенең «холкы» белән авария якынаюын да алдан кисәтеп тора. Язучының бу идеясе, мәгаен, ул әйткәнгә караганда, иртәрәк тә тормышка ашар, мең ел үткәнне көтеп тә тормас. Космонавт Г. Шонин үзенең күптән түгел басылып чыккан «Иң беренчеләр» дигән китабында болай искә ала: «Сергей Павлович Королев яктылык музыкасы идеясенә бик игътибарлы булды. Һәм ул һәр космик аппарат бортында «төсханә» булырга тиеш дип саный иде. Аның фикеренчә, ул космонавтларның эшләү сәләтен стимуллаштырырга, аларның рухи таләпләрен канәгатьләндерергә, рәхәт ял итәргә булышырга тиеш иде...» (Шуңа охшашлы приборлар «җирдәге» хаҗәтләр өчен сәф экспериментальпланда «Прометей» СКБсында уйланыла да инде.) Идарә ителә торган тавыш, тыңлаучан ялкын синтезыннан файдаланучы сәнгать жанрларын санап бетергесез...

Төсле музыканың «үз сүзе» нәрсәдән гыйбарәт соң? Аның кай ягы башка сәнгатьләр белән бәйләнгән һәм нәрсәсе белән аерылып тора? Әйе, ул музыкага якын. Чөнки төсле сурәтләр вакыт ягыннан музыка логикасы һәм музыкаль форма кануннары нигезендә үсәләр. (Скрябин моны аңлаган, әмма «Прометей»ның яктылык партиясен ул төс белән чикли, ә рәссам булмагач, ул төстән катлаулы формалар оештыра алмый.) Әйе, төсле музыка рәсем сәнгате белән дә бәйләнгән, чөнки яңгыраешлар белән бергә, ул катлаулы буяулардан да файдалана. Ни өчен Чюрленис «Соната»ларында, Кандинский — «Импровизацияләр»ендә рәсем композицияләрен «музыкаль» оештыруда камиллеккә ирешкәннәр? Әмма бу урында «музыкаль» сүзе буяулар һәм сурәтләр хәрәкәтсез булганлыктан гына куш җәяләр эченә алына.

Димәк ки, музыкантлар яктылык-төс сурәтләрен вакыт ягыннан, ә рәссамнар — киңлектә, экран яссылыгында катлаулы оештыруның зарурлыгын аңлаганнар. Төсле музыкада бу тенденцияләр берләшә! Ул ишетә-күрә торган, киңлек-вакыт сәнгате булып тора. Бу яктан ул кинематограф белән дә охшаш, ул да бит колак белән дә, күз белән дә бер үк вакытта кабул ителә. Тик кино конкрет сурәтләр һәм, нигездә, конкрет авазлардан файдалана. Шуңа күрә ул сынлы сәнгатькә карый. Ә төсле моң материалы булып гайре табигый авазлар (музыка) һәм шулай ук предметсыз төсле формалар тора, шуңлыктан ул тәэсир сәнгатьләре төркеменә карый. Югарыда телгә алынган кайбер сыйфатлар яңа сәнгатьнең үзенчәлекләрен, тегәлрәге, ул файдалана торган чараларны характерлый. Ләкин алар да «Нәрсә соң ул төсле музыка?» дигән сүзне аңлата алмый әле.

Сәнгать ул, мәгълүм булганча, нәфис сурәтләр аша чынбарлыкны чагылдыру һәм танып-белүнең үзенчәлекле формасы. Кешенең музыканы инде күптән күрә

белгәнлеген искә төшереп үтик. Әйтик, тамашачы аны биюдә, музыкаль пластика сәнгатендә дә күргән.

«Прометей» СКБсының соңгы эшләре төсле электрон нур трубкаларының яктылык музыкасын тормышка ашыру өчен зур мөмкинлекләре барлыгын күрсәтте. Ә бу техниканы күптән түгел совет галимнәре иҗат иткән лазерлы кинескоп белән бергә кушсаң, ничек булыр иде икән? Телевизион төсле музыкаль сурәтне гаять зур экраннарда күрсәтергә мөмкинлек туар иде. ФТР шагыйрьләр һәм фантаст язучылар прогнозларын узып, хыялланa белергә әйрәтте.

Хыял тормышка аша, Тбилисида, Грузия фәннәр академиясенең бер фәнни-тикшеренү институтында, калын катламлы тасмаларда күләмле голограммалар булдырдылар. Лазерлар тудырган бу сыннарны һәр яктан карарга мөмкин. Голографик фильмнарның хыял дөньясыннан бүген инде чынбарлыкка әйләнгәнен исәптә тотканда, реаль объектларны гына түгел, ә күләмле төсле музыка композицияләрен күрсәтә алырлык голограмма фильмнары турында да уйланырга мөмкин. Моннан берничә ел элек чыккан «XXI гасырдан репортаж» дигән китапта күренекле совет галиме, югары ешлыклар техникасы белгече Г. И. Бабатның тәҗрибәләре турында язылa. Бу галим, заманында төнлә зур шәһәрләр өстендә куәтле югары ешлык генераторлары антенналары нурларын бер ноктага җыеп, гаять көчле җегәрлекләр булдыру, шуның белән «ясалма кояш» кабызу идеясен тәкъдим иткән иде. Тәҗрибәләрен ул камалыштагы Ленинградта дәвам иттерә һәм бу хакта көндәлегенә болай дип яза: «Ниһаять, приборның металл таҗ яфраклары өстендә дерелдәп торучы электр ялкыны кабынды. Ул әле генә ачылган, балкып торган чәчәккә охшаган иде». Галим лабораториясен кечкенә генә кояш яктыртып ала һәм ул уйлап табучының йөрәгендә мәңгегә кала. Г. И. Бабат җайланмага гадәти «тигез» ток түгел, ә модульләнгән ток тоташтыра. Гадирәк итеп әйтсәк, ул аны эшләп торучы радиоалгыч аша җибәрә. Электр тогы тибрәнешләренә буйсынып, ялкын әле зурая, әле кечерәя, дерелди. Ул гүя мембранага әйләнә. «Кояшларың белән кил син миңа»,— дип җырлагандыр бәлкем ялкын. Ә уйлап табучы аннан күзен дә алмыйча сихерләнеп тыңлый. «Җырчы ялкын», «җырчы кояш»... Хәзер инде Чюрленисның «Әкият» дигән картинасын искә төшерик: киң күңелле корольләр кояш булып балкучы шәһәрне кулларына күтәргәннәр. Аның «Дуслык» дигән икенче картинасын исегезгә төшерегез. Ябык йөз, алга сузылган нечкә генә беләкле куллар. Ике картинаны бергә кушыйк,— мәһабәт һәйкәлне фараз итик. Биек постаментта зифа сынлы Прометей, аның кулында, бармак таҗлары эчендә «җырчы кояш» балкый, ул электрон аккордлары уңаена тибрәнә...

...Марста алма үсәрме, юкмы — анысы билгесез. Әмма айдагы тораклaрның гөмбәзләре, Марстагы фәнни базалар интерьерларында видеомагнитофон уйный башлар, һәм, экран җир шары кешесенә тантаналы яктылык — төсләр аккорды белән җавап бирер. Бу иртәгәге көн. Тик, билгеле булганча, киләчәк бит бүген башлана. Ул меңләгән радиотехника һәм студентлар түгәрәкләрендә, үзешчән сәнгать коллективларында башлана, өлгерә килә. Яктыртучы авазлар сәнгате — яшь сәнгать. Аның язмышы да яшьләр кулында.

**БУЛАТ ГАЛИЕВ.**

Бу проблема белән ныграк кызыксынган укучылар өчен түбәндәге китаплар бар:

1. Б. Галеев. «Светомузыка: становление и сущность нового искусства». Казань, 1976.
2. Б. Галеев. «Поющая радуга». Казань, 1980.
3. И. Ванечкина, Б. Галеев. «Поэма огня». Казань, 1981.
4. Б. Галеев. «Содружество чувств и синтез искусств». Москва, 1982.

# ӘДӘБИЯТ ҺӘМ СӘНГАТЬ ЯҢАЛЫКЛАРЫ

## ЯЗУЧЫЛАР СОЮЗЫ ПАРТИЯ ОЕШМАСЫНДА

24 майда язучыларның ачык партия җыелышында «Казан утлары» журналының проза бүлеге отчеты булды. Журналның проза бүлеге редакторы Марсель Галиев доклад белән чыкты. Бүлекнең эше, журналда басылган проза әсәрләре турында фикер алышуларда ТАССР Язучылар союзы идарәсе председателе Г. Ахунов, язучылар Г. Бәширов, Б. Камалов, «Казан утлары» журналының баш редакторы Р. Харис, тәнкыйтьчеләр Р. Мостафин, Ф. Миңнуллин, Татарстан язучылар союзының партия оешмасы секретаре Р. Мөхәммәдиев һ. б. чыгыш ясадылар. «Казан утлары» журналының проза бүлеге эшенә нигездә уңай бәя бирелде.

## ЯШЬЛӘР ИҖАТЫ — ҮЗӘКТӘ

31 майдан 2 июньгә кадәр Брежнев шәһәрендә РСФСР язучылар союзының яшь әдәбиятчылар белән эшләү советы күчмә утырышы булды. Автомобиль төзүчеләр каласы һәм Кама буе төбәге яшь әдәбиятчылар иҗатын тикшерү өчен Мәскәү, Ленинград һәм Казаннан танылган язучылар килде. Күчмә утырышта катнашучы кунакларны КПССның Брежнев шәһәр комитетының беренче секретаре Р. К. Беляев тәбрикләде һәм аларга яңа шәһәрдә культура үсеше, тәрбия эшендә әдәбият һәм сәнгатьнең мөһим роль уйнавы турында сөйләде, шәһәрнең социаль-экономик тормышы белән таныштырды.

Яшь әдәбиятчылар белән эшләү советының пленар утырышында Мәскәү делегациясе җитәкчесе, РСФСР язучылар союзы идарәсе секретаре Михаил Шевченко, ТАССР язучылар союзы идарәсе председателе Гариф Ахунов, Брежнев шәһәре язучылар оешмасының җаваплы секретаре Разил Вәлиев чыгыш ясады.

Проза һәм поэзия жанрлары буенча семинарларда яшь авторларның кульязмалары тикшерелде. Күчмә утырыш дәвам иткән көннәрдә кичен «Гренада» кинотеатрында һәм сәнгать училищесында кунаклар, яшь язучылар катнашында әдәби кичәләр үткәрелде. Яшьләр иҗатын тикшерүгә багышланган форум 4 июньгә кадәр Россия Федерациясе әдәбияты көннәре рәвешендә дәвам иттерелде. Күчмә утырыш эшендә КПССның Татарстан өлкә комитеты культура бүлеге мөдире М. М. Мусин катнашты.

## ФӘННИ КОНФЕРЕНЦИЯ

Май аенда Казанда «Әдәбиятта һәм сәнгатьтә сәнгатьчәлек критериена комплекслы караш» дигән фәнни конференция булып узды. Аны СССР Фәннәр академиясе каршындагы бөтендөнья культурасы тарихын тикшерүче фәнни советның художестволы иҗатны комплекслы өйрәнү комиссиясенең Казан база группасы, Татарстан язучылар союзы һәм Казан дәүләт университеты оештырды. Конференцияне Казан университетының фәнни эшләр буенча проректоры Ш. Т. Хәбибуллин ачты. Конференциядә Киев, Ереван, Казан, Свердловск, Чимкент, Днепропетровск, Тарту, Симферополь, Ижевск шәһәрләреннән килгән галимнәр һәм язучылар чыгыш ясадылар.

## ТАТАР ДӘҮЛӘТ ДРАМА ҺӘМ КОМЕДИЯ ТЕАТРЫ ТАШКЕНТТА

5—30 майда Үзбәкстан башкаласы Ташкентта Татар дәүләт драма һәм комедия театрының гастрольләре булып узды.

Театрның репертуарында татар драматургларының әсәрләре белән бергә күп милләтле совет драматургиясе үрнәкләре дә зур урын били. Ташкент шәһәренең «Яшь гвардия» театры бинасында башланган гастрольләрнең маршруты көннән-көн киңәя барды. Гөлстанда, Һавастта, Янгиерда, Сәмаркандта, Болыңгырда, Кәттәкурганда, Пахтакорда күрсәтелгән спектакльләрне тамашачылар алкышлап каршылады.

## ТАТАРСТАН СӘНГАТЬ ОСТАЛАРЫ ЛЕНИНГРАДТА

Бөек Җиңүнең 38 еллыгын билгеләп үткән көннәрдә Татарстан сәнгать осталары герой шәһәр Ленинградның иң яхшы Культура сарайларында чыгыш ясадылар. Концертларда совет халкының батырлыгы, аның тыныч тормыштагы фидакарьлеге темалары киң чагылыш тапты. Бер атнага якын сузылган концертлар һәркайда зур уңыш белән үтте.

Концертларда республиканың танылган сәнгать осталары — РСФСРның халык артисты Айрат Арсланов, Татарстанның халык артистлары Әлфия Афзалова, Вафирә Гыйззәтуллина, Гали Ильясов, Татарстанның атказанган артистлары Зиннур Нурмөхәммәтов, Римма Ибраһимова һәм яшьләр дә чыгыш ясады.

## КОЛ ГАЛИ ТУРЫНДА «ЮНЕСКО»

Халыкара «Юнеско» оешмасының «Новости» («Яңалыклар») информацион бюллетене үзенең быелгы 5 нче санында төрки-татар язма әдәбиятының күренекле вәкилләреннән берсе, Болгар чоры шагыйре Кол Гали иҗатына багышланган мәкалә урнаштырган. «Сигез гасыр халык күңелендә» дип исемләнгән әлеге мәкаләнең авторы — В. И. Ульянов-Ленин исемендәге Казан дәүләт университеты укытучысы тарих фәннәре докторы Миркасыйм Госманов.

Сигез гасыр буе әти-бабаларыбыз бик яратып укыган «Йосыф китабы» (атама вариантлары — «Йосыф вә Зөләйха», «Йосыф кыйссасы») авторының кыяфәт-сурәтен рәссам Тавил Хаҗиәхмәтов ясаган. Биредә шагыйрьнең Болгар шәһәре һәм Идел фонында иҗат итеп утырган моменты алынган.

«Новости» информацион бюллетене рус теленнән башка тагын инглиз, немец, француз, испан, гарәп, һинд, япон һ. б. телләрдә басылып таратыла.

## БАШКОРТСТАНДА ФАТИХ КӘРИМ КӨННӘРЕ

Татар совет шагыйре Фатих Кәримнең туган җирендә — Башкортстанның Бишбүләк районы Ает авылында шигърият бәйрәме уздыру матур традициягә әверелде. Ул бәйрәм быел да июнь аенда уздырылды. Башкортстан язучылар союзы чакыруы буенча анда Казаннан татар шагыйрьләре Ренат Харис, Рәдиф Гатауллин булдылар. Аетта шагыйрьнең музей-йортында чыгыш ясап, Р. Харис музейга китаплар бүләк итте. Ает авылы клубында башкорт шагыйрьләре Р. Бикбаев, Ә. Игебаев белән бергә уздырылган әдәби кичәдә шагыйрьләребез чыгыш ясап, татар шигърияте турында сөйләделәр, яңа шигырьләрен укыдылар. Икенче көнне Татарстаннан килгән кунакларны КПССның Башкортстан өлкә комитетының идеология буенча секретаре иптәш Т. И. Ахунҗанов кабул итте.

## «КЫЙССАИ ЙОСЫФ»: ӨЙРӘНҮ ТАРИХЫ, КАЙБЕР НӘТИҖӘЛӘР ҺӘМ ПРОБЛЕМАЛАР

Гасырлар дәвамында гомумшәрык мәдәнияту үсешендә тирән эз калдырган, халкыбыз өчен гүзәллек, мәхәббәт һәм тугрылык китабы булып килгән мәшһүр «Кыйссаи Йосыф» әсәре кульязма китапларда һәм телдән-телгә күчеп килүче риваятьләрдә яшәп, меңнәрчә күңелләрне яктырта, әдәбиятыбыз тарихының олылыгын раслый.

11 майда Татарстан язучылар союзының әдәби тәнкыйть секциясендә Кол Галинең шушы үлемсез поэмасы язылуга 750 ел тулу уңае белән галимнәр һәм язучыларның фикер алышуы уздырылды. Сөйләшүдә профессор Х. Госман, филология фәннәре докторы Н. Юзиев, язучы һәм галим Н. Исәнбәт, ТАССР язучылар союзы председателе урынбасарлары Ф. Миңнуллин һәм И. Юзеев, «Казан утлары» журналының баш редакторы Р. Харис, филология фәннәре кандидатлары Ш. Абилов, Ф. Фасиев, Н. Хисамов, Ф. Мусин һ. б. иптәшләр катнашты.

Н. Хисамов «Кыйссаи Йосыф» поэмасын әдәби һәм дини чыганаклары белән чагыштырып өйрәнүнең беренче нәтиҗәләре хакында сөйләде, әсәрнең идея проблематикасы, образлар системасындагы төрки әдәбият традицияләре белән уртак һәм үзенчәлекле якларга басым ясады. Докладчы «Кыйссаи Йосыф» әсәренең татар халкының рухи тормышындагы, культура тарихындагы, гомумтөрки һәм дөнья әдәбияты контекстындагы урыны турында фикерләре белән уртаклашты. Бәкер Яфаров, Җәвад Алмаз, Габдрахман Таһирҗанов, Хатип Госман, Шакир Абилов, Фазыл Фасиев хезмәтләренең әһәмиятен билгеләп, поэманы өйрәнү юнәлешендәге яңа бурычларга һәм проблемаларга игътибарын юнәлтте.

— Кол Гали поэмасының татар әдәбияты үсешенә ясаган тәэсирен, бигрәк тә аның хәзерге поэзиядәге традицияләрен тагын да әтрафлырак һәм тирән итеп ачкан хезмәтләр кирәк. Әсәрнең татар халык иҗаты контекстындагы яшәеше һәм эзләре бербөтен итеп күз алдына бастырылырга тиеш. Аннан халыкта яшәгән вариантлары һәм көйләре фәнни яктыртуны сорый. Әсәрне пропагандалау, көйләрен яңгырату, беренче чиратта балалар һәм яшьләр өчен текстын әзерләү — шулай ук бу юлдагы мөһим бурычларның берсе,— диде Н. Хисамов.— Бер хакыйкатьне, тарихи-фәнни таләпне истән чыгармыйк: «Кыйссаи Йосыф» поэмасы татар әдәбиятының кыйммәтле ядкаре булу белән бергә, язма культуралары борынгыдан килә торган төрки халыкларның уртак мирасы итеп тә бәяләнергә тиеш. Чөнки аның йогынтысы, кече, тарихи-әдәби әһәмияте милли чикләрдән киңрәк.

«Кыйссаи Йосыф» поэмасының татар халкының рухи культурасына, сәнгатьчә фикерләвенә һәм әдәбият тарихына тирән тәэсире турындагы сүзне дәвам итеп, Ш. Абилов аның шигъри үлчәме, сурәтләү алымнары белән халык авыз иҗатына якынлыгын искә төшерде.

— «Кыйссаи Йосыф»ның шигъри үлчәмендә һәм формасында (ягъни баштагы өч юлның рифмалашып килүе, ә дүртенче юлның «имди» рәдифе белән тәгәлләнүе рәвешендә) язылган әсәрләрне татарлардан башка төрки халыкларның поэзия тарихлары белми. Татар халкының «Кәҗә бәете», «Уяну бәете», «Мужик бәете» кебек авыз иҗаты әсәрләре дә Кол Гали поэмасының шигъри төзелеше үрнәгендә чыгарылганнар. Гасырлар дәвамында поэзиябез өчен гадәти норма, өлге булган «Кыйссаи Йосыф» нәзымына нәреп, аның калыбында иҗат ителгән иң борынгы әсәрләрнең берсе — XIV йөзләргә караган «Авык кыйссасы» (авык — ывык — кыр кәҗәсенең борынгы исеме):

**Авык әюр: тагдин тагга чыкар ирдем,**
**Төрлүк-төрлүк сачәкләрне утлар ирдем,**

**Кәчә кәлүп балаларым имезүр ирдем,**
**Бу көн кәлүп, бу бәлага төшдем имди.**

«Авык кыйссасы», «Кыйссаи Йосыф» поэмасы кебек үк, бары тик татарлар яшәгән урыннарда гына таралган.

Кол Галидән соң килгән һәр чор татар шагыйрьләре «Кыйссаи Йосыф» әсәрен яхшы белгәннәр, аны үзләренә үрнәк итеп алганнар. XVII йөз ахыры — XVIII йөз башларында яшәгән, хәзергә исеме билгесез татар шагыйре «Ишан Хуҗа хәзрәтләренә мәдхия» дигән поэмасы тулысынча «Кыйссаи Йосыф» нәзымында язган, XVII йөз шагыйре Мәүла Колый «Кыйссаи Йосыф»тан бик актив, иҗади файдаланган. Утыз Имәни «Ишаннар һәм суфилар» поэмасын (1789), Г. Кандалый «Нәзмы Йосыф» (1840) әсәрен әлеге поэма үрнәгендә иҗат иткәннәр. XX йөз башы поэзиясенә күз салсак, үзенчәлекле мисаллар тагын да күбрәк. Г. Тукайның «Русларга бер сүз», «Яз галәмәтләре», «Кечкенә генә бер көйле хикәя» кебек шигырьләрен генә искә төшерик. 1905—1907 елларда Кол гали әсәренең шигъри өлгесендә патша тәртипләренең череклеген фаш иткән сатирик һәм революцион рухлы шигырьләр дөньяга килә. 1906 елны «Карчыга» журналында басылган «Күз яшьләре» исемле шигырь әнә шундыйлардан:

**...Күбәйде һәр җирдә асылу һәм атылу,**
**Хисабы юк яндырулар һәм ватылу,**
**Мода булды сары алтынга сатылу,**
**Болар бар да — Столыпин ысулы имди.**
**Карангы төн никадәр озын булмасын,**
**Җир йөзе золым илә һәм тулмасын,**
**Арсланнар Себергә күпме куылмасын,**
**Ниһаять, бер таң атмый калмас имди.**

Бу — «Кыйссаи Йосыф»ның, аның шигъри төзелешенең гаять халыклашканлыгы турында сөйләүче мисалларның берсе. Кулына каләм алган һәр татар кешесенең уенда, күңелендә әлеге «кыйсса»ның музыкаль аһәңе, сәнгатьчә сурәтләре булган. Шушы дулкынлану, шушы аһәң аны иҗатка рухландырган. Кол Гали әсәренең олы традицияләре бүгенге поэзиягә дә актив тәэсир итә»,— ди Ш. Абилов.

Кульязмалар нигезендә «Кыйссаи Йосыф» поэмасының өйрәнелү дәрәҗәсенә бәя биреп, Ф. Фасиев шушы юнәлештәге кайбер ялгыш фаразлар һәм дәлилсез нәтиҗәләр булуын да искәртте.

— Әсәрнең исемен һич сәбәпсез «Йосыф һәм Зөләйха» рәвешендә үзгәртеп, без аның төп фикри акцентын бозабыз һәм бөтән халыкларның «Йосыф — Зөләйха»лары белән бутауга урын калдырабыз. Ә бит нәкъ шушы исем һәм сюжет охшашлыгы гади укучыны гына түгел, танылган филологларны да ялгыш юлга кертеп җибәргәли. Хәлбуки күчмә сюжет — бер нәрсә, ә шул сюжет нигезендә иҗат ителгән аерым автор әсәре — бөтенләй икенче нәрсә: ул мәгълүм җирлеге, чоры, халкы, дәүләте, язма теле һәм поэтик традицияләре булган конкрет язма әдәбиятка карый,— диде Ф. Фасиев.— Сюжет уртаклыгы гына бу очракта гомумилек «ярлыгы» тагу өчен һич тә нигез була алмый. Төрек, төрекмән, үзбәк, уйгур, әзербайҗаннарның һәркайсында үз «Йосыф — Зөләйха»лары булуы, авторлары да үзҗирлекле булып, кульязма нөсхәләре, китаплары һәм әдәби традицияләре шуннан табылуы әлеге фикерне куәтләп кенә тора.

Әсәрнең төп чыганаклары — кульязма нөсхәләре кайдан табыла соң? Ф. Фасиев бу сорауга җавап рәвешендә түбәндәге таблицаны тәкъдим итте.

— Төрле төбәкләрдә яшәгән татарлар арасыннан әлегә 161 нөсхә табылган,— диде ул.— Шуларның 115 данәсе Татарстаннан... Башка төбәкләр буенча мондый картина: Астрахань — 4, Башкортстан АССР — 9, Бәхтияр авылы (Волгоград өлкәсе) — 1, Горький өлкәсе (Сергач татарлары) — 6, Касыйм шәһәре (Рязань өлкәсе) — 2, Кировобад (Әзербайҗан ССР) — 1, Оренбург өлкәсе — 2, Пенза өлкәсе — 1, Пермь өлкәсе — 11, Свердловск өлкәсе — 3, Төмән өлкәсе — 3, Ульяновск өлкәсе — 1, Чиләбе өлкәсе (Троицк шәһәре) — 1, табылган урыны төгәл билгесез — 2. Шулардан Кировобад кульязмасы, мәсәлән, Идел буеннан күчеп килгән татар гаиләсе белән бәйле, Астраханьдагы кульязмаларның икесе Татарстанның Мәңгәр авылында күчерелгән. Күпчелек нөсхәләр XVIII—XIX йөзләргә карый.

Ф. Фасиев кульязма нөсхәләрне җыюда актив ярдәм күрсәткән галимнәрне, язучыларны һәм энтузиастларны рәхмәт хисе белән искә алды.

— Әлбәттә, кульязмаларның бер өлеше әлегә аерым кулларда, билгесез чормаларда саклана. Кульязма мирас — бөтен халык байлыгы һәм аның җуелмавы, бүген дә халыкка, фәнгә, әдәбиятка хезмәт итүе өчен барыбыз да җаваплы,— диде ул.— «Кыйссаи Йосыф» — әдәби культурабыз һәм язма телебезнең кыйммәтле җәүһәрләреннән берсе, ул халкыбызның университеты, сәнгате, әдәп-әхлак энциклопедиясе хезмәтен гасырлар буенча үтәп килгән һәм хәзер дә аңа хезмәт итә. Әсәрнең фәнни тексты Татарстан китап нәшриятында басылып чыгу Кол Гали шәхесен өйрәнү, аның үлемсез поэмасын төрле яктан тикшерү, кульязма чыганакларын туплауны дәвам итү юлында яңа бер адым һәм куәтле этәргеч булыр дип ышанабыз.

Х. Госман поэманың сюжет үзенчәлекләре, шигырь төзелеше, фәлсәфи эчтәлегенә бәйле күзәтүләре белән уртаклашты.

Н. Исәнбәт, Н. Юзиев, М. Гайнетдинов һәм Р. Даутов «Кыйссаи Йосыф» әсәрен төрле аспектларда өйрәнү бурычларына, Кол Галинең 800 еллыгын һәм аның үлемсез поэмасы язылуга 750 ел тулу датасын билгеләп үтү мәсьәләләренә тукталдылар.

# ШИШКИН «АЛАН»Ы

Күренекле якташыбыз Иван Иванович Шишкинның Татарстан сынлы сәнгать музеендагы картиналары арасында «Алан» исемлесе аерым әһәмияткә ия. Аның үз тарихы бар. Бу зур булмаган пейзажны рәссам гомеренең соңгы елларында иҗат итә. Казанлылар аны беренче мәртәбә 1898 елда Казан сәнгать мәктәбе бинасында оештырылган күргәзмәдә күрәләр. Шул ук күргәзмәдә художникның «Дача янында» дигән хезмәте дә була. Пейзажларның икесен дә тамашачылар зур игътибар белән, бик яратып карыйлар. Шул ук елда фән-промышленность музее советында бу әсәрләрне сатып алу өчен рөхсәт сорау турында сүз бара. Һәм менә 8 мартта Казанга мондый телеграмма килә: «Сезнең тәкъдимегез белән бик теләп килешәм — Шишкин». Мондый шатлыклы хәбәрне укыган кешеләрнең берсе дә нәкъ шушы көндә зур художникның йөрәге тибүдән туктавын белми әле. Чөнки ул кайгылы хәбәр Казанга соңрак килеп җитә. Шулай итеп, әлеге пейзажлар буенча килешү талантлы якташыбызның соңгы телеграммасы була.

Вакытлар узу белән, бу ике әсәрнең берсе — «Дача янында» дигәне Шишкинның Алабуга шәһәрендәге музей-йортына күчерелә. Картина бу музейның сынлы сәнгать залын бизәп тора.

Гомеренең соңгы елларында Шишкин Петербург янындагы Преображенск станциясендә яши. Һәм аның шунда 1897 елда иҗат иткән «Алан» исемле картинасы, менә дигән останың хушлашу бүләге булып, бөтенләйгә Казанда кала.

Типография ысулы белән ясалган рәсемнәрнең кайсын гына алма, аларның барысы да, сурәтнең үзе белән чагыштырып караганда, бик күпне югалта. Бу хакыйкать бездәге пейзажларга да кагыла, билгеле. Төсләрнең гаҗәеп гармониясен рәссам табигатьтә күреп алган, яз нурлары балкып торган якты, аксыл-зәңгәр күкне пөхтә һәм нәфис итеп киндергә төшергән. Бу әсәрендә рәссам 1880 елларда башланган палитраны яктырту эшчәнлегенең иң югары ноктасына күтәрелә. Нәкъ шул вакытта Шишкин хезмәтләренә кояш яктысы һәм һава иркенлеге килеп керә, ә буяулар үзгә бер сафлык белән үзләреннән-үзләре яктырта башлыйлар. «Алан»ны тормыш һәм яз шатлыгына мәдхия дип атарга да мөмкин.

Инде менә 85 ел узып китте, музейда бөек якташыбызның күп кенә башка хезмәтләре барлыкка килде, ләкин «Алан» картинасы һаман элеккечә музей экспозициясен бизәп тора һәм тамашачыларның иң яраткан картиналарыннан берсе булып кала.

**В. ЧЕРНЫШЕВА,**
Татарстан сынлы сәнгать музееның бүлек мөдире.

●

**Тышлыкның дүртенче битендә:** Социалистик Хезмәт Герое, СССРның халык артисты, СССР Дәүләт премияләре лауреаты, композитор Нәҗип Җиһанов.

Рөстәм Мансуров слайдлары.

**Таткниготоргның Казандагы 1 нче китап кибетендә түбәндәге шигырь китаплары бар:**

Равил Фәйзуллин. **Кошлар юлы.**
Илдар Юзеев. **Мәхәббәт китабы.**
Шәрәф Мөдәррис. **Дуслар күңеле.**
Марс Шабаев. **Көн арты көн.**
Сажидә Сөләйманова. **Сабыр канатлары.**
Зәки Нури. **Күңел яктысы.**
Нәби Дәүли. **Мин җирдә калам.**
Нури Арсланов. **Иделем-илем.**
Мостафа Ногман. **Акчарлаклар оча Иделдә.**
Әхмәт Ерикәй. **Ике йөз җыр.**
Әдип Маликов. **Туган як җиле.**
Сибгат Хәким. **Поэмалар.**
Рәшит Гәрәй. **Синдә калам.**
Шамил Маннапов. **Кайту.**
Дәрдмәнд. **Исә җилләр.**
Ренат Харис. **Замана эзләре.**

**Проза китаплары:**

Кави Нәҗми. **Сайланма әсәрләр, 4 томда, 1—2 том.**
Гариф Ахунов. **Сайланма әсәрләр, 4 томда, 1—2 том.**
Рафаэль Төхфәтуллин. **Сайланма әсәрләр, 2 томда, 1 том.**
Гомәр Бәширов. **Сайланма әсәрләр, 4 томда, 1—2 том.**
Адлер Тимергалин. **Кайтыр юллар.**
Газиз Мөхәммәтшин. **Без әле җирдә яшибез.**
Мостай Кәрим. **Озын-озак балачак.**
Гариф Галиев. **Без авылныкылар.**
Фатих Хөсни. **Утызынчы ел.**
Фаил Шәфигуллин. **Бәхет йолдызы астында.**
Рәфкать Кәрами. **Ашкыну.**
Фәнис Яруллин. **Һәркемнең үз сукмагы.**
Гадел Кутуй. **Илһам.**

**12 томлык татар халык иҗаты китапларыннан:**

Табышмаклар.
Мәзәкләр.
Әкиятләр, 1—2—3 том.
Йола һәм уен җырлары.
«Татар теленең аңлатмалы сүзлеге», 1—2—3 том.

**Бу китапларны почта аша алдырырга теләсәгез, заказларыгызны түбәндәге адрес белән җибәрегез:**

*420084, г. Казань-84, ул. Баумана, 19, магазин № 1, отдел «Книга-почтой».*

Бәясе 90 тиен.
Цена 90 коп.

Индекс 73210



**КАЗАН УТЛАРЫ**
**(ОГНИ КАЗАНИ)**

Ежемесячный литературно-художественный
и общественно-политический журнал
ОРГАН СОЮЗА ПИСАТЕЛЕЙ ТАТАРИИ
(на татарском языке)